фкать КәРәрами

Олы юл да сикәлтәле

Роман

Казан  Татарстан китап нәшрияты  2007

УДК 821.512.145-3
ББК 84 (2 Рос = Тат)-44
К95

Кәрами Р.К.
Олы юл да сикәлтәле: роман/ Рәфкать Кәрами. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 366 б. — 3000 д. — ISBN 978-5-298-01480-9

Үзен ир заты дип санаган һәр егет, вакыты җиткәч, яшьтәшләре белән бергә солдат шулпасы эчәргә, дары иснәргә, тәртипкә өйрәнергә, командирларның әмеренә берсүзсез буйсына белергә тиеш. Әлеге роман менә нәкъ шул хакта. Китап сөючеләрне ул битараф калдырмас.
Әсәрдә мәхәббәт маҗаралары да мавыктыргыч тасвирланган.

ISBN 978-5-298-01480-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Кәрами Р.К., 2007

# БЕРЕНЧЕ КИСӘК

## 1

Телефон шылтырады. Габделнур Галләмович, гадәтенчә, трубканы сул кулына алды да колагына куйды. Чөнки аның уң кулы һәрвакыт язу-сызу белән мәшгуль иде. Бүген дә ул, телефон шылтыраганда, өстәл өстендә яткан кәгазьләргә кул куя иде.

— Әйе.

Ерактан хатынының ягымлы тавышы ишетелде.

Алар телефоннан хәбәрләшкәндә беркайчан да исемнәрен әйтмиләр. Чөнки, озак еллар бер җан, бер тән булып яшәгән кешеләргә хас булганча, алар бер-берен тавышларыннан ук таныйлар иде.

— Тыңлыйм, — диде ире. — Әйт.

— Син төшке ашка кайтасыңмы?

— Кайтмаска уйлабрак тора идем. Ни булды?

Хатыны бераз гына тынып торды. Чөнки иренең талканы коры: эшенә шылтыратканны өнәми. Эш урынына килеп йөрү турында сүз дә булуы мөмкин түгел, ире ничә ел бу оешмада эшләп, хатыны аның кайда утырганын да белми. Хәер, әллә ни теләге дә юк. Сәбәбе — ире дә шулай. Кайберәүләр кебек, көненә әллә ничә тапкыр шылтыратып, ике көнгә бер янына килеп, борчып-бимазалап йөрми. Әгәр авыр әйбер күтәреп кайтасы булса гына... Анысы айда бер, кайда — бер генә. Эштә була торган Яңа ел каршылау, туган көн билгеләп үтү, пенсиягә озату кебек бәйрәм-мәҗлесләргә дә иренең бер мәртәбә дә килгәне юк. Әмма хатынына, барма, йөрмә, ике аягыңның берсен дә атламыйсың, дип тә әйткәне, тикмәгә теңкәсен корытканы юк. Кайчагында хатыны уйлап та куя: әллә бу бер дә көнләшми микән? Юктыр, көнләшәдер. Чөнки ул аны ярата, яратып өйләнде. Ләкин көнләшүен тышка чыгармый. Авызы тулы кан булса да төкермәскә өйрәнгән. Ул хатынына ышана. Үзенең беренче һәм бердәнбер икәнен яхшы белә. Яшь башлауларының тәүге көнендә үк бик каты кисәтеп тә куйды...

Аннары, байтак еллар бергә эшләгән хезмәттәшләр, бертуганнар сыман ук булмасалар да, бер гаилә әгъзалары кебек бер-беренә гадәтләнәләр: өстәл артында утырганда да, бию-танцыларда да тартынып-ятсынып тормыйлар. Ә берәр чит кеше кердеме, кемнең генә хатыны яки ире булуга карамастан, мәҗлеснең, күңел ачуның яме китә: артык сүз әйтүдән, хәрәкәт ясаудан тыела башлыйлар, ни генә эшләсәләр дә чит-ят кеше бу гамәлне өнәп бетермәс, гаеп итәр шикелле тоела. Гәрчә ул кайсысыныңдыр ире яки хатыны булса да, аны күбесе ишетеп, бер ише күреп белсә дә, барыбер күңелләре кабул итми — көтүгә чит мал килеп кушылгандай була. Күрәсең, иренең бу уй-фикерләрен дә сизә иде хатыны. Кыскасы, шактый ук үзенчәлекле, кырысрак холыклы иде Габделнур Галләмович.

Шулай да хатыны гозерен әйтергә батырчылык итте:

— Бүген соңгарак калып кайтам. Ашыгыч эш бирделәр. Ипи алмассыңмы дигән идем. Кичен әллә була, әллә юк.

— Ә кыз?
— Ул концертка бара.
— Яхшы. Ниндине? Ничәне?
— Караны...
— ... түгел, арыш ипие.
— Әйе. Берне.
— Ярар.

Икесе дә тынып калдылар: Габделнур Галләмович — хатыны тагын берәр йомыш кушмасмы дип, ә хәләл җефете — ире авызыннан берәр җылы сүз чыкмасмы дип.

Гудок ишетелгәч, Габделнур Галләмович трубканы куйды. Сәгатенә карады. Үзе кәгазьләргә кул куюын дәвам итте.

Ниһаять, бер ун минуттан, эшен төгәлләп, бүлмәсен бикләп, ул урамга чыкты.

Тышта эсселек — кырык булмаса да, утыз тугыз градус булыр. Күк йөзе зәп-зәңгәр, ник бер болыт әсәре күренсен. Машиналар узганда кайнар җил исә; агач яфраклары шәлперәйгән; аяк табаны асфальтка батып керә. Кыз-кыркынның изүе ачык, итәк кыска. Ир-атка җай чыкты: каерылып-каерылып карап калалар. Юкка гынамы күпчелек ир-атның муен таза...

Троллейбус тукталышында халык ничек тә түбә астына ышыкланырга, күләгәгә басарга тырыша. Ул хәтле халык кая сыеп бетсен?! Тәбәнәгрәкләр озын торыкларның артына басу ягын карый.

Бәхетенә күрә, троллейбусны озак көтәргә туры килмәде. Ләкин монда мәхшәр — тынчу, ачы тир исе борыннарны ярып керә. Җитмәсә, намус саклап иң ахырдан кергән һәм баскычтан күтәрелә алмаган Габделнур Галләмович аның белән бергә шулай ук кысыла-кысыла кереп, түбәнге басмада калган ике хатын уртасына туры килде. Ничек кирәк алай ишек ябылды. Хатыннар Габделнур Галләмовичны кайчандыр товар вагоннарын җылыткан «буржуйка» миче кебек пешерәләр иде. Алардан бер басмага биегрәк торган өченче юан хатын, урыны җайсыз булдымы, кисәк кенә аңа таба борылган иде, Габделнур Галләмовичның шактый тотрыклы борыны тегенең күкрәк уйдыгына — кофта изүеннән яртылаш чыккан имиләре арасына кереп кысылды. Сулыш алуы кыенлаша башлаганын тоеп, волейбол тубы хәтле юеш имиләрдән көч-хәл белән йөзен читкә бора алды ул.

Троллейбус уртасында Габделнур Галләмович кебек кысылып калган бер ир-ат шундый ук хәлгә дучар ителгән икенчесенә, артка каерылып, мәзәк сөйли:

— Бер адәм милициягә килгән. «Нишләп транспортта тәртип юк, кысан, хатын автобуста бәбәйләде, понимаешь», — дип зарлана икән. Милиция майоры тегеңә әйткән: «Ярый синеке бәбәйләп кенә калган, ә минеке трамвайда корсакка узган», — дигән.

— Булыр, булыр, — диде икенчесе. — Бер күрше хатыны, трамвайга утырганда кайсыдыр юньсезе трусикны салдыра башлады, дип сөйләде...

Аларга ияреп Габделнур Галләмович та елмаеп куйды: «Булмас димә — дөнья бу». Өч тукталыш арасы гына узасы, ничек тә түзәр иде әле, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, троллейбус «Кольцо»да бөтенләй туктады. Йөртүченең гамьсез тавышы барысын да тын калырга мәҗбүр итте.

— Юл ябык. Троллейбус ары бармый.

Пассажирлар шаулаша-сораша башлады. Ләкин анык кына җавап бирүче, бичараларга аңлатучы булмады.

Кыска җиңле ак күлмәге эсседән манма су булган Габделнур Галләмович бик аптырамады, троллейбустан төште дә җәяүләп сыпыртты. Чөнки алда, урам уртасында, трамвайлар да, поезд вагоннарын хәтерләтеп, озын бер рәткә тезелгәннәр иде.

Уң кулындагы авыр дипломатны сул кулына күчереп, сандали кигән аякларын да тоймыйча җиңел адымнар белән беркавым баргач, дипломатны тагын уңга авыштырды. Ул аның авырлыгына гадәтләнгән, кулына физик күнегү булсын өчен шулай йөртә. Хәрби хезмәттә чагында самбо көрәше белән шөгыльләнгән иде. Секцияне чандыр гына гәүдәле, озын буйлы офицер — капитан-лейтенант алып барды. Шуның сөйләгәне хәтереннән чыкмый. Атаклы көрәшче Иван Поддубный илле алты яшендә Америкага барып, шул илнең чемпионы була. Беренче көнне пароходтан төшүгә бу пәһлеванны зурлап каршылыйлар, андагы кагыйдә буенча хезмәтче негр аның чемоданын һәм тростен — тимер таягын ала. Ләкин тростне тотып кала алмый, аягына төшереп җибәрә. Чөнки ул бер потлы була. Поддубный шуны кулына күнегү булсын өчен гел үзе белән йөрткән. Дипломат та, бер потлы ук булмаса да, Габделнур Галләмович өчен үзенә күрә гантель ролен үти иде.

«Балалар дөньясы» кибетен узды; биек постаментта басып торучы халык шагыйренә сәлам биреп, мәшһүр театр бинасына таба юл алды.

Сулда Кабан күле җәйрәп ята, анда бер-ике көймәнең салмак кына йөзгәне күренә. Якында гына фонтаннар һавага су баганалары сиптерә, аларда кояш нурлары чагылып салават күпере хасил итәләр; бала-чага, фонтан астындагы суның сай булуына да карамастан, мәш килә: ауный, коена, су чәчрәтә, бер-беренә сибә... Бәхетле чаклар, кайгысыз гомер. Бигрәк тә шәһәр баласына... Алда, зәңгәргә буялган трамплинны хәтерләтеп, театрның авыш түбәсе ялтырап ята. Баштарак ул театр бинасы шактый еллар төзелештә эшләгән Габделнур Галләмовичның күңеленә бигүк хуш килмәсә дә, хәзер күнекте инде. Күрәсең, архитектура үрнәкләре һәрчак шулай авырлык белән халык тарафыннан кабул ителәдер. Эйфель башнясын да, Останкиноны да өнәп җиткер-

мәүчеләр булган бит. Ә хәзер исә Парижны да, Мәскәүне дә алардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел: алар бу шәһәрләрнең символына, визит карточкасына әверелде.

Ниһаять, театр да артта калды. Өенә җитәргә бер генә квартал арасы... Тар урамны аркылы чыгасы да... Ләкин монда токтарланырга туры килде.

Почмакта иңнәренә вак йолдызлы погон таккан тәртип сакчылары тора, юлда ике зур йолдызлысы хуҗа булып алган. Беркемне дә юл аркылы чыгармыйлар: олы урамнан да, тыкрык шикелле генә тар урамнан да.

— Нәрсә булган анда? — дип сорады Габделнур Галләмович бер хатын-кыздан.

Хатын аңа илтифат итмичә, дорфа гына җавап кайтарды:

— Белмисеңмени, теге исерекбаш килгән бит.

Хәзер генә кылт итеп исенә төште Габделнур Галләмовичның: урыс дәүләтенең башлыгы киләсе иде бит. Димәк, килгән. Димәк, мәчет күрсәтәләр.

— Нинди галәмәттер инде ул, — диде ак яулык ябынган карчык, — тоталар да теләсә кемне мәчеткә алып киләләр. Әллә тагы анда аю биетәләр. Изге җирне шулай мәсхәрә итмәсәләр... Тәһарәте булмаса, анда мөселманга да керү тиеш түгел.

— Әби, тегене ислам диненә күчермәкче булалар, — диде бер яшь егет.

— Күчәр сиңа...

— Ник күчмәсен, әби. Аңа кәләпүш кигерттеләр бит инде.

— Түбәтәй кидертү түгел, башына чалма уратсаң да күчми алар. Безнең халык кына ул...

Егет үзенчә шаяртмакчы булды:

— Хәзер печтерәсе генә калды.

Әбинең тәмам ачуы чыкты:

— Сөннәткә утыртасы дип тә әйтә белмисең, ичмаса!

Шуннан ул, әй, сиңа тел әрәм итеп торганчы дигәндәй, кул селтәп, теге егетне калдырып, янәшәдәге милиционерга таба борылды.

— Улым, пучти, пажалысты, бабай умирает, я аптик ходил, вот дару.

Милиционер, өлкән лейтенант, бик тәртипле кеше булып чыкты.

— Извините, бабушка, я не могу. Приказ. Обращайтесь вон к тому, он — начальник, — диде ул, урам уртасындагы подполковникка ишарәләп.

Икенче милиционер, ыспай гәүдәле лейтенант, әбигә татарча әйтте:

— Әби, түзегез инде. Ярамый бит.

— Мин түзәр идем дә... Шулайдыр инде, ярамыйдыр... Шулар килсә, ярты шәһәрнең юлын буып куялар.

— Әби, син аның килүенә сүз әйтмә, — дип, бая карчыкның кәефен кырган теге яшь егет тагын сүз катты. — Олы түрәләр килүнең уңай ягы да бар: чүтеки юлларны төзәтәләр, урамнарны тәртипкә китерәләр. Алар бит безгә кала. Берәр районга бара икән — авылларда капка-коймаларга тиклем буйыйлар. Зыянмы әллә?

Әй бәйләндең инде дигән сыман аңа карап, әбекәй:

— Килсен, күрше белән күрше йөрешә инде ул, — диде. — Килүе үзе мәслихәт, аралашу фарыз илбашларына. Әнә шул мәчеткә керүен генә өнәмим.

Ул да булмады, яшь кенә бер хатын погонлы егетләргә ялына башлады:

— Кечкенә балам өйдә берүзе калган иде. Зинһар, чыгарыгыз инде!

Моның да гозеренә колак салучы булмады. Габделнур Галләмович як-ягына каранып алды: тар гына Каюм Насыйри урамын да, аннан өч-дүрт мәртәбә киңрәк Татарстан урамын да милиционерлар, гаскәриләр һәм күзе үткер кешегә шулар сафыннан икәннәре әллә каян күренеп торган төз гәүдәле гражданскийлар биләп алган.

Урамны иңләп, әледән-әле милиция машиналары үткәли.

Кемдер шулчак, үзен бик белдеклегә санап, хәбәр бирә:

— Әнә киләләр!

Юк, әле иртәрәк икән. Кулларына күзлек савыты хәтле генә кара телефон — рация тоткан милиционерлар бер-берсе белән хәбәрләшеп торалар бит. Алар әлегә тыныч.

Һушын җуяр дәрәҗәгә җиткән корсаклы хатын:

— Я больше не могу, — дип юлга чыкмакчы иде, аны да кире бордылар.

Бая әбине үчекләгән егет янә телгә килде:

— Кичәле-бүгенле бөтен ишегалларын, подвалларны, чормаларны актарып-айкап чыктылар.

— Нигә? — диде кайсыдыр.

— Шуны да аңламаска... тегене чүкемәсеннәр дип.

Эссе. Кояш баш түбәсендә генә кебек. Җилләнсәң дә файда бирми. Күләгә дә юк. Урам чатында һәрчак утыра торган өтек киемле хәерчеләр дә бүген юкка чыккан. Ә, әнә агач аяклысы бар икән. Ул, гадәттә, сары протезларын, тезенә тикле чалбар балакларын сызганып, тротуарның яртысына хәтле сузып куя. Кайчагында шунда мәлҗерәп, кыңгыр авып та ята, еш кына асфальт та юеш була. Бүген ул юньләп күренми дә, чөнки халык килә тора, ташу акканда күпер турына килеп бүәлгән бозлар кебек җыела, кысыла. Һәрберсенең уе бер генә: ничек тә урамның теге ягына чыгу.

«Ничә адым булыр икән? — дип уйлады армиядә чакта спортның берничә төреннән разряды булган Габделнур Галләмович, сәгатенә карап алгач. — Егермедән артык түгел». Ләкин бу уеннан кире кайтты. Кулына дипломат тоткан, кыска җиңле күлмәктән генә булса да галстук таккан, чалбары белән сандалие да үтә затлыдан булган илле яшьләр тирәсендәге, чигә чәчләре агарган, карап торышка зыялы гына кыяфәтле кешенең милиционерларга тоттырмаска тырышып урам аркылы йөгерүе... Дөрес, бәлки, погонлы егетләр, постларын ташлап, аны куарга җөрьәт тә итмәсләр... Юк, батмый. Яшь чагы түгел бит. Моннан утыз еллар элек булсамы... Йөз метрга йөгерүдә аңа тиңнәр бөтен батальонда бер-ике генә иде.

...Йөгерү дигәннән, бервакыт, инде Казанда яшәгәндә, дус егетенең туеннан соң икенче көнне ул бер милиция сержантыннан качкан иде.

...Аны уйларыннан айнытып, кемдер сөрән салды:

— Киләләр!

Габделнур Галләмович үзалдына көлеп куйды. Бу тавыш авыл сабан туенда «Атлар килә!» дигән сымаграк яңгырады. Шушы дәртле аваздан болай да ярсыган, ашкынуы һич кенә дә сүрелмәгән халык, үзенең кайда торганын да, әле генә сукрана-сукрана кемнәрнедер аты-юлы белән эчтән генә сүгеп торуын да кинәт онытып, кая карарга белмичә алан-йолан килә башлады. Аннары, милиционерлар башларын кая борганны чамалап, барысы да артка каерылды: муеннар сузылды, кемдер аяк очына басты, кемдер икенче берәүнең култык астыннан җәлт кенә алга омтылды...

Иң алдан урам буйлап аның кыл уртасыннан, ажгырып, бер кара машина килә иде. Күрәчәге булгандыр инде мескеннең, урам аркылы чыгып килүче бер ак эт чинап кычкырды да шул минутта ук җан биреп тынып калды. Ак йомгак өстенә икенче машинаның тәгәрмәче килеп менде...

Кара машиналар сулга таба борылдылар: берәү, икәү, өчәү...

Габделнур Галләмович турыннан озын кара машина выжлап үтеп китте. Артта утырган кешенең егет чакта тәртә белән сугып сындырылган зур кызгылт борыны, халыкны сәламләгән өч бармаклы озын кулы гына күренеп калды. Бу машина артыннан ук, аңа тагылгандай, бәләкәй, тәбәнәк кара автобус узды. Аңа автомат көпшәләрен ачык тәрәзәдән чыгарып халыкка төбәгән башкисәр юлбасарлар кебек чырайларына күз турысын һәм авыз ерыгын ачык калдырып кара битлек кигән тән сакчылары утырган иде. Алар артыннан тагын кара машина...

Ниһаять, кабат юл уртасына чыккан начальник кул селтәде, һәм халык, ташкын булып, алга ыргылды.

Баягы әбинең тавышы колакка чалынды:

— Әстәгъфирулла, сытып китәрләр...

«Әйе, ике-өч сикерүдә йөгереп-атлап үтәсе урамны ярты сәгать чыга алмыйча интек инде, — дип куйды ташкын агымына бирелеп алга атлаучы Габделнур Галләмович үз-үзенә. — Яшь чак булса...»

Бар иде аның яшь чаклары, бар иде. Милиционер түгел, җил дә куып җитә алмас иде егет чагында. Ләкин җилдәй җитез чагы түгел, яшь тә бүтән, шуңа күрә көтеп торды. Хәер, ул заманда мондый галәмәт юк иде бит, түрәләр болай кыланмый, һәм аларны бу тиклем сакламыйлар да иде. Әйе шул. Кара син, ә... Кызык...

Еракта калды инде Габделнур Галләмовичның яшьлек еллары. Ул хәзер нык үзгәрде. Хәер, ул гынамы? Дөньясы үзгәрде. Узган еллар, агач кәүсәсендәге ел боҗралары кебек, аңа да, чорга да үзенең тамгаларын сызып калдырды.

Озын-озак уйлар ташкыны, көймәне үз агымына иярткән җитез елга суы кебек, Габделнур Галләмовичны бөтереп алды. Һәм ил-көн белән бергә үзенең дә үзгәрүе, тормышы, яшәеше поездда барганда тәрәзәдән берөзлексез күренеп калучы урман-болыннар, кала-салалар шикелле күз алдыннан үтте. Юк, ул аны якындагы станциягә барган сыман бер сәгатькә яки бер шәһәрдән икенчесенә чапкандай бер көндә генә күзаллап бетерә алмас иде. Моның өчен ул утырган поездның атналар-айлар буена хәрәкәт итүе — шактый вакыт сарыф ителүе шарт. Чөнки ул дөньяны байтак гизде, гөлбакчадай матур җирләрне дә күрде, тормышның ачысын-төчесен дә татыды, рәхәт минутлары, бәхетле чаклары да булмады түгел. Һәрхәлдә, утыз елдан артык вакыт үткән бит инде Казанга килеп төпләнүенә дә... Әйтергә генә ансат: өч дистә елдан артык... Шома маңгайлы яшь-яшь егет иде. Хәзер әнә тирән сызыклар ярылып ята. Ул дусларына, шаяртып, җир өстенең ярык-ерыклары булган сыман, ир-атның да йөзендә җыерчыклар булырга тиеш, дияргә ярата яратуын... Шулай да...

Габделнур Галләмович почмактагы зур йортның беренче катында урнашкан азык-төлек кибетенә кереп ипи алды, дипломатыннан целлофан пакет чыгарып, шуңа салды. Кибеттән чыкканда баягы күңел төшенкелеге каядыр юкка чыккан иде инде: кояшлы аяз көн эссе булса да, кем әйтмешли, дөнья матур! Ул җиңел адымнар белән якында гына күренеп торган ак йортка — һәрчак гаилә әгъзаларының җанга рәхәт җылысын, күңелгә хуш таныш исләрен, ягымлы мөгамәләсен саклаучы иркен фатиры булган, үзе яши торган өенә таба атлады.

Ә уйлар ташкыны язгы боздай кузгалган — туктатырмын димә — үзенекен итте: актарылып агылды да агылды...

## 2

Ноябрь уртасы җитсә дә, әле кар төшмәгән. Шулай да иртә-кич салкынча, ә төннәрен шактый суык. Көндез бераз җылыткан шикелле була. Ләкин кояш, хәлсезләнгән карт-коры сыман, көч-куәтен әллә ни күрсәтә алмый: карасу авыр болытлар аны гел каплап торалар. Аларның төрлесен төрле якка таратып ташлап, барча те-

реклеккә үзенең җылы нурларын үзе теләгәнчә чәчәргә кояшның да кодрәтеннән килми. Әйе, хәтта бик теләсә дә илаһи зур көчкә ия булган биниһая гайрәт иясе кояш та кайчагында көчсезлеген танырга мәҗбүр була. Көнозын кояш яктыртып тормагач, күк йөзе зәңгәрсу төскә манылып, баш түбәндә күз күреме җитмәслек биеклек-иркенлек булмагач, көннәр ямансу.

Кояш булып кояш та үзе теләгәнчә тереклек итә, гамәлләр кыла алмый икән, адәм балаларына ни сан?! Алар кояшка караганда бик күп мәртәбәләр көчсез бит, аларның яшәү рәвеше санап бетергесез киртә-чикләүләргә, бүтәннәрнең уй-теләкләренә, мәҗбүри саналган эшләргә бәйләнгән. Һәм алар гомумкешелек өчен бернинди әһәмияте булмаган шул шартлы чикләү-тыюларга буйсынырга тиеш булалар да, үзләре барырга хыялланган сукмакларны бер кырыйда калдырып, бөтенләй икенче юлга кереп китәргә мәҗбүрләр. Тора-бара алар балалык, яшьлек хыялларына хыянәт итеп яки аларны онытып, шул мәҗбүрият юлыннан кисәк кенә аерыла да алмыйлар. Кешеләр кайчагында аңлы-аңсыз рәвештә тәүге хыялларына хыянәт итәләр. Шуңа күрә балачактан ата-ана үгет-нәсихәте белән аңнарына сеңгән бик күп изге төшенчәләр юкка чыга.

Бүген Габделнур кендек каны тамган туган йортыннан — ата-баба нигезеннән, бу якты дөньяда яшәсен өчен аңа җан өргән газиз әти-әнисеннән, күңеленә якын кан кардәшләреннән, парта арасыннан ук уй-хыялларын бүлешкән яшьтәшләреннән, һәр бөртек тузанына хәтле таныш урамда, аның яшел чирәмендә ауный-тәгәри үскән һәм бер сынык ипидән дә өлеш чыгарган балачак дусларыннан аерылып армиягә китә.

Элегрәк елларны булса, туган авылында яшәсә, аны парлап яки өчләп җиккән атлы арбада район үзәгенә хәтле гармуннар белән озата барырлар иде. Ул анда әле ялгызы гына да булмас — быел каралганнардан һичьюгы дүрт-биш егет бергә китәрләр иде. Бәлки, күбрәк тә. Чөнки авылда алар — Габделнур белән бер елгылар — дистәдән артык иде бит. Юлда, чит-ят җирләрдә алар бер-беренә һәрчак terәk, егылганда таянырлык җилкә-иң булырлар иде.

Ләкин, ни хәл итмәк кирәк, аның язмышы бүтәнчәрәк шул: ундүрт яшеннән авылдан чыгып китте, өч ел укыганнан соң өч ай гына үз районында эшләде дә нефть чыккан якларга тайды. Менә хәзер ул үз районы кешесе дә түгел икән, ә нефтьчеләр каласы военкоматының, әбиләр әйтмешли, никруты. Авылдан берүзе китә; оялып-тартынып кына, күтәрмен, дип, егетенең учына пар күгәрчен чигелгән кульяулык төртүче дә юк.

Ләкин боларны озын-озак уйлап торырга, нечкә хисләргә бирелергә егетнең вакыты тар: капка төбендә соңгы тапкыр әнисе, ике әбисе, апасы белән җизнәсе, башка туган-тумачалары һәм күрше-күлән аңа изге теләкләрен әйтеп калырга ашыга.

— Улым, исән-сау әйләнеп кайт.

— Әйбәт хезмәт ит. Ир кеше эше инде ул.

— Ашлык кибәксез булмый, кешеләр дә төрлечә, юньсезләрдән читтәрәк йөр.

— Апаем, хат яз. Барып урнашкач та яз, яме.

— Безне онытма.

Энесе Газиз абыйсының кечкенә чемоданын алып чыкты. Әтисе машина кабинасында утыра иде инде. Бераздан:

— Ярар, балалар, кузгалдык, — диде ул.

Габделнур җәлт кенә кузовка менде; күңеле тулса да, сиздермәскә тырышты.

— Сау булыгыз!

Хатын-кызлар яулык почмагын яшьле күзләренә тидереп алдылар; куллар өскә күтәрелде... Шау-шусыз, сабыр гына, бөтен газапларын эчкә йотып, аерылышу минутларын кичерделәр. Берсенә дә җиңел түгел. Ләкин иң авыры Гөлзифа түтигә, бәгыреннән өзелеп төшкән икенче йөрәк парәсен солдатка бирүче Анага. Читтән караганда ул тыныч кебек. Ләкин эчендә нинди утлар янганын бары ул үзе генә белә.

Аның тышкы сабырлыгына сокланып, эчке халәт-кичерешләрен аңлап, хәтта бакчадагы сирень куаклары да тынып калганнар иде.

— Хушыгыз!

Ярый әле абыйсы Гатуф хромкасын тартып җибәрде, никрутны кузовта көтеп торган яшьтәшләре җыр башлады. Габделнур үзе аларны кочаклаган, үзе каерылып артка карый...

Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Су өстендә дулкын ничек,
Безнең шундый чагыбыз.

Тыкрыкка борылганда машина туктады. Күрше карчыгы Галләм абзыйга ишарәләгән икән.

Карчык Габделнурга дәште:

— Үскәнем, исән-сау йөре, — диде ул һәм аңа кул сузды.

Егет аны саубуллашырга суза дип уйлаган иде, әбинең бармак арасында бер сум акча икән.

— Мә, улым, ал әле. Исән йөре.

Габделнур, күңеле тулып:

— Рәхмәт, түти, — диде. — Үзең исән-сау тор.

Машина янә кузгалды һәм тыкрыктан төшеп китте. Капка алдындагылар күздән югалды. Яраткан абыйсын озата чыккан Актүш тә, чатка җиткәч, бу ни хәл, миңа нишләргә дигәндәй аптырап, арт аякларына утырып калды.

Җыр, отыры көчәеп, бәрәкәтле кара туфраклы бәрәңге бакчаларына таралды; су буендагы биек тал агачларының салынып төшкән моңсу нәзек ботаклары һәм әле коелып бетмичә берән-сәрән калган яшькелт-сары озынча яфраклары арасына кереп тулды; андагы сирәк кошларның сизгер колакларына барып иңде.

Сандугачлар басып сайрый
Зиярат киртәсенә;
Быел еллар бик ямансу
Әллә без китәсенә.

Машина тыкрыктан бер чакрымлы озын урамның кыл уртасына килеп чыкты да уңга борылды. Габделнур капка каршында торучы, юлда очраган берне өч итәргә омтылып яшәүче тырыш авылдашлары белән баш кагып исәнләшә-саубуллаша һәм шул ук вакытта дуслары белән җырлый-җырлый барды:

Ал кисәргә, гөл кисәргә
Үтмәс кайчыларыгыз;
Киләсе ел бу вакытта
Булмас кайсыларыбыз.

Югары очка җиттеләр. Һәр өе, һәр кешесе таныш булган туган авыл артта калды.

Авыл башында Галләм абзый машинасын туктатты. Егетләр берәм-берәм кузовтан коелдылар. Габделнур да җиргә сикерде. Инде яшьтәшләре-чордашлары белән аерылышыр вакыт җитте. Алар күп түгел. Ләкин алар чын дуслар — җан дуслар.

— Ну, пока, яшьти.

— Сау бул.

— Исәнлектә.

— Отпускыга кайтырга тырыш.

Габделнурның күзләре янә дымланды.

— Хушыгыз, егетләр.

Куллары — көчле, ихлас кысалар, кочаклары иркен авыл егетләренең, карашлары — самими. Беренче генә дусларын озатмыйлар. Бүген-иртәгә үзләренә дә повестка тоттырачаклар. Калса да, бер-икесе генә ак билет алып китмичә калыр.

— Хат яз.

— Обязательно.

Кабина ишеген ачып подножкага баскан Галләм абзый:

— Киттек, улым, — диде дә руль артына кереп утырды.

Машина урыныннан кузгалды. Егетләр төркеме артка чигә башлады; алар ягына авышкандай, юл буендагы телеграф баганалары да бер-бер артлы каршыга киләләр дә тиз генә ерагаялар — озын буйлары белән сураеп авылга таба агылалар.

— Хуш, туган авыл! Тагын сине күрергә язсын!

Абыйсы, уйнавыннан туктап, гармунын энесенә бирде.

— Мә, уйна бер. Тавышы авыл өстенә таралып калсын...

Габделнур аягөсте, авылга карап, хромканы сыздырып җибәрде. Егылмасын өчен аны иңбашыннан энесе кочаклады. Аннары алар эскәмиягә утырдылар һәм өч бертуган — олысы инде ватан алдындагы изге бурычын үтәп кайткан, уртанчысы бүген китә, ә төпчек малай ике елдан хәрби хезмәткә алынасы — җырлап җибәрделәр:

Үскән чакта үскән идек
Тал тамырлары кебек,
Үсеп җиткәч аерылабыз
Кош балалары кебек.

Туганнарның көчле көр тавышы ерак-еракларга тарала барды.

Өч урамлы авыл үзенең бәләкәй өйләре, биек агачлары, Габделнур хезмәтен үтәп кайтканчы ул белгән байтак кешеләрне үз куенына сыендырачак зиратлары белән артта калды. Авылдан читтәрәк, еракларга сузылып киткән межалар да, рәт-рәт куелган озын салам эскертләре дә әле бик озак җыр тыңлап, Габделнурга изге сәфәр теләп, моңаеп утырганнардыр. Эш-гамәлләренә көче-хезмәте кермәсә дә, ул бит шушы авыл малае, шушы туфракның газиз бер баласы. Ә тимер-томырдан укмашкан буровой вышкаларының яшел төстәге машинага

утырып каядыр китүче егеттә гамьнәре юк, аларның үз бурычлары бар — илдәге техникага нефть кирәк: үтеп киткән бәләкәй «газик»ка да, су асты көймәләренә дә, диңгез өсте корабларына да, һавадагы очкычларга һәм җирдәге танкларга да...

Инде Рудник (борын заманда бакыр базы булган) дип йөртелгән җир дә, авыл мәйданы көнне ат чабышы башлана торган Баллы күпере дә, кайчандыр Ачы исемен алган (кемдер биргән) уйсулык та — барысы да артта калды. Ә җыр агылды да агылды...

Галләм абзый — беренче көннән үк сугышка алынып, Сталинград фронтында каты яраланып, җиде ай лазарет-госпитальләрдә иза чиккән десантчы-солдат — улларына каты бәрелмәде, авыллар аша үткәндә «авыз күтәреп җыру җырлауларына» да сүз әйтмәде. «Өйдә җырласыннар, әле тагын кайчан бергә җыелалар, — дип фикер йөртте ул. — Бусы кайтканчы кечесе китеп барса...»

Уф дигәндә сулыш булырдай туганнар Әлмәткә барып җиткәнче алмаш-тилмәш гармун уйнадылар, өчәү бергә җырладылар. Аталарына сиздермичә генә өчесенә бер яртыны бушаткан мәлдә җыр өзелеп торды да кабат яңгырады. Фәкать таулар итәгенә, мул сулы тар елга буена утырган, әүвәл гади бер авыл, аннары эшчеләр бистәсенә әверелгән, ә соңгы вакытта төзелеш мәйданын хәтерләтеп аркылыга-буйга үсүче, елдан-ел биеккә күтәрелүче һәм зураючы-киңәюче яңа шәһәр эченә кергәч кенә гармунны тартмасына салып куйдылар.

...Габделнурның әтисе белән энесе куна калмадылар, ашап-эчеп бераз ял иткәч кузгалдылар.

— Ярар, килен, рәхмәт, — диде Галләм абзый олы улының хатыны Хәмидәгә. — Без китәрбез инде.

Бөтерчек кебек җиңел хәрәкәтле, кечерәк гәүдәле килене каенатасы белән каенанасына гына түгел, ә иренең барча туганнарына да ачык чырай күрсәтә иде: баракның озынча тар бүлмәсеннән генә гыйбарәт булса да, бу кунакчыл өйдә авылдан килгән һәркемгә йокларга чиста урын-җир табыла, табында аш-су әзер була. Кай арада барысына да ничек өлгерә торгандыр — моны килен балакай үзе генә белә булыр.

Бу юлы да килене каенатасын, кечкенә баласын күтәреп, урамга хәтле озата чыкты.

— Исән-сау кайтып җитегез, әти.

Машина Промысловая урамында бер катлы, такта блоклардан әмәлләнгән-корылган озын барак каршында иде. Аның янында озаклап сөйләшеп тормадылар. Кырысрак холыклы булса да, Галләм абзыйның күңеле тиз нечкәрә, күз төпләре дымланучан иде. Шулай да кабинага кереп утырганчы Габделнурга бер-ике авыз сүз әйтүне кирәк тапты.

— Улым, исән йөре, — диде ул. — Зур казанда кайнаган ит чи булмый, диләр. Зур дөньяга чыгасың, күзең дә ачыла төшәр. Безне онытма, хат яз.

— Ярар, әти, язармын.

— Моңарчы йөзгә кызыллык китермәдең, анысына рәхмәт. Моннан соң да шулай булсын. Син олы юлга чыгасың. Мин юлларны күп күрдем. Кайчак тар гына грунтовой юл да тип-тигез була. Кайсы төштә киң асфальт та сикәлтәле. Тормыш та шулай. Алдың-артың карап йөр, сак йөр. Курыкма, ләкин чит-ят җирдә икәнеңне онытма. Кемнәр белән бәйләнәсең — аны да кара. Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың. Әйбәт йөр. Кеше көлдерерлек булмасын.

— Ярар, әти.

Башына фуражка, өстенә телогрейка, аягына үкчәләре ашалып як-якка янтайган кирза итек кигән Галләм абзый уртача буйлы, илле бер яшьлек ир иде. Снаряд ярчыклары кереп калган аяклары еш кына авыртса да, озак еллар машина йөрткәнлектән, куллары таза иде аның. Габделнур әтисенең кулын кайчагында юри катырак кыса иде, ләкин ул аны уйлап та бирми, көч-гайрәте әлегә ташып тора. Бүген исә аның кул кысуы йомшак, гәүдәсе дә кечерәебрәк калгандай тоелды. Тышка чыгармаса да, икенче улын армиягә озату ата кешегә җиңелдән түгелдер. Ата белән ул шулай кул кысышып, артык сүз куертмыйча гына аерылыштылар.

Ә энесен Габделнур иңнәреннән кочаклап бертын торды.

— Мин кайтканчы сине дә алырлар инде.

— Отпускыга кайтсаң, күрешербез әле.

— Җибәрсәләр.

Энесе, кем әйтмешли, полный җегет булып җитте, бер айдан унҗиде тула бит. Буйга алар өчесе бер чама — әтиләре, Габделнур һәм энесе, ә абыйсы тәбәнәгрәк, гәүдәгә дә җыйнаграк. Ләкин туганлык хисләре барысыныкы да мулдан — ташып тора.

Габделнурга Әлмәттә дә, авылдан киткәндәге шикелле, тагын бик авыр булды аерылышу. Әтисенең машинасы күздән югалганчы карап калды ул.

...Кичке якта Габделнур йөргән кызы янына китте. Бара-барышка аны беренче мәртәбә очратуын исенә төшерде.

Аларның танышуы кызык кына булды. Әлмәткә күчеп эшли башлаганына бер айлап үткәндер, беркөнне ул эштән соң ипи кибетенә керде. Ике-өч кеше чират тора иде. Ул чиратның койрыгына барып басты.

— Кем ахыргы?

— Мин, — диде ярым борылып ак күлмәкле бер кыз һәм янә алга карады.

— Кызлар да ипи ашыймыни? — дип, теленә килгән беренче сүзне әйтте Габделнур.

— Мин коржик алырга торам, — диде кыз, бу юлы башын гына борып.

— Билгеле, кызлар арыш ипие ашамас инде. Ул безгә генә тансык. Кызлар сөттә генә пешкән коржик ашый. Шуңа күрә чибәр алар...

Бу хәтле юмарт комплиментка җитмеш яшьлек карчык та эреп китәр иде. Ә кызлар күңеленә сары май булып ята да ята инде андый сүзләр. Хәер, әллә ни исе китмәде шикелле. Чөнки ул болай да бик чибәр иде. Кыз дәшмәде. Аның чираты җиткән иде инде. Ул ике коржик алды, акчасын түләде һәм чыгып та китте.

— Сезгә нәрсә? — дип сорады сатучы.

— Бер буханка ипи.

Габделнур акча сузды. Кибетче ипине өстәлгә, егет каршына куйды.

— Сдачам юк бит. Вак акчагыз... — дип әйтә башлаган иде, егет аны тиз туктатты.

— Иртәгә керермен. Ипием дә калып торсын.

Ул кибеттән атылып чыгып йөгерде. Ни өчен шулай ашыкты, кая ашыкты — бу турыда уйларлык хәлдә түгел иде. Чөнки бая кыз яртылаш борылып аңа караганда, егеткә нидер булды: әллә карашы өздереп алды, әллә алсу яңаклы матур йөзе үзенә җәлеп итте, әллә кыска җиңле күлмәк кигән зифа буе сокландырды. Бәлки, бөтенесе бергә әнә шул мизгелдә — күз ачып йомган арада — Габделнурның йөрәген җилкенергә мәҗбүр иткәндер.

Егет, юл аркылы чыккандагы кебек, ялт кына як-ягына каранды. Юк. Уңда да юк, сулда да. Китеп барган. Шул арада... Әһә, әнә бер таза хатын үзенең симез гәүдәсе белән каплап бара икән. Ул су буеннан әүмәкләп кайтып килүче үрдәк кебек як-якка авышканда, егет кыска җиңле ак күлмәк кигән, билен ак төстәге киң каеш белән буган зифа буйлы кызны күреп алды. Йөгерә-атлый куып та җитте. Ике-өч адым ара калгач, йөгерүдән туктады һәм беркавым кызга сокланып барды. Кыз чыннан да сокланырлык иде: иңнәренә таралып яткан кара чәчләре гәүдә ритмына кушылып дулкынланып уйнаклыйлар, кулларын як-якка җәебрәк җибәргән, тыгыз балтырлы төз, килешле аяклары асфальт тротуардан җиңел атлыйлар.

Янына ук килеп җиткәч, Габделнур кызга:

— Сез дә безнең урамда торасыз, ахры? — диде.

Кыз ярым борылып карады, таныды, алсу битле йөзенә елмаю чыкты.

— Белмим. Мин Шевченкога барам.

— Әйттем бит. Мин дә шунда... ятим балалар йортында.

— Детдомдамыни?

— Тулай торакта. Шаярып кына әйтәм. Әти-әни янында булмагач, барыбер ятим инде. Ә сез Әлмәт кызымы?

— Әйе.

— Бәхетле җаннар бар дөньяда, — диде егет, уйчан гына, аннан теманы үзгәртте: — Бер урамда яшибез, әле күрешкән юк. Хәер, мин монда әле икенче генә аемны эшлим.

— Ә мин бу урамда тормыйм, — диде кыз һәм егеткә карап елмайды.

— Үзегез...

— Мин, Шевченкога барам, дип кенә әйттем, яшим, димәдем.

— Сорасам да әйтмисең инде кайсы урамда торганыңны.

— Иске Әлмәттә. Әти-әни белән, үз йортыбыз белән.

Габделнур үзенчә шаяртмакчы булды.

— Аңлашылдымы, ә хәзер хуш дип әйтәсең килә инде. Чибәр кызлар гел шулай кистереп сөйләшә инде.

— Аны мин түгел, сез әйттегез.

Кызның көлемсерәп әйтүеннән егетнең эченә җылы йөгерде. Ул, булдыра алганча теленә салынып, дөресрәге, тел байлыгын эшкә җигеп, кызны биш катлы яңа йортның беренче подъездына хәтле озата барды. Әгәр дә ул, хуҗасына тугрылыклы эт кебек, аның авызына гына карап, койрык болгагандай ялагайланып барса, кыз, бәлки, хушыгыз, дип кереп тә китәр иде. Ләкин үзен горур тотуы, оста итеп сөйләшүе, әңгәмә кора белүе кызда егеткә карата ихтирам уятты булса кирәк. Ул егетнең озак торасызмы дигән соравына бераз уйланып, йомшак кына җавап бирде.

— Белмим әле. — Егетнең кулына карап алды. — Гафу итегез, ә сез кибеттән бер әйбер дә алмадыгызмыни?

— Сдачасы булмады.

— Кибеттә очраган һәр кызны шулай озатып куясызмы?

— Юк. Минем әле монда бер танышым да юк. Эшлим дә кайтып ятам.

Габделнурның ихлас күңелдән әйткән сүзләренә кыз ышанды бугай. Шулай да сынаулы карашын егеттән алмады.

— Эшегез шулай авырмыни? Буровойда помбур яки верховой булып эшлисезмени?

— Юк. Мин — электрик. Көне буена багана башында йөрим, линия сузабыз.

Шуннан соң кыз, егетне башыннан аягына хәтле карап, бер мизгел тынып торды.

— Мин ун-унбиш минуттан чыгам.

Һәм ишектән кереп тә китте.

Томана булмаган кешегә аңлашырлык иде бу сүзләр. Габделнур тәбәнәк гөлҗимеш куаклары янында беркавым басып торды да йорт каршындагы эскәмияләрнең берсенә барып утырды.

Ул өс-башына күз салды. Әлбәттә, энәдән-җептән генә төшкән, кызлар куа торган кием түгел иде аның өстендә: кыска җиңле, акка беленер-беленмәс кенә кызгылт буй сызылган күлмәк, карасу чалбар һәм үрелгән күн «чабата». Чалбары чиста булса да үтүкләнмәгән, тез турлары кабарыбрак тора, чөнки иртән машина аларны егерме-утыз чакрымга басуга алып китә дә кич кайтара. Ярый әле эштән соң тар гына бер елгада су коенып чыкканнар иде, бит-куллары тузанлы түгел. Шулай да егет уйлап куйды: «Тулай торакка йөгереп кенә кайтып кием алыштырып килсәм... Юк, өлгерә алмасам, чыгар да китеп барыр. Алдакчыга санар... Үзем аннан колак кагармын». Һәм егет көтәргә булды.

Кемнәрдер өй каршындагы торбаларга сузылган бауларга кер юып элгән. Кич җитсә дә, чыгып алмыйлар. Кичәле-бүгенле аның күңеленә шушы ак керләр шикелле пакь, якты уйлар килә, эш-гамәлләре дә уңай. Кичә югарырак группага имтихан тотты. Авыр булды булуын, сорауларны шактый яудырдылар, ләкин китап кимерүе, бу эшнең рәтен белүе, курыкмыйча җавап бирүе файда итте. Хәзер ул югары вольтлы подстанциядә эшләргә — дежур торырга хокук алды. Бүген исә дөньяда ике чибәр булса, берсе — шушыдыр дип әйтерлек бер кызны озата килде. Дөрес, бу әле чын-чынлап озату түгел иде. Ләкин, белмәссең, әбисе әйтмешли, фәрештәнең амин дигән чагына туры килсә, бәлки, йөреп тә китәрләр...

Һәм, ни хикмәт... юраганы юш килде: йөреп киттеләр.

Кыз туганнарында озак тормады. Алар сөйләшә-сөйләшә түбән таба төштеләр. Девонская урамыннан җәяүләп киттеләр. Кыз Бөгелмәдә медицина училищесы бетереп кайткан, эшкә урнашып йөри икән. Гаиләсе турында да әйтте. Габделнур да авызына су кабып бармады: горурланып өч-дүрт катлы йортларга күрсәтте. Чөнки алар Чупай ташыннан салынган иде. Үзенең берара карьерда эшләвен, махсус комбайн ярдәмендә шушы ак, зур «кирпечләрне» кисүен искәртте. Кыскасы, бер-бере хакында алар шактый мәгълүмат алдылар, уртак тел таптылар. Чибәр булса да, шәһәрнең авыл өлешендә үскәнгәме, кыз тәкәббер түгел иде. Ләкин аны җебегән дип тә әйтеп булмый иде.

Икенче көнне Габделнур Рәйсәнәне «Родина» кинотеатрына дәште. Залда ут сүнеп, кино башлангач, Габделнур аның кулына орынды. Әмма кыз кулын кисәк кенә тартып алды.

— Тик кенә тор, — диде ул, егетнең авыр, саллы кулын тезеннән алып. — Кулыңа ирек бирмә.

...Габделнурга рәхәт иде шуларны исенә төшерүе. Беренче танышу көннәре, матур җәй, көз айлары үтеп тә китте. Дөрес, бөтен көннәр дә күңелле узмады. Бервакыт күршетирә егетләре каяндыр килгән бер килмешәккә күз өстендәге каш булган гүзәлне бирәселәре килмичә аны тотып кыйнадылар. Рәйсәнә кереп киткәч, унбишегерме адым да атларга өлгермәде Габделнур. Көчле булса да, үзе кебек үк таза дүрт егеткә каршы тора алмады — ярыйсы дөмбәсләделәр. Ул фәкать егылмаска гына тырышты. Рәхмәт Рәйсәнәнең абыйсына, эштән кайтышлый ул аралады. Кем икәнен дә белмичә. Габделнурның да аны беренче күрүе иде.

— Сез нәрсә, анагызны, — дип акырды ул адәм теге егетләргә, — дүртәүләп бер кешегә ябырылдыгыз? Бергә-бер сугышалар аны егет булсагыз! А ну ычкыныгыз!

Танышлары икән, ярар, дип исеме белән дәштеләр, туктадылар, тазалыгы да бар — момент шылдылар — таралыштылар.

Шулай да берсе, Габделнурга янап:

— Ярар, очратырбыз әле, — дип мыгырданды.

Тегеләр киткәч, миһербанлы бәндә:

— Син каян? — дип сорады дорфа гына. — Нишләп йөри идең бу тирәдә? Күргән кешем түгел.

Габделнурга әйтергә туры килде:

— Бер кызны озата килгән идем, — диде ул, кабарып чыккан иреннәрен ялап.

— Кемне?

— Әнә теге йортта...

Сораштырып-төпченеп, сеңлесенең егете икәнен белгәч, ай-ваена карамыйча үзләренә дәште коткаручы. Ләкин Габделнур бу кыяфәтендә өйгә кермәде, гарьләнде, ишегалдында гына юынды. Чөнки аның борынына сукканнар иде. Рәйсәнә аның канга буялган күлмәген алып калды, абыйсыныкын кидерде. Күлмәкнең җилкә тирәсе киңрәк, җиңнәре озынрак булса да, Габделнурга кыз әмеренә буйсынудан башка чара калмады.

Абыйсы, усал егетләр кулыннан йолып алса да, Габделнурга икенче яктан нык төшендерде.

— Колагыңа киртләп куй, егет: әгәр иркәмне обижать итсәң, болай гына җиңел котыла алмассың.

Бу төбәктә үзеннән кечеләргә иркәм дип дәшәләр иде.

Сеңлесе, оялып:

— Абый, син нәрсә инде, — диде. — Мин...

— Мин сине беләм. Ул да белеп торсын. Мин бит йөрмәгез димим. — Аннары, кисәтүен бераз йомшарту өчен булса кирәк, Габделнурны мактап, үсендереп җибәрде: — Аягыңда нык торасың, ә ударың слабыйрак.

Күрәсең, буровойда эшләүче абыйсының яшьләр арасында абруе саллы иде, ахры, Рәйсәнә егетенә кабат кул күтәрүче, юлына аркылы төшүче булмады.

Күз төбендәге «фонарь» бетте, ә Рәйсәнәнең абыйсы әйткән сүз, күңеленә юшкын булып ук утырмаса да, һәрдаим Габделнурның исенә төшеп торды. Хәер, кисәтмәсә дә, аларның йөрүе фәкать үзара мәхәббәткә корылган һәм ул үбешүдән ары узмаган булыр иде.

...Менә хәзер, ноябрь аенда, бер-берен яраткан ике яшь җанның ияләшеп җиткәндә генә аерылышуы гаделсезлек иде.

Кыз өендә булмады. Эштә икән. Габделнур хастаханәгә китте. Рәйсәнәне чакырып чыгарды.

Ул бик җитди иде. Күрешү дә коры гына булды.

— «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән бер авыруны китерделәр. Операциягә әзерләнәбез. Иртәгә военкоматка килермен, — диде кыз һәм кереп тә китте.

Кызның үзе кебек чиста ак халаты, зифа буе әкрен генә боегып абыйларына кайтучы Габделнурның күз алдыннан бик озак китмәде.

...Габделнур бер катлы такта баракнтан гыйбарәт булган военкомат каршында абыйсы белән сөйләшеп тора. Булачак гаскәриләр, аларны озата килүчеләр отыры военкомат тирәсенә җыела: шәһәрнекеләр — җәяүләп, авыллардан — атларда һәм әрҗәле колхоз машиналарында; гармун һәм җыр тавышлары тирә-юньгә яңгырый; кемдер балавыз сыга, кемдер бии, кемдер үгет-нәсихәт бирә; һәр егетне ата-анасы яисә туганнары белән бергә сөйгән ярлары озата. Бер урында татарча сөйләшсәләр, янәшә генә урыслар частушка сибә, мукшы авылыннан килүчеләр дә җырларын оста башкара, керәшен татарлары да алардан калышмый.

Әйе, һәркайсы үзләренә генә хас аваз-аһәңнәр белән өзгәләнеп эч серләрен бушата, уй-тойгыларын түгә. Кем белә, бәлки, кайберәүләр өчен бу туган җиреннән мәңгегә аерылудыр... Алар бит ил сагына китәләр... Шуңа җырлары да сагышлыдыр... Ә бер ишләре, бу өч көнлек дөньяга исебез китми әле, армиясенә дә барырбыз да кайтырбыз дигән кыяфәт белән, гармунга кушылып, шаян такмаклар тезә:

Әтәч менгән киртәгә,
Кикерикүк итәргә,
Әтәчкә хәбәр килгән
Армиягә китәргә.
Әтәч әйтә, бармыйм, ди,
Тавык әйтә, калмыйм, ди,
Әтәч китсә армиягә,
Бер күкәй дә салмыйм, ди...

Габделнур сәгатенә карады. Кыз киләсе юлга күз салды. Кояшсыз, авыр көн: карасу болытлар түбәнтен генә агыла, агач ботаклары җилдә чайкала. Тупыллар, өрәңгеләр яфракларын коеп шәрә калганнар. Аларның ботаклары ап-ачык күренеп тора — як-якка җәелгән куллар кебек. Һәм алар әйтә сыман: «Гафу итегез инде, без хәзер ялангач, шыксыз, матур да түгел, чөнки көзге ачы җилләр безнең бөтен гүзәллегебезне — яфракларыбызны койдылар. Без шул килеш салкын кышка керәбез инде. Кыш ничек булыр? Исән чыгарбызмы икән? Әгәр исән-сау кышны уздырсак, яз көне без тагын яфрак ярырбыз, матур кием — яшел күлмәк киярбез һәм сезне сөендерербез. Әгәр яңгырда калсагыз, без сезне үз канатыбыз астына алырбыз, куенбызга сыендырырбыз, юешләнүдән, җил-давылдан сакларбыз. Чөнки без сезне яратабыз...»

Габделнур, уйларыннан бүленеп, тагын сәгатенә карады.

Аның кыбырсып өзгәләнүен күреп:

— Борчылма, килер, — диде абыйсы Гатуф, сабыр гына.

Габделнурның баягы фикер сөреше янә күңеленә килде. Ул янә агачларга карады. «Әйе, без дә яратабыз, безне дә яраталар. Ә без киткәч ни булыр...»

Күрәсең, мондый уй бер Габделнурның гына йөрәген телгәләми. Шактый исерә төшкән бер никрут, кызын кочаклап, ныгып җитмәгән үсмер тавышы белән җырлый:

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласың;
Мин киткәч, кемнәр иркәләр
Син сандугач баласын.

Аны да юаталар, яшьле күзләрен сөртәләр...

Ниһаять, Рәйсәнәне күреп алды Габделнур. Каршына йөгереп барды, күкрәгенә кысты.

— Кеше бар бит, — диде кыз, шулай да үзе дә кочаклагандай итте.

Ул арада тезелергә боерган команда яңгырады.

Вәгъдәләр бирешү, кочаклашу, үбешү, елау-сыктау — барысы бергә буталды. Кемнәрдер кешедән дә тартынып тормый — хисләренә ирек бирә, әйтерсең мәңгегә аерылыша, икенчеләр тыйнак-тыенкы гына саубуллаша.

Автобус янында Рәйсәнә Габделнурны соңгы тапкыр бөтен гәүдәсе белән аңа сарылып, бар булган назын биреп үзе кочаклады, иреннәреннән суырып үпте дә, яшьле күзләрен күрсәтмәс өчен, башын читкә борды.

— Хуш, — диде ул, авыр сулап.

— Сау бул. Хат яз. Көт, — диде егет, өзгәләнеп.

— Ярар, — диде кыз, килешеп.

Андый чакта сөйләп сүзләр бетәме, иркәләп куллар туямы?!

Рәйсәнәнең йокысыз үткәргән төннән соң бераз сулыгып калган аксыл йөзенә кызыллык йөгерде. Кулын Габделнурның кулыннан тартып алды да йөгереп китеп барды.

...Читтәрәк берүзе автобус күздән югалганчы кул болгап калды кыз.

Ярар, дип әйтте әйтүен, ләкин егетнең хат яз дигәненә җавап идеме ул, көт дигәненәме — бу минутларда моны Рәйсәнә анык кына үзе дә белми, тәгаен дөресен дә әйтеп бирә алмас иде.

## 3

Кронштадт.

Бу исем Габделнур өчен Севастополь, Порт-Артур, Гангут, Синоп, Цусима һәм башка рус флотын данга күмгән исемнәр белән янәшә тора иде. Чөнки Хәрби диңгез флотының бик күп җиңүләре, диңгез сугышлары шушы шәһәр һәм анда яшәгән офицер-адмиралларның исемнәре белән дә бәйләнгән. Революцион матрослар турындагы кинолардан да күреп-ишетеп белә иде ул аны. Ләкин үзе шунда хезмәт итәр, аның тарих эзләре сакланган, меңләгән матрос аяклары таптаган таш һәм чуен плитәләр түшәлгән урамнарында йөрер дип күз алдына да китермәгән иде. Ә туры килде.

Әлмәт военкоматында комиссия үткәндә үк Габделнурны бик җентекләп тикшерделәр һәм бөтен табиблар да аның сәламәтлегеннән канәгать калдылар. Шул ук хәл Казанда да кабатланды. Гәрчә, космонавтларны караган кебек, энә күзеннән үткәрсәләр дә, гаеп-кыек — чир таба алмадылар. Иң кызыгы ниндидер түгәрәк урындыкка — «Барани» креслосына утыртып әйләндерү булды. Ләкин ул Габделнур өчен кызык булса да, комиссия әгъзалары өчен иң четереклесе һәм мөһиме саналган икән. Егеткә монда да тел-теш тидерерлек булмады.

— Годен!

Әйе, аны караган һәрберсе мактады. Ләкин бер кабинеттан җиңелчә генә сүгеп тә чыгарганнар иде. Озынча, ябык авызлы чиләк сыман бер савытка — спирометрга көпшәдән өргәч, капкач шикелле әйбер атылып чыкты да идәнгә төшеп китте.

— Әкренрәк өрергә ярамыймыни? — диде ак халатлы табиб.

— Үпкәсе атныкы шикелле моның, — дип сүз кыстырды икенчесе, көлә-көлә.

...Ленинград аларны чытык йөз белән каршы алды: пыскып вак яңгыр ява, томан төшкән сыман, бөтен күк йөзен карасу, түбәнтен генә агылучы болытлар каплаган. Монда кояш бөтенләй юктыр, инде бернichә көн бу шәһәргә карамагандыр, нурын чәчмәгәндер шикелле тоелса да, шәһәр үзе дә, кешеләре дә матур. Өч-дүрт катлы, һәрберсе үзенә генә хас бизәкле йортлар егетләрне тимер юл вокзалыннан хәрби частька кадәр озата бардылар.

Унсигезенче гасыр башында Петр Беренче тарафыннан Куян утравында төзелә башлаган, Фин култыгына коючы Нева тамагына урнашкан Ленинградта каналларның, күперләрнең күплеге Габделнурны хәйран калдырды. Һәм менә китаплардан укып, киноларда күреп белгән Нева — ике йөз ел башкала булып торган мәшһүр шәһәрнең мәшһүр елгасы! Габделнур елгаларны фәкать үз җаена агучы, ярлары сөзәк-комлы яки текә-балчыклы, һичьюгы — таулы дип күз алдына китерә иде. Ә монда аны гранитка төргәннәр, таш белән әйләндереп алганнар. Үзе артык киң түгел, суы караңгы төстә — коңгырт, вак дулкыннар тәгәрәшә; көймә яки катерлар да, балыкчылар да күренми; сирәк-мирәк акчарлаклар балык аулапмы яки су өстендәге ипи сыныкларынмы чүпләп йөри — түбәнтен генә оча.

Әллә кайларга хәтле сузылган булачак матрос һәм солдатлар колоннасы талгын гына аккан Нева елгасы аша салынган бөкрерәк киң күпергә килеп кергәндә яннан баручы кара шинельле офицерның катгый, яңгыравык тавыш белән әйтелгән командасы ишетелде:

— Шагать не в ногу!

Алан-йолан каранып баручы, унтугыз яшькә җитеп, үз күзләре белән күрергә насыйп булган бу шәһәрнең таш урамнарына беренче мәртәбә аяк баскан егетләр болай да тигезле-тигезсез атлыйлар иде.

Кайсыдыр авылдан аягына олтанлы киез итек киеп чыккан озынча гәүдәле бер егет, лачтыр-лочтыр атлап барган уңайга:

— Габделнур, нәрсә әйтә ул? — дип сорады. — Аяк белән атламаска кушамы әллә?

Аның соравын ишеткән бер егет көлеп җибәрде.

— Мүкәләп барырга куша.

Габделнур авыл малаен җәлләде.

— Сафта баручы солдатлар кебек бердәй атламагыз, ди ул.

— Ә нигә?

Габделнур белән Казанда ук танышкан Бөгелмә егете:

— Әгәр бөтен колонна бердәм атласа, вибрациядән күпер ишелеп төшәргә мөмкин, — дип аңлатты.

Теге авыл егете тагын нидер сорамакчы иде, кемдер аның иске бүреген башыннан тартып алды да суга томырды. Кайсыдыр Габделнурның фуражкасына да үрелгән иде, ул аны чак тотып калды. Әмма үзе аптырап тормады, тегенекен эләктереп һавага чөйде. Китте шуннан: чемоданнар, биштәр-капчыклары, бүрек-фуражкалар, тире яки йон бияләйләр, перчаткалар, телогрейкалар Невага очты.

— Тәртипсезлекне туктатыгыз! — дип кычкырды озата баручы офицерларның берсе.

Кая ул аны тыңлау: бу галәмәт елганың икенче ярына чыккач кына тукталды.

— Берегез дә колоннадан чыкмагыз, — диде чиста өс-башлы яшь өлкән лейтенант, кырыс кына.

Габделнур әле һаман алан-йолан карана; һич кенә дә үзенең бай тарихлы, ишетүенчә, безнең татар агайлар да төзешкән борынгы шәһәр урамыннан атлап баруына аның күңеле ышанмый, чын түгелдер кебек тоела. Рәсәйнең барча төбәкләреннән (1707 елдан — губерналарыннан) куып китерелгән йөзләгән, меңләгән кешеләр сазлык җирләрне корыта-корыта, һәр карышын авырлык белән яулап ала-ала, күбесенең гомерләре бәрабәренә һәркем сокланырлык шәһәр салып калдырганнар. Исемнәре билгесез ул гади крестьяннарның, осталарның инде сөякләре дә череп таркалгандыр. Ә шәһәр, гасырлар үтсә дә, юкка чыкмаган, шәһәр тора... Әйе, бу хыял да, төш тә түгел, өне икән. Әнә бит — иртә булуга һәм яңгыр төтәсләвенә карамастан — машиналар, трамвай-троллейбуслар йөри, әле болай, әле тегеләй дигәндәй, кешеләр агыла. Нинди бәхетле кешеләр бар дөньяда! Ленинград хәтле Ленинградның үзендә яшә инде! Мондый бәхет күпләргә тәтеми шул. Әнә колоннада баручы яшьтәшләренең күбесе авылдан, бер ишләре район үзәкләреннәндер, аның кебек Әлмәт яисә бүтән кечерәк шәһәрдән алынучылар да бар. Беркадәр яшьләр Казан яки Куйбышев, Сызрань яки Ульяновск кебек зуррак шәһәрләрдән.

Күперне чыкканда уң якта, еракта күтәрү краннары, озын юан торбалар һәм нәзек очлы шпильләр кукраеп калды.

Габделнур янәшәсендә атлаган авыл малае яр буендагы колонналы, иң өстә кеше сыннары булган бер йортка төртеп күрсәтте.

— Карале, теге егетнең «сөләйманы» асылынып тора.

— Кайда? — дип сорады Габделнур.

— Әнә теге өйгә, иң өскә кара.

— Соң, булгач асылыныр инде, — диде Габделнур, исе китмичә. — Шәрә ясагач, аны куймый калдырмаслар инде.

Колоннаның башы Хезмәт мәйданына барып керде. Матрос клубы янынан үттеләр. Уң якта бер катлы озын кызыл бина, ике арада — Адмиралтейский канал. Ул тар, суы яшькелт-кара.

Сул якта өч катлы кызыл кирпечтән салынган озын бина — Флот экипажы. Анда 1860 елда атаклы тупчы Матрос Кошка да хезмәт иткән. Аны гына түгел, меңләгән матросларны үз куенына сыендырган бина бу. Аскы һәм икенче катның тәрәзәләре гөмбәзле, өченчесенеке — шакмаклы, алар зур, биек. Беренче каттагыларына челтәрле тимер рәшәткәләр куелган.

— Бу — төрмә кебек икән, — диде Габделнурга Морат исемле егет.

— Әйе, чыгып качарлык түгел, — дип, аның сүзен җөпләде Габделнур.

Йорт бөтен бер кварталны биләп тора. Колонна Мойка каналындагы Поцелуев күперенә барып җитмәде, бинаның кыл уртасындагы аркага таба сулга борылды. Кызыл йолдыз һәм якорь чәпәлгән авыр тимер капкалар әкрен генә ачылды, һәм булачак гаскәриләр алагаем зур, киң ишегалдына керә башладылар... Аннары аларны казармаларга урнаштырдылар.

Ленинградта өр-яңадан комиссия үттеләр. Монда да Габделнурга Казандагы бәяне бирделәр: бик яхшы. Әйе, кергән бер бүлмәдә аны караган табиблар шул бәяне куеп чыгара тордылар. Тик иң соңгы кабинетта гына аны караган озын гәүдәле, ак халат астыннан кара төстәге хәрби кием кигән офицер-хирург медицина картасына нидер язар алдыннан, ручкасын бер читкә куеп:

— Яле, борыл да ишеккә таба бар, — диде.

Габделнур ишек катына барып туктады, борылырга кушканны көтеп калды.

Хирургның командасы яңгырады:

— Кру-гом! Ко мне!

Габделнур ялт борылды да аның каршына, өстәл янына килеп басты.

— Ә син нишләп аксыйсың?

Егет бермәл югалып калды. Табибның күзләренә туры карамыйча гына:

— Юлда, вагонда аягымны каймыктырдым, — диде.

— Сугыштыгызмыни?

— Юк, — диде егет, ашыгып. — Малайлар белән көрәшкәндә...

— Сабантуй оештырдыгыз инде... Татарлар бит... Юк, егет, мин сине су асты көймәсенә яза алмыйм.

— Ул авыртмый. Бетә ул...

— Юк, — дип кырт кисте хирург һәм өстәлдә яткан кәгазьгә тиз генә нидер язып егеткә бирде.

Аның кабинетыннан чыккач, Габделнурны бергә комиссия торган иптәшләре сырып алды.

— Нишләп озак тотты?

— Кая эләктең?
— Нинди команда?
Габделнур җилкәләрен сикертеп алды.
— Белмим.
Картада «БЧ» дип язылган иде. Ләкин берсе дә аның ни-нәрсә аңлатканын тәгаен генә әйтә алмады. Яннарыннан узып баручы, погонында буйлы озын сары тасма сузылган бер мичманга мөрәҗәгать иттеләр.
Ул кәгазьгә күз төшереп алды да:
— Яр буе частьларына эләккәнсең, бәхетең, — диде.
— Нигә алай дисез?
— Өч ел хезмәт итәсең.
Мичман китеп тә барды. Кемдер Габделнур өчен сөенде, чөнки дүрт ел урынына өч кенә ел бит, ә кемдер көенде. Хәер, көенүче Тәтеш егете Морат кына иде. Ул вагонда Габделнур белән бик дуслашып киткән иде. Үзе дүрт еллыкка эләккән.
— Болай булгач, аерылышабыз, — диде ул, көрсенеп.
Кемдер сүз кыстырды.
— Ничава, кунакка йөрешерсез.
— Юләр, — диде аңа каршы берәү. — Бу сиңа гражданка түгел. Әбиеңә коймак ашарга бара алмассың. Әле кай тирәгә эләгәсең...
Кыскасы, шул көннән эшелонда бергә килгән егетләрнең юллары аерылды: берәүләргә кара төстәге матрос киеме, икенчеләргә яшькелт гимнастерка кигерттеләр. Габделнур да соңгылар рәтендә иде.
Ул үзе моңа шатланмады да, уфтанмады да. Ләкин үрле-кырлы сөенүчеләр булды. Бер грузин егете (ул өр-яңа кара костюм, ак күлмәк һәм кара галстук, ялтыравык җәйге ботинкадан иде) өстенә яшькелт гимнастерка һәм шундый ук төстәге галифе чалбар, кирза итек киеп алгач, үзенең бөтен әйберләрен җыеп, рәхмәт укый-укый бер мичманга бирде. Күрәсең, теге аңа ничек итеп флотка эләкмәү юлларын өйрәткән булса кирәк.
Габделнурның кеше кызыгырдай киеме юк иде. Дөрес, аның замоклы өр-яңа сырган курткасы бар иде. Ләкин ул аны Флот экипажына китергән көнне үк, подвалга төшеп, андагы рәссамга биреп калдырды. Ә рәссам аларның сәгатьләренә (алар өч егет иде, икесе акча түләде) диңгез маягы һәм хәрби корабль сурәте ясап бирде.
Юантык гәүдәле, тулы битле, гражданский киемле рәссамның кечкенә тәбәнәк өстәлендә аракы шешәсе, стакан һәм кабымлык. Ул авыз эченнән гел бер көйне кабатлый:

Вэ пап, пап, вэ пап, пап.
Вэ пап, паб, ба, пап.
Все мосты разводятся,
А Поцелуев — нет.

Габделнур якташы Шишкинның монда укуын әйткәч, ул егетне кочаклап ук алды.
— О, Шишкин — гений! — диде ул, нәзек кенә пумала тоткан кулын югары күтәреп. — Син аның якташымыни?!
— Алабугада өч ел укыдым.
— Беләм ул шәһәрне, биографиясен дә яхшы беләм. Әллә үзең дә художникмы?
— Бераз гына.
— Шулай да мин сиңа бушка ясамыйм, гафу ит. Курткаңны бирәсеңме? Барыбер алып калалар... Рәсем сиңа гел юньгә туры килә...
Хәрби корабль сурәте ясап бирде. Ә подвалдан казармага күтәрелгәч, Габделнур үзенең бәләкәй чемоданын бер матрос белән баш старшина актарып маташканын күрде. Алар чемоданны тәрәзә төбенә куйганнар да, ачып, эчендә булган әйберләрне берәм-берәм бушаталар иде.
Габделнур йөгереп диярлек килде дә, аны-моны уйлап тормыйча, чемоданын тартып та алды.
— Син нәрсә, салага? — диде бескозыркасын кыңгыр салган матрос, коры гына.
— Бу — минем чемодан.
— Ә нишләп анда тиешсез әйберләр бар? — дип катгый тавыш белән сорады тәбәнәк гәүдәле, пөхтә кара киемле, погонында аркылы киң сары тасма сузылган баш старшина.
— Нәрсә?
— Менә бу!
Баш старшинаның кулында җыелмалы пластмасса стакан иде. Аның төбендә көзге дә бар.
— Бирмим. Бу — минем абыйның бүләге. Ул аны Германиядә хезмәт иткәндә алып кайтты.
Матросның да аңа күзе кызыккан иде, ахры.
— Тиеш түгел!
Ләкин Габделнур стаканны кисәк кенә тартып алды да кесәсенә салды.
— Бирмим!

Күрәсең, баш старшина үзенең хаксыз икәнен сизә иде булса кирәк, тавышын йомшартты. Нәкъ шул вакыт алар яныннан бер офицер да узып китте.

— Ярар, калдыр. Ә монысы ярамый.

Анысы Казан военкоматы янында телсез егеттән бер сумга сатып алган карточкалар җыелмасы — шәрә хатыннар сурәте иде.

— Алыгыз, — диде Габделнур һәм, ашык-пошык чемоданын җыештырып, иптәшләре янына шылды.

Ә тегеләр янына тагын икәү — икенче статья старшина белән өлкән матрос килеп калдылар һәм, тел шартлата-шартлата, карточка карарга керештеләр.

Ноябрь ахырында Татарстан төбәгендә инде кышка керү чоры була — кар ята, суыта. Ә монда әле җылы, көн саен яңгыр ява, тынчу, авырсы һава, кояш күренми — караңгы болытлар тәбәнәк күк йөзен каплап алганнар да берөзлексез талгын гына каядыр агылалар. Шуңа күрә туган ил кайда да, Кронштадт кайда икәнен егетләр чамалап та белә алмыйлар иде. Хәер, бу уй аларның башларына да керми әле. Чөнки алар Ленинградта. Ул ни җитте генә шәһәр түгел — революция бишеге, үзен мәңгелек данга күмгән «Аврора» крейсеры да шушында, тарихларга кереп калган Нева елгасы да аны аркылыга кисеп ага... Казан белән чагыштырганда аның йортлары да биегрәк, төрледән төрле орнаментлар белән чуарланган, кая карама гүзәл биналар, истәлекле урыннар...

...Команданы яр буенда зур гына үзйөрешле баржа көтеп тора иде. Кереп урнаштылар. Әкрен генә кузгалып киттеләр. Эреле-ваклы йортлар, чиркәү манаралары, шпильләр отыры артка чигә-чигә күздән югалдылар. Менә порттагы корылмалар һәм күтәрү краннары да күренмәс булды.

Өстән яңгыр ява. Аста — су, әйтерсең бөтен дөньясы фәкать судан гына тора. Каршыга күп палубалы ак төстәге теплоход килә. Ләкин ул Габделнур Чаллыда һәм Казанда күргән пароходлардан өч-дүрт тапкыр зур һәм биек иде. Еракта сылу гәүдәле, туплар белән коралланган бер хәрби корабль силуэты күренде. Ә егетләр утырган баржа бернигә карамый, бернигә исе китми алга баруын дәвам итә.

Кронштадт үзе күренгәнче аның әйләнә-тирәсендәге фортларның берсе пәйда булды. Ул урта гасырлар чорындагы замокны хәтерләтә — кечкенә генә утрауда кызыл кирпечтән корылган биек түгәрәк бина. Аның утрау икәне дә беленми, чөнки форт су эчендә утыра. Якын-тирәдә башка берни юк. Аның эчендә дә берни дә юктыр шикелле. Җан әсәре беленми. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Бу — хәрби ныгытма.

Күзлекле бер егет суга карап барды да үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Шулай да ничек бу фортларны су юып җимерми икән. Борынгы кытайлар әйткән бит: «Судан да нәфис һәм көчсез нәрсә юк, ләкин бу су бөтен нәрсәне җимерергә сәләтле».

Алда биек торбалар, ике-өч күтәрү краны һәм чиркәү гөмбәзе күренде.

Менә шәһәргә дә килеп җиттеләр. Хәрби корабльләр тезелеп торган пирстан — Усть-Рогаткадан читтәрәк, причалда баржага да урын табылды.

Егетләр тиз-тиз генә ярга чыгып, сафка тезелеп, Арсенальный тыкрыгы буйлап ары киттеләр. Уңда — тәрәзәсез, биек, озын кызыл бина (склад шикелле нәрсә), сулда бакча калды.

Таш түшәлгән, асфальт җәелгән, күбесе ике-өч катлы гына, бик сирәге дүрт катлы йортлардан гыйбарәт булган урамнардан тык-тык яисә шап-шоп атлап, Флотская урамындагы дүрт катлы бинага — Флот экипажына якынлаштылар.

Тимер рәшәткә-койма белән әйләндереп алынган ихата каршында туктадылар. Сулдагы бер катлы бинадан — КППдан — бер матрос чыгып, якорь ябыштырып куелган тимер капканы ачты. Солдатлар эчкә уздылар. Уңда кызыл кирпечтән салынган дүрт катлы казарма, сулда ике катлы йорт — клуб һәм складлар. Киң ишегалды — плац чиста, асфальты ялтырап тора. Агачлар казарма буйлап кына утыртылган, биек түгел.

Шушы минуттан төрлесе төрле тарафтан алынган, типсә тимер өзәрдәй сау-сәламәт егетләрне хәрби хезмәт үз эченә йотты, өермәдәй суырып алды.

**4**

Ленинградтагысы шикелле үк монысы да Флот экипажы дип атала икән. Шушы арада гына экипаж урыныннан күчкән, хәзер инде ул Кронштадтта төпләнәчәк, имеш.

Беренче көннәр. Каты дисциплинага корылган хәрби хезмәт. Гадәтләнмәгән кием. Режим белән генә туклану, яту, йокыдан тору. Чиратлашып швабра белән цемент идәнне ялт иттереп юып чыгару. Чиста булса да гади генә урын-җир. Илнең төрле төбәкләреннән җыелган, бүтәнчә холык-фигыле, фикерләү рәвеше һәм сөйләме булган милләт вәкилләре. Беренче көннәр — солдат тормышының иң читен вакытлары. Шулар өстенә — сагыну. Анысы инде яшеңә дә, милләтеңә дә, саулык-тазалыгыңа да карамый — барың өчен дә уртак хис. Әле тагын бертөрлелек, кемгәдер буйсынырга мәҗбүр ителү, тар даирә — болар да зур сынау, җанны кимерә.

Һәм тагын бер нәрсә — гаделсезлек. (Монысы яшь солдат күзлегеннән караганда, билгеле.)

...Сафта йөргәннән соң таралырга һәм казармага керергә рөхсәт бирелде. Ләкин Габделнур, гөнаһ шомлыгына каршы, дияр иде әбисе, керәсе килмичә, дөресрәге, урамга күз салу нияте белән КППга таба атлады. Капка янына килеп басты да башта каршыдагы ике-өч катлы сары йортларга, аннары күз күреме җиткәнче әле уңга, әле сулга урамга карады. Озак кына уйланып торганнан соң борылып китеп барды. Каршына сул беләгенә

кызыл повязка бәйләгән, часть буенча дежур офицер килә иде. Ул алан-йолан карана, күрәсең, ихатада тәртип барын-югын тикшерә иде. Менә ул Габделнур белән тигезләште.

— Рядовой, туктагыз, — диде офицер һәм аяк астына төртеп күрсәтте. — Тәмәке төпчеген алыгыз.

— Мин тартмыйм, иптәш лейтенант.

— Барыбер күтәрегез!

— Алмыйм, — диде дә Габделнур йөгереп казармага кереп тә китте.

Кичке сәгать ун тулганда ротаны сафка тезделәр. Командир белән янәшә часть буенча кизү офицер да тора иде. Габделнур нидер сизенеп куырылып куйды. Юкка булмаган икән: офицер плацта үзеннән качкан солдатны таныды һәм капитанга нидер әйтте.

Рота командиры, коры гына:

— Рядовой Гаделҗанов, сафтан чыгарга! — дип әмер бирде.

Лейтенантның да чырае кырыс, тавышы каты иде:

— Ну-ка минем белән киттек!

Габделнур урыныннан кузгалмады.

— Кая? Нәрсәгә?

Ротный:

— Синме тәмәке төпчеге алмаучы? — дип сорады.

— Әйе. Мин бит тартмыйм.

Сафтан берәүнең теләктәшлек күрсәткән авазы ишетелде:

— Иптәш капитан, ул чыннан да тәмәке тартмый.

— Отставить разговоры! — диде рота командиры кискен рәвештә һәм Габделнурга карап әйтте: — Сез үзегезнең кайда икәнегезне оныттыгызмы әллә? Монда тәртип гражданкадан үзгә: белмәсәгез — өйрәтербез, теләмәсәгез — мәҗбүр итәрбез. Аңладыгызмы? Рядовой Гаделҗанов, часть дежурные артыннан шагом марш!

Габделнурга алагаем зур ашханәнең идәнен юарга, бер миски суган чистартырга туры килде. Аннан соң кизү бүлмәсенә кереп эш бетерүен әйтте һәм унике тулганда гына казармага кайтты.

Габделнур янәшәсендәге солдат уянды.

— Кайттыңмы?

— Әйе.

— Карале, ул синнән, бу кем төпчеге, дип сорамадымы?

— Юк. Тәмәке төпчеген алырга гына кушты. Нигә сорыйсың?

— Бер мәзәк искә төште. Генерал килә тикшерергә. Плацта йөргәндә бер тәмәке төпчеге күрә. «Кемнеке бу?» дип өч тапкыр сорый. Дәшмиләр. Шунда бер җор телле солдат әйтә: «Иптәш генерал, иясе юк, алыгыз».

— Миңа да шулай әйтәсе калган, — диде Габделнур, көлеп. — Аннан нәрәт биреп кенә калмас, өч тәүлеккә губага ябып куяр иде.

Ул чишенде, урын-җирен бүсте. Ләкин тиз генә йоклап китә алмады. Дежурныйга үпкәләп, хәтере калып, озак кына рәнҗеп ятты. Нигә ул кемдер ташлап калдырган шакшы төпчек чүпләп йөрергә тиеш? Кем ташлаган, шул җыйсын иде. Аннары икенчерәк төрле уй баш калкытты: армия һәм дисциплина — аерылгысыз. Әйе, офицер, командир сүзе үтәлергә тиеш. Хаклымы ул, түгелме — аны тикшерү хокукы солдатка бирелмәгән...

Ләкин еллар үткәч, азмы-күпме дөнья күргәч, хәрби хезмәтнең әүвәлге чордагы кыенлыгы онытыла төшәчәк. Бик хәтәрләре генә истә калачак. Әлбәттә, әле кичә генә иректә булган, ә хәзер калын табанлы олы кирза итекләре белән көненә дүртәр сәгать буена асфальт таптап сафта йөрергә мәҗбүр ителгән таза егетләрне иң нык борчыганы ашау җитмәү. Югыйсә ашаганнары юклы-барлы ризык түгел: шулпалары да төрле-төрле (әчегән кәбестә эштие сирәк бирелә), икенчегә итле токмач, ботка яки балык белән бәрәңге, мае-шикәре, өченчегә компот ише туклыклы нигъмәтләр. Ләкин кысан нормаларга өйрәнмәгән, гел хәрәкәттә булып торган яшь организмга көненә өч тапкыр ашатсалар да барыбер җитми. Өйдән биреп җибәрелгән тәмле ризыкларның валчыгы да калмаган, кесәгә салынган акчалардан да күптән җилләр искән. Үзбәк егетләре кебек, сәгать саен буфетка кереп, ап-ак йомшак булка белән чәй эчәр идең югыйсә. Хәер, аларның чәйгә әвәслеге, бердән, кесәләре әле бушамаганнан килсә, икенчедән, дуңгыз ите салып пешерелгән ризык капмаудан иде. Габделнурга аларның тәмәке тартмаулары да сәер тоелды. Ул ни өчендер Урта Азиядәге барча ир-егетләр дә тәмәке белән көлгә дөя тизәге кушылган насвай кулланалар дип уйлый иде.

Беркөнне Габделнур үзе шикелле берничә яшь солдат белән кухняга эләкте.

Монда аны камбуз дип йөртәләр. Аңа казарма аша кереп-чыгып йөрисе, чөнки ул аның артында, шулай ук кызыл кирпечтән төзелгән ике катлы иске бина. Сул ягында озын торбалы котельная.

Бәрәңге чистартып, аларны идән уртасындагы сулы зур кәстрүлгә ташлаган арада, ул алан-йолан каранды: кайда нәрсә ятканын чамалады. Эшләрен бетереп, казармага кайтканда, ул Казан арты егете Хөрмәтне читкәрәк тартты.

— Тагын камбузга дәшсәләр, сало сугарга кирәк.

Коры җир булса да, монда, корабльләрдәге кебек, гамәлдәге флот сүзләре күп кулланыла иде. Әйтик, камбуздан тыш әле поварны да кок дип кенә җибәрәләр, бәдрәф туалет түгел, гальюн, казарма — кубрик һәм башкалар. Беренче көннән үк Габделнурлар да ул атамаларны эләктереп алдылар.

Җәлпәгрәк борыны астына яңа гына мыек чыгып килүче Хөрмәтнең күзләре очкынланып китте.

— Аны мин дә уйлап йөри идем. Без болай коры сөяккә калырбыз.

Хөрмәт — төптән юан, уртача гәүдәле таза егет, көрәшчеләр нәселеннән. Аның тулышып торган кызгылт бите соңгы көннәрдә бераз сулыга башлады. Шулай да алар — Хөрмәт, Сергач мишәре Атаулла, Ырынбур өлкәсе егете Шәрип, Габделнур һәм тагын берничә татар егете — көн саен спортзалда көрәш оештыралар.

Хөрмәт, яшь булуына карамастан, ике ел рәттән авыл сабан туенда батыр калган, кечкенәдән үк көрәш кагыйдәләрен һәм аның рәтен белә. Намуслы көрәшә. Габделнур белән Шәрип тә таза егетләр, ләкин алар көрәш алымнарын белмиләр.

— Сез көчле, тик сезнең белән көрәшүе читен, — ди Хөрмәт, көлеп. — Нинди приемга каршы торырга әзерләнәсеңне белмисең. Күкрәккә дә төшәсез, алай ярамый. Оста көрәшчеләр бер-берен саклыйлар, ә сезнең белән имгәнүең дә ихтимал.

Шулай дисә дә, ул алар белән озак маташмый — матрас шикелле калын маталар җәелгән идәнгә ларсылдатып сала. Тегеләр саннарын җыя алмыйча яталар.

Ә менә Атаулладан ул алай җиңел генә котыла алмый.

— Син аяк чалма, — ди ул, аптырагач.

— Мин аңгара алмыйм, берцәк, ницек үрәнгән, шылай көрәшәм, — ди Атаулла, үпкәләп. — Шкулда укыганда да шылай көрәштек, сабантуйда да. Син көрәшмәк keләмисең, шкураңны жәллисең.

— Ә, әле шулаймы?! Хәзер мин сине...

— Бик куркындым инде... Багып багарбыз...

Төптән юан Хөрмәт белән чандыр гәүдәле, ләкин бик елгыр Атаулла җан-фәрманга кызып китәләр — спортзалның түшәменә хәтле тузан күтәрелә.

Аннан егетләр, бераз хәл алгач, ике потлы ике герне чөеп уйныйлар, бер-берсе белән ярышалар.

— Во татары дают! — дип, әледән-әле тел шартлата ачыг- авызлар.

Дөрес, матрослар арасында да таза егетләр бар. Берсе, кап-кара чәчле, еш кырынудан яңаклары, ияге зәңгәрләнеп торган матрос, берчак аларга үзенең көчен күрсәтте.

Солдат-матрослар дәррәү җыелып, беравыздан, түшәм җимерердәй булып, хор белән кычкырып санап егетне дәртләндереп торды.

— Өчәү... бишәү... унау...

— Санап кына өлгер, — диде Шәрип, башын чайкап.

— Доа, атот, — дип шаккатуын белдерде Атаулла да.

Унбишкә хәтле күтәрде дә, карап торышка какча чырайлы күренгән матрос герләрне иләп кенә цемент идәнгә куйды һәм кара чалбарының киң балакларын каккалап китеп барды.

Кемдер шулчак:

— Ул дисбаттан кайткан, өенә җибәргәнне көтә. Алты ел хезмәт иткән, — дип әйтте.

Яшьләр бөтенесе аптыраушта калды: ничек, матрослар дүрт кенә ел хезмәт итә бит. Менә шунда Габделнур беренче мәртәбә дисбат дигән сүзне ишетте. Тәртип бозган, җинаять кылганнарның кайберләрен гауптвахта яки төрмәгә генә утыртмыйлар, ә дисциплинарный батальонга да җибәрәләр икән. Теге матрос су асты көймәләренә каршы торучы корабльдә дүрт елын хезмәт итеп кайтырга әзерләнгән көннәрдә, команда старшинасы белән телгә килә, аңа суга һәм... тагын ике ел мәҗбүри рәвештә хезмәт итә.

Әйе, матрослар арасында аңардан битәр дә куәтле егетләр бар иде. Безнең егетләр дә гайрәтле, киң күкрәкле (чөнки дүртесенең берсе дә тәмәке тартмый) — ашау гына җитми.

Беркөнне тагын камбузга, Атаулла әйтмешли, картуф әрчергә баргач, пешекчеләр чыгып киткән арада, Габделнур белән Хөрмәт уртача калынлыктагы китап зурлыгында дуңгыз салосы чәлдерделәр. Габделнур, тиз генә урамга чыгып, аны кар эченә тыгып керде.

Эш беткәч, казармага кермичә, дүртәүләп ишегалдының түренә киттеләр.

— Мә, тозла, — диде Шәрип, кесәсеннән шырпы кабы чыгарып.

Габделнур, каптан учына тоз салып, ышкый-ышкый, аны салога сеңдерде. Таш диварга күз салды. Шактый биектә бер уенты бар иде.

— Шәрип, син озынрак, минем җилкәгә менеп бас та әнә теге куышка яшереп куй, — диде Габделнур.

Ул иелгәч, Атаулла Шәрипне бер кулыннан тотыбрак торды. Габделнур көчкә тураеп басты.

— Буең җитәме?

— Җитә, — диде Шәрип һәм, салоны урнаштыргач, Габделнурның иңбашыннан сикереп төште. — Кар белән каплаштырдым.

Монда йортлар да, ихата диварлары да бер метр калынлыкта кызыл кирпечтән корылган иде. Сугыш вакытында снаряд кыйпылчыклары тиеп, күп урында уентылар хасил булган. Шуларның берсенә менеп урнашты сало. Һәм өч көннән тагын камбуздан суккан арыш ипие белән егетләр сало ора башладылар.

Ипине Хөрмәт юнәткән иде.

— «Белинский» булмады, «чернышевский» гына, — диде ул, буханканы юантык кыска бармаклары белән сындырып.

— Ярамаган татарга каз ите, — дигән булды Шәрип, ипи белән аралаштырып сало чәйнәп.

Солдатлар арасында ак ипи — «белинский», арыш ипие — «чернышевский», ә чәй «чайковский» дип йөртелә иде.

— Моның янына мунча аракысы да булса, — диде Атаулла, уфтанып.

— Анысы нәрсә тагын? — дип сорады Габделнур.

— Нәстә булсын, самогон, — дип көлде Атаулла, шуны да белмәскә дигән сыман. — Аракы тугайтмый, канишны.

— Сүләп торасың тагы, — диде Шәрип аны ирештереп, «сүләп» сүзенә басым ясап.

— Ә син мине үртәмә, мин кочык түгел. Болай гына эттем, кәбәм.

— Ярар, үпкәләмә, — диде Шәрип, дустының җилкәсенә кулын куеп. — Ә тегене бездә «төнге көмешкә» диләр.

Бер үзбәк егете, боларның дуңгыз мае бүскәннәрен күреп, чүт кенә косып җибәрмәде. Ләкин... тамак тәмугка кертер, ди...

Үзбәкләр исә, плацка чыгып сафта йөргәч, унбиш минуттан отделение командирына ялына башлыйлар. Командир, карадан киенгән булса да, сержант званиесендә.

— Товарищ сержант, я замез.

Бүрек колакчыннарын төшерү дә ярдәм итми көньякның җылы, иркә кояшында үскән малайларга. Алар туңудан хәрефләрне тутырып әйтә алмыйлар, шуңа күрә сүзләре өтек-сөтек килеп чыга.

— Зур Себергә караганда бәләкәй Ташкент яхшырак, — дип үчекли аны сафта кемдер.

Нишләсен, сержант та адәм баласы — хәлләренә керә.

— Бар, алайса, Хамракулов, җылын.

Мескен солдат йөгереп кереп китә. Ә биш минуттан сержантның командасы яңгырый:

— Хамракулов, чык! Син бар, Бәйрәмкулов!

Ишектән кергәч тә коридорда җылылык батареясын кочаклап торганы тышка чыга, аны урамнан йөгереп кергәне алыштыра. Ә Габделнурлар, кып-кызыл булып, тирләп-пешеп, тырыша-тырыша сафта йөрү күнекмәләрен үзләштерәләр.

Үзбәк егетләре бергә укмашыбрак, бүтәннәр белән аралашмыйчарак яшәргә тырышсалар да, татарларга мөнәсәбәтләре уңай иде. Шуңа күрә беркөнне Габделнур һәм тагын дүрт-биш татар солдаты алар белән сөйләшеп-гәпләшеп утырдылар. Моңа башта Шәрипнең, аннары Габделнурның баянда уйнавы сәбәпче булды. Ул бер-ике урыс көе уйнагач, татарча «Шахта», «Рамай» кебек моңлы җырларга күчте. Аны солдатлар сырып алды, арада үзбәк егетләре дә бар иде. Күрәсең, безнең җырлар аларның да күңеленә хуш килде, бәлки, кайберләренә кечкенәдән үк таныштыр: Урта Азиядә татар кешесе яшәмәгән шәһәр түгел, кышлак та юктыр.

Сүз, әлбәттә, ашау-эчүдән башланды. Аннары өй, гаилә хәлләренә күчте.

— Сезнең арада төрле елгылар күп, өйләнгәннәр дә бармы? — дип сорады Габделнур, гармунын бер читкә куеп.

— Юк, — диде барысы өчен дә үзбәкләргә бигүк хас булмаган озынча ябык гәүдәле, каратут йөзле, кара кашлы Халмурадов фамилияле егет. — Хале без хезматтан киген тиз уйланмеймиз.

— Нишләп? — дип сорады Хөрмәт, аптырап.

Уртача буйлы, табак битле Хамракулов атлысы:

— Атам-анам хал кыладе, — диде. — Чунки алдын безлорда өй-җайне кыладе, киген уйланаде.

— Үзбәк башта малаен үстерер өчен эшли, аннары — өйләндерер өчен, — диде Шәрип, бик белдекле кыяфәттә.

— Бездә дә элек шулай иде, хәзер әти-әнидән бик сорап тормыйлар, өйләнәләр, — диде Хөрмәт, тигез ак тешләрен ялтыратып көлеп.

— Бездә — юк, — диде тәбәнәк гәүдәле Бәйрәмкулов, башын чайкап. — Безлорда туй катта буладе, миһманнар киладе. Узбекда икки катта байрам: туй белән суннат.

Шәрип көлеп җибәрде:

— Ә сез барыгыз да сөннәткә утыртылганмы?

— Һа. Угыл баланы бер, уч яки биш яшьтә суннатлашаде. Җудо катта байрам: кариндаш-уруглар хархилбуюм яки пул совга кыладе.

— Ә кызның ата-анасына калым биреләме? — дип сорады Атаулла.

— Һа. Туй икки-уч кун буладе, шунча миһман чакырыладе: кариндаш-уруглар буладе, махалла кешеләре белән туй кыламыз. Пул хам җудо күп кирәк.

— Бөтен эш акчада икән. «Пүл, пүл, пүл, пүлгә карап үл» ди торган иде сезнең якларда йөреп кайткан бер зимагур абзый, белеп әйткән икән. Алайса, сезнең өйләнә алмыйча кырыкка да җитүегез ихтимал, — диде Хөрмәт, тегеләрне кызганып.

— Берәр татар кызын эләктерсәләр генә инде, — диде Габделнур, якташына күз кысып. — Безнең авылның ике-өч кызы Үзбәкстанда кияүдә. Берсенең дә әти-әнисенә калым түләмәделәр. Так что, әле сезнең безгә әҗәтегез бар икән... «Катта рахмат» белән генә котыла алмыйсыз...

...Авылыннан чыкмаган кеше, тик яткан таш шикелле мүкләнеп, бертөрлелеккә иялә. Тормыш гел шулай гына барадыр кебек тоела аңа. Аны чолгап алган мохит тар, кешеләр санаулы. Ул инде аларның барысын да

белә, аларга ияләнә. Һәрхәлдә, аның даирәсен ничәмә-ничә еллар гел бер үк кешеләр чолгап алган була, тормыш та бер агымда гына диярлек йокысын китерерлек итеп кенә, тирбәлеп агып бара. Хәлбуки, авылыңнан чыгып китсәң, тормыш — ярсу елгадай. Көн саен булмаса да, еш кына син төрле җирләр, сала-калалар белән танышасың.

Габделнур, Әлмәттән чыгып киткәч, байтак шәһәрләр, ят җирләр күрде.

Читтә аның кешеләре дә төрледән төрле. Бераз гына «шомарган таш» булса да, Габделнур да Кронштадтта яшь сугышчы курсын узганда бу фикернең хаклыгына инанды. Чөнки кемнәр генә юк иде алар ротасында! Егетләрнең күбесе унтугыз яшьтә, хәрби хезмәткә чакырылу вакытлары җиткәч солдатка алынганнар. Ә менә Сарьев фамилияле берәү алардан алты яшькә олы иде. Аның яшьтәшләре хезмәт итеп кайтканга да өч ел үтеп киткән. Сарьев — грек кавеменнән.

— Мин укыганда география фәнен бик ярата идем, — диде аңа Габделнур. — Грецияне кайдадыр Әдрән диңгез буенда дип белә идем. Ә син — Ставропольдән.

Ни хикмәттер, Сарьев ачылып китте, койкасыннан торып утырды. Ул уртача буйлы, тулы гәүдәле, яңак-ияген кара төк баскан, иртән кырынса, кичкә тагын үсеп чыгалар, күкрәк һәм беләкләре генә түгел, кул аркаларына хәтле йонлач.

— Мин Грецияне белмим дә, анда булганым да юк. Безнең бабайлар да Ставрополь краенда яшәгән.

— Ә син грекча беләсеңме соң?

— Беләм, билгеле. Өйдә ана телендә сөйләшәбез, мәктәп тә булган, япканнар гына.

— Ә нишләп армиягә соң киттең?

— Туры килде инде... Ә син Ставрополь краенда татарлар яшәгәнен беләсеңме?

— Юк.

— Анда бер авылның исеме үк Татарка. Шәһәрдән унбиш чакрымлап кына бугай. Мин — нефтяник. Нефтекамск шәһәре тирәсендә дә бер татар авылы бар иде.

Габделнур үзенең дә һөнәре нефтькә бәйләнешле булуын әйтте. Бераз гәпләшеп утыргач, ул сүзне кабат элекке эзгә төшерде — үз халкы тирәсенә әйләнеп кайтты.

— Кызык, алар аралашып беткәндер инде башка халыклар белән, — диде Габделнур һәм аннары әйтергәме-юкмы дигәндәй уйланып торды да, тәвәккәлләде: — Сезне дә бит: мама — турок, папа — грек, а я русский человек, диләр.

— Ишеткәнем бар, — диде Сарьев Габделнурга, үпкәләмичә. — Ләкин минем икесе дә грек, үзем дә.

— Мин дә татар, — диде Габделнур, Сарьевның хәтерен калдырмавына сөенеп.

Габделнур аның армиягә ни өчен соң китүен тагын сорашмакчы булган иде, тыелып калды, төпченеп тормады. «Үз хәлен үзе беләдер», — дип уйлады.

Сарьев казармада күп вакытын койкага сузылып ятып, дәшмичә үткәрә. Занятиеләрдән буш вакытта, билгеле. Ул, кулларын баш астына куеп, чалкан ята, сирәк сөйләшә, ә солдатлар белән бөтенләй диярлек аралашмый. Бүген үзе белән сөйләшеп китүенә Габделнур сәерсенде хәтта. Чөнки ул өченче елын хезмәт итүче солдатлардан да дүрт яшькә олырак бит инде. Аның өендә хатыны, баласы калган. Шуларны уйлый идеме ул (хәер, анысы да булгандыр), башка нәрсәнеме, берәү дә анык кына белмәде. Ниндидер грек егетенең гомумән үзләре белән бер елда хәрби хезмәткә алынуы да Габделнурга аңлашылып бетми иде. Кайчагында отделение командиры яки икенче бер сержант аңа кисәтү ясый:

— Сарьев, урын-җиргә ятма.

Солдатның калын кашларында бер бөртек тә селкенми.

— Фәлән җиргә кит, — дип, ул аларны аты-юлы белән өч хәрефкә җибәрә.

Баштарак мондый әдәпсезлеккә җен ачулары чыкса да, олы яшьтә һәм гаиләле икәнен исәпкә алыпмы, әллә һәрчак уйчан булгангамы — кече командирлар аңа каты бәрелмәскә тырышалар иде бугай.

Алар взводында тагын бер гаҗәп солдат бар иде. Габделнурларның яшьтәше Хромов иске дин кешесе булып чыкты. Башта моны берәү дә сизмәде, белмәде. Ул солдатлар белән бергә занятиеләргә йөри, ашханәдә туклана, бер үк казармада ятып йоклый. Ә шулай да күзәтүчән кешегә сизелми калмый бит.

Беркөнне кич белән Габделнур, энә-җеп алып, гимнастерка якасына яңа ак ситсы-подворотничек тегеп мәш килә иде. Аның белән янәшә койкада каеш аелын чистартып утыручы Соловьев фамилияле солдат сүз башлады:

— Сиңа бер әйбер әйтим әле, — диде ул.

— Нәрсә?

— Безнең Хромов икенче тапкыр инде киноның бармый.

— Ничек? — дип сорады Габделнур, энәсен кулыннан төшермичә генә аңа карап.

— Белмим. Теге көнне дә әйттем — бармады, кичә дә.

Хромов Габделнурдан бер койка аша гына ята, Соловьевка ул да күрше иде. Әле үз урынында күренми.

Габделнур белән Соловьевның сөйләшүен алар янына килгән Хөрмәт тә ишетте.

— Хромов иртән юынмый да бугай, — дип әйтеп салды ул.

Өчесе дә аптырашта калдылар. Гаҗәп хәл иде бу. Ышанасылары да килмәде. Тиктомалдан кешегә бәйләнеп тә булмый. Күтәргә дигән карарга килделәр. Бер-ике көн күзәткәч, чыннан да Хромовның юынмавы ачыкланды. Соловьев моны тагын берничә егеткә тишкән.

Солдатка кызык кына булсын: ике-өч көн күзәтеп йөрделәр дә, иртәнчәк Хромовны күтәреп, юынгычның озын калай ялгашына илтеп салдылар, ә кичен, ике ягыннан икәү култыклап, казарма каршындагы ике катлы бинаның аскы катына — клубка кино карарга алып керделәр.

Ул, еларга җитешеп:

— Миңа ярамый, мин — старовер, белсәләр, мине үтерәләр, — дип, серен чишәргә мәҗбүр булды.

— Курыкма, — диде Соловьев, аның аркасыннан кагып. — Монда синең авылдашларың юк бит.

Шуннан соң Хромов иртән кеше рәтендә юына һәм башкалар белән бергә клубта кино карый торганга әйләнде.

Озынча буйлы, мокыт кыяфәтле Хромовның сөйләшүе дә кызык иде: «эти» диясе урынга ул «энти» ди, «этот» дип әйтәсене «энтот» ди.

Соловьев, Хромовны шефлыкка алгандай, гел үзе белән ияртеп йөртә башлады. Беркөнне алар икесе Габделнур янына килделәр.

— Мин Хромовны бер кыз белә таныштырмакчы булам, хат язып бир әле, — диде Соловьев.

— Нинди кыз белән?

— Үзебезнең авылныкы. Аның йөргән кызы да булмаган икән әле. Әйдә бергәләп языйк әле.

Габделнур, чынлапмы дигәндәй, Хромовка күтәрелеп карады. Тегесе кызлар кебек кызарынды, авыз эчендә ботка пешереп, нидер әйтте.

Габделнур Соловьевтан кызның исемен генә сорады да, бөтен шартын китереп, беренче биткә томшыкларын терәшкән күгәрчен сурәтләре ясап, сүз арасына җырлар кыстырып, аларга ике битлек хат язып бирде. Аны кычкырып укыгач, Хромов янә кызарды, шулай да канәгать икәне күзләрендә, ирен читендәге елмаюында чагыла иде.

— Рәхмәт, — диде ул.

— Үз кулың белән күчереп яз. Монысын үзеңдә калдыр. Мин сиңа һаман-һаман язмам. Юкса кыйбатка төшәрсең, — дип шаяртты Габделнур.

Соловьевның аңа гозер белән мөрәҗәгать итүе тикмәгә генә түгел иде. Чөнки Габделнур көнаралаш хат ала, үзе дә еш яза. Моны барысы да беләләр.

Яшьтән үк өеннән чыгып киткәнгә күрә ул хатларны һич иренмичә яза, җавап килсә, кош тоткандай шатлана иде. Хатлар аны авылы, әти-әнисе, туганнары, дуслары белән бәйләп торучы ышанычлы, өзелмәс ефәк җеп иде. Әлмәттән дә, еш булмаса да, хатлар килә. Сөеклесеннән килгәне аеруча күңелне җилкендергәне була иде.

...Габделнур Рәйсәнәдән бүген килгән хатны кулына алды. Хаттан борынны кытыклап торучы ят ис килгән шикелле булды. Ләкин бу ислемай исе түгел. Әйе, чынлыкта ул Габделнур ярата торган, авыл әбиләре теле белән әйтсәк, бүлнис исе иде. Бу ис кызның чәчләреннән дә тарала, Габделнур Рәйсәнәнең үзенә сиздермичә генә бу баш әйләндергеч тәмле исне рәхәтләнеп сулый, үзенә сеңдерә иде. Чөнки ул аның яраткан кызының, сөйгәненең шомырт кара чәчләреннән килә иде бит...

Шуны тою, истәлекләргә бирелү егеткә шулхәтле рәхәт булып китте ки, ул күзләрен йомды. Сагынуын ничек басарга белмәде... Күрәсең, Рәйсәнә бу хатын эштә, дежур торганда язгандыр... Егет күзләрен ачты. Янә бер мәртәбә хатның кечкенә хәрефләрдән тезелгән тыгыз юлларын укып юанды: «Үзем беркөе генә яшәп ятам. Аһ итәрлек үзгәрешләр юк. Яңа ел да килеп җитте. Сизми дә калдым. Гомер бигрәк тиз уза инде: әйләнеп карасаң, сәгать йөргән шикелле үтеп кенә тора көннәре... Синсез ямансу көннәр... Фотомны салам... Матур чыкмады».

Габделнур, хат укудан туктап, янә карточканы кулына алды, йотылып Рәйсәнәнең йөзенә текәлде. Матур булмыймы соң?! И бу кызларны... Кыланчыкларны... Ә артына ни дип язган бит:

Идел дулкыннары җем-җем итә,
Ай нурлары балкып торганда;
Мин бәхетле шундый өзелеп-өзелеп
Юксынырлык кешем булганда.

Габделнур үзе турында: «Ә мин синнән дә бәхетле, сөеклем, — дип уйлады. — Син дә мине яратасың бит. Их, бер кайтып күрәсе иде! Бар, җәяү кайтып кит, дисәләр, ике дә уйламас идем...»

...Декабрь, гыйнвар, февраль айлары Кронштадтта иң хәтәр вакыт: Котлин утравы диңгездән — Фин култыгының һәр тарафыннан искән барча ачы җилләрне кабул итә. Кар явамы, буран котырамы, чатнама суыкмы — солдат-матрос үз эшен эшләргә — ил сагында торырга тиеш. Ләкин аңарчы ул әле яшь сугышчы курсын үтәргә — төз атлап сафта йөрергә һәм кулына мылтык тотарга өйрәнергә, химик һәм атом-төш коралларыннан саклану чараларын үзләштерергә, аннары белгеч буларак осталыгын арттырырга, сәяси яктан чыныгырга тиеш. Боларның барысына да фәкать көн саен даими рәвештә күнегүләр ясап һәм белем эстәп кенә ирешергә мөмкин.

Соңгы көннәрдә Габделнур һәм аның иптәшләре дүртәр сәгать сафта йөриләр: аяк табаннары ут яна. Чолгавыңны ашык-пошык урасаң, бармаклар суелып бетә; отбойдан соң йокыга китә алмыйча иза чигәләр... Аларны смотрга әзерлиләр.

Җитмәсә, Габделнурны иң алга куйдылар. Югыйсә аңардан бер башка диярлек озын Белобродов фамилияле солдат бар иде. Ул егетнең буе ике метрга якын. Ләкин ике норма ризык бирергә ике сантиметр җитми. Өстәл артына утырып иптәшләре порциянең яртысын да ашарга өлгерми, ул инде миски тотып «амбразура»ны каплый.

— Өстәмә бирегез әле, — ди ул һәм үзенчә шаярткан була: — Сыеграгын... казан төбеннән.

Бик ялынгач, камбуздагы егетләр хәленә керәләр — савытына ботка салалар.

Менә шул егет сафта иң алда йөри иде. Күрәсең, Габделнурның аяк атлавы күңеленә хуш килгәндер, рота командиры — ыспай җиңел гәүдәле, һәрвакыт диярлек кызу-кызу атлап йөрүче офицер — беркөнне аларның урынын алыштырды.

— Гаделҗанов, алга чыгып бас, — диде капитан, читтән генә солдатларның сафта йөрүен күзәтеп торганнан соң. — Ә син, Белобородов, аның урынына.

Ант кабул итү көненә Ленинградтан адмирал киләсе, дип сөйләнәләр иде. Һәр командирның үз кул астындагыларны югары башлыкларга яхшы яктан гына күрсәтәсе килү гадәти хәл. Күркәмрәк сыйфатлы солдатларны, ышанычлы белгечләрне һәрчак шулай алгарак «этәрәләр».

Солдат тормышының иң мөһим тагын бер тармагы — ил сакчыларын идеологик яктан тәрбияләү, чыныктыру. Моның өчен һәр подразделениедә сәяси хезмәткәрләр штаты бар.

Майор Каргиев — озын гәүдәле, каратут йөзле, калын кашлы, тулы битле кеше. Өстендә кара кием, ләкин ул диңгез офицеры түгел, чөнки кителенең җиң очында алтын сыман саргылт тасмалар юк. Шуңа күрә ул өченче ранг капитаны түгел, ә майор дәрәҗәсендә. Аларны үзара шаяртып, два просвета и одна звезда, диләр. (Сүз уңаенда әйтик: матрослар арасында икенче статья старшинаны да, старшина следующей статьи, дип шаярталар.) Кайдан ул, нинди уку йорты бетергән — болары Габделнурлар өчен караңгы иде, әлбәттә. Ләкин ул үз эшен белеп, яратып башкара. Сөйли башласа, сәгатьләр буе авызына каратып тора ала: һәр сүзе дәлилләнгән, ышандырырлык. Ул фикерләрен тыңлаучыларның күзенә карап әйтә.

— Кораллы көчләрдән башка дәүләт ул кабырчыксыз ташбакага тиң, — дип башлады ул беренче политзанятиесен. — Ә Советлар Союзының Хәрби диңгез флоты — кабырчыкның үзәк өлеше. Сез үзегезнең флотта хезмәт итүегез белән горурланырга тиеш. Чөнки Хәрби диңгез флоты ике йөз илле ел эчендә үзен данга күмде. Патша Россиясенең Бояр думасы мең алты йөз туксан алтынчы елның утызынчы октябрендә карар чыгара: «Морским судам быть». Шул чордан бирле диңгезчеләр үзләрен, кабатлап әйтәм, данга күмделәр. Макаров, Нахимов, Ушаков һәм башка адмиралларның осталыкларын, матросларның һәм офицерларның батырлыкларын барыгыз да ишетеп беләдер булыр.

Кронштадтта адмирал Макаровка һәйкәл дә бар икән. Габделнур аны соңрак күрде.

— Рус флотының диңгездә иң беренче җиңүе 1714 елның 7 августында була. Петр Беренче командалык иткән флот шведларны Гангут борыны янында җиңүгә ирешә. Аннан соңгы диңгез алышлары — дистәләгән, моряларның ул орышларда күрсәткән батырлыгы — тиңдәшсез. Мәсәлән, 1904 елның 9 февралендә, рус-япон сугышының беренче көнендә, — дип дәвам итте сүзен замполит, — ундүрт корабльдән торган япон эскадрасы безнең «Варяг» крейсерын һәм «Кореец» канонеркасын чолгап ала, ультиматум куя: «Бирелегез!» Әмма безнең куркусыз моряклар алар белән каһарманнарча сугыша башлыйлар: бер миноносецны батыралар, ике крейсерга зыян салалар. Безнең дә йөз егерме ике матрос һәм офицер һәлак була. Калганнары, корабльләрне дошман кулына төшертмәс өчен, «Варяг»ны батыралар, канонерканы шартлаталар.

— Без бит корабльдә хезмәт итмәячәкбез, — диде солдатлар арасыннан кемдер.

Ләкин батыраеп сүз каткан кыю солдатның да авызын тиз томалады майор:

— Әйе, сез су асты көймәсендә дә, крейсер яки торпеда катерларында да булмассыз. Кстати, сез беләсезме су асты көймәләренең кайда һәм кайчан төзелә башлаганын? 1704 елның ноябрендә Петр Беренче Адмиралтейский верфькә нигез сала. Верфьтә төзелгән беренче суднолар — галералар була. Аларны Төньяк сугышта файдаланалар. Менә шул верфьтә Ефим Никонов «Потаенное судно» дип аталган кораб төзи, хәзерге су асты көймәсенең прототибын. Су асты көймәләре рус-япон сугышында да катнаша. 1905 елда Балтикадан «Дельфин» атлы унөч көймә Владивостокка китерелә. Ләкин Хәрби диңгез флоты ул корабльләрдән генә тормый. 1705 елда Петр Беренче «Диңгез солдатлары полкы» турындагы Указга кул куя. Шуның белән үзен данга күмгән диңгез пехотасы барлыкка килә. Әйе, сез корабльләрдә булмассыз. Ләкин сез аларның һәрвакыт сугышчан әзерлектә булуын тәэмин итүгә лаеклы өлеш кертәчәксез. Кайда гына булсагыз да — бу сезнең хезмәтегезнең кадерен, дәрәҗәсен, бәһасен төшерми. Инде сезгә шуны да әйтим: бер танкны сафка бастыру өчен өч йөз завод эшли, су асты көймәсен төзүдә биш йөз предприятие катнаша. Күпме кешенең тырышлыгы, фидакарь хезмәте салынган ул дәһшәтле субмариналарга. Халык безгә ышанып тапшырган корал, техника сугышчан әзерлектә булырга тиеш. Бүген — чагыштырмача тыныч вакыт. Ләкин без — хәрбиләр — яхшыга өмет иткән очракта да, начарына исәп тотарга, теләсә нинди агрессорга отпор бирергә әзер булырга тиешбез. «Рус моряклары бүтәннәр башкара алмаган гамәлләрне дә үтәргә сәләтле», — дигән адмирал Макаров. Бу сүзләрне бөтен хәрбиләргә карата да әйтергә мөмкин.

Аннары майор Каргиев командирлары Әсгать Җиһаншин булган дүрт солдатның батырлыгын да искә алды. 1960 ел башында кырык тугыз көн буена океанда дрейфта булуларын, ачлыктан интегүләрен, ләкин көчле рухлы совет солдатлары булып калуларын әйтте.

Габделнур янында утырган бер солдат шыпырт кына:

— Бәхетләре инде, Америка авианосецы «Кирсардж» аларны табып ала, — диде. — Бөтен дөнья шаулады, орденнар бирделәр. Үзебезнекеләргә эләксәләр, йә губага утыртырлар, йә төрмәгә үк тыгып куярлар иде.

— Нигә алай дисең?

— Качып китәргә маташканнар дигән ярлык тагарлар иде.

Солдат моны бик белдекле кыяфәт белән әйтте. Гәзиттә язылган, радиодан сөйләнгән һәрнәрсәгә карусыз ышанучан Габделнур иңнәрен сикертеп куйды: бу егетнең тел төбен аңлап җиткермәде. «Башкачарак фикер йөртүчеләр дә була икән, — дип уйлады ул. — Кайберәүләр, безнең шикелле, кем нәрсә әйтсә, шуңа сукырларча ышанып, «ә»ме — «ә», «җә»ме — «җә» дип кенә тормыйлар икән».

## 5

Габделнур Хөрмәтне үтә дә тыныч холыклы, хәтта ки бераз пошмасрак кеше дип йөри иде. Алай түгел икән, ялгышкан булып чыкты.

Ашханәгә кереп, өстәл артына утырып кына өлгерделәр, Хөрмәт янындагы бер солдатның маңгаена нидер очып килеп бәрелде. Өстәлгә төшкән нәрсәне җентекләбрәк карасалар — бер телем ипи.

— Кем ыргытты? — дип сорады Хөрмәт янәшә утырган, маңгаена ипи катысы эләккән солдаттан.

Солдат, күрәсең, шәйләп калган.

— Әнә Трофимов, — дип, Габделнур башы аркылы күрше өстәлгә күрсәтте.

Габделнур исә Хөрмәт белән кара-каршы, бер өстәл артында утыра иде. Ул артына борылып карады. Чыннан да, Трофимов алар өстәленә күзен текәп елмая иде.

Хөрмәт ипи телемен кулына алып сикереп торды да Трофимов янына килде. Солдат иң кырыйда иде.

— Син ыргыттыңмы?

— Әйе.

Хөрмәт, әле һаман елмаеп торган батыр кыяфәтле Трофимовтан уңай җавап ишетүгә, күз ачып йомганчы тегенең яңагына тартты.

— Син нәрсә? — дип сикереп торды Трофимов. Ябык чырайлы булса да, ул Хөрмәттән буйлырак иде. Сугып өлгерә алмады, Хөрмәт аның кулын читкә этәрде.

— Ә син? — диде ул, ярсып. — Нигә ипи белән атышасың?

Габделнур, Атаулла белән Шәрип, урыннарыннан сикереп торып, алар янына килделәр. Хөрмәтне беркайчан да мондый кыяфәттә күргәннәре юк иде: аның юка иреннәре тагы да кысылган, авыз читендә аксыл төгәрек күбеге хасил булган, күзләре зәһәр елтырый, йөзе бурлаттай.

— Атышса соң? — диде Трофимов, ачу белән.

— Тамагың туйдымыни?

— Ә мин ач түгел. Беркайчан да ач булмадым.

— Мин булдым. Бер телем ипигә тилмердем. Шуңа күрә үскәч комбайнга утырдым. Менә шушы кулларым белән үзем иген үстердем.

Хөрмәт үзенең юантык кыска бармаклы зур кулларын учын өскә каратып җәеп салды.

Атаулла исә:

— Моның өчен гүргүненә бацкыс куеп, йөгереп менеп, бәбәкләрен цукып алырга кирәк, — диде.

Камбуздагы пешекче егетләр белән амбразура аша сөйләшеп торган сержант шау-шу ишетеп йөгереп килеп җитте.

— Нәрсә бар монда? Ник җыелдыгыз? Кайсыгыз җәнҗал кубара?

— Ипи белән ыргытты, — диде Хөрмәт, сул кулындагы ипи кисәгенә ымлап һәм Трофимовка төртеп күрсәтте.

— Соңыннан ачыкларбыз, барыгыз урыннарыгызга, — диде сержант күрше өстәлне уратып алган егетләргә. — Ә сез нәрсә бастыгыз? Утырыгыз!

Соңгы сүзләре Габделнурларга кагылмый иде. Чөнки Трофимов утырган өстәл артыннан да, чәкәләшүчеләрне араларга яисә үз күршеләрен якларга ук әзер булып, бер-ике солдат торып баскан иде инде.

Иң гаҗәбе шул: өченче өстәлдән дә бер литвалы егет алар янына килде һәм Хөрмәтнең сүзен җөпләде:

— Мин дә күрдем, — диде ул сержантка. — Ул ипи атты. Яхшы түгел.

Хөрмәтнең ярсуы әле басылмаган иде.

— Тагын бер сыйпыйсы калган икән, — дип сөйләнә-сөйләнә ул, ниһаять, урынына барып утырды. — Иманын киим... Әле селтәнгән була тагы... Тетмәсен тетәсе... Безне, яманнан ярты кашык аш калыр, дип, ризыкны ашап бетерергә, җиргә коймаска, коелган валчыкны идәннән җыеп, өреп кабарга өйрәттеләр.

— Берцәк угомонись, — диде Атаулла, аны тынычландырып.

— Мәнсез, ипи ыргыта бит...

Габделнур, тамак туйдырганда, теге литвалы егеткә карап-карап алды.

Литвалылар монда унбиш-егерме кеше иде. Алар гел бергә йөриләр. Бүтәннәр белән аралашмыйлар. Монысы, урысча вата-җимерә сөйләшсә дә, кысылуны кирәк тапкан. Ничек бу җәнҗалга борын тыгарга җөрьәт иткәндер, Габделнур башта аңламады.

Бер-ике көннән Заранка фамилияле Иозас исемле бу егет белән якыннан танышырга җай чыкты.

Армия — гадәти тормышның кечерәйтелгән чагылышы. Монда хәрби әзерлек кенә өстәлә. Ә калганы — барысы да нәкъ гражданкадагыча. Бигрәк тә көнкүреш мәсьәләсендә. Әйтик, пешекче кирәкме? Кирәк. Итекче дә кирәк. Ә чәч алучы? Әлбәттә. Дөрес, чибәрләнү өчен чәчтарашханәгә барырга мөмкин. Акчаң булса һәм... шәһәрдә. Ә бәләкәй генә берәр ноктада яки чик буе заставасында?

Шуңа күрә солдат шулхәтле шомара — ул күпчелек эшне үзе башкара, ягъни үз арасыннан һөнәрчеләр таба, тәрбияли.

Литва егетләреннән Бразаускас фамилияле солдатның чәч ала торган машинкасы бар икән. Гап-гади, җыйнак кына, ак төстә, кул белән хәрәкәткә китерелә. Сул кулына тарак тотып, уң кул бармакларын өзлексез тиз-тиз хәрәкәтләндереп, ул якташларының чәчен тәртипкә китерде. Ләкин үзенә чират җиткәч, арадан берсе дә аның чәчен тиешенчә кыркый алмады. Тотынып караучылар булмады түгел, ләкин кайсы йолкый, кайсы тигез алмый. Моны күреп торган Габделнур түзмәде:

— Кая, мин алып карыйм әле, — дип батырчылык итте, машинкага үрелде.

Чөнки аларның өендә нәкъ шундый машинка бар иде, тоткасының бармак тери торган урыны сынык, берике төштә никеле дә купкан иде. Шулай да туганнар үзләренекен дә, этиләренекен дә тырыша-тырмаша шуның белән алалар иде.

Бразаускас, сары чәчле башын борып, бик ышанып җитмичәрәк Габделнурга зәңгәр күзләре белән карап алды. Шулай да кыркырга рөхсәт бирде.

Башта Габделнур машинканы сүтте, өреп тузаннан һәм чәч бөртекләреннән азат итте — чистартты, кабат җыйды.

— Сиңа нинди прическа кирәк?

— Ничек? — дип аңышмыйча сорады Бразаускас.

— «Бокс», «Полубокс», «Полька», «Подполька», «Канадка»...

Солдат кул гына селтәде, янәсе, үзең кара, барыбер андый сүзләрне ишеткәнем юк.

— Аңладым, — диде Габделнур, машинканы эшләтеп карап.

Биш-ун минут үтте микән, юк микән, ул эшен төгәлләде...

Шул көннән Литва егетләре аны үз итте. Бигрәк тә Заранка белән сөйләшеп киттеләр. Ул бер хутордан, ягъни ипи кадерен белүче авыл малае икән. Шуннан алар сөйләшеп-аралашып йөри башладылар. Иш ишен эзли дигәндәй, ничектер күңеле тартылды ул тыныч холыклы егеткә.

Беренче карашка гына алар халкы кеше сөймәүчән, йомыкыйрак сыман тоела икән. Озын буйлы, яңаклары алсуланып торган түгәрәк йөзле, сары чәчле, мөлаем кыяфәтле Заранка бик дустанә холыклы, яхшы әңгәмәдәш һәм намуслы иптәш булып чыкты. Җитмәсә, алардан ерак түгел генә Кырык Татар авылы бар икән. Воке елгасы буенда.

— Анда татарлар яшиме соң? — дип сорады Габделнур.

— Әйе. Мәчетләре дә бар. Тик алар безнеңчә сөйләшә инде...

...Мунча керү — солдатлар өчен иң шатлыклы, бәйрәмгә тартым көн. Чөнки мунчага бөтен шәһәр аша диярлек барасы.

Салкынча көн. Бүген көчле җил юк — сизелер-сизелмәс кенә. Әкрен генә кар ява. Сирәк агачлар акка күмелгән, юллар, сукмаклар чистартылып, кары читкә өелгән. Сирәк кенә машиналар узгалый, урамда хәрбиләр күренә, күбесе офицерлар. Шәһәр чиста, һавасы башларны әйләндерерлек саф, сулавы җиңел. Салкын яратып кына колак яфракларын чеметә, шуңадыр аяк атлавы рәхәт.

Сафта барсалар да — строевой адым белән түгел. Сөйләшергә дә мөмкин. Караштырып-күзәтеп баралар. Бигрәк тә кызлар очраса күңелләре күтәрелә егетләрнең. Кыз-кыркын яныннан үткәндә (солдатлар — урам уртасыннан, ә алар — тротуардан) эндәшмичә түзә алмыйлар.

Бүген дә, яшь кенә бер кыз күренүгә, солдатлардан кемдер аваз салды:

— Ризасызлык белдерергә!

Шуннан бөтен взвод, бертавыштан:

— У-у-у! — дип үкерде.

Уенчак кыз булса — елмая, кул болгый, җитдирәге очраса — чигә тирәсендә бармагын борып күрсәтергә дә күп сорамый.

Бүген соңгысына юлыктылар.

Шунда бер солдат, ачуы килеп:

— Ах, как идет! — диде.

Икенчесе күтәреп алды:

— Не идет, а пишет!

Өченчесе өстәде:

— Пишет как Лева!

Беренче солдат йомгаклады:

— А Лева пишет хреново!

Взвод командирының ярдәмчесе:

— Сөйләшмәскә! — дияргә мәҗбүр булды.

Солдатлар тыналар. Ләкин шәһәрдә кызлар күп бит — очрап кына торалар. Янә баягы хәл кабатлана.

— Да, чибәр, ырларга да ярый моны, — дип куя Атаулла.

Габделнур белән янәшә барган Шәрип, уфтанып:

— Безгә шул сүз зинасы белән күз зинасы гына калды инде, — диде. — Борын белән җибәреп...

— Син әйтәсеңме аны, мин әйтимме, әллә икебез бергә әйтикме, — диде Габделнур да көлеп. — Ничә ай инде кызлар кулы тоткан юк.

— Их метро юллары, йомшак иде куллары, дип җырларга гына калды.

— Йомшак кулларыннан тотып бер үбешкән булмадымы?

— Анысы гына булды, — диде Шәрип.

— Җәмиләне тагын бер искә төшер әле, — диде Габделнур, көлеп. — Ул миңа бик ошады.

Шәрип ялындырып тормады.

— Җә, Җәмилә, җиттек Җаекка. Җаек җәрминкәсендә җөрдек, җиләк җыйдык, җырлап җибәрдек. Җаек җәрминкәсендә җырлап җөргәч, җаңадан җир җимертеп җырладык.

— Җаек Урал елгасымы инде ул?

— Әйе.

Шәрип, гомумән, җор телле. Иптәшләре белән сөйләшкәндә генә түгел, сафта йөргәндә дә мәзәк сүзләр кыстырып куярга ярата. Әле беренче көннәре иде. Плацта басып торалар. Сержант аңа сафтан чыгарга кушты.

Шәрип «есть» дип кенә калмады:

— Есть, товарищ генерал, пять солдатым умирал, остальные окопта, чыгарып булмый атып та, — дип такылдады.

Татар малайлары көлешеп алдылар.

— Нәрсә, нәрсә? — диде сержант, аңа күзен алартып.

— Болай гына, иптәш сержант. Онытылып киткәнмен.

Икенче юлы мәрткә китмәсен өчен сержант аны йөгертеп ишегалдын өч тапкыр әйләндерде. Ләкин аңа карап кына Шәрип теленә салынудан туктамады, билгеле, чир китә, гадәт кала, диләр бит. Икенче вакыт рота командирына да ул: «Есть, товарищ капитан, ач артыңны чап итәм», — дип җибәрде. Тегесе сизмичәрәк калды. Аңышса, сержант кебек урамда чаптырып кына калмас иде. Әле дә ярый «башы тишек» түгел.

Берәрсе саф алдында исәнләшкәч, гадәттә солдатлар, исәнлек телибез, иптәш фәлән, дип, командирның дәрәҗәсен атап сөрән сала. Шәрип шунда да җор сүз кыстырырга җай таба һәм: «Здравия желаем, чыгараем салаем...» — ди. Ул баштагы ике сүзне тамагы ертылганчы акыра да соңгыларын күршедәгеләр ишетерлек кенә итеп әйтә. Габделнурлар пырхылдап җибәрүдән көчкә тыелып калалар.

...Трофимов Хөрмәткә ачу саклап йөри иде: яңагына сукканын оныта алмый. Ләкин берүзе килеп ябышырга шүрли. Бәйләнергә җай эзләп йөргән көне. Мунчада да бер талпынып карады.

Габделнур күргәндә, берничә егет Хөрмәтне уратып алганнар иде.

— Атаулла, Шәрип, әйдәгез әле, — диде ул һәм тегеләр янына барып та җитте.

Бер блатной гына солдат бөеренә таянып алган да, күзләрен кысып, иреннәрен чалыштырып, Хөрмәт каршында боргаланып-селкенеп төкерек чәчә, теленә салынып маташа иде.

— Ты чего возникаешь? Тазамыни, бер тапкыр да авырмадыңмыни? Әллә сине гражданкада аз кыйнадылармы?

Хөрмәтнең бу лыгырдавыкка исе дә китмәде. Кысыграк күзләрен тегеңә төбәгән дә көлемсерәп тик тора. Ул Габделнурга, татарчалап:

— Тотып бәримме таш идәнгә башы белән? — диде.

Болар янына Шәрип тагын берничә дус егетне дәшкән иде инде.

— Син нәрсә, теге юлы судан коры чыкканыңа сөен, — диде Шәрип, куркаклардан булмаса да, аңлы егет. — Нәҗескә тисәң, сасысы чыгар.

Габделнур да:

— Бәйләнмә шул әнчеккә, — диде. — Алар юри син башлаганны көтә, тавыш кубарырга маташа.

Хөрмәтнең бирешәсе килми, күрәсең, кулы кычыта иде.

— Үзләре котырта бит.

— Син эт түгел бит котырырга, — диде Габделнур Хөрмәткә һәм Трофимовка карап өстәде: — Гаеп үзендә. Без ипинең валчыгын да идәннән чүпләп ашарга өйрәнгән.

Атаулла да бу егетне кисәтүне кирәк тапты.

— Син безнең тирәдән читтәрәк йөр.

Нидер мыгырданып китеп барды Трофимов. Аңа әшнәләре дә иярде. Чөнки отделение командирлары — сержантлар да — алар ягына караштыра башлаганнар иде инде.

Трофимовның эчендәге үч алу уты сүрелмәгәне көн кебек ачык иде.

...Габделнур армия тормышына тиз ияләште. Чөнки тәне сәламәт, зиһене ачык, теләге — күрү-өйрәнү, кушканны үтәү, ир-егет өлешенә тигән солдат хезмәтен вакытында һәм тиешенчә үткәреп кайту иде. Соңыннан военкомат хезмәткәрләре борчып йөрерлек булмасын.

Ләкин аны сагыну хисе бимазалады, бу тойгы аны беркайчан да тынычлыкта калдырмады. Ул барысын да сагынды: авылын, әти-әнисен, туганнарын, кардәшләрен, күршеләрен, дусларын, җиде ел укыган авыл мәктәбенең тузанын бергә эчкән классташларын, студент елларындагы курсташларын. Ләкин еш кына ул балалык чорын сагынды. Юкса бер дә сагынырлык түгел иде кебек бала чагы.

Бер сынык ипи аркасында килеп чыккан Хөрмәт-Трофимов низагыннан соң ул еш уйланды. Үзенең бала чакларын исенә төшерде. Әтиләре каян да булса ераграк юлдан кайтса, алар йөгереп килеп итеген салдыралар да, аның күзенә карап, «куян күчтәнәче» көтеп торалар иде. Ул бер-ике сынык ипи була. Әйе, Габделнурлар чоры балалары барысын да күрде. Әтилеме ул бала, ятимме — заман аралап тормады. Бал-майда гына йөзгән кешеләр бик сирәк булгандыр сугыш вакытында һәм аннан соңгы авыр елларда. Алар әледән-әле искә төшеп, өндә генә түгел, аерым күренешләр рәвешендә төшкә кереп тә йөдәтә һәм онытмаска тиешлеген искәртеп торганлыктан, ул чорны да сагынды Габделнур. Аның күз алдына еш киләләр ачлыктан күз төпләре кара көйгән, олыларча җитди чырайлы, арык тәнле, ялан аяклары чебиләп, чиләнеп-кутырланып беткән нәни иптәшләре; чит-читләрендә ак эреннәр хасил булган, трахомадан чепиләнгән күзле балалар; суыктан унары берьюлы чыгып, тәннәрен тоташ чуан баскан малайлар: бетле башларын кан чыкканчы шатор-шотыр кашып җәфа чиккән бәләкәй кызлар; кыш көне чаңгы шуып туңып-күшегеп кайткач боз кебек туңган нәзек бармакларын кыска чәчле башларына ышкып җылыткан «бәхетле спортчылар»; тамак артыннан йөреп, мичтән алган, кичәгедән калган ашлы чуены белән бергә ачык икәнен абайламыйча идән астына — өй базына очкан «лачыннар». Чөнки алар арасында ул үзе дә бар иде. Ул да, авыл баласы буларак, шул заманның бөтен авырлыгын үз башыннан үткәрде. Аерма шунда гына: кемгәдер күбрәк, кемгәдер әзрәк әлакте ул интегүләр. Ләкин Габделнур шул балалар белән бергә уйнады, бергә укыды, бер урамда, бер авылда үсте.

Хәтерендә калган: ул әле бик бәләкәй иде, ишле балалы берәүләргә керде.

Ике кыз баш карыйлар. Бетләре кәгазьгә коела.

Бала-чага гадәтенчә башта шаяра, ахырда талаша ук башлый бит.

— Бусы минеке.

—Юк, монысы синеке. Әнә үзең кебек кара. Минеке ак.

Сабыйларның берсе елап җибәрә.

— Юк, минеке кара түгел!

Аналары — ире сугыштан кайтмаган тол хатын карап тора. Эчтән сыза, тавышсыз гына елый торгандыр, чөнки күзләре элпәләнгән.

— Ач булмасагыз, бет чыкмас иде, балакайларым, — ди ул, авыр сулап.

Ә бер хатын, керосин салып, чүт кенә баласының башын яндырмый...

Вакыт — барысына да дәва, диләр. Шуңа күрә ул хәлләр көн саен, сәгать саен хәтеренә төшеп тормый торуын, әмма ни генә булмасын, ул аларны оныта да алмый иде. Онытырга хакы юк иде.

...Ни хикмәт булгандыр, шәһәр уртасындагы дүрт катлы бинадан февраль аенда аларны шәһәр читенә күчерделәр.

— Бу казармаларны моннан ике йөз илле еллар чамасы элек Петр патша төзеткән, — диде отделение командиры, ярыйсы гына укымышлы, күп нәрсәдән мәгълүматлы, солдатларына да хәерхаһлы егет.

Кызыл кирпечтән, диварлары берәр метр калынлыкта, түшәмнәре көймәле итеп эшләнгән иде бу бер катлы казармалар. Тәрәзәләре тар, биек түгел. Калай белән тышланган түгәрәк мичләргә утын ягасы. Күп итеп яксаң, җылы төшә үзе. Стеналар гына түгел, түшәм дә кирпеч, идән — цемент. Монда да тормыш — гадәти солдат хезмәте, дөресрәге, әле карантин узу вакыты — сафта йөрү, уставлар өйрәнү, ант кабул итәргә әзерләнү.

Менә ул тантаналы көн дә килеп җитте. Аларны янә каршы якка һәйкәл сыманрак итеп су асты көймәсенең рубкасы урнаштырылган Флотская урамына, әүвәлге казармага кайтардылар.

Кичтән үк кием чистарттылар, үтүкләделәр, итекләренә гуталин сылап куйдылар, башка вак-төякне барладылар. Иртән торгач, физзарядкадан соң итекләренә су бөркеп, щетка белән көзгедәй ялтыраттылар, юындылар-кырындылар, ашханәгә бардылар. Ашау-эчү дә мулрак иде бүген.

— Адмираллар көн саен килеп торса да шәп буласы икән, — диде тамак мәсьәләсендә үзен рәнҗетмәүче Хөрмәт.

Киенеп, карабиннар тотып, урамга чыктылар, сафка бастылар. Сафта юньләп йөрергә өйрәнмәгән Белобородовны плацка бөтенләй чыгармадылар.

Бүген бәйрәмчә киенгән офицерлар да өтәләнеп әрле-бирле йөриләр, казарманың тышкы ишеге өзлексез ачылып-ябылып тора. Көне дә килешкән — кояшлы, җылы. Плац — чип-чиста. Кыскасы, бер сүз белән генә әйткәндә — тантана.

Габделнурның мәктәп еллары исенә төште: мондый дулкынлану — ашкынып нидер көтү — ул Октябрь яки Май бәйрәмнәре вакытында була торган иде. Укучылар, бар булган «затлы» киемнәрен киеп, мәктәпкә җыелалар, сафларга тезелеп урамнарда йөриләр, укытучылар кычкырган өндәмәләрне хуплап, «ура!» дип авылны яңгыраталар.

Бүген дә аңарда нәкъ шундый халәт.

— Смирно!

Команда яңгырагач, солдатлар кулларын сыннары буенча сузып, тын алырга да куркып, катып калдылар.

Андый чакта, башың борылмаса да, күз чите белән генә плацтаниләр һәм кемнәр барын күзәтәсең. Габделнур да кара киемле, уртача буйлы, кырык биш-илле яшьләрдәге адмиралны күреп алды. Погонында бер зур йолдыз — контр-адмирал дәрәҗәсендә икән. Бу минутта Габделнурны адмиралга бирелгән рапорт сүзләре дә, бүтән олы һәм кече командирлар да кызыксындырмый иде. Әйе, аның күзе фәкать адмиралда гына. Беренчедән, тере адмиралны беренче күрүе, икенчедән, ул киләсе булганга, Габделнурны иң алга чыгарып бастырдылар, дүртәр сәгать сафта йөрергә мәҗбүр иттеләр бит...

— Исәнмесез, солдат иптәшләр!

— Исәнлек телибез, иптәш контр-адмирал!

Күбесе ул сүзләрне тәгәл әйтми дә, фәкать, «һау, һау» дигән шикелле, бар көченә күкрәк читлегеннән һава гына чыгара. Ләкин бик игътибар белән тыңласаң, барыбер адмиралны олылау сүзләрен аермачык шәйләргә була иде.

— «...Мин — Совет Социалистик Республикалар Союзы гражданины...»

Һәр сүзне иҗекләп, чатнатып әйтеп, яттан өйрәнгән текстны сөйләп, кулына корал тоткан хәлдә ант биргәч, солдат өч ел буена туган иленә тугрылыклы хезмәт итәргә тиеш була. Шуңа әзерлеген бүген сафта йөреп күрсәтә...

Адмирал каршыннан күкрәкләрен киереп, югары күтәрелгән аякларын мөмкин хәтле ераграк сузып, каты асфальтка шап-шоп басып, тигез сафлар булып үткәч, иңнәреннән гүя авыр йөк төшкән шикелле тоелды. Командирлар да канәгать иде. Кыскасы, истәлекле, тантаналы көн матур узды.

...Егетләрне беренче мәртәбә ату кырына алып киттеләр. Көн салкын, ләкин кояшлы иде. Иңнәренә карабиннар асып, сафка тезелеп шактый вакыт баргач, шәһәр читендәге ачык кырга килеп чыктылар. Бер катлы бәләкәй генә будка янынннан узып, ату урынына керделәр.

Бөтен җир ап-ак. Кары чиста. Еракта форт күренә. Бу Ленинград ягыннан килгәндә күренгәне түгел, ә икенчесе. Ләкин әллә ни аермасы юк: кызыл кирпечтән биек итеп төзелгән түгәрәк корылма, өске өлешендә тәрәзәгә тартымрак тишекләр бар, ләкин рамнары да, пыялалары да күренми. Фортның әйләнә-тирәсе боз белән капланган. Арырак тагын бер форт күренә...

Очсыз-кырыйсыз диңгез җәелеп ята каршыда. Әкрен искән җилләр вак кар бөртекләрен боз өстеннән куа яки үз артларыннан иярт — басудагы җәяүле буранга тартым бу манзара егетләргә туган як табигатен хәтерләтә.

Габделнурның туган иленнән чыгып китүенә өч ай булды инде. Сагыну хисе отыры сүрелә барырга тиеш иде кебек. Ләкин юк икән, сүнми дә, сүрелми дә икән, арада йөрүче хатлар гына әти-әниеңне, туган-тумачаларыңны, сөйгән ярларыңны күрәсе килү теләген, һич бетмәс бу сусауны баса алмый икән... Боз өстеннән беленер-беленмәс кенә искән җил куган кар бөртекләре дә авыл басуындагы җәяүле буранны хәтерләткәч...

Һәр отделение аерым тезелеп, инструктаж һәм патроннар алып атарга әзерләнде.

Беренче мәртәбә ату, гәрчә моңарчы вак калибрлы мылтыктан атканы булса да, Габделнурны нигәдер дулкынландыра. Ул, каешын ычкындырып, кар өстенә ятты. Аякларын аерып, шинель итәкләрен тез турысынарак җыештырды, өч бармаклы бияләен салды.

Карабин, шактый авыр ату коралы булса да, аның таза кулларында бик җиңел йөри иде. Бу юлы ул аны, терсәкләрен карга батырып, сул кулына сузып салды.

— Түтәсен уң як иңбашыңа ныгытып терә, — диде отделение командиры. — Төзәгәнче мушка белән тигезлә. Төбәп тормыйча ату — юкка пуля югалту. Яхшылап төбә.

— Ярар.

«Мелькашка» белән эш иткәне булса да, бу — чын сугыш коралы, шуңа күрә командирның киңәше ярап куяр.

— Чакмага басканда сулыш алма...

Класста карабинны сүтү-җыю, атарга өйрәнү күнекмәләре күп мәртәбәләр булса да, барыбер каушата, кирәкмәгәнгә дөп-дөп йөрәк кага башлый, сулыш алу ешая. Әйтерсең суга керер алдыннан күкрәк читлеге үзенә кирәкле һаваны җыеп-сулап калырга тырыша.

Габделнур, сул күзен йомып, еракта күренгән мишеньгә — мәргә төбәп, командирлар өйрәткәнчә атып җибәрде. Тәтегә менә басам, менә басам дип ята торгач, пуляның ничек очып чыгып киткәнен дә сизми калды. Ә менә карабин түтәсе үз эшен эшләде: шактый сизелерлек итеп солдатның кулбашына китереп бәрде. Димәк, мушка, төзәгеч һәм чакма белән мавыгып, ул карабинның тимер кадакланган авыр түтәсе барын исеннән чыгарган икән. Икенчеләй акыллырак булырга, дөресрәге, саграк кыланырга, берсен дә истән чыгармаска кирәк...

Өч патронын да атып бетергәч, Габделнур урыныннан торды, кагынды, гильзаларын җыеп сержантка бирде. Тезелешеп яткан укчыларның барысы да атып бетергәч, команда бирелгәч кенә, кар ерып, мәрәләргә таба атладылар.

Солдатларның һәрберсе үз мәрәсенә таба ашыга. Чөнки беренче мәртәбә атулары. Ничәгә тиде икән? Ә гомумән тигәнме? «Сөт»кә китмәде микән? «Сөт» дигәне кәгазьнең мишень «алмасы» — кара түгәрәк читендәге ак килеш калган өлеше. Юк, «сөт»кә китмәгән. Габделнур үз күзләренә үзе ышанмады: ике бәләкәй генә тишек ун саны эчендә, берсе — тугызда.

— Ура!— дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды ул.

Аның янына килеп җиткән отделение командиры да гаҗәпләнүен-соклануын яшерә алмады.

— Ничего себе! Егерме тугыз очко! Әйбәт! Мәргәннәрчә!

Габделнурның шатлыгын Хөрмәт, Шәрип, Атаулла һәм бүтән якташлары да уртаклашты. Аларның да мәрәләре тишкәләнгән: берсенең егерме биш очко булган, икенчесе егерме өчне җыйган... Бер мишеньнең генә «алмасы»нда гомумән ертылган-тишелгән урын юк иде.

— Ата алмаган атасына үпкәләр, — диде Хөрмәт, Шәрипкә төрттереп.

— Миңа мылтыкның бозыгы туры килде, ахры.

Атаулла да Шәрипкә «тибеп» алды.

— Начар биючегә нәрсә комачаулый әле...

Ату тәмамланып кайтырга җыенганда ыгы-зыгы купты: бер солдат гильза югалткан. Әйе, атылган патронның бушап калган гильзасы гына.

Әмма барыбер рота командиры, зурдан кубып, барысын да сафка тезде.

— Гильза табылмыйча кайту юк, — диде ул, әрле-бирле кар өстендә йөреп, күн пирчәткәле кулларын бутап. — Эзләгез!

Башта әллә кесәсенә салды микән дип тә шикләнделәр.

Ләкин солдат бөтен кесәләрен әйләндереп күрсәтте, алмадым, дип ант итте.

Гильза энә түгел, чәнти бармак юанлыгы бронза дары савыты. Шулай да эзләү шактый вакытны алды. Унунбиш минут берәмтекләп дигәндәй тапталган карны куллары белән аралый торгач, гильза табылды. Һәрбарчасы җиңел сулап куйдылар. Әйе, патрон гына түгел, һәр гильза исәптә икән армиядә.

**6**

«Үскән чакта үскән идек, тал тамырлары кебек...» дип җырлый-җырлый туган авылыннан, газиз ата-анасыннан, якын кардәшләреннән бер аерылып киткән егетләр, тагын шул ук җырны күңелләреннән кабатлап, бер-берсе белән саубуллаштылар. Дөресрәге, аларны «сатып алучылар» аерды.

Хөрмәт Ульяновск өлкәсендәге бер частька эләкте. Бәхете — өйгә якынрак.

— Трофимов та сезнең белән икән, — диде Габделнур, саубуллашканда.

— Әйе, — дип кенә әйтте Хөрмәт.

Шәрипнең авыз ерык.

— Мин юл йөрергә яратам, — диде ул. — Начар булмас әле, дөнья күрербез. Йөргән таш шомара...

Аны һәм Атаулланы Ленинград өлкәсенә — хәрби йөкләрне озата баручы ротага билгеләделәр.

Габделнур Ярославль өлкәсенә — каравыл ротасына җибәреләсе иде, литвалы егетләр белән.

— Через день — на ремень, через два — на камбуз, — диде аңа отделение командиры, әллә җәлләп, әллә шул кирәк сиңа дигән сыманрак.

Беренчесе дөрескәрәк туры киләдер, теләктәшлек күрсәтүедер. Габделнур начар солдат булмады бит.

Кем кая эләгә, нинди частька, кемнәр белән — бәхет эше. Киләчәк тормышың, язмышың үз кулыңда түгел. Сайлап алалмыйсың, сорап — бирмиләр.

Үзбәк егетләре дә кайсы кая юл тоттылар. Алар арасында иң нык сөенгәне Хамракулов булды. Аны кайсыдыр частька пешекче итеп алдылар. «Сатып алучы» пылау ярата торган кеше булды, ахрысы.

— Пылау пешерә беләсеңме? — дип сорады ул үзбәк егетеннән, бер дә тартынмыйча.

Хамракулов пешерә белә иде микән, юк микән, форсатны кулдан ычкындырырга ярамаганын тиз төшенде булса кирәк.

— Беләм! — диде ул, чатнатып.

— Алам, — диде офицер.

Шатлыгы эченә сыймады егетнең — хезмәте җылыда үтәчәк иде.

Бер җырчы егет бар иде — ансамбльгә яздылар. Һәрбер хәрби округта, гаскәр төрләрендә үзенең җыр һәм бию ансамбльләре бар икән. Музыка училищесы бетергән егеткә үз һөнәре буенча «эш» таптылар — Балтыйк Флоты ансамбленә алып киттеләр.

Эшелонда танышкан, юл «газабы»н бергәләп, гармуннар белән җырлашып-сайрашып күңелле итеп үткәргән егетләрнең күбесе белән дусларча кочаклашып, кул кысышып аерылышты Габделнур. Чөнки яшь сугышчы курсын — карантинны бергә үттеләр. Ә менә Тәтеш егете Морат белән хушлаша алмады. Өйләреннән адрес соратып, хат алыша иде югыйсә. Морат та Кронштадтта, ләкин бүтән частьта — учебкада, матрос киемендә, дүрт еллыкка эләккән иде. Әйе, аның белән саубуллашу насыйп булмады.

...Март башы Ленинград тирәсендә дә март башы икән — кояш та мулрак җылыта, чыпчыклар да шатланыбрак чыркылдаша, агач төпләрендә дә кар эреп, былтыргы үләннәр күренә башлаган, басуларда кар эри.

Машина Ленинградка килеп җитте. Аларны вокзалда төшереп калдырды да кирегә борылды — Кронштадка китеп барды.

Тагын Ленинградны күрү бәхетенә ирешә Габделнур. Бу юлы анда озак тотмадылар — поезд аларны ары алып китте. Юллары Ярославль ягына борылган иде.

Авылда җидееллык мәктәпне бетереп чыкканда Габделнурның өчлесе дә, бишлесе дә (тәртибен исәпләмәгәндә) юк, бөтенесе дүртле булды, ләкин иң яраткан фәне география иде. Шуңа күрә ул, поезд чакрым баганаларын санаган саен, үзенең туган ягына табарак якынлашуын тойды. Гәрчә, Мәскәүдән шактый төньяктарак булса да, өй түбәсеннән, сылаулы ак морҗадан төтен чыкканы күренмәсә дә, Кронштадт белән чагыштырганда Ярославль күпмедер дәрәҗәдә Казанга юл алу иде.

Шәһәргә алар төнлә килеп төштеләр. Маңгаена «Ярославль» дип язылган тимер юл вокзалын һәм якын-тирәдәге станция корылмаларын гына күрү насыйп булды. Вагоннан да чыгармадылар. Аларның юлы ары икән әле.

Таң беленгәндә, бәләкәй генә бер станциядә поездан төшереп җәяү хезмәт итәсе частька алып киттеләр.

Өйгә якынрак булса да бу тирәнең табигате кырысрак икәнен Габделнур вагоннан чыгу белән аңлады. Кояш саран җылыта, күрәсең, әле монда кыш уртасы кебек — карның җебергә гамендә дә юк, суыгы да куырып ала, тынга каплана. Тигезле-тигезсез атлаган солдат итекләре астында кар, шыгыр-шыгыр килеп, төнге тыныч һавада әллә кайларга тарала. Монда үзенә бертөрле саф, чиста һава — биек-биек нарат, чыршылардан таралган хуш ис борыннарны ярып, кытыклап керә.

— Табигате матур икән, — диде Габделнур янәшә атлаган Заранкага.

— Әйе, — дип раслады мондый хозурлыкны беренче тапкыр күргән Иозас һәм казармада да алсуланып торучан, ә хәзер кызарып ук чыккан битен ялан кулы белән ышкып алды. — Шалта*. Хезмәт ничек булыр...

— Ияләнербез әле, — диде Габделнур һәм ул да сул колагына кагылып алды. — Без татарларга барыбер: сабантуй ни, сугыш ни — барыбер орышасы.

Габделнур кебек, Иозасны да солдат хезмәте әллә ни куркытмый иде.

— Ипи белән балык булса, тозы, борычы җитәчәк.

Ул, иптәшенә карап, теләктәшлек йөзеннән елмайды.

...Постта торганда урман эчендә ара-тирә тукран «пулеметтан сиптерә» — агач чукып җим эзли, шартшорт иткән тавышлар ишетелә — агачлар суыкка түзә алмыйча ярыла... Нарат ябалдашларына ап-ак кар кунган, саргылт-көрән кәүсәләре уклау кебек төз үзләре. Наратның аста ботаклары юк. Алар, сынган мөгез шикелле, кәүсәдән бераз гына чыгып торалар. Шулай булса да аларга да кар кунган. Чыршылар да карлы, ләкин яшел — күзгә күрекле, горур. Җирдә ак кар астыннан куак, вак чыршы һәм нарат үсентеләре башларын калкытканнар.

Ике сәгать сакта тору әллә ни авыр түгел үзе: башында бүрек, өстеңдә аксыл төстәге мул якалы толып, аягыңда калын олтанлы киез итек. Итеге авыррак булса да, аякка җылы, олтаны да авыл баласына кечкенәдән таныш. Яңа киез итекне озакка чыдатмыйлар иде алар. Шуңа күрә әтиләре кышкы кичләрдә итекләренә олтан сала торган иде. Малайлар карап-өйрәнеп утыралар, тегәрҗеп сумалаларга булышалар, әтиләренең кулыннан безе төшеп китсә алып бирергә әзер торалар иде... Кулыңда бармаклы өр-яңа солдат бияләе. Карабин тоткан уң кулың туңса, коралыңны сулына авыштырасың. Монда син үзеңә-үзең хуҗа, йоклама гына. Көндез, иртәкич ярыйсы, ләкин төнлә һәм бигрәк тә таң алдыннан үзең дә сизмәстән оеп китәсең... Сәгатьнең чылбырга аскан гере сизелмичә генә аска төшә барган кебек, синең баш та әкрен-әкрен аска иелә, күз йомыла. Аягүрә шулай йоклап китәсең вышкада... Нинди дә булса кош агач башында кыбырсып алса яки тиен-мазар сикерсә — уянып китәсең... Аннан тагын баягы хәл кабатлана... Бигрәк тә иртәнчәк йокы баса... Үзең дә сизмәстән нәүм базарына китеп барасың... Андый чакларда Габделнур йөренә, уяулыгын югалтмаска тырыша, туган авылын искә төшерә. Ләкин бүген, үч иткәндәй, нәкъ әнә шул йокыга кагылышлы вакыйга хәтерендә яңарды.

Болында ат саклаганда үлеп йокылары килә иде малайларның. Кем әйтмешли, арт якларын кисеп алсалар да берни сизмиләр. Ат караучы кызык өчен кайберләрен үшәнрәк, картрак атның койрыгына тагып та җибәргәли иде. Ә чыбыркыларын яшереп куюны әйткән дә юк инде, анысы — һәр төнне.

Бервакыт абзый Габделнурга:

— Син йокыга бик сак икән, матри малай, барыбер чыбыркыңны урлыйм, — диде.

— Урлый алмыйсың.

— Ярар, карап карарбыз. Баш астыңа гына куеп ятма.

Габделнур төне буе йокламады. Ләкин иртәнге якта һич чама юк чыдарга — изрәде, йокысы килә башлады. Өздереп сандугачлар сайрый, атлар шыгырт-шыгырт үлән ашап йөриләр...

Күзләре йомыла малайның, башын күтәрә алмый, ләкин сизә: агай чыбыркысын алырга килә. Күзен ачарга тели — булмый, башын да күтәрә алмый.

Шуннан көч-хәл белән әйтте Габделнур:

— Чыбыркыны гына алма, башны күтәреп булмый.

— Чистый җен икәнсең. Иманың юк икән, — диде ат караучы, көлеп.

Әйе, башыңа төшсә түзәсең... йокысына да, хезмәтенә дә...

Хәер, түзә алмаучылар да бар икән. Бер солдат постта торганда үзенә үзе атты.

Габделнур ул вакытта каравыл бинасында, ике сәгатен йокламый үткәрергә мәҗбүр булып, өстәл янында утыра иде. Анда домино, шахмат-шашка уйныйсың, хезмәттәшләрең белән гәп корасың. Кыскасы, каравыл уставы таләп иткәнчә ике сәгать буена йокламаска тырышып утырасың.

Кинәт урамда нидер шартлаган сыман булды — мылтыктан аткан тавыш яңгырады. Барысы да тынып калдылар. Каравыл башлыгы — кече сержант сикереп торды да кычкырып җибәрде:

— Каравыл, коралга!

Уяу смена да, черем итеп алырга ятканнары да — барысы да сикереп торып, карабиннарын эләктереп, тышка чыктылар. Прожекторлар яктысында ерактан ук шәйләнгән сулдагы вышкага таба йөгерделәр...

Сергеев фамилияле солдат җиргә төшкән. Үзе ап-ак булган.

Як-ягына карана-карана йөгергән кече сержант тирә-юньдә бернинди дә шикләнерлек нәрсә югын чамалады.

— Нәрсә булды? — дип сорады ул килә-килешкә. — Нишләп монда торасың?

Сергеев, башын аска иеп, юаш кына:

— Аттым, — диде.

— Кемгә? Нәрсәгә? — Кече сержант як-ягына каранды. — Кая?

— Үземә.

— Ә?!

Шунда гына Сергеевның уң колагыннан ак карга кызыл кан тамганын абайлап алды кече сержант. Ул Сергеевның кулыннан карабинын бәреп очырды.

— Анаңны!.. Нәрсә, үләсең килдемени? Алайса, нигә маңгаеңа атмадың? Сволочь! Маңка!

Чөнки каравылда ЧП булса, каравыл башлыгына да рәхмәт әйтмәсләр. Шаукымы аңа да тиячәк иде.

Сергеев елый ук башлады.

— Мин...

— Дәшмә! Атла әйдә! Гаделҗанов, постта кал. Заранка, ал Сергеевның карабинын.

Кече сержант, аты-юлы белән сүгенеп, Сергеевны алга чыгарды. Солдат, кулы белән колагын тотып, әкрен генә атлап китте, аның артыннан — башкалар.

Габделнур постта калды. Ул, баскыч араталарын шыгырдатып, вышкага менде, як-ягына каранды, сукмактан тезелешеп киткән хезмәттәшләренә күз салды. Аннары, карабинның түтәсен идән тактасына төшереп, аны җиңелчә генә тотты.

Тирә-юнь тыныч. Бернинди дә хәвеф юк. Ләкин барыбер бүтән чактагы кебек түгел. Ниндидер шом йөрәгенә төште. Юк, бу курку түгел. Ниндидер аңлаешсыз борчу катыш ризасызлык уянды күңел түрендә. Нәрсәдән, кемнән разый түгел Габделнур? Бу тойгы теге солдатка карата туган икән. Ничек үз-үзеңә кул күтәрмәк кирәк?! Мордар китү гомер-гомергә гаеп, хурлык саналган. Аны беркайчан да өнәмәгәннәр. Хезмәт авыр дисәң, кемгә җиңел иде ул? Әнә Кронштадтта переходящая ротада күргән матрос алты ел хезмәт иткән бит әле. Башкалар дүртәр ел су асты көймәсендә (икешәр-өчәр ай диңгез-океан караңгылыгында булалар) яки башка корабльләрдә үз бурычларын үтиләр, һәр минут сугышчан әзерлектә торалар. Ә сугыштан соңгыларга җидешәр-сигезәр ел каеш буып йөрергә туры килгән. Элекке заманнарда егерме биш ел солдат хезмәте... Хәзер нәрсә булыр икән? Кайтарып җибәрерләрме, гауптвахтага утыртырлармы? Әллә башта санчасть, госпиталь юлын таптармы?

Габделнурга әтисенең сөйләгәне бар иде. Сугыш вакытында да кайбер акыллы башлар үз-үзләренә зыян салганнар икән. «Бәхетлеләре», җиңелчә яраланып, өенә кайтып киткән, ә «бәхетсезләрен» — кеше ышанырлык итеп мәтәштерә белмәгәннәрен — шундук атып үтергәннәр яки штраф батальоннарына озатканнар.

Абыйсы сөйләгән дә исенә төште. Кайберәүләр, комиссоваться ителү өчен, тиен акча йота торган булалар. Ашказаны авырта дип госпитальгә баргач, рентген тегендә кара тап күрсәтә икән. Ипи валчыгына әвәләп гуталин кабучылар да булган.

Ә без? Күрәсең, безгә икенчерәк тәрбия бирелгәндер. Энесе белән булган вакыйга хәтеренә килде.

Габделнур җәй көне чиннек каршында утын яра иде. Энесе әле бәләкәйрәк (хәер, үзе дә унике-унөч яшьләрдә генә булгандыр), карап тора. Габделнур балтасын күтәреп бүкәнгә чабыйм дигәндә генә, энесе ни сәбәпледер аягын бүкән өстенә куйды. Абыйсы балтасын чак читкә борып өлгерде. Энесен каты ачуланды шулчак Габделнур...

Иң истә калганы шул: энесе илереп елап җибәрде һәм әйтте:

— Армиягә бармыйча каладырыем бит!

Әйе, аяк бармаклары өзелү түгел, ә армиягә бармый калу аның өчен трагедия, хурлык булачак иде. Чөнки ул чорда армия хезмәтенә караш шундый иде шул. Авыл кызларының кичке уенда җырлавы исенә төште:

Алмы синең кигәнең,
Гөлме синең кигәнең;
Нинди хурлык, армиягә
Ярамаса сөйгәнең.

Габделнур тынлыкка колак сала. Селкенгәли, таптана, йөренә. Тагын туктап кала. Күз күреме җиткәнче һәр тарафта урман. Яшел чыршы ботакларын, нарат ябалдашларын кар сарган. Кары нинди — ап-ак. Куе зәңгәр күк йөзен йолдызлар бизәп тора, алар арасында ай йөзә. Түм-түгәрәк. Габделнурның туган авылы күгендә дә, Әлмәт өстендә дә шул ук ай, шул ук Зөһрә кыз көянтә-чиләк асып суга бара. Гаҗәеп хозурлык, сокланып туймаслык... «Ничек шушы матурлыкның, тормышның рәхәтен, тәмен тоеп яшәмичә үз-үзеңә кул саласың инде?! Ахмак, яшьлегеңнең һәр минуты яшәү дәрте белән сугарылган бит. Кадерен генә белергә кирәк югыйсә. Күрәсең, кайтарып җибәрерләр дип өметләнәдер?»

...Ике көн дә үтмәде, төнлә казармада тавыш купты.

Бер солдат акырып җибәрде:

— Тагын минем өскә сиясеңме? Анаңны...

Дневальный ут яндырды. Ике этажлы караватның аскы катында торып утырган солдат янына килде.

— Нәрсә бар?

Ап-ак күлмәк-ыштанлы солдат аягына итеген киеп маташа иде.

— Тагын Черняев астына сигән, — диде ул.

Икенче катта йоклаган яшь солдат та уянган. Күзләрен йодрыклары белән уа-уа:

— Мин юри эшлимме әллә, — дип елап җибәрде.

— Төш, — дип боерды аларның отделение командиры.

Солдат төште, чалбарын кия башлады...

Аны госпитальгә озаттылар. Ул яңадан бу частька кайтмады.

Нишләттеләр икән ул бичараны? Кайсы яктан гына карасаң да бичара инде аның ише бәндә: әгәр чыннан да астына җибәрә икән — авыру буларак кызганыч, хәрби хезмәткә түзә алмыйча хәйләгә сабышса — егетлек түгел: кылган гамәле якыннарына барып ирешер, сөйгән кызына да ишетелер. Әгәр комиссовать итсеннәр өчен генә җәймә чылата башласа, кайтаваз булып үзенә кагылгандыр — тиешле җәзасын алгандыр, табиблар алдатмас. Чөнки беренче көннәрне андый гадәте беленмәгән икән.

Менә шундый инде ул солдат хезмәте: кем — түзә, кемнең буыны сыек — сыгылып төшә.

Әйе, берәүләр, түзә алмыйча, хезмәттән котылу юлын эзли — төрле хәйлә кора, икенчеләр исә уйлап та бирми — курортка килгәндәй хис итә.

Бертуган Карасевлар Мәскәү өлкәсеннән алынганнар. Башта алар ике тамчы су шикелле бер-беренә охшаганнар иде. Ләкин тора-бара игезәкләрне таный-аера башладылар. Чөнки берсе унөч килога тазарды, ә сыңары — алтыга гына.

...Каравыл бинасыннан чыккач, карабиннарын корып, иңнәренә асып, олтанлы киез итекләре белән тар сукмакны тыгызлап, ак толыплы солдатлар постка китә. Карасевларның Володя атлысы, йокыдан айнып җитмәгәнлектән, бара-бара да кар өстенә авып төшә.

Разводящий — өченче елын хезмәт итүче ефрейтор сүгенә:

— Тор, дуңгыз! Уян! Һаман йоклыйсың...

Тагын китәләр. Карасев вышкага менә, постта кала.

— Нинди сакчы инде бу?! — ди аңа җирәнеп караган разводящий һәм солдатларны ияртеп ары китә.

...Каравыл ротасында Габделнур Башкортстаннан чакырылган Нурмөхәммәтов фамилияле татар егете белән танышты. Ул — тәбәнәк гәүдәле, чандыр гына, өченче елын хезмәт итә, коптерщик. Беркөнне Габделнурга үз башыннан үткән хәлләрне сөйләде:

— Мине беренче елны берәү бик интектерде, — дип башлады ул сүзен, коптеркада утырганда. — Сиңа да бәйләнүләре мөмкин. Беренче көннән үк нык тор, үзеңне бастырма, басымчак итәрләр. Не надо оказаться в роли битой собаки. Син — таза, буйлы да. Мине, кечкенә булгач, баштарак кыерсыттылар. Федоров фамилияле берәү нык бәйләнде. Казармада да, плацта да, караульный помещениедә дә, вопщем, кайда туры килсәм дә тынгы бирми бит бу. Ротныйдан собаководлар взводына күчерүен дә үтенеп карадым, урын юк, диде. Шуннан түзәргә калды инде. Ә күпме түзәргә була? Бервакыт, каравыл постка басар алдыннан урамга чыккач, карабинны кордым да тегенең корсагына китереп терәдем. «Туктыйсыңмы миңа бәйләнүдән, юкмы? Атып үтерәм!» — дип кычкырып җибәрдем. Чөнки түзәр әмәл калмады. Ул көнне дә мине майсыз калдырды.

— Ничек? — дип сорады Габделнур.

— Ужинда май бүлгәндә, шаярган булып, миңа, сиңа, тагын миңа, дип, минем өлешне үзенә салды... Мин корсагына китереп төрткәч, катып калды бу: бер агара, бер күгәрә. Шунда каравыл буенча дежур офицер да бар иде. Ул тиз генә минем карабинны читкә этәрде. Мине сүгә башлады. Ә мин ярсыган идем инде, елый-елый тегенең җәберләвен сөйләдем. Бүтән яшь солдатлар да аннан гарык иде инде, алар да эшнең нидә икәнен әйткәч, мине яклагач, офицер Федоровны әрләргә тотынды. Эшне зурга җибәрмәделәр. Шуннан соң гына туктады теге хайван.

— Ә хәзер ничек? — дип сорады Габделнур.

— Ул китте бит инде. Мин хәзер үзем «картлач». Ләкин аңа карап кеше рәнҗеткәнем юк. Безнекеләр арасында да юньсезләр җитәрлек. Алдыңны-артыңны карап йөр, сак бул. Берәр хәл килеп чыкса, үземә әйт. Тартынма.

— Ярар.

Солдатлар арасында гына түгел, солдатлар белән офицерларның үзара мөнәсәбәтләрендә дә шактый четерекле хәлләр булгалый кайчак.

...Каравыл дежурные иркенләп, каешын салып, изүен ычкындырып, йокламыйча утырырга тиешле смена егетләре белән домино сукты. Кызып-кызып уйнадылар: ул — үзенең офицер икәнен, егетләр солдат икәнлекләрен оныткандай тугарылдылар. Чөнки кече лейтенант әле үзе дә солдат-сержантлардан өч-дүрт яшькә генә олы иде. Егетләр аны үзара «микромайор» дип йөртәләр.

Офицерның үзен иркен тотуы да аңлашыла: постлар тикшерелгән, часовойлар үз урынында, солдатларның тамагы тук, бер смена тулысы белән монда утыра, икенчесе ял итә. Кыскасы, тышта да, каравыл бинасында да тәртип, тынычлык хөкем сөрә. Борчылырга сәбәп юк. Дөрес, вакыт-вакыт йокы бүлмәсеннән берәрсенең гырлаганы ишетелеп ала да, нәрсәдер дөпелдәгәч, кисәк туктый. Андый чакта дежурный, тавышка колак салып (кулында домино, күзе өстәлдә булса да), үзалдына елмаеп куя, чөнки белә: гырлый башлаган солдатка кайсы да булса берәү йокы аралаш олтанлы итек белән тондырган... Янә тынлык урнаша.

Шактый озак утыргач, кече лейтенант кузгалды.

— Миңа вакыт, — диде ул һәм киенә башлады.

Каешын биленә буып, өйрәнелгән гадәт буенча кобурасын капшап, җайлабрак куймакчы булды. Һәм... кинәт аның йөзе агарынды, үзе тораташтай катып калды: корал савыты җиңел, буш иде.

— Кем минем пистолетны алды? — дип кычкырып җибәрде ул. — Сержант, тез каравылны! Тиз бул!

Уяу смена да җыелды, эчкәре бүлмәдә йоклаганнар да торгызылды — тәмле төшләреннән бүлгәнгә ачуланып, шешенгән кызгылт чырайларын сытып, ялкау гына сафка килеп бастылар.

Габделнурга әле генә үзләре белән балаларча шатланып, уен-көлке сөйләшеп, шап-шоп домино суккан дежурныйның шултиклем тиз үзгәрүен һәм ачуы кабаруын аңлавы кыен түгел иде: корал югалту, бигрәк тә офицер кешегә, иң хәтәр нәрсә. Моны гаеп эш дип кенә карамыйлар, ул җинаять санала.

Саргылт кашлары җыерылган, ярсудан, каушаудан тотлыга ук башлаган офицер үз-үзен белештермичә җикеренде. Читлектәге киек җанвар кебек, строй алдында әрле-бирле йөренде.

— Кайсыгыз минем пистолетны алды? Кем? Бирегез хәзер үк!..

Сержант куркып калды.

— Бәлки, идәнгә төшкәндер, иптәш кече лейтенант?

— Син нәрсә, сержант, ул бит энә түгел! Кобура эләктерелгән иде, ә хәзер — ачык. Ачык калган! Аңлыйсыңмы? Димәк, кемдер тиз генә алган. Йә, кем алды?

Каравыл башлыгы һаман үзенекен тәкрарлады:

— Иптәш кече лейтенант, беркем дә алмагандыр. Бәлки...

— Дәшмә!

Шулай диде дә офицер кинәт кенә йөрүеннән туктады, аннары строй алдында үзе белән янәшә ык-мык итеп торган сержантны кырыйга этеп җибәрде. Ул бер солдатның каршына барып басты, күзләренә текәп карады. Нидер исенә төште бугай.

— Малдышев, син алдыңмы? — дип сорады ул, бөтенләй икенче, тыныч тонга күчеп.

Яңаклары чыгынкы битле, кысыграк күзле, тәбәнәк гәүдәле Алтай егете Эркелей Малдышев дәшмәде. Ул үзе дә каушады, ахры. Уеннан уймак чыгуы ихтимал иде.

Сержант та:

— Әйт, син алдыңмы? — дип сорады.

Кече лейтенантның эченә җылы керде. Тавышы йомшады. Үзе элеккеге үрнәк, тәртипле совет офицерына әйләнде. Тавышында — ялвару.

— Бир генә, Малдышев, беркемгә дә әйтмим. Сиңа бер начарлык та эшләмим.

Солдат, сафтан чыгып, каравыл бинасының бер почмагында торган, ком тутырылган мичкәдән офицерның пистолетын алып килеп бирде.

— Гафу итегез, иптәш кече лейтенант.

— Рәхмәт. Син дә мине теге вакыттагы хәл өчен гафу ит.

Эш шунда иде: узган атнада әлеге офицер постта торган Малдышевның карабинын сорап алган. Солдат ни сәбәпледер биргән. Аннан үзенә үк әрләү эләккән — устав буенча ул коралын беркемгә дә бирергә тиеш түгел.

**7**

Нурмөхәммәтовның кисәтүе юкка гына булмаган икән: Федоров кайтып китсә, кеше рәнҗетеп тәм табучы бүтәннәр табыла.

Беркөнне Габделнур юыну бүлмәсендә кырына иде. Аның белән янәшә басып торган бер солдат тиктомалга бәйләнә башлады. Ул үзе дә яңакларын, ияген сабынлап алган, әледән-әле Габделнурга караштыра, ахырда яшь солдатны мыскыл итмәкче булды бугай.

— Син нигә кырынасың?

— Ә нәрсә?

— Синең анда бернәрсә дә юк бит. Әнә сөлге белән генә кырын. Лезвиеңне миңа бир. Синең анда өч төк ике рәткә тезелеп баскан.

Ул үзе кырына, үзе шырык-шырык көлә. Үз сүзеннән үзе тәм таба, күрәсең. Габделнурның ачуы кабынды. Карап торышка метр ярым буе бардыр, чирләшкә сыманрак нәрсә, аксыл ябык чырайлы. «Замухрышка, и ты туда же, кем әйтмешли, метр с кепкой», — дип уйлады Габделнур. Ул әле ротадагы солдатларның бөтенесен дә танып-белеп бетерми, мөгаен, бу инде соңгы елын хезмәт итәдер. Шулай да Габделнурның җене кузгалды.

Ул, дорфа гына:

— Минем дуңгызчылык хуҗалыгымда син этнең ни эше бар?!— диде.

Солдатның бритва тоткан кулы ярты юлда асылынып калды.

— Нәрсә?

— ... җилкә аша! Кайнар булса, икенче җилкәң аша ташла!

Солдат, күрәсең, моны көтмәгән иде. Чыраен сытты, аннан әле яртылаш ак күбекле йөзендә, ирен читләрендә мыскыллы елмаю чалынды.

— Мин күрәм: зәһәр шаяртасың...

— Син дә шаярт. Этнекеннән дә очлырак була алмассың.

— Син, авыл гыйбады!

— Әйе, тууын авылда тудым. Ләкин бөтен гомеремне шәһәрдә яшәп үткәрдем.

— Син, маңка! Кемгә?.. — дип кычкырып җибәрде солдат һәм Габделнурга таба омтылып куйды. — Мин бит — «картлач»! Ә син кем? Син нәрсә, аңламыйсыңмы әллә? Син нәрсә, тупыйкмы, аңгырамы әллә?

— Син үзең аңгыра, себер итеге кебек упа башлы.

— Мин сине... Гафу үтен! Ну!

— Хрен гну.

«Картлач» чыгырыннан чыкты, кулын күтәреп, Габделнур өстенә килә башлады. Приборларын куеп, Габделнур боксер стойкасын алды: аякларын аерып басты, кулларын йодрыклап, берсе белән йөзен каплады, икенчесен күкрәк турысында тотты.

— Кил әйдә, кил, башың ике булса!

Моны күреп, «карт этәч»нең кикриге шиңде.

Шулай да:

— Ярар, без сиңа күрсәтербез әле, — дип янады ул һәм ашык-пошык кырынып бетерде дә әйберләрен җыеп чыгып китте.

Габделнур, текәлеп карап, аның йөзен хәтерендә калдырды: бетчәле бит, очлы чөенке борын, сары чәч.

Габделнур озакка сузмыйча әлеге хәлне Нурмөхәммәтовка сөйләде.

Теге «картлач» белән бик батыраеп әрепләшсә дә, ул тәртәне катырак бөгеп ташлавын аңлады. Беренче көннәрдән үк алай тупас кылану, бәлки, кирәк тә булмагандыр. Ә икенче яктан уйлаганда, Нурмөхәммәтов аны кисәтте бит: бастырма, басымчак итәрләр. Әле кешесе адәм рәтле егет булса бер хәл иде — солдат бияләе белән бәреп егарлык нәрсә.

— Кем икән ул? Миңа күрсәтерсең әле, — диде якташы.

— Ярар.

Җаен туры китереп, Габделнур теге солдатны өлкән иптәшенә күрсәтте.

— Әнә теге...

— Ә, Нелидов. Бер бәйләнчек инде шунда. Дуслары бар, искәрт.

Габделнур белән Кронштадттан, нигездә, Литва егетләре килде. Ул аларга да бу хакта сүз катты. Чөнки алар да яшьләр. Кемнең кем икәнен белеп торсыннар.

Бу минутларда ротада дневальный вазифасын башкаручы, коридордагы тумбочка янында басып торучы Заранка яшьтәшен игътибар белән тыңлады. Нелидовка күз төшереп алды. Беләгендәге повязкасын рәтләбрәк куйды. Аннары:

— Ул иптәшләренә аркаланып бәйләнәдер, бүре булышса, куян да атны җиңә. Мин үзебезнең егетләргә әйтермен, — диде ул һәм шундук казармадагы бер якташын дәшеп алды. — Красаускас, кил әле.

Тегесе килгәч, ул аңа үзләре телендә нидер әйтте.

Анысы да озын буйлы, тырпаеп торган сары чәчле, ләкин ябыграк егет иде. Бер генә сүз әйтеп баш какты да, ул китеп тә барды.

Алар халкы гомумән аз сүзле. Дөрес, үзара алар сөйләшәләр, ләкин башка милләт егетләре аларның телен аңламый. Ә гомуми әңгәмәләргә алар кушылмый. Моның серен соңыннан белде Габделнур.

Литвада совет власте кырыгынчы елны гына урнаша. Аннары дүрт ел сугыш. Аннан соң да әле алар тиз генә яңача яшәүгә ияләшә алмыйлар. Бәлки, теләмәгәннәрдер дә. Күбесенең чит илләрдә туганнары бар, посылка җибәреп яталар. Күрәсең, тормышлары житү, начар урнашмаганнар.

Адомас Рудис исемле, хәтта укый-яза белмәүче солдат берчак ычкындырды:

— Мин монда яшәгәнче Канадада яшәр идем.

Аларда җиде класс белемле булу бездәге урта мәктәп бетерүгә бәрабәр. Чөнки күбесенең — дүрт класс, бишенче — коридор.

Алар бик бердәм егетләр иде. Заранка Габделнурны да үз даирәләренә тартты. Нурмөхәммәтов та Нелидовны кисәткән, ахры, шуңа күрә ул «картлач» тарафыннан нинди дә булса омтылыш сизелмәде. Ә шулай да сак-

лык чаралары күрү комачауламый иде. «Егетләргә әйтеп дөрес эшләдем бугай», — дип уйлады Габделнур. Хезмәте тыныч кына дәвам итте.

...Көн кичкә авышкан. Аяз зәңгәр күк йөзенә кояшның соңгы нурлары таралган. Сирәк болыт итәкләрен алсуландырып, көнбатышны гаҗәеп матур төсләргә манып, кояш баерга азаплана.

Урман эчендә кар күп. Агач кәүсәләренең түбәнге өлеше кар эчендә утыра. Бәләкәй генә чыршы үсентеләре киң итәкле яшел тун кигән балалар кебек — алар карга батканнар да гаҗәпләнеп туктап калганнар диярсең. Икенче карасаң, алар монда, олылар ышыгына ялгышып кына килеп чыккан нәниләрне хәтерләтә. Чөнки өлкәннәр күп, ә болар берничә генә. Кояш нурлары нишләп безгә килеп җитми икән, без туңарбыз бит, дип тә уйлыйлардыр әле.

Әйе, кояш нурлары әкрен генә офык артына төшеп күздән югала бара. Ул инде кыш буена яшеллеген җуймаган киң ябалдашлы нарат, сөңгедәй очлы, зур өчпочмакны хәтерләткән чыршы агачлары аша чак кына беленә. Шуңа күрәдер болай да салкын көн тагын да суына төште. Тып-тын. Кайдадыр, объект эчендәге агачларда, бернидән курыкмыйча тиеннәр сикерешсә дә, тыелган зона тышындагы урман эчендә берәр кыргый җәнлек ашыкмыйча гына узып китсә дә — аларның хәрәкәт итүе Габделнурның сизгер колагына чалынмыйча калмый. Әйе, әнә нәрсәдер чәнечкеле тимерчыбык койма артында әкрен генә йөри, ахры.

Солдат, игътибар белән карап аны күрмәкче булып, күзләрен шул якка төбәде. Ләкин... җәнлек түгел, ә кеше булып чыкты ул. Бот тиңентен кар ерып, бер адәм әкрен генә Габделнур вышкасына турылап килә иде. Дөрес, аңа килеп җиткәнче ул әле ике рәт чәнечкеле тимерчыбык аша узарга тиеш. Әмма ләкин часовойның вазифасы — аны үткәрмәү. Анымы, башка бүтәннеме — кем генә килсә-якынлашса да — тоткарлау. Сакчы шуның өчен куелган. Аның хезмәтенең төп бурычы — хәрби объектны саклау.

Габделнур бөтен көченә кычкырып җибәрде:

— Тукта, кем килә?!

Аның калын тавышы, урман яңгыратып, еракларга таралды, әйләнә-тирәсендәге һәр агачка барып ирешге. Әмма, гәүдәсен тигез тота алмаса да, башына бер колакчыны тырпаеп торган, икенчесе салынып төшкән мескен бүрек, өстенә иске генә кайры тун кигән теге бәндә киез итекле аякларын тирән кардан көч-хәл белән тартып ала-ала болай таба якынлашуын дәвам итте.

Габделнур, инде эшнең уен-муеннан узганын искәртергә теләп, карабинын кулына алды, баягы әмерен тагын да катгыйрак итеп, кискен рәвештә кычкырды:

— Тукта, атам!

Юк, туктамый. Язмышы белән уйный. Үз башына ашкынамы?!

Габделнур аның гәүдә торышыннан — төз тота алмавыннан, чайкалып-чайкалып китүеннән, башы салынып төшүеннән — ул кешенең аек булмавын аңлады. Чын исерекме, әллә мәтәштерә генәме?

Нинди җитди объект саклавын яхшы белгән солдат тревога кнопкасына басты, вышканың читенә үк килеп, алгарак авышып, карабинның көпшәсен һавага каратты да саклагычтан алып атып җибәрде.

Урман эчен яңгыратып, әллә кай тарафларга таратып, шартлау авазы яңгырады. Бер агач башыннан кар коелды — кошмы, җәнлекме, куркып, икенче урынга күчте.

Габделнур теге кешедән күзен алмады, аның һәр хәрәкәтен җентекләп күзәтте. Менә билгесез кеше башын күтәрде, үзеннән бер-ике адымда гына уңга да, сулга да тезелеп киткән баганаларга, аларга рәт-рәт сузылган чәнечкеле тимерчыбыкларга һәм вышкага карагач, анда мылтыгын аңа төзәп торган солдатны күргәч, айнып киткәндәй булды, ахры: борылып артына карады, беравык тын торды. Аннары ул бер аягын кар эченнән суырып алды, әкрен генә гәүдәсен бора башлады.

Габделнурның кисәтүе тагын урман яңгыратты:

— Тукта, атам!

Исерек исерек тә, хәлбуки мондый усал һәм боерулы тавышны ишетеп, кораллы часовой белән шаярырга ярамаганын, буйсынырга тиешлеген аңлап булса кирәк (бәлки, үзе дә кайчандыр армия хезмәтен үткәндер), ир-ат Габделнурга таба борылды һәм катып калды.

Ул арада каравыл бинасы ягыннан солдатларның йөгереп килгәнен абайлап алды Габделнур.

Теге адәм, ялан кулын сузып, ялварулы аваз салды:

— Солдат, җибәр, мин адаштым.

— Урыныңда тор, атам! — диде Габделнур, карабинын аңа төзәгән килеш.

...Әлбәттә, бернинди дә диверсант та, шпион да булмады ул бәндә. Гап-гади авыл мужигы, самогонны күбрәк чөмергән дә, ориентирны бутап, саклана торган объект тирәсенә килеп чыккан. Моны частьтагы особистлар тиз ачыкладылар.

Икенче көнне рота командиры, солдатлар алдында булып узган хәлне анализлагач, Габделнурны саф каршына чыгарды.

— Рядовой Гаделҗанов, постта уяулык күрсәткән өчен сезгә рәхмәт белдерәм, — диде ул.

— Советлар Союзына хезмәт итәм! — дип, казарма яңгыратты Габделнур.

Солдатлар арасында бу вакыйгага караш төрлечә булды.

— Нигә һавага аттың?

— Каравыл хезмәте уставы кушканча.

— Юләр, мондый очрак сирәк туры килә. Син башта аңарга ат идең дә аннары — һавага.

— Ничек инде башта ук аңа атасың? Ул бит кеше!

— Булса соң! Сиңа отпускы бирерләр иде.

— Ә губага тыгып куйсалар яки төрмәгә утыртсалар?

— Ул — часовой. Часовой — лицо неприкосновенное. Аның һәр кылган гамәле дөрес.

— Әгәр мин аткач ул үлсә? Ә аның өендә хатыны, балалары бардыр.

Җыелышып әңгәмә корган солдатларның берсе бик усал кыланды.

— Анысы инде синең кайгың түгел, — диде ул, зәһәрен йөзенә чыгарып. — Мин булсам, чәнечкеле тимерчыбыкка ябышканын көтеп торыр идем дә чүкер идем. Ике дә уйламас идем.

Габделнурның исенә төште: бу бит Сидоров фамилияле солдат, өченче елын хезмәт итә. Аның белән булган хәлне Нурмөхәммәтов сөйләгән иде.

Узган ел, кухняда бәрәңге чистартканда, сүз иярә сүз чыгып, Костоглотов фамилияле солдат: «Мин дуңгыз чәнчергә җәллим, җан иясе бит», — ди. Ә Сидоров әйтә: «Мин дуңгыз гына түгел, кешене дә чәнчи алам»,— ди. Юләр башлар: китә бәхәс. Костоглотов әйтә: «Юк, чәнчи алмыйсың!» Сидоров үзенекен такылдый: «Чәнчим!» «Мә алайса, минем күкрәккә када», — ди таза гәүдәле Костоглотов һәм гимнастерка изүен чишә дә аягүрә калкына. Сидоров та торып баса һәм әле генә бәрәңге әрчегән пычагы белән кизәнә дә... Бөтенесе өнсез кала: Сидоровның пычагы Костоглотовның күкрәгендә тырпаеп тора...

Бәхетенә, Костоглотов тәненә пычак тирән керми. Госпитальдә бераз ятып чыккач, ярасы төзәлә. Эшне дә хәрби прокуратурага җибәрми командование. Чөнки шаһитлар бар: Костоглотов үзе сораган. Сидоров частьта калган.

Габделнур, бу солдатка карагач, моның чыннан да ике дә уйламыйча, иман нуры булмаган күзен дә йоммыйча башта кешегә, аннары гына һавага атачагына инанды. Ләкин ул үзе алай булдыра алмас иде: тәрбиясе, холык-фигыле, кавеме андый түгел. «Нинди генә кешеләр юк бу дөнья йөзендә?! Ярар, син аттың ди тегеңә. Сиңа чираттан тыш ял бирделәр ди. Отпускыга кайткач, атаң-анаңа, йөргән кызыңа, авылдашларыңа ни диярсең? Кеше үтергән өчен бүләкләделәр диярсеңме? Юк инде, күрәләтә коралсыз, бер гаепсез кешене үтерү егетлек түгел».

Солдат тормышында физик көч — иң кирәкле нәрсәләрнең берсе. Ә моңа даими рәвештә күнегүләр ясап кына ирешергә мөмкин.

Бу частьта чаңгы ярышлары еш була икән. Беренче тапкыр Габделнур эстафетада катнашты. Унбер команда иде. Чөнки алар батальоны солдатлары гына түгел, матрослар һәм стройбат егетләре дә килгән. Беренче этапка барасы чаңгычылар урман авызындагы киң аланда бер рәткә тезелеп бастылар да, судья кызыл флагчык болгап команда бирүгә, дәррәү кузгалдылар.

Габделнур җан-фәрманга алга ыргылды һәм лыжняга беренче булып килеп чыкты. Тизлеген арттырганнан-арттыра барып ул шуса да шуды, очса да очты. Бераздан, урман эченә кергәч, артына борылып карады. Ләкин беркемне дә күрмәде. «Әллә ялгыштыммы?» дигән шөбһәле уй башына килде. Юк, юлдан язмаган, әнә борылмада кечкенә кызыл флажоклар ак карга төртеп куелган. Һәм ул, башлык белән җиңел спорт костюмы — трико гына кигән ялан куллы солдат, таяклары белән берөзлексез этенеп, алга баруын дәвам итте. Көчле кулларындагы озын таякларның очлы тимерләре карга кадала, фәкать боҗралары гына аларга җиргә хәтле батып керергә ирек бирми. Аягында ботинка, чаңгылары җиңел, майланган, чаж да чож килә — ак карга салынган пар эз буйлап барды да барды. Ун чакрым якын ара түгел — тирләп чыкты, бермәл тыны кысыла башлады, әмма бераздан яңадан ачылып китте, ягъни ярыш вакытында ерак дистанцияләрдә була торган хәл — икенче сулыш барлыкка килде. Спортчы янә күкрәк тутырып сулый башлады. Гүя күпчелек агачы нарат белән чыршыны тәшкил иткән урман аңа үзе берөзлексез саф һава өстәп тора иде. Бу тирә кай ягы беләндер Алабуга янындагы Шишкин картиналарында тасвир кылынган гаҗәеп матур урманнарны хәтерләтә... Дөрес, чаңгы юлы куе чытырманлыкка керми... Бөтен уе ярыш дәрте белән сугарылган, карашы алга төбәлгән булса да, ул инде йөрешен бер ритмга салган һәм, лыжня аркылы үтеп киткән көртлек кебек, кош-корт, куян ише киек җәнлек эзләрен дә шәйли башлады... Ә артта аны куып килүче спортчы күренмәде...

Шулай итеп, ул старт бирелгән урынга беренче булып килеп җитте һәм, эстафетаны тапшыргач, тынычланып, өченче, дүртенче этапка әзерләнеп торучы үз взводы егетләре белән сөйләшә башлады.

— Нишләп берсе дә минем арттан чапмады?

— Ә монда свалка булды, — диде егетләрнең берсе.

— Ничек?

— Синең арттан ыргылган узышчы егылды да, өч солдат, ике матрос аның өстенә менде. Ә син очтың. Тегеләр торып, исенә килеп юл алганчы синнән җилләр исте.

Взводныйның да, рота командирының да күңелләре күтәренке иде. Чөнки калган өч солдат Габделнур алып килгән кадерле минутларны озайтмадылар. Киресенчә, берсе тагын да киметә төште.

Икенче тапкыр, монысында рота солдатлары һәркем үзе өчен бара иде, Габделнурның үзенә егылу ачысын татырга туры килде.

Монда инде чаңгычылар, ара калдырып, берәм-берәм киттеләр. Дистанция уртасында Габделнур ике солдатны узды, өченчесенә дә:

— Лыжня! — дип кычкырды.

Кагыйдә буенча ул чаңгычы да, ике эзнең берсен калдырып, читкәрәк чыгарга тиеш иде. Ул шулай эшләде дә. Ләкин артына карап кем килүен күргәч, таягын Габделнурның аяк арасына тыкты. Егет мәтәлеп барып төште, чаңгысы сынды. Егылса да, ул алга киткән теге солдатны танып алды — Нелидов икән.

Ә өченче ярышта аны бер сержант этеп екты. Күрәсең, Нелидов эшнәләреннән берсе булгандыр. Әмма бу юлы Габделнурның чаңгысы исән калды, һәм ул финишка үзеннән шактый алда киткән берничә солдатны узып килеп җитте.

Соңыннан шуны белде Габделнур: аны төртеп еккан сержант ротада иң оста чаңгычыларның берсе булган икән. Димәк, яшь солдат — аңа көндәш.

Вак-төяк сүзгә килүләр болардан башка да булгалады. Ләкин аңа карап кына Габделнурның күңеле төшмәде, хезмәткә булган дәрте сүрелмәде. Ул һәр эшен җиренә җиткереп башкарырга тырышты, рота һәм батальонда уза торган чараларда актив катнашты. Моны командирлар да күрми калмаган, әлбәттә.

Габделнур ике айлап хезмәт иткәч, аны рота командирына чакырттылар. Ни өчен икәнен әйтүче булмады. Хәер, аңа әйткән солдат-дневальный үзе дә берни белмәгәндер. Аңа кушканнар, ул — үтәүче.

Ишек шакып керде. Рота командиры үзе генә түгел иде. Аның янында таза гәүдәле, юан муенлы батальон командиры подполковник Зирюк утыра иде. Яланбаш, куе яшел гимнастеркадан, күкрәгендә орден-медаль планкалары.

Габделнур аякларын шапылдатып янәшә куйды, тураеп басты, кулын чигәсенә куеп честь бирде.

— Иптәш подполковник, иптәш капитанга мөрәҗәгать итәргә рөхсәтме?

— Мөрәҗәгать итегез.

— Иптәш капитан, рядовой Гаделҗанов сезнең боерык буенча килде.

Комбат, елмаеп:

— Капитан, карале, синең бөтен солдатларың да шундый булса?! — дип куйды. — Һич шикләнмичә Кремль полкына, почетлы каравылга җибәрергә була. Утыр.

Соңгы сүзе Габделнурга адресланган булса да, солдат бермәл югалып калды. Аның моңарчы батальон командирын болай якыннан күргәне юк иде. Ул — солдат, ә комбат — йөзләгән солдатның «атасы». Плацта сафка тезелгән чакта гына аны күреп була яисә казарманы тикшереп-карап йөргән минутларында. Ә болай каракаршы утыру ул — гайре табигый хәл. Ләкин кушканнар икән, димәк, син утырырга тиеш.

Күрәсең, комбатның кулында Габделнурның шәхси карточкасы иде. Ул әкрен генә укый. Калын иреннәрен кыймылдатып, сүзләрне өзек-өзек әйтеп бара.

— Тәк-тәк... Начар түгел... Бара... Монысы да яхшы... — Ул, кыска чәчле башын күтәреп, рота командирына карады. — Минемчә, бар яктан да туры килә. Ничек уйлыйсың, Степан Максимович?

Рота командиры, егерме биш-утыз яшьләрендәге ябык гәүдәле капитан, аның сүзен җөпләде:

— Борис Федорович, җибәрергә кирәк, — диде ул. — Менә дигән командир чыгар. Үрнәк солдат. Бернинди замечаниесе юк. Яхшы ата, спорт белән шөгыльләнә — икенче разрядлы чаңгычы. Сафта йөрүе карап туйгысыз.

Капитан сөйләгәндә, комбат, зур башын әледән-әле селкеп, канәгать икәнен белдереп утырды. Аннан үзе сүз алды.

— Якташ, — диде ул, Габделнурга карап елмаеп. — Мин — Башкириядән. Әйе, анда да украиннар бар. Инде күптән ул яклардан чыгып китүемә... Сине кабат Кронштадтка, кече командирлар мәктәбенә җибәрергә исәп. Ничек уйлыйсың?

Солдат ничек уйласын инде? Аның өчен «батя» уйлый, рота, взвод, отделение командирлары һәм, ниһаять, рота старшинасы бар. Солдат күп уйламаска тиеш.

— Белмим, — диде Габделнур чын күңелдән. — Әгәр булдыра алсам...

— Булдырырсың, — диде подполковник, солдатның ихлас җавабыннан разый булып, һәм шадрарак тулы йөзе тагын җәелеп китте. — Анда дүрт-биш классны Балтыйк буе егетләрен җибәреп булмый бит инде.

— Димәк, риза?

Рота командирының сүзенә Габделнур икеле-микелесез, төгәл җавап бирде.

— Әйе.

— Алты айдан кабат үзебезнең частька кайтырсың, — диде батальон командиры. — Аннан соң күз күрер. Һәрхәлдә, синнән яхшы сержант чыгачагына шигем юк. Бар, әзерлән.

— Калганын соңыннан әйтермен, — диде рота командиры.

Габделнур торып басты. Бөтен шартын китереп честь бирде.

— Китәргә рөхсәт итегез!

— Барыгыз.

Шулай итеп, Габделнурга, инде ияләнә башлаган җиреннән кубып, вакытлыча тагын яңа-иске урынга күчәргә туры килде.

Үзе булмаган кеше хәрби хезмәтне берьяклырак кына күз алдына китерергә мөмкин: солдат яки матрос көне буе занятиеләрдә утыра, ату белән шөгыльләнә, сафта йөри, фәкать кич белән генә эт булып арып-талып йокларга ята. Кайберәүләрнең фикер сөреше киресенчәдер: солдат көне-төне йоклый, ә хезмәте бара. Юк шул, солдат хезмәтенең дә үз романтикасы, шатлык-сөенечләре, мәзәк хәлләре була, авырлыклары — анысы да җитәрлек.

Дөрес, солдатның һәр минуты булмаса да, һәр сәгате билгеле бер тәртипкә буйсына: йокыдан тору, физзарядка, иртәнге аш, занятие, көндезге аш, эш яки тагын занятие, кичке аш, буш вакыт һәм, ниһаять, отбой. Ләкин шуның өстенә солдат әле кино да карый, атна саен мунчага да йөри, экскурсияләргә дә бара, кайчагында урамда патруль вазифасын да башкара, увольнениегә дә чыга.

Беренче мәртәбә чагыштырмача ирекле рәвештә Кронштадт урамнарында йөрү Габделнур өчен кызык һәм истәлекле булып калды.

Аларны комендатурада озын буйлы (ике метр бардыр) капитан каршылады. Ул шәһәр комендантының урынбасары икән. Морякларныкы шикелле кара киемнән, ләкин погоннары кызыл сызыклы, җиңнәрендә дә алтын тасмалар юк. Тиешенчә инструктаж биреп, патруль булып йөргәндә ни-нәрсәгә игътибар итәргә тиешлекләрен аңлаткач, ул солдатларны ияртеп чыгып китте.

Әле кояш баемаган, шулай да «кызыл шар» әкрен-әкрен диңгез артына шуышып бара. Аның алсу нурлары ерактагы хәрби корабльләрнең мачталарына, челтәрле радарларына, крейсерның колач җитмәстәй юан, озын, өчәр-өчәр куелган туп көпшәләренә, су асты көймәләренең сырты гына күренеп торган кит түшкәседәй алагаем зур корпусларына һәм алар өстендә калкып торган рубкаларына, кечерәк катерларның торпеда аппаратларына — салкын тимерләргә, шул кораблар эчендә көнне төнгә ялгап, айлар-еллар буена сугышчан вахтада торучы матрос-офицерларга җылы биреп калырга теләгәндәй яктылык тарата. Фин култыгының коңгырт-кара су өстен алсуландыра, тыныч көн булса да сизелер-сизелмәс хәрәкәттә булган вак дулкыннарның ак сыртларын кызарта, янәшәдәге бакчаның — Петр паркының юкә агачларын иркәли — яшел яфраклар арасыннан каралҗым кәүсәләренә хәтле үтеп керә.

Җәйге бакчада халык берән-сәрән генә әле. Матрослар да, кыз-кыркын да сирәк.

Юкә генә түгел, өрәңге, каен агачлары арасында тары ярмасы хәтле генә вак кызгылт таш-ком түшәлгән сукмаклар салынган. Мондый кызгылт сукмакны Габделнурның беренче күрүе иде. Ул, иелеп, бер-ике ташкомны кулына алудан үзен чак кына тыеп калды. Бакча эче җиләс, һавасы саф, өзлексез сандугачлар сайрый, күгәрченнәр йөренә. Өстә сирәк кенә акчарлаклар күренә — чыелдап очалар. Еракта, артта да (су өстендәдер) тавышлары ишетелә.

Егет тукталып калды. Чөнки бакча уртасында почмаклары яфрак сыман сырлы чәчәкле орнаментлар белән бизәлгән кызгылт гранит постаментта шәһәргә нигез салучы Петр Беренче басып тора иде. Биек постамент берсеннән икенчесенә тимер чылбырлар сузылган кыска кара баганалар белән (алар җир өстеннән ярты метр чамасы гына калкып торалар, тышка таба авышлар) уратып алынган.

Патшаның сыны буенча салынып төшкән уң кулында камчы, ә сулы белән бөеренә таянган, кыяфәте горур, хәтта тәкәбберрәк. Хәер, алай булса да гаеп түгел, урыс дәүләтен дөньяга таныту, көчен ныгыту өчен байтак эш майтарган бит ул. Әнә түшендә бүрек хәтле орден. Башына да кимәгән, чәчләре бөдрәләнеп тора (әллә парик микән), мыегы нәкъ рәсемнәрдәгечә, тезенә хәтле җиткән өс киеменнән; киеме, гомумән, катлы-катлы шикелле, уң иңеннән биленә тасма төшә, киң билбау, чалбар, берсен алгарак чыгарып баскан аякларында озын кунычлы, тез турында киңәеп киткән итек — ботфорт. (Бу итекне ул үзе тегеп кигән, диләр.) Сул якта, артта, таякмы, нәрсәдер асылынып тора. Һәйкәл үзе кара төстә, патша тыныч карашын диңгезгә, бераз уңгарак (үзе «тәрәзә ачкан» Европагадыр инде) төбәгән. Кыскасы, ике метрга якын буйлы, киң җилкәле чын баһадир һәм үз иленең хуҗасы. Юкка гынамы аны Алла урынына күрәләр: кинофильмнар төшерелгән, китаплар язылган, рәсемнәр ясалган.

Хәер, үзе дә бик булдыклы, куркусыз кеше булган. Гангут янында шведларның флотын җиңгәч, аңа вице-адмирал дәрәҗәсе бирелә бит. Постаментта дүрт юллык язу: «Петру Перьвому Основателю Кронштадта 1841 года». Габделнур, язуны укыгач: «Күрәсең, ул заманда кагыйдәсе шулай булгандыр», — дип уйлады. Чөнки «Перьвому» дигән сүздә нечкәлек билгесе бар. Елы да һәйкәл куелу елыдыр, чөнки Кронштадтка ул 1704 елны нигез сала, Петербургны саклау өчен кирәк була.

Габделнур патрульгә чыккан иптәшләреннән аерылып калса да, әле һаман һәйкәлдән, аның тирәсеннән күзен ала алмый иде. Кайчан килә, кайчан күрә әле ул моны тагын. Әнә һәйкәл әйләнәсенә куелган бетон-агач утыргычларда ике-өч ир-ат гәп кора. Өлкән яшьтәге бу агайлар элекке диңгез офицерларыдыр инде — киемнәре ярым хәрби. Алар, әлбәттә, монда көн саен чыга алалар. Биек шакмаклы баганаларны, алар өстендәге ваза шикелле тоткалы кара савытларны, әлегеләреннән дә биегрәк, шәм шикелле төз баганалардагы борынгы фонарьларны алар көн саен күзәтә бит. Һәйкәлгә таба сузылган, як-ягында шарлы кыска тимер торбалар утыртылган киң сукмакта көненә ничәмә-ничә кешенең аяк эзе каладыр...

— Гаделҗанов, калма, — дип кычкырган тавышка Габделнур айнып киткәндәй булды, ерак гасырлардан бүгенге көненә кайтты һәм, йөгереп, патрульне куып җитте.

Һәйкәл яныннан китеп, парктан башта киң урамга, аннан алагаем зур, биек өч-дүрт күтәрү краны булган ДОКка килеп чыктылар. Монысы да «Петровский» дип атала, патшаның үзе тарафыннан проектланган һәм

аның указы нигезендә хәрби корабларны ремонтлау өчен 1719–1752 елларда корылган. Аңа пирс ягыннан канал ерганнар һәм корабларны кертү-чыгару өчен култыктан су җибәргәннәр. Әле хәзер дә бер кораб каналда тора. Ул кергәч, суны шлюз — тимер капка буып куйган. Патруль ДОК яныннан тар гына кыска күпердән үтте. Күпернең аргы башында ак төстәге биш тәрәзәле маяк, түбәсе кызылга буялган.

Аннары юлга таш урынына чуен плитә-пластинкалар җәелгән урамны узып үттеләр. Габделнурның дагалы итеге чык-чык иткән һәр адымын санап калды ул урам. Сулга борылып, янә бер киң урамга чыктылар.

Урамның каршы ягында тротуардан ашыга-ашыга бер матрос бара иде.

Капитан көр тавыш белән аңа дәште:

— Матрос, кил монда! — диде ул, сул кулын күтәреп һәм имән бармагын ике-өч тапкыр үзенә таба бөгеп.

Матрос туктады, борылды, йөзенә гаҗәпләнү галәмәте чыгарып, уң кулының имән бармагы белән күкрәгенә төртеп күрсәтте. Минме, янәсе.

— Әйе, әйе, син, — диде капитан, янә кулы белән ымлап.

Йөз-кыяфәтенә караганда матросның киеме, авыл карчыклары әйтмешли, «чын ясау» — чиста, үтүкләнгән, үзенә таманлап киселгән-тегелгән, беренче генә елын хезмәт итми иде булса кирәк. Башында кара тасмалары җилкәсенә төшкән ак түбәле бескозырка, зәңгәр якалы ак форменка эченнән тельняшкасы күренеп тора, клеш балаклы кара чалбарын якорь рәсеме төшкән ялтыравык аеллы кара каеш белән буган, аягында кара ботинка. Бер яктан икенче якка авышыбрак атлап килде дә бик килешле генә итеп честь бирде. Киемендә дә, йөрешендә дә тел-теш тидерерлек нәрсә сизелми иде. «Ник дәште икән моны капитан?» — дип уйлады Габделнур.

— Иптәш капитан...

— Увольнительный?

Матрос кесәсеннән кәгазь алып күрсәтте. Капитан аны игътибар белән укып чыкты.

— Кая барыш?

— Таныш кыз янына.

— Шешәңне калдыр.

Матросның гаҗәпләнүдән күзләре маңгаена менде.

— Нинди шешә, иптәш капитан?

— Ярар, ярар, матрос, бир шешәңне.

Кемнең инде үзе теләп кулга кергән «мал»ны бирәсе килсен. Бигрәк тә ул күренеп тормаса.

Габделнур янындагы хезмәттәшләре белән карашып алды. Чөнки матросның кулында бернәрсә дә юк, кесәләре дә тырпаеп тормый. Ләкин озак еллар комендатурада хезмәт иткән капитан Катерина (аның фамилиясе шулай иде) үзен алдарга ирек бирмәс: әллә каян сизеп-күреп тора кемдә нәрсә барын. Ул, иелеп, матрос чалбарының киң балагын тездән түбән чеметеп кенә күтәрде. Беренче мәртәбә патруль булып чыккан Габделнурның күзе шарланды: бер шешә аракы матросның аягына бәйләп куелган иде. Күрәсең, капитан аны йөрешеннән сизеп алган. Матроска, иелеп, аяк балтырындагы шешәне ычкындырып, офицерга бирүдән бүтән чара калмады...

Бераз баргач, урамда тагын бер матросны, дөресрәге, погонында аркылы өч тар тасмалы беренче статья старшинаны туктатты капитан. Бу юлы да «бер гаепсез» морякның аракысын чыгарттырды. Анысы каеш астына кыстырылган (корсак турысында) булып чыкты.

Комендатурага әйләнеп кайтканда дүрт немец матросы очрады. Эш шунда: Кронштадтта, ДОКта, ике ГДР эсминцы ремонтта икән. Алар турында хәрби частьларның барысында да беләләр һәм һәрбер солдат-матрос кисәтеп куелган: алар белән аралашмаска, конфликтка кермәскә. Ләкин безнең солдат кайчагында киресен эшли бит.

Габделнур ике тапкыр алар белән урамда очрашты: немецлар да сафта, безнекеләр дә. Алар белән «бәрелешү»дән сак булырга дип әйтелгән булса да, безнекеләр:

— Гитлер капут! — дип каршыладылар. — Хенде хох!

Тегеләр дә җавапсыз калмады:

— Руссиш швайн! Саляга! — дип кычкырдылар.

Сафлар шулай бер-беренә «ягымлы» сүзләр әйтешеп «дусларча» аерылыштылар.

Ә безнең бер матрос, увольнениегә чыккач, урамда очраган ике немец матросының берсен изүеннән эләктереп:

— Ни өчен минем әтине үтердегез?! — дип, тегенең ипи шүрлегенә менеп төшкән.

Моңа да һич аптырарлык түгел. Чөнки Габделнурлар белән хезмәт итүчеләрнең байтагының аталары немец-фашистларга каршы сугышта һәлак булган. Ятим үскән малайларның, немец милләте вәкилләрен күрүгә (аның кем булуына карамастан), күкрәгендә нәфрәт уты дөрли башлый иде.

Аннары, аларга бигүк ышанып та җитмиләр иде бугай. Чөнки Габделнурларның замполиты солдатларны кат-кат кисәтеп кенә калмады:

— Ул корабльдәге кайбер офицерларның безнең хәрби объектлар белән кызыксыну очраклары билгеле, — диде. — Алар белән танышкан хатын-кызлар да безнең чекистларның күзәтүе астында.

Менә шулай, урысларның дружба — дружбой, а табачок — врозь, дигәне кебек, немец егетләре белән брудершафтка эчү юк.

…Немец матрослары дүртәү иде. Икесенең кулында ятьмә сумка, ә анда сыра шешәләре һәм кәгазьгә төрелгән кабымлык булса кирәк.

Капитан Катерина матросларны туктатты һәм чип-чиста немец телендә алар белән сөйләшә башлады.

Габделнур авылда җидееллык мәктәптә немец телен өйрәнгән иде. Аларны сугыш вакытында ничәдер ел әсирлектә булган бер абый укытты. Ул китаптан уку гына түгел, ә сөйләшүен дә чатнатып немецча сөйләшә иде. Бер-ике елда шактый нәрсә өйрәнделәр укучылар аңардан.

Менә шул, техникумда чит тел кермәгәч, Габделнурның бар белгәне исеннән чыгып очкан инде.

Ә капитан Катерина, саф немец телендә тегеләр белән сөйләшеп, аларны комендатурага алып керде, корабль номерларын язып алды да ятьмәләрен кире биреп чыгарып җибәрде. Иң гаҗәбе шул булды патрульгә чыккан егетләргә: Катерина сыраларын алып калмады. Ә безнең матросларны аракыларыннан мәхрүм итте.

Икенче вакыт Габделнур, увольнениегә чыккач, үзе чак кына «янмады». Алар өчәү киттеләр: озын таза гәүдәле солдат — Новгородтан, ә икенчесе — ябыграк чырайлысы — Псков өлкәсеннән чакырылган егет.

Өч солдат иң беренче нәүбәттә нишли инде, әлбәттә, кесәсендә «рәте» булса, кибеткә керә. Һәм, җыештырып, шулай иттеләр дә.

Флотская урамыннан бераз баргач, сулга, Карл Маркс урамына борылдылар. Бихисап колонналы озын йорт — үзе бер кварталны биләп торучы Гостиный дворның — сәүдәгәрләр курасының беренче катына сугылып чыктылар. Янәшәдәге сквер-бакча эчендә генә хәл итмәкчеләр иде дә, шикләнделәр, чөнки урамда ун кеше очраса, аның сигезе хәрби бит. Гражданская урамындагы өч катлы йортларның (ә монда алар барысы да тәбәнәк — ике-өч-дүрт этажлы гына) берсенә юнәлделәр. Подъездга кереп, иң беренче фатирның кыңгыравына бастылар. Егетләр кырыйдарак, ә Габделнур ишек турында иде.

Уртача буйлы, илле яшьләр тирәсендәге ак чәчле ир кеше ишек ачты. Ул спорт костюмы чалбарыннан һәм майкачан иде.

— Исәнмесез.

Хуҗа аларның сәламен алды һәм:

— Ни йомыш? — дип сорады.

Габделнур, читенсенеп кенә:

— Стакан бирмәссез микән? — диде.

Хуҗа елмаеп куйды.

— Була. — Аннан, нидер исенә төшкәндәй, кире борылды. — Баскычта гына эчәсезмени? Керегез өйгә. Бу йортта офицерлар күп. Күрүләре ихтимал.

Солдатлар бер-беренә карашып алдылар. Берсе дә фатирга аяк басарга кыймый иде. Әмма офицерлар күзенә чалынмавың да хәерле. Новгород егете тәвәккәлләде.

— Мөмкин.

Коридорга кергәч ишек катында ук өчесе дә өнсез калдылар: кием элгечендә ике йолдызлы погоннары ялтырап торган кара китель эленеп тора иде.

Гомерендә тотлыгуның нәрсә икәнен белмәгән Габделнур:

— И-иптәш икенче ранг капитаны, — дип көчкә телен әйләндерде, — гафу итегез, зинһар…

Хуҗа, елмаеп, аңа аркаларын күрсәтә башлаган солдатларга дәште:

— Мин запаста инде, курыкмагыз.

Шуннан соң гына егетләрнең эченә җылы керде. Тулы гәүдәле, әмма хәрәкәтчән хуҗа, аларны кухняга дәшеп, стаканнар куйды, кабарга әзерләде. Габделнур аңа үзенә дә стакан алырга кушты.

Хуҗа:

— За тех, кто в море! — дип бушаткач кына егетләр стаканнарын күтәрделәр.

— Сезнең исәнлеккә, иптәш икенче ранг капитаны, — диде Габделнур.

Хуҗа, күрәсең, аның сөйләмендә акцент барын сизгән, ахры.

— Син кайсы милләттән? — дип сорады. — Татар түгелме?

— Әйе.

— Мин дә татар бит, — диде хуҗа һәм болай да дустанә йөзе тагын да яктырып китте.

…Алар ярты сәгать чамасы утырдылар бу кунакчыл җыйнак кына өйдә. Хуҗаның аларны, бигрәк тә Габделнурны җибәрәсе килмәгән иде. Чөнки ерак бабаларының туган якларыннан солдатка алынган кеше белән бер сөйләшү үзе бер гомер иде аның өчен.

Ул Хәрби-диңгез училищесын тәмамлаган, су асты көймәсендә хезмәт иткән, сугышта катнашкан, хәзер ялда икән. Гаиләсе дә булган, ләкин сугыш вакытында алар йортына бомба төшеп, хатыны белән баласы һәм әнисе һәлак булганнар.

Офицер укымышлы кеше иде. Киштәләре китап белән тулган. Ул, икенче очрашкач, солдатларга Ленинградның һәм Кронштадтның төзелү тарихы, Петр Беренче, Хәрби диңгез флоты турында бик күп нәрсәләр әйтте. Үзе татар булгач, аны күбрәк бу якларда яшәгән милләттәшләренең язмышы да кызыксындыра икән.

— Петербургны төзегәндә безнең бабайлар да нык тырышканнар, юрталарда, салкын землянкаларда ачлытуклы яшәгәннәр, күбесенең сөякләре сазлыкка батып калган… Шәһәр кеше сөякләре өстенә корылган, имән

субайларда гына тормый… Әле 1710 елда ук Казаннан Россия флотына биш кораб төзеп җибәргәннәр. Берсенә шәһәр исеме бирелгән була...

Ленинградта татарлар шактый күп икән, ә Кронштадтта — азрак. Нигездә, диңгез офицерлары һәм аларның хатыннары.

— Элек Кронштадтта безнең халык флотны азык-төлек, кирәк-ярак белән тәэмин итүдә катнашкан, сәүдәгәрләр инде. Владимир урамы чатында Татар йорты да булган. Хәзер дә гражданский халык арасында татарлар бар, — диде ул. — Мин күпчелек үз ишләрем белән аралашам. Ә флотта татар егетләре элек-электән намуслы хезмәт иткәннәр, хәтта адмираллар да бар… Патша Россиясендә үк адмирал булган бер татар турында беләм...

Офицерның бүлмәсендә баян күреп, Габделнур аны сорап уйнады. Икенче ранг капитаны өчен бу аерата шатлык иде.

— Рәхмәт, энекәш, — диде ул, сөенеп. — Мин үзем эч пошканда гына тоткалыйм. Уйнавым да — ташка үлчим, үзем өчен генә. Шулай да бер юаныч. Татар көйләрен ишеттергәнең өчен аеруча рәхмәт.

Бераз уйланып утыргач, ул көрсенеп куйды.

— Мин ана телен дә бик белмим, фамилиям генә калган. Чөнки минем ерак бабайны унбер яшеннән ата-анасыннан тартып алып, Петр Беренче мәҗбүри рәвештә флотка китерткән, юнга итеп. Аның оныклары тырыша-тырмаша офицер дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр. Минем эти дә өченче ранг капитаны иде. Сугышта һәлак булды. Зиратта аларның су асты көймәсе экипажы тулысы белән… Барып чыксаң, күрерсең әле. Анда сугыштан соң баткан экипажларга да кабер ташлары куелган…

...Соңрак Габделнур чыннан да аларны күрде: бер кабер ташына дистәләгән фамилия язылган. Төрле милләтләрнең газиз уллары ташка уелган. Кемнәрнеңдер кадерле балаларыннан, баһадирларга тиң асыл егетләрдән фәкать шул язулар гына калган. Чөнки ул морякларның күбесе кайдадыр диңгез төбендә, корыч табутлар эчендә яталар булыр. Бу ташлар — христиан зиратында. Моннан тыш шәһәр читендә мөселман (татар) һәм лютеран (католиклар) каберлеге дә бар икән әле.

Офицер белән саубуллашып урамга чыккач, егетләр Якорь мәйданына таба атладылар.

Кызгылт гранит ташта (ә ул галәмәт зур ташны бөтен килеш китергәннәр) сакаллы бер карт басып тора. Сул кулын алга сузган, уңы шинель кесәсендә, башында фуражка. Кызгылт таш өстенә астан кара төстәге дәһшәтле диңгез дулкыннары ургый, менә-менә аны юып төшерерләр төсле. Ләкин курку белмәс диңгезче аларга һич игътибар итмичә горур кыяфәттә басып тора. Һәйкәлнең һәр дүрт почмагында да чылбырлар белән үзара тоташкан якорьлар, алар хәтта икешәр. Әйләнә-тирәсен чәчәкләр бизи, газонда яшел чирәм үсә, читтәрәк шакмаклы таш — булыжник түшәлгән. Һәйкәлдә язу: «Адмиралу Степану Осиповичу Макарову». Астарак ташның каян, кайчан һәм ни өчен китерелүе, һәйкәлнең Император Николай Икенче катнашында ачылган икәне дә (1913 елның 24 июле) язылган. Ләкин Габделнурның иң нык исендә калганы һәм соңыннан күп мәртәбәләр уйланырга мәҗбүр иткәне менә бу язу булды: «ПОМНИ ВОЙНУ!». Рус-япон сугышы каһарманы, күпне күргән адмирал, һәрчак сугышны истә тотарга кушкан икән, димәк, бу тикмәгә түгел...

— Кечкенә генә шәһәр, — дип, иптәшләренә мөрәҗәгать итте Габделнур, — ә саный китсәң, Макаровтан башка да бик күп мәшһүр исемнәр монда үзләренең эзен калдырган: Белинсгаузен һәм Крузенштейн, Даль һәм Римский-Корсаков, Попов, Николай Гумилев, Айвазовский...

— Аңа мин дә хәйран калам, — диде егетләрнең берсе.

Һәйкәл артында тирән чокырлы канау, җәяүлеләр йөри торган тар тимер күпер, ике як ярда да агачлык. Сулда яшел түбәле, биек гөмбәзле, тәрәсез зур Диңгез Соборы. Анда Матрос клубы, шунда ук «Максимка» кинотеатры. Сугыш вакытында Собор күзәтү пункты булган, чөнки ул шәһәрнең иң биек урыны. Уңда таш койма, артта чылбыр белән әйләндереп алынган киң мәйдан һәм арырак, урам чатында, йортлар күренә. Әйләнә-тирәдә юкә агачлары, Собор артында сирень куаклары шау чәчәктә. Бу шәһәрдә, гомумән, диңгез һавасы белән кушылып, һәр тарафтан сирень, юкә һәм кәстәнә агачларының хуш исе аңкып тора.

## 9

Солдат-матрос арасында «байка» дип йөртелә торган гыйбарә бар. Ул кеше ышанмастай хәлләр, вакыйгаларга корылган була. Ләкин кайчагында хәрби хезмәттән кайткан егетләр сөйләгән бу «байка»лар чын дөреслеккә дә туры килә торгандыр. Шулай да, әйтик, Габделнур, мин оборона министрын күрдем, дип сөйләсә, ышанучы сирәк булыр. Фәкать үзе солдат шулпасы эчмәгәннәр генә авыз ачып тыңлап торыр. Ә аны үз башыннан үткәргәннәрнең берсе, ну, егет, шыттырасың да инде, дияр, ә икенчесе, кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә, дияр, өченчесе исә, аны ярты юлда ук бүлеп, алдакчы дигән ярлык тагарга да күп сорамас. Чөнки солдат кайда да, министр кайда?! Солдат җәһәннәм астындагы бер казармада, ә министр Мәскәү Кремлендә утыра. Ләкин, ни хикмәт, министр да гел үз кабинетында гына утырмый икән шул.

Икенче мәртәбә патруль булып чыккан көн иде. Әлбәттә, министр киләсе, нихәтле яшерен гамәл булса да, хәрби частьларда сизелми калмый. Андый дәрәҗәле кеше түгел, полк яки батальонга дивизия командиры киләсе булса да бөтен җир чистартыла-тазартыла, солдатның киеме, кыяфәте кат-кат тикшерелә, казармада үрнәк тәртип урнаштырыла, плац һәм сукмаклар себерелә. Кыскасы, карт солдатлар әйтмешли, саргая башлаган үләннәрне дә яшелгә буяткан солдафон-командирлар була.

Шуңа күрә, патрульгә билгеләнгәнче үк, Габделнур оборона министры киләсен белә иде. Аңлашылса кирәк, аның белән Хәрби диңгез флоты командующие да булачак.

Патрульнең үз вазифасы бар: урамнардагы тәртипне (хәрбиләргә кагылышлысын) күзәтү, солдат-матросның төскыяфәтен, киемен тикшерү һәм башкалар.

Бүген кояшлы җылы көн. Яр буенда гадәттәгечә җиләсрәк. Габделнур бу тирәләрдә элекке чыгуында да булган иде инде. Ул чакта капитан Катерина аларны туктатып тормыйча ары алып киткән иде. Бүген нишләптер пирс тирәсеннән ерак китми, әледән-әле су буена караштыра. Ниһаять, ул адымын акрынайтты, туктады.

Усть-Рогатка пирсында «Киров» крейсеры, эсминецлар, су асты көймәләренә каршы көрәшүче кече һәм зур кораблар, мина тральщиклары, торпеда катерлары һәм су асты көймәләре генә түгел, алагаем зур крейсердан да ике мәртәбә озынрак һәм биегрәк «Юрий Долгорукий» атлы кит аулау флотилиясе дә тора иде. Зифа буйлы хәрби кораблар арасына бу котсыз зур гражданский кораб, кем әйтмешли, күн итекләр рәтенә килеп эләккән кирза кебек, ни өчен килеп елышты икән? Күрәсең, бүтән җирдә бу гигант туктарлык урын булмагандыр.

Пирсның бу ягында, кораблардан уңдарак, бер катлы озын кызыл бина — Петр Беренче заманыннан бирле сакланып калган «Голланд кухнялары». Ул — ярлары гранит ташлар белән ныгытылган «Итальян буасы» белән янәшә буаның уртасында өскә таба су сиптереп торучы фонтан. Гомумән, монда чит ил сүзләре еш кулланыла, чит җирләр белән бәйле корылмалар шактый. Буадан ерак түгел агачларга күмелеп бер бина утыра — аны «Итальян сарае» дип йөртәләр. Капитан Катеринадан Габделнур тагын бер сүз ишетте — футшток. Безнең ил территориясендәге биеклекләр һәм тирәнлекләр Кронштадт футштогындагы нульдән исәпләнә икән.

Әлбәттә, авылына кайткач, Габделнур, малайларның күзен кызыктырып, менә бу — министр белән күрешкән кул, шул көннән соң бер атна буена юмадым, дип тә лаф ора ала. Ничек дисәң дә була, ни әйтсәң дә ышанулары ихтимал. Ләкин ул һич тә алай әйтә алмас иде, чөнки чынбарлык бүтәнчәрәк.

Патрульдәге солдатлар министр Малиновскийны да, флот башкомандующие Горшковны да ерактан гына, алар ап-ак катердан төшкәндә генә күреп калдылар.

Капитан Катерина, егетләргә карап:

— Бу мизгелне хәтерегездә саклагыз: сез тере Малиновскийны күрдегез, — диде. — Дүрт сугышны — Беренче бөтендөнья, гражданнар, Испания һәм Бөек Ватан сугышларын үз башыннан кичергән каһарман ул.

Азмы-күпме газета караштырып барган, телевизор караган кеше буларак, Габделнур аны шундук таныды. Чөнки Родион Яковлевич Советлар Союзы Маршалы булу өстенә ике тапкыр Советлар Союзы Каһарманы да иде. Сугыш вакытында үсеп чыккан полководецларның берсе, иң тәҗрибәле, иң күренекле маршаллардан санала.

Безнең татар егетләре турында бик күп җылы сүзләр әйткән кеше. «Мин, карт солдат, сугышта татар сугышчыларын һәм командирларын күп күрдем. Һәм аларның сугыштагы түземлегенә, корычтай нык ихтыярына соклана идем», — дигән ул. Габделнур, шул сүзләр хәтеренә килгәч, аның үзен дә туган авылындагы бер абзыйга охшатты: битләре тулышып тора, яңаклары киңчә, калынча кашлар астында кысыграк күзләр, тыныч холыклы, мөлаем һәм хәтта ки ягымлы дип әйтерлек караш. Егерме яшьлек солдат аның рәсми кәгазьләрдә поляк дип йөртелсә дә, асылда төрки кавемнән булган караим халкы вәкиле икәнен каян белсен. Аның йөзендә күпчелек хәрби башлыкларга хас кырыслык та, кискенлек тә чагылмый. Күрәсең, тәвәккәллек, уйлап эш итү, ихтыяр көче, полководец осталыгы, рухи ныклык кебек асыл сыйфатлары бик нык эчкә яшеренгән. Алар фәкать кирәк чакта гына тышка бәреп чыгалардыр. Менә шундый иде ул батыр ир-егетләребезне зурлаган маршал. Хәер, безнең асыл егетләргә-каһарманнарга Жуков, Конев, Рокоссовский кебек бөек полководецлар да сокланмыйча калмаганнар. Конев хәтта: «Татар егетләре арысланнар кебек сугышты», — ди. Әйтерсең лә Тукай сүзләрен кабатлый: «Без сугышта арысланнан көчлебез».

Малиновский белән янәшә Советлар Союзы Флоты адмиралы Горшков атлый. Сергей Георгиевич күзлекле, таза гәүдәле, уртача буйлы, ак китель һәм алтын кокардалы фуражка кигән. Анысы да сугыш вакытында күп батырлыклар күрсәткән командир, кыю диңгезче.

Ә менә алар артында, элеккечә итеп әйткәндә, свита составында бик яшь — утыз-утыз бишләр тирәсендәрәк адмираллар һәм генераллар күреп, Габделнур шаккатты.

Ул, ирексездән:

— Иптәш капитан, ә каян бу яшь генераллар һәм адмираллар? — дип сорады.

Капитан Катерина бер генә секундка әйтергәме-юкмы дип икеләнеп торды. Аннары, егетнең кызыксынуына һәм күзәтүчәнлегенә күңеле булып, үзенең шул сорауга җавап бирә алуына горурланып:

— Алар Корея сугышын үткән егетләрдер, — диде.

Кистереп әйтмәгәнлектән, аның тавышында бераз серлелек тә чагылды.

Яңадан сүз озайтылмады.

Анысын инде Габделнур үзе дә белә: илленче елларда аның туган авылы өстеннән бик еш кына унар-унбишәр самолет берьюлы көнчыгыш тарафка очып үтә иде. Аларның кай якка баруын кунакка кайткан бер офицер әйтте. Соңыннан, техникумда укыганда да, политзанятиеләрдә дә ул сугышның сабаклары турында сүз күп булды. Күрәсең, батырлык кылып исән калган офицерлар хәрби хезмәт баскычы буенча тиз күтәрелгәннәрдер. Моны гаеп итеп булмый. Бу гаҗәп тә түгел. Офицер булырга хыялланган егет үзенең ни-нәрсәгә бар-

ганын яхшы аңлый. Аңламаса, училище курсантларына моны яхшы төшендерәләр: син — гаскәри, илне саклаpга, кирәксә, гомереңне дә җәлләмәскә тиеш, исән калсаң — үсәсең, лампаслы чалбар да киярсең. Тик аның өчен намус белән хезмәт ит, кирәк чакта яу кырында яки җай чыкканда батырлык күрсәт. Тора-бара бу офицерның канына сеңә, яшәеш рәвешенә әйләнә. Әллә кайдагы чит-ят җирләргә дә озаталар аларны. Күбесе ирекле булып та бара. Чөнки ул гомере буе сугышырга өйрәнә, шуңа әзерләнә...

Тыныч тормышта да нык үскән офицерлар очрый. Кичә Ленин бүлмәсендә күптиражлы хәрби газета укып утырган Габделнур бер язмага игътибар итте. Анда сүз диңгезче-офицер турында бара. Ул татар егете күрше Чувашстаннан, өченче ранг капитаны, егерме җиде яшендә. Һәм менә шушы офицерны атом су асты көймәсе командиры итеп билгеләгәннәр. Димәк, ул хезмәт урыны буенча беренче ранг капитаны булачак — адмиралга бер генә адым кала. Була алырмы бу егет адмирал, юкмы, анысы язмыш эше. Ләкин шул яшьтә баллистик ракеталар белән коралланган куәтле субмарина командиры булу — үзе зур дәрәҗә, утыз яшьләрендә беренче ранг капитаны булу да зур бәхет. Моңа ирешү җиңел бирелмидер. Хәзер бит сугыш чоры түгел. Габделнурның кайдадыр укыганы булды: кырык өченче елны Сталинград фронтында егерме ике яшьлек дүрт полковник булган.

Егет тагын бер фактны белә: генерал-полковник Василевскийга, армия генералы званиесен алгач, егерме тугыз көннән Советлар Союзы Маршалы дәрәҗәсе бирелә. Ул — канлы сугыш барган заман, ә монда... Дөрес, беренче космонавт, өлкән лейтенант Гагарин, чираттагы капитан погоннарын тага алмый калды, — ил җитәкчеләре вакланып тормадылар, — Галәмгә очканнан соң аны майор иттеләр...

Габделнур дулкынлануын яшерә алмады һәм:

— Иптәш капитан, сез аларны еш күрәсездер инде? — дип сорады.

Ике метрга якын буйлы капитан Катерина аңа сәерсенеп, багана башыннан түбән караган сыман, иелебрәк күзләрен текәде. Аның карашы гүя кара син нинди кызыксынучан икәнсең дип әйтә иде. Ләкин ул егетнең күзләрендә самимилек чагылышын гына күрде.

Шулай да җавап урынына үзе сорау бирде:

— Нинди мәгънәдә?

Габделнур иңнәрен сикертте.

— Шундый зур кешеләрне безнең беренче күрү бит. Шуңа сорыйм. Яңадан әллә күрәбез, әллә юк. Ә сез...

— Аларны мин дә көн саен күреп тормыйм, — диде капитан, елмаеп, солдатның җавабыннан канәгать калып. — Ә вагракларын күрергә туры килә. Тикшерүләр еш була. Чөнки безгә, диңгез державасы буларак, флотны сугышчан әзерлектә тотарга кирәк. Флотны гына түгел, армияне дә. Әле патша Александр Өченче үзенең улына, булачак Император Николай Икенчегә: «Исеңдә тот, Ники, Россиянең рус армиясеннән һәм Хәрби диңгез флотыннан башка союзниклары юк», — дигән.

Капитан Катеринаның патша сүзләрен китерүе Габделнур өчен сәеррәк яңгырады, чөнки бүгенге көндә безнең союзникларыбыз күп бит: Варшава Договоры бар, социалистик илләр дистәдән артык, Куба — Американың борын төбендә үк.

Шулай да соңгы вакытта халыкара хәлләр куерып китте. Габделнурларны еш кына тревога белән күтәрәләр дә төне буе урамда, бөркәвечле машинаның кузовында утырталар...

**10**

Беренче көнне палаткалар кору һәм башка вак-төяк эшләр белән мәшгуль булып эленке-салынкы йөрсәләр, икенче көнне иртүк, үгезне мөгезеннән әләктереп дигәндәй, Габделнурларны сафларга тезеп танкодромга алып киттеләр. Шулай итеп, бер айга сузылачак тактик өйрәнүләр башланды.

Солдатларның иңнәрендә камыт кебек бөтереп төрелгән шинель-скатка һәм авыр карабин, янтыкта кыска саплы җыйнак сапер көрәге — шанцевый инструмент һәм противогаз савыты.

Юл буенда тал агачлары, сирәк-мирәк тәбәнәк каеннар, куаклыклар күзгә чалына, өзлексез кошлар сайрый. Рота командирының калын тавышы да аларны куркытмый.

— Калмаска! Җәһәтрәк атла!

Алан-йолан каранып, солдатлар алга бара. Менә берзаман ачыклыкка, тигез җиргә килеп бастылар.

— Тукта! Тарал!

Алда, күз күреме җитәрлек ераклыкта, ясалма калкулыклар, күпер шикелле нәрсәләр, кыска баганалар, танк яки йорт макетлары.

Каршыда гына танк гусеницасы эзләре бихисап. Танкодром дигәннәре шушы икән. Ул гаять зур дүртпочмакны хәтерләтә. Еракта-еракта, танкодром артында, урман шәйләнә. Аннан да арырак, Пулково тирәсендә, һавада сирәк-мирәк кенә самолетлар күренгәли — берсе төшә, берсе күтәрелә.

Ротный кече командирларны җыеп нидер аңлаткач, тегеләр үз отделениеләрен танкодромга каратып бер шеренгага тезделәр дә ни-нәрсә эшләргә кирәген аңлаттылар.

— Һәрберегезгә окоп казырга. Тирән булсын, иркен булсын.

Һәм егетләр коралларын, скаткаларын, противогазларын бер кырыйга салып куйдылар, аннары сапер көрәген эшкә җиктеләр. Баштарак бик җилле тотындылар, янәсе, кем алданрак казып бетерә. Ләкин аска төшкән

саен җир катылана барды, һәм чәч төпләре, аркалар тирләп чыкты, хәлсезрәкләр пилоткаларын салып, бил каешларын ычкындырып, туктап-туктап ял итә дә башладылар.

Габделнурның сафтагы урыны алдарак булганга, ул иң кырыйда иде. Алны-ялны белми җир чокыды. Рота командиры аның янына килеп, бертын карап торды.

— Гаделҗанов, ну-ка чүгәлә әле.

Егет мөмкин хәтле гәүдәсен җыебрак окоп төбенә чөмәште.

— Яхшы. Тагын бер ун сантиметр казысаң, таман була. Дәвам ит.

Габделнур, дәртләнеп, янә сапер көрәге белән җир «кимерергә» кереште. Берзаман нинди тавыш килә икән дип алга караса, еракта күренгән калкулыкларга таба бер-бер артлы менә-төшә өч танк бара. Аларның гөрелтесе монда өзек-өзек килеп ирешә, чөнки танклар калкулыкка үкерә-үкерә менәләр, артларыннан куе кара төтен болыты бөркелеп-таралып кала, ә аска төшкәндә тавышлары бөтенләй ишетелмәс була.

Бүтәннәр дә, эшләреннән туктап, танкларны күзәтәләр иде. Менә бермәлне танклар, бер рәткә тезелеп, нәкъ Габделнур казыган окоп турысындагы юлдан бирегә таба килә башладылар.

— Барыгыз да окопларга! — дип кычкырды рота командиры.

Габделнур чүкте. Окоп кашыннан чак кына башын калкытып, алга карады. Ажгырып киләме-килә авыл өе хәтле кырык-илле тонналы «корыч айгыр» нәкъ Габделнур өстенә. Ул якынайган саен, егет, муенын җыерып, ирексездән башын җилкәсенә батырды, гәүдәсе кечерәеп калгандай тоелды. Ә танк килә: үкереп, җир селкетеп, ажгырып… Изәм, сытам бөтен дөньясын, башыгызны бетерәм дигәндәй, якынаюын дәвам итә. Торып йөгерә алмыйсың — приказ. Дөрес, танклар йөри торган юл Габделнур окобына дүрт-биш адым кала борыла. Ләкин ул бит машина. Аның холкын белеп булмый… Башына икеле-микеле уйлар килсә дә, гәүдәсе үзеннән-үзе җиргә сеңсә дә, Габделнур окоптан карап торуын дәвам итте.

Өзлексез әйләнеп торучы киң чылбырларыннан алга таба коры балчык, тузан коела, яссы түгәрәк башня уртасындагы бүрәнә юанлыгы озын тубы алга төбәлгән… Һәм, инде окопка килеп җитте, солдатны сытты дигәндә генә, танк кырт кына сулга борылды. Габделнур җиңел сулап куйды, чак кына калкынды. Окоплардан берәм-берәм башлар күтәрелде. Сынау әле моның белән генә бетмәгән икән. Янәшәдә генә басып торган рота командиры, солдат каршына килеп, кулындагы кечкенә йомры туп кебек шартлату пакетының шнурына ут төртте дә Габделнурның артына, окопка ташлады. Үзе күзен алмыйча карап тора башлады. «Ни булса, шул булыр», — дип, Габделнур да окоп кашы аркылы ротныйга күзен терәде. Кинәт артта шартлау авазы яңгырады, аркасына һава дулкыны килеп бәрелде. Ул бер мәлгә генә күзен йомып алды. Ротныйның елмаеп торганын күргәч, үзенең дә ирен читләрендә елмаю галәмәте чагылды.

Бераздан команда яңгырады:

— Сафка тезелергә!

Шинель-«камытларын» баш аркылы киеп, сапер көрәге һәм противогазларын янтыкка җайлап беркетеп, кулларына карабиннарын тотып сафка бастылар. Командир шактый озак нотык сөйләде, беренче сугышчан заданиене үтәүләре, чирканчык алулары белән котлады, мактау сүзләрен җәлләмәде. Габделнурга һәм тагын ике солдатка рәхмәт белдерде.

— Служим Советскому Союзу! — диделәр егетләр.

Ә берәү танктан куркып окоптан чыгып качкан, куаклыкка таба йөгергән икән.

Командир:

— Беркайчан да алай эшләмәгез, — дип, әлеге солдаттан бигрәк, бүтәннәргә дә сабак булсын өчен, барысына да мөрәҗәгать итте. — Дошман пулясы сезне бик тиз куып җитәчәк… Сез — булачак кече командирлар. Үзегез үрнәк булырга тиеш…

Аның вәгазе шактый озакка сузылды.

Аннары ротный хәзер нишләргә тиеш булачакларын аңлатты.

— Задание тагын да катлаулана, — диде ул. — Сезнең бурыч шуннан гыйбарәт: каршы килгән танк астында калып, ул үтеп киткәч тә сикереп торырга һәм яндыргыч катнашма тутырылган шешәне, бу очракта гранатаны, танкка ыргытырга. Адмирал Ушаков әйтмешли, дошманны санама — юк ит.

Ротный кат-кат саклык чаралары турында кисәтте, әгәр кем дә кем үз-үзенә ышанмый икән, иң яхшысы, урыннарыннан кузгалмаска кушты.

— Танкларның тизлеге бу юлы артык зур булмаячак, алар интервал калдырып, берәмләп кенә киләчәк, ләкин барыбер ул махинаны секундның ничәнчедер өлешендә генә туктату мөмкин түгел. Шуңа күрә бу очракта, мин әйтер идем, сак була белү — үзе иң яхшы батырлык. Мин сездән шуны таләп итәм.

Солдатлар бер-беренә карашып алдылар. Барысы да алга куелган бурычны дөрес аңлый: монда максат танкны шартлату, юк итү түгел, ә үз-үзеңне сугышка, тәвәккәллеккә әзерләү, танк хәтле танктан да шөлләмәскә, куркып калмаска өйрәтү.

— Иң беренче отделение командирлары бу сугышчан бурычны үти, аннары — сез.

Габделнур эчке бер дулкынлану кичереп алды һәм үзенең тәвәккәлләячәген аңлады. Менә кайда сынала солдат, тез буыны нықмы-түгелме икәне ачыклана. Бу инде сиңа тыныч залда кино карап, совет солдатларына сокланып, аларның батырлыгын хуплап кул чәбәкләп утыру гына түгел. Синең үзеңнең дә кемлегеңне күрсәтер сәгать җитте. Чөнки булачак кече командирларга бу хакта, мондый бурычлар турында Кронштадтта да

кат-кат әйткәннәр, бәйнә-бәйнә сөйләгәннәр иде. Мораль яктан һәрберсе әзер сыман күренде. Ләкин менә сынау вакыты җиткәч, кайбер егетләрнең йөзендә каушап калу, икеләнү, күзләрендә курку галәмәте дә чагылды. Әйе, сүз сөйләү, лаф ору — бер нәрсә, ә үзең тыныч кына, артык шапырынмыйча гына ниндидер гамәл кылу — икенче. Күрәсең, сугыш вакытында батырлык күрсәткән егетләр дә әнә шул мизгелгә гомер буе (хәер, егерме яшьлек егетләрнең яшәүләрен, зурдан кубып, гомер буе дип әйтеп була микән, алар бит әле яши генә башлаган!) әзерләнәләр. Юк, алар, менә мин шушы минутта фәлән итәрмен, төгән итәрмен дип уйламагандыр, ә яшәү рәвеше, ата-ана, мәктәп, пионер, комсомол тәрбиясе, аларны чолгап алган мохит, укыган китаплар яки караган кинолар кирәк чакта шул юлга этәргәндер. Шулар нәтиҗәсендә каһарманлык кылу юлына басканнардыр, бәлки, шул адымны ясарга мәҗбүр булганнардыр.

Отделение командирлары берәм-берәм һич куркусыз танклар астына ташланып, нәкъ ротный әйткәнчә сикереп тордылар да гранаталарын танкка тондырдылар. Монда бит әле гранатаны китеп баручы танкка тидерергә дә кирәк иде, ул сине көтеп тормый. Бары бер сержантныкы гына «корыч айгыр»ны куып җитә алмады…

…Габделнур танк үтәсе юл кырына тузанлы балчык өстенә сузылып ятты, башын чак кына күтәрде. Килә. Ротный тизлекләре артык зур булмас дигән иде, ә бу ажгырып нәкъ аның өстенә килә. Бер генә мизгелгә егетне икеләнү тойгысы биләде, ирексездән җиргә сеңәсе, башын иеп, аны куллары белән тотасы яки торып йөгерәсе килде. Ләкин ул бик тиз үз-үзен кулга алды. Ничә адым калгач тиз генә ике гусеница арасына ятасын, башын каплыйсын, аннан ничек сикереп торасын күңеленнән янә бер кабатлады. Ә танк килә… Алагаем зур, чылбырлары киң… өлгерә алырмы?.. Һәм… инде килеп җитте дигәндә генә Габделнур, калкынып, күз ачып йомган арада гәүдәсен сулга таба атты — танк астына ташланды. Авылда күпер астында утырганда өстән трактор узып киткәндәй куркыныч булды… Ләкин уй-хисләргә бирелергә вакыт юк… Илле тонналы тимер аждаһа үтеп китү белән сикереп тә торды һәм, кырт борылып, уң кулында кысып тоткан гранатаны бар көченә танкка ыргытты. Граната башня төбенә үк барып төште, ләкин шартламады. Хәер, монысы инде Габделнурның фантазиясе генә иде. Чөнки аның эчендә шартлаткыч матдә дә, ядрә дә юк, ул — уенчык граната гына… Ләкин барыбер бу тию — танкны юк итү, җиңүгә бәрабәр иде. Танкны гына түгел, ә үз-үзеңне җиңү иде. Моннан соң инде кеше күзенә күренергә дә оят түгел, көзгегә карап, их син, булдыксыз, җебегән, дип, ямьсез кыяфәтеңне дә шелтәләүнең кирәге калмый. Чөнки син җиңдең: куркуыңны, икеләнү-шикләнүләреңне, кадерле җаныңның кайчагында бер мизгелдә генә булып ала торган ваклыгын… Моннан соң син гомер буе үкенү хисләре кичермәячәксең, кешеләргә туры карарга кыймыйча яшәмәячәксең, чөнки син нидер эшли алырга, кирәк чакта утка-суга керергә сәләтле икәнеңне беләсең… Әйе, бу мизгел зур җиңүгә тиң иде.

Ләкин бүген күрәселәре әле моның белән генә бетмәгән икән. Резин көпчәкле арбага көйләнгән кыр кухнясы янында тамак ялгап беркавым ял иткәч, төштән соң сугышчан уен башланды.

Рота командиры, саф алдында йөренеп:

— Хәзер техника заманы, шулай булса да солдат һәрчак үзенең физик көченә дә ышанырга тиеш, — диде. — Пуля — юләр, штык — молодец, дип юкка гына әйтмәгән Суворов. Кул сугышы алымнарын да яхшы үзләштерергә омтылыгыз. Аннары Кутузовның «сабырлык һәм вакыт — менә минем сугышчыларым-баһадирларым» дигән сүзләрен дә онытмагыз. Һәрнәрсәнең үз моменты була. Обстановкага карап эш итегез, теорияне практикада кулланыгыз.

Һәм куаклык, әрәмәлек арасында, чытырманлык эчендә бер отделение икенчесенә каршы «сугышырга» тотынды, разведчиклар «тел» алырга тырыштылар. Габделнурлар каршы як отделениесенең солдатларын «кырып бетереп», командирларын «тел» итеп алдылар. Таза гәүдәле сержант тиз генә бирешмәде. Габделнур һәм тагын икәү, мышный-мышный аның өстенә ятып, кул-аякларын бәйләделәр. Алар бу шөгыльне шулхәтле тырышып, бирелеп башкардылар ки, хәтта үзләрен сугыш киноларындагы кыю разведчиклар итеп тоя башладылар, онытылып киттеләр. Күрәсең, егетләр аны катырак бөтереп алганнар, сержант аты-юлы белән сүгенә үк башлады.

— Җибәрегез! — дип кычкырды ул. — Чишегез!

Ләкин, кулга бер эләккәч, андый кадерле «тел»не җибәрү кая! Сержант күпме генә чәбәләнмәсен, ай-ваена карамыйча, Габделнурның сыртына салып, «штаб»ка алып кайтып тапшырдылар.

Ара шактый бозылырга мөмкин иде. Шулай да үз отделение командирлары ничек кирәк алай бәхилләтте булса кирәк дустын-коллегасын, сержант кабат буза куптармады, Габделнурларга бәйләнмәде, ачу сакламады.

Кичке якта танкодромда мәхшәр купты. Танкистларның үз расписаниеләре буенча өйрәнүләр билгеләнгән икән: пулемет тырылдаталар, бөтен тирә-юньне дер селкетеп (палатка тәрәзәләре зыңлап тора) туптан гөрселдәтәләр. Берсенең тавышы таралып бетүгә, икенчесе тондыра. Кайчагында бер-бер артлы дөп тә дөп, бух та бух бәрәләр генә. Әйтерсең берөзлексез күк күкрәп тора. Ләкин яшен яшьнәгәне — күктә кылыч яки камчы уйнатканнары күренми, хәтәр ут баулары һаваны ярып җиргә төшми... Бик озак тыңлап ятты Габделнур бу өйрәнүләрнең тавышын...

Чөнки бу гөрселдәүләр аңа Чупай таш карьерында эшләгән чорын хәтерләтте. Таш шактый тирәндә ятканлыктан, аның өстендәге җир катламын алырга кирәк. Ә кыш көне экскаватор-бульдозерларга җир кимерүе читенгә туры килә. Шуңа күрә кечкенә буровой установкасы ярдәмендә шурфлар тишелә. Махсус чакырылган белгечләр әлеге тишекләргә тутырылган аммоналны бикфорд шнурлары сузып шартлаталар. Ул вакытта карь-

ерда эшләр туктатыла, кешеләр читкә китә, будкаларга керә. Шартлау бик көчле була, каты балчык кантарлары әллә ни ерак атылмаса да, вак кисәкләр шыбыр-шыбыр будка түбәләренә коела, әллә кайларга оча иде...

Палаткада йокыга китә алмыйча кыбырсып яткан яшь солдатның да уйлары еракларга оча: Әлмәткә барып җитә, Рәйсәнәләр өе тирәсендә чуала башлый...

Икенче көнне походка бардылар. Командирлар кабат-кабат өс киемен генә түгел, чолгауны ничек урауларына хәтле тикшереп чыктылар.

— Поход шактый еракка — ун чакрымга исәпләнгән, — диде рота командиры. — Аяклары суелып, бозылырлык булмасын.

Аның бу сүзләре кече командирларга адресланган иде. Тегеләр үз чиратында солдатларын кайгыртты. Чөнки һәр сержантның үз хезмәтен-эшен үрнәк итеп, яхшы яктан күрсәтәсе килү — гадәти нәрсә.

Көн кояшлы. Июнь аеның күге монда да зәп-зәңгәр. Аксыл болытлар да сирәк-мирәк кенә күренә. Баруы рәхәт, иртәнге һава җиләс. Гомумән, монда һава бераз дымлырак. Чөнки әйләнә-тирә сазлыграк урыннан гыйбарәт. Кояш күзне чагылдырмый, ул егетләрнең аркаларын җылыта — кичә көнчыгыш тарафка барсалар, бүген көнбатышка карап киттеләр.

Бераз баргач, якында гына авыл күренде. Юлда очраган бер абзыйга кемдер дәште:

— Теге нинди авыл?

— Низино, — диде юл читендә туктап калган карт.

Янәшә генә агучы тар елгага күрсәтеп, Габделнур да сорыйсы итте:

— Ә бу елга ни атлы?

— Черная речка.

Саф тукталмыйча үз юлында булды. Кинәт кенә Габделнурның исенә төште. Пушкин шул Кара елга буенда атып үтерелгән бит. Техникумда рус теле укытучысы бик тәфсилләп сөйләгән иде. Ул карт мөгаллим Ленинградтан эвакуацияләнгән булган, үзен сыендырган шәһәрдә — Алабугада төпләнеп калган. Бу якларны, бигрәк тә бөек шагыйрьнең биографиясен биш бармагы кебек белә һәм үз фәнен студентларның исендә калдырырлык итеп, хәтер сандыкларына сеңдерерлек итеп укыта иде. Әйе, Кара елга тирәсендә Дантес Пушкинны атып үтерә. Мәетне яручы табиб язучы һәм сүзлек төзүче Даль була. Дуэльгә хатыны намусын яклап барса да, чынында сәбәбе бүтән була. Пушкин жандармериягә һәм бүтән чиновникларга багышлап усал-зәһәр эпиграммалар яза. Бигрәк тә генерал Бенкендорф аңа каныга, ачу тота. Шагыйрьне Михайловское авылында Святогорский монастыре янында җирлиләр. Ун чакрым ара узып, урман эчендә солдатлар кичкән икенче елганың да исеме шулай икән, чөнки бу тирә сазлык булганлыктан суы коңгырт-кара төстә. Пушкин дуэленә килсәк, ул шәһәрнең төньягындагы Парголовка юлында, бүтән Кара елга янында була. Язмыш шуклыгыдыр, күрәсең, шул тирәдә Лермонтов та беренче дуэленә чыга: француз Барант, бик тырышып төзәсә дә, тидерә алмый, ә шагыйрь читкә ата.

Биш-алты чакрым узгач, кайберәүләрнең хәле бетә башлады. Ләкин привал турында авыз ачып сүз әйткән кеше юк — колонна бер алган темп белән бара да бара. Солдатлар шыпырт кына үзара сөйләшәләр, як-якка караналар, кемдер сукрана, ә бер ише уйлап та бирми.

Менә каршыга килүче өч-дүрт кыз күренде. Кая баралар икән: җиләккәме, гөмбәгәме? Әллә бүтән йомыш белән йөриләр микән бу чибәрләр — белгән кеше юк. Әмма аларны күргәч, егетләрнең аякларына дәрт-дәрман өстәлде, авызлары ерылды, күзләре очкынланды, йөрәкләре дуылдап, кан тамырлары ешрак тибә башлады. Саф алар белән тигезләшкәч, кемдер кызларга таба кечкенә туп ыргытты. Кыз-кыркын аны-моны абайлап өлгергәнче, кичә Габделнур окобындагы кебек шартлау булды. Кызларның итәкләре күтәрелде, балтырлары каралды, үзләре, котлары алынып, чыр-чу килделәр; солдатларга усал күзләр карады, авыздан зәһәр сүзләр чыкты.

— Юньсезләр…

— Маңкалар…

Ә солдатка кызык кына булсын — шырык-шырык көләләр.

— Кем ыргытты? Кем? — дип авыз күтәреп көлүчеләр янына рота командиры килеп җитте.

Ә кем белсен кем ташлаганны?! Бер-берсен сатамы соң солдат! Хәер, командирның үзенең дә яшь чагы булгандыр. Аннары, ул пакет ядрәсез бит, куркыту-өркетү өчен өйрәнүләрдә генә кулланыла. Шуңа күрә ул сафны туктатып мәшәкатьләнмәде.

Габделнур арада бер кызны жәлләп тә куйды: аның ак күлмәк итәге корымга буялган иде. Тик буласы булган, эш узган. Ул да артык нечкәртеп, хискә бирелеп тормады, гомуми шаукым аны да үз эченә бөтереп алды.

Тагын ярты сәгать чамасы бардылар. Алда тар гына елга күренде. Аңа килеп җитәр-җитмәс команда яңгырады:

— Колонна, тукта!

Ротный сафны уңга борып каршына басты да әмер бирде:

— Елганы кичәргә!

Һәм ул елга аша ничек чыгарга, коралларны, противогазларны ничек тотарга икәнен аңлата башлады.

— Кесәгездә документлар юкмы?

Гәрчә бу турыда җәйге лагерьда ук кисәтелгән булсалар да, ике солдатның сансызлыгы ачыкланды. Ротный аларның кәгазьләрен үзенә алды. Озак та үтмәде, солдатлар берәм-берәм суга кереп киттеләр.

Габделнур суның салкынча булуына игътибар итте. Менә итек тә күренми башлады, билдән тиң керелде, су күкрәккә җитте. Елганың төбе нык, тыгыз, ләме юк, аяк атлавы әллә ни кыен түгел. Шулай да ун чакрым җәяү килеп тирләгәннәр иде. Каз тәне чыкты. Әмма су муенга җитмәде. Югары күтәрелгән кулларда шинель, корал, противогаз. Шул рәвешле тагын берничә адым атлагач, каршы як ярга чыктылар. Яшел чирәмгә утырып, итекләрен салдылар, кунычын аска каратып суын түктеләр, чолгауларын сыгып, яңадан урадылар. Киенеп аякка басулары булды, теге як ярда калган рота командиры кире чыгарга әмер бирде.

Әмма бу юлы суга керүе дә, елганы янә кичүе дә читен булды. Болай да юеш гәүдәгә ябышкан чалбар һәм гимнастерка кабат чыланды, салкын су тәнне куырып алды. Ләкин бүтән чараң юк: су төбенә чак-чак басып тиз-тиз атлавыңны бел. Суворов бабай әйтмешли: «Өйрәнүләрдә авыр булса, сугышта җиңелгә туры килер». Аның үзен солдат белән бергә йоклаган, бер котелоктан ашаган диләр бит. Шуңа күрәдер чандыр гәүдәле, ябык чырайлы булган. Тик хәзер түбәнрәк чиннар да солдат тормышының авырлыгын алар белән уртаклашырга атлыгып тормыйлар.

Кайту юлы әйләнечтән булды. Бер урында, урман эчендә, туктап ял иттеләр. Тамагы бик кипкәч, Габделнур җыелып торган күлдәвектән бәләкәй генә бака баласын чеметеп кенә сыртыннан тотып читкә атты да кульъяулыгын суга җәеп салды. Ике солдат, шәһәр малайлары, чырайларын чытып, бу нишләргә җыена дигән кыяфәт белән аңа карап тордылар. Габделнур аларга игътибар итмәде. Бармагы белән кульъяулык уртасына басты, ятып, сусавы басылганчы саз суын эчте. Бәләкәй чакта җырлап йөргән такмак исенә төште: «Байлар, байлар бал эчә, урта байлар сыра эчә, ярлы, мескен, ни эшләсен, ярга ятып су эчә».

Урман эчендәге тар сукмактан тезелешеп киттеләр. Коңгырт-кара сулы кечкенә инеш-елгачыкларны сикереп үттеләр, чытырманлыкларны ерып чыктылар.

— Сукмактан читкә тайпылмаска! — диде командир.

Урыны-урыны белән урман эче караңгы, шомлы булып күренде. Бигрәк тә сукмак буенда окоп, блиндаж калдыклары, җимерек траншеялар яныннан үткәндә, җирдә аунап яткан каска тутыкларын күргәндә Габделнур күңеленә төрле уйлар килде. «Болар бит чын сугыш булган урыннар, — дип уйлады ул. — Күпме газиз җаннар кырылгандыр монда…»

…Бер михнәтнең бер рәхәте була дигәндәй, җәйге лагерьга килеп ике атна яшәгәч, шимбә-якшәмбе көннәрне аларны, машиналарга утыртып, экскурсиягә алып киттеләр. Царское Селода булып, Петродворец фонтаннарын карап йөрделәр. Ял көне, кайткач, Габделнур өчен тагын сөенеч — Рәйсәнәдән хат.

Кыз җылы гына хат юллаган солдат егеткә. Эшен, өйдәге хәлләрен тәфсилләп язган, сабантуйлар җитүен дә искәрткән. Кыскасы, Габделнурның түбәсе күккә тиде хат укыгач. Йөреп кайткан экскурсияләрдән алган тәэсирләре суынып та җитмәгән, шуның өстенә тагын бер куаныч. Ул түзмәде, палаткада берүзе генә калгач, шундук хат язарга кереште.

«Исәнме, Рәйсәнә! Сәлам хатыңны алдым. Рәхмәт. Мин синең өчен бик шат. Үземнең хәлләр дә әйбәт, хезмәт дәвам итә. Без әле һаман өйрәнүләрдә. Мин сиңа алдагы хатта язган идем. Бүген менә ял көне, тагын экскурсиядән кайттык, патшаларның җәйге ял итү урыннарын карап йөрдек. Петергофның (ә аны Русский Версаль дип йөрткәннәр) бакча-паркы гаять зур, Фин култыгына хәтле канал казыганнар, шлюзлар бар, фонтаннар атып тора, төрле зурлыктагы дворецлар, павильоннар — ни генә юк. Олы каскад, Түбән каскад дигәннәре аеруча нык тәэсир калдырды. Андагы сыннарның саны-исәбе юк, һәрберсе алтын белән йөгертелгән, сап-сары. Ут биреп торучы Прометей да, мөгезле егет тә, ялангач хатын-кызлар да бар. Бигрәк тә Самсон дигәне шаккаткыч: арысланның авызын каерып тора, көчле, гайрәтле. Һәр җирдә фонтан — кояш нурында су бөртекләре уйный, салават күпере хасил була, гаҗәеп манзара инде. Драконнар каскадында зур-зур шахмат такталары ята. Их Рәйсәнәм, сиңа да аларны күрсәтәсе иде! Ул матур җирләр сиңа да бик ошар иде! Бигрәк тә кытай ефәге белән бизәлгән бүлмәләрне күрсәң, ушың китәр иде…

Мондагы каскадлар Европа илләрендә күптәннән булган икән, Петр Беренче, шулардан күреп, тагын да матуррак итеп эшләткән. Александр Бенуа, таң калып, болай дип язган: «Зур каскад ул — дөнья һәм галәм моделе».

Рәйсәнә, сугыш вакытында мәшһүр, зиннәтле Екатерининский дворецны фашистлар конюшня иткәннәр, янтарь кабинетның бер ташын да калдырмыйча урлап алып киткәннәр. Әле булса табылганы юк. Ә бит ул янтарь панноларны Петр патшага Пруссия короле Фридрих Беренче бүләк иткән була. Немецлар үз бүләкләрен үзләре урлаганнар. Без шактый озак йөрдек, бөтенесен диярлек карадык. Трон залына кергәндә аякка киндер бахилла кидерделәр. Син дагалы кирза итек белән шул затлы җиргә кертмәсләр инде диярсең. Юк, гражданскийлар да шулай керә. Ул соклангыч паркет идәнгә аяк басарга да читенсенәсең. Әле тау куышы — грот бар. Ул серле, сихри һәм куркыныч. Грот эчендә виноград һәм башка җимешләр куелган өстәл тора. Кулыңны сузсаң, фонтан сиптерә башлый. Кеше куркып китә… Гроттан чыкканда өстән су ага. Ә инде Царское Село дигәнен дәреслекләр буенча хәтерлисеңдер, анысы лицей һәм Пушкин белән бәйләнгән. Булса да була икән могҗиза дип уйлыйсың боларны карагач. Башка төрле уйлар килә. Күпме художник, скульптор, төзүчеләр аны эшләгән, никадәр көч салганнар… Минем кичәле-бүгенле күргәннәрне бер утыруда гына язып бетерерлек түгел. Икенче хатка да калсын. Очрашкач, барысын да берәмтекләп сөйләрмен әле, яме, бәгырем…»

## 11

Рәйсәнәдән килгән хат Габделнурның күңелен күтәреп, мәхәббәт учагына ялкын өстәп, яшь йөрәгеn тагын да ешрак, сөенебрәк тибәргә мәҗбүр итсә, Хөрмәтнең хаты егетне пошаманга салды. Габделнур бер-ике көн үз эченә бикләнеп, килеп туган хәлне бөтен тулылыгы белән аңларга тырышты. Әйе, үзе генә. Чөнки киңәш-табыш итәр кеше юк. Гәрчә кече командирлыкка бергә укучы ярыйсы гына төпле егетләр бар, отделение командиры да аны чит итми. Ләкин бу мәсьәләдә алар ничегрәк фикер йөртерләр, нindирәк киңәш бирерләр — Габделнур өчен караңгы. Моны белеп булмый. Гомумән, аларны катнаштыру кирәкме? Дусты бит хатны аңа атап кына язган. Шуңа күрә Габделнурның кемгәдер, чит кешегә эч серен чишәсе килмәде. Бер баш — яхшы, ике баш — тагын да шәбрәк, дисәләр дә, никтер күңеле тартмады.

Хөрмәт тә, Габделнур кебек, каравыл ротасына эләккән һәм хезмәтеннән канәгать иде. Һәрхәлдә, алдагы хатлары шул хакта сөйли, моң-зар сизелми иде. Хәер, авыл малайлары беркайда да киреләнеп маташмыйлар, «кәҗәләнеп» тормыйлар — кая җибәрсәләр, кая куйсалар, шунда тырышып хезмәт итәләр, авырлыкларга — түзем, теләсә нинди шартларга да тиз ияләшәләр, нинди генә кыен хәл тумасын, сыкранмыйча аны ерып чыгалар. Билгеле, Хөрмәт кебек таза тәнле, шат күңелле егет бер җирдә дә югалып калачак, ким-хур булачак түгел иде. Ләкин Габделнурның күңел түрендә, бәлки, кайсыдыр почмагында гынадыр, гел бер шик йөрде. Әнә шул шөбһәләнү аны гелән бимазалап, йөрәк тирәсен тырнаштырып торды, аңа тынгы бирмәде. Бу — Хөрмәтнең Трофимов белән бер частька эләгүе иде. Һәм юраганы (бу очракта, бәлки, борчылуы дип әйтү дөресрәктер) юш килде. Дустының соңгы хаты моны раслады.

Хөрмәт, сәламнәр юллап, Габделнурның хатын алуын язганнан соң, болай дәвам иткән: «Яшьти, госпитальдә яткан көнем. Трофимов, көч белән җиңә алмагач, аркага пычак кадады. Кайда, кайчан, ничек икәннәрен язып тормыйм. Аны нишләтерләр, белмим. Прокурор на всю катушку бирмәкче җәзаны. Минем исем китми. Теләсә нишләтсеннәр. Частьта гына калдырмасыннар. Иначе мин аны яшәтмим».

Шушы юлларны укыгач, Габделнур туктап калды. Янә хатка күз салды, ары таба укуын дәвам итте: «Хәтерләмим, исерек идем, дип әйтә икән. Юлит, сволочь. Бөтенесен белеп эшләде». Бу юллар егетнең әллә ни исен китермәде. Хөрмәтнең шундый бәлагә таруы, ярасы ничек кенә тирән булмасын, инде кире кайтара торган түгел, булган хәл. Габделнурны иң нык борчыганы, шик-шөбһәгә салганы — «Иначе мин аны яшәтмим» дигән сүзләр иде.

Үчен кайтарасы килү аңлашыла. Бигрәк тә Хөрмәт кебек типсә тимер өзәрдәй егет ул хәшәрәтне болай гына калдырмас. Ләкин бер бәладән котылып икенчесенә килеп эләгүе ихтимал: үзенең йә дисбатка, йә ташкапчыкка килеп кабуы бар. Шуңа күрә мөмкин хәтле йомшак итеп, мин-минлегенә тимәскә, аңа «акыл сатуын» сиздермәскә, бер үк вакытта хәтерен калдырмаска тырышып, яшьтәшенә хат язды. Әлбәттә, ул да җитмеш яшьлек бетәшкән карт түгел. Үзе дә нәкъ Хөрмәт кебек уйлый һәм эшләр дә иде. Ләкин ахыры ни белән бетәр? Нәрсәгә алып барыр да нәрсәгә китереп җиткерер андый үчләшү, башсызлык? Хөрмәт бит бу дөньяда ялгызы гына түгел. Аны өйдә ата-анасы, туганнары, ниһаять, сөйгән кызы көтә... Һәрхәлдә, дусты аны дөрес аңлар шикелле.

Үч алу димәктән, канга — кан дип артык үчләшү дә юньлегә алып бармый. Яхшылык җирдә ятмый, үзеңә дә яхшылык булып кайта дигән кебек, начарлыкның да, бумеранг кебек, үзеңә әйләнеп кайтуы мөмкин. Габделнурның исенә төште: Алабугада студентларга сольфеджио өйрәтүче, матур-матур көйләр чыгаручы бик инсафлы бер укытучы бар иде. Хатыны, ике баласы белән алар үсмерләр яшәгән тулай торакның өске катында торалар иде. Кайчан сөйләгәне хәтерендә түгел, ә менә фикере миенә сеңеп калган. Сүз фашистлар оккупацияләгән җирләрдә тегеләрнең кылган вәхшилекләре, безнең солдатларның алар халкыннан үч алуы хакында иде.

— Сугыш вакытында безнекеләр дә ниместән ким кыланмады, — дип сөйләгән иде укытучы абыйлары. — Бер лейтенантның, ул Украинадан иде, бөтен семьясын немесләр юк итә. Гел әйтә торган иде: «Фрицлар җиренә барып керсәм, үчен кайтарам: беренче очраган хатынны тотып рәтлим». Ул шулай итте дә. Без, алар чиген узып, ике чакрым бардык микән, басуда эшләүче бер төркем нимес хатыннарына һәм ике ир-атка тап булдык. Лейтенант арада иң яшь, иң чибәрен сайлап алды да: «Фрау, коммен!» — диде. Ирләрнең берсе, ул аксак иде, шуңа күрә армиягә алмаганнардыр инде, әйтте: «Майн фрау! Найн!» «Чего, фашистская морда, жить надоело?» — дип, лейтенант пистолетын тартып чыгарды. Хатын моны күреп чишенә үк башлады. Чөнки ни өчен чакырганы билгеле иде. Лейтенант аны безнең алда, ире каршында көчләде. Ире, ачуына буылып, сәнәк тотып килә башлаган иде, лейтенант аны атып үтерде... Без ары киттек. Авылларга килеп керсәк, нимес хатыннары, ыштаннарын салып, караватка яталар иде. Чөнки бездән алда авылга иң беренче булып кергән солдатлар аларны совет сугышчыларын ничек каршыларга кирәген кисәтеп, өйрәтеп куйганнар иде инде... Ә лейтенант... Нәрсә дип әйтим, энекәшләр, бик күп нимесне кырды, кызларны, хатыннарны көчләде... Сифилис эләктерде... Ахырда үзен дә атып үтерделәр... Үз башына ашкынган икән...

Укытучы абыйлары теге лейтенантны яманламады да, аклаганы да сизелмәде. Әлбәттә, бәлки, болар — Хөрмәтнең явыз бәндәне акылга утыртырга теләве һәм сугыш чоры галәмәтләре — икесе ике нәрсәдер. Ә бит төптәнрәк уйлап карасаң, асылы шул ук — үч алу, канга кан белән җавап кайтару...

...Өйрәнүләр бетәргә бер-ике көн кала, чираттагы якшәмбедә, увольнениегә чыктылар һәм командирларына алдан ук әйтеп, Ленинградка киттеләр. Алар белән бер сержант та бар иде. Ә юл күрсәтүче шул шәһәрдә туып үскән Петров фамилияле солдат булды.

Шәһәргә җитеп электричкадан төшкәндә, Габделнур аңа:

— Сине өйдәгеләр көтәдер, — диде. — Үзебез йөрербез әле.

Озынча ябык йөзле, күзлекле Петровның моңа бик күңеле булды. Шулай да аның бергә хезмәт иткән дусларына туган шәһәрен дә күрсәтәсе килә иде.

— Өлгерермен, — диде ул, күзлегенә кул тидереп һәм шаяртып алды: — Сезне дә ташлап китеп булмый бит инде: йә адашырсыз, йә кызлар алып калыр үзегезне. Казанга барсам, син дә минем гид булырсың.

Габделнур да елмайды.

— Мин Әлмәттән бит. Казанны белүем, танышлыгым бик чамалы.

— Алайса, мин сиңа мондагы Казанны күрсәтермен, — диде Петров, трамвайга утырганда. — Монда Казан исеме белән бәйле урыннар шактый. Мин шул тирәдә үстем. Хәзер Литейный проспектта яшибез.

Габделнурның кинәт исенә төште: студент елларында аларны декоратив бизәү фәненнән укыткан рәссам абыйлары Иван Иванович Шишкин турында тәфсилләп сөйләгән иде.

Янында барган солдатларга ул, горурланып:

— Монда безнең якташ Шишкин яшәгән, — диде.

— Кем соң ул? — дип сорады бер солдат.

— Рәссам. Алабугада туган, Казанда укыган, Санкт-Петербургта сәнгать академиясен тәмамлаган. Бервакыт ресторанда алар компания белән утыралар икән: ашыйлар, эчәләр, җырлыйлар, күңел ачалар. Шишкин Кышкы Сарайда яшь кенәзләргә дәресләр бирә торган булган. Шуларның мәнсезлеге, наданлыгы турында мәзәкләр сөйли башлаган. Шунда моның янына эзләү полициясенең яшерен агенты килә дә үз артыннан ияреп чыгарга куша. Шишкин шүрләп калмый: «Син нәрсә мине куркытасың? — ди. — Әйдәле Сарайга барыйк, мин анда да шуны ук әйтермен». Рәссам кесәсеннән Кышкы Сарайга керергә рөхсәт бирә торган пропуск чыгарып тегенең борын төбенә тери. Ә пропускка патша үзе кул куйган була.

— Теге агент нишли?

— Нишләсен, тизрәк ычкына...

Ленинградның Казанга, татарларга мөнәсәбәте бер Шишкинда гына чагылмый икән. Санкт-Петербург төзелә башлаганда Кронверк каршындагы бер урын элек-электән Татарское дип йөртелгән. Мойка каналы буенда кенәз Юсуповларның, Фонтанка елгасы ярында кенәз Шереметьевларның зур йорт-сарайлары бар. Грибоедов каналы Невский проспект белән кисешкән төштә күпер, шул тирәдәге мәйдан һәм урам — барысы да Казан исемен йөртә. Ә шәһәрнең төп кафедраль храмы — Казанский собор. Ул үзе биек һәм мәһабәт кенә түгел, әле аның колоннадасы да һәркемне таң калдырырлык. Невский проспектка каратып корылган бу могҗиза шәһәргә килгән барча кешенең игътибарын үзенә җәлеп итә. Янәшәсендә атаклы фельдмаршал Кутузов һәйкәле дә калыккан. Боларны егетләргә Петров әйтте һәм күрсәтте.

Габделнур, Исаакий соборының алтын гөмбәзен ерактан күргәч, беренче көннәрен үткәргән Флот экипажының да шул тирәдә икәнен абайлады, чөнки өченче катның тәрәзәсеннән аңа карап торганы бар иде. Мойка каналы, Поцелуев мост исенә төште. Подвалда сәгатенә корабль силуэты ясап биргән рәссамның: «Все мосты разводятся, а Поцелуев — нет», — дип җырлаганы да хәтерендә.

Петров Габделнурга:

— Державинның менә мондый юллары бар, — диде дә яттан шигырь сөйләргә тотынды.

Я пел, пою и петь их буду,
И в шутках правду возвещу;
Татарские песни из-под спуду
Как луч, потомству сообщу...

Бу егетнең белеменә сокланудан һәм аның туган халкын ихтирам итүенә күңеле булудан башка чара калмады Габделнурга.

Петров егетләрне Эрмитажга алып килде.

Нева яры буенда Дворцовый күпер белән янәшә генә урнашкан гаять озын матур бина үзенең тышкы кыяфәте белән дә, эчке бизәлеше белән дә Габделнурны хәйран итте. Алабугада укытучысы сөйләгән, альбомыннан бәләкәй генә рәсемнәрен күрсәткән картиналарның үзләрен үз күзләре белән күрүе — бу әйтеп кеше ышанмаслык хыялның тормышка ашуы иде. Егет, бөтен игътибарын туплап, экскурсоводның авызына керердәй булып аның сөйләгәннәрен тыңлады.

Менә алар нинди икән?! Рембрандтның «Даная»сы. Бер карасаң әллә нәрсәсе юк та шикелле: таза гына шәрә хатын... «Күәс камыры кебек җәелгән», — дип уйлады егет. Ләкин шундук як-ягына каранды. Янәсе, аның уйларын берәрсе укымыймы? Әгәр шулай булса, ояты ни тора! Бу бит дөнья җәүһәре!

Әнә Леонардо да Винчиның «Мадонна Литта»сы газиз баласын имезеп утыра. Чибәр, яшь хатын. Үзе дә сөйкемле, баласы да. Ә бит әнә шул беренче карашка гади генә күренгән картиналарны озак-озак карап тора-

лар, сокланалар. Безнекеләр генә түгел, чит ил кешеләре дә бар монда. «Болар инде безнең кебек туң баш түгел, ак белән караны аера беләләр», — дип уйлады Габделнур, залдан залга күчеп йөргәндә иптәшләренә дә күз ташлап.

Әнә бер скульптура: «Рубенс. Союз земли и воды». Егет, язуны укыгач, сыннарга карады. Монда да бер таза хатын. Тик монысы басып тора. Беренче күз ташлауга, Габделнурга аның уң кулы терсәктән түбән өзелгән, гарип шикелле тоелды. Җентекләбрәк карагач кына аның җимеш тутырылган ваза артында икәнен шәйләде. Хатын янында экскурсантларга арты белән бер ир-ат тора. Аның аркасы кантар-кантар мускуллардан гыйбарәт.

Ләкин егеткә иң ошаганы Роденның «Мәңгелек яз» статуэткасы булды. Ап-ак мәрмәрдән чокып эшләнгән ике сын — кыз белән егет — ярым ятып үбешеп торалар. Ялангач булсалар да, аларның бу кыланышында оят нәрсә, килешмәгән гамәл күрмисең. Чөнки алар яшь, саф, самими һәм бер-беренә шулхәтле яратышып сыенганнар... Аларның бу фани дөньяда, бүтән кешеләрдә гаме юк. Алар өчен бу назлашу мизгеле — бәхет-сәгадәт китерүче мәңгелек яз...

Аннары солдатлар шәһәр карап йөрделәр. Киноларда күргән, биек тимер капкасына матрослар һәм солдатлар үрмәләп штурмлаган Кышкы Сарай, ахырынача җиткерелмәгән декабристлар восстаниесе булган Сарай мәйданы һәм 1812 елгы Ватан сугышында җиңүгә багышланган һәйкәл — дөньяда иң авыр бербөтен табигый таштан юнып-шомартылган, үтә дә озын, түгәрәк Александр баганасы, ерак-ераклардан күренеп торучы алтын гөмбәзле гаять зур Исаакий соборы — болар һәммәсе үзләренең могҗизага тиң бөтен матурлыгы, мәһабәтлеге белән Габделнур каршында иде. Кая карасаң да күзләр камаша. Күңелләре һаман моның чынлыгына, төш түгеллегенә ышанып җитә алмый. Әйе, болар барысы да чынбарлык. Әнә бит Исаакий соборы каршында, Нева елгасы буенда Петр Беренче һәйкәле. Ул атка атланган. Аты алагаем зур ташка арт аякларына баскан. Патшаның карашы Васильев утравына һәм Петропавел крепостена төбәлгән.

Егетләрне ияртеп йөрүче Петров:

— Хәтерлисезме Пушкинны? — диде дә, җавап көтеп тормастан, шигырь сөйли башлады: — ...стоит с простертою рукою кумир на бронзовом коне. О мощный властелин судьбы! Не так ли ты над самой бездной, на высоте, уздой железной Россию поднял на дыбы?»

Хәтерлисезме дип нәкъ үзенә карап әйтелмәсә дә, Габделнур Петров сүзләреннән бераз кыенсыну халәте кичерде. Дөресен генә әйткәндә, ул шагыйрьнең «Бакыр җайдак» поэмасын ишетеп кенә белә иде. Алабугадагы әдәбият укытучысы абыйлары авызыннан... Егет бөек Тукайның да шушы урамнар буйлап йөргәнен әйлешәйле генә чамалый. Ул аның фәкать «Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам, әкрен-әкрен югарыга үрләп барам» дигән сүзләрен генә хәтеренә китерде.

...Петров өенә кайтып киткәч тә егетләр әле байтак вакыт шәһәр карап йөрделәр. Киров күпере аша чыгып, «Аврора» крейсерында булып, революцион матрослар тыз-быз йөргән тимер палубада үзләренең дә аяк эзләрен калдырдылар. Рәсемнәрдә күргәләгән Урта Азия шәһәрләрендәге хан сарайларына тартымрак итеп салынган гөмбәзле мәчет манарасын да күреп калды Габделнур шул тирәләрдә.

Төш турында кайдадыр еракта нәрсәдер гөрселдәде. Бер егет, кая аталар, кем ата, дип сораштыра башлады.

— Монда шундый традиция — көн саен сәгать уникедә туптан аталар, — диде алар белән бергә увольнениегә чыккан сержант, бик белдекле кыяфәттә. — Буш снаряд белән һавага. Крепостьның сигнал пушкасы элекке заманнарда эш башлануын һәм бетүен, су күтәрелүен хәбәр итә торган булган. Аннары, йөз ел чамасы элек, көндез бер генә атуга күчкәннәр.

Шәһәр күзләштереп йөргәндә Габделнурның башына төрле уйлар килде. Киң урамнар, матур бакча-скверлар, фонтаннар, һәйкәлләр, гасырлар буена урыныннан кузгалмаслык нык итеп салынган, гранит һәм мәрмәр белән бизәкләнгән йортлар аны хәйран гына калдырмады, ә күңелен, бөтен рухын горурлык хисе белән тутырды. Чөнки моңа нигез бар иде. Әйтерсең моннан егерме ел элек кенә монда дәһшәтле бәрелеш-кырылыш бармаган, бомба һәм снарядлар шартламаган да, завод-фабрикалар, борынгы сарайлар һәм өйләр авып төшмәгән, халык кырылмаган, дошманны үткәрмәс өчен солдат-матрослар актык сулышларына кадәр сугышып газиз гомерләрен бирмәгән... Кыска гына вакыт эчендә җимерелеп беткән кала бөтен гүзәллеге белән аякка баскан! Никадәр физик һәм рухи көч тупланган совет кешеләренең беләкләрендә, йөрәкләрендә! Габделнур шуларны уйлап, аңлап, ышанып һәм киләчәккә өмет белән карап барды. Бу илне беркем дә, беркайчан да җиңә, тез чүктерә алмас дип фикер йөртте ул. Чөнки аның горур халкы, куәтле техникага ия булган Кораллы Көчләре бар! Солдат-матрослардан, сержант-старшиналардан, офицерлардан, генерал-адмиралльардан торган Көче бар. Һәм Габделнур да шушы Көчнең бер вәкиле. Кирәксә, ул да утка-суга керер, кулына корал тотып Ватанын явыз илбасарлардан батырларча саклар... Мондый матур шәһәрләр кабат беркайчан да хәрабәгә әйләнмәсен, халык әрәм булмасын өчен...

Неваның сул ярына күпер аша кабат чыкканда Габделнур судан күзен алалмады. Карап торуга тыныч, талгын гына аккан елганың әледән-әле ярларыннан ташып, ярты шәһәрне басуын күзаллавы кыен иде. Ләкин ул шулай. Андый афәт фәлән елга бер мәртәбә гел кабатланып тора икән. Ышануы авыр булса да, хакыйкать шундый.

Трамвайдан төштеләр. Күрәсең, сержантның да Ленинградны белүе чамалы иде. Урамда бер карчыкка мөрәҗәгать итте:

— Әби, әйтегез әле, зинһар, Марс кырына ничек барасы?

Борынгырак фасондагы эшләпә, озын күлмәк кигән, бөкрәя төшкән гәүдәле, күзлекле кортка, бик озак тәфсилләп аңлатканнан соң:

— Гафу итегез, улларым, сезне озатып куя алмыйм, — диде. — Оныгым авырган, шуның янына барышым иде. Әнисенә эшкә барырга кирәк.

Бу сүзләрне ишеткәч, күпме җәбер-җәфа күргәннән соң да кешелек сыйфатларын саклап кала алган бу зыялы әбекәйгә Габделнур хәйран калды.

— Рәхмәт, әби, рәхмәт, — диделәр егетләр. — Үзебез табарбыз.

...Габделнур дневальный иде. Төн. Тынлык. Шулай да бу беренче карашка гына талгын тынлык. Чөнки үлән арасында нидер кыштырдый, тычкан, күрәсең. Куаклыкта сирәк-мирәк кошлар сайраштыра. Әллә белеп сайрыйлар, әллә төш аралаш саташып кына тавыш бирүләре. Көнчыгыш тарафтагы Ленинград каласы өстенә кызгылт утлар балкышы булып яктылык сибелгән. Пулковога төшеп килүче самолетларның уты әүвәл ерактагы йолдыз кебек кенә, ләкин ул бер кабына, бер сүнә. Очкычларның тавышлары да тын һаваны ярып килеп ирешә. Фин култыгы ягыннан тымызык салкынча диңгез җиле исә. Кайдадыр ялгызы чабучы машина гөрелтесе төнге тынлыкны боза. Кыскасы, тормыш дәвам итә.

Петергоф, Ломоносов шәһәрләре тирәсендәге урман-болыннар артына ук төшеп баеган кояшның соңгы нурлары хәзер инде офыкны каплаган, буй-буй сузылган карасу болыт итәкләрендә дә чагылмый. Ә барыбер күк йөзендә таң аткандагы кебек аксыллык. Бу — бөек язучы Достоевский «ак төннәр» дип кулланышка кертеп җибәргән табигатьнең могҗизалы бер чоры.

Габделнур палатка янында, Кронштадтан үзе белән алып килгән Мопассан романын кулына тоткан хәлдә, урындыкта укып утырды. Чөнки күк йөзе якты булу өстенә лагерьда баганаларда да утлар яна иде.

Китаптан күзен алып, ул кайчагында солдатлар йоклап яткан палаткаларга, алар арасындагы сукмакларга караштыра. Иңенә салган шинелен рәтләп куя. Җәй булса да, төн үзенекен итә — бераз салкынча. Ләкин зыянсыз. Дневальныйлар ике сәгатьтән ике сәгатькә алмашынырга тиеш. Тик Габделнур үзен алыштырасы солдатны уятмады. Әйдә йокласын. Бер йокыга киткәч, торып чыгуы читен. Аннан, Габделнурны әле йокы басмаган. Башына төрле уйлар килә. Китабыннан арынып, күк йөзенә карый, җиде йолдызны тәшкил иткән Чүмеч йолдызын эзләп таба. Кызык, бер уйлаганда күк йөзе нәкъ аның туган авылындагы кебек, ә җентекләбрәк карасаң, йолдызларның урнашу тәртибендә аерма да бар шикелле... Рәйсәнә кайда микән хәзер? Больницада дежурда микән? Операция бүлмәсендәме, әллә ял итәме? Бәлки, өйләрендә, йомшак мендәргә кара чәчләрен таратып, мамык юрган ябынып, изрәп йоклый торгандыр. Берәр төш күрә микән? Әгәр аны күрсә? Ничек итеп күрә икән?..

Габделнур сискәнеп китте: аның янына рота командиры чыккан икән. Ул гадәти кыр киеменнән: гимнастерка, фуражка... «Әллә йокламаган да инде?» — дип уйлады солдат. Сикереп торды.

— Иптәш капитан, минем дежурство вакытында...

Капитан аны бүлдерде:

— Утыр, Гаделҗанов. Тәртипме?

Солдат басып торуында булды.

— Әйе, иптәш капитан.

— Ә нигә сине алыштырмыйлар? — дип, ул сәгатенә карады.

— Иптәш капитан, мин үзем аны уятмадым. Менә китап укып утырам. Бездә бит ак төннәр юк. Хәтердә калдырасы килә.

Капитан беркавым аның белән гәп корганнан соң ары китте. Чөнки җәйге лагерьда дневальныйдан тыш тагын төнге патруль дә бар. Ротный шуларны тикшерергә китте.

...Табигать кочагындагы җәйге рәхәт хозурлыктан соң, чагыштырмача чиста, саф һавалы шәһәр булса да, Кронштадтка кайтасылары килмәде. Ләкин син үз иркеңдәге кеше түгел. Синең теләү-теләмәвең исәпкә алынмый, беркемне дә кызыксындырмый.

Тагын авыр тимер капка ачылып, дүрт катлы кызыл бина — казарма аларны үз эченә йотты. Янә гадәти солдат тормышы башланды.

Барлык занятиеләр дә бер максатка — булачак кече командирларны физик һәм мораль яктан чыныктыруга корылган иде. Тән тазалыгын, кыюлык, тизлек, хәрәкәтчәнлек, тәвәккәллек кебек күнекмәләрне җәйге лагерьда өйрәнүләр вакытында кайгыртсалар (әлбәттә, сафта йөрү, корал белән эш итү, уставлар өйрәнү һ.б. монда да дәвам итте), сәяси-мораль якка күбрәк бирелдә — казармада басым ясалды.

Бу арада замполитка эш күп — көн аралаш әңгәмә үткәрә. Төп тема — Куба. Солдатларга бөтенесен әйтеп бетерми, күбрәк гомуми купшы сүзләр белән, кинаяләр белән канәгатьләнә. Ләкин тел төбен яшереп тормый.

— Сез Кубадагы хәлләрне белеп-ишетеп торасыз. Бәләкәй генә утраудагы героик, хезмәт сөючән, горур халыкны безнең илебез ялгыз калдырмас. Америка Кушма Штатларының идарәче даирәләре, «коммунистик куркыныч»ны сылтау итеп, ә сәбәбе булса, сылтау табыла, кораллы интервенция әзерләделәр. Алар Куба халкының курку белмәс батыр йөрәкле улы Фидель Кастро һәм аның көрәштәшләре тырышлыгы нәтиҗәсендә империалистик коллыктан азат булулары белән килешмиләр. Бу хәвефле көннәрдә без агрессорга Куба халкын өзгәләп ташларга ирек бирмәбез, аңа һәм рухи, һәм матди, һәм хәрби яктан ярдәм итәрбез. Барадеро пляжларын-

да капкорсак капиталистлар түгел, ә гади хезмәт халкы ял итәр, Сиерра-Маэстро тауларыннан Кубада хөкем сөрәчәк коммунизмның алсу таңнары күренер...

Ул юантык зур гәүдәле булуга карамастан, хәрәкәтчән — бер урында гына басып тора алмый, үз-үзенә ышанып, пафос белән шулкадәр ихлас сөйли, солдатлар аны миңгерәүләнер дәрәҗәдә бирелеп тыңлыйлар, бөтен җан-тәннәре белән азатлык сөюче Куба халкы ягына авышып бетәләр...

Габделнур политзанятиеләрне бик ярата, анда әйтелгән һәр сүз аның йөрәгенә сары май булып ята. Әгәр кирәксә, ике дә уйламыйча, ирекleләр сафында Кубага барып, империалистларга каршы сугышырга әзер. Әйтсеннәр, чакырсыннар гына.

Бу арада һәр төнне аларны тревога белән күтәрәләр, плацка чыгарып, баштанаяк коралланган килеш бөркәвечле машиналарга утырталар. Бер-ике сәгатьтән соң гына отбой игълан ителә.

Озын колаклардан, чыбыксыз телефоннан кайбер серле хәбәрләр аларга да килеп ирешә: имеш, безнең су асты көймәләре инде анда икән. Ни өчен дигәндә, моннан ракета Америкага ярты сәгать очса, Куба ярларыннан — биш минут... Кыскасы, Габделнурлар халыкара хәлләрдән генә түгел, Куба мәсьәләсендә Советлар Союзы тоткан кыйбладан да ярыйсы гына хәбәрдар иде.

...Увольнениегә чыккач, Габделнур Морат янына Усть-Рогаткага китте.

— Нәрсә кирәк, солдат? — дип сорады пирстагы КППда дежур торучы мичман, аның сәламен алгач.

— Дус янына килгән идем.

— Кайсы корабльдә?

— Эсминецта, — диде Габделнур һәм хәрби корабның номерын гына түгел, исемен дә әйтте.

Бәхетенә мичман үзе шуннан булып чыкты.

— Чакырыйкмы?

— Ул увольнениегә чыгарга тиеш.

— Көтеп тор алайса. Хәзер чыгар.

Үзе Габделнур белән гәп корып җибәрде: сораштырды, үзе турында да әйтте. Ябык битен кояш ашаган, диңгез җилләре маңгаена сай гына сырлар уйган утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге бу ир-егет Чиләбе якларындагы бер татар авылыннан булып чыкты. Ун елдан артык хезмәт итә икән инде. Аның өс-башы чиста, киеме пөхтә, буйга Габделнур чамалы, ләкин күкрәкләре киңрәк. Үзен бик иркен тота. «Бу чын моряк булган», — дип уйлады Габделнур, аның аякларын киң басып торуына карап һәм төс-кыяфәтенә сокланып.

Озакламый, алтын хәрефләр белән «Балтийский флот» дип язылган ак түбәле бескозыркасының кара тасмаларын җилфердәтеп, кара чалбар кигән озын аяклары белән җил-җил атлап, Морат килеп җитте. Зәңгәр җирлекнең читенә өч рәт ак сызыклар сузылган гюйс та, ап-ак форменка изүеннән күренеп торган тельняшкасы да үтүкләнгән, бил каешындагы аелы гына түгел, кара ботинкасы да кояшта җем-җем итә, үзе көләч. Егетнең юка гәүдәсе тыгызлана, ябык чиста йөзе тупаслана төшкән сыман — җил ашаган. Алар бик җылы күрештеләр.

— Держи краба! — дигән булды Морат, елмаеп.

Габделнур бу гыйбарәне белә иде: бармакларын тырпайтып, уң кулын алга сузды, дустының җиңенә тидереп алды.

— Хәлләр ничек?

— Настроение бодрое — идем... ко дну, — диде шат йөзле Морат, шаяртып.

Кәефе шәп икәне әллә каян күренеп тора иде.

Бу инде моннан җиде-сигез ай элек Габделнур белгән йомшак табигатьле, кызларныкы кебек нәзек беләкле, педучилище бетереп кенә чыккан юаш, яшь укытучы түгел иде. Кыяфәтендәге басынкылык та юкка чыккан, күз карашы, үз-үзен тотышы — барысы да ирләрчә нык, ышанычлы, кискен. Һәр хәрәкәтеннән көч-гайрәт ташып тора.

— О, малай, синең күкрәкләр тагы да киңәеп киткән, ахры!

— А как же?! Грудь — моряка! — диде Морат, көлеп.

Габделнур ялгап китте:

— ... спина — грузчика, ж... — старика!

Бераздан Морат дежурныйга мөрәҗәгать итте:

— Иптәш мичман, якташка үзебезнең хуҗалыкны күрсәтик әле.

— Корабльгә керәсезмени?

— Әйе.

— Юк, анда кермәбез, — диде Габделнур, артык әрсезләнмичә. — Әнә «Киров» крейсерын, «Юрий Долгорукий»ны карасак, шул җитә. Сезгә бүтән вакыт керербез.

— Барыгыз.

Алар капкадан эчкә үттеләр. Бераздан яр буенда тезелешеп торган эреле-ваклы хәрби корабльләр яныннан иң зурысына таба уздылар.

Тар траптан күтәрелеп, вахтенныйдан рөхсәт сорап, башта «Киров» крейсерын, кубрикларга, тиешле-тиешсез җиргә кермичә, өстән-өстән генә карап чыктылар. Сугыш вакытында немец снаряды аның борынын җимереп, кыеп төшерә. Ләкин ДОК эшчеләре бер төн эчендә аны ремонтлап, сафка бастырганнар. Габделнурны

хәйран калдырганы — аның туплары. Аслы-өсле, өчәр-өчәр куелган бу туплар колач җитмәстәй котсыз юан һәм бик озын иде. Ерактан ул тиклем түгел, ә якынга килеп карасаң, кырык-илле чакрымга ядрә җибәрә алучы бу дәһшәтле туплар галәмәт зур икән. Күпме җимергеч көч тупланган аларда...

«Юрий Долгорукий» кит аулау флотилиясендә беләгенә кызыл тасма бәйләгән дежур моряк егет тә (анысы гражданский киемнән, билгеле) аларның теләгенә каршы килмәде.

— Озак йөрмәгез, — дип кенә калды.

Крейсердан да ике тапкыр зуррак бу судноның койрыгындагы уемга — китларны тартып мендерә торган «авызына» хәйран калды Габделнур.

— Моннан авыл өен өстерәп менгерергә була икән, — диде ул, дустына карап, һәм корабның озынлыгына да исе китте. — Футбол кыры моңа как наять кереп утырыр иде.

Аска төшеп, җиһазларның чит телдәге язуларын укыштырдылар. Аларның гаҗәпләнеп кызыксынуына узып баручы берәү:

— Бу судно — немецларныкы, сугыштан килгән зыян хисабына контрибуция рәвешендә безгә эләккән, — дип аңлатты. — Капремонттан соң аңа яңа исем бирелгән.

Шунысы кызык булды: аска таба өченчеме-дүртенчеме катка төшкәч, егетләр йөзеп йөрүче бу заводта (әйе, консерва банкалары аның үзендә үк әзерләнә) адаштылар...

Пирстан бераз ераклашкач, Габделнур сорап куйды:

— Гөлсинурдан хәбәр юкмы?

— Юк.

Морат Габделнурга юлда ук ул кыз турында сөйләгән иде. Педагогия училищесында укыганда егет аңа гашыйк була. Ләкин кыз бүтән егет белән йөри. Габделнур Моратны хат язарга күндергән иде. Күрәсең, кыз аның сөюен кабул итмәгән.

— Авылдан хат аласыңмы?

— Әйе. Ә кичә төш күрдем, сагынгангадыр инде. Безнең авылда өч чишмә бар. Сиңа сөйләгәнием бит. Шуларның өчесен дә әйләнеп чыктым. Кое сиртмәләрен, тәрәзә капкачларын аермачык күрдем — алар нәкъ элеккечә. Ә менә педучилищеның ике катлы озын бинасы үзгәргән — тәрәзәләре ни өчендер түгәрәк.

— Анысы инде синең хәзерге халәтең белән буталган — тавык төшенә тары кергән, — дип көлде Габделнур. — Корабльнең иллюминаторлары белән алышынган...

Аннары Морат кыяр-кыймас кына әйтте:

— Кичә вахтада торганда тагын бер шигырь яздым әле. Менә болай башлана:

Сандугачның балалары
Сайрый-сайрый су эчә;
Туган илгә кайта алмыйм,
Бик сагындым югыйсә...

Шәһәр карап байтак вакыт бергә йөргәннән соң, Морат уңайсызланып кына әйтеп куйды:

— Мин монда бер хатын белән таныштым.

— Кит аннан?! Уже наматросил и бросил? — дип шаяртты Габделнур. — Ыһы, белдем эшеңне, коярмын тешеңне...

— Әле ташламадым, дөресрәге, башламадым, — диде Морат, уңайсызланыбрак кына. — Ял көнне килерсең, дигәние. Әйдә, бергәләп кереп чыгабыз.

Габделнур өчен бу яңалык көтелмәгәнрәк булды. «Кара син астыртын мыштымны, кызлар кулы да тотмаган килеш, кай арада өлгергән, — дип уйлады ул эчтән генә, әмма ләкин дусты өчен шат иде. — Әйдә, йөрсен, монда әллә ни барыр урын юк. Күңел ачар, вакыт үткәрер».

Ул, сәгатенә карап алгач:

— Син үзең генә бар, — диде һәм елмаеп өстәде: — Алай икән, болай икән, эшләрегез шулай икән... Ярар, ашыгызга таракан булып төшмим...

— Диңгезгә чыгарга җыенабыз, — диде Морат, саубуллашканда. — Тиз генә күрешеп булмас.

— Семь футов под килем, — дигән булды Габделнур алар артыннан телендә.

## 12

Кая барсаң да бер кояш дигән шикелле, Кронштадтта да июль ае Габделнурның туган ягындагы кебек: көннәр җылы, кояшлы. Дөрес, шәһәр Фин култыгында урнашканлыктан, өзлексез диярлек салкынча җил — бриз исеп тора. Ул, диңгез өстен дулкынландырып, ярга таба эреле-ваклы дулкыннар тәгәрәтә. Кояш, су өстендә күзләрне чагылдырып, төрле төсләргә кереп уйный. Озын канатлы акчарлаклар да уйный сыман, ләкин боларның шөгыле үзгәрәк — алар балык язмышы белән уйный.

Габделнур белән дә язмыш үзенчә уйный иде. Ул — хәрби хезмәткә алынган, фәкать шул эшнең остасына әверелеп, иңенә мылтык асып, өч ел буена илен сакларга тиешле солдат — бүген авыл агайлары яки урманчылар башкара торган гап-гади эшкә – урман кисәргә барырга тиеш. Тиеш икән, димәк, шулай кирәк. Ахыр чик-

тә алар мичкә ягар өчен утын әзерләргә бармыйлар — ул хәрби максатлар өчен кирәк икән — яр буена өстәмә маяк мачтасы куясылар. Хәер, алай булмаса да, командирлар әмеренә буйсынмыйча чараң юк.

Габделнурлар утырган машина хәрби кораблар пирсыннан читтәрәк урнашкан причалга килеп туктауга, солдатлар берәм-берәм җиргә коелдылар. Командирлары, һәрберсен күздән кичереп, төшкән берсен, кулы белән ишарәләп, койрык өлеше ачык судногa озата торды.

— Паромга, паромга!

Ярга терәлеп быгыр-быгыр су кайнатып торган паром, машиналар да кереп урнашкач, озын гына итеп гудок бирде дә китеп тә барды.

Казармадагы бертөрлелектән, муштрадан туеп беткән, урамга чыгуны, мунчага баруны да бәхеткә санаган солдатлар өчен бу сәяхәт үзе бер куаныч иде.

Кара син бу иркенлек-хозурлыкны! Әйләнә-тирә тоташ су, саф һава — күкрәк тутырып сула, ләззәтлән. Зәңгәр күк йөзендә сирәк кенә ертык ак юрганнар күренә — болытлар тулгана, һава дулкыннарын куып диңгез җиле исә, ерактагы корабның карасу силуэты шәйләнә.

Алда әле каршы яр күренми, ә артта инде үзенең торба-манаралары, биек йортлары, пирстагы хәрби корабльләре, причалдагы балык тоту һәм йөк ташу суднолары белән Кронштадт һаман ерагая бара. Аны саклаучы кызыл төстәге крепость-фортлар да отыры артка күчә.

Монда алар бихисап. Шәһәрнең бу ягындагылары: Кроншлот, Павел Беренче, Петр Беренче, Беренче — Өченче Көньяк, Константин... Котлин утравының иң аргы башындагысы Риф дип атала.

Ә шәһәрнең теге ягында, ягъни төньякта, шулай ук берничә: Тотлебен, Беренче — Җиденче Төньяк, Обручев.

Әйе, мондагы һәр фортның исеме, тарихы бар. Кронштадтның бу ягындагы Александр форты, мәсәлән, 1845 елда төзелгән. Аңа патша Николай Беренче үзе күзәтчелек иткән, һәрнәрсәне җиренә җиткереп эшләткән: нигезенә агач субайлар кактырган һәм гранит валуннар салдырып калдырган. Төзүчеләр — Рәсәйнең бик күп губерналарыннан куып китерелгән крестьяннар — бүрәнәдән әмәлләнгән баракларда яшәгәннәр.

Фортның диварлары өчәр метр калынлыкта. Ул — үзенә бер автономия белән яшәүче ныгытма, аның эчендә ни барын, нәрсә эшләнүен чит кеше белми, андагы вакыйгалар читкә бик таралмый. Шуны истә тотып, 1908 елда Александр фортында чума авыруына каршы дару эшләүче лаборатория оештырып җибәрәләр. Вакцина әзерләү өчен күп күләмдә ат каны кирәк була, шуңа күрә монда китерелгән малларны өскә күтәрү өчен хәтта лифт урнаштыралар, ат үләксәләрен яндыру өчен крематорий да корыла. Биредә эшләнгән сыворотка чумага каршы чәчәк салу өчен бөтен Рәсәйгә таратыла.

Кеше яши торган бүлмәләрне (табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар, лаборантлар һәм хуҗалык эшчеләре фортта ук яши) башкаларыннан калын тимер ишекләр белән аералар. Ләкин докторларны ул ишекләр генә саклап кала алмый — аларның үзләренә дә чума микробы — авыру эләгә, чөнки саклык чаралары бик примитив, түбән була. Күпме генә яшерергә тырышсалар да, форттагы хәлләр тышка бәреп чыга. Халык арасында бу фортның яманаты тарала, һәм аны «Кара үлем форты» яки «Чумный форт» дип атап йөртәләр.

Октябрь революциясеннән соң сыворотка ясау туктатыла, форт яңадан үзенең төп вазифасын башкарырга тиеш була — хәрбиләр кулына тапшырыла.

Аерым шәһәрләрне, аларга диңгездән керү юлларын саклауның үрнәген урыслар Аурупа илләреннән алганнар. Франциядә, мисал өчен, нәкъ шул исемдә — Александр форты бар.

Бөек Ватан сугышы чорында Ленинградны саклауда да Кронштадт фортларының өлеше бәһаләп бетергесез: фашистларның бер генә корабы да аларны урап уза алмый; күпме генә бомбага тотылса да, Кронштадт бирешми — аның урамнарына дошман солдаты аяк басмаган.

Паромның тимер, салкынча бортына таза итләч кул-бармаклары белән ябышкан, кайсы терсәкләренә таянган, карашларын алга төбәгән, сирәк-мирәк як-якка караштырып баручы солдатлар үзара әңгәмә кора.

— Без Ленинградка керәбез микән?

— Кермичә, аны узып барасы бит әле.

— Син, монда туганнар яши, дигән идең. Алар яныннан үтмибез микән? Чәй эчәргә кереп чыгар идек.

— Юктыр. Аларның йорты шәһәр читендәрәк.

— Без бер генә ай булырбыз микән?

— Командир шулай диде бит.

— Анда эш авыр булыр әле.

— Булса, бу эсседә плацта айт-двага басып йөргәнче, урман эчендә эшләвең артыграк.

Бераздан тынып торалар. Яшьләре белән барысы да бер чама булсалар да, һәр кеше — үзе бер дөнья. Хәзер инде хезмәткә күнегелгән дияргә мөмкин, өйгә ашыгасы юк — кайту турында уйларга иртәрәк. Шулай да туган йортлары, әти-әниләре, туган-тумачалары һичкайчан исләреннән чыкмый. Яшь-җилкенчәкнең күңел түрендәге иң яшерен хисләрен тирбәлдереп, күбесенә сәлам хатлары килеп тора; инде ара өзелгәннәре дә юк түгел.

Хат дигәннән, кичә Габделнур да ике хат алды: берсе — энесеннән, икенчесе — Әлмәттә аны озатып калган чибәркәйдән. Энесе, гадәттәгечә, авыл хәлләрен язган, өйдәгеләрнең, агай-энеләрнең барчасыннан да сәлам юллаган. Барысы да сау-таза икән әлегә. Хат укыгач рәхәт булып китте. Ә менә кызының хаты ничектер

икеле-микелерәк сыман тоелды. Әле Габделнурның андый төшенке рухтагы язмага дучар булганы юк иде. «Отпускыга кайтырсың микән? Бигрәк озак инде өч ел...» — дип язган сөйгәне.

Габделнур үзе дә белә өч елның озак икәнен: утыз алты ай, һәр айда дүрт атна, фәлән көн... Ә нишләсен ул? Хәзер, кызымны сагындым, ул да мине бик зарыгып көтә, дип кычкырып еламас бит инде. Мине өйгә җибәрегез әле дигән мәгънәсез үтенеч белән командирга да керә алмыйсың... Фәкать бер генә юл кала: көтәргә, көннәреңне, атна-айларыңны саный-саный еллар үткәнен көтәргә...

Үзе дә өч ел хезмәт иткән абыйсының озатканда әйткән сүзләре исенә төште: «Энекәш, кызлар өчен бик саргайма, юләрлек эшләп ташлый күрмә. Алар барыбер көтми...»

Шулаен шулай да бит, ә яшьлек үзенекен итә: яраткан кешеңнең көтүен телисең, аның белән очрашасы килә, яратасы, сөясе... Бик тә бәгырь өзелгән чаклар ай-һай еш була... Әгәр дә үз иркеңдә булып, кем беләндер танышып-аралашып, онытылып торсаң бер хәл иде... Монда андый мөмкинлек тә юк. Дөресен генә әйткәндә, әле андый теләге дә юк иде Габделнурның. Аның бөтен уйлары Рәйсәнә тирәсендә генә болгана-тулгана... паром бортына кагучы дулкыннар кебек...

Габделнур, уйларына чумып, суга карап, авыз эченнән күптән түгел радиодан ишеткән җырны көйләп бара башлады:

Ах ты, палуба, палуба,
Ты меня раскачай,
И печаль мою, палуба,
Расколи о причал.

— Габделнур, карале, еракта яр күренә.

Янәшәсендә торган бер солдат аның терсәгенә кагылды, уйларын бүлдерде.

— Анда Ломоносов булырга тиешме? — дип сорады ул.

— Белмим, — диде Габделнур, бераз кәефе кырылып.

Алар арасындагы Ленинград егетен түгәрәк эченә алганнар. Ул, экскурсантларга аңлаткан гид кебек, нидер сөйли иде.

— Әйдә, Петров янына барыйк, — диде Габделнур.

Түгәрәк читенә килеп бастылар.

— ...1815 елда Русиядә төзелгән беренче пароход «Елизавета» Санкт-Петербург белән Кронштадт арасында йөри... Уңдарак — зур Ижора, — диде Петров һәм кулы белән алга төртеп күрсәтте. — Каршыда Дубочки, Лимузи, Куккузи һәм бүтән авыллар.

Габделнур түзмәде:

— Ничек дидең? Куккузи дидеңме?

— Әйе.

— Бәй, татарча «күккүз» дигән сүз бар.

Ул аны урысчага да тәрҗемә итеп күрсәтте.

— Ихтимал, бик ихтимал, Питерда татарлар бик күп. Бу тирәдә дә элек-электән үк яшәгәннәрдер, — диде Петров һәм өзелгән сүзен дәвам итте: — Ломоносов — сулдарак. Элек ул Ораниенбаум дип аталган.

— Ничек, ничек?

Ят исемне яңадан кабатлап, Петров дәвам итте:

— Патшаларның ял итә торган урыны булган. Дөресрәге, берничә урынның берсе. Анда әфлисун үстергәннәр.

— Патшалар әфлисун гына ашап торганнар икән, — дип сүз кыстырды кемдер.

— Үскәч, ашаганнардыр инде. Шәһәр гербында да әфлисун агачы төшерелгән булган.

— Хәзер нәрсә?

— Анысын белмим, бабайдан ишеткәнне генә әйтәм, — диде озын ябык гәүдәле, күзлекле, чип-чиста кырынган зәңгәрсу яңаклы Петров.

Ул үзенең төс-кыяфәте белән аерылыбрак тора иде: киеме һәрчак үтүкләнгән, пөхтә, беркайчан шапшаклык галәмәте күрмәссең. Китап укырга ярата. Бәлки, аның ата-бабасы аксөякләр нәселеннән булгандыр, ул сөйләшкәндә беркайчан да Ленинград дигән сүз ычкындырмас, һәрчак Питер дия. Петербург та, Петроград та түгел, ә Питер гына. Габделнур моңа башта аптырады, аннары ияләнде. Нева ярында туып үскән кешеләр гәрчә совет власте чорында шәһәр Ленинградка әйләнгәч туган булсалар да, нигәдер Питер дип сөйләшәләр икән. Бигрәк тә интеллигенция.

Петров янына әти-әнисе дә килеп китте. Кронштадт ябык шәһәр булганлыктан, командованиегә алдан ук рапорт язып мөрәҗәгать итәргә, пропуск юлларга кирәк булды Петровка. Бер тапкыр гына күрсә дә, әти-әнисе дә бик күркәм, зыялы кешеләр шикелле тоелды Габделнурга. Һәрхәлдә, шундый тәэсир калды. Әтисе дә сөйләшкәндә үзе яшәгән шәһәрне Питер дип әйтте. Ә аның улы белән бергә хезмәт итүче егетләрнең барысы өчен дә ул мәшһүр, данлыклы шәһәр фәкать Ленинград кына...

...Паром яшеллеккә күмелеп утырган җыйнак кына шәһәргә отыры якынлаша. Йортлар ике-өч кенә катлы, эчтәрәк, бәлки, биегрәкләре дә бардыр, ләкин яр буенда андыйлар шәйләнми, киресенчә, бер катлы өйләр дә бар. Агачлары ниндидер, әфлисун агачы бармы, юкмы, аны да аера алмыйсың, чөнки ул агачлар еракtan яшел урман кебек. Хәер, Габделнурның моңарчы әфлисун агачын күргәне юк, танымас та иде, шул җимешенә карап аерса гына инде. Анысын бер тапкыр ашаганы булды.

Паром килеп туктауга:

— Тизрәк яр буена чыгарга! — дип кычкырды взвод командиры һәм, берәмләп дигәндәй, кул астындагы солдатларны ашыктыра-озата торды.

Бөркәвечле машиналарга төялеп, асфальт юлдан, аннары шәһәр урамнары буйлап киттеләр. Габделнур иң артта утырган иде, шәһәр карап барды. Яшеллеккә төренгән шәһәр чиста, урамда гражданскийлар белән хәрбиләр аралаш. Бу шушы тирә шәһәрләре өчен гадәти күренеш булса кирәк.

Шәһәр артка чүкте, юл да күгелҗем тасма булып кала бирде.

Көр күңелле, таза тәнле солдатка күп кирәкмени — кемдер башлап җибәрде, һәм җыр, асфальтка гына коелып калмыйча, юл буендагы куакларга, биек нарат агачы ботакларына да эленеп тирбәлә иде.

...Выходила, песню заводила
Про степного сизого орла,
Про того, которого любила,
Про того, чьи письма берегла.

Аны икенче көй алыштырды. Кәеф күтәренке чакта җыр өзлексез агыла да агыла бит ул.

Мартышкино, Петродворец, Иске һәм Яңа Петергоф, Стрельна кебек шәһәр-авыллар артта кала бирде.

Күпмедер вакыт узгач, Ленинградка килеп керделәр. Моның шулай икәнен сиздереп, машина туктады. Взвод командиры, кабинадан төшеп, машина артына чыкты.

— Хәзер шәһәргә керәбез, — диде ул, кашларын җыерып. — Җырлауны туктатыгыз.

— Есть, иптәш мичман! — диде Габделнур кебек иң артта аңа каршы утырган отделение командиры. — Җырны туктатырга!

Машина кузгалды. Күңелләре алгысыган яшь-җилкенчәкне тиз генә «суытып» буламыни — янә җырларга тотындылар. Сержант, солдатларын тыя алмагач, үзе дә кушылды. Бу юлы инде бөтен көчләренә кычкырып, урамнан узып баручылар артларына борылып карарлык итеп җырладылар:

А для тебя, родная,
Есть почта полевая.
Прощай, труба зовет.
Солдаты, в поход.

Киң проспектларда урнашкан, маңгайларына эре хәрефләр белән исемнәре язылган завод-фабрикалар, берсеннән-берсе матур, зиннәтле йортлар һәм... чибәр-чибәр кызлар артта кала. Машина трамвай-троллейбуслар белән ярыша-ярыша чапкан уңайга кайсы тар, кайсы киңрәк каналлар аркылы салынган күперләр аша чыга, ары китә.

Кичтән дуслары белән бик каты типтереп, иртәнчәк махмырдан аякларына киез итек киеп, кәбестә ашы сорап «баш төзәтә» торган, ата казлар сугыштырып ләззәт ала торган һәм башка мәзәк гадәтләре булса да, күрәсең, үз заманы өчен бик булдыклы кеше булгандыр Петр Беренче. Уналты яшендә өйләнеп, чит илләрдә балта тотып кораблар төзү эшенә һәм башка һөнәрләргә өйрәнеп кайткан, алыптай гәүдәле, көчле ир-егет курыкмыйча сазлык уртасына шәһәр кору эшенә керешкән. Әлбәттә, моның өчен ифрат тәвәккәл кеше булырга кирәк. Чик буенда булса да, ун ел да үтми — 1712 елдан ул шәһәр башкалага әверелгән.

Хәзер дә, беренчелекне бирсә дә, Мәскәүдән кала иң шанлы шәһәр ул: бай тарихлы, матур, һәр йорты соклану уята торган.

Әлбәттә, ул йортларның һәрберсе нинди дә булса тарихи әһәмияткә ия яисә кемнеңдер исеменә, иҗатына бәйле истәлекле урындыр.

Машина әрҗәсе бөркәвечле, солдатлар алда ни барын күрмиләр, бары машина узып киткәч кенә ни-нәрсә икәнен абайлыйлар иде. Шуңа күрә алан-йолан карап барудан бүтән чара калмады. Габделнур әле уңга, әле сулга башын борып күзәтүен дәвам итте.

Машина Невский проспектын аркылы үтеп Киров күперенә килеп чыкты. Сулда Петропавел крепосте, «Аврора» крейсеры калды. Аптекарь һәм Таш утрауларны үттеләр. Тагын ике тапкыр елга кичтеләр. Хәер, бу юлы Нева аша түгел, алар таррак һәм аның беренчесе — Кече Невка, ә икенчесе Олы Невка дип атала иде. Аннары, соңгысының яры буйлап бара торгач, Фин култыгына ук килеп чыктылар.

Ленинградта кая карама су — Фин култыгы (ул диңгездән ким түгел), мул сулы Нева, кечерәкләр, каналлар... Юкка гына Петр Беренче указ чыгармагандыр: «Һәркем суда хәрәкәт итү средстволары булдырырга тиеш». Чөнки ул чорда әле күперләр булмаган бит. Димәк, һәр гаилә көймә юнәтүне кирәк тапкан.

Машина тимер юл белән янәшә сузылган асфальттан бара, дачалар, авыллар кала. Монда тоташ агачлык: нарат, чыршы, каен, юкә, чәчәк атып утыручы сирень. Габделнур бер ят агач та күрде. Ул аның туган авылы инеше буендагы тәбәнәк таллар биеклегендә, вак ботаклары һәм яфраклары өстә генә, ябалдаш алагаем зур зонтик кебек кабарып-күпереп тора, ә аста — карасу төстә бик күп ботаклар, әйтерсең тал агачының аскы яфракларын сыдырып алганнар. Хәер, аскы өлешендә вак ботаклар да юк.

Юл буйлары чиста, агачлар арасында өстәл биеклеге валуннар — зур-зур йомры, шома ташлар күренә. Алар элек-электән, бозлык чорыннан анда калганмы, әллә аларны матурлык өчен махсус куеп чыкканнармы — эш анда түгел, һәрхәлдә, алар урман эчен, юл буйларын ямьләп, үзенә бер үзгәлек биреп торалар, күзне иркәлиләр. Бу тирәдә элек финнар яшәгән, диләр.

Кронштадт турысындагы Лисий Нос, Горская кебек кечкенә шәһәр һәм поселоклар, уң якта Разлив күле, ә юлның сул ягында кайчандыр Ленин бабай качып яткан печән куышы — шалаш һәм зур автобуска төялеп аны карарга килгән чит ил туристлары да артта калды. Арырак Сестрорецк, Солнечное, Репино, Комарово, Зеленогорск кебек эреле-ваклы кала-салаларны машина выжлап кына үтте, Выборг юнәлешенә таба җилдерүен дәвам итте. Юл әле урман эченә керә, әле аланлыкка элдертә, әле Фин култыгы ярына ук килеп чыга. Анда очсыз-кырыйсыз диңгез җәелеп яткан гаҗәеп күренеш хасил була.

Күп тә үтмәде, машина янә урман эченә кереп китте. Тар гына юлдан шактый баргач, кабат яр буена килеп чыкты, ниһаять, туктады.

...Палаткалар кору, урнашу, ашау-эчү мәнфәгатьләрен кайгырту, балта-пычкылар кайрау — болар барысы бергә эшләнде һәм икенче көнне иртүк яшь, таза егетләр урман кисүгә керештеләр.

...Урман эченә, гаять зур өчпочмак ясап, көннән-көн күбрәк керә бардылар. Эше авыр булса да — агачларны аударасы, ботакларын чабасы, үлчәп кисәсе, читкә ташыйсы — табигате, яшәү шартлары уңай булганлыктан, зарланучы сирәк иде. Көндез, төшке ашка туктаган арада диңгезнең саф суында коенып, тәннәрен сихәтләндерделәр, кичләрен взвод командирына балык тотарга булыштылар... Кыскасы, эш тә барды, ял да иттеләр.

Взвод командиры балык тотарга бик әвәс кеше булып чыкты. Ул һәр көн диярлек тамаклык балык эләктерә иде. Кайчагында аның янына Габделнур һәм башка егетләр дә килеп утыра. Балыкларны куркытмас өчен шыпырт кына сөйләшәләр. Кулында кармак сабы, күзе су өстендәге калкавычта булса да, күбрәк ул сөйли. Табигатьнең һәр мизгелен аңлап, алда ни буласын белеп-сизеп тора бугай. Мәсәлән, яр буена акчарлаклар килеп утырганны күрсә, ул:

— Акчарлаклар ял итә, димәк, һава бозылачак, — ди.

Һәм аның сүзе дөрескә чыга.

Монда табигать бик күркәм, үзенчәлекле. Фин култыгына бер карыйсың, көчле җил исә, эре-эре дулкыннар ак сыртларын кабартып тәгәрәшә, икенче карыйсың, бигрәк тә иртәнчәк, өсте шулкадәр тыныч, еракка-еракка күз салсаң, су белән һава кисешкән урын — горизонт — бөтенләй беленми, әйтерсең кушылганнар. Кичке шәфәкъ — үзе бер тылсымга тиң вакыт.

Рейдта торучы сылу хәрби кораблар, Ленинградка килүче һәм китеп баручы зур, ак теплоходлар — мондагы пейзажның аерылгысыз бер өлешләре.

Диңгез суы чиста, гәүдәң күмелгәнче керсәң дә су төбендәге ташлар, диңгез кабырчыклары аермачык күренә. Тирәнгәрәк кергән саен салкыная...

Урман кисү дәвам итә. Өчпочмакның асты — киң өлеше — яр буенда, ә тараеп килгән очлы түбәсе урман эченә төртелергә тиеш иде. Бәлки, солдатлар, эшләрен бетереп, сузып салынган өчпочмакны хәтерләткән ачыклыкны — маяк мачтасына кирәкле урынны хәстәрләп тә куйган булырлар иде, ләкин көтелмәгән хәл килеп чыкты — Ленинград егете Петровны агач басты.

Габделнур алардан еракта эшли иде. Кулдашлары белән шау-шу килгән якка йөгерделәр. Петровның болай да ак чиста йөзе кәгазь кебек, аңын җуйган, маңгаеннан кан ага...

Машинага салып госпитальгә озатканда ул әле исән иде.

Солдатлар бик кайгырыштылар.

— Исән калыр микән?

— Ничек алай килеп чыкты икән?

Взвод командиры:

— Юкка борчылмагыз, ул исән, — диде ачу белән, чөнки таякның юан башы аның һәм бу арада көндезләрен гел югалып торучы рота командиры җилкәсенә төшәчәк иде. — Телегезне дә артык озайтмагыз. Барыгыз, эшегездә булыгыз.

Ләкин эш кайгысы түгел иде инде өлкән командирларда. Кронштадттан кайтырга дигән әмер килгән.

Тиз-тиз генә җыенып, кече командирлар буласы солдатлар янә Кронштадтка кайтып киттеләр. Сүз күп булды: кемдер андый эштә тәҗрибәсе булмаган шәһәр егетенең үзен гаепләде, кемдер солдатка урман кистерүне дөрес дип тапмады. Ни генә булмасын, Габделнурлар Петровны яңадан казармада күрмәделәр. Терелүен терелгән, диделәр. Мөгаен, комиссовать иткәннәрдер. Анысын инде табиблар һәм командирлар хәл итә.

Кронштадтта укуын әйбәт кенә тәмам итеп, Габделнур яңадан үз частена әйләнеп кайтты. Казармага кергәч тә иң беренче эш итеп коридордагы дневальный белән исәнләште.

Аннары:

— Ротный үзендәме? — дип сорады.

— Әйе, — диде телефон куелган тумбочка янында басып торган солдат. — Бар кер. Үзе генә бугай.

Габделнур коридор буйлап алга үтте. Ишек шакыды. Эчтән җавап килгәч, бүлмәгә узды. Капитан погоннары таккан булса да, бу аны Кронштадтка укырга димләп озаткан рота командиры түгел иде. Ләкин бүлмәсе дә, өстәле дә, дивардагы дөнья картасы да шул ук, дневальный да, үзендә, диде. Димәк, честь биреп, үзеңнең кем икәнеңне, нигә керүеңне аңлатудан башка чара юк.

— Иптәш капитан, ефрейтор Гаделҗанов хезмәтен дәвам иттерү өчен ротага кайтты.

— Аңламадым. Син кем? — дип сорады нәрсәдер язып утырган капитан, коңгырт төстәге кыска чәчле башын калкытып, сөзеп карап.

Төз гәүдәле, ябык йөзле ефрейторны аның беренче күрүе иде, аптырабрак баштанаяк карап чыкты. Хәер, яңаклары тулышып торган утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге офицерны Габделнурның да моңарчы бу частьта очратканы юк иде. Солдат үзенең кем икәнен, каян кайтуын хәрбиләрчә кыскалык һәм төгәллек белән, әмма аңлаешлы итеп әйтеп бирде.

— Ә-ә, хәтерлим, элекке ротный әйткән иде, — диде капитан һәм, бераз уйланып торгач дәвам итте: — Син хәзергә үз отделениеңдә булырсың. Аннары, «картлар» киткәч, күз күрер.

Әйе, кабинет шул ук, мебель ише җиһазлардан, дивардагы кәгазь-фәләннән — бернинди үзгәреш юк. Ә барыбер нәрсәдер җитми: ят бүлмәгә килеп кергән шикелле хис итте үзен Габделнур. Комбат белән элекке ротный кодалап, аны мактый-мактый юмалап укырга җибәрделәр. Дөрес, мәҗбүр итмәделәр. Габделнур алар сүзенә колак салып китеп барды, укуын яхшы гына төгәлләп, аң-белем алып кайтты. Ә монда... Ниндидер авыр тойгы биләп алды солдатны, билгесезлек, бушлык дип әйтсенме... Үзен кирәкмәс кеше кебегрәк хис итте. Әлбәттә, ул ата-анасы янына түгел, элек хезмәт иткән һәм хәзер дә итәчәк хәрби частька әйләнеп кайтты. Аны колач җәеп каршыларга тиешләр дигән уйдан ерак тора. Ләкин ул шушы ротадан, шушы казармадан, җан дуска әверелә башлаган иптәшләреннән аерылып, билгесезлеккә китеп барды бит... Яңадан әйләнеп кайтырга дип. Аны җибәрделәр. Булачак кече командир кайтыр дип, аңа зур өметләр баглап торганнардыр дисә, бик нык ялгышкан икән. Хәер, бу офицер бит яңа кеше. Аны гаепләп тә булмый. Әгәр мәслихәт биргән элеккесе шулай кырыс каршыласа...

— Китәргә рөхсәт итегез!

— Бар.

Казарма буш. Солдатлар кайсы занятиедә, кемнәрдер каравылда, бер ише нарядта икән.

Дневальныйдан:

— Старшина мондамы? — дип сорады.

— Юк.

Шуннан Габделнур түргә узды, каптеркага керде. Өлкән дусты белән кочаклашып диярлек бик җылы күрештеләр.

— Оho, — диде Нурмөхәммәтов, аны күздән кичереп, — әллә үсеп тә киткәнсең инде. Звание дә биргәннәр.

— Син үзең дә тик ятмагансың, — дип көлде Габделнур, егетнең погоннарына ишарәләп. — Кече сержант. Авылга кайткач, бөтен кызлар синеке булыр инде.

— Сорап алмадым, биргәч — каршы килмәдем, — диде гәүдәсе бераз калыная төшкәнгәме тагын да кечерәебрәк калган сыман күренгән Нурмөхәммәтов.

— Монда үзгәреш булган икән.

— Әйе. Утыр, нәрсә казак сыман басып торабыз. Кайтуың хөрмәтенә әзрәк тотабызмы? Минем күптәннән бер акбаш ятадырые. Сине көткән икән.

— Юк. Соңрак. Әле сыңар аяк кына кергән килеш, урнашмаган да бит.

— Дөрес әйтәсең, кул куям. Киләчәктә дә шул линиядән тайпылма... Монда ротный гына түгел, комбат та бүтән.

— Ничек? Ә Зирюк кайда?

— Югарырак урынга алдылар. Ротный академиягә керде.

— Ничего себе!

— Ул бик белемле, толковый офицер иде бит, хәрбиләр токымыннан, үсәсе килгәндер.

— Безнең егетләр барысы да исән-саумы?

— Әйе. Литвалы өч егет пожарныйга күчтеләр. Бер ай элек.

— Шулаймыни? Кемнәр?

— Синең дус Заранка, тагын Красаускас белән Бразаускас.

— Алай икән.

— Син отделение аласыңмы соң?

— Белмим. Бик атлыгып тормыйм. Дөресен генә әйткәндә, үз яшьтәшләрем өстеннән командовать итәсем дә килми. Әле биргән кеше дә юк. Кайттым гына бит. Ротный, сез киткәч, ди.

Беркавым сөйләшеп утырдылар. Нурмөхәммәтов дембельгә әзерләнә икән, беренче партиягә эләкмәсә дә, икенчесеннән калмаска өметләнә, шуңа күрә кара погонга алтын сыман сары тасмалар тагып яткан көне. Габделнур белә: кызыл погонлы егетләр дембельгә дип караны әзерли. Юкса монда «Ф» хәрефе белән кызыл погон да бик килешле, ярыйсы гына күренә. Ләкин кызыл погон — пехота билгесе — почетта түгел.

Чемоданын калдырып коптеркадан чыкканда (дусты белән очрашуга карамастан), Габделнурның кәефе төшенке иде. Ләкин борын салындырып йөрү хәерлегә илтмәс, әле ике ел хезмәт итәсе бар, шуңа күрә яңа шартларга җайлашырга, үз урыныңны табарга кирәк. Әйе, әлегә шушы котсыз зур бинада аның ятар урыны да юк, чөнки караватында бүтән солдат йоклыйдыр. Ул барысы бертөрле пөхтә итеп җыештырылган тимер койкаларга, алар арасындагы тумбочкаларга, ятканда киемеңне җайлап салып куя торган артсыз урындыкларга караштырып, диварның зур тәрәзәләре өстенә һәм алар арасындагы буш урыннарга эленгән, беркетелгән портретларга, плакат яисә шигарьләргә күз ташлап, сарыга буялган такта идәнле казармадан чыгып китте. Янгын сүндерү командасына барып (ә ул хәрби шәһәрчек эчендә үк, моннан биш минутлык арада гына урнашкан), Заранкаларны күреп кайтырга иде нияте.

Ләкин тышта, баскыч төбендә, рота старшинасы белән бәрелешә язды, йөзгә-йөз очрашты. Бөердән чыккан тавышы белән:

— Гаделҗанов, иплә6рәк, — диде аны танып старшина һәм, киң елмаеп, кул суздың. — Әйләнеп кайтуың белән.

— Рәхмәт, иптәш старшина.

Рота старшинасының хәрби дәрәҗәсе дә старшина, погонында «Т» хәрефенә тартымрак аркылы һәм буйлай калын сары тасма сузылган. Уртача буйлы таза гәүдәсен төз тота, калын мыеклары ике якка тырпаеп тора, козыреклы фуражкасын батырып кигән, куе яшел гимнастеркадан, аркылы-торкылы тар каешларны погон астына кертеп җибәргән, билендәгесе исә киң. Аның түшендәге орден-медаль ленталары дүрт рәт. Күкрәгенең уң ягын нәни байрак сыман гвардия значогы бизи. Коры кеше булса да, сугышта утны-суны кичкәнлектән гаделлеге белән аерылып тора иде.

— Кая юл тоттың? Ротныйда булдыңмы?

— Әйе, булдым. Әле болай гына чыгуым иде.

Солдат үзенең кай таба юнәлүен әйтеп тормады. Старшина аны үз артыннан ияртте. Ялгызы гына ротныйга кереп чыккач, Габделнурга бер буш койканы күрсәтте.

— Суслов әлегә лазаретта. Урын-җирен алыштыр.

Шулай итеп, иске казармада яңа тормыш башланды.

...Стадионда, сезон ябылуга багышлап, җиңел атлетика буенча ярышлар үтәсе икән. Габделнурны, әле генә сержантлар мәктәбен бетереп кайтуын исәпкә алып, йөз метрга аерым йөгерергә һәм эстафетага да куйдылар, өстенә кияргә зәңгәр төстәге юка спорт костюмы, аягына щипасыз җиңел кеды бирделәр.

Стадионга частьның бөтен подразделениеләреннән дә спортчылар, ярыш карарга дип хезмәттән буш офицерлар һәм макаронниклар, аларның хатыннары һәм бала-чагалары җыелган иде. Егетләр күзләргә кыз-кыркын да килгән — алар бер читтә, аерым төркем булып торалар. Баш-башында ятьмәле футбол капкасы булган зур спорт мәйданы гөж килеп тора. Гравий җәелгән йөгерү юлларында тезләрен югары күтәреп бер урында таптанып, сикерә-атлый йөренеп, спортчылар ярышка әзерләнә; музыка уйный.

Габделнур янгын сүндерү командасы егетләрен ерактан ук шәйләде. Ләкин алар арасында Заранка да, якташлары да (егет кичә алар янына барып кайтса да, иркенләп сөйләшә алмаган иде) күренмәде.

— Алар дежурда, — диде бер солдат аның соравына каршы.

Ярыш гаять киеренке үтте. Матрослар арасында да шәп йөгерүчеләр байтак икән, ә собаководлар белән янгынчылар элек-электән спорт ярышларында дан казана, бөтен тартыш алар арасында бара иде. Шулай да Габделнур да сынатмады: шәхси беренчелектә икенче урынны алды, эстафетада да өч этапта иң ахырдан килүче каравыл ротасын бу хурлыктан коткарды — унбер команда арасында бишенче урынга менгезде.

Ярыш беткәч, аның янына бер офицер килде. Ул уртача буйлы, җирәнгә тартымрак саргылт чәчле һәм шул ук төстәге калын кашлы кеше иде. Бик әдәпле генә итеп исәнләште:

— Исәнмесез.

— Исәнмесез, иптәш өлкән лейтенант.

Габделнур үзенә карата шундый итагатьлек, хөрмәт күрсәткән ят офицерның сипкелле йөзенә текәлде. Күрәсең, өлкән лейтенант аның турында инде мәгълүматлы кеше иде. Шуңа күрә ул әллә каян — уравычтан килеп боргалап маташмады, сүзне хәрбиләрчә кыска тотты:

— Мин янгын сүндерү часте башлыгы. Сезнең йөгерү миңа бик ошады. Безгә күчәргә теләмисезме?

«Дембель башланды бит, тагын китүчеләре бардыр», — дип уйлады Габделнур һәм аның җитди карашына, сүзләрен украиннарга тартымрак сөйләвенә дә игътибар итте. Беренче минуттан ук бу офицерга карата үзендә ниндидер эчке бер җылылык туганын тойды. Кыскасы, әүвәлге күрешү уңай тәэсир калдырды. Ләкин ул бит солдат, җитмәсә, әле генә кече командирлар мәктәбен бетереп кайтты. Ә аны каравыл ротасыннан аңа зур өметләр баглап, кайткач үзләрендә отделение белән командалык итәчәгенә исәп тотып җибәрделәр. Үзен ях-

шы яктан күрсәтсә, тора-бара дәрәҗәсе дә үсү ихтималы бар, әйтик, взвод командиры урынбасары дилбегәсен дә тоттырулары ихтимал. Кыскасы, Кронштадтка ул әнә шундый ерак перспективаны истә тотып озатылды. Дөрес, аны кодалаган капитан да, подполковник та юк. Ә каравыл ротасы бар, ул беркая да китмәгән дә, таралмаган да. Андагы замполит, старшина, взвод һәм отделение командирлары, ниһаять, солдатлар үз урынында.

Күрәсең, Габделнурның дәшми торуы озаккарак сузылды.

— Мин ашыктырмыйм, уйлагыз, — дип, өлкән лейтенант үзенең спортчы егетләре янына карап алды, китәргә ашыга иде булса кирәк.

— Мин каршы түгел, риза, — диде Габделнур, ниһаять, телгә килеп. — Ләкин мин үз иркендәге кеше түгел. Күчүне үзем генә хәл итә алмыйм.

— Мин аңлыйм. Мөһиме — сезнең теләк. Калганын үзем җайлармын.

...Кич белән Габделнур нарядка билгеләнде. Дөресрәге, патруль булып йөрергә тиеш иде. Сәгать ун тулганда, хәрбиләр телендә егерме ике дә ноль-нольдә, ул, киенеп, шинелен кысып буган бил каешына штык-пычак тагып, казармадан чыгып китте һәм аңа хәтле йөргән патруль солдатны алыштырды. Вазифа шуннан гыйбарәт: пекарня, котельня, кибет тирәләрен караштырырга. Аерым будка ише нәрсә юк, шуңа күрә ял итәргә, җылынырга кая тели, шунда кереп чыга ала.

Ноябрь җитсә дә, әле көннәр үзәккә үтәрлек салкын түгел. Моннан бер-ике көн элек явып киткән юеш кар эреп юкка чыккан, ләкин, кояш саран яктырткanlыктан, асфальт кибеп өлгермәгән. Баганалардан, зур тәрәзәләрдән төшкән ут яктысында чокыррак төшләрдә җыелып торган су ялтырый. Каен, өрәңге, тупыл кебек агачлар инде шәрәләнгән, ә нарат һәм чыршы үз гүзәллеген дә җуймаган, хәрби шәһәрчеккә дә ямь биреп утыралар. Клуб һәм командирлар яши торган йортлар тирәсендә әле яшьләрнең шау-шуы басылмаган. Котельняның өч якка тимерчыбыклар белән тарттырып куелган озын тимер торбасыннан куе зәңгәр күк йөзенә, сирәк йолдызларның кайберләрен каплап, кара төтен күтәрелә. Түм-түгәрәк ай көянтә-чиләк аскан гүзәлен саф һава сулап керергә дип кичке прогулкага алып чыккан. Ул кызый кайчагында әкрен генә йөзеп баруыннан туктап, Габделнурны күзәтә шикелле... Ә җир өстендә машина-фәлән йөрүдән туктаган, җилсез, моңсу бер тынлык хасил булган.

Ул сәгать уникеләргә хәтле урамда киләп сарып йөрде; кичтән үк бикләнгән кибетнең солдат бияләе хәтле йозагы урынында, тәрәзәдән котельня учагының янып торганы күренә, пекарняда да эш туктамый, урамда шикле кешеләр күренми. Шинель җиңен этәреп, сул кулын чак кына өскә күтәреп сәгатенә карады: унике туларга унбиш минут калган.

Габделнур, тәвәккәлләп, пекарня ишеген ачты. Чөнки ул алыштырган солдат казармага кайтып китәр алдыннан аңа нишләргә икәнен, монда бер җайга салынган тәртипне искәрткән иде.

— Кыенсынып торма, ул шулай көйләнгән инде.

— Уңайсыз бит.

— Син — беренче, син ахыргы түгел, — диде солдат китеп барышлый.

Зур авызлы эссе мич каршында ак халатлы, юантык гәүдәле олы яшьтәге бер хатын мәш килә, икенчесе — яшьрәге, зифа буйлысы — әле генә мичтән чыккан шакмаклы ипиләрне дивар буендагы киштәләргә тезә. Пекарня эче хуш ис — яңа пешкән тәмле, бәрәкәтле ипи исе белән тулган. (Хәер, ул бөтен урамга ук таралган иде инде, ике сәгать буена Габделнурның борынын кытыклап, авыз суларын китереп торды.) Егетнең башы әйләнеп киткәндәй булды: гүя үз авылына кайткан да үз өйләренә кергән. Нәкъ ул бәләкәй чактагы кебек, менә хәзер әнисе мичтән озынча кайнар шишара алып, аны сындырып, бер түтәрәмен аңа тоттырыр һәм ягымлы тавышы белән: «Аша, улым», — дияр.

Юк шул, монда әнисе юк. Шулай да таза хатын әнисedәй мәрхәмәтле булып чыкты. Башындагы яулыгын төзәтеп, кул аркасы белән маңгаена тибеп чыккан тир бөртекләрен сыпырып, артына борылды.

— Настя, солдатка бер буханка бир, — диде ул, исәнләшеп кыяр-кыймас ишек катында тукталып калган Габделнурга карап алгач. — Чәй дә сал. Утыр, солдат.

Уң кул якта почмагы кыршылган шакмаклы клеенка җәелгән кечерәк кенә өстәл бар иде. Аның өстендә стаканнар, чынаяк, чәйнек һәм чәй кабы, банка белән шикәр комы, калак ише нәрсәләр. Егет калҗыраган артсыз урындыкка килеп утырды. Яшь хатын өстәлгә, аның каршына китереп куйган кайнар ипине бармакларын пешерә-пешерә урталай сындырды. Аннары, кибән башын яратуы исенә төшкәч, яртысын тагын бүлде һәм кетердәтеп ашый башлады. Ипи сыныгыннан биткә җылы бөркелә, бераз чәйнәгәч, үзе авызда эри кебек. Күптән болай тәмле итеп кадерле нигъмәтне ашаганы юк икән. Тыгылмыйм тагы дип, вакыт-вакыт стаканның яртысы шикәр комыннан гыйбарәт булган чәйне калак белән болгаткалап һәм уртлап, күшәвендә булды. Ипинең яртысын төгәлләгәндә чәе дә бетте. Настя тагын ясап китерде.

— Бик тәмле, рәхмәт, — диде Габделнур, ипинең калган өлешен дә «хәл иткәч» һәм күбрәк олы яшьтәге хатынга карап әйтте: — Аяк-кулыгыз сызлаусыз булсын.

Хатын аның чыраена, акцент беләнрәк сөйләшүенә һәм соңгы җөмләсенең урысча бигүк төгәл һәм шома булмыйча колакка ятрак яңгыравына игътибар итте, ахры, кайдан, кайсы милләттән булуы белән кызыксынды. Егет әйтеп бирде.

Хатын өстәлгә якынрак күчте.

— Минем иремне сугышта бер иптәше үлемнән коткарып калган, синең якташың. Шәһәрен дә әйтә торган иде, хәтеремнән чыкты. Мавзолей сүзенә охшаганрак исем.

Габделнурның моңа бик күңеле булды һәм республикадагы ваграк шәһәрләрне атый башлады.

— Менә, менә, Мензелинск, — диде хатын, сөенеп. — Кызганыч, ул татар егете Берлинны штурмлаганда һәлак була. Ирем гел сагынып искә ала иде. Хәзер үзе дә юк инде. Яралары күп иде шул...

Чыгып киткәндә бу миһербанлы апа солдатка тагын бер бөтен ипи сузды.

— Иптәшләреңә алып кайт.

...Бер атнадан ефрейтор Гаделҗановны янгын сүндерү частена күчерделәр. Теге өлкән лейтенант тәки сүзендә торган: бөтенесен үзе хәл иткән.

Каравыл ротасындагы солдатлар постта тик басып торырга да авырсынып, көнаралаш — каешка, ике көн саен — камбузга, дип зарлансалар да, аларның хезмәтен биредәге белән чагыштырып, хәтта якын куеп та булмый. Әйе, мондагы хезмәт, кем әйтмешли, шикәр түгел, бермә-бер авыр: катлаулырак та, хәтәррәк тә. Янгынның исә графигы юк, көне-сәгате дә билгеләнмәгән — теләсә кайсы вакытта машинага төялеп чыгып чабарга кирәк булачак. Яшерен, үтә дә мөһим һәм зур объект өстенә, әле хәрби шәһәрчек һәм гражданский халык яшәүче поселок, аңа терәлеп торган авыл да бар. Бөтенесе өчен фәкать ике машинасы булган команда җаваплы. Аннары, монда кеше дә аз, расчетта һәркемнең үз урыны, үз вазифасы билгеле. Ләкин болар Габделнурны өркетми, киресенчә, хезмәт авыр булган саен ул мактаулырак дигән төшенчә егетнең аңына сеңдерелгән.

Аны егетләр белән таныштыргач, өлкән лейтенант бөтен хуҗалыкны күрсәтеп чыкты. Иваново шәһәрендә махсус хәрби училище бетергән бу офицер үз эшенең-хезмәтенең чын остасы булса кирәк, кул астындагы техниканы, җиһазларны бөтен нечкәлекләренә кадәр иренмичә тәфсилләп аңлатты.

— Янгын сүндерүчегә физик көч, җитезлек һәм курку белмәс йөрәк кирәк, — диде ул. — Ләкин башсызлык түгел. Саклык, бер-береңә ярдәмгә килү — безнең хезмәтнең аерылгысыз шартлары, пожарный өчен иң мөһим сыйфатлар.

Габделнур шунда «пожарник» сүзе белән «пожарный»ның аермасын да белде. Авылда янгын сүндерүчеләрне «пожарник» дип йөртәләр. Баксаң, пожарник түгел, ә пожарный икән алар. Чөнки янгынга дучар булып, хәер сорашырга чыккан кешеләргә әйтелә икән «пожарник» сүзе.

Офицер янгын сүндерүнең тарихына да кагылып үтте.

— Патша Алексей Романов 1649 елның 30 апрелендә «Шәһәр иминлеге турында» Указ чыгара. Шулай итеп, Россиядә профессиональ янгын сагы оештырыла. Ә Петр Беренче исә, гомумән, агачтан йортлар салуны тыйган. Шулай да янгыннар булып торган. 1812 елда, Наполеон шәһәргә кергәч, Мәскәү өч тәүлек яна. 1907 елдан мичкәле арбаларны машиналар алыштыра башлый, каланчалар төзелә.

Габделнур өлкән лейтенантның сүзен җөпләп, баш кагып кына утырды. Шулай да ул әйткәннәрнең кайберләре таныш икән. Лермонтовның «Скажи-ка, дядя, ведь недаром Москва, спаленная пожаром, французу отдана?..» дигән уку программасына кертелгән юллары хәтеренә килде.

— Янгынны сүндерүгә караганда кисәтүе җиңелрәк, — дип сүзен дәвам итте Лукъянчук. — Безгә объектны карап-тикшереп тору вазифасы да йөкләнгән. Анда игътибарлы булыгыз, тиешле-тиешсез урыннарга кермәгез, коралларга кагылмагыз, артык сораулар бирмәгез. Безнең бурыч — профилактика һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Бер атна эчендә Габделнур командирлар, Заранка кебек дуслары һәм бүтән солдатлар ярдәмендә каланчадагы тәрәзәләргә пычкы теше сыман киртләч җайланмалы баскыч — «штурмовка» куя-куя дүртенче катка мендәргә, җитен җиңсәләр күтәреп тар гына бумнан чабарга (менә кайчан искә төшә икән ул малай чакта мәктәп ишегалдында турникта атыну, бүрәнәдән йөгерү, арканнан өскә үрмәләү, биек баскычтан фәкать куллар белән генә югары күтәрелү...), йөгереп килгән шәпкә ике метрлы койма аша сикереп «очып» чыгарга өйрәнде. Ут сүндергеч белән дә үзлегеннән эш итә ала, җиңсә башына кидерелә торган көпшә белән су сиптерергә дә булдыра ала. Монда вакыт секундлар белән генә исәпләнә. Сине өйрәтеп-тикшереп торучының кулыннан кесә сәгате (чылбырлы, «штамповка» атлы андый сәгатьне Габделнурның абыйсы энеләренә Германиядән алып кайткан иде) шикелле түгәрәк, түшкә асарлык итеп бау таккан секундомер төшми.

Баскыч та, көпшә дә, кирәк чакта җиңсәләрне тоташтыручы ярым гайка, переходниклар — барысы да дюралюмин дигән материалдан коелган икән. Чөнки, беренчедән, җиңел, икенчедән, су тигәч тутыкмый, күгәрми.

Габделнур әйткән бер сүзне эләктереп алырга тырышты, тиешле инструкцияләрне һәм кәгазьләрне өйрәнде, һәр күнегүне җиренә җиткереп, шагыйрь әйткәнчә, эшкә чын күңел биреп башкарды; аз гына уңышка да куанды, нормативка сыешкан чакларында шатлыгы эченә сыймады. Кыскасы, аңа ышаныч белдергән офицер (җитмәсә, ул әле укыган чорда спортның пожарно-прикладной төре буенча «СССРның спорт остасы» дигән исемгә дә лаек булган икән) алдында да, бу хезмәтне үз итеп өлгергән солдатлар каршында да сынатасы, булдыксыз ярлыгы тактырасы килмәде. Эчен-тышын бакмыйча бер нәрсәне дә юньләп белмәячәген яхшы аңлаганга күрә, ул гидрант һәм колонкаларның да, машинадагы насос эше механизмнарның да төзелешен, эш принцибын һич иренмичә җентекләп өйрәнде. Шофер гаиләсендә үскәнгә аңа боларның серенә төшенү кыен түгел иде. Аннары, янгын сүндерү машиналарын төзәткән вакытларда да ул кул кушырып утырмады, эшләгә-

нең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен, дип хәл кадәренчә егетләргә булышты. Бу да командирлар күзенә чалынмый калмады.

Шулай дәртләнеп йөргән көннәрдә ул хат алды.

— Гаделҗанов, бие, — диде почта китерүче солдат. — Сиңа биш хат. Дүртесе Кронштадттан ук әйләнеп кайткан. Син китеп өлгергәнсең, күрәсең, ә бусы туры монда килгән, почеркы бик матур, кызлар язуына охшаган.

Кулын югары күтәргән солдат Габделнур үрелүгә читкә тайпылды.

— Шаяртма! Бие!

Нишләсен, йоласы шундый булгач, егет тыпырдап алды, башкалар кул чабып торды.

Иң әүвәл конвертлардагы адресларга күз салып чыкты: Әлмәттән килгәне чыннан да Рәйсәнәдән икән, Коспаш шәһәреннән — шахтадагы туганнан туган абыйсыннан, Азнакайдан — ташчы булып эшләүче классташыннан, Ерак Көнчыгыштан — балык тотудагы күрше егетеннән, авылдан — колхозда тракторчы булып калган яшьлек дустыннан.

Билгеле, иң беренче сөенә-сөенә Рәйсәнә хатын ачты. Ләкин... андагы хәбәр егетнең башына күсәк белән китереп органнан ким тәэсир итмәде. «Габделнур, исәнме! Син мине кибеттә күреп, озата баргач, бераз аптырап та калгансыңдыр әле. Минем бик тиз ризалашуыма диюем. Җилбәзәк кыз икән дип тә уйлагансыңдыр. Ә мин сине таныдым. Шуңа ризалаштым. Хәтерлисеңме, кыш көне Горький клубында район үзешчәннәренең смотр конкурсы булды. Ул көннәрдә мин Әлмәттә идем, каникул вакыты. Сез Чупайдан килдегез. Хордагы кызларыгыз ак алъяпкычтан иде. Хәтерлисеңме?.. Ә син, баянда ялгыз уйнап, беренче урынны алдың. Ә минем кече абый икенче булып калды. Минем шул чакта сиңа ничек ачуым чыкканны белсәң икән?! Менә мин сине шуннан хәтерләп калдым. Ә инде очрашкач таныдым да, ачуым сүрелде... Мин сиңа бу хакта әйтмәгән идем. Читенсендем... Ачуым килсә дә, үзең ошаган идең... Син бик әйбәт егет. Ләкин... Гафу ит син мине. Чөнки мин соңгы вакытта бик күп уйландым, озак баш ваттым һәм сине аңладым: син музыкага тартыласың, рәсем ясыйсың, нечкә күңелле, хисчән егет. Бәлки әле укырсың. Син әле үз юлыңны табып бетермәгән сыман тоелдың. Унтугыз яшь нәрсә ул?! Бигрәк тә егетләр өчен. Ә мин җир кешесе. Мин инде бүтән укымыйм. Кияүгә чыгып, бәби табып, балалар үстереп, табигать алдындагы вазифамны үтәп, иремә әйбәт кенә хатын булачакмын. Мине әни шулай тәрбияләде. Шәһәр кызы булсам да, мин авылча үстем. Шуңа күрә миңа ачу саклама, каргама да, каргышы башыңа төшә күрмәсен. Минем әни гел шулай ди. Матур гына аерылышыйк. Хуш. Мин сине онытмам. Ир малай тапсам, синең исемеңне кушармын... Габделнур, гафу ит. Менә сине көтә алмадым. Мин кияүгә чыгам. Кабат миңа хат язма... Хуш!..»

Егет хатны бер укыды, ике... Ләкин андагы җөмләләрнең эчтәлеге үзгәрмәде, хәрефләр урыннарын алыштырмады. Ачык һәм конкрет язылган сүзләр тезмәсе бераздан гына яшь егетнең түнгән миенә барып җитте. Ул аптырап калды. Ничек була соң әле бу? Бер ел гына үтте ләбаса... Аның китүенә бу айда нәкъ бер ел тулды. Бүтәннәр көтә иде бит, өчәр ел...

Заранка — зирәк акыллы егет, дустының коелып төшүен сизде. Янына килеп утырды. Чөнки хат алу гелән генә сөенечле хәбәрләр җиткерми, һәркемнең өе, әти-әнисе, туганнары — үз мохите бар, хәвефле хәлләр дә килеп ирешүе ихтимал.

— Нәрсә бар? — дип сорады ул.

Аның да гел елмаеп диярлек торган кызгылт йөзенә борчу чыккан иде.

Габделнур аңа конверты белән хат сузды.

— Менә, укы, — диде ул, битараф караш, төшенке күңел белән, һәм, дустының йөзендә аптырау галәмәте чагылганны күреп, конвертны кире алды. — Гафу, син бит татарча белмисең... Кыз кияүгә чыккан.

— Ничек?

— Үзем дә шуңа аптырыйм.

Солдатларның бер-береннән сере булмый. Заранка Рәйсәнә турында белә иде. Дустының альбомында кызның карточкасын беренче тапкыр күргәч:

— О, гражи мергайте! — дип сокланган иде. (Аларча «чибәр кыз» дигәнне аңлата.)

Бүген Заранка булдыра алганча Габделнурны юатырга, аның хәленә керергә тырышты.

Ике катлы бинаның өскесендә казарма, аста янгын сүндерү машиналары гаражы, расчет өчен кечкенә генә ял бүлмәсе, мастерской кебегрәк урын, җиһазлар куелган бүлмәләр иде.

Бераздан Габделнур, урындыктан торып тәрәзә янына килде. Шәрәләнеп калган шыксыз агачларга карады. Аларның өске ботаклары һавага сузылган ялварулы бихисап кулларны, бармакларны хәтерләтте. Алар арасында ике саескан нәрсәдер бүлешә алмыйча даулаша — ботактан ботакка сикерешә... «Боларга да дөнья тар, нидер җитми...»

Егет көне буена боегып йөрде.

Төштән соң, фотоальбомын ачып, озак кына Рәйсәнәнең сурәтенә карап утырды. Гүя аның йөзен хәтерендә калдырырга теләгәндәй, аскы ирене белән ияге арасындагы үзенә килешеп торган кечкенә миңенә хәтле игътибар итте. Һәр чалымы таныш. Егет хәтта рәсем артындагы язуына кадәр ятлап бетергән иде инде: «...Мин бәхетле шундый өзелеп-өзелеп юксынырлык кешем булганда». Әйе, Габделнур да бәхетле иде. Менә бүген ул бәхет юкка чыкты. Гүя ул сокланып туймаган аяз күкне кара болыт басты, гүя җылы суында коенган якты күл

өстен салкын боз каплады. Саклап кына куенында йөрткән кадерле әйберсен югалтты ул... «Ярар, башны ташка орып булмый! — диде егет, кисәк кенә, һәм карточканы альбомнан куптарып алды да ачу белән тураклап атты. — Хуш! Син дә... Хуш!!»

Ләкин күңел түреңә кереп урнашкан гүзәл фәрештәне тиз генә куалап җибәреп, исемен йөрәгеңнән сызып ташлап буламы соң?!

Кичке якта ул дежурда иде. Кабул итү беткәннән соң урамга чыкты. Гараж каршында туктады. Башы ничектер миңгерәүләнеп калды бугай. Кая барырга дигән сыман алга карады. (Гәрчә дежурствоны ташлап беркая да китмәсен белсә дә.) Анда урман, объект. Урманы калын, куе, чын карурман. Юаныч табарга теләгәндәй бик озак аның биек агачларына карап торды солдат. Эченә кереп китсәң иде шул карурманның, йөрсәң иде адашып, кайгы-хәсрәтеңне басып, җырлап... «Карурманга кермәс идем, карурманда атларым; кычкырып җырламас идем, бик ямансу чакларым...» Габделнур, тиктомал монда чыгып басуына хәйран калгандай, як-ягына каранды, карашын өскә юнәлтте. Күк йөзендә сирәк болытлар йөзә. Кояш баеп килә. Болытларга гүя ут капкан — барысы да кызгылт төскә манылган, ә астарак бөтен көнбатыш тараф кып-кызыл — болытлары да, арасындагы ачык урыннар да... Кояш үзе күренми инде, ә кызгылт ялкыны ярты күкне, бөтен әтрафны чолгап алган... Гүяки ялкын капкан бөтен дөньясына... Аны ничек сүндерәсе булыр иде, бу кадәр ялкынны йөгәнләрдәй көч-куәт юк бит әлегә кешедә... Аның да йөрәге мөлдерәмә сагыш, эче тулы ялкын... Ничек сүндерергә? Ничек дөртләп кабынып янып үлмәскә? Ничек үзендә сыгылып төшмәслек көч-дәрман табарга? Башны алып кая олагырга? Аһ-зарыңны кемгә сөйләргә дә тубалдай газиз башкаеңны кемнең тезенә куярга? Кем басар синең тау дәрьясыдай йөрәк ярсуыңны?.. Кайгысын эченә йотып күпме йөри алыр ул?..

Икенче көнне, увольнениегә чыккач, Заранка аны мәҗбүри рәвештә диярлек клубка алып китте.

— Әйдә клубка барабыз.

— Нәрсәгә?

— Анда бүген танцы.

— Иң әйбәте — кибеткә. Үзем сыйлыйм.

Дустының нинди хәлдә икәнен яхшы тойган Заранка каты торды. Чөнки белә: су тулы савытны ут өстендә озак тотсаң, ул кайнап чыга һәм түгелә... әгәр парын чыгармасаң.

— Юк. Бүген түгел.

— Йөргән кызың бармы әллә?

— Әйе. Сиңа да булыр. Башыңны югары тот, сыгылып төшмә. Бәла аяк турайта.

Хәрби шәһәрчекнең зур клубы шыгрым тулы. Халык чуар: тоташ кара киемле булсалар да коры җирдә хезмәт итәргә мәҗбүр, кайчандыр күбесе хәрби диңгез училищеларын тәмамлаган көяз офицерлар һәм төрле сәбәпләр аркасында үзләре теләп хәрби хезмәтне дәвам итүче мичманнар, яшькелт төстәге армия формасы кигән лейтенантлар һәм старшиналар, язмышларын шулар белән бәйләгән яшь хатыннар, матрослар һәм солдатлар, яңа өйләнешкән парлар, гражданский киемле кыз-кыркын һәм егет-җилән. Күбесе оркестр уйнаган көйгә зур, иркен фойе уртасында бөтерелә. Кайберләре дивар тирәли яисә ишек катында басып тора, утырганнар да бар.

Күп тә үтмәде, ишектән кергән ике кыз туп-туры Габделнурлар янына килеп басты. Исәнләштеләр. Заранка кызларны дусты белән таныштырды һәм бераздан кечерәк буйлысын танцыга алып кереп тә китте. Габделнурга, башын чак кына ия төшеп, икенчесен — калкурак һәм тазарак гәүдәлесен биергә чакырудан гайре чара калмады.

Кызның биюе ярыйсы гына, сүзгә дә кесәгә керә торган түгел — теле телгә йокмый, кыюлыгы да җитәрлек — вальсның беренче хәрәкәтеннән үк егеткә сарылды.

Уртак сүзләр бик тиз табылды. Кызга егет ошады. Берәр сәгать биегәч, як-ягына каранды да, үрелебрәк, Габделнурның колагына пышылдады:

— Качабызмы?

— Кая?

— Миңа. Мин бүген үзем генә.

Егет артык сорау да бирмәде, кыстатып та тормады. Юкса, ялындыра башласаң, бу чибәр нәрсә, аны калдырып, бүтән белән китәргә дә күп сорамас. Ни булса, шул булыр, тәвәккәлләргә кирәк. Дөньясы болайга киткәч, нигә әле ул намус саклап ятарга тиеш. Яшьлек бер генә килә ләбаса. Ул бит басса бакыр изәрдәй таза егет, төс-кыяфәте дә кешедән ким-хур түгел... Ир-атка, җиккәндә ат куркып китмәслек булса ярый инде, дип әйтсәләр дә, кыз-кыркын кемне сайларга икәнен үзе белә, теләсә кемгә килеп сүз катмый... Моңарчы Габделнур үзен, һәрхәлдә, маймылдан чүт кенә кайтышрак саный иде — насыйбы чыгар... Аңа да табылыр... Менә инде берсе табылды да...

Биш катлы йортка җитәрәк, кыз фатир номерын әйтте һәм:

— Мин алданрак керәм, — дип, кулын егетнең биленнән алып, җәлт кенә култык астыннан чыгып китеп тә барды.

Кыз аны коридорда каршылады.

— Шаулама, әкрен генә кер, — диде ул, аның колагына авызын якын ук куеп шыпырт кына. — Кызымны уятырсың.

Габделнур ачык ишектән килеп керүгә үк, ут та алдырып тормыйча, Зоя аның шинелен, фуражкасын һәм итекләрен салдырып, бүлмәгә уздырды. Сабырсызланып солдатның корычтай таза гәүдәсен кочарга, иреннәреннән үбәргә кереште. Икесе дә ашык-пошык чишенгәч, караваткa ятты һәм бераздан, исерек кешедәй сөйләнә-сөйләнә, тукта, юләркәй, анда түгел, ашыкма, менә шулай, дия-дия, егетне «тирбәтергә» кереште...

— Син беренче тапкырмы әллә? — дип сорады ул, хәлсезләнгән гәүдәсен ятакта таратып ятканда.

— Әйе, — диде үзен ничектер бушанып калган хәлдә сизеп, чалкан яткан Габделнур, чак ишетелерлек итеп читенсенеп кенә.

Шуннан хатын, калкынып, шатлыгыннан елмаеп, дымлы куллары белән оялчан егетне янә чорнады, көйдереп алырдай кайнар иреннәре белән үбәргә кереште.

— Ягымлым минем... Сөеклем... Саф егетем минем... Мин сине үзем барысына өйрәтермен...

## 14

Яңа урында Габделнур солдатлар белән бик тиз уртак тел тапты.

Билгеле, аны да беренче көннәрне сынап карадылар. Отделение командиры бик җитди кыяфәт белән аңа бер бит кәгазь бирде.

— Ефрейтор Гаделҗанов, менә шушыны матур итеп, үзегезнең фамилиягезне куеп, күчереп язарга кирәк.

— Есть.

— Тик башта укып чыгыгыз.

Бу — беренче отделение солдатының шәхси социалистик йөкләмәсе иде. Габделнур укый башлады һәм өченче пунктта төртелеп калды. Чөнки анда «узган ел өч янгын сүндергән идем, быел бишне сүндерергә йөкләмә алам» диелгән.

— Иптәш сержант, монда хата киткән, — диде ул. — Янгынны алдан белеп булмый. Формулировкасын үзгәртергә кирәк.

Боларны сырып алган солдатлар бердәй көлеп җибәрделәр. Шунда гына егет моның шаяру икәненә төшенде.

Сержант әле һаман «җитди чырайлы» иде. Ул солдатларга карап күз кысып алды да шыттыруын дәвам итте.

— Син, Гаделҗанов, бер дә кайгырма, янган әйбер череми ул, — диде. — Янгын чыгып, сүндерә алмыйча калганда да исең китмәсен, иптәш командир, янгын сүнделде, йорт янып бетте, дип чатнатып әйтеп бир.

— Аңлашылды, — диде Габделнур, елмаеп. — Шулай итәрмен.

— Менә, акыллы кешегә бер әйтүдә үк барып җитә...

Монда ике рәтле гармун — хромка бар иде. Габделнур бер дә иренмичә еш кына аны кулына алды, урыс көйләрен дә сайрата башлады. Литва егетләреннән «Ожалис» («Кәҗә бәтие») дигән шаян дәртле бию көен отып алып «сиптерергә» өйрәнде. Бер солдатның фотоаппараты бар икән. Техникумда фотодело дигән фән кергәнлектән, аның иске «Фотокор» аппараты белән эш иткәне бар иде, аңа пленка, ачыгайткыч, ныгыткыч кебек нәрсәләр дә таныш һәм ни рәвешле сурәткә төшерергә кирәген дә яхшы чамалый иде. Монысы да ярдәм итте, ахры. Аннары егетне стена газетасы мөхәррире итеп куйдылар. Газетаның беренче саны ук ярыйсы чыкты. Бусы командирларга ошады. Әгәр син хөрәсән ялкавы булмасаң, һәр җирдә яраталар... Хезмәттән зарланмады, ни кушсалар да, авырсынмыйча башкарды. Хәтта арттырып җибәргән чаклары да булды: «камыт»ның олысын киярггә, «бүрәнә»нең авыр башын күтәрергә тырышты. Әлбәттә, болар иптәшләре тарафыннан бәяләнмичә калмады. Биредә халык санаулы гына, һәрчак сугышчан әзерлектә торырга кирәк, ул-бу була калса, берберeңә ярдәмгә килү кадәресе дә бар бит әле. Шуңа күрә солдатлар һәм сержантлар дустанә яши иде.

Гадәттәгечә, егетләр төрлесе төрле төбәктән хезмәткә алынган, холык-фигыльләре дә аермалы, белем дәрәҗәсе һәм тормышны танып белүләре дә үзгә.

Постнов фамилияле егет, мәсәлән, Мәскәүнең үзеннән. Башка егетләр белмәгән күп нәрсәләр аңа таныш, бөтен илгә билгеле бер атаклы футболчы белән күршеләр икән.

— Ул институтта ун ел укый инде, — дип көлдерде. — Аягы ашаткач, баш кирәк түгел бит.

Ләкин Постновта кәпәренү дигән нәрсәнең әсәре дә сизелми. Югыйсә үзе беренче разрядлы хоккейчы, капкада торган. Шулай да армиядән кыякламаган. Кызык егет ул. Үзе яшен ташыдай атылган резин шайбаны тота алучы, курку белмәс капкачы, йөзендә ничәмә-ничә җөй, ә үзе тычканнан да курка. Табигать кочагында сирәк була торган чын шәһәр малае.

Бервакыт дежур торганда, Постнов, черем итеп алырга дип, ян бүлмәгә кереп ятты. Ул гадәттә кулын баш астына куеп, уң ягына ята һәм еш кына: «Король — чалкан, саран — йөзтүбән, ә акыл иясе яны белән ята», — дип әйтергә ярата иде. Бу юлы да шулай яткан. Дусты-якташы Лавров, теге йоклап киткәч, җиңелчә генә аның җилкәсенә кагылды.

— Слава, тартырга бир әле.

Янгын командасында хезмәт итүчеләрнең йокысы сак була бит, Постнов шундук сикереп торды.

— Нәрсә?

Лавров гозерен кабатлады:

— Тартырга бир әле.

Постнов кулын галифе кесәсенә тыкты һәм... шул секундта ук кире чыгарды.
— Володя, тычканны ал! — дип кычкырып җибәрде ул.
Тегесе башын юләргә салды.
— Нәрсә? Нинди тычкан?
Кулын күтәргән килеш кырын яткан Постнов еларга җитешеп ялына башлады:
— Зинһар, ал инде! Кабы белән бирәм папиросны!
Кай арада Лавров тычканын тоткан, кай арада дустының кесәсенә салып өлгергән, беркем сизмәгән...
Постнов — бик эрудицияле егет. Спорттан тыш музыкага да әвәслеге бар: гитара кылларын чиртә. Параллель рәвештә музыка мәктәбендә укыган булса да, монда ул җитди музыка уйнамый, сөйләшкәндә дә композиторлар, музыкантлар тормышының кызыклы вакыйгаларын, көлкеле ситуацияләрен генә искә төшерә. Чөнки урыны башка, кешеләре бүтән. Беркөнне, мәсәлән, иҗат әһелләренең аралашуы хакында сүз иярә сүз чыгып, ул болай дип сөйләп китте:
— Пришел Римский-Корсаков к Бетховену в гости. Тот начал его угощать Мясковским, Хренниковым, Сметаной и Чайковским. Вдруг у Римского-Корсакова получилось Пуччини. Он выбежал на Дворжак, шлеп-шлеп по Глинке. Сорвал Лист для Шопена, подумал, что будет Гуно, а получилось Бах и образовалась Могучая Кучка.
Әлбәттә, моны аңлар өчен классик музыка өлкәсеннән азмы-күпме хәбәрдар булырга кирәк иде. Техникумда нота грамотасын үзләштергән, сольфеджио фәнен өйрәнгән, баян буенча дәресләр алган Габделнур беренче җөмләдән үк төшенде сүзнең кемнәр турында баруына, рәхәтләнеп көлде. Һәм бу Постновның игътибарыннан читтә калмады. Шуннан соң ул яңа солдатны үз тиңе күреп йөри башлады.
Алар еш кына гәпләшәләр, яшәеш, музыкага карата уйфикерләре белән уртаклашалар.
— Музыка өч компоненттан тора: ритм — йөрәк тибеше, тавыш — күк күкрәү һәм җил, хәрәкәт — җиһанда бар нәрсә хәрәкәттә, — диде Постнов берчакны. — Бу — борынгы заманнардан ук мәгълүм әйберләр, кешеләр шуларга колак салганнар.
Бәлки, моны берәр акыл иясе әйткәндер, һәрхәлдә, солдат үзе уйлап чыгармагандыр. Ләкин ничек кенә булмасын, Габделнур өчен дә Постнов рухына якын әңгәмәдәш иде. Чөнки ул да үзен табигать белән бербөтен итеп тоя, аның һәр мизгеленә, үзгәрешенә колак сала, аңа мөкиббән китеп яши.
Кызык инде ул хәрби тормыш. Юктан гына да мәзәк табып, уен-көлке белән үткәрергә ярата аны солдат халкы, үз күңелен үзе күрергә, шукланырга тырыша.
Беркөнне старшина казармага кереп солдатлар белән сөйләшеп торганда, Габделнур үзе белән бер чама буйлы Лавров артына яшеренде. Аннан ике теш арасыннан һава сызгыртып чыгара башлады. Ул аны өзек-өзек чыгара, тавыш исә сызгыруга түгел, ә нәкъ мәче мияулаганга тартым иде.
— Нәрсә бар монда? — дип, артына борылды старшина. — Песи баласымы?
— Кайда, кайда? — диештеләр солдатлар, юри белмәмешкә сабышып.
Шуннан старшина ишек төбеннән түргә таба китте. Барысы да аның артыннан иярделәр. «Песи баласы» да алардан калмады. Старшина, иелеп, карават асларын карый, аптырагач тумбочкаларны ача — песи юк. Ә тавыш бар.
Ахырда ул:
— Да ну сезне, үзегез тотыгыз, — дип, кул селтәп, казармадан чыгып китте.
Постнов белән Лавров бер-берсенә якташ дип йөрсәләр дә, соңгысы башкала тирәсендәге Люберцы шәһәреннән. Армиягә хәтле шофер булып эшләгән, өйләнгән. Хатыны айга бер килеп китә, ирен сагынган яшь кәләшкә ерак җир түгел бит. Лавров хәзер тәртипле, акыл утырткан ир. Ләкин егет чакта бик шук булган. Ул үзләренең «батырлыкларын», һәрнәрсәдән кызык табып йөрүләрен рәхәтләнеп искә төшерә. Дөрес, аларның шуклыгы кайчагында тупасрак килеп чыккан икән.
— Бервакыт, төнге сәгать уникеләрдер, егетләр белән урамнан барабыз. Күрәбез, ялгызы гына бер кыз каршыга килә. Без моны туктаттык, уратып алдык, анадан тума чишенергә мәҗбүр иттек. Ләкин үзенә тимәдек. Киемнәрен кулына тоттырып җибәрдек...
Булгандыр, чөнки аның беренче көннәрне старшина белән дә бик батыр сөйләшкәнен әле дә искә алалар.
Лавров нидер эшләгән дә, старшина моны сүгә икән. Бу җавапсыз калмаган. Җитмәсә, ул тотлыгыбрак сөйләшә, дулкынланган чагында тотлыгуы тагын да көчәя төшә.
— Мин түгел, дисең, ә үзең әнә тотлыга да башладың, — ди моның ул гадәтен белмәгән старшина.
— Син нәрсә, к-кәҗә тәкәсе, х-хәзер берне с-сыйпыйм! С-син нәрсә м-мине үртисең!
Старшинаның күзе шар була. Мондый дорфалыкны беренче күрүе. Ничек? Яшь солдат, шундый оятсыз рәвештә каршы әйтергә батырчылык итә...
Сабыр холыклы Постнов арага керә.
— Иптәш старшина, ул тотлыгып сөйләшә, тумыштан шулай.
...Ябык чырайлы, уртача буйлы, эре сөякле Епифанов Сухуми шәһәреннән, кызу канлы егет, чөнки әтисе — урыс, әнисе — әрмән кызы. Ул, берни булса:
— Зарыжу! — ди.

Ләкин моны шаяртып кына әйтә. Кешегә кул күтәрә торган егет түгел. Аннан ул Тбилисиның тимер юл вокзалында поезд китүне ничек игълан итүләрен әйтеп күрсәтә. Бигрәк тә «п» хәрефенә басым ясый.

— Поезд номыр пыятдесят пыят отходит в Советский Союз!

Әлбәттә, ул заман өчен көлке, мәзәгрәк һәм, әйтергә кирәк, куркынычрак яңгыраса да, күрәсең, бәлки, берничә мәртәбә булгандыр андый игълан.

Шофер вазифасын башкаручы Шота Чхиквадзе буйга арада иң тәбәнәге, ләкин аның ирен өстендә тар гына чем-кара мыегы бар. Ул еш кына авыз эчендә «ботка пешереп», мыгырданып йөри. Ләкин кеше аңларлык түгел. Габделнур аны берәр җыр көйли дип уйлаган иде. Баксаң, Шота дога укый икән. Иң гаҗәбе дога укуында түгел, ә аның Габделнурга әбиләре һәм әнисе өйрәткәнчә булуында иде.

Ул болай ачыкланды.

Сүз иярә сүз чыгып, берчакны дин турында сөйләшеп киттеләр. Әлбәттә, барысы да пионер һәм комсомол сафларында тәрбияләнгән булганлыктан, күзләрен үк капламаса да, дин сөреме әби-бабаларыннан, ата-аналарыннан күбесенә күпмедер микъдарда йогып калган. Кечкенәдән өйрәткән нык истә кала бит ул.

Урыс егетләренең кайберләре ничек «чебен куу»ны гына түгел, аерым догаларны да беләләр икән. Ләкин моны уен-көлкегә әйләндерделәр.

— Ә чукынганда нинди дога укыйсыз? — дип сорады Габделнур.

Лавров, авызын ерып:

— Әтигә, әнигә, үземә, хатынга... — дип төртенеп күрсәтте.

Көлеш тәмам булгач, Габделнур:

— Мин дә сезнеңчә беләм, — диде.

— Ничек?

Һәм ул керәшен егетләреннән — Алабугада бергә укыган курсташларыннан отып калган такмазаны әйтте:

— Менә тыңлагыз: Господи, помилуй, урыс мине танымый, таныса да сукмый, үтергәнче тукмый...

Үзе үк тәрҗемә итеп биргәч, егетләр көлештеләр.

Постнов (комсомол оешмасы секретаре, аз-маз тарихны белгән укымышлы егет), шаяртып:

— Шул кирәк сезгә, — диде.

Тагын көлештеләр.

Горький шәһәре егете, шофер Тресков:

— Ә татарлар ничек гыйбадәт кыла? — дигән сорау бирде.

Габделнур бераз уйланып торгач кына җавап кайтарды:

— Ул бөтен мөселманнар өчен бер. Чөнки гыйбадәт кылу, догалар — гарәпчә.

— Укып күрсәт әле, — дип ялындылар егетләр.

— Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим...

Ләкин Чхиквадзе аны бүлдерде:

— Башы алай түгел. Менә болай башларга кирәк: әгүзе биллаһи...

Егет, башлаган көйгә, «Әлхәм»не бер ялгышсыз укып чыкты. Габделнур гаҗәпләнде.

— Шота, син боларны каян беләсең?

— Ә мин мөселман.

Постнов та аптырады.

— Ничек? Грузиннар, минемчә, православныйлар. Безнең күршедә грузин гаиләсе бар иде. Күрсәтеп гыйбадәт кылмасалар да, сизә идем. Аннары, Грузиядә чиркәүләр генә шикелле.

Чхиквадзе:

— Мин бит Аджариядән, — диде. — Безнең авыл Төркия чигенә урнашкан. Тау башына менсәң, төрек авылы күренеп тора.

Утыра торгач, бәхәс китте: ни өчен христианнарга эчәргә ярый, ә ислам динендәгеләргә юк?

Постнов мәзәк тә сөйләп алды.

— Поптан, батюшка, күпме эчә аласың, дип сорыйлар икән. Батюшка әйткән: шәп кабымлык белән, әйбәт дуслар янында, аракысы кеше хисабына булса — чиксез-чамасыз.

— Бездә әле поплар турында болай да әйтәләр, — диде Тресков һәм, Максим Горькийның якташы буларак, «о» хәрефенә басым ясап сөйли башлады: — Обозревая окрестности Онежского озера, отец Онофрий обнаружил обнаженную Ольгу. Отец Онофрий оговорил: Ольга, отдайся, озолочу, обую, обмундирую. Ольга отдалась. Отец Онофрий оставил обманутую Ольгу около Онежского озера.

Габделнур үз сүзен әйтте:

— Ә бездә муллаларга гына түгел, бөтенләй эчәргә ярамаган...

Бу сөйләшүгә Заранка да, аның якташлары да кушылмадылар, фәкать тыңлап кына утырдылар. Динне уен-көлкегә әйләндерү, ул хакта болай җәелеп сөйләшү аларга бик үк ошап җитмәде булса кирәк. Андый изге нәрсәләр күбрәк кешенең күңелендә була, тышка бәреп чыкмый. Аны һәркем үзенчә аңлый, үзенчә ышана һәм бу хакта теләсә ничек тел чарлап, чүбек чәйнәп утыру кирәк тә түгел дип уйлаганнардыр, мөгаен.

...Йөз метрга йөгерүдә иң яхшы күрсәткечкә ия булган Габделнурны өлкән лейтенант Лукьянчук ике атнадан ярышка да куйды.

Ярославль белән Костромадан һәм Ростов (Великий), Углич, Тутаев, Рыбинск, Нерехта кебек якын-тирәдәге ваграк шәһәрләрдән дә берничә команда җыелды.

Пожарно-прикладной дип аталган бу спорт төрен янгынчылар үзара шаяртып «ат спорты» дип йөртәләр. Кирза итек кигән егетләрнең лап-лоп йөгерүен атлар чабуы белән чагыштырды микән берәре, әллә башка сәбәпме, кыскасы, читтән карап торучыга бик җиңел сыман тоелса да, ярышка әзерлек чорында аттан ким тир түкми егетләр.

Җитезлек, осталык белән генә түгел, монда әле ярышның иң соңгы этабында тәвәккәл һәм курку белмәс йөрәкле булуың да ярап куя. Дүртпочмаклы, сай, зур гына тимер савытка — противеньгә — су кушып бензин салынган. Ярыш вакытында аңа ут төртәләр һәм спортчы-янгынчы шуны сүндерергә тиеш.

Габделнур башта күнегүләрдә командир өйрәткәнчә эшләргә исәп тотса да, никтер ул уеннан кайтып, савытның эченә үк керергә ниятләде, ут сүндергечне як-якка боргалап, тиз генә ялкынны ялмап алмакчы булды. Бит-кул пешү дә, киеменә ут кабу ихтималы да аны куркытмады, фәкать тизрәк сүндерсен генә. Спорт ярышларында була торган азарт биләп алды егетне.

Ул, йөгереп килгән уңайга савыт эченә кереп, ут сүндергечне як-якка боргалый башлауга, майор погоннары таккан баш судья аты-юлы белән акырып җибәрде:

— Выйди... немедленно! Синең аркада төрмәдә утырасым килми! Чык!

Габделнур берни дәшми савыт читенә чыгып басты һәм, иелә төшеп, ут сүндерүен дәвам итте. Майор әле һаман тынычлана алмый иде.

— Син нәрсә, егет, янып үләсең килдеме әллә?! Кабат алай эшләмә!

— Алай тизрәк, — диде Габделнур, аңа карамыйча гына.

— Ә шунда янып китсәң?!

«Мин бит агач түгел, солдат утта чыныга гына ул», — дип уйлады Габделнур.

...Ярыштан соң спортчылар янына хезмәттәшләре җыелды.

— Ну син майорны астына җибәрттең.

— Ул хаклы, кыю кеше икәнсең, сак кеше дә була бел, — диде өлкән лейтенант Лукьянчук, ләкин артык орышмады, чөнки бүгенге ярыштан бик канәгать калган иде. — Озакламый Костромага барабыз. Ныклап әзерләнегез.

Габделнур моңа бик шатланды. Бераз сөйләшеп торгач, казармага юл алдылар.

...Костромада шулай ук сынатмадылар. Ярыштан соң шәһәр күрү дә насыйп булды. Ул — таулар-калкулыклар өстенә салынган Идел буендагы борынгы кала. Романовлар династиясенең патшалык итә башлавы да шушы тирә белән бәйле: урыс патшасына хезмәткә күчкән бер татар морзасы нигез салган Ипатьев монастыре, Домнино авылы (Романовлар гаиләсенең нәселдән килгән утары), Иван Сусанинның Михаилны поляклардан коткарып калуы, соңгысының тәхеткә утырырга ризалык бирүе...

Шулай да иң истә калганы ярыш та, шәһәр дә түгел, ә бу шәһәр командасыннан бер егет белән танышу булды. Дөресрәге, сержант үзе килеп Габделнур белән күреште. Ул Кострома каласының Татар бистәсеннән булып чыкты. (Иделнең сул ярында шундый урын бар икән.) Ефрейтор Гаделҗановны кунакка чакырды егет, адресын да калдырды.

Габделнур, рәхмәт әйтеп, аның чакыруын кабул итсә дә, аларга барып чыга алмаячагын яхшы белә иде. Шулай да әллә кайдагы, кем әйтмешли, җәһәннәмдәге бер ерак калада үз кешеңне күрү, җитмәсә, үз телеңдә (сержантның, вата-җимерә булса да, бик тырышып ана телендә аралашасы килә иде) бер-ике авыз сүз сөйләшү бик рәхәт вә куаныч иде.

...Габделнурларга объектта янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең төгәл үтәлешен тикшерү вазифасы да йөкләнгән иде. Беркөнне алар, ике солдат, икенче проходнойдан (әле өченчесе дә бар, ләкин аның аша фәкать офицерлар гына керә ала иде) эчкә узып, корал һәм запас җиһазлар саклanучы складларны карарга киттеләр.

Ел фасылларының һәрберсенең үз матурлыгы бар. Маңгай күзенә күңел күзен дә кушып баксаң, кышның да үз гүзәллеген һәрдаим күрергә була. Менә бүген бөтен тарафны акка чорнап ябалак кар ява. Эре кар бөртекләре каяндыр өстән — ак томан эченнән килеп чыгалар һәм җиргә якынлашалар да «төшик микән, юк микән» дигән шикелле икеләнеп торалар. Аннары, чак кына җил исеп китсә, «өлгерербез әле, бераз гына тирбәлеп-уйнап калыйк» дигән сыман, әрле-бирле тулгана башлыйлар. Кайберләре тәбәнәк чыршы-нарат ботакларына эләгеп кала, кайсылары ак юрганны тагын да күпертү өчен җиргә түшәлә. Ә кайсыбер әрсезрәкләре-наяннары җиңел адымнар белән кар шыгырдатып атлап баручы солдат абыйларының колакчыннарын күтәреп бәйләгән зәңгәрсу мехлы бүрекләренә, киң каеш белән буган, көрән төстәге озын шинельләренә килеп куналар...

Габделнур үзе дусты Заранка белән гәп кора, ә үзе шушы гүзәл хозурлыкка сокланып, бер рәхәтлек тоеп атлый. Ул, туган авылына кайткач, шулай түшәп-түшәп кар яуганны карарга ярата. Бигрәк тә төнлә. Чөнки иртүк торып кар көрисе була. Үз йортының чын хуҗасы беркайчан да капка төбендә, ишегалдында кар тотмый. Бу ата-бабадан калган гадәт. Гәрчә анда даими яшәмәсә дә, кайткач, егет иренеп тормый, ул шөгыльне яратып башкара.

Менә монда да чын хуҗалар бар икән: киң юл да, тар сукмаклар — аллеялар да чип-чиста. Хәер, биредә — хәрби объектта — шунсыз булмый да. Урамда гына түгел, цехларда, складларда да һәрчак идеаль тәртип саклана. Бу — катгый рәвештә үтәлергә тиешле тормыш таләбе.

Бер бинага кергәч, әле яңа гына агач әрҗә эченнән чыгарылган, өстәл зурлыгы бер җиһазга тап булдылар. Корпусына бәләкәй генә калай кисәге дә ябыштырылган. Язуны укыгач, Габделнурның күз төпләре дымланды.

— Якташ, саумы?! — диде ул, үзе дә сизмәстән җиһазның салкын тимер корпусын сыйпап.

Чөнки аңа «Казан компрессорлар заводы» дип язылган иде.

— Нәрсә бар? — дип сорады Заранка, иптәшенең туктап калуын күргәч.

Язуны укыгач, ул дустының халәтен аңлады, гадәтенчә елмаеп читкәрәк китеп торды: «Безнең бабайлар белми әйтмәгәннәр шул: туган якның төтене дә чит илдәге уттан җылы».

Янә бер корпуска керделәр. Монысында озын, төз бүрәнәләр кебек биш-алты метрлы, юан торпедалар тимер киштәләргә тезеп куелган. Киноларда күргәнчә, торпеда катерларыннан суга җибәрелгәч, зур тизлек белән барып дошман корабларын шартлатучы, аларның көлен күккә очыручы, диңгезгә батыручы бу дәһшәтле кораллар янында басып торганда, егет әйтеп бетергесез зур дулкынлану кичерде. Никадәр куәтле аның иле-ватаны, нихәтле көч тупланган әле алар саклаган объектта гына да...

Хәтерендә, узган җәй, өйрәнүләр вакытында, танкодромдагы гайрәтле машиналарга күрсәтеп, Габделнур рота командирына сорау бирде: «Иптәш капитан, әгәр Бөек Ватан сугышы алдыннан бездә бу танклар эшләп чыгарылган булса, сугыш күпмегә сузылган булыр иде?» Капитан авыр сулап куйды, аннары күзендә очкыннар кабынды: «Әгәр кырык беренче елны болар булса, Гитлер сугыш башларга җөрьәт итмәс иде».

«Әйе, хәзер илнең саклану чаралары көчле, без беркемнән курыкмыйбыз. Шуңа күрә башка илләр дә безне тиң күреп сөйләшә» дип уйлады Габделнур, горурланып.

...Хәрби тормыш үз агымына куелган һәм җай гына дәвам итә. Клубта танцы, төрле кичәләр оештыралар, кино күрсәтәләр, батыр фронтовиклар, часть ветераннары белән очрашулар була, Мәскәүдән танылган җырчылар килгәли. Бер мәртәбә Ярославльдән килеп спектакль куеп киттеләр. Ул атаклы Волков исемендәге театр иде.

Ярославль дигәннән, Габделнурның яңа танышы шунда эшли икән, ял саен булмаса да, ике атнага бер кайта. Алар клубта, танцыда очрашалар. Берәр сәгать фойеда биегәч, хатын аны йә үзләренә (әгәр аулак булса), йә берәр иптәш хатынына алып китә. Ул тәки сүзендә торды: яшь егет шактый тәҗрибә туплады...

Габделнур тагын бер спорт секциясенә — самбо көрәшенә дә йөри башлады. Тренер ике метрлы, үзе нәзек, кызлар шикелле зифа буйлы капитан-лейтенант иде.

— Моңа самбо белән түгел, баскетбол яки волейбол белән шөгыльләнергә кирәк булган, — диде Габделнур, беренче мәртәбә аны күргәч.

— Спорт мастеры ул, — диде моңа каршы каравыл ротасыннан килгән бер егет. — Монда бер особист бар, ул да спорт мастеры. Менә көрәшеп күрсәтәләр.

Өч ай йөргәч, әлеге егетнең тренировка вакытында кабыргасы сынды. Ләкин аңа карап кына берсе дә йөрүдән туктамаган иде, кызганыч, капитан-лейтенантны бүтән урынга күчергәч кенә секция таркалды.

Егетләргә сирәк-мирәк кенә булса да посылка килгәли. Аны алган көн бәйрәмгә әйләнә. Шота Чхиквадзега адресланган тартмада чача атлы эчемлек була, ә украин егете Михаил Омельченкога туганнары сало җибәргәли. (Арасында горилка да булгалый.)

Әлеге посылканы ачып, бергәләп ашап утырганда, Постнов мәзәк тә сөйләп алды:

— Поезд. Купеда хохол белән казах бара. Бераздан, ашыйсылары килеп, ризыкларын чыгаралар. Хохол, ят әйбер күреп, сорый, имеш. «Бу нәрсә?» — «Бишбармак». — «Кабып карарга бир әле». — «Мә». Аннары казах тегенең ризыгына төртеп күрсәтә: «Ә бу нәрсә?» — «Сало». — «Кабып карыйм әле». — «Ә нәрсәсен кабып карыйсың аның, сало сало инде ул», — ди хохол.

Вак-төяк чеметтереп алулар була икән, солдат аны үткәреп җибәрә. Постнов сөйләгән мәзәккә, мәсәлән, Омельченко үпкәләмәде. Михаил шаяруны кабул итә белә. Ул — шахтер, Донбасстан. Уртача буйлы, чандыр, ләкин тыгыз тәнле, сары чәчле, озын борынлы егет. Монда тагын бер шахтер бар — Патреев. Ул Ленинград өлкәсендәге Сланцы шәһәреннән, тәбәнәк, әмма таза гәүдәле, штанга белән «шаярырга» ярата. Алар икесе дә иптәшлеккә кулай эшче егетләр. Дөрес, Омельченко ярты чакрымлы ташкүмер базында эшләсә, Патреевның эш урыны сиксән-туксан метр гына тирәнлектәге сланец катламында икән. Ләкин аларның эшендә уртаклык күп, бу уртаклык сөйләмнәрендә дә чагыла. Алар авызыннан еш кына шундый сүзләр ишетә Габделнур: клеть, штрек, головка, шпур, баран, тау токымы, метан газы, тормозок, маркшейдер... Кыскасы, алар бер-берен ярты сүздән аңлый. (Шуны истә тотып булса кирәк, өлкән лейтенант Лукьянчук аларны бер расчетка янәшә куйды.) Габделнур аларның үзара сөйләшүен тыңлап утырырга ярата, сүзгә дә катыша. Чөнки кайбер терминнар аңа да таныш. Чупай таш карьерында өлкән яшьтәге маркшейдер бар иде. Уң кулының имән бармагы бөгелми, ручканы баш һәм урта бармакларына кыстырып язганда катып калган имән бармагы аның каршында утырган кешегә гел төртеп күрсәткән шикелле була иде. Аннары, Габделнурның әтисе утызынчы елларда авылдаш иргегетләр белән Донбасс шахталарына барып эшләп йөргән.

Бу хакта әйткәч, Михаил:

— Анда хәзер дә синең якташлар бик күп, — диде. — Хәтта тоташ татарлардан гына торган бригадалар да бар. Бик тырыш шахтерлар, гел макталып киләләр.

Бу сүзләрне ишетү Габделнурның күңеленә хуш килде. Ул егетләргә карьерда таш кисүен сөйли, ничек нефть чыгаруларын аңлата. Болар — һәр эшне җиренә җиткереп башкарырга, тәртип-дисциплинага өйрәнгән, бер сынык ипине урталай бүлешә торган егетләр. Болар белән һич курыкмыйча разведкага барырга була. Һөнәрләре — династия буенча килә. Алар вак-төяккә генә үпкәләми.

Михаил Постновтан соң үзе үк шахтерлар турында мәзәк сөйләп атты.

— Шахтер төн уртасында сменадан, эштән кайта. Эт булып арыган, аякларын көчкә сөйри. Ничек кирәк алай чишенә дә кухняга узышлый йокы бүлмәсенә күз сала — анда хатыны ниндидер ир-ат белән. Ул гаҗәпләнеп әйтә, имеш: «Ничек ятасыгыз килә торгандыр...»

— Михаил, элек шахталарда кенәри дигән кошлар асраганнар дип ишеткәнием. Дөресме шул? — дип сорады Габделнур.

— Әйе. Метан күбәя башласа, алар тавыш бирә торган булганнар.

Ләкин армиядә дә саксызрак әйтелгән, кешенең мин-минлегенә тия торган сүз җавапсыз калмый. Бервакыт, аскы катта шаярганда (көч-куәте ташып торган яшь-җилкенчәк тик тора беләмени?!), Габделнур Лосев фамилияле солдатның муенын ялгыш катырак кысты, ахры. Теге, кызарып-бүртенеп, көчкә сулу алды да:

— Татарин, — диде.

Ничек тиз булгандыр, соңыннан Габделнур үзе дә аптырады: ул каршында еламсырап торган Лосевка киерелеп бер тартты. Бичара калай белән тышланган түгәрәк мичкә барып сыланды. Монда булган егетләр — Постнов, Лавров, Тресков — бер сүз әйтмәделәр. Лосев, лышык-лышык борын тартып, икенче катка — казармага менеп китте.

Ул Вологда өлкәсеннән армиягә алынган, беренче елын гына хезмәт итүче солдат иде. Уртача буйлы, сипкелле, тырпаеп торган сары чәчле, дөнья күрмәгән — моңарчы беркая да чыкмаган авыл малае. Өч көн буена Габделнурга дәшмәде. Аннары, килеп, кулын сузды.

— Гафу ит.

Билгеле, ачу сакламаган бу егеткә Габделнур яңадан кул күтәрү түгел, авыр сүз дә әйтмәде. Хәер, сәбәбе дә булмады.

Андый, кем әйтмешли, гадәттән тыш хәлләр сирәк була. Күбрәк бергә җыелып альбом актаралар — фотолар карыйлар, тормыш, кызлар турында сөйләшәләр. Кәеф күтәренке булганда җырлыйлар. Мондагы җырларның, билгеле, байтагы солдат хезмәтенә кагылышлы. Кем чыгарган — аны белүче юк, ләкин солдатлар буыннан буынга аларны бер-беренә тапшыралар. Җырларның исемнәре дә бар: «Самовольщик», «Янгынчы мәхәббәте», «Профилактика бүтән», «Гашыйк янгынчы җыры», «Картлач янгынчы анты» һ.б.

Постнов ялындырып тормый: үзе гитара чиртә, үзе җыр суза:

Замела метель гидранты, запорошила,
Рукава разбросаны вокруг...

Монысы бетүгә икенчесен башлый:

Пусть задохнусь в противогазе,
Порву пожарную петлю,
И трехколенную сломаю,
И все равно я вас люблю.
Клянусь багром большим и малым,
Клянусь стволом ВПС-5,
Еще клянусь штурмовкой,
Что буду в жены тебя брать.

Бик үк камил булмасалар да, җырларны барысы да ярата, чөнки алар янгын сүндерүче егетләр турында. Шуңа күрә җырга башкалар да кушыла. Күбесендә, Постнов әйтмешли, «полевой тенор», ягъни басу-кырларда ялгыз гына, кешегә ишеттермичә генә җырларлык тавыш булса да, аңа иярәләр, чөнки гаеп итеш юк.

И ломы дугой согнутся,
Все равно любовь жива...

Көр тавышлар тирә-юньне яңгырата.

От тебя в стороне, я горю наедине,
Никакой огнетушитель не поможет мне.

Габделнур бу җырларны беренче көннәрне үк блокнотка язып алды, күбесен ятлады. Һәм ул шуны аңлады: солдат беркайчан да төшенкелеккә бирелми, шыңшымый, хезмәтеннән тәм таба һәм аны булдыра алганча бизәргә тырыша.

Тыйнак кына итеп туган көннәр үткәрү дә, часть байрагы янында төшкән фотосын әти-әнисенә җибәрү дә, стена газетасына мактап язу да, тревогалардан соң исем-фамилиясен атап үтү дә — барысы да солдатның авыр хезмәтен азмы-күпме җиңеләйтә, бертөрле ялыктыргыч тормыш агышына үзгәреш кертә. Моны командирлар бик яхшы белә һәм бөтен чаралардан да файдаланырга тырыша, әлбәттә, партия һәм комсомол оешмалары ярдәмендә.

Менә шулай ял сәгатьләре һәм уен-көлке белән, дежурство һәм тревогалар вакытында җан тирләреңне чыгарып, әмма бу хезмәтнең кирәген тоеп, кайчан да булса төгәлләнәчәгенә өмет тотып, хезмәт үз җаена дәвам итә.

## 15

Гимнастерка төймәләрен, каеш прәшкәсен чистартып, итеген көзгедәй ялтыратып, Габделнур беренче этажга — гаражга төште. Анда солдатлар ак брезент курткалар киеп, кечкенә балта тагылган киң бил каешлары буып маташалар иде. Ул да тиз генә өс киемен һәм башына кызыл йолдызлы яшел каска киеп алды да сафка тезелә башлаган егетләр янына килеп басты.

Уен-көлке, сөйләшүләр тынды, чөнки гаражда Лукьянчукның биек фуражкасы һәм сипкелле йөзе күренде. Дежур сержант, ике отделениене дә сафка тезеп, янгын сүндерүчеләр начальнигына рапорт бирде.

— Иптәш өлкән лейтенант...

Гәүдәсен төз тотып йөрүче командир, рапортны кабул иткәч, яшь офицерларга хас таләпчәнлек белән һәрберсенең өс киемен тикшерде, устав һәм инструкция буенча белергә тиешле кагыйдәләрне сорады.

— Сез үзегезнең нинди частьта хезмәт итүегезне, сезгә Хәрби диңгез флотының гаять әһәмиятле бер объекты ышанып тапшырылганын исегездән чыгармагыз, — диде ул, башта инде солдатлар яттан белгән сүзләрне кабатлап, аннары өстәде: — Бу арада көннәр бик коры тора, объектта, хәрби шәһәрчектә һәм поселокта да янгын чыгу ихтималы бик зур...

Инструктаждан соң солдатлар ялтырап торган кызыл буяулы машиналарны, аларга урнаштырылган янгын сүндерү җиһазларын элекке сменадан кабул итеп алдылар. Отделение бер тәүлеккә дежурга басты. Балта тагылган киң каешларын, брезент курткаларын һәм каскаларын салып, стена буендагы озын эскәмиягә тезеп куйдылар.

Габделнур иптәшләре белән бер-ике партия домино, шашка уйнады, берсенең фотокарточкалар альбомын карап утырды. Дневальныйны алыштырыр алдыннан гаражга кереп, машинадагы инструментларны янә бер тапкыр барлап чыкты, эскәмиядәге киемен, йөгереп килгән уңайга киярлек итеп, җайлабрак куйды. «Белмәссең дөнья хәлен. Чыннан да бу арада бик эссе...»

...Отбойдан соң өске каттагы йокы, астагы дежур бүлмәләре тынып калды. Өлкән лейтенант белән старшинаны озаткач, отделение командиры:

— Мин бераз черем итеп алам, — диде һәм күрше бүлмәдәге койкаларның ишек катындагысына барып ятты.

Габделнур гараж ишеген ачып куйды. Өстәл тартмасыннан кичтән әзерләп куйган конверт белән чиста кәгазь, гимнастерка изүен ычкындырып, эчке түш кесәсеннән авторучка алды. Конвертка, мәктәптә матур язу дәресендәге кебек, хәрефләрне тигез тезеп, әкрен генә адрес һәм әтисенең исем-фамилиясен язды. Аннары ак кәгазьгә хатның беренче юллары төште. «Исәнмесез, хөрмәтле әти һәм әни! Сезгә үзенең кайнар солдат сәламнәрен озатып, тормышыгызда уңышлар һәм үзегезгә нык сәламәтлек теләп калучыны улыгыз Габделнур дип белерсез...» Аннары егет әбиләренә, туганнарына һәм агай-энеләргә, берәм-берәм исемнәрен атап, сагынычлы сәламнәр юллады. Йөрәк җылысы белән сугарылган, күңел түреннән чыккан хисләрен тәфсилләп, ничек барысын да күрәсе килүен, сагынуын кәгазьгә төшерәсе дә килә, ләкин аларның — уй-борчуларының — бөтенесен дә бәйнә-бәйнә тезеп китсә, артык төчеләнү булмасмы, моң-зар булып ирешмәсме дип тә шиккә кала. Язуыннан туктады. Каршыдагы телефонга, яндагы тәрәзәгә карап, бераз вакыт уйланып утырды. Күрше бүлмәдә иптәшләренең тигез сулап йоклавы, вакыт-вакыт койка пружинасы шыгырдавы ишетелә. Тәрәзәдән төшкән ут яктысында казарма каршындагы агач яфраклары, солдат куллары шомарткан турник тимере ялтырап күренә. Арырак — бруслар, ике баганага эре ятьмә тартылган волейбол мәйданчыгы, солдатлар уйнаганны карарга килүчеләр өчен куелган тар эскәмияләр.

Солдат тормышына тәмамысы ияләнеп җиткән булса да, үзе язганда яки ерак-ераклардан килгән сәлам хатларын укыганда, аның күзләре кымырҗый, күңеле җилкенә, алгысый башлый, йөрәге сыкрый, кысылып-кысылып куйгандай итә. Юк, аның йөрәге әле, әбиләре әйтмешли, сөбханалла, ул аның кайда икәнен дә белми. Бу сагыну, җирсү аны шулай дулкынланырга мәҗбүр итә, шул хәлгә китереп җиткерә. Көндез алай ук түгел, иптәшләр белән, хезмәт белән вакыт сизелми дә диярлек уза. Ә төннәрен йоклый алмыйча ятканда яки үзе генә калган мизгелләрдә аны әйтеп бетергесез, берни белән дә басып булмас шикелле тоелган, һич чиге-чамасы күренмәстәй сагыш биләп ала. Ундүрт яшеннән, әле яңа гына балигъ булган бала яшеннән, өйдән чыгып китү, туганнарыннан, өеннән-җиреннән аерылу аны һәрдаим бимазалап, йөрәк бәгырьләрен телгәләп, гел эчтә

нәрсәнедер тырнаштырып-сызлатып тора иде. «Бар бит ул бәхетле кешеләр! — дип куя кайчак Габделнур. — Үз өендә, ата-анасы, кардәш-ыру янында гомер ки...»

Шулчак шык иткән тавыш ишетелде. Габделнур башын күтәрде. Өске каттагы телефон станциясеннән торба буенча жетон — номер сугылган калай кисәге төшергәннәр иде.

Солдат сикереп торды. Йөгереп барып жетонны алды. Шул секундта тревога кнопкасына басты. Үзе уктай атылып гаражга керде. Тревога сигналыннан дивар зыңлап торды; дежур бүлмәсе шундук хәрәкәткә килде. Солдатлар, дәррәү урыннарыннан торып, дөбер-шатыр гаражга йөгереп керделәр.

Артык сүз юк. Хәрәкәтләр өзлексез булып торган күнегүләр дәвамында кабат-кабат чарланган — төгәл, бернинди каушау, алан-йолан карану, кием эзләп маташу, этеш-төртеш яки тиктомалга уңга-сулга бәрелешү, болганыш-тулганыш галәмәте юк.

Берничә секундта киенеп, машинага утырдылар. Шак-шок кабина ишекләре ябылды. Ул арада Чхиквадзе стартерга басты. Габделнур жетонны шофер белән янәшә утырган отделение командирына бирде.

— Икенче проходнойга! — диде ул, Шотага карамыйча гына, һәм кая барырга кирәген әйтте.

Машина гараждан чыккан уңайга ике тапкыр әче итеп сирена улатты һәм, уңга текә борылып, таш юлдан чапты.

Объектка керә торган проходнойдагы солдатлар зур тимер капканы киң итеп ачып куйганнар иде инде.

Берсе, өч бармагын погонына куеп, объектта кем барын аңлатты һәм:

— Батя! — дип, телдән дә кычкырып, кулы белән алга ишарәләп калды.

Сержант шоферга:

— Ку! — диде.

Әйтмәсә дә була иде, чөнки Шота — үз эшен яхшы белә торган егет.

Объектның иң аргы башына килеп җиткәч, йокылары качкан солдатлар, кулларын артка куеп басып торган тулы гәүдәле, кыска муенлы полковникны — часть командирын һәм әледән-әле сәгатенә карап торучы, озын буйлы штаб начальнигын күрделәр. Машинаны тиз генә бассейн янына урнаштырып, җиңсәләр суздылар, «янгын» сүндерергә әзерләнделәр. Беләк юанлыгы җитен җиңсәләрдән су килүгә, сержант саф адымы белән өлкән офицер каршына барып басты, честь бирде һәм әзерлек турында белдерде.

— Иптәш полковник...

Канәгатьлеге йөзенә чыккан командир рапортны тыңлагач, кулын селтәде. Бу аның «отбой» дигән сүзе иде. Отделение сафка тезелгәч, ул:

— Тиз килеп җиттегез, — дип мактады. — Сезгә рәхмәт белдерәм.

Суланып авырайган җитен җиңсәләрне машинага төяп, тирләп-пешкән солдатлар кире гаражга кайттылар. Аларны өлкән лейтенант Лукьянчук, старшина (яши торган фатирлары шушы озын бинаның икенче башында гына иде) һәм монда калган расчет каршы алды. Машинага коры җиңсәләр куеп, юешләрен гараж эченә кибәргә элеп, техниканы тәртипкә китергәч, солдатлар тагын ял итәргә яттылар.

Габделнурның вакыты әле чыкмаган иде. Ул үз урынына утырды. Тавышлар тынгач, кемдер өстәл тартмасына салып куйган баягы язылып бетмәгән хатын алды.

Егет, фикерләрен җыеп, бераз уйланып утырды. Уңышлы үткән тревогадан соң аның күңеле күтәренке иде. Менә бит, әгәр чын тревога булса... Мондый вакытларда Габделнур үзендә һәрвакыт горурлык хисе тоя.

Әлеге тревогадан соң бик нык дулкынлану кичергәнгәме, ул зиһенен бер ноктага туплый алмады. Хатны бер читкәрәк этәреп, өстәл тартмасыннан инглиз язучысы Голсуорси китабын алып, кичә тукталып калган төшенә кыстырган кәгазьне өстәлгә ташлап, укый башлады. Романдагы вакыйгалар аны үз эченә алып кереп китте, бит арты бит ачылды. Күпме вакыт үткәндер, укуга мавыгып, ул тиз генә әйтә дә алмас иде, мөгаен, кинәт, Габделнурны сискәндереп, телефон шылтырады. Ул трубканы алды.

Трубкада ашыгудан тотлыга-тотлыга сөйләгән хатын-кызның өзек-төтек чәрелдек тавышы ишетелде:

— Пожарный!.. Яна!.. Поселокта яна!..

— Нәрсә? — дип сорады Габделнур. — Тыныч кына әйтегез.

— Яна! Сарайлар яна! Тизрәк! Зинһар! Бик нык...

Сөйләшкәндә үк урыныннан сикереп торган Габделнур телефон трубкасын оясына ташлады да тревога кнопкасына басты...

...Ярты минуттан кызыл машина, утларын яндырып, улаган сиренасы белән төнге тынлыкны ярып, янгын сүндерергә чыгып чапты. Хәрби шәһәрчек тә, объект кебек, урман эчендә, куе булып үскән биек нарат һәм чыршы агачлары арасында урнашкан иде. Июль чилләсендә әлсерәп, моңсуланып утырган агачлар фара яктысында берәм-берәм артка чиктеләр.

Машина якынлашуга, КППның тимер капкасы шар ачык иде инде. Машина ажгырып хәрби шәһәрчектән чыгып та китте. Алда, поселок урнашкан иңкүлектә, һавага төтен күтәрелә, ялкын телләре айкала-чайкала отыры биеккә үрләп төнге бушлыкта нидер кармалыйлар, каяндыр астан, ике катлы йортлар артыннан, бертуктаусыз күтәрелгән очкыннар тирә-юньгә һәм югарыга таба чәчрәп, янгынның инде шактый нык җәелгәнен һәм аны сүндерү җиңел генә булмаячагын искәртәләр иде.

Отделение командиры объекттагы, хәрби шәһәрчектәге һәм поселоктагы барлык коеларның кай тирәдә урнашуын, алардагы гидрантларның нинди хәлдә икәнен биш бармагы кебек белә иде. Чөнки өченче елын төгәл-

ләп килүче бу сержантка еш булып торган тревогалар вакытында аларның һәммәсен дә карап-барлап чыгарга туры килде. Әйе, күнегү-өйрәнүләр — бер нәрсә, ә бүгенге янгын — алар өчен җитди сынау.

Ике тоннадан артык су сыйдырышлы цистернасы булган авыр машинаны шофер урам уртасына — кое янына китереп куюга, егетләр, «ә» дигәнче кабиналардан коелып, эшкә керештеләр: башы кәкре тимер җайланма белән кое капкачын ачып ташладылар, гидрантка машина янтыгының бер бүлкәсеннән алынган колонканы борып керттеләр. Аларның кулы-кулга йокмады, тиз-тиз генә колонкага басымлы суыручы ике кыска җиңсә ялгап, икенче башларын насоска беркеттеләр. Аннары төргәкләрнең берсен җиргә таратып җибәрделәр дә, башын машинага тоташтырып, икенче башындагы тоташтыргыч «эшләпә»гә янә бер җиңсә ялгадылар, линия суздылар. Һәрнәрсә үз урынында, хәрәкәтләре төгәл, күнегелгән, исәпләнгән...

Ә менә янгын берни белән дә исәпләшми: каяндыр вакытлы-вакытсыз исә башлаган төнге җилдә ул отыры көчәя, котырына, дулый, бөтен әтрафны ялмап алырга теләгәндәй, өскә һәм як-якка үрли...

Поселокның һәр тарафыннан — ике катлы таш йортлардан, озын бараклардан — халык җыела: өс-башына ни туры килсә шуны эләктергән ир-ат, эчке күлмәкчән яки халаттан гына атылып чыккан хатын-кыз, күзләре шар ачылган һәм йокы аралаш ни булганын абайлап та өлгермәгән бала-чага... Кемдә чиләк, кемдә чүмеч димәсәң, кулына нинди савыт туры килгән, шуны эләктергәннәр; акырыш-бакырыш, елау-сыктау, хафалану-өзгәләнү машина тавышын да күмә, такта, шифер һәм башка нәрсәләр янган авазлар белән буталып, тирә-юньдәге гарасатка тагын да ямьсезрәк, куркынычрак төс бирә.

Габделнур һәм аның иптәшләре үз эшләре белән мәшгуль: колонкадагы краннар ачылды, машина артындагы насос эшкә кереште, җиңсәләрдән су ага башлады. Җиргә җәеп салган буш, корылары тиз арада су белән тулды, түгәрәкләнде, юешләнде, бер урында энә очы кадәр генә тишек булган икән, бәләкәй генә фонтан хасил булды — аннан өскә таба нәзек кенә булып су чәптерә башлады...

Габделнур дөрләп янган сарайларга мөмкин хәтле якынрак килде дә җиңсә очындагы дюралюмин көпшәне каты куллары белән тоткан хәлдә аның кранын ачып җибәрде, дүрт-биш атмосфера басымы белән килгән су агымын утның нәкъ үзәгенә юнәлдерде...

Көчле басым астында куылган су юлында ни очраса, шуны очырта башлады. Көпшәне җайлы-җайсызрак тотсаң, җиңсә пожарныйны селтәп атарга да күп сорамый. Шуңа күрә Габделнур янында аның кулдашы-ярдәмчесе тора иде. Ләкин ялкын бер-берсенә терәтеп корылган егермеләп сарайның яртысына капкан иде инде...

Ул арада сирена улатып икенче машина да килеп җитте. Өлкән лейтенант Лукьянчук дилбегәне үз кулына алды, кыска-кыска, әмма кул астындагы солдатларга аңлаешлы командалар бирә башлады. Сарайлар ике рәт булып, әле берсе генә яна иде. Шуңа күрә, анысын коткарып калу мөмкин булмаганга, ул икенче рәтне саклап калу чарасын күрергә кушты: бер машина исән сарайлар өстенә су бөркергә тотынды.

Җыелган һәм әле һаман агылуын дәвам иткән поселок халкы да аңына килде: бер сафка тезелеп, чиләкләр белән булса да су биреп тора башладылар.

Батыррак ир-атлар утка якын ук торып багор, көрәк ише нәрсәләр белән сарайларны сүтеште. Поселок белән янәшә авыл. Аннан да кулына нәрсә дә булса тоткан ир-атлар ашык-пошык янгын сүндерергә киләләр иде.

Хәрби шәһәрчектән йөгереп килгән солдатлар һәм матрослар, офицерлар һәм мичман-старшиналар да ут кыерлаучыларга кушылды.

Тавыш, шау-шу, кычкырыш-елаш колак төбендә өзлексез шаулап торды.

Су агымы өскә, аска һәм утның үзәгенә бәрә... Шарт-шорт килгән тавыш өзелми, чытыр-чытыр ниләрдер яна, тирә-юньгә күңелне болгата торган исләр тарала.

Өлкән лейтенант Лукьянчук елашып торган хатын-кызлар янына килде.

— Сарайларда шартлый торган әйберләр юкмы? — дип сорады ул.

Бензин, керосин ише нәрсәләрдән тыш хәрби объектта эшләгән кешеләрдә шартлаткыч матдәләр дә булуы ихтимал иде. Гәрчә бу мәсьәләдә контроль бик каты булса да, ул әлеге сорауны бирмичә кала алмады. Чөнки ул-бу була калса, солдатлар өчен командир җавап бирә.

— Юк, юк, — диделәр хатыннар.

Күккә ялкын ургыла, төтен күтәрелә, як-якка очкыннар чәчри. Янгынның туктарга исәбе дә юк. Инде сарайлар рәте бер башыннан икенче башына хәтле тоташ ут эчендә. Алар тирәсенә якын килерлек түгел — температура күтәрелгәннән-күтәрелә бара. Өскә таба берөзлексез чаткылар оча...

Күпмедер вакыт узгач, таң беленгәндә һавага зәңгәр төтен күтәрелә башлады, ялкын басыла төште.

Лукьянчук егетләре армый-талмый эшләделәр. Ләкин ничек кенә тырышмасыннар, сарайлар янып бетте. Шулай да икенче рәтне саклап калдылар. Сарайлар тирәсе су белән тулды. Лачтыр-лочтыр су ерып йөри башладылар. Киемнәре баштанаяк манма су булды.

Гражданский халык үз сарайлары тирәсендә кайнаша башлады. Солдат-матрослар да шул тирәдә мәш килә: янган велосипед, мотоцикл, карават башлары кебек тимер-томырлар сөйрәп чыгаралар.

— Егетләр, пешкән бәрәңге ашыйк, — диде бер матрос, иптәшләренә мөрәҗәгать итеп.

Ә каравыл ротасыннан килгән солдат:

— Кая, кем аракыга йөгерә, монда шәп закуска бар, — дип кычкырды.

— Нәрсә?

— Дуңгыз ите.

Аны сырып алдылар.

Ул арада икенче баштан берәү:

— Монда тагын бер чучка баласы кара күмергә әйләнгән, — диде.

Шул тирәдә булган Габделнур, якын килгәч, имәнеп китте.

— Кит, юньсез, кеше бит бу, — диде ул.

Карарга чирканыч хәлдәге янган кешене аның беренче күрүе иде. Мондый җан өшеткеч күренешкә тап булганы юк иде әле.

Халык җыелды. Бер хатын якынрак килде һәм аяк-куллары кара күмергә әйләнгән, чырае да танымаслык хәлгә килгән ир-атның гәүдәсенә иелеп карый башлады.

— Әйләндер әле, — диде бер офицер янындагы солдатка.

Янып үлгән кешенең аркасында калган зәңгәр комбинезон кисәген танып:

— Шул, үзе, — диде хатын һәм, йөрәк өзгеч тавыш белән чәрелдәп, ире янына тезләнде. — Витенька, милый!.. На кого ты нас оставил?! Ой! Ой!..

Һәм хатын өзек-төтек сүзләр, аңлаешсыз авазлар тезә-тезә, яртылаш кына калган иренең җансыз гәүдәсен коча-коча илереп кемгәдер ялварырга, кемнедер каргарга, такмаклап еларга тотынды.

Моны карап торуы ук, әле ничә сәгать элек кенә исән кешенең, кемнеңдер кадерле иренең, кемнеңдер газиз атасының менә шулай мәгънәсез үлеме, кара күмергә һәм инде хәзер мәеткә әйләнүен күрүе егетләргә дә авыр тәэсир итте. Күбесенең мондый фаҗигале үлем-җитем белән беренче мәртәбә очрашуы иде.

Хәрби шәһәрчектәге гараждан өч-дүрт машина да килеп туктаган иде. Бераздан, хатыны өеннән алып чыккан одеалга төреп, мәрхүмнең гәүдәсен стройбат солдатлары, машинаның бортын ачып, кузовка илтеп салдылар.

Габделнурлар әле һаман пыскыган кисәүләрне сүндерү белән мәшгуль булдылар. Янгын беткәндә, һавага аксыл-зәңгәр төтен күтәрелде. Бөтен поселок төтен исе белән тулды.

Иртәнчәк янгынчылар әйбер-караларын җыештыра башладылар. Су бирү тукталгач, җиңсәләрне берсен икенчесеннән аерып-ычкындырып ташладылар. Суы агып беткәч, җитен җиңсә эче бушап калган һәм авызын ачкан ябык елан шикелле җәелеп ята. Аннары, чама белән уртасын табып, аны өскә күтәрәләр дә ике катлы итеп әкрен генә җыя-бөтерә башлыйлар. Йөзләре корымга буялган, куртка-чалбарлары лычма булган егетләр, юеш куллары белән тәмәке кабызып, еш-еш эчкә алып, бер-беренә бирәләр... Сәгать сигезләрдә генә Габделнурлар частька кайтып киттеләр. Икенче машина поселокта калды...

Әлеге янгынның шаукымы озакка барды. Каян, ничек килеп чыгуы турында сүз күп булды. Дөрес, янгынчыларга тел-теш тидерүче табылмады. Чөнки алар тиз килеп җиттеләр, хәлдән килгәнчә тырыштылар. Ләкин иң хәтәре — өч көн буена егетләрнең тамагыннан юньләп ризык үтмәде. Ашарга утыруга мәрхүм ир-атның күмерләнгән аяк-куллары күз алдына килә, өстәлдәге ризыктан пешкән адәм итенең авырсы исе борыннарына килеп бәрелгәндәй була. Хәтта объект территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү нисбәтеннән карап-тикшереп йөргәннән соң, биредә мул булып үсүче шәмәхә төстәге караҗиләк ашаганда да кисәү күмерләре күз алдына килгәли иде.

Бу араларда Габделнур еш кына әтисен, аның сөйләгәннәрен исенә төшергәләде. Дөрес, Галләм абзый, чын мәхшәрнең үзен күргән, кан койган кеше буларак, сугыш турында сөйләргә яратмый иде. Фәкать сирәк-мирәк, бераз «төшереп» алгач кына, ул үзенең сугышчан дусларын хәтереннән барлый. Аларның — яшь-яшь егетләрнең — ачы язмышы, үкенечле үлеме турында да әйткәли иде. Окоптан сикереп чыгып, атакага иңгә-иң терәлеп дигәндәй янәшә йөгереп барганда җан дустына әверелгән берәр солдатның йөрәгенә пуля тиеп, кинәт туктап калуын һәм сүз дә әйтә алмыйча авып җан бирүен күрү бик авыр булгандыр шул. Галләм абзый бигрәк тә бер Кукмара егетенең үз кулында үлүен авыр кичерә иде. «Адресы да хәтердә калмаган, семьясына хат та язып сала алмыйм бит», — дип уфтана иде ул.

## 16

Беркөнне, гадәттәгечә кич белән очрашкач, танцы вакытында Зоя Габделнурга сүз катты:

— Ярославль күрәсең киләме?

— Ә минем аны күргәнем бар, хәтта берничә тапкыр, анда ике вокзал барын да беләм: Главный һәм Московский, — диде егет, шаяртып, һәм хатынның тулы булса да җиңел биюче, буйсынучан гәүдәсен үзенә тартып, колагына пышылдады: — Бүген минем сине генә күрәсем килә...

— Мин синең карамакта, — дип, тыйнак кына көлде Зоя, башын күтәрә төшеп егеткә яратып карагач, һәм сүзне баягы эзгә төшерде. — Син шәһәрне узып барышлый гына күргәнсең бит.

— Анысы да дөрес. Килүен килә дә... Ничек диләр әле: оҗмахка керер идем дә, гөнаһларым җибәрми шул.

— Ә синең нинди гөнаһларың бар? Гауптвахтага утыртканнары юк шикелле...

— Сүз уңаенда гына әйтүем. Мин бит солдат. Ярославльгә хәтле чыгып китә алмыйм. Безгә увольнительный монда һәм поселокка чыгу өчен генә бирелә. Шәһәргә бару өчен күп вакыт кирәк.

— Әгәр мин сөйләшсәм?

Габделнур музыка ритмына җай гына биегән хәлдә иңнәрен сикертеп куйды. Ул Зояның әтисе отставкадагы офицер икәнне белә иде инде. Күрәсең, шуңа аркалануыдыр.

— Әтиең беләнме?

— Билгеле. Лукьянчук аңа каршы килмәстер.

— Мине дөрес аңлар микән соң?

— Тыйнаклык большевикларны да бизи...

— Эш анда гына түгел. Әле иптәшләр дә бар бит. Ә миңа алар белән хезмәт итәсе.

— Бөтен дөньяның бөкресен син генә төзәтеп бетерә алмассың. Әзрәк үзең турында да уйла.

— Ярар, сөйләш, — диде Габделнур, теләр-теләмәс кенә.

Әлбәттә, табигате белән кызыксынучан егетнең берничә мәртәбә узып киткән шәһәр белән якыннанрак танышасы, аны сәйран кылып йөрисе килә килүен... Ләкин... «Ярар, егетләр гаеп итмәс әле. Мин алар өлешенә кермим бит. Отпускыга да кайта алмадым. Епифановка, әниең каты авырый, дигән пичәтле телеграмма килгәч, аны җибәрергә туры килде...»

Аннары, дип фикер йөртте солдат, әгәр мөмкинлек чыкканда файдаланмасаң, форсатны кулдан ычкындырсаң, үкенечтә калачак. Гражданкада кайчан килә ул бу якларга? Ай-һай... Кем көтеп тора аны Ярославльдә? Ярый әнә Ленинградны бераз күреп калды. Хәзер анда кайчан барасың? Гомумән, бара алырсыңмы, юкмы үз гомереңдә?!

Зоя сүзен сүз итте.

Шулай да, ефрейтор Гаделҗановның кулына кәгазь тоттырганда, өлкән лейтенант Лукьянчук кисәтте:

— Патруль күзенә чалынмаска тырыш...

Алар станциядә очрашырга килешкәннәр иде. Габделнур беренче килде. Ул һәрвакыттагыча увольнениегә чыга торган киемнән: кыска козыреклы биек фуражка, калын яшькелт китель һәм шундый ук төстәге галифе чалбар, ләкин ул як-якка кабармаган, ә тәненә сыланып диярлек тора, билендә сары аеллы киң каеш, аягында гади кирза итек. Ләкин бар булганы пөхтә: үтүклисе үтүкләнгән, чистартыласы елкылдый.

Менә бераздан Зоя да күренде. Зифа буйлы яшь хатын, гаскәриләр телендә «ножки с бутылочкой» дип аталган тыгыз балтырлы, төз аяклары белән тиз-тиз атлап килә иде. Аның өстендә җиңелчә җәйге ак кофта белән кара итәк, аягында тәбәнәк үкчәле кара туфли. Кулында җыйнак кына ридикюль. Чәчләрен чак кына артка җыебрак эләктереп куйган. Ләкин аяк атлаганда бераз кедрәрәк алтын сыман сары чәчләре җилкәсен каплап, селкенеп-таралып китәләр; киң, биек маңгае, кабарынкы иреннәре, ачык йөзе кояш нурында тагын да яктырак күренәләр. Иртәнге һаваның сафлыгына, бәхет вәгъдә итүче якты көнгә сөенгән күзләре дә нурлана төшкән; бүген ул бөтенләе белән балкый сыман. Иннек-кершәнне чама белән генә сөртеп бизәнгән зәңгәр күзле, коңгырт кашлы, тулышып торган яңакларына ятышлы гына озынча юка туры борынлы Зояга егет беренче мәртәбә күргәндәй текәлеп карады.

Кисәк кенә Габделнурның күңел түрендә бер хыялый фикер чагылып үтте: каршына Зоя түгел, ә сары чәчле, зәңгәр күзле түбән оч кызы — аның беренче мәхәббәте килсә икән хәзер!..

Зояның колагындагы кечкенә фирәзә кашлы алкасына һәм ачыграк калган түшенә үк төшеп торган алтын чылбырлы кулонга, бармагындагы алтын йөзегенә — бар булган зиннәтле әйберләрен тагып килүенә дә игътибар итте егет. Шулар янына кофта эчендәге калку күкрәгә дә мулдан. Ни генә димә, олырак яшьтәге ир-атның гына түгел, үз чордашлары егет-җиләннең дә күзе төшәрдәй яшь, таза тәнле, чибәр хатын басып тора иде аның каршында.

Егет түзмәде.

— Син бүген үтә матур! — дип соклануын яшермичә мактап куйды.

— Син мине кызартасың, — дип, чыннан да оялыбрак, солдатына яратып карады Зоя. Ә серле өмет белән тулы зәңгәр күзләре: «Кадерен бел. Мин синең өчен, фәкать синең өчен генә бизәндем-ясандым бүген», — дип әйтәләр иде.

Хатын (Ярославльдә текстиль һәм җиңел сәнәгать техникумы тәмамлаган, туку фабрикасында смена мастеры булып эшли) ярыйсы гына укымышлы да булып чыкты. Поездда, бераз гына тирбәлеп барган вагонда кайнар тәне белән егеткә терәлеп утырган мәлдә, шәһәр һәм аңа багланышлы вакыйгалар белән солдатны таныштырды. Үз төбәгенең патриоты икәне дә сизелә иде.

— Риваятьләргә караганда, князь Ярослав Мудрый, Которосль елгасы Волгага килеп кушылган урынга, калын урманнарга ауга чыккач, бик зур аю белән очраша. Һәм шунда Ярославль шәһәренә нигез сала. Бу моннан тугыз йөз илле еллар элек була. Шәһәр гербындагы аю да шул вакыйгага ишарә, диләр...

Һәм ул үзе белгән кадәресен солдатка сөйләп барды. Габделнур исә, аны тыңлап, бу якның кырысрак табигатен дә күзәтеп хозурланды. Нарат, чыршы, каен агачлы куе, калын урманга, тимер юл полотносына ук килеп тоташкан сазлык урыннарга карады. Юл буенда, авыл эчләрендә үсеп утырган, чәчәкләре алагаем зур ак абажурны хәтерләтүче, кеше буе, беләк юанлыгы балтырганнар да (солдатның туган ягында алар тәбәнәк, нәзек була) аның игътибарыннан читтә калмады. Юан нарат, чыршы бүрәнәләрдән салынган, күбесе караеп торган зур өйләр якты тәрәзәләре белән алар утырган поездны сәламләп калалар төсле.

Габделнур Зояга сирәк-мирәк кенә булса да сораулар да биргәләде, бүтән темаларга да кереп чыккаладылар. Кыскасы, авызга авыз куеп дигәндәй, Ярославльгә барып җиткәнче гәп куерттылар.

Кояшлы, җәйге көн булгангамы, бу юлы тимер юл вокзалы — Ярославль Главный — аксыл төскә буялган бер катлы озын бина — аларны ачык чырай белән каршылады. Бер катлы булса да биек, гаҗәеп матур, якты иде ул. Перроннан вокзал бинасы аша киң мәйданга чыгып бераз баргач, егет түзмәде, артка борылып карады, туктады.

Габделнур шунысына да игътибар итте: вокзал бинасының урта өлеше тагын да биегрәк, ишек турылары ярымтүгәрәк, бинага терәтеп үк колонналар утыртылган. Ә тагын да өстәрәк дүртпочмак рәвешендә калку урын, аңа зур, түгәрәк сәгать беркетелгән, почмакларда очлаеп килгән кыска баганалар. Дүртпочмак өстендә, уртада, әле тагын күпкырлы, тәрәзә урыннары ачык калдырылган, чатыр формасындагы түгәрәк корылма. Ә иң югарыда очлы башын зәңгәр күккә сузган шпиль.

— Кая барабыз? — дип сорады Зоя.

— Белмим. Монда син хуҗа. Мин ияреп кенә йөрүче, — диде Габделнур, һәрнәрсәгә мөкиббән китеп, әле артка каерылып, әле як-якка карый-карый вокзал бинасыннан ераклаша барганда.

Каршыда тәбәнәк куаклы сквер, аның артында һәм як-якта, агачлар арасында, дүрт катлы йортлар күренә, сулда Тимерьюлчылар мәдәният сарае мәйданны бизи, трамвай-троллейбусларга халык ашыга...

Шәһәр эченә керделәр.

Әлбәттә, Зоя әлеге сорауны болай гына бирде. Чөнки монда үзе хуҗа икәнне ул бик яхшы белә. Ләкин солдатның күңелен күрү нисбәтеннән бу сорауны бирүе урынлы булды дип саный. Аннары, поездда килгәндәге кебек, ул аңа артык елышып та бармады, бераз ара калдыра төшеп атлады. Шәһәр зур булса да, таныш-белеш очрамас дип кем әйтә ала. Артык сүзнең, гайбәтнең аңа һич кирәге юк иде.

Билгеле, Габделнур хатынның үз-үзен тотышындагы мондый нечкәлекләрне искәртерлек хәлдә түгел иде. Ул, аланйолан каранып, Зоя сөйләгәннәрне тыңлап, атлавында булды.

Трамвайга утырып киттеләр...

Шәһәр уртасындагы бер мәйданның байтак өлешен Волков исемендәге театрның алагаем зур, өч катлы бинасы биләп тора. Каршында биек, зәңгәрсу төсләргә манылган чыршылар. Гомумән, шәһәрдә агач күп, яшеллек мул.

Рәсәйдә беренче даими театр оешуы белән Ярославль хаклы рәвештә горурлана. Әлбәттә, Зоя әйтмәсә дә, Габделнур бу турыда — Кострома шәһәрендә туып үскән артист Федор Волковның биредә театр ачуы хакында хәбәрдар, чөнки техникумда режиссура укытучысының сөйләгәне исенә төште.

Хәер, бу шәһәрне дөньяга таныткан бүтән шәхесләр дә байтак икән. Шагыйрь Некрасов шәһәрдән ерак түгел урнашкан Карабиха авылына еш кайтып йөргән. Аның «Рус илендә яшәү кемгә рәхәт?» поэмасын белмәгән мәктәп укучысы юктыр. Сорауны шулай катгый итеп куйса да, бер зур йорты, ике флигеле (аерым өйләр) һәм өч буасы булган усадьбада шагыйрь үзе начар яшәмәгәндер. Ә менә авыл исеме...

— Ул авылда берәр татар баеның тол хатыны яшәгәнме әллә? — дип сорады Габделнур, елмаеп.

— Нигә алай сорыйсың?

Егет, ул сүзне икегә аерып, ике татар сүзеннән ясалган булуына ишарә итте. Ягъни кара — төсне аңлата, ә биха — бикә, барыня.

Зоя моны ошатмады, ләкин солдатка сиздермәде.

— Белмим, — диде дә сүзне икенчесенә борды.

Җырчы Собинов, рәссам Саврасов та (Габделнур аның «Каргалар килде» исемле картинасын яхшы белә) бу шәһәрдә туганнар икән. Император хокук училищесын тәмамлап Мәскәү сенатында һәм Эчке эшләр министрлыгында хезмәт иткән шагыйрь Иван Аксаков та, хөр фикерләре өчен кулга алынгач, бирегә эшкә җибәрелә, чынлыкта башкаладан сөрелә. Космонавт кыз Терешкованы әйткән дә юк инде. Хәзер монда гына түгел, бөтен илдә аның исеме халык телендә.

Шулар өстенә унсигезенче йөз ахырында Мусин-Пушкин тарафыннан «Слово о полку Игорове» әсәре дә биредәге Спасс монастырендә табылган икән. (Күрәсең, Мусин-Пушкин да безнең халыкның бер вәкиледер, ерак бабаларыннан берсе Муса булгандыр, дип уйлады егет. Ләкин дәшмәде.)

— Әнә тегендә, еракта, Туговая гора диган урын бар, — диде хатын. — Татар-монголлар белән сугышта һәлак булган рус баһадирларын шунда күмгәннәр. Хатыннары шунда килеп елаганга, тауга Туговая исеме бирелгән.

— Ә нәрсәне аңлата соң ул?

— Хәсрәтләнү, кайгыруны, ягъни тужить дигәнне.

— Тушить дигәнне беләм.

— Анысы сезнең, янгынчыларның эше инде. Ә тегесе икенче. Бер җырда бар бит: «Любо, братцы, любо, любо, братцы, жить. С нашим атаманом не приходится тужить...»

Әлбәттә, шактый тормыш тәҗрибәсе туплаган бу яшь хатынның Габделнурны Ярославльгә дәшүе тиктомалдан гына килеп чыккан уй түгел иде. Авылда туып үскән, бәләкәй генә бер шәһәрдән армиягә алынган, тыныч холыклы бу таза, ирлек гайрәте ташып торган асыл егетне ничек тә үз ягына аудару, зур шәһәрнең мавыктыргыч тормышы белән кызыктыру, рәтен-җаен белеп эш йөрткәндә, бер тотынгач, кулдан ычкынмаслык итеп бәйләп тә кую иде. Әле бермәлне, ике ай чамасы элек, Зоя, әллә корсакка узыйм микән, дип тә уйлаган иде. Ләкин бу төпле фикер йөртә белүче җитди егетне, яшь кенә булса да, кем әйтмешли, чүбек белән генә алдап

булмас дип, андый тупас адым белән генә үзенә бәйли алмаячагын төшенеп өлгерде. Аннан соң, мәҗбүрилек белән эшләнгән эшнең ахыры хәерле бетәр дип кем гарантия бирә ала? Ярар, уздың да ди, бала да таптың ди, алай-болай киреләнә башласа, сабыеңны күтәреп командование каршына да бардың ди. Шуннан, ярар, өйләндерден дә ди. Ә хезмәт срогы беткәч аны кем тотып тора ала? Койрыкны сыртка салмас дип кем әйтә ала? Аны чылбырга утыртып булмый... аю түгел... Шуңа күрә хатын егетне үзенә карату өчен бүтән тактика сайлады: кала тормышы, анда эш яки уку мәсьәләсендә үзеңә ошаганны, җаның теләгәнне сайлау мөмкинлеге булу һәм башка нәрсәләр белән кызыксындырырга кирәк тапты. Егет үзе фикер йөртсен, нәкъ Зоя теләгән уйга үз башы белән килсен. Хатынның бөтен тырышлыгы шул максатка юнәлде. Шуңа күрә ул булган хәтле акчасын җәлләмичә тотты, бу сәяхәтне төрлеләндерергә тырышты, күбрәк өлешен күңел ачуга корды. Шәһәрнең дә иң күркәм, күңелгә хуш килердәй урыннарын гына әйләнделәр.

Биек таш койма белән әйләндереп алынган, почмакларында очлы чатырлы тәбәнәк башнялары булган, Казанныкыннан шактый кайтыш җыйнак кына Кремльгә, крайның һәм шәһәрнең борынгы бай тарихын үзенә туплаган архитектура тыюлыгына, сәнгать музеена кереп, өстән-өстән генә булса да экспонатларга күз йөртеп чыгу шул планны гамәлгә ашыруда бер адым булды.

Ары киттеләр.

Менә каршыда бихисап колонналы озын бина — сәүдә йорты.

Аны күргәч, солдат:

— Бу Ленинград һәм Кронштадттагы Гостиный дворларны хәтерләтә, — диде. — Күрәсең, алар барысы да бер проект белән төзелгән һәм бер үк вазифаны — сәүдә итү үзәге вазифасын үтәгәннәр.

Сәүдә йортына кереп үзенә вак-төяк сайлаганда, Зоя Габделнурны да истән чыгармады.

— Болары сиңа, — диде ул, елмаеп, һәм сәгать браслеты белән авторучканы аңа сузды.

— Рәхмәт, кирәк түгел иде.

Башкарма комитетның иске стильдәге, өлкә комитетының заманча, очлы түбәсез генә корылган биналары һәм кызыл кирпечтән эшләнгән борынгы чиркәү янәшә торалар. Бер-берсенә комачауламыйча. Хәер, ул чиркәүдә гыйбадәт кылмыйлардыр, бары архитектура һәйкәле буларак кына сакланадыр. Чөнки кергән-чыккан кеше дә күренми, ишеге дә ябык. Аларга иске агач йортлар да очраштырды. Зур, биек өйләрнең кәрнизләре, тәрәзә йөзлекләре гаҗәеп матур, катлаулы бизәкләре нәфис, алтын куллы балта осталары чуарлаганы әллә каян күренеп тора. Бер-беренә охшаган, берсен икенчесе кабатлаган өй юк — һәркайсы аерым сәнгать әсәренә тиң.

Гомумән, шәһәрдә иске һәм яңа бер-берен тулыландырып тора. Идел буенда да борынгы, яшел түбәле, алтын тәреле чиркәүләр, күптән түгел генә калкып чыккан заманча йортлар янәшә.

Габделнур бу каланы Ленинград белән чагыштырып карады. Монда тынычрак: кешеләр дә аз, хәрәкәт тә әллә ни түгел; йортлар исә фәкыйрьрәк — гранит-мәрмәр белән тышланмаган, бизәлмәгән, купшылык сизелми, искеләре күбесе ике-өч катлы, яңараклары бер-ике этажга югарырак күтәрелгән. Аның каравы биредә агач күп: каен, юкә, тупыл, өрәңге...

Алар текә яр читенә килеп чыктылар да яшел түбәле, бүрәнә юанлыгы алты ак колонналы, аскы өлеше бизәкле тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган, тирә-юнендә агачлар үсеп утырган түгәрәк формадагы күзәтү чатырына керделәр.

— Бу Пушкин беседкасы дип атала, — диде хатын.

— Нигә алай?

— Әллә тагы. Яр буенда шушындый өч беседка бар, уртадагысы — исемле.

— Кызык.

Моннан гаҗәеп манзара ачылды.

Әнә пристаньга ике, өч палубалы ак теплоходлар килеп елышкан, читтәрәк әкрен кыймылдаучы бәләкәй генә буксир кайнаша, нәфис гәүдәле су трамвае килә, елга уртасында моторлы көймәләр күренә...

Машиналар, кешеләр төягән паром теге як ярга — причалга якынлаша. Аргы як гел агачлык белән капланган — уңда да, сулда да күз күреме җитәрлек ераклыкта моңсу таллар, озын наратлар һәм тагын бүтән агачлар үсеп утыра. Алар арасында тәбәнәк йортлар шәйләнә, кирпеч, тимер торбалардан чыккан төтен баганалары зәңгәр күккә күтәрелә. Алардан да ары, югарыда, карасу төстәге «мендәрләр, түшәк-ястыклар» күпереп күренә — яңгыр болытлары куера. Ләкин су читендәге комлыкта ял итүчеләр әле аларны күрми...

Суда бер катер, үз артыннан аксыл эз калдырып, сулга таба чаба, Идел аша салынган озын, биек, челтәрле тимер юл күперенә якынлаша. Тыныч су өстендә сирәк-мирәк акчарлаклар каерылып оча, балык күзли. «Шул ук Идел акчарлаклары да бездәгеңә охшаган, — дип уйлап куйды Габделнур. — Тик шәһәре, иле-җире генә башка». Кая бара икән бу теплоходлар? Өскә күтәреләме, әллә аска төшәме? Утырып китсәң иде шуларның берсенә су буйлап түбән таба... Кайтып төшсәң иде Казанга... Дөрес, Идел монда Казан тирәсендәгегә караганда таррак. Ләкин ул барыбер Идел! Идел... Габделнур әле аның үзен күргәнче үк җырларда ул елга турында ишеткәне бар иде. Аның әнисе бик моңлы итеп җырлый торган иде ул малай чакта. «Идел бит ул, Идел бит ул, Идел бит ул, киң бит ул. Караңгы төн, болытлы көн, без аерылган көн бит ул...» Уртанчы малаеның тальян гармунда уйнарга өйрәнгән иң беренче көе дә «Идел бит ул...» иде. Бары соңрак кына егет аның «Су буйлап» дип аталган, Бөек Ватан сугышы чорында барлыкка килгән татар халык җыры икәнен белде. Никадәр моң һәм

сагыш салынган бу җырга... Габделнур, янында кем барын да, кайда басып торуын да онытып, күкрәк тутырып киң сулап, кычкырып җырлап җибәрүдән үзен чак кына тыеп калды. Ә җырлыйсы килә... Ярсыган йөрәкне ни беләндер тынычландырасы, түзә алмаслык мизгелләре булган сагыну хисен җыр белән басасы килә... Үзе генә булса, ул һичшиксез шулай итәр иде. Җыры-көе генә түгел, сүзләре дә телгә килеп тора бит аның: «Сары каеш билләрдә лә, җилфердәми җилләрдә. Сандугачлар да сайрамый сез булмаган җирләрдә...» Хәер, монда да сандугачлар сайрый торгандыр. Су буеннан искән тымызык җилдә сизелер-сизелмәс кенә чайкалучы, яфракларын серләштерүче агачларда ниндидер кошлар аваз сала бит. Араларында сандугачлар да буладыр.

Шулчак башта каяндыр еракта ишетелгән кебек, ә аннары янәшә генә җыр агыла башлады. Җыр сузучы Зоя иде.

Светится город над Волгой,
К морю уходят суда.
Пусть я уеду надолго,
Снова вернусь я сюда.
Пахнет прохладой вечер
Липами темных аллей,
Здесь непременно я встречу
Старых и новых друзей.
Ярославская сторонка,
Ярославская земля,
Я иду дорогой звонкой,
Там, где юность шла моя.
Здесь ждала меня подруга,
Здесь живет любовь моя —
Ярославская сторонка,
Ярославская земля.

Егетнең, әсәрләнеп, ерак-еракларга җәелеп аккан елгага карап торуын Зоя үзенчә аңлады, юньлегә юрады: «Волга бик ошады, ахры».

— Матурмы? — дип сорады ул, егеткә яннан карап.

— Әйе.

— Анда җәен-кышын балык тотарга була. Безнең бу якларда Волгага коючы Которосльдән башка да Пахма, Туношна, Солоница, Ить, Черная елгалары бар. Аларда да балык мыжгып тора дип сөйлиләр. Безнең эштә бер хатынның ире балыкчы.

— Кара елга дидеңме?

— Әйе.

— Кызык. Ленинград өлкәсендә дә Кара елга бар.

— Беләм. Пушкинның дуэле шунда булган.

— Анда берничә Кара елга бар.

— Кызык.

— Күрәсең, сазлык урыннарда суның чиста булмавына, төсе дә караңгырак булуга ишарә рәвешендә исем кушылгандыр.

— Әйе, безнең якта да сазлыклар бар. Аның каравы черника, клюква күп...

Хатынның һәр сүзенә мәгънә салып егет тирәсенә ятьмә корып маташкан көне. Әләгерме ул аңа? Алдагысын Алла белсен... Аның ефәк бавы нык булырмы? Әллә беренче тартылуда ук шартлап өзелерме?

Чатырда тыныч. Көн җылы. Артта ишетелгән шәһәр гөрелтесенә теплоход гудоклары авазы килеп орына. Су буеннан өзлексез җил исеп торганга, салкынча һава биткә килеп бәрелә, агач яфраклары шыбырдый. Яр буенда акчарлаклар чыелдый, су өстендәгеләре каерылып-каерылып очалар, түбәннән генә очып балык күзлиләр, кайберләре өзлексез дулкын уйнаган елгага төшеп тә утыра.

Су уртасында юл-юл булып аксыл эзләр хасил була, дулкыннар белән бергә алар уңга — түбән таба юл алалар. Бер акчарлак, сулга таба карап, агымга каршы утырды. Ләкин агым аны мәҗбүри рәвештә отыры артка таба агызып алып бара. Акчарлак бик озак интегә-интегә арты белән йөзеп барды. Канатларын җилпеп калкынып-калкынып карый да янә суга утыра бахыр. Аны нәрсә тота икән соң һаман шулай: тәмле балык күзлиме, башка сәбәп карышырга мәҗбүр итәме? Ахырда агым аны үз уңаена борды. Әмма, бераз агып баргач, горур кош, буйсынасы килмичәме, ак канатларын тиз-тиз җилпеп, судан күтәрелде, түбәннән генә беркавым очып барды һәм әкренләп югары үрләде — каты томшыклы, «кара эшләпә» кигән башын алга сузып, ерак-еракка очып китте. Габделнур аны, сокланып, тавыш-тынсыз гына озатып калды.

Зоя үзенчә егетне кызыксындырдым дип уйласа да, асылда киресе килеп чыкты, ахры. Казан ягына агучы Иделне, әнисен, үзенең балачагын искә төшерүләр Габделнур күңелен янә бер алгысытып җибәрде. Табигате

күңеленә хуш килсә дә, ул кайдадыр читтә яши алмас иде. «Матур булса да торган җир, сагындыра туган ил», — дип, юкка гына җырламаганнардыр зимагорлар, иленнән аерылганнар...

Кузгалдылар. Яр буендагы юан-юан юкә агачларыннан хуш ис бөркелә. Киң сукмактан ял итәргә чыккан яшьләр, гаиләләләр атлый, карт-коры эскәмияләрдә утыра, асфальт юлдан машиналар уза. Яр буе урамында, ике-өч катлы таш йортлар бетүгә, сул кул якта Иделгә карап басып торучы бөек шагыйрь Некрасов пәйда булды. «Я лиру посвятил народу своему» дигән сүзләрен гранит ташка язып куйганнар. Һәйкәл артында сквер — юкәләр үсеп утырган, чиста аллеялы, эскәмияләр тезелешкән бакча. Шуның аша шәһәр эченә керделәр һәм... Кызыл мәйданга килеп чыктылар. Дөрес, анда мавзолей юк, шулай да шартын китергәннәр — уң кул яктагы постаментта Ленин бабай басып тора, ә каршыда балконлы биек янгын каланчасы...

— Хезмәтеңне бетергәч, шәһәрдә эш табуы проблема булмас, — дип куйды аңа елышып утырган Зоя, трамвайда барганда. — Барысы да синең теләктән тора...

Ләкин ул артыгын җәелеп сөйләшмәде. Үзенең соңгы сүзләренең ничек тәэсир итүен дә белә алмады, әле егетнең ел ярым диярлек солдат шулпасы да чөмерәсе бар. Дөрес, әгәр аның белән тормышын бәйләргә уйласа, әтисен үгетләп, аның элек күрсәткән хезмәтләрен эшкә җигеп, егеткә бер ел узуга ук — сентябрьдә, ягъни министрның приказы чыгу белән үк — дембель оештырырга була...

— Әйдә бер җиргә кереп чыгабыз.

Моңарчы дәшми барган, шулай да хатынның киная белән әйткәннәреннән нәрсәнедер төшенә башлаган Габделнур, уеннан бүленеп, кисәк кенә сорап куйды:

— Кая?

— Миңа. Тулай торакка.

— Соңга калмыйбызмы? — диде солдат, яңа браслетлы иске сәгатенә карап, чөнки ул вакытында кайтып җитәргә тиеш.

— Өлгерербез.

...Трамвайдан төшеп, җәяү киттеләр.

— Әнә безнең «Красный Перекоп» проходное, — диде Зоя һәм, алга таба ымлап, каршыдагы ике катлы бинага төртеп күрсәтте. — Мин шунда эрләү цехында эшлим.

— Без фабрикага керәбезмени? Тулай торак эчтәмени?

— Юк инде, юләрем минем! — диде хатын, серле, назлы тавыш белән. — Бүтән җирдә...

Сул кул якта өч катлы яңа ак йорт, ә унда кызыл кирпечтән корылган иске озын бина сузылган. Алар фабрикага таба китмәделәр, ә ак бинага җитәрәк Стачкалар урамыннан сулга борылдылар һәм бераздан Бахвалов урамына килеп чыктылар.

Биш катлы таш йорт. Керделәр. Исәнләшкәч, вахтер карчыкның колагына иелеп нидер әйтте Зоя. Читтәрәк торган Габделнурга карап алды. Вахтер да аңа күз төшерде. Зоя, имән бармагын иреннәренә тидереп, карчыкка тагын нидер әйтте. Тегесе башын як-якка чайкап куйды. Алар янә пышылдашып алдылар.

— Әйдә, өскә менәбез, — диде Зоя, егет янына килеп.

— Бар, солдат, кер, — диде вахтер, алар узып киткәндә.

Аерым бүлмәдә тора икән хатын. Әллә ни җиһазлы түгел. Уң почмакта шифоньер, каршыда, тәрәзәгә якын җирдә, өстәл, урындыклар, стена буйлап ике якта ике карават: зур, тимере — үзенекедер, ә кечкенәсе, агачы — баласыныкы булса кирәк. Хатын тиз генә чәй хәстәрләде, тумбочкадан шешә чыгарды... Ләкин ашау-эчү белән озак мавыкмадылар. Бер рюмка тоткач та Зоя, урыныннан торып, елмаеп, егет каршына килеп басты. Аны итләч, дымлы куллары белән әкрен генә тартып дигәндәй торгызды, кайнар беләкләре белән муенына сарылды, үзенең дәртле иреннәрен егетнең иреннәренә тидерде...

Бик озак үбешеп торганнан соң:

— Чишен, — диде ул, сихри ләззәт вәгъдә иткән йомшак, назлы тавыш белән.

Үзе дә тиз генә бөтен киемнәрен салып атты. Габделнурның анадан тума хатын-кызны болай якыннан беренче күрүе иде. Дөрес, Алабугада укыганда ук Кама буенда комда кызынып ятучы кыз-кыркынны күргәләде. Шәрә хатыннар сурәте төшкән открыткалар да кулына эләккәләде. Армиягә киткәндә Татвоенкомат каршында телсез егеттән сатып алганнарын Ленинградта, Флот экипажында «конфискацияләделәр». Пляждагылар су коену костюмыннан булса, открыткадагылары кәгазьдә генә иде. Ә бүген аның каршында тере, зифа буйлы, яшь чибәр хатын...

Тәҗрибәле Зоя, беренче көнне вәгъдә иткәнчә, җай белән генә аңа дәрес бирә килде: хатын-кызны ничек танып белергә, алар белән ничек мөгамәлә итәргә, аның уй-теләкләрен ничек тоемларга, кай төшләрен үбәргә һәм назлап дәртен кузгатырга... Бүген шул дәресләрнең дәвамы булды...

Егет аның кабарынкы сусыл иреннәрен, йомшак муенын, ияк астын һәм колак артын, күкрәк уентысын һәм ими башларын берөзлексез үбә башлады. Хатын киерелеп-киерелеп куя, еш-еш сулыш ала, гәүдәсе өзлексез хәрәкәттә, куллары Габделнурның иңбашларын, аркасын сыпыра, назлый, кисәк-кисәк ухылдап йә ыңгырашып, тырнап та ала... Ул егетне җиде катлы ләззәт күгенең соңгысына чөяргә теләгәндәй кылана: алар тирбәлгәндә панцирьлы сетка карават астындагы чемоданга тиеп-тиеп ала иде...

Аларның тәннәре дымланды, икесе дә тирләп чыктылар, ләкин бер-берен иркәләү, бер-беренә бәхетле мизгелләр бүләк итү теләге әле һаман бетмәгән, дәртләре сүрелмәгән иде... Ниһаять, икесе дә «эштән чыгып», бушанып калдылар һәм тар гына караватка чалкан яттылар...

— Сиңа минем белән рәхәтме? — дип сорады Зоя, күзләрен ачмыйча гына ярым пышылдап.

— Әйе.

— Мин һәрвакыт сине шулай сөярмен... Хәзер, Валентина космоска очкач, безнең фабрика бөтен илгә билгеле. Бәлки, тиздән квартира да бирерләр әле. Инженер-технолог итеп тә куймакчылар үземне, — диде хатын, гомерендә беренче мәртәбә үз-үзен онытырдай исерткеч ләззәт татыган Габделнурның ялангач күкрәген, көчле беләкләрен сыйпап-назлап. — Мин сине яратам. Бик яратам! Гомер буе шулай яратыр идем...

Хатын тәненең һәр күзәнәгеннән дәрт ташып торган хәлдә янә егетнең куенына керде, бөтен барлыгы белән аңа бирелде...

Йомырканы кайсы төшеннән ватсаң да ярый, тәмле генә булсын, дисәләр дә, бу кайда туры килсә, шунда, аулаграк өйдә ятып яки ышыкта аягүрә генә, ашык-пошык, курка-өркә генә бер-береңнең күңелен күрү түгел иде инде. Бүген Зояны бәхет басты: кемдер килеп чыгар яки күрер дип тә курыкмады, кабаланмады, бөтен шартын китереп, якын күреп йөргәне белән аулакта яратышты. Һәм ул, һичшиксез, чын мәгънәсендә канәгатьләнү алды, үзен хатын-кыз итеп тойды. Шул ук вакытта егеткә дә чын ләззәтнең ни-нәрсә икәнен төшендереп күрсәтте. Ярый ла кадерен белсә...

...Ләкин күп тә үтмәде, аларның арасы бозылды.

Габделнур урта мәктәпкә кичке әзерлек курсларына йөри башлады. Зоя, моны белгәч, аның алдагы планнары белән кызыксынды.

— Казан дәүләт университетына юрфакка керергә җыенам, — диде уенда мәкер-фәлән булмаган риясыз егет, беркөнне клубта очрашкач.

Ул бу сүзләрнең тәэсире ничек буласын, әлеге хәбәрне хатын ничек кабул итәсен, кыскасы, алдын-артын уйламады.

— Ничек?

Бермәл аптырап, тораташтай катып калды Зоя. Ничек? Ул бит бу егеткә зур өметләр баглаган иде. Ярославльдә калыр, эшкә урнашыр, киләчәктә аның тормыш йөге арбасын тартыр дип уйлаган иде. Соңгы көннәрдә ул хакта конкрет сүз булмаса да, теге вакытта шәһәргә барып йөрүләре нәрсәгәдер өметләнергә җай калдырган сыман иде. Шулай ук барысы да әрәмгә китте микәнни?.. Ә бит мыштым гына үз кирәген ала бирде... Ни аяныч, Зоя күз алдында торган кыйммәтле бәллүр вазаның — корган уй-планнарының, хыялларының — шушы секундта клуб идәненә төшеп чәлпәрәмә килүен аңлады. Ипле холыклы хатын, кем әйтмешли, гомер кыланмаганны, кисәк дөртләп кабынды, чөнки монда эш читләтеп кенә әйтүдән, кемгәдер ярарга тырышудан узган иде инде. Ул танцевать итүеннән туктады, түгәрәктән читкәрәк чыгып, стенага сөялде.

Аннары кинәт:

— Әйдә урамга, — диде бик нечкәртеп тормыйча һәм чыгу белән пырдымсызланып солдатка ябырылды. — Ярославльдә вуз беткәнмени сиңа? Шул сасы Казанында нием калган сиңа?.. Как сопли с пальца меня выкинуть хочешь?.. Кирәк чакта әвәләдең дә...

Китте, китте тезеп... Хатынның борын яфраклары киңәйде, йөзеннән алсулыгы качты, егет соклана торган зәңгәр күзләреннән зәһәр очкыннар чәчрәгәндәй булды.

Габделнур, ни әйтергә белмичә, аңа карап катты да калды: бу соң улмы, аны яраткан кешеме?

Шулай да солдат сабырлыгын җуймады.

— Кызма әле, — диде ул, Зояны җәлләп. — Ипләп кенә сөйләшик...

Хатын аны бүлдерде:

— Кирәгең бар иде... пеләшкә тарак кебек...

Һәм янә тәтелдәүгә күчте...

Бераздан, зиһене ачылып, чыгырдан чыгуын, ярсып китүен аңлап, әгәр һаман егетне битәрләсә, төпсез чиләккә утырып калачагын сизенеп, хатын яңадан элекке назлы Зояга әйләнде. Ләкин эш узган, егеткә чын йөзе ачылган, үзе әйтергә яратканча, поезд киткән иде инде...

Ялгызы гына өенә кайтып барышлый, Зоя үзенең күбәләктәй очынып йөргән гамьсез елларын исенә төшерде.

Яшьлеге белән, каравыл ротасында хезмәт итүче бер Мәскәү егетенең тасма теленә ышанып, ул аның теләгенә каршы килә алмады. Тәҗрибәсезлеге аркасында (техникум бетерәсе елы иде) буйга да узды. Соңгы айларда кадерле кияү булып өйләренә килеп йөргән сержант, сине килеп алырмын дип, корсагы борынына җиткән Зояны тынычландырып китеп барса да, кабат хәрби шәһәрчектә мыегын да күрсәтмәде. Зояның баласын кочаклап балавыз сыгып утырган минутлары сәгатьләргә генә түгел, тәүлекләргә дә җыелгандыр. Үзенең йомшаклык күрсәтеп алдануына да, атасына кирәк булмаган бала табуына да үкенгән чаклары ай-һай күп булды ялгыз хатынның. Ләкин вакыт дигән дәва барысын да булмаса да, кешедәге байтак җөй-яраларны төзәтә икән. Сержант онытылды, аны башкалар алыштырды. Әмма... Сөткә авызың пешсә, суны да өреп кабарсың, дип әйтәләр әйтүен, ләкин ул тагын башта көн үтсенгә генә очраша башлаган солдатка нык ияләште, үзенчә төрле планнар корды. Һәм менә аннан да колак какты, янә кәкре каенга терәлеп калды.

Зоя, подъездга кергәч, баскычка утырып, язмышын каргый-каргый елады.

Алар кабат очрашмадылар. Зоя үзенә бер матросны ияләндерде, ә Габделнур бөтен күңелен хезмәткә, укуга салды.

Отделение командиры демобилизацияләнгәч, Лукьянчук дилбегәне ефрейтор Гаделҗановка тоттырмакчы иде. Ләкин Габделнур, укуын сылтау итеп, отделение алудан баш тартты һәм үз чиратында Заранканы тәкъдим итте. Аңа шундук кече сержант дәрәҗәсе бирделәр. Шулай итеп, Габделнур дусты кул астында хезмәт итә башлады.

Габделнур әти-әнисе, туганнары белән даими элемтәдә тора — арада хатлар йөри. Менә ул тагын бер хат алды. Ләкин монысы бик еракта — Владивостоктан, энесен армиягә алганнар икән. «Абый, исәнме! Мин Владивосток якларына килеп эләктем, погранвойскага. Безнең часть Посьет дигән поселокта, Кытай белән Корея чигендә. Бер якта Япон диңгезе икән. Монда гел таулар, аларны сопка дип йөртәләр, урманнар калын. Диңгездә безнең колак ишетмәгән кальмар, гребешки, йолдыз, омар күп, ди. Аларны әле күргән юк, насыйп булса, татып та карарбыз. Ә менә татар өрәңгесе дигән агачны күрдем...

Көннәр җылы, алай зарланырлык түгел. Хезмәт җиңел булмас инде. Машинага утырсам гына. Ярар, дөнья күреп кайтырбыз. Старослужащийлар мактана: «Не каждому дано ходить по последнему метру родной земли», — диләр. Служба почетный инде анысы. Әлегә обижать итмиләр, без күбәү бит, район егетләре дә бар. Корал белән нәрәткә йөргәч, солдатлар тату яши, диләр. Элек, без бәләкәй чакта, хәтерлисеңдер, дөнья читенә барып, яр буенда аякны асылындырып утырсаңые дип хыяллана идек. Менә теләккә ирештек. Мин хәзер шунда инде. Владивостокта булган егетләр, анда Казанский собор бар, диләр. Ул нәрсәдер, әле күргән юк. Ярар, кыскача сәлам хаты тәмам. Әтиләргә, абыйларга һәм апаларга да яздым. Әтиләргә юлдан да язып салганыем. Без поезд белән бик озак килдек бит. 17 декабрь, 1963 ел».

Габделнур энесе өчен артык хәсрәтләнмәде, югалып калмас. Ә менә әнисе ничек түзә икән? Өченче малае хәрби хезмәттә. Әле уртанчысы кайтып җитмәгән, инде төпчеген дә алганнар. Бер ана өчен күбрәккә китә шул. Сагынганда карарга янында бер баласы да юк, ичмаса. Олы улы ешрак кайткалап китсә инде. Кызының, якын булса да, үз тормышы бар, ул да еш килалмас, кеше кешесе. Әнисенең балаларын ничек яратуын телдән әйткәне булмаса да, Габделнур моны һәрчак тоеп яшәде. Аларны бергә күрсә, аның йөзе тагын да нурлана, күңеле күтәрелә, хәтта үзалдына көйләп тә йөри башлый иде. Берчакны, Габделнур абыйсы белән ишегалдында сөйләшеп утырганда, әнисенең алар яныннан: «Ике каен янәшә, яфраклары шаулаша; ике туган очрашса, сандугачтай сайраша», — дип үтеп киткәне хәтерендә. «И газиз әнкәйләр! Ходай Сезгә сабырлык бирсен!»

Энесеннән хат алганның өченче көнендә, декабрь ахырында, тагын янгын чыкты. Бу юлы авылда бер мунчага ут капты. Ләкин Лукьянчук егетләре эшне тиз тоттылар: мунча исән калды; өйгә һәм каралты-курага да үрләргә ирек бирмәделәр; күршеләренә дә җәбер-җәфа килмәде.

## 17

Авыл кешесе район үзәгенә килгәч, районда яшәүче бәләкәйрәк кенә булса да калага барып чыккач, ә инде бу шәһәрчекнеке өлкә яки республика башкаласына юлыккач нинди тойгылар кичерсә, Габделнур да, Мәскәүгә килеп төшкәч, шул халәттә иде. Ул инде тормыш баскычларыннан үрмәли-үрмәли хәтта Ленинградны да күрү бәхетенә иреште, ә Мәскәүне — юк. Шуңа күрә ул Ярославль вокзалында поездан төшеп, өч вокзал мәйданына килеп чыккач, авызын ачып дигәндәй хәйран калды: мондагы иркенлек, матурлык, берөзлексез машиналар һәм трамвай-троллейбус агылышы, һич туктый белмәгән һәм әрле-бирле килүче халык ташкыны ыгы-зыгысы аның игътибарын җәлеп итте. Әйе, авыз ачып карап торырлык иде шул. Кая карама — биек йортлар: очлы манаралы, шакмаклы, күп катлы, искеләре, яңалары, йөзләгән тәрәзә уелганнары... Ә инде Казан вокзалының бинасын күргәч, ул аптырауның соңгы чигенә җитте: Сөембикә манарасын монда китереп утырткаңнар түгелме соң?

Ул манараны Габделнур беренче мәртәбә Казанга килгәч күргән иде. Аны — Чупай таш карьерында машинист ярдәмчесе булып эшләүче егетне — яшь төзүчеләрнең республика слетына делегат итеп сайлаганнар иде. Слетның рәсми өлеше тәмамлангач, шәһәр буенча экскурсия булды. Шул чакта ул шанлы Казан каласын, биек таш диварлы борынгы Кремльне һәм тарихларга кереп калган гүзәл ханбикә Сөембикә исеме белән бәйле мәшһүр манараны күргән иде. Ә икенче тапкыр ул аны, хәрби хезмәткә алынып, Казаннан поезд белән киткәндә вагон тәрәзәсеннән генә күреп калды. Менә тагын очрашу! Дөрес, бу Сөембикә манарасының үзе түгел, фәкать шуңа охшатып төзелгән дүртпочмаклы, сигез ярусы корылма гына. Шулай булса да күңелгә якын икән...

— Гаделҗанов, артка калма!

Габделнур туктап ук калган икән. Куып җитте.

— Иптәш өлкән сержант, — диде ул аларны Мәскәүгә алып килүчегә, — бу безнең Казандагы бер бинага охшаган!

— Булыр, булыр. Тик син бездән калма, адашырсың.

Ефрейтор Гаделҗанов белән тагын бер өлкән матросны партиягә алырга тиешләр. Аларның часте турыдантуры Мәскәүгә буйсына, һәм үзәк политидарә дә бирелдә иде. Кандидатлыкка частьта гына кабул итсәләр, партия әгъзалыгына алу — Габделнур өчен истәлекле вакыйганың иң мөһим өлеше — Мәскәүдә икән. Аларны частьның партком әгъзасы, тиешле срогын тутырганнан соң килешү нигезендә хәрби хезмәттә калган (солдат-

матрос аларны «макаронник» дип кенә йөртә), утыз биш яшьләр тирәсендәге өлкән сержант Гигевич озата килде.

Габделнурны тагын да гаҗәбрәк могҗиза көткән икән әле — ул, үзйөрешле баскыч-эскалатор белән җиде кат җир астына төшеп, метроны күрде, вагонга утырып, берничә станция үтте. Тавыш-тынсыз диярлек, шаушусыз гына чаба да чаба икән ул метро поезды. Станциядә дә озак юанмый: ягымлы гына хатын-кыз тавышына буйсынып, төшәселәрен төшереп, утырасыларын үзе белән ала да китеп тә бара... Һәр станция үзгә, әмма зәвык белән бизәлгән, кая карама төрле төстәге таш та мәрмәр, ялтыравык плитә, рәсем, сыннар... Гаҗәп инде... Бинаһая зур, зиннәтле заллар... Әкиятләрдә генә укыганы бар иде Габделнурның андый могҗизалы патша сарайлары турында... Үзләре җир астында, үзләре яп-якты... Әллә бу әкият микән дип тел шартлатырсың, төш кенә түгел микән дип колагыңны чеметеп алырсың...

Җир өстенә чыгып, янә әйләнә-тирәгә күз салгач, чуар халык төркемнәренә карагач, Габделнур ачыш ясагандай булды, ирексездән үзалдына елмаеп куйды. Чөнки кечкенәдән үк Мәскәү каласы аның ише авыл балалары өчен буй җитмәстәй хыял иде. Ул гына да түгел, малайлар анда гади кешеләр яшәми дип бәхәсләшәләр иде. Күбесе башкалада фәкать профессорлар, язучылар, артистлар, генераллар һәм ил җитәкчеләре генә көн күрә дип күзаллыйлар иде. Баксаң, монда да бик күп төрле һөнәр ияләрен һәм гади генә кешеләрне дә очратырга була икән...

Аннары, авыл укучылары, Май һәм Октябрь бәйрәмнәрендә, урам яңгыратып, үзләре күрмәгән ерак шәһәрләр турында җыру җырлап йөриләр иде:

Ленинград — Москва,
Урамнары таш кына;
Кызыл гаскәр фашизмны
Бетерергә ашкына.

«Урамнары таш түгел, асфальт икән», — дип көлеп куйды егет.

Өлкән сержант аларны политидарәгә алып килде. Кат-кат инструктаж узып, устав һәм программа текстларын күңелләреннән янә бер кабатлап, соңгы инстанциягә җиттеләр — зур гына бүлмәгә керделәр.

Кеше шактый күп — барысы да хәрбиләр, флот киеменнән. Өлкән сержант Гигевич үз эшен җиренә җиткереп башкарды — анкета кәгазьләрен укып чыкты. Аннары өстәл артындагылар сорау яудырырга тотындылар.

Габделнур аларның устав, программа һәм халыкара хәл буенча бирелгән һәр соравына чатнатып җавап бирә торды.

— Ни өчен партиягә керәсең?

Анысына да үзләре көткән җавапны ишеттеләр.

— Коммунизм төзүчеләрнең алгы сафларында булыр өчен.

Барысы да канәгать калдылар. Шул вакыт иңнәренә беренче ранг капитаны погоннары таккан, күзлекле, өлкән яшьтәге берәү кулындагы кәгазьдән аерылмыйча гына сорау бирде:

— Сезнең биредә, иптәш ефрейтор, ВЛКСМ сафларында мең тугыз йөз илле бишенче елдан дип язылган, ә туган елыгыз — кырык ике. Минем белүемчә, комсомолга ундүрт яшьтән алалар иде. Аңлатып үтсәгез иде. Бәлки, илле алтынчы елдыр? Монда ялгыш язылгандыр...

Габделнур, каушамаска тырышып, алдагы сорауларга биргәндәге кебек, үз-үзенә ышанып җавап кайтарды.

— Элек өлгереше начар укучыларны икенче елга утыртып калдыру гадәте бар иде, — диде ул, кәгазеннән арынып, күзлеге белән аңа баккан беренче ранг капитанына. — Аннары, кайберәүләр, өсләренә кияргә кием булмау сәбәпле, кыш көне укырга йөрмәделәр дә класстан класска күчми калдылар. Шунлыктан классташ малайларның күбесе миннән бер-ике яшькә олы иде. Алар, ундүрт-унбиш яшьләре тулгач, комсомолга керде. Алардан каласым килмичә, мин дә гариза яздым.

Күзлекле карт коммунист бирешмәде.

— Ә ничек унөч яшьтән алдылар?

Габделнур, күзен дә йоммыйча:

— Мин анысын әйтә алмыйм, — диде.

Ә чынлыкта исә аның туган елын, бер яшькә арттырып, кырык беренче елгы дип гариза яздыртканнар иде. Монысын әйтмәскә Габделнурның башы эшләде.

— Ә комсомол билетыгыз мондамы?

«Булса да булыр икән бәйләнчек кеше» дип уйлады Габделнур һәм тәмам коелып төште.

— Юк, — диде ул, шүрли калып.

Аны кабул иттеләр. Өлкән сержант Гигевич җиңел сулап куйды. Өстеннән тау төшкәндәй булды.

Эшләрен бетереп урамга чыккач, ул түзмәде:

— Үткен егет икәнсең, — дип мактады. — Янганын көтмичә, очкынын сүндердең.

Өлкән матроска алай күп сорау биреп тормаганнар, җиңел котылган.

Троллейбуска утырып, шәһәр карарга киттеләр. Габделнурның күзе урамда булса да, күңеле белән ул әле политидарәдә иде. Егет бераз вөҗдан газабы кичерде. Ләкин үз-үзен акларга да тырышмады. Чөнки «ни өчен

КПСС сафларына керәсең» дигән сорауга ул һич шөбһәсез чын дөресен әйтте. Аның бүтән максаты юк, аңа партиядән берни дә, һичнинди ташлама да кирәк түгел иде. Кайберәүләр кебек, алда ни буласын чамалап, шуңарга әзерләнүне дә максат итеп куймады. Гәрчә Габделнур андыйларны да күрмәде түгел.

Каравыл ротасында хезмәт иткәндә, Баринов фамилияле күп сөйләшергә яратучы бер елгыр егет бар иде.

Ул бүтән солдатлар кебек лезвие белән кырынмый, ә җыелмалы бритва куллана иде. Аны, нәкъ авыл агайлары кебек, бил каешына ышкый-ышкый үткенләп, ияк-яңагын күбекләп көзге каршына баса да, сул кулы белән битен, ияген, борынын тоткалап, тиресен тартып кырына иде.

Ул Габделнурдан өч яшькә олы, ике ел төрмәдә дә утырып чыгарга өлгергән. Һәм шул егет тиз генә комсомолга керде, актив булып китте.

— Нигә кирәк ул сиңа? — дип сораучы хезмәттәшләрен шаккатырып, чын дөресен әйтеп салды.

— Тагын бер елдан партия членлыгына кандидат булам, ә дембельне коммунист һәм сержант дәрәҗәсендә каршылыйм.

— Шуннан? — диде кемдер, астыртын көлемсерәп.

Баринов турыдан ярды:

— Ә шунсыз үсеп, карьера ясап булмый.

— Син утырып чыккан бит...

— Ә кем белә аны? Минем инде хәзер үк судимость алынган. Миңа чип-чиста булып кайтырга кирәк.

Габделнурның исә уенда андый еракка китә торган планнар юк иде. Ул бары олуг идеалларга тугрылыклы булырга, илгә мөмкин хәтле күбрәк файда китерергә генә теләде.

Яшь коммунистлар ефрейтор Гаделҗанов белән өлкән матрос кына түгел, өлкән сержант үзе дә кайтырга бик ашкынып тормый иде, ахры.

— Егетләр, әле тагын киләбезме-юкмы, әйдәгез, шәһәр карап йөрик, — диде Гигевич, яшьләрне сөендереп.

Чиратсыз гына (кизү торучы милиционерлар рөхсәт итте) мавзолейга кереп, Ленин бабайның саргылт, әмма «нурлы» йөзен карап чыктылар. Габделнурның исенә төште: мәктәптә, исемен дөрес итеп әйтә дә белмәгән вакытта ук — башлангыч классларда, алардан шигырь ятлаталар иде: «Лилин бабай тыныч йокла Мавзолееӊ эчендә». Әйе, тыныч кына ята икән «Лилин» бабай.

Ополчение оештырып, Мәскәүне поляк баскыннарыннан азат итәргә килгән Минин (Түбән Новгород халык ополчениесенә 1611 елның 2 мартында татар кенәзләре һәм морзалары да килеп кушылган) һәм этник татар булган Пожарский һәйкәле янында фотога төштеләр. Кремльгә килгән туристларның игътибарын җәлеп итүче, Рәсәй империясенең зурлыгын, бөеклеген күрсәтүче, әмма бер тапкыр да атмаган царь-пушканы һәм үз вазифасын үтәмәгән — чаң какмаган царь-колоколны карап чыктылар. Кыскасы, авызларын ачып, башларын күтәреп, әледән-әле алан-йолан як-якка каранып, шактый озак тинтерәп йөрделәр.

Василий Блаженный соборы янында туристлар бар иде. Егетләр төркемнең артына килеп бастылар да, гидның аңлатуын тыңлап, тыныч кына басып тордылар. Ләкин экскурсоводның бер сүзенә Габделнур рәнҗеде.

— Бу собор Казанны җиңү хөрмәтенә салынган, — диде төркем алдында басып торган, аларга карап сөйләүче ырмаулы күзлек кигән хатын.

Габделнур түзмәде. Чөнки кылт итеп техникумдагы тарих укытучысының сөйләгәннәре исенә төште.

— Гафу итегез, нинди җиңү хөрмәтенә?

Хатын, күзен дә йоммыйча:

— Мең биш йөз илле икенче елгы, — диде.

— Минем белүемчә, ул Казанны басып алу елы, — диде Габделнур, аңа таба борылып караган туристларның барысы да ишетелерлек итеп.

— Барыбер түгелмени? — диде гид, бирешергә теләмичә.

— Җиңү белән басып алу — икесе ике нәрсә, — диде Габделнур да, үз сүзен сүз итәргә теләп. — Берлинда, Триптих паркында, совет солдатына һәйкәл куелган. Менә ул фашистик Германияне җиңү хөрмәтенә.

Туристлар, алар Мәскәү тирәсендәге берәр өлкәдән генә иде булса кирәк, башта таркалып калдылар, аннары шаулаша, ризасызлык белдерә башладылар.

Өлкән сержант, шыпырт кына:

— Ефрейтор Гаделҗанов, бик эчкә кермә, — диде. — Әйдәгез киттек.

Бераз дәшми бардылар. Белорус егете Гигевич Габделнурга астыртын гына күз салгач әйтеп куйды:

— Син карап торуга гына гади икәнсең. Хәер, мин сине аңлыйм. Атасы балыкчы икән, баласы да суга карый бит. Тик син яңадан бу хакта беркайчан да, бер җирдә дә авыз ачма. Кыен ашарсың. Чыпчык дип кенә әйтсәң дә, торна дип арттырырлар.

Алар белән янәшә атлаган озын буйлы өлкән матрос дәшмәде. Күрәсең, мие сыеграк һәм боларның сөйләшүенең мәгънәсе аңа барып җитми иде.

...Мәскәү артта калды. Юл буенда, үзәнлектә, урман. Поезд тиз үтеп киткәндә, урмандагы агачлар әйләнбәйлән уйнаган кызлар кебек артта калалар. Зифа буйлы, ак күлмәкле, коңгырт челтәр яулыклы кызлар — каеннар, сыек яшел тар күлмәкләре — усаклар, ә киң итәкле куе яшел күлмәк кигәннәре — чыршылар. Әйтерсең бөтен үзәнне, аланны тутырып кызлар хоровод әйләнә.

Габделнурның исенә туган авылы, кичке уеннар төште... Шушы агачлар кебек гади, эчкерсез, гүзәл авылдаш кызлары да хуш исле болында төрле-төрле уеннарда җырлап-биеп күңел ачалар, ачлы-туклы тормышларына аз булса да ямь өстиләр иде...

Бераз баргач, юл буена су чыкканы күренә. Тәбәнәк куаклар су эчендә утыра һәм аларның судагы шәүләләре әйтерсең аларның як-якка җәелгән тамырлары... Агач, куаклар никадәр биегрәк булса, «тамырлар» да шулкадәр тирәнгәрәк киткән сыман.

Габделнур үзен шул биек агачлар, суда чагылган «тамырлар» кебегрәк хис итте. Менә хәзер тагын бер баскычка күтәрелде сыман. Йөзләгән солдат-матрос арасыннан икәве генә, Мәскәү хәтле Мәскәүгә барып, партиягә керделәр. Бу инде бик күп бурычлар йөкли, ил-көн алдында йөзең кызармаслык итеп хезмәткә күңелеңне, бар осталыгыңны бирергә тиеш буласың... Монысы — агачның өске өлеше. Ә аскы ягы — Габделнурның да «тамырлары» ныграк җәелгән сыман — ул аягында нык басып торадыр кебек, ни генә кылса да, аның гамәлләре ил тормышы белән бергә үрелеп бара, миллионлаган партия әгъзалары белән алар олы эшләр майтарырга сәләтле кешеләр.

Сулыкларда болытлар да чагыла.

Урманда әле кар ята.

Авылларда, басуларда анда-санда кар эрегән, җир ачыла башлаган. Көздән куйган печән богыллары йә яртылаш, йә аста аз гына калган, йә баганалары гына утырып тора.

Урман эчендә атлы чана юллары, тирә-юнендә кары эреп, каралып, күтәрелеп калган...

...Бер караганда, солдат хезмәте ялыктыргыч бертөрлелек белән барырга тиеш кебек. Ләкин ил-көн бар, дөнья бар дигәндәй, булып узган һәр вакыйга армия-флот тормышында да чагылыш тапмыйча калмый. Узган ел КГБ хезмәткәре, подполковник дәрәҗәсенә хәтле күтәрелгән Пеньковскийның ЦРУ һәм Англия разведкасына сатылуы мәгълүм булды. Шуннан соң бөтен частьларда тикшерү-күзәтү, аңлату-тәрбия эшләре көчәйтелде. Американың җиңү белмәс штангистлары «күтәрү краны» Пауль Андерсенны, «тимер гавaец» Томми Кононы егып салган Юрий Власов һәм Казан студенты Александр Курыновларның фантастик күрсәткечләре, атаклы Валерий Брумельның биеклеккә сикерү буенча тагын дөнья рекорды куюы яшь егетләрне спортта яңа казанышларга этәрде. Габделнур да чаңгы һәм үзләренең янгын сүндерү-гамәли спорты ярышларыннан тыш янә берничә төрдән разрядка тапшырды. Частьта бер әрмән егете оештырган бокс секциясенә язылды, борыны җимерелгәч тә анда йөрүдән туктамады. Кайчагында, занятиеләрдән соң, йоклаганда саташып, хук, свинг, апперкот дип кычкырып та уянып киткәли иде. Итальян малае Робертино Лореттиның җир буе сузып «Ямайка» җырын башкаруын ишеткәннән соң Габделнур да «Җәмәйкә, Җәмәйкә» дип борын астыннан шыңшып йөри торганга әйләнде.

Ә хәрби тормыш элеккечә дәвам итте: тревогалар, өйрәнүләр, казармада уен-көлке сөйләшеп утыру, плацта сафта йөрү, солдат тормышын төрләндерергә омтылу... Шуларның берсе, мисалга, сәгать алмашу. Ул әледән-әле булып тора. Әйтик, берәү икенче солдат каршына килеп баса да, сәгатен уң кулы белән каплап:

— Шух, карамыйча гына? — ди.

Риза булганы әйтә:

— Шух.

Алмашалар. Ә алмашасы килмәгәне, үзенең әле сыкрап булса да йөреп ятучы сәгатеннән колак кагасы килмәгәне, әдәп саклап тормый (үз иптәше бит):

— Хрен на хрен менять — только время терять, — дип ярып сала.

Габделнурга, алыш-биреш итә торгач, Ленинградта, Флот экипажының подвалында «все мосты разводятся, а Поцелуев — нет» дип көйләп утыручы салмыш рәссам корабль сурәте төшереп биргән үз сәгате килеп эләкте. Һәм ул аны яңадан беркемгә дә тәкъдим итмәде, үзенә төбәлгән «шух»лардан да баш тартты.

Хезмәттән тыш икенче мөһим эше — әзерлек курсларында укуы да җай гына барды — май ахырында ул аны әйбәт кенә тәмамлады.

Шуның өстенә, үзләрендә хромка гына булганлыктан, көндезләрен клубка да сугылгалый һәм, онытып бетермәс өчен, берәр сәгать баянда уйнап кайта иде.

**18**

Мең тугыз йөз алтмыш дүртенче елның август ае. Габделнур Казанга кайтты. Бу көнне ул зарыгып көтте. Хәер, ул армиягә китәсен дә көтеп алган иде. Чөнки армиягә бармау ул хурлык санала. Армиягә алынмаган егетләргә кызлар «нигүҗин» дип кенә җибәрәләр. Күбесе аның «не годен» дигән урыс сүзеннән бозып әйтелгәнен белмидер дә. Андый сүзләр безнең телдә байтак бит. Әйтик, берәр авыл корткасыннан урысча белү-белмәвен сорасаң, һичшиксез, юк, дип җавап кайтарачак. Шулай да бик ачуы килгәндә, әбекәй, әй эсминҗә, дип тә тиргәштерергә мөмкин. Шуның шикелле, армиягә яраксызлар халык теленә «нигүҗин» булып, ак билетлы «хәчтерүшләр»гә әйтелә торган мәсхәрәле сүз булып кереп калган.

Егетләрнең дә байтагы армиягә алынмавына кимсенә, үзен хезмәт итеп кайтканнардан түбәнрәк саный. Чөнки монда калганнар өч-дүрт ел (элегрәк дүрт-биш ел иде) эчендә әллә ни үзгәрми: ни гәүдәгә, ни йөз-кыяфәткә, ни сүз-сөйләмдә. Ә тегеләр... буйга үсеп киткәннәр, җилкә-күкрәкләр киңәйгән, арка турайган, кигән кием дә үтүкләнгән, чиста, төймә-аеллары елык-елык килеп тора, итек-ботинкалары көзге кебек... Акыл

утырткан бу егетләр (күбесе тыныч тормышта кирәк булырдай һөнәр дә үзләштереп кайткан) белән элек хәрби хезмәттә булып кайткан агайлар гына түгел, ә авыл күрке булган аксакал картлар да һич тартынмый гәп кора, олылап эндәшә, үз тиңе саный. Ә кызлар...

Габделнур, техникум бетергәч, беркая укырга кермичә, ике ел эшләп, армиягә китте. Әмма укырга кирәген беркайчан да исеннән чыгармады: соңгы елны аның кулыннан китап төшмәде. Һәм өченче елны, рапорт язып, укырга җибәрүләрен сорады. Частьта аның гозеренә колак салдылар. Әлбәттә, әгәр ул, кем әйтмешли, шәләйвәләй генә, көн үтсенгә генә йөргән булса, аны беркем дә беркая да вакытыннан алда җибәрмәс иде. Ләкин Габделнурның кечкенә солдат чемоданы хәрби-политик хәзерлек һәм спорттагы уңышлары өчен бирелгән мактау кәгазьләре, ә күкрәге значоклар белән тулган иде.

Шуңа күрә университет дигән затлы, ымсындыргыч мәшһүр уку йортына сынау бирергә Казанга кайтты ул. Әле кайсы бүлеккә диген — юридическийга — Ленин укыган факультетка.

...Яртысы диярлек хәрбиләрдән, ә калганы гражданский киемле егет-кызлардан торган төркем сынау буласы бүлмәгә-аудиториягә кереп кенә утырды — шундук укытучыны коридорга чакырып чыгардылар.

Ул озак юанмады. Керде дә, җитди генә:

— Барыбыз да урамга чыгабыз, — диде.

Бер сабырсызы сорау бирде:

— Нигә?

— Никита Сергеевичны каршыларга.

Егет-җилкенчәк аякка җиңел халык: дөбер-шатыр китереп, урындыкларны күчергәләп, коридорга чыктылар да аска төшеп киттеләр.

Тышта инде гүя сабан туе — урамның ике ягына да халык тезелешә. Габделнур үзе кебек солдат-матрослар — хәрбиләр белән урам аркылы чыкты да юл кырыена басты.

Ул әйләнә-тирәгә күз салды. Каршыда юан-юан колонналы дүрт катлы уку бинасы. Аны «химкорпус» дип йөртәләр икән. Уң якта түбән таба берничә тәбәнәк бина тезелешкән һәм юл да аска төшеп китә. Сул кулда урам аркылы янгын сүндерү командасы — зур капкалы гаражлар, капкалар каерып ачып куелган; бер кызыл машина урамда ук тора. Аның янында саргылт брезент роба һәм яшел каска кигән егетләр кайнаша. Габделнурга боларны күрү частьта калган иптәшләрен күрүгә тиң иде.

Төрлесе төрле яклардан җыелган урыс, украин, грузин, литва, белорус егетләре җан дуслар булып киттеләр. Моны фәкать үзләре шундый частьта хезмәт иткәннәр генә бөтен тулылыгы белән аңлый аладыр. Чөнки син, кирәге чыкса, ут эченә керәсең, бәлагә тарысаң, янәшәдәге иптәшең сиңа ярдәм кулын сузачагына һәрчак ышанып эш итәсең.

Бик зурлап, матур теләкләр теләп озатып калдылар хезмәттәшләре Габделнурны изге сәфәргә.

Берсе хәтта, шаяртып:

— Яңадан монда кайтма! — диде.

Габделнур бу сүзләргә үпкәләмәде. Чөнки дусларының «укырга кер» дип әйтүләре иде бит.

Үз чиратында ефрейтор Гаделҗанов та аларга беренче карашка гадәтирәк тоелган сүзләрне әйтте:

— Сухих вам рукавов!

Янгын сүндерә торган беләк юанлыгы җитен җиңсәләрне урысча «рукава» дип йөртәләр. Теләге — хәвефхәтәр булмасын диюе, чөнки кайдадыр янгын чыкса, ул җиңсәләрдән су ага бит, алар чылана, юешләнә. Янгын вакытында ни буласын беркем дә әйтә алмый, бигрәк тә утлы корал һәм хәрби техника тупланган җирдә.

...Янгын сүндерү частеннан бирерәк юл аска төшеп китә. Чак кына сулга борылып карасаң, университетның бихисап колонналы тәбәнәк озын бинасын күрәсең... Аның каршында китапханә икән, ә бирге якта бәләкәй генә бакча, уртасында — бөтен гомерен университетка һәм фәнгә багышлаган бөек галим бюсты. Ул, геометрия фәненә тагын нинди ачыш ясыйм икән дигән сыман, башын иеп, уйланып тора.

Габделнур, үзе кебек егетләр белән тегене-моны сөйләшкәләп, ун-унбиш минут вакыт үткән микән, сул яктан бер кара «Волга» машинасы күренде. Аның артыннан өсте ачык алагаем озын җиңел машина килә иде. Ул да кара төстә. Габделнурның телевизордан күргәне бар: Мәскәүдә, Кызыл мәйданда, хәрби парад вакытында оборона министры һәм парад командующие да шундый өсте ачык машинада йөриләр. Аягүрә баскан Хрущевның пеләш башы кояшта ялтырады; машина, алар турыннан узып, уңга — түбән таба төшеп тә китте.

Шулай да Габделнур ил җитәкчесенең уң кулы белән ниндидер тимер терәккә ябышуын, ә сул кулын күтәреп, юлның ике ягы буйлап тезелгән халыкны сәламләвен абайлап алды. Хәер, машина әллә ни кызу да бармый иде. Озын лимузин артыннан тагын бер-ике «Волга» ияргән...

Габделнурның уң ягында олы яшьләрдәге, чал чәчле ике ир-ат тора иде. Күрәсең, университет укытучылары яки профессорларыдыр. Егет аларның үзара сөйләшүенә колак салды.

— Бик тәвәккәл кеше икән.

— Нигә алай дисез?

— Ачык машинада бара бит. Хәтерлисезме, узган елның егерме икенче ноябрендә Америка президенты Джон Кеннедига һөҗүм иттеләр.

— Әйе, әйе, Далласта аны Освальд атып үтерде бит.

— Минемчә, дәүләт эшлеклеләрен ачык машинада йөртмәскә кирәк.

— Ә алар йөриләр, бернигә карамыйча. Димәк, үз халкына ышаналар.

— Бу — башсызлык.

— Бәлки, батырлыктыр? Хрущев егерменче съездда курыкмыйча Сталинны да тәнкыйтьләп чыкты бит.

— Курыкмагач, нигә ул аңа исән чакта хаталарын әйтмәгән? Сугыш беткәч, батыр күбәя, диләр.

— Исән чакта?! Утыз җиденче елнымы?! Хрущевның сөякләре әллә кайчан череп беткән булыр иде инде... Шулай да мин аңа сокланам, коллега. 1959 елда курыкмыйча Америкага барды, иң беренче булып. Аңа кадәр совет дәүләте башлыкларының Штатларга барганы юк иде.

— Анысы белән мин дә килешәм, коллега. «Мы вас похороним» дип тә аларны куркуга салды. Хәлбуки бу очракта ул сугышны түгел, конкурент буларак, безнең системаның өстенлеген күз уңында тотып әйтте булса кирәк.

— Да, кстати, аның турында яңа мәзәк чыккан...

Ак башлы агайлар гәп кора-кора кузгалдылар.

Габделнурның сул ягында торган, зәңгәр погоннарына ике тар сары тасма тегелгән кече сержант татарча:

— Нишләптер абзый караңгы чырайлы, — дип куйды. — Кара көйгән.

Хрущевның йөзе шат түгел иде сыман. Моны Габделнур да абайлады.

— Похмельдәндер, — диде ул, як-ягына каранып. — Сөмсере коелганые шул...

— Баш төзәтергә бирмәгәннәрдер.

Икесе дә көлешеп алдылар.

Тәбәнәк гәүдәле, кара чәчләре фуражка читенә чыгып торган, елтыр күзле кече сержант Габделнурга дәште:

— Син каян?

— Ярославльдән.

— Юк, мин, кайсы районнан, дип сорыйм.

— Сарман.

— Бәттәч, якташ бит алайса. Мин — Мөслимнән. Ирек.

— Билгеле, якташ. Без карантин узганда Оренбург, Куйбышев, Сергач, Ульян егетләрен дә якташ дип йөртә идек. Урыс малайлары, земляк — три лапти по карте, дигән булалар иде. Мин — Габделнур.

Ирек түзмәде, озын буйлы, ыспай гәүдәле, җитди йөзле ефрейторга текәлеп карады да, аның погоннарына ым кагып, сорыйсы итте:

— Бу нинди «Ф» хәрефе?

— Футболист, — диде Габделнур, көлеп.

— Ничек? Спортротаданмыни?

— Юк, шаяртам. Флотка карыйбыз.

— Ә диңгездә йөзәсезме соң?

— Б... кына йөзә, ә моряк диңгезгә йөри, походка бара, — диде Габделнур, матрослардан ишеткән гыйбарәләрне хәтерендә яңартып.

Икесе дә урам яңгыратып шаркылдап көлделәр.

— Ну юмор синдә! Хоть стой, хоть падай!

— Стою — хоть дой! Без — коры җирдә, — диде Габделнур, бераз тынычланып.

— Кызык: үзең — флотта, җитмәсә, солдат киеменнән... — дип, иңбашларын җыерып куйды кече сержант.

Габделнур, иелә төшеп, Ирекнең колагына гына нинди частьта хезмәт итүен әйтте һәм кычкырып өстәде:

— Анда төрлесе бар. Иркенләп сөйләшербез әле.

— Әйе, әнә чакыралар.

Алар җиңелчә адымнар белән каршыдагы бинага кереп киттеләр.

**19**

Үзенә калса, имтиханнарга ул ярыйсы гына әзерләнгән иде. Яшьтән үк тәмәке-аракы белән мавыкмаган тәне таза, зиһене ачык иде аның. Армия хезмәте дә егет-җиләнгә тугарылып китәргә ирек бирми, аннары, уку теләге дә көчле иде. Кулында китап еш булды.

Казанга кайтып, әнисенең туганнан туган апасында торып, сынауга әзерләнгәндә дә ул солдат гадәтен ташламады: иртән һәрчак, җиңел генә спорт костюмы киеп, өй каршындагы скверда физзарядка ясады, салкын су белән коенды. Аннан соң көне-төне диярлек китап «кимерде». Апасының бүлмәсе кечкенә булганлыктан, ул күп вакытын бакчада үткәрде. Ашарга гына дәшеп кертәләр. Аны апасының унбиш яшьлек кызы дәшә.

— Габделнур абый, өйгә кер. Әни ашарга чакыра.

— Ә син...

— Мин дә чакырам.

Каратут йөзле, зифа гәүдәле үсмер кыз оялып китә. Ләкин үпкәләми. Чөнки ул, әнисе белән генә үскәнлектән, абыйсының аларда яшәвенә шатлана гына. Кечкенә буйлы, һәрчак елмаеп торучы әнисе дә Габделнурга гелән генә ачык чырай күрсәтә, хәзинәдә бары белән сыйлый. Егет тә, укудан бушаган араларда, аларның вак-

төяк электр җиһазларын рәтли; душ (бу йортта ванналар юк иде) тирәләрендә тәртип ясады. Бер коридорда өч гаилә торганлыктан, аңа хәтта апасының күршеләре дә вак-төяк йомыш кушкалый иде.

Чәйләп алгач, солдат егет, кулына китап тотып, янә бакчага юнәлә.

— Караңгыга калма, күзеңне бозарсың, — дип кала апасы.

— Ленинград тирәсендә хезмәт иткәндә, дневальный булып торырга туры килсә, мин төне буе китап укый идем. Җәй көне анда ак төннәр була бит.

— Яп-якты идеме? — дип сорый сеңлесе.

— Көндезге кебек үк түгел инде, шулай да китап укырлык.

Һәм Габделнур аңа Ленинград, Кронштадт турында сөйли башлый...

...Соңгы имтиханны биргәч, таныш егетләр белән саубуллашты да Габделнур «Кольцо»га төшеп китте. Анда троллейбуска утырды. Свердлов урамыннан, Татвоенкомат яныннан узганда, армиягә киткән чаклары исенә төште: койма аша сикереп качып чыгулары, иртән тагын килүе, комиссия үтү, андагы шау-шулы болгавыр вакытлар... Аннан китеп барулары: эшелонга төялеп Ленинградка юл тоту, Сызрань шәһәрендә бик озак тукталып тору, акча салышып гармун-гитара алу, тагын юл... Берничә тәүлек буена уен-көлке, җыр-бию белән үткән көннәр... Усал офицерның аракы шешәләрен ватуы, шуннан соң, суга чыккан булып, бер чиләк аракы алып керүләре... Ләкин, ни хикмәт, сугышу, хәтта телгә килү дә булмады шикелле. Һәрхәлдә, истә калмаган.

Университетка керү теләге көчле булса да, яшьлек үзенекен итә: Габделнур артык борчылмады-кайгырмады, керү-кермәү хакында озаклап баш ватмады. Чөнки, бер урынга унике кеше, диделәр. Күрәсең, яшь-җилкенчәкне юридик факультетта уку романтика белән үзенә тарткандыр, ә акыл утыртканнар инде үзләренең нинәрсәгә сәләтле һәм кайсы һөнәрне яратуларын, кулларыннан нинди эш килерен белеп, күптән хәл итеп, бу бүлеккә гариза биргәннәрдер.

Апасы скверда, өрәңге агачлары күләгәсендә, үзе кебек өлкән яшьтәге хатыннар, карчыклар белән эскәмиядә сөйләшеп утыра иде. Аларны монда көн саен күрергә була. Бу тирәдә апалары яшәгән зур, бөтен бер кварталны биләп торган корпустан тыш, эчтәрәк рәт-рәт тезелеп киткән дүртәр катлы тагын берничә йорт бар. Шуңа күрә әби-сәбиләр күп. Габделнур бу карчыклар янында озаграк торырга яки, читтәрәк утырып, чип-чиста татарча сөйләшүләренә колак салырга ярата. Чөнки хезмәтенең соңгы ике елында аңа үз телендә сөйләшергә туры килмәде диярлек. Шуңадыр кайтканда кызык булды.

...Ярославльдән Горькийга баручы поездда төшеп, Казанныкына күчте. Ул поездның утыргычлары автобусныкы кебек иде: йомшак, арка терәрлек биек. Берзаман солдат артта ике хатынның быдыр-быдыр сөйләшүенә игътибар итте. Әүвәл ул аларны казах телендә сөйләшәләр бугай дип уйлады, аннары башкортка тартымрак тоелды, бары соңыннан гына татарча икәненә төшенде. Укый башлаган китабын тезенә куеп, күзләрен йомып, рәхәтләнеп теге хатыннарның әңгәмәсен сеңдереп-тыңлап, кем әйтмешли, сүзләрен урлап кайтты.

...Ләкин бүген сквердагы әби-сәбиләр янында озаклап юанырга вакыты тар иде.

— Исәнмесез, апалар, — диде Габделнур, алар янына килгәч, барысын да күздән кичереп.

Алар аңа төрлесе төрлечә җавап кайтардылар:

— Исәнме, үскәнем.

— Аллага шөкер, улым.

— Үзең исән генә йөрисеңме?

Апасы:

— Икзамыңны ничек бирдең? — дип сорады.

— Әле белмим — язма эш иде. Результатын көтеп тормыйм, иртәгә авылга кайтып китәм. Билет алдым.

Апасы, эскәмиядән торып:

— Өйдә чәйләп ал, — диде. — Мин, базарга барып, күчтәнәчләр алып кайткан идем инде.

Алар сөйләшә-сөйләшә подъездга керделәр.

...Казан аэропортында, халык телендә «кукурузник» дип йөртелгән ике канатлы җиңел самолет бераз гына җирдән җилдереп барды да улый-үкерә һавага менеп тә китте. Зур шәһәрнең бихисап йортлары, шау-шулы урам-мәйданнары, аларны тутырып йөргән меңләгән кешеләре, армый-талмый килеп сарып йөрүче тыгын трамвай-троллейбуслары, автобуслары артта калды. Алда — иркенлек, зәңгәр күк йөзе, күпереп торган мамыктай аксыл болытлар һәм... туган як.

Юлчылар ике стена буйлап тезелгән каты тимер урындыкларга кара-каршы утырганнар. Һәрберсе билен брезент каеш белән буган.

Бер абзый, йөзе белән борылып, авызын аның колагына ук китереп:

— Менә синең шикелле тагын солдат булдык, — дип, Габделнурга эндәште. — Бөтенләйгәме?

Габделнур, самолетның каты тавышыннан уздырырга тырышып, кычкырыбрак:

— Юк әле, абый, — диде.

— Кунакка, алайса. Ярар, бик рәхмәт. Атаң-анаң исәннәрме?

— Әйе.

Абзый канәгатьлек белдереп баш какты да сүздән туктады. Бердән, самолет шавы иркенләп сөйләшеп барырга комачаулаcard, икенчедән, күрәсең, кайчандыр үзе дә солдат шулпасын гына татып калмаган, ә дәһшәтле сугыш кырларын да узган бу кеше үз уйларына чумды булса кирәк. Аның да яшь чагы булгандыр, хәзергеләр

белән чагыштырганда бик күпкә авыррак солдат хезмәте үткәндер, кулына корал тотып, илен-җирен саклагандыр...

Габделнур салондагы пассажирларны күздән кичерде дә карашы белән самолет кабинасында тукталды. Чөнки ул ачык иде. Колакларына наушниклар кигән яшь кенә ике пилот очкычны отыры югары күтәрәләр, тигез генә алга куалар. Приборлар тактасындагы әле бер, әле икенче кнопкага — тумблерга кагылалар, үзарамы, аэропорттагы диспетчер беләндерме сөйләшәләр; берсенең кулында астын өскә әйләндереп тоткан велосипед руленә тартым идарә итү җайланмасы — штурвал.

Кечкенәдән үк очучы булырга хыялланган Габделнур, җирдә басып торганда да, һавада берәр самолет күрсә, башын күтәреп карамыйча түзә алмый иде. Шуңа күрә ул очучыларны бик рәхәтләнеп, җентекләп, хәтта ки бала-чагадай кызыгып күзәтте.

Малай чакта, әллә кайда биектә, һавада күренгән серле очкычка карап, алар:

— Сәмәлүт, безне дә утырт әле, — дип кычкырып калалар иде.

«Сәмәлүт» малай-шалайның ялвару авазын ишетми, авыл өстеннән узып китә.

Бервакыт Габделнур әнисенә:

— Әни, үскәч мин летчик булам, — дигән иде. — Өй турыннан үткән саен сезгә камфит-пирәник ташлап китәрмен.

— Ярар, улым, рәхмәт...

И беркатлы, хыялый сабый! И изге җанлы ана!..

Техникум бетергәч, Габделнурның Казанга, Хәрби һава көчләренең махсус мәктәбенә — очучылар әзерләүче училищега китәргә дә исәбе бар иде, белешеп тә йөрде. Ләкин нишләптер тәвәккәлләмәде. «Егерме биш ел биленә каеш буып йөрмәссең инде», — дип, иптәшләре үгетләделәр һәм әлеге ниятеннән кире кайтардылар. Әмма авиациягә булган мәхәббәте мәңге сүрелмәстер, ахры.

...Аста тар гына, борма-борма агучы елгачыклар, түгәрәк көзге кебек кенә ялтырап ятучы, кояш нурларын чагылдыручы күлләр, күзне иркәләүче яшькелт урманнар, көзге муллык билгесе булган саргылт иген басулары күренеп кала.

Ул комсызланып аска карый, күңелгә якын басу-кырларны, җир өстен күзәтә. Әнә Чулманның сул ягында агачлар белән капланган биек яр, арырак, шәрә җирдә, «Шайтан каласы» күренде. Ул ак таштан корылган, түгәрәк, түбәсе очлаебрак килгән. Самолет белән бергә егетнең дә карашы алга шуыша: анда Алабуга җәйрәп ята. Габделнур өчен гадәти бер шәһәр генә түгел ул, бу — үзгә шәһәр, чөнки аның өч ел гомере шушында узды.

...Җиде классны бетергәч, үз авылларында урта мәктәп булмаганлыктан, үсмерләр кайсы кая тарала: берәүләр район үзәгенә сигезенчегә, икенчеләр күрше авылдагы урыс мәктәбенә (сигезенчегә алмасалар, кабат җиденчегә дә керәләр), өченчеләр техникумнарга, ФЗӨгә һәм һөнәр училищеларына... Авылда, колхозда калучылар да була.

— Алабугада ФАШ бар икән, — диде укулар бетәр алдыннан класста иң яхшы укучы кызларның берсе Габделнурга. — Әйдә шунда барабыз.

— Тагын кемнәр җыена?

— Без — өч кыз сөйләштек.

Шулай да Габделнур тиз генә җавап бирмәде. Чөнки малайларның кылын тартып карарга кирәк иде.

Иң әүвәл ФАШ дигәннең нәрсә икәнен белештеләр. Фельдшер-акушерлар мәктәбе икән. Аны бетереп чыкканнар авыллардагы медпунктта эшли.

Ул чорда балаларны класста «утыртып калдыру» гадәте бар иде. Педагогика күзлегеннән чыгып караганда дөрес булгандырмы ул, юкмы, анысын тәфсилләп тикшереп торучы булмаган, күрәсең, Габделнур белән бер класста аннан ике, хәтта өч-дүрт яшькә олы малайлар да укыды. Димәк, җидене бетереп чыкканда аңа ундүрт булса, тегеләргә унбиш-унсигез дигән сүз. Нишләптер яшьтәшләре арасыннан да, олыраклардан да Алабугага китәргә атлыгып торучылар булмады.

Бер малай (каян ишеткәндер), бик белдекле кыяфәт белән, җирәнеп:

— Анда беренче көнне үк үлгән кешене ярдыралар икән, — диде. — Мин мәеттән болай да куркам. Күпер төбендәге үлек суы түккән җирдән дә, бисмилламны укып, йөгереп үтеп китәм.

Аңа калса, ул төштән Габделнур да шикләнмичә, тыныч күңел белән үтә алмый... Укыйсы да килә бит.

Шулай итеп, әти-әниләренең фатихасын алып, өч кыз һәм бер малай Алабугага китеп бардылар.

Әмма ФАШ дигән уку йорты аларны үз канаты астына сыйдырмады. Чөнки имтиханнарны урысча бирәсе иде. Үтмәделәр.

Борыннарын салындырып, кайтырга җыенгач, бер кыз әйтте:

— Монда культура-агарту мәктәбе бар икән.

Культура дигән сүзе мәгълүм булса да, агарту дигәнен бигүк аңлап җиткермиләр иде. Дөрес, агарту сүзен беләләр — әниләре таш катыгы ясап, кайнатып, мич агарта, өйнең бүрәнә араларын сылау балчыгы белән сылагач, аларны да агарта. Җылы да, матур да.

Таш катыгы тотылып бетмәсә, сакларга базга төшереп тә куялар. Берчакны күрше кызлары аулак өй ясады. Укытучылар, сизенеп, өйгә басып керә башлагач, малай-кызлар, тиз генә сайгакны ачып, өй базына коелды-

лар. Чыккач карасалар, эчләре катып көлделәр: бер малай караңгыда таш катыклы чиләкне аударган да чалбар балаклары ап-ак булган.

Әйе, агарту сүзе таныш. Ләкин культураны ничек агарталар?.. Монысына төшенүе читенрәк иде.

— Анда нәрсәлеккә укыталар икән соң? — диде Габделнур, барысын да борчыган сорауны уртага куеп. — Әйдәгез барып карыйк.

Тагын Алабуганың таш түшәлгән урамнары буйлап, үзләрен кабул итмәгән ФАШ бинасы яныннан үтеп, шәһәр читенә үк килеп чыктылар. Пристаньга бара торган юл өстендә өч катлы ак бина икән аларга кирәкле уку йорты. Биек таш койма белән әйләндереп алынган ихатага зур капка аша үтәсе.

Бардылар, күрделәр һәм... керделәр. Әлеге уку йорты клуб мөдирләре хәзерли икән. Урысча әйткәндә, «недобор» булган анда. Авылдан бер чыгып киткәч, кая да булса укырга керә алмыйча кире әйләнеп кайту — гарьлек. Шуңа күрә үсмерләр, әллә ни күп уйлап тормыйча, культура-агарту мәктәбенә кереп кайттылар. Чөнки мәктәп дип кенә аталса да, техникум санала икән ул.

— Һөнәрле дә булырсыз, урта белем турында таныклык та алып чыгарсыз, — диде бер мәрхәмәтле укытучы, аларны юатып. — Безнең диплом белән теләсә кайсы институтка керергә була.

Икенчесе болай дип тә юмалады:

— Без малайларны баянда, кызларны домрада уйнарга да өйрәтәбез... Стипендия дә түлибез...

Август ахырында, бишмәт ише киемнәрен һәм азык-төлек алып, такта яки фанер чемодан-сандыкларын күтәреп, беренче мәртәбә очарга ниятләп курка-өркә генә ояларыннан чыккан кош балалары кебек, әти-әниләреннән (ятимнәр — туганнарыннан) аерылып, белем эстәргә дип, Алабугага китеп тә бардылар.

## 20

Самолеттан караганда тау башындагы «Шайтан каласы» — очлы башлы түгәрәк бина — ап-ак булып җирдән калкып тора. Габделнур укыган заманда аның килеп чыгышын Пугачев явы чорында бер төн эчендә корып куйганнар дип аңлаталар иде. Аны төзүче осталар кем булган, килгән кешеләрме, әллә җирле халыкмы, материалын каян ташыганнар, бер төн эчендә ашык-пошык салынган ныгытма ничек гасырлар буена ишелмичә тора — болар хакында тәгаен генә әйтүче дә, белүче дә, уйлаучы да юк иде шикелле. Андый четерекле сорауларны, гомумән, читләтеп үтәләр иде. Күрәсең, Габделнурлар укыган дәвердә шулай җиңел генә аңлату кулайрак саналгандыр...

Шулай да ул чорда да үз фикере булган кешеләр яшәгән, ахрысы. Аларның тарих укытучысы, мәсәлән, «Шайтан каласы» турында сүз чыккач, әйткән иде:

— Сугыш вакытында төзү эшләре белән шөгыльләнмиләр, киресенчә, җимерәләр генә. Пугачев бу тирәдә озак тукталып тормый, бакыр заводы хуҗасының өендә төн кунып чыга да ары китә.

Габделнур да, курсташлары да ул вакытта моңа әллә ни игътибар итмәделәр. Ләкин күңеленә уелып калган икән. Менә хәзер, самолетта очканда әлеге корылманы күргәч, кылт итеп исенә төште тарих укытучысының сүзләре. Ул, гомумән, сәеррәк холыклы, кырысрак дисәң дә ярый, кыскасы, һәрнәрсәгә үз карашы булган һәм аны турыдан ярып салырга яратучы, тәбәнәк тыгыз гәүдәле, шадра йөзле, күзлекле, утыз яшьләр тирәсендәге өйләнмәгән кеше иде.

Бер дәрестә кызлардан кайсыдыр сорау бирде:

— Абый, әйтегез әле, мәхәббәт нәрсә ул?

Укытучы, күп уйлап тормыйча:

— Шәрә муенга — йонлы камыт, — диде.

Күпләр моны бик соң гына аңлады...

...Ә шәһәр йортлары аермачык күренми, фәкать милиция мәктәбе территориясендәге биек чиркәү манаралары гына «без кем» дип масаеп, кукраеп утыралар. Шулай да Габделнур үзе укыган мәктәпне (мәктәп дип аталса да, ул чыннан да техникум белеме биреп чыгарды) шәйләде кебек. Чөнки ул пристаньнан шәһәргә бара торган ике чакрымлы таш юл өстендә иң беренче йорт.

Ә пристань турысында өскә таба текә баскыч күтәрелә. Анда, биек тау башында, ашлык кабул итү пункты — заготзерно урнашкан. Эшче көчләр җитенкерәмәгәндер инде, студентларны эшкә дә алып баралар иде.

Бервакыт Сәвия исемле кыз шунда арышка батты. Балалык галәмәте инде. Ул болай булды. Түбәсе ябулы алагаем зур амбар эчендә көшел. Өстән, транспортердан, аңа берөзлексез ашлык агып тора. Ә көшелнең уртасы конус сыман чокырлы. Чөнки аста тишек һәм анда да күзгә күренмәс транспортер бар икән. Тишектән ашлык берөзлексез агып тора. Ә үсмерләргә кызык: көшел читеннән, өстән, әкрен генә, агым белән бергә аска шуып төшәләр. Аннан, гәүдәләрен суыра башлагач, шаяра-шаяра өскә үрмәлиләр. Ул көнне дә берничә кыз шулай уйнаганнар.

...Акырыш-елаш, шау-шуга бөтен халык җыелды. Күрше амбарда эшләгән Габделнурлар йөгереп килеп җиткәндә, Сәвиянең өскә сузылган ак куллары гына күренеп тора иде. Заготзерно эшчеләреннән кемдер, электр рубильнигына басып, транспортерларны туктатты. Шау-шуга җыелган берничә таза ир-ат ничек кирәк алай кызның хәлсез гәүдәсен чокырдан тартып алдылар: авызы тулы арыш, үзе үлем хәлендә, һушсыз... Көчкә аңына килеп, берничә көн хастаханәдә ятып чыкты кызыкай һәм шуннан соң күзлек киеп йөри торган булды.

Алабуга... Габделнурның тормышында, әле яңа гына мөстәкыйльлеккә юл алган үсмернең беренче адымнарында, аңа бик күп яхшы һәм яман нәрсәләр белән күзгә-күз калып, мәсьәләне үзенә хәл итәргә туры килде. Ул гомерендә беренче мәртәбә чекерәеп күзгә бәреп торган гаделсезлек белән очрашты. Дөрес, малай-шалай сугышмыйча, бер-беренең танавын канатмыйча яисә башын тишмичә үсми. Тукмашу, бәргәләшү, дөмбәсләшү — авылда туган ир бала өчен гадәти күренеш. Ләкин ул яшьтәшләрең, классташларың, күрше-тирә, бер урам яки авыл малайлары арасында була. Әмма олы кешеләр, егетләр авыл баласын юкка рәнҗетми. Чөнки авыл халкы олыны олы итеп, хөрмәтләп, кечене кече итеп, баласытып яшәргә күнеккән. Ә монда, чит җирдә һәм чит-ят арасында сине яклау гына түгел, кешелегеңне (бәләкәй булсаң да син дә кеше бит) салып таптарга әзер торучылар да табыла икән.

...Габделнур тулай торакка урнашты. Ул техникум бинасыннан бераз читтәрәк, бакча эчендәрәк, ләкин бер ихатада урнашкан ике катлы агач йорттан гыйбарәт иде. Өй бик озын, тышкы ишеге уртада, аскы катта; кечкенә коридордан ике якка тагын ишекләр уелган; бүлмәләр тулай торак өчен җайлаштырылган. Өскә баскыч менә, анда, югары катта да ике бүлмә, аларда гаиләле укытучылар яши.

Аскы каттагы бүлмәләрнең берсенә кертеп урнаштырдылар Габделнурны. Унсигез караваТ. Төрле курстагы, төрле яшьтәге унсигез егет. Хәер, бер-икесенең гаиләсе дә бар икән инде. Хатыннары — авылда. Идән юу — чират белән, диварга график эленгән. Габделнурның чираты бишенче көнне үк килеп җитте. Рәвешен китереп идән юды. Ләкин икенче көнне берәү аңа тагын идән юарга кушты: сары кашлы, озын какча гәүдәле өченче курста укучы егет. Ул яше белән Габделнурдан шактый өлкән, инде армиядә дә булып кайткан. Егет Германиядә хезмәт иткән, пешекче булган. «Ач немкалар, кәстрүл яки бүтән нәрсә тотып, минем янга киләләр, — дип сөйләгән иде ул, беренче курска килгән яшьләр алдында мактанып. — Мин, аларны куак арасына алып кереп, тиз генә үз эшемне эшлим, аннары берәр черпак ботка салып җибәрәм савытларына». Ул бөтен ваклыкнечкәлекләренә кадәр алар белән ни кыланганын сөйләгәндә, Габделнур, чыраен сытып, җирәнеп, бүлмәдән чыгып киткән иде. Күрәсең, бу тегенең хәтерен калдырган һәм хәзер өлкәннәрне хөрмәт итмәгән өчен «салага»дан ачуын алмакчы.

Дәрестән соң, көтмәгәндә-уйламаганда, ул Габделнурга:

— Бар, су алып кер, — диде. — Әнә чүпрәк. Идән юарсың.

Габделнур, әле генә авылдан килгән ундүрт яшьлек малай, башта аңламыйчарак торды. Әллә минем кичә җыештырганны күрмәде микән, дип уйлады.

— Я вчера стирал, — диде ул.

— Салага, я тебе про пол говорю, а не про твои грязные трусы, — диде сары чәчле егет. — Пол не стирают, а моют.

— Мин ялгыш әйттем, — диде Габделнур, акланып.

Озын егет тагын әмер бирде:

— Бар, чиләк белән су алып кер дә идәнне юып чыгар.

Габделнурның хәзер генә башына барып җитте: бу үз чиратында аңардан идән юдыртмакчы. Бүлмәдә алар икәү генә иде. Шулай да үсмер тәвәккәлләде.

— Мин кичә юдым. Чиратымны үткәрдем.

— Булса соң?! Бүген — минем чират, минем өчен юарсың.

— Юмыйм.

Гәүдәсе метр ярым гына булса да, Габделнурда үҗәтлек шактый мул иде. Ул үз сүзендә торырга булды.

Тегенең дә үз сүзен сүз итәсе килде, ахры. Бәләкәй генә малайдан мондый каршылык та көтмәгән иде.

— Бар, маңка, кабат әйттермә!

— Юмыйм!

Алар кара-каршы караватларда утыралар иде. Сары чәчле егет сикереп торды да Габделнурны караватыннан суырып алды һәм, күтәреп, идәнгә томырды. Малай түрдәге караватларның берсе астына ук кереп китте.

Моның ахыры нәрсә белән беткән булыр иде, билгесез, шулчак бүлмәгә бер егет килеп керде. Ул икенче курста укый, уң кулын токарный станокта өздергән, шуңа да карамастан сулы белән язарга, рәсем ясарга өйрәнгән. Ул — шәһәр малае, какча булса да, гәүдәгә ярыйсы калку иде.

— Нәрсә бар? — дип сорады ул идәннән күтәрелеп килүче Габделнурдан.

Малай, аның соравына җавап бирмәстән, йөгереп килеп, баш белән сары чәчнең ияк астына бәрмәкче иде, теге читкә тайпылды. Габделнур килгән уңайга ишеккә барып бәрелде. Ә анда тагын ике-өч егетнең кереп килүе икән. Алар аны егылудан тотып калдылар. Сары чәч бүлмәдән чыгып китте.

Кулсыз егет тагын бер кабат:

— Нәрсә булды? — дип сорады.

Габделнурның кинәт күңеле тулды. Әле яңарак кына әти-әнисенең җылы канаты астыннан чыккан, чит-ят җирдә дөньяның ачысын-төчесен татырга күнекмәгән гөнаһсыз җан күз яшьләрен тыя алмады. Чөнки монда яклаучылар булачагына аның өмете уянды. Әгәр алар кермәгән булса, ул тегенең белән көче җитсә-җитмәсә дә чәкәләшкән булыр иде, теге аны бәргәләп ташласа да күз яшен күрсәтмәс, дошманын сөендермәс иде. Ә хәзер...

— Миңа идән юарга кушты, — диде Габделнур, йодрыгы белән күзләрен сөртеп.

— Син кичә генә юдың бит, — диде егетләрнең берсе.
— Әйе шул, — диде икенчесе, аны җөпләп.
Бу хәлдән соң Габделнур шуны аңлады: чит-ят җирдә үз-үзеңне яклар өчен егет кешегә көч кирәк икән. Һәм ул ныклап спорт белән шөгыльләнә башлады. Физкультура укытучылары икәү иде. Аның берсе бокс секциясен дә алып бара, икенчесе — волейболны... Габделнур, укуына хилафлык китермичә, курсташ малайлар белән бергә икесенә дә йөрергә тырышты. Алар берничә мәртәбә милиция мәктәбе курсантлары һәм балигъ булмаган җинаятьчеләр колониясе тоткыннары белән дә ярыштылар. Спортзалдагы штанга янына да еш киләләр иде. (Бервакыт кызык өчен, штанганы өчесе бергә күтәреп, фотога да төштеләр. Ул карточка хәзер дә Габделнурның альбомында саклана.) Ә кышын Алабуга белән Затон арасындагы Олы Бор һәм Кече Бор дип йөртелә торган урманнарда, нарат агачларының шифалы һавасын сулап чаңгыда йөрүе үзе бер ләззәт, тәнгә сихәтлек иде. Ә теге сары чәчле егеткә килгәндә исә, Габделнурның кечкенәдән үк хәтере яхшы иде һәм ул аның җәберен онытмады: чыгарылыш кичәсенә дип алган сары туфлиләрен, караватастыннан чәлдереп (картон тартмасы шунда калды), таш бәйләп, урамдагы әбрәкәйгә салып, каникулга китеп барды.

Самолет очуын дәвам итә. Ә Габделнур хатирәләр дулкынында тирбәлә.
...Саный китсәң, күп инде ул өч ел буена җыелган истәлекле вакыйгалар. Икенче елның сентябрендә Габделнур һәм бергә укучы тагын ике студент районның ерак бер авылына көзге кыр эшләренә җибәрелде. Алексей атлы керәшен малаеның туган авылы иде бу.
— Җураман гына эшләп җөрербез, җал күрмичә, бөкре чыкканчы эшләмәбез, — диде ул, мактанып. — Бригадир справка җазып бирер әле.
— Авыл кешесеме соң ул? — дип сорады Михаил, шикләнебрәк. — Ышанычлымы?
— Гумер буе шунда җәши, җегерме җылдыр инде бригадирлыкта. Мин аның кызын да җаратып җөргәнием әле.
— Кияүне обижать итмәс инде, — дип төрттерде Габделнур.
— Мин аны ташладым инде, — диде Алексей, эре генә.
Әйе, бардылар, эшләделәр.
Бригадир белешмә язып бирде бирүен, ләкин «к работе относились недобросовестно» диелгән иде анда. Авылдан заготзерногакайтканчы, егетләрнең башы катты. Чөнки андый белешмә белән барлы-юклы стипендиядән дә колак кагуың ихтимал иде. Ярый ла Алексей туганнарында яши, тамагы тук. Ә Габделнур белән Михаилга стипендия бик ярап тора. Шулай да җаен таптылар.
— Әйдәгез бәдрәфкә, — диде машинадан төшкәч алар арасында яшькә дә олырак, буйга да калкурак Михаил.
Аңа инде унҗиде яшь. Күрәсең, мондый хәлгә тарыганы булгандыр яки берәрсеннән ишетеп беләдер нишләргә кирәген.
— Минем керәсе килми, — диде юантык гәүдәле Алексей, ары атлап.
— Нәстә?! Җарар, күзәтеп торырсың. Бер кызык эшлибез.
Ашлык кабул итү пунктының алагаем зур, ышкыланган нарат такталардан ясалган әбрәкәенә керделәр. Күрәсең, ипи-ризык белән эш итүче мондый предприятиеләрдә санитария кагыйдәләре төгәл үтәлгәндер — савыты белән акбур сыман ап-ак хлорка тора иде. Михаил шуннан бер чеметем алды да, аны юешләп, белешмәдәге «недобросовестно» сүзенең алдагы ике хәрефе өстенә тамызды.
— Бөтенләй бозып ташласаң? — дип борчылды Габделнур.
— Курыксаң, мә, минем фуражканы ки, — диде Михаил, аңа карамыйча гына. — Менә күрерсез...
Бераздан алдагы ике хәреф юкка чыкты.
— Әле ярый бригадир грамотный булган, «не» дигәнне аерып язса, сизелер иде, — диде Габделнур, елмаеп.
Егетләрнең эченә җан керде, шаярта ук башладылар.
— А как же! Керәшен булсын да, грамотный булмасын! — диде Михаил, горурланып, һәм юка борынын өскә чөйде.
Ул үзе дә күрше районндагы керәшен авылыннан иде.
Болай да кызгылт йөзле Алексей дәшмәде, бурлаттай кызарды гына. Чөнки гаеп аңарда бит.
Тизрәк кәгазьне киптереп, үсмерләр саф һавага чыктылар. Аны әйләндереп-тулгандырып өскә күтәреп тә, түбән төшереп тә, кояшка каршы куеп та карадылар. Әллә ни беленми иде.
«Җегетләр»нең кәеф күтәренке.
Михаил үзенең яраткан такмагын да әйтеп алды:
— Господи, помилуй, урыс мине танымый, таныса да сукмый, үтергәнче тукмый.
Аларга карап, Габделнур көлеп җибәрде һәм:
— Керәшен, ат эченә керәсең, анда ниләр күрәсең, чыккач безгә сөйләрсең, — дип такмаклады да торып йөгерде.
Михаил белән Алексей аны куа киттеләр, һәм бераздан юрамалый гына дөмбәсләшү-бәргәләшү башланды.
— Ах ты, татарчонок гололобый! — дип, Михаил Габделнурның өстенә үк менеп атланды...

Бер урында тик тора белмәүче, юктан да кызык эзләүче яшь-җилкенчәк арасында мондый дусларча шаярулар еш булучан.

Икенче көнне белешмәне курс җитәкчесенә бирделәр. Режиссурадан укытучы абыйлары кәгазьне җентекләп укыды.

Аннан ул, урысчалап:

— Молодцы, егетләр! — дип мактап, белешмәне өстәл тартмасына салып куйды.

Ул укытучы Мәскәүдә ГИТИС дигән институт бетереп кайткан икән. Зур театр, Кече театр, МХАТ, Вахтангов театры дигән сүзләрне, Станиславский, Немерович-Данченко (баштарак студентлар аны ике кеше дип буталдылар), Завадский атлы фамилияләрне Габделнур һәм курсташлары беренче мәртәбә аңардан ишеттеләр. Ул өйләнгән, хатыны шифаханәдә эшли иде. Һәм менә хатынының табибә булуы, иренең аның хезмәттәшләре белән якыннан аралашуы икенче вакыт Габделнурны ярты елга стипендиясез калдырды.

...Үзләре керә алмаган ФАШта бер авылдаш кыз укый иде. Ул унны бетергәннән соң анда барып кергән. Габделнурдан өч яшькә олы иде.

...Көз көне, Октябрь бәйрәмендә, җыйнаулашып авылга кайтып киттеләр.

Кайтканда бу кыз Габделнурга һәм аның белән бергә укучыларга:

— Бер-ике көнгә соңга калырбыз, — диде. — Мин сезгә справка табам.

Алга китеп булса да шуны әйтик: ул ике уйлап тормаучы, тәвәккәлрәк кыз иде шул. Укуын бетергәч, аны күрше районадагы керәшен авылына эшкә җибәрәләр. Өч ай да үтми, ул кияүгә чыга. Габделнурның әтисе машина белән аның әйберләрен илтә бара. Туй вакытында салып алган карчыклар: «Галләм, кызыгызны чукындырдык, түшенә тәре тактык», — дип мактанып сөйләгәннәр.

Шофер да җавапсыз калмый, исереп ишек төбенә үк егылган берәүгә күрсәтеп:

— Керәшеннәр баеганнар, аяк сөртергә дә керәшен җәйгәннәр, — дип, тегеләрне үрти.

...Габделнур, аңа ышанып, укуга ике көнгә соңгарып барды. Кызый юнәткән белешмәне курс җитәкчесенә тапшырды.

— Нәрсә, авырып киттеңмени? — дип сорады ул, һәрчак чиста итеп кырынган, тулышып торган йөзенә борчылу галәмәте чыгарып.

— Әйе.

— Каяле, — дип, ул белешмәне кулына алды, икенче кулы белән симез муенын кысып торган галстугын җайлап, күз йөртеп чыкты. — Бу кем кулы?

Укытучы табиб имзасын студентның борын төбенә үк терәде. Туп-туры аның күзләренә карады.

— Фәлән врачныкы, — диде Габделнур, күзен дә йоммыйча теге кыз әйткән фамилияне атап.

— Юк, бу аның кулы түгел. Калдыр, ачыкларбыз.

Эш зурга китте, директорга барып җитте... Тагын бер елдан режиссер абыйлары үзенең студенткасы, Башкортстаннан килгән бер кыз белән ачыктан-ачык типтерә башлады. Аңа бик нык рәнҗегән Габделнур шул вакыт эчтән генә әйтеп куйды: «Их, узган ел ук йөри башласагыз, миңа алай каты бәрелмәс идең, стипендиядән мәхрүм итмәгән булыр идең».

**21**

Габделнурга ничәмә-ничә тапкыр Чулманны көймәдә кичеп чыгарга туры килде: Чаллыдан — Затонга яки киресенчә — Затоннан — Чаллыга. Менә батабыз, менә батабыз, дип, суыктан күшеккән ябык куллары белән көймә кырына ябышып, дер калтырап утыруларын гомергә дә онытасы юк. Яз-көз айлары бик хәтәр, биек дулкыннар бәләкәй көймәне әйләндереп ташлар шикелле тоела иде. Бигрәк тә пароходлар үтеп киткәндә берәр метрлы авыр дулкыннар хасил була һәм алар көймәне йотардай булып өскә ябырылалар. Көймәчегә акча кирәк, шөгыле шул, керер җире шул — сыйдыра алган хәтле утырта...

Ә өстән караганда елга әллә ни киң дә түгел икән югыйсә.

Чаллы. Анысы инде кечкенәдән үк таныш шәһәр. Анда әнисенең туганнары да яши. Габделнурның әтисе шофер булганга күрә, үзен белә белгәннән бирле дип әйтерлек аңа утырып элеваторга ипи ташыдылар. Габделнур күргән беренче шәһәр Чаллы булса, иң биек йорт — тау башындагы элеватор, скульптура һәйкәле — пристаньнан күтәрелүче халыкны елмаеп сәламләп торучы Сталин сыны. Чаллы искә төшсә, бик күп хатирәләр яңара.

Бервакыт Габделнур белән энесен әтиләре «хитрый базар»да калдырды. Әйе, яр буендагы кечкенә базарны шулай атап йөртәләр иде бугай.

— Балалар, алдыгызны-артыгызны карап сатыгыз. Монда төрле халык бар. Акча алырга онытмагыз. Капчыкларны да күздән ычкындырмагыз.

Машинасына утырып, Галләм абзый колхоз эшләре белән китеп барды. Кызыл галан бәрәңге эре, яңа гына баздан чыгарылган, шуңа күрә халык, кем әйтмешли, ябырылып алды. Өченче капчык та бетә дип торганда, бер маржа бәйләнде бит. Ул бәрәңге алып китеп барган иде инде, яңадан әйләнеп килгән.

— Нишләп аз саласыз? Бер кило җитми, — дип, малайларга ябырылды. — Кая, бир әле чиләгеңне.

Ул Габделнур кулыннан иске чиләкне тартып алды да бәрәңгесен җиргә бушатты.

— Карагыз, әнә төбенә карагыз, яртылаш цемент каткан. Алдакчылар! Бир акчаны! Мә бәрәңгеңне!

Рәхмәт бер абзыйга: ул теге хатынганиләрдер әйтте, тынычландырды.

Аннары Габделнурга татарча:

— Улым, бир шул туймас күзгә берәр кило бәрәңге, тамагы тыгылсын, — диде.

— Ярар, бабай, — диде Габделнур һәм аның кушканын үтәде.

Аннары абзый:

— Олан, калганын миңа сатып бир дә, тизрәк моннан таю ягын карагыз, — диде һәм китеп баручы юан хатынга таба ымлады. — Ул бер каныкса, тиз генә тынмый, йә милиция ияртеп килер. Ул юри тавыш чыгара. Ә үзе бая сездән алып киткән бәрәңгенең бер-ике килосын өендә калдырып килгәндер әле. Беләм мин аны... Фатирыгыз еракмы?

— Әнә теге өйдә, — диде Габделнур, базар яныннан күренеп торган ике катлы йортка ымлап.

Шулай итеп чак качып котылдылар. Базар шундый урын инде ул: кемдер алдый, кемдер алдана. Хәер, малайларның андый уй башларына да кермәгән, чиләкне дә махсус сайлап алмаганнар иде.

Икенче вакыт он сатканнары исендә. Бу юлы әтисе белән Габделнур гына иде. Оннары әйбәт булса да, алучы юк. Киләләр, бәясен сорыйлар, ачык капчыкка үрелеп карыйлар, кайберсе берәр чеметем он алып, учына салып тикшергәндәй дә итә.

Шулай берәр сәгать торганнардыр. Галләм абзыйның бер танышы килеп чыкты. Тегене-моны сөйләштеләр, хәл-әхвәл белештеләр. Галләм абзый танышына зарланып куйды.

— Нишләптер алучы юк әле.

— Һы, шулаймы? Хәзер, Галләм, кызык итәбез аларны.

Шул сүзләрне пышылдап кына әйткәч, ул китеп барды. Габделнур әле аптырап та калган иде. «Үзе, кызык итәбез, диде, үзе китте». Ләкин әтисенең танышы бераздан әйләнеп килде. Чит кешедәй сөйләшә башлады, тавышы — бөердән.

— Нәрсә, агайне, он сатасыңмы? Кыйбатмы хакы?.. Каяле, карыйм әле... Оны әйбәт! Тәк, синең оның ничә капчык?

— Ике.

Абзый куен кесәсеннән калын гына бумажник чыгарды, бармакларын төкреклəп, акча санагандай итте.

— Җитә икән, — диде ул үз-үзенә һәм Галләм абзыйга күтәрелеп карады. — Барысын да үзем алам. Җыен әйдә. Илтеп куярсың.

Яңарак кына килеп баскан ике-өч хатын, икеләнеп, ни алырга, ни китәргә белмичә терәлеп торалар иде, шаулаша башладылар.

— Нишләп син генә аласың? Ә безгә ни кала? Спекулянт...

— Мин бит...

Галләм абзыйның танышына авыз ачарга да ирек бирмәделәр, аннары үзенә ябырылдылар.

— Нигә бөтенесен аңа бирәсең? Әллә безнең тамагыбыз юкмы? Без дә шул ук совет акчасын түлибез бит, кәгазь түгел. Хатыннар, җибәрмәгез!.. Башта безгә үлчә, калса, аңарга...

Узып баручы хатын-кызларның да игътибарын җәлеп итте бу гауга. Ярты сәгать эчендә он сатылып та бетте.

Сату-алуның рәтен белүче агайлар Чаллыда күп иде, ахры, ул заманда. Бервакыт Галләм абзыйга күршесе-авылдашы утырып барды. Ит сатарга. Әтисе, Габделнурга да шул тирәдә генә булырга, тегеңә булышырга кушып, колхоз йомышы белән китеп барды. Чабылган итне прилавкага тезеп тә куйдылар. Бер Чаллы агае килде.

— Итең кыйбатмы?

— Фәлән сум.

— Нәрсә ите?

— Тана, абзый, тана, яшь тана, — диде авыл кешесе, күзен дә йоммыйча.

Чаллы агае кисәкләргә күз салды да шыпырт кына тегенең колагына әйтте:

— Танаң күкәйле булган бит.

Чөнки теге үгез итен тана ите дип сата иде.

Нишләсен, бахыр, Чаллы агаена:

— Абзый, шым бул, — диде. — Кая, сумкаң бармы? Бер җүннерәк кисәген салыйм.

— Рәхмәт. Мин икенче берәүдән алырмын инде, — дип китеп барды агай.

Шуннан Габделнурның авылдашы тагын сатып алучыларны дәшә башлады.

— Тана ите, апа, килегез, тана ите, бик яшь, бик тәмле, бик симез...

...«Биек Шыгай таулары, өзелә камыт баулары», — дип көйләгәннәре, каһәрләгәннәре әле дә исендә. Ат белән булсаң да (кыш көннәрендә аларны каникулга алып кайтырга Алабугага ат белән киләләр һәм илтеп тә куялар иде), җәй көне машинада барсаң да (яңгыр яуса, әҗәл инде), интекми калмыйсың ул тауларны менгәндә.

Игәнә елгасы буйлап әллә кай тарафларга сузылып киткән ул биек тау тезмәләре самолеттан караганда дөя үркәчен хәтерләткән калкулыклар кебек кенә икән.

Әнә аста спирт заводының төтенләп утыручы тимер торбасы күренеп калды. Заводтан «лафка»га аракы алып кайталар, ә колхоз малларына зур мичкәгә яки шакмаклы олы тимер савытка тутырып барда ташыйлар иде. Фермада терлек карауларның өйдәге маллары да кышны исән-имин чыга, көр була торган иде.

Сул якта, еракта, Габделнур ай ярым клуб мөдире вазифасын башкарган бәләкәй генә авыл. Ул анда бик мәрхәмәтле бер апада торган иде. Исән микән әле үзе? Вафат булса, урыны җәннәттә булсын... Өйләнмәгән, утызларга җитеп килгән улы бар иде. Хәзер бала-чагалар үстереп ятадыр инде. Тракторда эшли иде шикелле.

Ә алда — район үзәге. Укуын бетергәч, иң әүвәл ай ярым шунда эшләгән иде бит, район мәдәният йортында баянчы булып. Беренче хезмәт хакын шунда алган иде. Үз баянчылары чираттагы ялыннан чыккач, Габделнурны теге авылга клуб мөдире итеп җибәрделәр. Өч ел укыганга өч ай мәдәният өлкәсендә эшләде дә Габделнур абыйсы янына — Әлмәт якларына китеп барды. Чөнки мондагы хезмәт хакы кеше өстендә фатирда торып, үзбаш яшәүче унҗиде яшьлек егеткә киенергә түгел, җан асрарга да җитми иде.

Район үзәгендә дә бер апаларда фатирда торды ул. Апаның өч улы бар, өчесе дә спортчылар, ишегалдында ике потлы герне чөеп кенә уйныйлар иде егетләр. Берсе район җыенында кулын пешергән булган: гер мәйдан уртасында кояшта озак торган, бу егет беренче булып ярышка чыккан да күтәрә дә күтәрә икән. Хәле бетеп, герне ташлагач, уч төбе кабарып чыга, аннан тиресе кубып, чиләнеп тора. Ул аны бинт белән бәйләгән иде. Август ае беткәнче шулай йөрде. Көчле, таза егетләр иде. Ләкин алар көрәшмәделәр. Ә Габделнурның абыйсы район үзәгендә урта мәктәптә укыганда өч ел фатирда торган йортның хуҗасы үзе дә, уллары да атаклы көрәшчеләр иде.

**22**

Кулына кечкенә чемодан тоткан Габделнур гадәттә халык машина көтә торган чатта тукталып та тормады. Чөнки анда кеше юк. Хәер, юлаучылар булса да көтмәс иде. Ун чакрым ара нәрсә ул өч ел туган авылын, ата-анасын, туган-тумачасын күрмәгән солдат егеткә. Минзәлә елгасы аша салынган биек агач күпердән дагалы итекләре белән дөп-дөп басып үтте дә тауга күтәрелә башлады. Район үзәге булса да, гадәти авыл өйләрен тәшкил иткән кырый урамнар артта калды.

Сулда колхоз фермалары шикелле озын, бер генә катлы «глубинка» бинасы. Анысы да таныш. Буыннары ныгып җитмәгән унөч-ундүрт яшьлек малайлар, аркаларына капчык күтәреп, тактадан ясалган тар басмадан көшел өстенә менәләр иде. Менеп җиткәч, бер якка янтаеп, капчыкны бушатасың. Ул мизгелдә, чыннан да, җилкәдән тау төшкән кебек җиңеләеп каласың инде. Ә кайчакта, менгәндә тигезлегеңне саклый алмасаң, иң-башына салган капчык сине бер кырыйга сөйри дә, аның артыннан үзең дә мәтәләсең. Ә аста кладовщик тора.

— Бар, алып мен!

— Абый, авыр бит, шушында гына бушатыйм инде.

— Күп сөйләшмә, сыпырт өскә!

Әлеге капчыкны көч-хәл белән сыртыңа салып, тагын менеп китәсең...

— Хәзер булса! — дип куйды барган уңайга Габделнур, елмаеп. — Күрсәтер идек ул абзыйга нинди икәнлекне!

Әйе, уртачадан калкурак, төз гәүдәле, ыспай, әмма киң күкрәкле гайрәтле егет Габделнур. Армиягә алынуларының беренче көннәрендә, Кронштадтта карантин узганда, күрше-тирә республика һәм өлкәләрдән җыелган татар егетләре ике потлы икешәр герне чөеп кенә уйныйлар иде. Өчәр-дүртәр ел хезмәт иткән солдат-матрослар да хәйран калып карап торалар иде...

— Солдат, кая кайтасың?

Габделнур кинәт артына борылды. Аны бер йөк машинасы куып җиткәнен, уйга бирелеп, абайламый калган икән. Шофер кабинадан башын чыгарган да елмаеп тора.

— Сиңа әйтәм. Әйдә утыр. Кая юл тоттың?

Габделнур аны танымады, билгеле. Шуңа күрә күрше авылларга кайтучыдыр дип уйлады.

— Туган Йортка. Турыдан гына кайтам.

— Әйдә күрше авылга хәтле апкайтам. Аннан дүрт кенә чакрым кала бит.

— Ярар алайса, — дип, Габделнур бер кулын кузов бортына, бер аягын баллонга — машина тәгәрмәченә чак кына тидереп алды һәм... очып кына менде.

— Җилле күренәсең, — диде шофер, соклануын яшермичә, һәм кузгалып та китте.

Габделнурның кабинага утырмавының сәбәбе бар: анда бер чибәр кыз, шофер үзе дә яшь егет, «газик» кабинасы ике генә кешелек. Хәер, дәшсә дә утырмас иде Габделнур: өченче кеше артык.

Машина тырыша-тырмаша тау менә башлады. Бу — җырларга кергән зәңгәр таулар тезмәсе иде. Аларның түбәләре шәрә, агач-куаклык юк, сирәк-мирәк ак кылганнар гына шәйләнә. Кайбер урыннары көрәнсу-кызгылт, ташлар да күренгәли. Борынгы заманнарда бу таулар астыннан бакыр рудасы чыгарганнар дип сөйлиләр. Алабуга тирәсендәге заводларга ат белән ташыганнар. Бакыр базлары әле хәзер дә исәндер...

Машина таудан түбән төшә башлады. Тауның бу ягы сөзәк иде. Сул кул якта бәләкәй генә урманы — «руша»сы (Габделнур кечкенә чакта әбисе белән анда җиләккә дә килгәне бар иде. Ләкин күп җыя алмадылар: урманчы куып җибәрде) булган авылга килеп керделәр. Урам чатында машина туктады.

Шофер кабинадан башын чыгарды.

— Ачуланма инде, миңа сулга.

— Монысына да рәхмәт, — диде Габделнур, житез генә җиргә сикереп төшкәч.

— Кемгә кайтасың? Минем сине бер дә күргәнем юк. Күрше авыл егетләрен таныйм югыйсә.

— Мин ундүрт яшьтә үк зимагорлыкка чыгып киткән идем инде, — дип көлде солдат.
Шофер да, елмаеп:
— Җимәгүрнең эш рәхәт инде аның: ашый калҗа, коча марҗа, ник кайтсын ул иленә, — дип такмаклап алды.
— Так что, белмәвең гаҗәп түгел, — диде Габделнур һәм кабинадагы кызга да карап алгач өстәде: — Әтине, бәлки, беләсеңдер, ул да шофер.
— Галләм абыймы әллә?
— Әйе.
— Ник аны баштук шулай димисең?! Әнәң к... Әйдә, кире мен! Илтеп куям.
— Юк инде, рәхмәт.
— Рәхмәт соңынтын булыр, — дип, кабина ишеген ачты шофер егет һәм ай-ваена карамыйча кире кузовка менәргә мәҗбүр итте Габделнурны. — Ул үзе юлда бер кешене калдырмый, ватылсак, безне дә ташлап китми.
Кузгалдылар. Шулай да, ике авыл кырларын аерып торучы межага җиткәч, Габделнур, иелеп, кабинага дәште:
— Агайне, туктале.
— Ни булды? — дип сорады шофер, машинасын туктатып.
— Бу межа буйлап сезнең авылга кайтып була бит. Әйеме?
— Әйе.
— Алайса, сиңа бик зур рәхмәт. Ә мин моннан җәяү генә кайтыйм инде. Рәхмәт, яме.
— Ихтыярың. Ну, сау бул. Син бетерепме соң? Әле иртәрәк бит.
— Юк, кунакка гына. Дембельгә тагын өч-дүрт ай кала.
— Түз казак — атаман булырсың, диләрме әле. Күп түгел инде.
Машина, сулга борылып, агачлар тирәли китеп барды.
Юлында шундый изге бәндә очравына Габделнурның күңеле тагын да күтәрелеп китте. Ул бәләкәй чакта ук утыртылган кыр ышыклау урман полосасының, халыкча әйткәндә, посадка яки межаның, шактый биек булып үскән өрәңге агачларындагы кошлар да солдат абыйларын сәламлиләр иде шикелле. Туган якның тымызык кына искән җылы җиле дә тәнне генә түгел, җанны да иркәли сыман... Кояшы да яктырак, болытлары да аграк, күге дә зәңгәррәк... Ә инде еракта шактый зур булып җәелеп утырган туган авылын, кайсында озын-озын эскертләр салынган, икенче җирдә рәт-рәт салам күбәләре тезелешкән, ә бер урында инде сөрелгән чем-кара туфраклы басу-кырларны, үз артларыннан тузан болыты ияртеп әкрен генә хәрәкәтләнүче комбайннарны, аларга таба барганда тәрәзә пыялаларында кояш нурлары чагылып киткән җитез машиналарны күргәч, Габделнурның күңеле бөтенләй нечкәрде, күзләре дымланды: «Туган җирем! Мин сине гомерем буе сагынып яшәдем!..»
Аргы басулар да, биргеләре дә, кыскасы, туган авылының һәр карыш җире таныш... Таныш дигәннән, әнә Рудник тирәсеннән авылга таба бер машина ипи төяп кайтып килә. Җыйнак кына машина, артык кумый да, ләкин әкрен дә кыймылдамый.
— Әти булса кирәк, — дип куйды Габделнур.
Аның кечкенәдән үк күзе үткен булды: һавадагы торналарны, тилгән яки бүтән кошны бик ачык күрә торган иде. Бүтән малайлар инде аларны күздән югалта, ә Габделнур әле һаман, башын күтәреп, күккә карап тора. Болай гына түгел, ә күреп. Аннан инде кош күк йөзе белән бер төскә кереп эри, югала яки аны ак болытлар үз кочагына алып йота.
Самолетлар белән дә шулай була иде. Илленче елларда алар авылы өстеннән берәмләп кенә түгел, ә унар-унбишәр самолет берьюлы көнчыгышка таба оча иде. Габделнур аларның Корея ягына, сугыш барган дәһшәтле якларга юл алуын соңрак төшенде.
Әнә нәкъ шул маршрут белән биектә-биектә ак эз калдырып бер самолет китеп бара.
Малай чагында ул, сәмәлүт, мине дә утырт әле, дип, аларга кычкырып кала торган иде. Теләге, карчыклар әйтмешли, фәрештәләрнең «амин» дигән чагына туры килде бугай — самолет булмаса да, машина-поездлар аны утыртып, туган төбәгеннән әллә кайларга, чит-ят җирләргә илтеп ташладылар...
...Бабай елгасы дип аталган кечкенә елгачыкның аргы башыннан бу як ярга сикереп чыксаң, Алып чабата каккан җиргә юлыгасың. Ул — бәләкәй генә калкулык. Малай чакта әкиятләр, риваятьләр, уйдырмалар сөйләү гадәти нәрсә бит. Шул тирәгә җитәрәк, Габделнур һәм аның дуслары — урам малайлары — бәхәсләшә-бәхәсләшә, бер-берен бүлдерә-бүлдерә сөйли башлыйлар иде.
— Алып батыр урманнан кайтканда бик нык арыган булган...
— Юк ла, урман кисүдән түгел.
— Шуннан инде, Баграж урманыннан... Бик беләсең килсә.
— Аңа Багражда ни калган? Ул заманда безнең авылның үзендә кара урманнар тулып яткан.
— Алайса, нигә бер агач та калмаган?
— Нигә көләсең? Көлмә кешедән — авызың өшегән...
— ...Көлсәң дә ярый синең ишедән... Төртмә миңа...
— Бик беләсегез килсә, яудан кайтышы булган аның, Пугач явыннан.

— Син белгәнне без әллә кайчан киптереп элгән... Сәнәкчеләр явыннан түгелме тагын?! Әйттең сүз. Беләсең әбиеңнең келәсен...

— ...Бабаңныкын күргәчтен, шырык-шырык көләсең... Син б... та белмисең, апаем, шуңа быел утырып калдың... Ул әнә теге тау астында, базга төшеп, бакыр казыган... Бер байга, фабрикантка ялланып эшләгән безнең авыл егете ул Алып батыр...

— Мин дә күрше авылныкы димим лә...

— Казыган сиңа... Бакырны Рудниктан гына алганнар... Бабай үзе сөйләде...

— Синең бабаң сөйләр...

— Ни булган минем бабайга? Герман сугышыннан ике Георгий алып кайткан ул! Белдеңме?!

— Шул тәреләрне тагып йөриме?

— Нишләп йөрсен ди. Сандыкта саклый...

Аннары малайлар, бәхәсләшүдән арып, уртак бер нәтиҗәгә киләләр: чыннан да, Алып батыр каяндыр кайтышлый ул төшкә туктаган, утырып, чабатасын каккан. Һәм менә шул калкулыкны «Алып чабата каккан җир» дип йөртә башлаганнар. Кайчан булган бу хәлләр, аны беркем дә белми, әлбәттә. Ул тирәгә Габделнурлар еш барды. Чөнки анда кәҗә сакалы котырып уңа иде. Аны ашаганда иреннәр чабырып бетә. Өйгә дә алып кайтасың. Көлтә шикелле итеп бәйләп, аркага асып күтәреп кайтасың да кар базына салкынга төшереп куясың...

...Халык телендә Иске Авыл дип йөртелсә дә, чынлыкта инде күптәннән монда бер генә йорт та калмаган. Ләкин нигез, баз урыннары сакланып калган чокыр-чакырлы яр буен, тар һәм аз сулы елганы, ике текә ярны тоташтыручы борынгы Таш күперне күргәч, егетнең йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Ә уңга таба яр буйлап бераз барсаң, Корт сызасына — җиләклеккә, арырак китсәң, кайчандыр тарантаслы ат төшеп юкка чыккан, дилбегә җитмәслек тирән Төпсез күлгә, аның янәшәсендәге Олы күлгә, кеше күзеннән читтәрәк качып яткан Якты күлгә тап буласың...

Кая гына карасаң да, балачак хатирәләре булып шушы изге урыннар белән бәйле вакыйгалар искә төшә. Әйтик, Олы күлдә су коену, аннан да бигрәк балык тотуы рәхәт иде. Авылдан алты чакрым ераклыкта булса да күл авыл халкына гомер-гомергә игелекле хезмәт итте: мал көтүе туплауга шунда килеп туктый, су эчә, әйләнәсенә ятып ял итә; бала-чага камыш арасыннан (кул-аяклары үткен камышка киселүне дә тоймыйча) балык сөзеп мәш килә; шул тирәдә иген иккән яки печән чапкан ир-ат, аның саф суында коенып, ә хатын-кыз, биткулларын гына чылатып, тәненә сихәтлек ала, җиңеллек таба.

Элегрәк елларда андагы балыкның саны-чуты булмаган. Габделнурга әтисе сөйләгәннәр әле дә хәтерендә: биш-алты ир-ат (яшьрәк чакта) баралар икән дә балык сөзәләр, капчыкларга тутыралар. Аннары, берәүне арты белән бастырып, капчыкларга төртеп күрсәтә-күрсәтә, балык бүләләр.

Әйтеп торучы:

— Бусы кемгә? — дип сорый.

— Фәләнгә.

Әлбәттә, әз-мәз хәйләсез булмый инде берәр төрле эш-гамәл башкарганда, бигрәк тә әйбер бүлгәндә. Арты белән басканы һәм әйтеп торучы арасында язылмаган канун шикеллерәк сүз берләшү бар: бусы кемгә, димичә, бусысы кемгә, дисә, икесенең берсенең исеме әйтелә. Чөнки бу юлы бармак мулрак капчыкка төбәлгән. Моны хәрәмләшү дисәң дә ярый, авылча гади генә эчкерсез шаярту — кызык табу дип исәпләргә дә мөмкин. Югыйсә калган капчыклар да буш түгел, хәтта ки бертигез чамада балык белән түбәләмә тулы. Кыскасы, бу игелекле күлдән балыкны күрше авыллар да олау-олау тотып кинәнгән.

Дөрес, Габделнурлар үскәндә алай капчыклап тоту юк иде инде, бары каз утырта торган, нәзек талдан үрелгән чуман яки җиңнәрен бәйләгән күлмәк белән генә сөзәләр иде чистартып кайнар табага салгач та сикереп-кыймылдап куючы үтә тере һәм тәмле табан балыкны. Нефть эзләүчеләр килеп, бораулау өчен су кирәк булганлыктан, Олы күл янына алагаем зур насос китереп куйгач, аның суы яртылаш кына калды, балыгы да бетте диярлек. Шулай да кыр үрдәкләре һәм акчарлаклар әле һаман ул борынгы, мәрхәмәтле күлдән бизеп бетмәгәннәр иде.

Габделнур кителенең өске төймәсен ычкындырды, чөнки нык кыздыра иде.

— Монда патруль очрамас инде, — дип көлеп куйды ул, үз-үзе белән сөйләшкәндәй.

Иске Авыл өстендәге басуга башак җыярга килгәннәре хәтерендә. Әйе, элек мәктәп балаларын басудан башак җыярга алып чыгалар иде укытучылар. Икмәкнең кадерле чаклары бар иде...

Ә Иске Авылдан сулга таба яр буйлап китсәң, Кече Юкәле һәм Олы Юкәлегә килеп чыгасың. Кече Юкәледә яз көне әниләре чип-чиста кар суында кер чайкыйлар, бәләк белән аны бәргәлиләр; куллары салкыннан кып-кызыл була, ә үзләре һаман эштә. Олы Юкәле үзәнендә атлар көтәләр иде малайлар, аларны чабыштыралар. Ябык ат өстендә утыруы бик читен, артлары суелып бетә торган иде. Ә барыбер күңелле чор булган.

Тагын да арырак Шалкан тавына, сул як ярдан бераз өскәрәк үрләсәң, Кыр чишмәсенә юлыгасың. Суы сапсалкын — тешеңне сындырырлык, үзе бик тәмле. Шул турыдан тагын да югарырак күтәрелсәң, торымнан торымга тау битен каплаган әби чәче — ак кылганнар сине каршылый. Алар, өзлексез чайкалып, әллә ничә төрле, хуш исле чәчәкләрне җил-яңгырдан саклыйлар булса кирәк.

Ул тирәләр инде Пестемәс тавы. Кем әйтмешли, бот буе авыл малайлары өчен ул китаплардан укып белгән ике бертуган Сак белән Сокны аерган, Каф тавына тиң иде. Үтә биек иде ул. Ә хәзер... Өстәге тигез басуларга

еш кына борчак чәчәләр иде. Малай-шалай басуда борчак өлгерүен түземсезлек белән көтә. Аның кузаклары әле яссы, эчендәге борчаклары яңа гына борынлаган — беленер-беленмәс булып тернәкләнеп кенә килүләр, ә барыбер ач балаларны җәлеп итәләр, күңелләрен алгысытып, йөрәкләрен җилкендереп үзләренә тартып торалар. Малайларның тәкате бетә, көтәр әмәлләре калмый һәм... борчакка «көбеләә төшә» — кузагы белән бергә чәйнисең дә, катырак өлешен — кабыгын — җиргә төкерәсең. Ә борчак җитәрәк, тулыша башлагач, анда каравыл куела: берәр бетәшкән картны яисә усаллыгы белән даны чыккан хәллерәк абзыйны. Ләкин аларның берсе дә авылның чая, курку белмәс җитез малайларын куып җитә алмый. Хәйлә бар бит сугыш турында күп китап укыган, кино караган «башлы» малайларда: ике-өч төркемгә бүленеп, хәрби фәннең бөтен кагыйдәләрен төгәл үтәп, берсе — уң «фланг»тан, икенче төркем — сул «фронт»тан, ә өченчесе — «авангард»тан «һөҗүм»гә күчәләр, бәлки, «атакага ташланалар» дию дөрескәрәк туры киләдер. Кайсы «дошман»га таба йөгерсен җитмешнең теге ягындагы, таягы булмаса, җил иссә дә аварга торган сәлперәйгән авыл агае? Туйганчы «бүсеп», кесәләренә һәм түшләргә тутырып, авыл ягына шылалар бәләкәй «караклар». Өйгә кайтып, үз-үзеңне белештермичәрәк салкын су эчсәң, кайчан күбенү галәмәтләре дә булгалый. Күбенгән сыерларны ике ягыннан кабык белән суккалап, куып йөрткән шикелле итмәсәләр дә, малайларны да жәлләмичә йөгертәләр. Алар артыннан шарт-шорт «мылтык аткан» тавыш ишетелеп-ияреп бара. Ләкин андый хәл бик сирәк була торган иде.

Габделнур, үзалдына елмаеп, атлавын белә. Иске Авыл күперенә җитте. Күпер киң, унбиш-егерме адым озынлыкта, ике ягында нык тимер култыксалар, бер урында яньчелгән — машина яки трактор бәреп киткәндер. Күпернең аскы өлеше таш һәм бетоннан коелган. Кайчан корылганын тәгаен генә белүче юк, унтугызынчы гасыр ахырында булса кирәк, гамәлгә ашмаган Чаллы—Бөгелмә юлы өчен салынган бугай ул.

Бәләкәй «караклар»дан Габделнурның уйлары мал-туарга күчте. Чөнки күпернең ике ягында да, каршы текә ярда, маллар салган сукмаклар киртләч-киртләч булып ярылып яталар иде. Көн туса, мал кайгысы бит крестьянда: ашатасы-эчертәсе, көтүгә чыгарасы, тәрбиялисе... Хәер, хайван ул еш кына үз көнен үзе күрергә ярата. Алар, чирәм, печән, каудан үләне белән генә канәгатьләнмичә, иген басуына да күз аталар. Һәм, әйтергә кирәк, еш кына аңа «хуҗа» булып алалар да күңелләре хушланганчы туклаланалар. Дөрес, сыртларына таяк та эләгә. Ләкин барыбер таякның юан башы мал иясенә төшә: ат атланган каравылчылар малларны җыеп алып кайталар да, кәнсәләр ихатасына яки ферма абзарына ябып та куялар. Хуҗалары штраф түләмичә чыктым юк ул әрсезләргә иркен дөньяга...

## 23

Ә алда биек-биек тупыл агачлары, сәрви, сирень һәм чия куаклары белән урмансыз авылны бизәп торган (әгәр шулай әйтергә яраса) зират. Алар авылда өчәү: берсе — олысы — шушы, икенчесе аннан сулдарак, өченчесе — искесе — урам башында гына. Соңгысында инде күптәннән яңа каберләр юк. Ә тегеләрендә һәр нәселыруның үз урыны бар; адәм баласы вафат булганнарны да бер тирәгәрәк тупларга тырыша. Чит җирләрдә җан тәслим кылганнарны да, васыятьләре буенча яисә якыннарының теләген искә алып, туган авылы каберлегенә җирлиләр, җиде ят арасында калдырмыйлар. Шуңа күрә мазарстан эче һәрчак чиста, чүп-чардан арындырылган була. Борынгылар юкка гына, кешенең нинди халык вәкиле икәнен беләсең килсә, аның зиратын барып кара, димәгәннәр. Урыннары оҗмахта булсын гүр ияләренең! Тыныч йокласыннар.

Зират малайлар өчен кечкенәдән серле, шомлы урын булып саналды. Әмма шуңа да карамастан алар җиләк чемченергә дә, кукы-кузгалак ашарга да зиратка керәләр иде.

Киртә аша эчкә атлаганчы яки капка аша үткәнче иң әүвәл кычкырып сәлам бирергә кирәк.

— Исәнмесез, кабер әһелләре!

Әлбәттә, аларга җавап бирүче юк. Ләкин йоланы үтәү зарури. Шуннан соң малайлар тавыш-тынсыз, куе үләнгә йомшак кына басып, эчкәрәк керәләр һәм, бисмилла әйтеп, җиләк ашарга керешәләр. Бераздан, кайда икәнлекләрен дә онытып, алар тагын да түргәрәк узалар, туйганчы кып-кызыл тәмле җир җиләге белән сыйланалар.

Аннары, кинәт исенә килеп, берсе куркып әйтеп куя:

— Малайлар, әйдәгез чыгабыз. Әнә теге агач артыннан әллә нинди тавыш килә.

Һәм бераз тамак ялгаган ач малайлар зираттан атылып чыгып чабалар.

Габделнур, күп ботаклы биек тупыл агачларына хәл җыярга кунаклаган каргаларның сирәк кенә ишетелгән моңсу тавышларын тыңлап, такталары каралган иске коймалы каберләргә күз салгалап, белгәннәрен укып, сирәк тотылган һәм инде күбесе муртайган киртә буеннан тыныч кына узып китте.

Яшьләр кичке уенга чыга торган, бүтән беркайда да очратмаган исле үләнле болын... Солдат түзмәде, исле үләнне эзләп тапты, бер-ике төп өзеп алды, рәхәт итеп иснәде һәм, як-ягына карангалап, әйләнә-тирәдә кеше юклыгына ышангач, чалбар кесәсенә салып куйды.

Габделнур әле укырга кергәнче үк тальян гармунда уйный, аны яшьләр кичке уенга алып чыгалар иде. Үзенә атап җыр да чыгардылар: «...Самавыры-чәйниге, әллә килеп тә җиттеңме, кичке уен начальнигы?» Бервакыт, ара якын гына булса да, малай кешенең күңелен күрергә теләптер инде, кемдер аны кичке уенга атка атландырып алып китте. Нәкъ чишмә турында бер егет атның сыртына бил каешы белән сыптырган да, тегесе куркуданмы яки авыртуданмы арт аякларын күтәреп тибенүгә, Габделнур гармуны белән бергә лып итеп җир-

гә килеп тә сыланды. Елап, кәҗәләнеп, өйгә кайту ягына борылды. Урамның җиткән кызлары аны юмалап-җайлап көчкә күндерделәр һәм җитәкләп кичке уенга алып киттеләр.

Мәктәп укытучылары яшь-җилкенчәкне кичке уеннан куганда (шундый ямьсез гадәт бар иде шул), кызлар-егетләр кайсы кая тарала, ә Габделнур берүзе артсыз урындыкта утырып кала. Чөнки ул әле уку яшендә түгел...

Еш күргәнгә һәм тыңлагангадыр инде, сәйранлыктагы күңел ачуларның берничә төрле уеннан («Чума үрдәк, чума каз», «Сигезле», «Кулъяулыклы» һ.б.) гыйбарәт икәнен һәм кайбер җырларын да күңел түрендә саклап йөртә Габделнур.

Ачлы-туклы яшәгән, әмма пионер һәм комсомол сафларында тәрбияләнгән авыл яшьләре, алдагы тормышларының бәхетле булачагына өмет итептер инде, болайрак җырлыйлар иде:

Роза, роза...
Роза — гөлнең чәчәге;
Хәзерге матур тормышның
Күңелле киләчәге.

Егетләргә телдән әйтергә базмаган сөю сүзләрен кызлар, җырга салып, тартынып кына булса да кичке уенда түгәрәк әйләнгәндә җиткерәләр.

Роза, роза...
Роза гөлләрем сиңа;
Роза гөлем — саф күңелем —
Бүләк итәм мин сиңа.

Кызлардан егетләр дә калышмый: аларда да гыйшык тота белүче, саф мәхәббәтне аңлаучы, яратудан янып көюче «җон үсмәгән» йөрәк, сөйгәне өчен саргаючы җан бар! Күңел түрендәге яшерен хисләреңне гелән генә кабатлап кадерен җибәрмәсәң дә, кичке уенда алар үзеннән-үзе телгә килә һәм аны әйтү гаеп саналмый. Чөнки кемнең кемгә атап җырлаганын фәкать бер-берсенә гашыйк йөрәкләр генә чамалый бит.

Алия, Гөлия...
Гөл яфрагын ия;
Бер күрүдә гашыйк булдым,
Җаннарым сине сөя.

Җавапсыз мәхәббәт яисә кемнеңдер хыянәте дә җыр булып, мәне булган кеше аңларлык мәгънәдә, башкаларга гыйбрәт-сабак булсын өчен, ләкин әтрафлы яңгырый иде.

Дулкынланып сулар керә
Парахут идәненә;
Ышанмагыз егетләрнең
«Яратам» дигәненә.

Кичке уенда һәрдаим җитди җырлар гына җырланмый. Мәсәлән, бәйге сыманрак уенда җырга маһирлыгы булмаган яки оттырган кеше болай дип такмаклый торган иде: «Бишмәтемдә биш төймә, валлаһи, алтынчысы каптырма, билләһи, бар җырымны җырлап бирдем, кояштыр, белмәгәнне таптырма, җир йотсын».

...Бу болында малайлар елның елында әрлән, йомран ауладылар. Әрлән бик усал, хәйләкәррәк тә — сирәк тоттыра, ә йомранны, буадан чиләк белән су ташып, оясыннан чыгарга мәҗбүр итәләр, ат кылыннан әтмәлләнгән ау белән дә эләктерәләр иде. Тиресен салдырып, киергегә элеп киптерәләр һәм иске-москы җыючы түбән очтагы бер бабайга илтеп тапшыралар. Тире генә түгел, сөяк һәм тимер-томыр да кабул итә иде ул мәрхәмәтле бабай... Авыл малайларының кесәсендә аз булса да, күңелне җилкендереп, горурлык уятып, тиеннәр чылтырый. Ә тиен бик кирәк: шәмәйле уйнаганда да, коймага бәреп акчалы уйнаганда да, пәкене чөеп уйнаганда да... Урыны җәннәттә булсын ул картның... Сугыштан соңгы елларда болында үләксә түгел, бармак башы хәтле сөяк тә аунап ятмый иде.

Яз җитсә, болында әбиләр, тилгән типмәсен дип, бәбкә саклый. Кояш аларны «бик яратып» кыздырганга, борын өстенә яшел яфрак ябыштырып куярлар иде.

Болынның сул ягында, колхозның озын ферма каралтысы белән янәшә, артезиан коесының челтәрле биек манарасы кукраеп утыра. Аның очындагы зур ромашка чәчәген хәтерләткән калай канатлары әйләнми, күрәсең, суны йә иртән, йә кич суырталардыр.

Артезиан коесын Габделнур армиягә китәсе елны, каяндыр чакыртылган осталар, зур машинага көйләнгән җайланма ярдәмендә җирне бораулап, манарасын күтәртеп, берничә көндә эшен бетереп киткәннәр иде. Фәлән

дистә метр тирәнлектән чыккан суы чишмәнеке кебек тәмле булмаса да, маллар йөз чөермичә эчәләр, дип сөйләделәр.

Габделнур отыры авыл мохитенә керә: шифалы суы белән дан тоткан чишмә (солдатның чишмә буена төшеп, салкын суын эчәсе килсә дә, бу уеннан үзен тыеп калды), үз-үзен белә-белгәннән бирле малайлар белән шәмәйле, лапталы уйнап, көрәшеп, кыйнашып-сугышып бетә торган тау башы, Сабир буасы...

Чишмә тау башы урамнан кала малайларның иң яраткан урыны. Монда язлыкта кояш тиз карый, тау башы кардан иртә ачыла, малайлар, уенга мавыгып, әбиләре әйтмешли, дөньяларын оныталар иде. Ул чорда әле сугыш шаукымы бетмәгән (ул тиз генә бетмәс тә) «нимес», «Гитлер» дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә, төрле җырлар, такмаклар халык арасында йөри иде. Малайлар исә халык авыз иҗатының бу төрен бик тиз эләктереп ала һәм тиешле-тиешсез урында кулланырга ярата. Ә монда — иркенлек, фашист явызларны курыкмыйча сүгәргә, аларга карата булган тискәре карашыңны һич тартынмыйча белдерергә була.

Мәсәлән, бер малай, кушучын авыз турысына куеп, репродуктордан чыккан Левитан тавышына охшатыбрак кычкыра:

— Внимание, внимание! Ипи сорый Германия. Бирикме, юкмы?

Ә калган малайлар, сугыш афәте һәрберсенең үз өйләренә кергәнлектән, нәфрәт белән акыралар:

— Юу-у-ук! Ашасын б...!

Малайлар бу авазларга ачлыкта, ятимлектә үткән бәхетсез балачакларының бөтен ачуын салып сөрән салалар ки, Гитлер, әгәр исән булса, дерт итеп китәр иде, дөмеккән булса, каберендә куырылып-калтыранып сикереп торыр иде.

Тәмәке тартырга өйрәнү «дәресләре» дә күпчелек вакыт шул тау башында үтә иде. Чын тәмәке булмаганлыктан, мамык һәм мүк тарта торган иде малайлар. Мамык — иске телогрейка эченнән, ә мүк өй бүрәнәләре арасыннан йолкына. Ләкин кайчагында алар үз урамнарында тәмәке үстерүче бердәнбер абзыйның бакчасына да, сугыш киноларындагы тел алырга барган кыю совет разведчикларына охшарга тырышып, бөтен шартын китереп, кача-поса «рейд» ясыйлар иде.

Ә шәмәйле уйнау — анысы үзе аерым бәян итүне сорый торган, бик күп җәнҗалларга сәбәпче, ләкин малай-шалай өчен иң кызыклы уен иде. Сөяк шәмәйләр, тимер аткыйлар — болар һәр малайның кадерле уен кораллары... Аткыйлары кайчагында «сугыш коралы»на да әйләнә иде. Әйе, бала-чага сугыша да, биш минуттан дуслаша да. Зиһенле авыл хатыннары аларның чәкәләшүенә игътибар да итми. Берәрсе арага кысылырга итсә дә, аны тиз урынына утырта. Бервакыт Габделнур аткый белән җибәргән иде, шәмәйләр яныннан китәргә өлгермәгән мыштырдык уенчының маңгаена килеп тиде. Шул чакта тегенең әле кияүгә чыкмаган апасының чишмәгә суга килеше икән. Ул, чиләкләрен ташлап, малайларның икесен дә җитәкләп, җилтерәтеп Габделнурның әнисе каршына алып барды. Дулый гына башлаган иде, Гөлзифа түти аны тиз туктатты.

— Үскәнем, монда син түгел, анаң килергә тиеш ие... Мин хәзер Габделнурны сүгәрмен, бәлки, сугармын да... Ә бераздан алар тагын бергә уйный башлыйлар бит. Икенчеләй бала-чага артыннан йөрмә...

Шуннан Гөлзифа түти күрше малаен юындырды, икесен янәшә утыртып чәй эчертте. Һәм ике почык борын, берни булмагандай, тагын шәмәйле уйнарга чыгып йөгерделәр...

Сабир буәсенә җиткәч, Габделнур елмаеп куйды. Сансыз-хисапсыз иде монда аларның су коенулары. Кайвакыт дер-дер калтырап беткәнче, сакал чыкканчы коеналар иде. Әйе, озаграк су коенсаң, сакал чыга. Ләкин ул чын сакал түгел, билгеле, ә судагы тузан, ләм яки бүтән пычрак ияккә башта беленер-беленмәс кенә булып ябыша, аннары инде бөтенләй каралтып тора.

Кем күбрәк чума, кем озаграк су астында тора, кем тизрәк бер ярдан икенче ярга су астыннан атлап (монда һәркем өскә калыкмасын өчен кулына үзе күтәрә алырдай таш тота) бара, кыскасы, малай-шалай һәрчак үзенә кызык таба.

Анда уйнау-шаяру гына түгел, тәпәләшеп китүләр дә еш була иде. Берчакны Габделнур үзеннән ике-өч яшькә кечерәк бер малайны күтәреп суга томырды. Ә бу вакытта нәкъ шул турыда аста да бер малай булган икән. Чәкештеләр. Берсенең яңагы, икенчесенең маңгае ярылды. Китте елаш-кычкырыш...

Бәлагә тарыган малайларның берсенең абыйсы да шунда иде, гөнаһ шомлыгына каршы. Абыйсы дигәч тә, ул аның бертуган абыйсы түгел, ә кодаларына кунакка кайткан шәһәр егете иде.

Ул ел саен кайта, кайткан саен, урам малайларын җыеп, урысча сүгенергә һәм оятсыз такмаклар җырларга өйрәтә. Сүзләрен, җырның мәгънәсен юньләп аңламаган авыл гыйбадлары, тау башында берсеннән-берсе уздырып, «Семеновна»ны сибәләр.

Шәһәр кунагын рәхмәт йөзеннән татарча җырларга өйрәтәләр һәм ул, авыз тутырып, малайлар артыннан кабатлый:

Сездә сөтне нишләтәләр?
Бездә катык итәләр.
Төнге сәгать уникедә
Кызны хатын итәләр.

Шәһәр малаеның татарчасы такы-токы — чамалы. Гел урысча сөйләшеп йөргәнгә, ачуларын китерсә, малайлар аның үзенә дә, такмаклап, үзе татар булып та юньләп ана телендә сөйләшә белмәгән шәһәр малайларына атап чыгарылган татарча такмак әйтәләр.

Шуннан соң ул чынлап торып татарча сөйләшергә өйрәнә башлый. Монда сөйләшә, ә шәһәргә киткәч, тагын оныта, күрәсең. Икенче елны кайтканда татарчасы тагын ташка үлчим — килделе-киттеле була торган иде.

Бервакыт боларның күршесе бер абзый, улым, әбиең ни ашата, дип сорый икән. Малай, мулла буткасы, дигән. Бабасы авылның мулласы иде. Менә шуннан аңа бу кушамат йогып калды. Инде хәзер егет булып җиткән кунак яр башына килеп кенә туктаган иде.

— Кем обидел? — дип сорады ул елап торучы энесеннән.

Малай, обиделның ни аңлатканын белмәсә дә, кем дигәннән үк яхшы төшенде булса кирәк, Габделнурга төртеп күрсәтте.

Югыйсә малайлар инде судан чыккан, җәрәхәтләрен карап, бер-берен юатып торалар, бәлки, шуның белән бәхилләшкән дә булырлар иде. Әле бит иртәгә дә көн бар...

Кунак егет җилдереп таудан төшә башлауга, Габделнур күпернең икенче ягыннан түбән таба элдертте. Мулла Буткасы аны куа китте.

Ничек башына килгәндер, Габделнур кеше буе булып үскән куе кычытканлык арасына ыргылды. Ә шәһәрдә үскән иркә егетнең бу чытырманлыкка керергә йөрәге җитмәде, гәрчә ул киемнән булса да. Габделнур сыпыртты гына. Байтак вакыт узгач кына ул, бөтен тәне кып-кызыл булган хәлдә, кычытканлыкның аргы башында, әллә кай еракլыкта, ачык җиргә чыкты. Бераздан, аның киемнәрен күтәреп, энесе килеп җитте...

Ул төнне Габделнур таңга чаклы саташып, бастырылып чыкты. Бермәлне уянып китсә, әбисе аны, белгәннәрен укып, өшкереп утыра иде. Шуннан соң гына малай тынычлап йоклап китте.

Икенче вакыт, шәмәйле уйнаганда, бер малай белән сугышып туйгач, ул кулындагы шактый саллы ташны, суга карамыйча гына, яр өстеннән буага ыргытты. Кирәк бит, таш бер казның башына килеп тигән. Аның өчен күрше карчыгы каргады Габделнурны.

— Әй шомлык, олтырак бит, чабата чырай, яхшыдан яман туган нәрсә. Каһәр иңгере! — дип әйткәне генә хәтердә калган.

Әлбәттә, сүгү сүзләре моның белән генә бетмәгәндер. Йә инде, аның миңгерәү казының төп-төгәл таш төшәсе урынга йөзеп килүенә малай гаепләме?! Таш дигәннән, кайчагында малайлар, кесәләренә яссырак җиңел ташлар тутырып, буа кырыена киләләр дә суга таш аталар. Ташны җай белән, яткырыбрак ыргытырга тырышалар, һәм ул судан сикереп-сикереп бара.

— Минеке өч тапкыр мәчте!

— Минеке — җиде!

— О-о малай, син җиде тапкыр өйләнәсең икән болай булгач.

— Өйләнерсең, бар, шәригатькә сыймый ул алай.

— Әйе, Коръәндә дүрт тапкыр гына дигән.

Шуннан китә бәхәс, сүз көрәштерү, чыр-чу килү, көлеш-шаярыш, ә ташлар су өстеннән сикерә тора... «җегетләр»нең ничә мәртәбә «өйләнәчәген» саный...

Кызганычка каршы, мондый гөнаһсыз уеннар гелән генә ике арада «солых төзеп», тынычлык һәм үзара килешү юлы белән бетми. Кайчагында берәрсе көнчелегенә чыдый алмыйча чамадан тыш арттырып җибәрә.

— Ә минеке — ун мәртәбә!

— Әләй, кит әле, алдакчы, биш кенә мәчте бит! Үзем санап тордым.

— Кем яңгалчы, минме? Күзеңне ачып кара, Кылый пәри!

— Ә син — Кендек!

— Хәрәмләшә ул. Шәмәйле уйнаганда да шулай. Маңка керис, артыннан килә бер ис.

— Ә син тик тор, Төлке!

— Әле шулаймы? Бәкри, Бәкри, Бәчмәчә, атаң арыш чәчмәсә, анаң урак урмаса, ни ашарсың, Бәчмәчә?!

Бер-берсен ялганда тотудан яки, киресенчә, яклаудан башланган низаг кушаматлар белән үртәшү, әрепләшү, кыр талашып олыларча сүгенү белән дәвам итә дә тәпәләшү белән очлана.

Кыш җитсә, шул тирәдә чана шуалар иде: күпчелек вакыт бәләкәй чаналар белән, ә кайвакыт ат чанасына утырып. Аңа бер-ике генә түгел, бөтен урам малайлары-кызлары сыя. И кызык та була торган иде чана ауган чакларда... Хәер, аста калучыларга бигүк кызык та булмагандыр. Аста дигәннән, бәләкәй генә шушы буада боз астына китүчеләр дә булгалады, бәкегә төшүчеләр дә... Берчакны Габделнурның энесе дә бәкегә егылды. Ярый әле абыйларыннан калган кайры тун кигән иде: чалкан ята җәелеп... Апасы тартып чыгарды...

**24**

Габделнур бәләкәй капканы ачуга ук әнисен күрде. Бәрәңге һәм кар базлары, аларның бирге башындагы суган түтәле тәбәнәк койма белән әйләндереп алынган иде. Кар базы турысында, агач келәткә хәтле, коймага терәп утын әрдәнәсе өелгән. Әнисе сул кулының беләгенә ашыкмыйча гына утын салып маташа. Күтәрә алган хәтле салды да, буш булмасын өчен уң кулына бер ярка тотып, ул капкага таба борылды һәм, чемоданын бас-

кычта калдырып, тиз-тиз аңа таба атлап килүче солдатны күрде. Улын танып сүз әйтергә өлгергәнче, Габделнур, җайлап кына әнисенең кулыннан утыннарын алып, әрдәнә өстенә куйды. Шуннан соң гына кулын сузды.

— Әни, исәнме!

— Исәнме, улым! И балакаем, кайттыңмы?!

Габделнур тартынып кына әнисен кочаклагандай итте. Кайбер халыкларда кабул ителгәнчә лач-лоч үбешүне әйткән дә юк, хәтта кочаклавы да аркасыннан кагу гына иде. Кечкенәдән үк төчеләнүгә өйрәнмәгән, күнекмәгән бала да, аларны шулай тәрбия кылган ана да беренче карашка салкынча, корырак исәнләштеләр кебек тоелырга мөмкин иде. Ләкин ананың мөлдерәмә яшь тулы күз карашы, улының зур кулын үзенең кечкенә учларына алып каты итеп кысуында, аны сыпырып-сыйпап торуында шулкадәр наз, җылылык, көчле сагыну ярылып ята иде. Артык сүз, артык хәрәкәт һич кирәк түгел иде бу минутларда аларга ана белән баланың якынлыгын аңлатырга.

— Әни, исән-сау торасызмы?

Гөлзифа түти күз яшьләрен алъяпкыч итәге белән сөртте. Сулу алды. Шуннан соң гына әйтте:

— Ару әле, улым. Үзең исән генә кайтып җиттеңме? Бөтенләйгәме?

— Әле белмим, ничек булыр. Экзамен бирдек тә таралыштык.

Габделнур әнисе кулыннан алып куйган утын агачларын үзенең беләгенә сала башлады.

— Улым, бигрәк күп төйисең, — диде әнисе. — Киемеңне пычратырсың. Кая, үзем күтәрим.

— Каккач бетә ул.

Тугыз-ун адымны алар янәшә атладылар: моннан өч ел элек улын күз яшьләре белән изге теләкләр теләп солдатка озатып калган, аны көнаралаш төшләрендә күргән, бер көн дә уеннан чыгармыйча иртә-кич аның исәнлегенә дога кылган, хәзер менә улы янында ничектер тагын да кечерәеп калган ябык гәүдәле ана һәм шактый дөнья күреп, дары иснәп, солдат шулпасы эчеп кайткан төз буйлы, таза җилкәле улы.

Әнисенең өстендә җиңнәрен сызганып куйган чуар ситсы күлмәк, алъяпкыч, башына ак яулык бәйләгән, аягында йон оекбаш белән кызыл эчле кара галош. Гадәти авыл киеме. Ләкин Габделнур өчен алар дөньяда иң затлы кием. Чөнки аларны әнисе кигән. Борынгы көмеш беләзек белән гәрәбә муенса да Габделнурга кечкенәдән таныш. Чигә чәчләре тагын да агара төшкән, ябык булса да, йөзе түгәрәк, һәрчак нурлы, ягымлы.

Гөлзифа түти улының исән-имин кайтуына шөкрана кылып, сөенеп, сокланып туя алмый. Улы ыспай яшел киемнән, төймәләре август кояшында ялтырап тора, кызларныкыдай нечкә билен киң каеш белән буган, аның да аелында кояш нурлары уйный, башында козыреклы фуражка, аягында күн итек. Ана өчен ул һаман бала, йөрәк парәсе. Ә бит элеккегә караганда олыгаеп киткән; гәүдәгә төз күренсә дә, йөзе ябык чырайлы: чип-чиста итеп кырынган, чәче дә артык җитү түгел.

Габделнур әнисеннән күзен алмый, үзе сораштыра:

— Әти эштәме?

— Ие. Комбайннан ипи ташый.

— Әбиләр ни хәлдә?

— Алар да беркөе. Арҗак әбиең үз өендә яшәп ята.

— Суны син илтәсеңме?

— Ие.

— Апалар килгәлиме соң?

— Апаң — сирәк... Кыз баланың... Бәндәләргә бәндә бит ул кыз бала, мескенкәем... Кияү ике көнгә бер кереп чыга.

Әнисе дә сорауга күчте:

— Улым, абыең беләме синең кайтасын?

— Юк.

— Апаең белән хат язышасызмы?

— Әйе.

Ишек төбендә Гөлзифа түти:

— Бир, улым, моннан үзем алып керим, — диде.

— Юк инде. Әнә чемоданны гына ал.

Барысы да таныш: сап-сары итеп юылган буялмаган баскыч, кожаннар эленгән караңгырак өйалды, сул якта чолан ишеге, уңда веранда, клеенка белән тышлап җылытылган өй ишеге... Габделнур ничек кенә тырышып иелсә дә, бусаганы атлап кергәндә, фуражкасы чак кына төшеп китмәде.

Утыннарын мич каршына куеп, ул ачык ишектән сак кына олы якка күз салды. Әбисе намазга утырган икән.

Ана улына дәште:

— Улым, өстеңне сал.

— Ярар.

Шулай дисә дә, Габделнур кителен салмады, чөнки аның өстендә якасыз ак солдат күлмәге иде.

— Улым, утыр. Тәпи өсте торма.

Габделнур, күңеле нечкәреп, өй эчен — бәләкәй якны күздән кичерде: әнисе таш катыгы белән агарткан ап-ак мичне дә, тәрәзә каршындагы озын өстәлне дә, ике тәрәзә арасына эленгән рамы бизәкле борынгы көзгене дә, стена буендагы түшәк-ястыгы җыештырып-өеп куелган тимер караватны да, иске урындыкларны да (икесе — артсызлары — өстәл астына этәрелгән). Бөтенесен хәтерли, һәрберсе үз урынында: матча кашагасы, сөлге-тастымаллар, юынгыч... Түшәмнең киң нарат такталары бераз түбән төшкәнме, әллә инде сап-сары итеп юылган идән сайгаклары чүт кенә өскә калыкканмы, һәрхәлдә, өй ничектер тәбәнәкләнеп калган шикелле иде. Әллә егет үзе үсеп киткәнме? Кечкенә чакта иске шкаф янына басып, аның почмагын пәке белән киртләп-киртләп куялар иде. Ул олы якта... Исән микән әле?..

Габделнур, өйалдына чыгып, итеген, фуражкасын салып керде. Ачык ишектән олы якка күз ташлады. Әбисе намазын тәгәлләп торып килә иде.

Габделнур бусаганы атлап керде, аңа дәште:

— Әби, исәнме?!

Әбисе башта аптырабрак калды, күзләрен йомгалап алды, аннары, оныгын танығач, йөзе ачылып китте.

— Ай Алла, кем бу дип торам. Исәнме, улым, исәнме!

Алар бик җылы күрештеләр, хәл-әхвәл сораштылар. Кызгылт-чуар француз яулык бәйләгән, озын күлмәк кигән, йөзен җыерчыклар яргалаган әбисенең яше шактый булса да, әле гәүдәсен туры тота, ябык, үзе әйтмешли, чәүкә чукырлык та ите юк. Шулай да аның чирләп урын өстендә ятканын Габделнур хәтерләми. Әбисе белән күрше авыл урманнарына (үзләрендә урман түгел, бер агач та юк) чия, миләш җыярга барган чаклары исенә төште Габделнурның: терек-терек җәяү атлыйлар иде барганда да, кайтканда да... Әбисе артыннан көчкә өлгереп. Әбисе мунча ярата иде. Хәзер дә шулай микән? Кайчагында көненә икешәр тапкыр да керә. Әнисенең «кием черетеп» дип сукранганы бар иде. Ике керүнең сәбәбе шул: күрше-күлән алар мунчасына яга да, карчык-корчык иптәшкә бер-берсен дәшә.

Габделнур кечкенә чагында әбисенең аны ләүкәгә сузып салып, ай-ваена карамыйча, акырта-бакырта каен себеркесе белән чапканын һич онытмый. Үсә төшкәч, егет өчен мунча яхшы гадәткә әйләнде.

Әбисе диванга утырды, солдат — артлы урындыкка. Ишек янындагы кыйбла як почмакта туку станы тора иде. Ул инде иске, кем әйтмешли, кадими заманыннан калган. Ләкин әле дә хезмәт итә икән: корылган, соса һәм кылыч-шүреләре үз урынында, аркау җепләре тартылган.

— Әле һаман палас сугасыңмыни, әби? — дип сорады оныгы, станга таба ымлап.

— Тик торганчы, — диде әбисе, дисбесен тәрәзә төбенә куеп. — Идәнгә генә ул...

Чыннан да, идәнгә тар палас җәелгән — каты җептән — яңа, ә әбисе йоклый торган караватның паласы — төрле төсләргә манылган йон җептән сугылганы иске — аңа таныш иде. Туку станы янында, идәндә, каба, аңа йон бәйләп куелган, орчык кыстырылган.

Әбисе шушы авыл кызы. Аның өч апасы күрше авылларга кияүгә чыкканнар, ә абыйсы белән энесе читкә китмәгәннәр. Абыйсы, Беренче бөтендөнья сугышында немецларның газ атакасына эләгеп, сукыраеп кайта, инде вафат. Энесе исән, Урта урамда яши, ул да сугышта булган, ләкин соңгысында.

Әбисе сигез бала таба, өчесе кечкенә чакта ук дөнья куялар. Хәзерге көндә өч кызы һәм бер улы — Габделнурның атасы — исән. Ә аның энесе...

Оныгының уйларын белгәндәй, әбисе:

— Улым, Зыяфетдин абыеңны күрмәдеңме? — дип сорады. — Син ерак җирләрдә йөрдең бугай бит.

— Юк шул, әби, күрмәдем.

— Төшкә гел кайтыр төсле керә... — диде әбисе һәм үзалдына сөйләнеп алды: — Ай кайтсын, көн кайтсын, газиз бәбкәем кайтсын... И-и, кайтмас шул инде, кайтырлык җирләрдә түгелдер...

Әбисенең кече улы сугышта хәбәрсез югалган. «И әби, әле һаман көтәсең икән. Инде сугыш беткәнгә егерме ел була бит». Габделнур Зыяфетдин абыйсын белми. Карточкасын гына күргәне бар. Истәлеккә калган. Чистай медицина училищесында бергә укыган иптәше белән төшкәннәр. Зыяфетдин үзенең абыйсына, ягъни Галләм абзыйга тартымрак озынча йөзле, туры борынлы. Фотода ул җитү чәчле, өстендә пиджак белән ак күлмәк һәм эре кыек сызыклы киң галстук, түшендә ниндидер значок. Ул сугышка киткәндә, Габделнур әле тумаган да. Ә менә бабасы үлгәндә аңа ике яшь була.

Ике олау белән Чаллыдан кайткач, ул атларын да тугара алмыйча, хәлсезләнеп, өйгә кереп ята. Кулын чак кына кыймылдатып, агач кашыклар белән идәндә уйнап утырган Габделнурны үзенә чакыра... Боларны ул әнисе сөйләве буенча гына белә. Әнисенең, бабаң белән, ягъни каената белән сөйләшми идек, дип тә әйткәне бар. Әйе, элек килен балакай каенатадан гына түгел, аның абый-энеләреннән дә тел яшергән. Хәзерге кайбер «отчаянный» киленнәр кебек пәрмә-пәр әйткәләшүне уйлаган кеше дә булмаган. Билгеле инде, каенанага да кадер-хөрмәт зур булган. «Киленкәе эштән кайта Берлинны алган кебек, каенанасы дер калтырый пленда калган кебек» дигән такмаза соңгы сугыштан соң гына чыккан булса кирәк.

«Бабай иртәрәк киткән шул, әле алтмышның өстенә генә чыккан була югыйсә», — дип уйлады Габделнур.

Хәзерге алтмыш яшьлек кешеләр генә түгел, аннан өлкәнрәкләр дә сакал-мыек йөртми.

Ә бабасы турында:

— Мин әткәйнең сакал-мыексыз чагын белмим, — ди торган иде Габделнурга әтисе.

Бабасы бик җор телле, шук кеше булган. Аның уң аягының бармаклары Герман сугышында өзелгән, күн итек башына чүпрәк тыгып куя икән. Бервакыт, Чаллыдан кайтканда, каршыга очраган күрше авыл олаучылары белән, сүз иярә сүз чыгып, бәхәсләшә.

— Бөтен арбаларыгызның тәгәрмәчләрен аяк башыннан чыгарам. Түзәм.

— Юк, чыдый алмыйсың, — дип кызып китә тегеләр. — Үткәрсәң, бер литр спирт куябыз.

Аларның спирт заводыннан килүләре икән. Билгеле, «бик авырлык белән чыдый» карт һәм соңгы тәгәрмәч «аяк йөзен изеп» китүгә ухылдап җиргә ава...

Бәхәс димәктән, юлда андый хәлләр еш булгандыр. Күрше авылның бер кешесе, бәхәсләшеп, икенче берәүнең күн итек башын олтаны-ние белән тешләп өзгән, дип сөйлиләр.

Икенче әбисе — әнисенең анасы — Урта урамда яши иде. Габделнур аның хакында да сораштырды.

— Кодагый әле исән генә йөреп тора, безгә дә килгәли, мине дә чәйгә чакыргалый, — диде әбисе, күңеле булып.

Олы якта да әйбер-кара үз урынында, әллә ни үзгәреш юк: ишектән кергәч тә сул якта, караңгы стенага якынрак, калай белән тышланган түгәрәк мич, ике карават, түгәрәк өстәл тирәли берничә урындык, саргылт төстәге шифоньер. Өстәл өстендә зур гына радиоалгыч, патефон, янәшә үтүк. Урам яктагы өч, верандага караган ике тәрәзәнең пәрдәләре ак, чигүле. Тәрәзә төпләрендә берничә төрле гөл чәчкә атып утыра. Ун телле тальян гармуны күренмәде. Шкафтадыр, мөгаен.

Әбисе белән бераз гәпләшеп утыргач, Габделнур бәләкәй якка чыкты. Ул арада әнисе самавырга су салды, йомырка тезде, капкачын япты да чыра белән ут тергезеп җибәрде, конфоркасын кигезеп күмер салды, торбасын мичтәге тишеккә тыкты...

Әнисенең кулларына карагач, Габделнурның исенә төште: бервакыт, келәттә лар күчергәндә, аның бер бармагы олы агач әрҗә астына кысылган иде.

Әнисе ул чакта, тыныч кына:

— Балалар, чак кына күтәрегез әле, кул кысылды, — диде.

Карасалар, кара кан ага... Никадәр сабырлык биргән аңа Ходай! Хәзер ни хәлдә икән бармагы? Икенче вакыт, бәрәңге базын саман кирпеч белән әйләндергәндә, башына кирпеч төшкән иде. Күпме эш эшләгән үз гомерендә бу бәләкәй, ләкин каты, нык, көчле куллар! Өйдәге эш, бер көн калмый йөргән колхоз эше... Эш... эш... Урагын да урган, чүбен дә утаган, бәрәңгесен дә казыган... Кем аларны санап бетергән дә, кем исәбен алган?!

— Улым, Мәһрүсә апаңнар ни хәлдә?

— Әйбәт кенә. Сәлам әйттеләр.

— Сәлам китерүеңә рәхмәт. Кызы укыймы, эшлиме?

— Укый. Әле унбиштә генә бит.

— Мәһрүсә үзе чирләмиме соң?

— Буладыр инде. Ул вредный цехта эшләп пенсиягә иртә чыккан бит.

Габделнур чемоданыннан Мәһрүсә апасы җибәргән һәм үзе алып кайткан әз-мәз күчтәнәчләрен чыгарды, янә бер кат сәламнәрен ирештерде.

— И улым, рәхмәт инде, — диде Гөлфизә түти, өстәл янында мәш килеп. — Син үзең безгә күчтәнәч. Бу юлы бик озак кайтмый тордың. Берчакны, мунча артында керләр элгәндә, «әни!» дип эндәшкәнеңне ишеттем. Бик сагынганмындыр инде. Икенчеләй чишмәгә суга барам сине уйлап. Кинәт «әни!» дигән тавыш килә. Якягыма каранам, үзем шикләнәм. Чишмә буенда утырып җыладым. «Юләрләнә күрмим тагы», — дим үземә.

— Әни, алай бик еш уйлама инде, — диде Габделнур, елмаеп.

— И улым, бала — бавыр ите, дип юкка гына әйтмәгәннәр инде. Бигрәк яшьли чыгып киттең шул.

— Әни, колхоз эшенә йөрисеңме соң?

— Йөрмәгән кая... Әле кичәле-бүгенле, башым авыртып торгач, сорап калганыем.

Бераздан Габделнур чемоданын верандага алып чыкты. Чалбар кесәсендәге исле үләнне чемодан төбендәге мактау грамоталары арасына кыстырып куйды, үзе уйланды. Әнисенә, алай бик еш уйлама, дисә дә, бер генә минутка аның хәленә кереп карады. Күбрәккә китә икән шул бер кешегә: әтисе өч ел сугышта булган, абыйсы тиешле срогын хезмәт итеп кайтты, Габделнур үзе әле бетермәгән, инде энекәше киткәнгә дә бер ел тула. Йөрәге генә чыдасын!..

Чәйгә утырганчы Габделнур «патшалар җәяү йөри торган җир»гә барып киләсе итте.

Өйдән чыгуга ук биләмнән кайтып килүче песине күрде. Ул солдат абыйсына күтәрелеп бер карады да баскыч янына килеп утырды. «Актүш әрәм булган», — дип уфтанды, чөнки этнең үлеме турында хатта язганнар иде инде.

Каршыдагы бакчада шомырт һәм миләш агачларында чыпчыклар чыркылдаша, аларның бер төркем иптәшләре туры лапас өстендәге яңа кайткан саламны да сырып алганнар. Лапаста кызгылт төстәге бозау утлыктан нидер чемченә иде, ят абыйны күргәч, капка янына килеп, тәбәнәк койма өстеннән юеш борынын сузды. Аның аяк астында да, ишегалдында да тавыклар җим эзләп йөри, карт әтәч, башын горур тотып, аларны бөртек күбрәк җиргә чакыра. Тавыклар, генерал артыннан ияргән офицерлар шикелле, аның күз карашын тоеп, һәр хәрәкәтенә буйсынып, бөтен теләкләрен дә үтәргә әзер торалар. Кое сиртмәсенә кунган саескан да, бу кем

тагы монда тулгана дигән сыман, Габделнурга карап алды. Солдат, бакча капкасын ачып, эчкә үткәч, чиләге булмаса да, коега килә, ахры, бу, бәладән баш-аяк диептер инде, озын койрыгын сузып очып китте һәм келәт төбәсенә барып кунды.

Әбрәкәй кечерәеп, тараеп калган, кысан, баш тия — чак кына фуражкасы төшеп китмәде. Өч ел зур-зур гомуми бәдрәфләргә өйрәнгән кешегә монда бик җайсыз иде. Югыйсә әллә ни үсмәде дә сыман, бер-ике сантиметрга гына. Алабугада укыганда гына өч елга егерме бер сантиметрга үскән иде.

Габделнур, арт капканы ачып, бәрәңге бакчасына күз салды. Өлгереп килүче бәрәңге сабаклары әле ямьяшел. Күршеләрнең дә бәрәңгеләре уңар шикелле. Бу җир гомер-гомергә аларны туендырды. Сугыштан соңгы ачлык елларны яз көне черек бәрәңге җыяр иде халык, кабартма сыманрак итеп юка гына кәлҗемә пешерер иде. Ләкин ул әллә ни туклыклы түгел иде шул. Шуңа күрә дә халык арасында такмак йөри иде.

Кәлҗемә, кәлҗемә,
Нигә чәчәк атмыйсың?
Күпме генә ашасам да,
Йөрәгемә ятмыйсың.

Сарай-чиннек артындагы бакчада карлыган куаклары куе, биек булып үскәннәр; аларны бәрәңге бакчасы ягыннан әйләндереп алган койма искергән, җепсәләре ярылган, муртайган, алыштырырга вакыт.

— Әти берүзе, абый эштән бушый алмый торгандыр, энекәш армиядә, — дип куйды Габделнур, кеше белән сөйләшкәндәй. — Менә мине дә ай күрде, кояш алды диярлек кенә, берничә көн генә торам да китеп барам. Ярар, исән булсак, отпускыларда кайткаларбыз.

Мунча каршындагы куакларны аралап, бер-ике кура җиләге тапты. Баягы саескан мунча түбәсенә килеп кунган. Мунча ишегендә йозак-фәлән юк, келә урынына да бау бәйләнгән түгәрәк тимер кисәге генә тыгып куелган иде.

...Ашагач, Габделнур, рәхмәт, дип урыныннан күтәрелмәкче булган иде, аны әбисе туктатты.

— Улым, амин тотмадың бит.

Габделнур, гаеп эш өстендә тотылган кеше сыман, кыенсынып кына:

— Өч ел казармада яшәп онытылган икән, — диде һәм, кул күтәреп, бит сыпырды.

Каенанасы олы якка палас сугарга чыгып киткәч, Гөлзифа түти улы янынарак утырды.

— Улым, син догалар беләдериең бит. Онытмадыңмы?

— Юк, әни, — диде Габделнур, көлеп. — Сөйләп күрсәтимме? Әлпи, тиси, әнә бара бер песи, коерыгын кәкрәйткән, анасына кайтып әйткән...

— И улым...

— Ярар алайса, икенчеләрен укыйм. Әлхәм тәбәрәк, җилкәм тагарак, әлхәм шөкер, җилкәм чокыр. Кәлимәтен, таибәтен, безнең әнкәй бай хатын, кесәсе тулы тәңкә, танавы тулы...

— И улым, алай мыскыл итмә инде. Мин бит сиңа «Әлхәм»не дә, «Колхуалла»ны да өйрәткәнием.

— Соң, аның боларын да син өйрәттең инде.

— Анысы шаярып кына бит аның. Без дә олылардан отып алганыек инде.

— Беләм, әни, берсен дә онытмадым. Тик аларны кеше алдында укып, дога кылып утырып булмый бит.

— Күңелеңнән укып йөр белгәннәреңне, сине кеше тикшермәс, юлларың уң булыр. Кояш чыккан чакларда бисмилла әйт. Мин сезнең өчен көн дә теләк телим, балалар. Ходай рәхмәтеннән ташламасын. Тәннәрегезне тәмуг утларына хәрам кыл... Улым, бик ябык күренәсең.

— Безгә күп ашарга ярамый, фигура бозыла, — диде Габделнур, елмаеп. — Әни, үзең әйтмешли, арык тәнем сау булсын.

— Анда ашарыгызга җитәме соң?

— Җитә. Артып та кала әле.

— Анысын нишләтәсез?

— Ашап бетерәбез, — диде Габделнур, көлеп.

— Тамагыңа аша, ач йөрмә. Ябыккансың. Син бәләкәй чакта түм-түгәрәк иең. Элек авылда түгәрәкләр эшләде бит. Түгәрәккә барыгыз, дип әйтеп йөриләр ие. Син шунда, мин үзем түгәрәк, без бармыйбыз, дип әйтә торганыең. Көлеп чыгып китәләр ие.

Тагын бераз сөйләшеп утыргач, Габделнур:

— Әни, мин келәт арасына барып кайтам, — диде. — Берочтан әбине дә күреп чыгармын.

— Рәхмәт, улым, бар, бар.

— Коедан су алып керәсе юкмы?

— Иренмәсәң, бер чиләк кенә керт. Чиләк өйалдында, каплап куйган.

— Беләм.

Дөресен генә әйткәндә, Гөлзифа түтигә әле су кирәкми иде. Шулай да улының теләгенә каршы килмәде. Баласының нинди дә булса эш эшләргә атлыгып торуы, әнисенең исә шуны башкарып чыгарга рөхсәт бирүе — икесенә дә рәхәт иде әлеге минутларда.

Габделнур су алып кергәндә, әнисе өстәлдәге җилпучка он иләп бетергән дә, аның урынына куна тактасы куеп, камыр басарга әзерләнә иде.

— Әнә шунда идәнгә куй, улым, — диде ул.

Габделнур, чиләкне урнаштырып, мич артына күз салгач, үзалдына елмаеп куйды. Элек мич артында бауга тезелгән, кызлар чәче сыман үрелгән суган асылынып торыр, аралыкта лакан, тас һәм комган була иде. Авылның бер кызы, күпмедер вакыт шәһәрдә яшәп кунакка кайткач, зарланып әйткән, имеш: «Шушы авылга кайтсаң, тас та кумган булыр инде». Кемгә ничек, ләкин Габделнурга балачак хатирәләренә чуму, кечкенәдән күреп үскән йорт җиһазлары арасында кайнашу әйтеп бетергесез юаныч, күңел тынычлыгы бирә иде.

**25**

Габделнур урамга чыкты. Иркенләп һава сулады. Кем әйтмешли, күкрәкләре киңәеп китте. Аһ, нинди рәхәт үз авылында, аунап-тәгәрәп үскән урамында!.. Үз яшьтәшләреннән генә дә унлап малай булгандыр; берике яшькә олыраклар яки кечерәкләр җыелса, урам гөр килеп торыр иде җәен дә, кышын да... Әле бит малайлар янында кызлар да була... Хәзер урам тынычрак. Хәер, әнә бер төркем бала-чага чыр-чу килә, бер-икесе велосипедка атланган.Ерактарак өлкәннәр дә күренә: капка төбендә утыручы карт-коры, иңнәренә көянтә-чиләк асып суга баручы хатын-кыз... Этләр дә күзгә чалына — җанлы урам үзенең гадәти тормышы белән яши. Бакча эчләрендә алма һәм чия, урамда өрәңге, тупыл һәм тирәк агачлары.

Әүмән-тәүмән килеп бер оя үрдәк су буеннан кайта. Габделнур үскәндә дә, хәзер дә алар гаиләсе үрдәк асрамады. Үрдәк, ни бирсәң дә, һаман, вак, вак, дип зарлана, ә бер ише әрсезе, бак-бак, өеңне сат, безне ашат, ди бит. Бәлки, шуңа күрәдер авыл халкы күбрәк каз тотты, әби-чәби гомергә болында, су буенда бәбкә саклады. Хәер, бер абзый үрдәк асрады. Ләкин ул аларга тозлы су эчертә торган булган... су буеннан кайтмасыннар өчен.

Күркә асраучы да бар иде алар урамында. Ул йортның хуҗасы Донбасстан кайткан шахтер. Алар энесе белән икәү эшләгәннәр. Энесе шахтада басылып үлгәч, аналары монысын кайтартты. Хет берсе янымда булсын, исән калсын, дип әйткән. Хатыны, татар кызы булса да, шул якта туып үскәнлектән, татарча авырлык белән сөйләшә, ләкин авылча гади, җиңел итеп түгел, ә һәр сүзен җиренә җиткезергә тырышып әйтә иде. Теле йөгерек булмаса да, сөйләме матур. Үзе дә ул бик чибәр, пөхтә итеп киенеп йөри. Бәлки, аның туган якларында күркә асрау гадәте булгандыр... «Сыкы белән күркә симерә», — дип, күркәләрен кышка кергәндә, сыкы төшкәч кенә суялар иде.

Күркә талый, кызыл киемле хатын-кызларга каныга. Хәер, каз да талый, бигрәк тә ата каз: чукып кына ала, сизми дә каласың. Күршедәге бер егет (яшьтәшләре инде армия хезмәтендә иде) Габделнурларга коега суга кергәндә гел аның абыйсыннан яклау сорый иде.

— Ата казыгыз талый, ку әле.

Югыйсә кулында чиләкләре бар, тибеп җибәрсә дә яки чыбык тотып керсә дә була. Күрәсең, кеше малына тияргә кулы күтәрелмәгәндер.

Габделнур, урамнан тыкрыкка борылганчы, чаттагы йортка кереп, анда яшәүче күрше карчыгының хәлен белеп чыкты. Әле исән икән. Егет армиягә киткәндә бу әби, машинаны туктатып, аңа бер сум акча биргән иде. Өч ел буе шул исеннән чыкмады. Юкса үз әбиләре дә бирде, эти-әнисе, туган-тумачасы да. Саубуллашырга дип кузовтан иелгән Габделнурның учына төрткән бер сумы гел хәтерендә сакланды.

Тыкрыкка борылды. Бәләкәй мотоциклга атланган бер үсмер исәнләшеп китте. Алда уңга-сулга ерак-еракларга сузылган Урта урам, аның артында тагын бер урам, анысы кыскарак. Бу авылның өч урамы да бер-беренә буйлай нигезләнгәннәр. Авыл башында буровой вышкасы, арырак икенчесе...

Тыкрыкның ике ягына да бәрәңге бакчасына мал кермәсен өчен сирәк киртә тотылган.

Кая гына караса да, кайдан гына барса да, солдатның хәтеренә нидер төшә.

Әле бик бәләкәй иде Габделнур. Шушы тыкрыкта бер апага, сабый акылы белән аңламыйча, аның халык арасында таралган кушаматы белән эндәшкән. Соңыннан бу апа Гөлзифа түтигә (алар чордаш-ахирәтләр икән), и малай, гарьләндем дә соң, улың, исәнме, Җенле түти, дип эндәште, дигән. Күрәсең, зиһене ачылган вакыт булгандыр, зиһене томаланган чакта аны исендә калдырып, күңеленә авыр алмас иде. Әнисе әрләп тә ташлаган иде Габделнурны.

Ә икенче вакыт, монысы бераз үсә төшкәч булды, ап-ак чиста киемнән — чигүле алъяпкыч, бәбәй итәкле күлмәк, тула оектан йөрүче берәүгә:

— Исәнме, әби, — дигән иде.

Бала бит, каян белсен аның соңгы сүзе тегенең күңелен рәнҗетәсен.

— Фәлән нәрсәңә җон чыксын әле, аннан миңа, әби, диярсең, — дип дулап китеп барган иде теге апа.

Хәзерге акылы белән уйлый Габделнур: күрәсең, ул «әби»гә әле кырык-кырык биш яшьләр тирәсе генә булгандыр, ире сугышта үлгәндер...

Сабый күңеле барысын да ничек нечкәртеп торсын да кемнең нинди уй белән яшәгәнен каян белсен?! Аны өйрәткәннәр, колагына тукыганнар: үзеңнән олылар белән исәнләшеп үт! Һәм ул шулай итә дә, бетте-китте, вәссәлам! Ә кайчагында синең бу «тырышлыгың» кемнедер кимсетү булып чыга, хәтерен калдыра икән.

Моннан, тыкрыктан караганда, агачлар арасына күмелеп утырган мәктәп тә күренә. Мәктәп ихатасын биек тупыл агачлары әйләндереп алган. Кайчандыр аларны Габделнурның абыйлары утырткан һәм тәрбияләп үстергән.

— Директор коштабак белән сыер тизәге алып килергә куша иде яңа утырткан тупылларның кәүсәләрен сыларга, — дип сөйләгән иде абыйсы бервакыт. — Кәҗә ашаган җирен...

Анда җиде ел уку дәверендә Габделнур хәреф танырга өйрәнде, бик күп фәннәрне үзләштереп аң-белем алды; концерт-спектакльләрдә катнашты; әдәби кичәләр дә оештырдылар алар; мәктәп бакчасында эшләделәр; чаңгыга басып, турникта атынып, колгадан яки арканнан үрмәләп көч-куәтләрен арттырдылар, беләк мускулларын ныгыттылар; тәнәфесләрдә (кайчагында дәрестә дә) шаярдылар-шаулаштылар, мәктәптән кайтканда бер-берсен дөмбәсләп, кызып китеп сугыштылар да. Барысы да булды җиде елда. Саный китсәң, аларның исәбе юк. Ләкин кайчагында шуклык кылулары, укытучыларны борчыган мәлләре дә бихисап булды. Хәзер менә шулар исенә төшеп, ниндидер сагыш, үкенү сыман нәрсә өскә калкып чыга.

Бервакыт, авылга буровой бригадасы килеп урнашкач, рус теле укытучысы, яшь кенә кыз, бер егет белән йөри башлады. Бала-чагадан яшереп буламыни андый хәлне. Бигрәк тә малай-шалайдан. Малайлар клубка кино карарга дип чыгалар. Алар билет алган кешеләр арасына кысылып яки алданрак керәләр дә, сәхнә астына үрмәләп, кино башланганчы шунда качып яталар. Анда рәхәт түгел: кысан, тынчу, кайчагында эче киткән берәр малайның нәҗесенә дә буялып чыгасың. Ә шулай да кино карыйсы килү теләге барысына да түзәргә мәҗбүр итә.

Ул көнне малайлар әле клуб тирәсендә йөриләр — ничек тә качып керергә исәп тотып. Укытучы кыз белән «буровой» егет тә клубка киләләр икән, җитмәсә, кычкырып сөйләшәләр. Шунда малайлар Шура апаларының тавышын аермачык ишеттеләр.

— Тише, тише, Николай, ученики есть.

Икенче көнне, рус теле дәресе башланыр алдыннан, Габделнур кара такта янына чыгып басты һәм ишектә марҗа апалары күренүгә сөрән салды:

— Тише, тише, Николай, ученики җис!

Ул йөгереп барып партасына утырды.

Укытучы кып-кызыл булды, класс журналын һәм китап-дәфтәрләрен өстәлгә атып бәрде.

— Гаделзянов, выйди из класса! — дип кычкырды ул.

Габделнур чыгарга уйламады да. Шура апалары, озын аяклары белән олы-олы атлап, ул утырган парта янына килде. Тагын үзенең боерыгын кабатлады:

— Вон из класса!

Шушы укытучы аркасында урысча ярыйсы гына сукалый башлаган Габделнур:

— Не выйду! — диде һәм чытырдатып партага ябышты.

Янәшә утырган укучы кызны торгызды да көчле, таза куллары белән укытучы калын такталардан эшләнгән авыр партаны бөтереп йөртә башлады. Ләкин бәләкәй малай бирешмәде. Ахырда, укытучы аны калдырып, такта янындагы өстәл артына утырып елап җибәргәч, класстан чыгып ычкынды. Билгеле, соңыннан тәртип бозучыны директор чакыртты. Ә анысы, ир кеше, күп сөйләшеп, вакыт сарыф итеп мәшәкатьләнмәде, Габделнур бүлмәгә килеп керүгә яңагына чалтыратып та җибәрде: малайның күзеннән утлар күренде... Югыйсә Шура апасы, аның кыланышын уенга алып, берәр җор сүз белән генә үткәреп җибәрә ала яисә урысча белүе өчен мактап кына да куя ала иде бит. Күрәсең, болай ярамагандыр...

Икенче вакыт, малайлардан кайсыдыр шаярып утырганда, укытучы апалары (кем икәне дә, нинди фәннән укытканы да хәтерендә түгел) бармак калынлыгы линейка белән тондырды. Сулагай кулдан чыгып очкан саллы линейка күршедәге бер гаепсез кызның танавына эләкте. Әйтерсең акыртып суялар: кызый чырулап, үкереп елап җибәрде; борыныннан гөжләп кан китте. Апалары йөгереп кенә чиләк белән су алып керде, юды, маңкасына тикле сөртте, юмалады — ике дәфтәр белән бер бозгыч биреп бәхилләтте.

Әйе, мөгаллимнәр дә бик «тәвәккәл» иде элек. Химия укытучысы, шаярып утырганыңны күрсә, дәшминитми генә килә дә сөяк белән тиредән генә торган беләгеңне узып барышлый гына шундый итеп чеметә, астыңа җибәрердәй буласың. Ә математик абыйлары малайларның «миңгерәү» башын йодрыгының чыгыбрак торган урта бармагы белән төя-төя «акыл бирә» иде: «Башыңны эшләт, аңгыра бәрән, башыңны эшләтмәсәң, миең ачы катыкка әйләнер». География укытучысы гел колакларын бора торган иде. Малайлар җаен таптылар: аның дәресе алдыннан колак яфракларына каз мае сөртә торган булдылар...

Яманы да, күңелле мизгелләр дә, авыр чаклар да — барысы да булды җиде елда. «Балалык юләрлеге белән ачуыгызны чыгарып, кәефегезне җибәреп рәнҗеткән чакларыбыз өчен гафу итегез безне, хөрмәтле һәм кадерле (моны соңрак аңладык!) укытучы абый-апаларыбыз! Булдыра алсагыз, кичерегез эчкерсез, гади авыл балаларын!.. Без сезнең педагогика кысаларына сыймаган, кайчагында гел юктан гына артык уяулык, кирәкмәгән кырыслык күрсәтеп безне кыерсытуларыгызны күптән кичердек инде... Без сезгә ачу сакламыйбыз...»

Габделнур тыкрыктан түбән төшеп китте. Алда зур булып, таралып үсүче биек тал агачлары күренде. Уң якта ялгыз ихата. Ул ике урам арасында берүзе. Ихата буш түгел, анда бер гаилә яши: өйләре, каралты-кура, мунча, бәрәңге бакчалары бар. Өй каршыннан тар гына булып инеш ага һәм күпер төбендә югары очтан төшү-

че елгага тоташа. Хуҗа — йорт җанлы кеше — су буйлап тал агачлары утырткан. Алар инде ботак җибәргән, яфрак ярган.

— Безнең якның кара туфрагы нинди бәрәкәтле, — дип куйды солдат егет. — Юкка гына, тәртә тыксаң, арба үсә, димәгәннәр шул.

Габделнур күпергә карады. Кайсыдыр елның ташу вакыты хәтерендә яңарды. Күпер өстеннән шаулап салкын, бозлы су ага. Ике якта да халык җыелган: кемнәрдер теге яки бу якка чыгарга ниятләп килгән дә туктап калган, кайберәүләр — ничә елга бер генә була торган көчле язгы ташу карарга. Чөнки соңгы елларны су күпер өстенә менми иде.

Теге яктагы ир-егетләр бу урамның салырга яратучы бер кешесен котырталар:

— Вәли абый, әйдә безнең янга чык!

— Аракы бар!

— Менә.

Һәм алар шешә күрсәтәләр. Күпер озын түгел, чыннан да аракы икәне аермачык. Кичә түнеп ятканлыктан махмырлы башы юньләп эшләмәсә дә, бүген тагын «төшерергә» җай чыгуын күреп, иске солдат шинеле кигән Вәлиулла абый тәвәккәлләп кермәкче була. Урамдашлары аны бу уеннан кире кайтармакчы.

— Нишлисең, Вәлиулла, тилермә!

— Ташу алып китәр үзеңне!

— Башсызланма!

Ул туктап кала.

Теге яктан тагын, ымсындырып, аракы шешәсен болгыйлар.

— Әйдә, чык, курыкма!

Бу як кисәтә:

— Суга батып үләрсең!

Вәлиулла абый кеше сүзенә колак салмыйча алга атлый һәм... күпер өстеннән ургылып аккан ташуның куырып ала торган бозлы салкын суына ботинкасы белән кереп китә. Җиде-сигез адым атлап, уртага җиткәндә генә сандык кадәрле бер боз кисәге аны аяктан бәреп тә ега. Халык аһ итә, кычкыра, шаулаша башлый.

— Вәли ага-а! Вәли ага-а-а!

Ә Вәлиулла абыйның соры солдат шинеле боз кисәкләре белән бергә күпердән ераклашып та бара. Ярый әле башындагы иске бүреге үз урынында. Ике яктан да халык, күбесе яшьләр һәм малай-шалай, йөгерешә башлый. Кайсыныңдыр башы җитә: теге якта торган җигүле атның дилбегәсен ычкындырып ала. Ә бу якта ике егет бәрәңге бакчасы киртәсеннән бер колга суырып алалар да яр буйлап Вәлиулла абыйны «куа» китәләр... Күпердән ике-өч йөз метр китеп өлгергән «башсыз» адәмне колга ярдәмендә көч-хәл белән ярга тартып чыгаралар...

Колга дигәннән, тагын бер вакыйга Габделнурның хәтерендә яңарды. Авылда кыз тоту йоласы бар. Урамда, борылмада, тыкрыкта берничә егет юлга аркылы колга сузып куялар да атлар килеп җиткәндә генә аны күтәрәләр. Арада иң «әтчәенние» кыңгырауларын чыңлатып, шөлдерләрен чылтыратып килгән атның башыннан эләктерә. Кияү егете уяу булса, тоттырмаулары да ихтимал, йоклабрак барса — сүзгә яки җырга мавыгыбрак китсә — килеп каба инде: кияүнең алдан әзерләп куйган шешәләрен чыгарта. Габделнурның үзе кебек үсмерләр һәм бер-ике олырак егет белән беренче тапкыр кыз тотуы шушы тар күпердә булды...

Сул якка карап бара торгач, янә бер вакыйга кылт итеп Габделнурның исенә төште: энесе белән икесен бер абзый куган иде. Малайлардагы мутлыкның, дөресрәге, наянлыкның чиге-чамасы юк бит. Ул абзый алар урамында көнбагыш һәм яшелчә үстерүче бердәнбер кеше; яшелчәсенә кереп булмый, анысы өй түрендәге бакчада. Үз малаена да юл ябык, бүтәннәргә ни сан... Бу бервакыт әйткән ачудан: «Әткәй үлсә, рәхәтләнеп кишер ашар идем». Ә көнбагышны бәрәңге бакчасының берникадәр өлешенә, түбәнгә утырта иде абзый.

Менә шул, Габделнур белән энесе, аръяк әбиләренә чыкканда, шайтан коткысына бирелеп, абзыйның инде өлгереп килүче көнбагыш башларына күз кызартып карап бардылар да астан, су буеннан, көнбагыш арасына кереп тә киттеләр. Гөнаһ шомлыгына каршы, абзый киермә бакчасына ук чыгарып салынган мунча тирәсендә кайнаша икән. Берзаман малайлар шул якка карасалар, котлары алынды: туп кебек йомры тәбәнәк гәүдә томырылып йөгереп төшә.

— Бетте баш, калды муен сереп, — дип кенә әйтеп өлгерде Габделнур. — Сыздык!

Алар, бәлеш зурлыгы көнбагыш башларын җиргә атып, җан-фәрманга күпергә таба элдерттеләр. Монда инде су буена төшү дә юк, кинолардагы «маскировка» — саклык чаралары турында кайгырту да юк, җан кадерле! Күзләренә ак-кара күренмәде «җегетләр»нең!

Тыкрыктан атылып, бүредән качкан куяннардай, Урта урамга чабып менделәр менүен, ләкин урам буйлап әбиләренә хәтле йөгерү үзеңне үлем җәзасына дучар итүгә бәрабәр.

Ялт кына уңга борылып, чаттагы ихатаның бәләкәй капкасыннан ишегалдына керделәр дә катып калдылар.

— Ни бар, үскәннәрем? — дип сорады котлары алынган малайларны күргән хуҗа хатын.

Ул җиргә җәеп салган торыпшага таратылган ашлыкны капчыкка тутырып маташа иде.

— Насрулла абый куа! — диде сулуы капкан Габделнур. — Көнбагышына кергәниек...

— Ай Алла, тотса... Барыгыз тизрәк лапаска!

Малайлар торып йөгерделәр. Баскычтан менеп, печән эченә кереп чумдылар.

Бераздан абзыйның ачулы, калын тавышы ишегалдын тутырды:

— Кайда малайларың?

Хуҗа хатын, берни аңламаганга сабышып:

— Аталары белән тегермәндә, — диде. — Ни бар, Насрулла? Исәнме юк, саумы юк...

— Җаңа гына ике малай минем көнбагышны ботарлап чыгып чаптылар. Алар синең малайларың гына, бер дә бүтән түгел! Берсе озын, берсе тәбәнәк...

— Ни сөйлисең, Насрулла, әстәгъфирулла, гөнаһысыннан курык! Тегермәндә, дим бит. Ышанмасаң, бар, тегермәнгә мен. Кайтырлар да инде, юлда ук каршы очрарлар. Менә тагын җыйныйм...

Ышанып җитмәсә дә (боларның малайлары нәкъ Габделнур белән энесе яшендә иде), абзый бераз йомшады булса кирәк. Аларның сөйләшүен ишетеп-тыңлап яткан Габделнурга шулай тоелды.

— Шулаймыни? Һы... Монда керүче булмадымы?

— Юк, юк, Насрулла, булмады.

— Эт җаннар! Кая югалды соң алар? Тотсам, үтерәм!

— И Ходаем, ике баш көнбагыш өчен... — дип әйтә башлаган хуҗа хатынны абзый кырт өзде.

— Кермәсеннәр!

«Ярый әле тотмады, — дип сөенде Габделнур. — Тотса, әтигә әйтмичә калмас иде. Аңардан тагын эләгер иде». Абыйсы кыяр урлап тотылганнан соң нәрсә булганын үзе дә күрде. Әле колхоз кыярын... Әйе, ата кеше ир баласын «песиемләп» үстерми. Бер Галләм абзый гына түгел, барысы да шулай. Бервакыт, апалары классында бер малайны әтисе кыйнагач, атасы сугышта һәлак булган икенчесе, ярый әле әти юк, ату мине дә кыйнар иде, дип әйткән. И ятим нарасый, беркатлы гөнаһсыз җан...

Шактый вакыт узгач кына Габделнур печәнлекнең тыкрык ягындагы бәләкәй тәрәзәсеннән карарга җөрьәт итте. Абзый әкрен генә күпергә таба атлый иде.

Мәрхәмәтле түти, аларны капкадан озатканда:

— Икенчеләй кеше әйберсенә тимәгез, үскәннәрем, — диде.

— Ярар, — диештеләр малайлар беравыздан.

Габделнур атна буена куркып-саташып уянгалады. Ләкин бала-чаганың бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга үгет-нәсихәт. Әле күп мәртәбәләр булгалады шуклыклары.

**26**

Габделнур туган авылының елдан-ел үзгәрүенә, капка-коймаларның төзеклегенә, бертөрлерәк рәвешкә керә баруына да игътибар итте. Элек, ул бәләкәй чакта, таш коймалар да бар иде, җилкапкалы өч рәт киртә тотылганнары да, хәтта буйлый яисә утыртма читәннәр дә. Ә элекке байлардан калган ихаталарны калын тактадан буйлый җибәргән койма белән юан имән баганалы урыс капкалар әйләндереп алган иде.

Әйе, капка-коймалар яңартыла, соңгы елларда салып кергән өйләрнең түбәләре калай да шифер, хуҗалыкта кирәкле абзар-кураныкы — рубероид. Дөрес, араларында инде тузган-искергән йортлар, хәтта кадакланган тәрәзәле, капка төбенә үлән үскән өйләр дә күренгәли. Телевизор антеннасы, су колонкасы кебек әле кайчан гына халыкка ят булган әйберләр дә авыл пейзажының аерылгысыз бер бизәге булып тора. Бакчаларда алмагачлар ишәйгән...

Әбисе өенә барып җиткәнче, Габделнур байтак кына авылдашлары — олысы-кечесе белән күреште. Нинди якын иде алар солдат егет өчен! Туган авылың урамыннан атлау, кечкенәдән үк син белгән, сине таныган кешеләр белән хәл-әхвәл белешү рәхәт. Өч урамлы зур авыл булса да, очраган һәркем таныш... Хәер, болай әйтү чынбарлыкка хилафлык китерү була икән. Чөнки ул үз чордашларын, өлкәннәрне генә белә, ә үсмерләрне, бала-чагаларны тануы аңа авыр иде. Ул укырга киткәндә (өеннән бер чыгып киткәч, Габделнур йә каникулга, йә отпускыга вакытлыча гына кайткалады) сигез яшьлек булган малай-кызлар бүген уналты яшьтә икән бит инде. Шулай булса да, аңа ифрат якын иде алар.

Әбисенең өе кайчандыр авылның бизәге үк булып тормаса да, һәрхәлдә, үз заманы өчен ярыйсы гына иде. Хәзер исә биек, юан кәүсәле тупыл агачлары арасында моңаебрак, үзенең искерә баруыннан читенсенгәндәй оялыбрак утыра сыман. Тупылларның да берсе үзенең яшәү дәверен очлаган — корыган. Ишегалды нәкъ элеккечә: ямь-яшел чирәм, арба эзе юк, абзар тирәсенә илтүче сукмак та чак кына шәйләнә. Шомырт агачлары кыйбла якны бизәп утыралар, алар янына карлыган куаклары елышкан, чәнечкеле крыжовниклар читтәрәк. Сул якта, түрдә, озын сиртмәле коеның баганасы бер якка кыйшайган. Сиртмәнең иң очына кунган саескан бер дә курыкмыйча озын гәүдәле, яшел киемле солдат абыйсына тасраеп карап торды да ишләренә яңа хәбәр җиткерү өчен очып та китте.

...Габделнур кергәндә, өй эченә туң май исе таралган иде. Казан янында күлмәк җиңнәрен сызганган, яулыгын чөеп бәйләгән, озын гәүдәсе бераз бөкрәя төшкән әбисе сөзгеч белән олы бадъянга кош теле салып маташа иде. Кайчандыр аркан очлары кебек салынып торган калын кара толымнары хәзер зур көмеш тәңкә тагылган тычкан койрыгы кебек кенә булып калган. Күрше карчыгы да аңа булыша — сәкедәге куна тактасына җәелгән камырны кисү белән мәшгуль.

Габделнур кычкырып сәлам бирде.

— Исәннәрмесез?! Керергә була микән?

Бусагада солдат күренүгә, әбисе борылып карады: гаҗәпләнде, күзләрен челт-челт йомгалады, җыерчыклы йөзе яктырып китте, кулындагы әйберләрен кая куярга белмичә бер мизгелгә аптырап калды. Күрше карчыгы да Габделнурның көр тавышына борылып караган иде инде. Аны танып алдылар. Шуннан китте: сөенечле каушау, аптырау, шатлык авазлары чыгарып гаҗәпләнү; онга, камырга, майга буялган кулларын ак тастымалга, алъяпкыч итәгенә сөрткәләү.

— Исәнме, әби.

— И Алла, танымый да торам. Исәнме, улым, исәнме.

Габделнур әбисе белән ике куллап күреште. Әбисе аның кулларын җибәрмичә озаграк тотты, ахры.

Күрше карчыгы:

— Мин дә күрешим инде, — дияргә мәҗбүр булды.

Кара-каршы исәнлек-саулык, юл, Казан, мондагы тормыш-көнкүреш хәлләрен сораштырдылар.

— И, бәхетле авыз булырсың икән, үскәнем, — диде күрше карчыгы.

— Белгән күек, кичәгенәк, бу арада пешергәнем юк, дип тотынганыем, — диде әбисе. — Күршедә бер хатын бәбәйләде, бәби ашы да кертәсем барые.

Габделнур, елмаеп:

— Солдатның борыны шулай сизгер була инде аның, — диде. — Синең кош теле пешерәсеңне белеп кайттым.

— Бик рәхмәт, улым.

— Әле бу исәнмени? — дип сорады Габделнур, тимер- чыбыклардан челтәрләп үзе үреп биргән сөзгечкә ишарәләп.

— Исән, улым, исән. Аңа рәхәтләндем генә.

Күрше карчыгы да сүзгә кушылды:

— Тәм-том пешергән саен сине искә алабыз, үскәнем.

Беразга гына эшеннән туктап, әбисе солдатны олы якка дәште, үзе сөйләнүендә булды:

— Әле бездә кунак барые.

— Кем?

Һәм әбисе күрше авылдан бертуган абыйсы килүен, әле генә бер кордашы янына кереп китүен әйтте.

— Озак тормас, кайтыр. Син утырып тор, улым. Чәй эчертмичә җибәрмим.

Куанычы эченә сыймаган карчык, чәч толымына таккан чулпыларын чыңлатып, бүлмә тактасы белән аерып куелган бәләкәй якка чыгып китте.

Габделнур үзе генә калды.

Бу өй музейны хәтерләтә: борынгы зур сандык, чүпләмле, чигүле кызыл сөлгеләр һәм матча кашагалары, бизәп-сырлап ясалган савыт-саба шкафы, шундый ук бизәкле олы көзге, суга торган, герләр эленгән чылбырлы стена сәгате, киң нарат такталардан җәелгән түшәм-сайгак, туку станы, акшарланган олы мич, иске тимер карават, әбисе үзе суккан паласлар... Бу өйдә әйбер күп, ә фотокарточкалар юк.

...Кешенең кулы гына нидер тотып эшләр өчен яратылган, ә башы — уйлар өчен. Күрше хатыны, Габделнурны күргәч, үз балаларын күргәндәй шатланды. Әйе, аналар һәрдаим газиз балаларын көтә. Тик алар гына сирәк кайта. Аның да балалары, бәхет эзләп, кайсы кая таралды: олы улы Латвия дигән җирдә балык тота, икенчесе дә армиядән соң читтә калды — Урта Азиядә ком чүлендә трактор белән канал казуда, игезәкләре нефть эзли, бер кызын азәрбайҗан егете алып китте... «Һай бу тормыш, — дип уфтанды ирен сугышта югалткан тугыз бала анасы, гомер буе нужа куган хатын. — Балаларның бергә җыелганын күрер көннәр булыр микән, Ходаем?!»

Күп тә үтмәде, пешекчеләр эшләрен тәмам иттеләр, олы җиз самавыр да өйне ямьләп үз урынын алды.

— Улым, утыр әйдә, — диде әбисе, олы якка хәстәрләнгән өстәл янына Габделнурны дәшеп.

Әбисенең үз кулы белән әзерләнгән сый-нигъмәт өстәлгә куелган: төш, чәкчәк кисәге, кош теле... Бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки әбисе авылда беренче аш-су остасы. Атна саен диярлек кем дә булса аны пешерү-төшерү өчен чакырмыйча калмый. Туй буламы, кунак киләме, Коръән укытырга ашка җыялармы, яшь киленнәр бәби алып кайтамы — барысына да Габделнурның әбисе кирәк. Беркемнең дә күрше-күлән, кардәш-ыру алдында йөз кызартасы, сер бирәсе килми, шуңа күрә хәзинәдә булганның һәммәсен чыгаралар, кысынкырак чакта әҗәткә кереп булса да кешечә аш әзерлиләр.

Хәер, әбисе үзе өчен дә пешеренә. Халкыбызның бу борынгы тәмле һәм туклыклы, айлар буена бозылмыйча саклана торган ризыклары аның өендә өзелми иде.

Чәй янында әбисе:

— Улым, йөргән җирләреңдә Әлтәф абыең күренмәдеме? — дип сорады.

Әлтәф — Габделнурның әнисенең бертуган энесе, сугышта хәбәрсез югалган. Әле авылда чакта, сугыш турында кино карап кайтсалар, әбисе гел бер сорау бирә иде: «Солдатлар арасында Әлтәф абыең күренмәдеме?» Әбисе улын гел исән дип өметләнде. Ул аңа кәләш тә сайлап-әзерләп куйган. Бер олы кызны (аңа насыйп ярларның күбесе яу кырыннан кайтмагач, утырып калган авыл кызын), Әлтәфем кайтса, шуңа өйләндерер идем, дип әйтә торган иде.

— Юк шул, әби, күренмәде, — диде Габделнур, мөмкин хәтле йомшак итеп, әбисенең хәтерен калдырмаска тырышып.

Әбисенең ире дә, ягъни Габделнурның икенче бабасы да хәбәрсез югала, ләкин анысы егерменче еллардагы гражданнар сугышы чорында. Авылга аклар килгәч, аны, үз атын җиктереп, олау белән Бөгелмәгә алып китәләр, һәм шул китүдән әйләнеп кайтмый. Юкса аклар урамда күренүгә ул качкан була. Балаларга әйтмәскә кушыла.

Ак офицер, кереп:

— Хуҗа кайда? — дип сорый.

Хатыны:

— Ул өйдә түгел шул, күрше авылга китте, — ди.

Ә офицер, хәйләкәр нәрсә, бәләкәй Әлтәфкә күз кысып елмая да:

— Әтиеңнең кайда икәнен син беләсеңме? — ди.

Сабый олылар кисәтүен үзенчә «үти».

— Безнең әткәй сәке астында юк!

Һәм хуҗаны өстерәп чыгаралар да алып китәләр. Карт атасының — Георгий тәресе кавалеры булган элекке патша солдатының ялыну-ялваруы да ярдәм итми...

Чәй янында әбисе үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Өем искерде, улым. Кияүгә әйтеп караганыем да, ярар, диде дә онытты бугай.

Габделнур бераз тын торды, атасыннан узып сүз әйтергә, вәгъдә бирергә кыймады.

Ахырда ул, җайлап кына:

— Ярар, әби, уйлашырбыз, — диде.

Әбисенең шундый зур эш турында аның белән сүз кузгатуы Габделнурның күңеленә хуш килде.

...Габделнур чыгарга җыенгач, әбисе, тартыныбрак:

— Улым, күземне карамыйсыңмы? — диде.

— Онытмасам.

Шулай да Габделнур бик теләп риза булды. Әбисенең берничә керфеге күз кабагының эчке ягына карап үсә, күзен кырып аны даими борчып тора. Габделнур, күз кабагын әйләндереп, аларны бәләкәй эскәк белән йолкыды. Кечкенәдән өйрәнгән шөгылен, чыннан да, онытмаган икән.

— Ай рәхмәт төшкере, — диде күрше карчыгы.

— Рәхмәт, улым, аяк-кулың сызлаусыз булсын, — диде әбисе. — Әле кая барасың? Кайтасыңмы?

— Юк, келәт арасына. Әти белән күрешмәгән бит әле.

— Улым, электр куыгын да алыштырып куй инде. Бусы нишләптер караңгы яна.

Габделнур олы яктагы лампочканы борып алды да яңасын беркетте.

Габделнур инде чыгарга җыенган иде, бусагада алагаем зур гәүдәле, озынча ябык битле, чал сакал-мыеклы бер бабай күренде. Егет аны шунда ук таныды, бу әбисенең бертуган абыйсы иде. Чөнки Габделнурның аны монда да күргәне бар, үз авылларына да барып чыккалады.

Карт бөкрәя төшеп, башын аска иебрәк эчкә узды.

Алар бик җылы күрештеләр. Яше сиксәннәр тирәсендәге эре сөякле бу агайның куллары озын, зур, бармаклары әле дә каты, күрешүе ирләрчә нык.

— Солдат кайткан икән. Чын гәрнәдир булгансың бит, — диде ул, елмаеп.

Габделнурга кабат табынга утырырга туры килде. Чәй эчкәндә дә, аннан соң да карт егеттән армия хәлләрен сораштырды, үзе дә сөйләде. Аның сөйләр сүзе күп иде, чөнки шактый гомер яшәгән, күпне күргән. Ул Герман сугышында, унбишенче елны, әсир төшкән чакларын, алман җирендә бер алпавытта батрак хезмәтен башкарганын, немецларның ниндирәк халык, тормыш-көнкүрешләре, яшәү рәвешләре ничек икәнен бәйнә-бәйнә сөйләде. Ул аларның гореф-гадәтләренә хәтле белә иде. Әсирлектән качып, гражданнар сугышында кызыллар ягында ел ярым совет власте урнаштырып йөрүен, фәкать каты яралангач кына өенә кайта алуын, сәнәкчеләр сугышы да аны читләтеп үтмәвен әйтте. Эчкә баткан күзләрен челт-челт йомгалап утыручы, яңгырсыз елны кипкән җир кебек җыерчыклы йөзле бу картның хәтеренә Габделнур таң калды. Әйе, үзенең маҗараларын, һәр вакыйганы көне-сәгате белән истә тота, кемнәр белән аралашуын исем-фамилияләренә тикле күңел түрендә саклый. Ул кырылган башына кара түбәтәй кигән, шакмаклы күлмәктән, озын муенында кара йоннан бәйләнгән юка шарф, өстендә буйлы пиджак һәм чалбар. Йон оекбаш кигән аякларын әледән-әле селкеп куя, еш кына озын йомры борынын тарта, кан тамырлары зәңгәрләнеп беленеп торган куллары белән диванны сыпыргалый. Үзе зур гәүдәле булса да, аның тавышы әкрен, күгәрчен тавышы кебек гөрләп ишетелә. Тыңлаучы булса, ул шулай сәгатьләр буе сөйләшеп утырыр иде бугай...

...Габделнур әбисенең бәрәңге бакчасы буйлап тар тыкрыктан югары менеп китте. Бәрәңге бакчалары — авыл халкын иң авыр елларда да ачлыктан коткарып калган мәрхәмәтле буразналар — быел да муллык вәгъдә итә иде. Бигрәк тә урмансыз, бүтән яктан керем керер җире булмаган авылда бәрәңге — бар карап торган бәрәкәтле ризык. Тик эше-мәшәкате күп.

Габделнурларга бәрәңге алу икеләтә авырга туры килә иде, чөнки ике бакча бит: үзләренеке, бу әбисенеке. Әүвәл бәрәңге сабагын йолкыйлар, аннан буразнаны рәттән казыйлар, бераз җилләгәч капчыкларга тутыралар

һәм, җилкәгә салып, кайсын кая ташыйлар: орлыкка дигәнен — бәрәңге базына, сатлык эресен — чиннеккә, малларга насыйп буласы вагын — сарайга, кыш ашарга җитәрлек итеп уртачасын — өй базына... Һәр елны ике бакча.

Берчакны абыйсы, Габделнур һәм энесе агач көрәк белән әбисе бакчасын казыйлар, авылча әйтсәк, бәрәңге алалар иде. Әниләре дә монда, гадәтенчә, булышырга чыккан.

Ул:

— Балалар, бу тирәсе әйбәтме? — дип сорады.

Абыйсы, турыдан ярып:

— Әни, ат башы хәтле булып күренәләр инде, — диде.

Икенче вакыт, тагын алар өчәү казыганда, сугыштан гарипләнеп кайткан, бәрәңгесен тезләнеп кенә җыя ала торган күрше абзый чыгып, эшләренә сокланып карап-карап торды да:

— Котыра буран! — диде.

Чем-кара җир, үзе йомшак, коп-коры, өч ир туган агач көрәкләр белән ут уйната иде ул көнне бәрәңге бакчасында...

Элегрәк елларны халык кызгылт төстәге галан бәрәңге утырта иде. Ул озынча, уңышы әйбәт — аны beләккә салып та ташырга була. Аннары сары бәрәңге китте — түгәрәк, кушуч йодрык хәтлеләре була — котырып уңа. Ничәнче елныдыр, хәтерендә түгел, Габделнур бер төптән унсигез бәрәңге санап алды.

Шул күрше абзый:

— Сары бәрәңге — честный бәрәңге, — ди торган иде.

**27**

Авылның өченче урамына кертмичә, юл солдатны ындыр табагына алып китте. Шифер түбәле, озын-озын келәт-
амбарлар, өсте ябулы зур рига, машиналар керерлек үлчәү бинасы — барысы да элеккечә икән.

Ул тирә гөр килә: комбайннардан ипи ташучы машиналар тыз да быз чаба, мул булып өелгән көшелләр таудай кабарып тора, агач көрәк токкан хатын-кыз ашлык җилгәрә, ир-ат машиналарга капчык төйи, бер җилгәргеч әллә кайларга кибәк очырта, тузан тарата... Кыскасы, гөрләп тора ындыр табагы.

Тагын танышлар, дуслар, абый-апалар, хәтта өлкән яшьтәге әби-бабайлар белән мәктәп балалары да бар иде монда. Габделнур алар белән күрешеп чыкты.

Бер читкәрәк китеп ике-өч ир-ат белән сөйләшеп торганда, басу ягыннан кайтып килүче таныш машина күренде. Габделнур аны йөзләгән машина арасыннан да таныр иде, мөгаен. Яшелгә буялган кабиналы, әрҗәсенә такта түшәп күтәртелгән, кабина артына, кул белән тотыныр өчен, торба бөгеп беркетелгән, номерлары да онытылмаган...

Егет алга таба атлады. Әтисе солдат улы янына җитәр-җитмәс туктады, кабинадан төште. Башында салам эшләпә, өстендә искерәк кара костюм-чалбар, аягында кирза итек. Чиста итеп кырынган, кызгылт йөзе шат, елмая.

— Исәнме, әти!

Әтисенең куллары көчле.

— Исәнме, улым! Кайттыкмы?

— Әйе.

Илленең өстендә булса да, әтисе әле нык, кем әйтмешли, сыендагы ир-ат, таза гәүдәле. Буйга бераз чүккән сыман. Анысы инде Габделнурның төз сыны янында шулайрак күренәдер.

Улы белән бер-ике авыз сүз алышкач, Галләм абзый машинасын көшелгә яны белән куйды. Укучы балалар, бортны ачып, кузовка менделәр һәм гәрәбәдәй бодайны бушатырга тотындылар.

Галләм абзый белән Габделнур янына ир-ат җыелды. Алар сөйләшә, ә ата улына карап тора. Кай арада үсеп тә җиттеләр. Олы улы күптән кайтты. Менә икенче малае да соңгы елын хезмәт итә. Өченчесе әле бер елын гына тутыра. Бер гаиләдән өч солдат! Ата өчен моннан да зур горурлык бар микән?!

Галләм абзый, нидер исенә төшеп, елмаеп куйды. Зурысы армиядән кайткан көнне ул ишегалдында нәрсәдер эшләп маташа иде. Капкадан башына фуражка, өстенә бушлат кигән юка гәүдәле солдат — улы килеп керде. Кулында чемодан, авызында папирос, үзе елмая. Ул әтисе янына килеп күрешергә кул сузуга, Галләм абзый үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде:

— Ташла тәмәкеңне! Нәселдә булмаганны!

Бәлки, өч ел күрешмәгән улына алай каты бәрелергә дә кирәк булмагандыр. Чөнки улы армиягә хәтле тарту-эчүне белми иде бит, һәрхәлдә, күрсәткәне булмады. Очрашу бик коры килеп чыкты. Соңыннан гына ата кеше болайрак фикер йөртте: «Район үзәгендә урта мәктәп бетерде, кайтышлый классташларын-дусларын очраткандыр, бераз кабып та алгандыр... — Шулай да Галләм абзый олы улының авызында кабат тәмәке күрмәде... — Монысы да тартмый, ахры, ис-мазар сизелми».

Габделнурның буй-сынына, киеменә — яхшы китель, үтүкләнгән галифе чалбар, кыска гына козыреклы фуражка, сары аеллы коңгырт каеш һәм бераз җыерылып торган кунычлы чиста кирза итекләренә карагач, ирексездән сугышта булган чаклары хәтерендә яңарды. Сталинград тирәсендәге сугыш афәтләре, яралану, ун-

сигез көн лазарет атлы сарайда гөбедәй шешкән аягын кузгата да алмыйча бет ашатып яту, Саратов, Ульяновск, Казан госпитальләрендә җиде ай ятып, ике култык таягы белән өенә кайтып егылуы исенә төште. Өстендә почтальоннар кия торган, инде төсе уңган зәңгәр пиджак, иске генә галифе чалбар (берсенең балагы тезгә тикле ерык), бер аякта олы ботинка, ә икенчесе мамык, бинт белән уралган... Улының киеме пөхтә, түшендә значоклар, погоннарында бер сары тасма... Аның да орден-медальләре байтак иде. Ләкин ул аларның кадерен җибәреп почтальон кителенә тагарга кыймады, биштәр капчыгына салып алып кайтты.

Ындыр табагында Галләм абзыйның кордашларыннан да бер-ике кеше бар иде. Алар әле аңа, әле солдатка мөрәҗәгать итеп гәп кордылар. Бу очрашудан һәм сөйләшүләрдән күңеле тулган карт шофер, дымлы күзләрен кешегә күрсәтмәс өчен, машинасының капотын ачып, нәрсәгәдер кул тидергән булды, караштырды. Аннары, балалар йөкне бушатып бетергәч, улына дәште:

— Басу әйләнәсеңме?

— Үзем дә әйтмәкче идем. Әйдә.

— Рульгә утырасыңмы?

— Юк.

Галләм абзый улының рульдән баш тартуына үпкәләмәде. Монысы нигәдер техникага әвәс булмады шул. Бервакыт ишегалдында дүртәүләп машина ремонтлыйлар иде. Берәр сәгать җәфалангач, Габделнур, эшен ташлап, беркемгә берни әйтмичә өйгә кереп китте. Бераздан, ун телле тальянын күтәреп чыкты да, баскычка утырып, шыңгырдатып уйнап та җибәрде. Галләм абзый аптырап калды. Алар монда муеннан дигәндәй майга, пычракка батып машина рәтли, тирбәтмә алыштыра, ә ул, берни булмагандай, гармун тарта.

Ата кешенең кулында саллы гына ачкыч иде. Ул:

— Әллә шушының белән җибәрим микән? — дип, олы улына карады.

— Тимә, эти, уйнасын. Аның уенда башка нәрсә.

...Асфальт булмаса да, юл тигез, машина җай гына чаба. Ата улы белән сөйләшә. Ә башында тагын истәлекләр... Берчакны, күрше авылдан шушы юл белән кайтканда, Галләм абзый рульне унбер яшьлек Габделнурга бирде. Ярты чакрым үттеләр микән, кече малае рульгә ябышты.

— Мин утырам, мин, — дип тәкрарлый башлады тугыз яшьлек төпчеге.

Габделнур түзмәде, каты итеп тормоз педаленә басты.

— Нишлисең? — диде ата кеше.

— Әнә утырсын, — диде кашларын җыерып Габделнур һәм, кабинадан чыгып, икенче ишектән кереп тә утырды.

Әйе, шулай итеп уртанчы улына урын күчәргә туры килде.

«Анысы минем юлдан китте», — дип уйлады Галләм абзый, балаларының кечкенә чакларын хәтерендә яңартып. «Армиягә киткәнче үк шофер булып эшләде, анда да машинада икән. Ә монысы... Ярар, бөтен кешегә дә шофер булырга димәгән. Әнә Казанда икзам биреп кайткан бит. Бу юлы үтмәсәм, хезмәтне бетереп кайткач керәм, ди. Керер. Төпле күренә. Үз юлын беләдер».

...Бункердан шаулап аккан бодайга карап торуы ук рәхәт иде. Күпме байлык! Тир түгеп табылган хезмәт җимеше! Аңа Габделнур гына түгел, көн-төн тирләп-пешеп, тузанга батып басуда эшләгән комбайнерлар да, гомерен шушы авылга багышлаган Галләм абзый да, кайчандыр үзе дә штурвал артында утырып кыр корабында басулар гизгән каты куллы колхоз рәисе дә карап туя алмый — барчасының да күңелләрен сөенеч биләп ала.

Һәр карашыннан шөлләп, кем әйтмешли, шәүләсеннән үк куркып торалар персидәтелнең. Чөнки ул үзе дә көне-төне чаба, кешеләрне дә эшләтә, эшләгән кешенең кадерен дә белә — тиярен мулдан бирә.

Вакыты тар булса да, рәис Габделнур белән дә, аны тиң күреп, гәп корырга җай тапты. Үзенең япон самурайлары белән чәкәләшкән чакларын искә төшерде.

Ахырда ул сүзен:

— Авылга кайтмыйсыңмы? Бер толковый электрик кирәк иде, — дип төгәлләде.

— Юктыр, — диде Габделнур, икеле-микеле уйларга урын калдырмыйча.

— Ярар. Шулай да минем тәкъдим үз көчендә кала.

Машинага кереп утыргач, Габделнур тузан туздырып китеп баручы комбайнга күз салды һәм кылт итеп бер вакыйга исенә төште. Ул, җидене бетергәч, ун көн ат белән комбайннан ипи ташыды. Комбайн иске — «Сталинец-6», үзйөрешле түгел, аны трактор сөйри, ашлыгы да хәзергеләрнеке кебек туп-туры машина кузовына акмый.

Соңгы көнне алар урамында яшәүче бер егет белән, берәр йөк солы төяп, туп-туры өйләренә кайтып киттеләр.

Габделнур ык-мык килә башлагач:

— Шым бул, йөргән аякка йөрем иярә ул, — диде егет. — Беркем дә сизмәс.

Капканы үзе ачып, ишегалдына килеп керде Габделнур. Өйдән чыккан әнисе ах-вах килә башлады.

— Бар, улым, бар, келәт арасына илт! Бер кило арыш өчен дә кешеләрне утырттылар бит. Өтермәгә ябып куярлар.

— Әни, Сәмирхан абый да өенә кайтты. Ул бушаткандыр да инде. Мин бит хәзер аны чагам булып чыга. Без бит икәү бергә ташыдык...

Ничек кирәк алай тынычландырды Габделнур әнисен. Чөнки иренең машина әрҗәсе төбенә сыланып-ябышып кайткан ярты чиләк ашлыкны да җыеп алырга курка иде Гөлзифа түти.

«Менә яшьлек-җүләрлек, — дип үзалдына көлде Габделнур. — Җүләрлек кенә түгел, башсызлык».

Комбайннар яныннан урап кайтышлый Габделнур авыл башында төшеп калды. Әтисе әле кичке якта гына эшен бетерер, тугыз-уннарсыз өйгә кайтмаячак иде.

**28**

Габделнур урамга көтү каршыларга чыкты. Капка төпләренә баскан яки эскәмиягә утырган күршеләре янына барып исәнләшеп килде.

Тау башында тузан болыты күтәрелде: урам тутырып маллар кайта башлады.

Гөлзифа түти дә бәләкәй капкада күренде.

— Улым, син малларны танымыйсыңдыр инде.

— Үземнең сарыкны гына таныйм.

Аңа атап калдырылган, ел саен өч бәрән китерә торган бер олы сарык егетнең хәтерендә калган. Хәер, аларның бөтен сарыклары да ак төстә иде. Габделнур әнисенең кара йоннан оекбаш бәйләгәнен белми.

— Ул юк шул инде, — диде әнисе, авыр сулап.

Озакламый сыер, бәрәннәрен ияртеп сарыклар, үзләренә генә билгеле тоемлау белән капка-коймаларны, өй каршындагы агачларны һәм тәмле су, ипи сыныклары белән сыйлаучы юка гәүдәле әбиләрен танып, тезелешеп бәләкәй капкадан керделәр. Шулай да, кергәнче, бер сарык агач яфракларына үрелде, буе җитмәгәч, икенчесенең сыртына басып, муенын сузып, берничә яфрак эләктереп авызына капты. Хәер, башкалары да бер генә секундка икеләнеп калдылар: кичә дә, өченче көн дә капка турысында бу солдат абый юк иде. Каян килеп чыккан ул? Нинди ният белән тора? Әллә ихатаны ялгыштылармы? Юктыр, сарык булсалар да, алар да кешеләр уйлаганча ук аңгыра түгелләр. Киң күңелле булсалар, барысы да сыярлар. Тәвәккәлләргә кирәк. Керә-керешкә барысы да озын тастагы ашлы суга ябырылдылар.

Аларның бер-беренә комачаулый-комачаулый, этешә-төртешә йотлыгып, комагайланып су эчүләрен карап торуы Габделнурга кызык та, рәхәт тә иде.

Әнисе, чиләк һәм имиләрен сөртү өчен чиста тастымал тотып, сыер янына килде.

— Түгәнәй, түгәнәй, әшәкеләнмә, — дип, тыңлаусыз малкайны орышмый гына, әмма йомшак тавышы белән оялтып кызартырга теләгәндәй, тәртипкә чакырды.

Бераздан «сөт фабрикасы» тынычланды, тулышып ике бот арасына көчкә сыешып кайткан җилененнән чаж-чож ап-ак сөт ага башлады. Габделнурның, сагыну хисеннән күзләрен мөлдерәмә итүгә сәбәпче булган, болай да алгысыган күңелен кытыклап торучы, туган авылы тормышының садә бер мизгеле иде бу.

Савып бетергәч, сөтне сөзеп, ярты литрлы банкага салып, әнисе Габделнурга суզды.

— Мә, улым, җылы сөт эч.

Күптән мондый кадер-хөрмәт күрмәгән, аның барын да оныткан солдат башта теләр-теләмәс кенә эчә башлады. Авызы күнекмәгән, тәме онытылган. Шулай да отыры җылы, йомшак, болын печәне вә чәчәкләренең хуш исен үзенә сеңдергән сөт аның күкрәген йомшартып эреп киткәндәй булды...

...Кичке җиделәрдә машинасы белән әтисе дә кайтты. Кайчандыр аңарда ярдәмче булып эшләгән, хәзер Әлмәт шәһәрендә яшәүче Данис исемле егет белән икәү ишегалдына килеп керделәр.

Данис Габделнур белән кочаклашып күреште, хәл-әхвәл сорашты.

Үзе турында исә, гадәттәгечә, уенга борып:

— Исән җирләр таза-сау, — дип кенә җибәрде.

Өчесе дә солдат каешы буып йөргән кешеләр бит — уртак тел тиз табылды.

Аннары Данис:

— Галләм абый, бер дә борчылма, тәртип булыр, — дип, гадәтенчә бөтен йөзе белән якты елмаеп, машинага утырып китеп барды.

Әтисе Габделнурга:

— Кичке якта ул да ындыр табагына килде, — диде. — Сүз иярә сүз чыкты. Синең кайтканны белгәч, бар, бар, шундый көнне соң... Комбайннар туктаганчы үзем йөреп торырмын, ди.

Данис берничә ел Галләм абзыйда «памушник» (элек, авылда машина бер-ике генә чагында, шоферларга ярдәмче каралган иде) булып йөрде. Алар бер урамда үстеләр. Ул өч яшькә олы булса да, ничектер Габделнурны якын итте. Велосипедына утыртып, урам буйлап гармун уйнатып йөрткәне истә калган. Аннары бервакыт аларның ишегалдында борчак боткасы ашаганнар иде. Унлап малай яшел чирәмгә түгәрәкләнеп утырдылар да Данисның әнисе агач табак белән чыгарып куйган ботканы чит-читләре кителгән агач кашыклар белән туйганчы ашадылар. И ул борчак боткасының тәмлелеге!..

Галләм абзый да Данисны бик яратты. Машина ремонтлаганда көннәр буе алардан китми иде бит егет.

Данис китеп баргач, Галләм абзый көлеп куйды:

— Чаллыга ипи ташыганда гел йөк өстендә йоклап бара торганые. Кабинага утырмый да. Таш төясәң дә, рәхәтләнеп шуның өстендә йокларые, бер дә талымламады, йокы ястык сорамый, дип кенә җиппәрәдерие.

Гөлзифа түти баскычка җылы сулы комган, сабын куйды.

— Мә, улым, бит яулыгы, — дип, борынгы озын сөлгене Габделнурның кулына тоттырды. — Озак юанмагыз, керегез.

— Ярар.

Әтисе юынганда, бәләкәй чактагы шикелле, улы су салып торды. Әтисенең кояшта янып каралган таза муенына, дәү кулларына карап, аның әле җегәре нык икәнен чамалады.

Малай чакларын искә төшереп, Габделнур:

— Аркаңа салыйммы? — дип сорады.

Әтисе, аңа карамыйча гына:

— Түбән җибәрмә, — диде. — Матри, беләм мин сине.

— Юк ла инде, — дигән булды солдат.

Габделнур, муен тирәсенә генә агызып, әтисенең киң аркасыннан тузаннарын юып төшерде. Эштән арып кайткан Галләм абзый пошкырына-пошкырына юынды, озын сөлгенең чигүле кызыл очларын битенә каплап, рәхәтләнеп сөртенде, муенына, колак артларына да тидереп алды; майкасын һәм күлмәген киде. Аннары алар өйгә керделәр.

Әнисе өстәл хәстәрләгәндә, Габделнур кече якта әбисе белән сөйләшеп утырды. Олы яктан әтисенең бармак белән генә үзенә таба ымлаганын күреп алды.

— Әби, түргәрәк кереп утыр, — дип, урыныннан кузгалып, җай гына аңардан аерылды Габделнур.

Әтисе ишек катындагы шкаф янында тора, ике кулында ике тустаган.

— Әйдә, тегеләргә сиздермә, — диде Галләм абзый һәм, артык сүз әйтмичә, чәкештермичә каплап та куйды.

— Тутырып салгансың...

— Буеңа сеңдер, — диде әтисе, коры гына, һәм кул аркасын гына иснәде дә, борынгы бәләкәй чынаякларны шкафка куеп, кече якка чыгып та китте.

Әтисенең талканы коры икәнен Габделнур белә. Беренче мәртәбә исергәч (техникумның икенче курсын бетергән җәй иде, берәүләргә йорт нигезенә көнозын таш ташышты), аны атлы арбага салып китергәннәр. Икенче көнне үтереп башы авырта, косасы килә. Әнисе иртәнчәк чәйгә чакыргач, Габделнур баш кына селекте. Шуннан верандага әтисе чыкты. Аның кулында ярты стакан аракы иде.

— Мә, эч.

— Үтми.

— Эч! — дип кабатлады Галләм абзый, ачу белән. — Иначы тиз генә терелә алмыйсың. Әниең аш җылыткан, шулпа эчәрсең. Матри, икенчеләй бу хәлгә төшкәнеңне күрмим!

Нишләсен, үсмер егеткә зиңкеп башы авыртса да калкынырга, күңеле болганса да мәҗбүри эчәргә һәм урыныннан күтәрелергә туры килде.

...Аштан соң аталы-уллы бакча буендагы эскәмиягә чыгып утырдылар. Көн сүрелгән, кояш баеп бара. Зәңгәр күктә болыт-фәлән күренми. Җил дә юк. Тышта җанны иркәләүче, авыр эштән соң утырып хәл ала торган кичке җылы тынлык хөкем сөрә иде.

Галләм абзый Казан хәлләрен, андагы туган-тумачаларын сорашты, туганнан туган энесе дә шунда яши иде. Улының ничә көнгә, нәрсәләр белән кайтуы хакында кызыксынды. Аның Ярославльдән Иваново, Горький шәһәрләре аша кайтканын белгәч әйтеп куйды:

— Мин йөргән якларда да булгансың икән. — Аннары дәвам итте: — Безне моннан сугышка машина белән бергә алдылар. Районнан икәү. Икебез дә утыз тугызынчы елны Мамадышта шоферлар курсын бетергәниек. Үз хутыбыз белән бардык. Казанда, теге атлар чабыштыра торган җирдә...

— Ипподром...

— Ие, шунда машиналарны җыеп тездерттеләр дә үзебезне кәнүшниләргә урнаштырдылар. Атларны сугышка алганнарые инде. Ике катлы нарларда берничә көн яттык: комиссия үттек, строевой атладык. Аннан соң, командага туплап, җәяү тимер юл вокзалына алып киттеләр, вагоннарга төяделәр. Ивановода десантка эләктем. Башта урындыктан, өстәлдән, соңрак өй түбәсеннән сикерергә өйрәттеләр. Соңра сәмәлүттән... Бер солдат, мескен, бик куркак булып чыкты, сикерми генә бит. Анда күп сөйләшеп тормыйлар — старшина типте дә төшерде.

— Парашюты ачылдымы соң?

— Ачылды, ул бит автоматически...

Әкренләп сүз ил-көн, авыл хәлләренә күчте. Өч ел эчендә үлем-җитем шактый булган икән, күбрәк карт-коры. Габделнурның бабасының энесе, тирә-юньгә данлыклы балта остасы һәм... чәч алучы мәрхүм икән. Чәчләре җитсә, әтиләре Габделнур белән энесен аңа җибәрә иде. Ап-ак сакал-мыеклы бабай үткен чалгы пәкесе белән, ай-вайларына карамыйча, акыртып дигәндәй, аямыйча аларның чәчләрен китәрә — кырып төшерә. Ахырдан, ябалактан — җон, бүдәнәдән — май, дип, шәрә башка ялтыратып та җибәрә. Ә аның куллары алагаем зур — ипи көрәге хәтле иде. Андый да юан бармаклы кулларны Габделнурның беркайчан да, бер кешедә дә

күргәне булмады шикелле. Елап та булмый, еласаң, икенчеләй килмә, дип кенә җибәрә иде бабакай. Хәер, ул абыйсының оныкларына авырттырырлык итеп тә сукмады бугай. Курыкканга куш, дигән шикелле, малайларның гына коты очып торгандыр. Ул бабайның тагын бер гадәте истә калган. Кич белән, бала-чага урамда койма буенда таш (элек кайбер кешеләрнең капка төбендә зур-зур ташлар ята иде) яки бүрәнә өстендә утырганда, ул тәравихка барышлый, кәкре таягын култык астына кыстырып, юри койма сыдырттырып килә. Үзе:

— Бала тәкәләр, төчт-төчт, — дип сөйләнә иде.

Нәрсәне аңлаткандыр аның бу кыланышы — аңламассың өлкәннәрне. Үзенчә бала-чага белән шаяртуы булгандыр инде, бик миһербанлы намаз карты иде бит ул: аракы эчми, тәмәке тартмый. Хәер, бабаңның җиде ир туганыннан берсе дә тәмәке тартмый иде, дип сөйләгәне бар әтисенең Габделнурга. Ә аның эш кораллары... Нәрсә кирәк булса да — бораумы, струкмы, ышкымы — аңа баралар иде.

Күршедәге тимерче абзыйның да кораллары бихисап, ләкин аныкы күбрәк калай, тимер-томыр белән эш итүчеләргә яраклы... Ул да якты дөньяны калдырып киткән.

— Шахтага бергә барганыек, — диде Галләм абзый. — Бик йөрәкле кеше иде. Иң куркыныч штрекка ул беренче керәдерие... Утызынчы елны без шахтадан кайткан көнне колхоз персидәтелен үтергәннәр. Ул күрше авылныкы икән, гәүдәсен Иске Авыл күпере янында тапканнар. Милиция килде. Безнең җидебезне дә Урта урамдагы бер таш келәткә ябып куйдылар. Без, яшьләр, бик шүрләдек. Ә ул, курыкмагыз, егетләр, шахтерларның андый пычрак эшкә бармасын халык белә, дип, безне юатты. Аннары соң чыгардылар инде, гаепсез икәнне белгәч.

— Кем үтергән соң?

— Тәки таба алмадылар.

Яшь чагында Минзәләдән, тәтәйләр йортыннан, хатынлыкка кыз алып кайткан бер бабай да үлгән. Аның тарихын Габделнур армиягә китәр алдыннан очраклы рәвештә генә ишеткән иде. Яшьлегендә бик йөремсәк бу карт әле олыгайгач та әйләнә-тирәдәге генә түгел, ә шактый ерак базарларны да иңләп кайтырга иренмәгән.

Биштәрен аркасына асып, урамга да чыгып тормыйча, ындыр артлап бәрәңге бакчасыннан гына китеп бара торган була.

Очраган кешеләр:

— Абзый, кая юл тоттың? — дип сорыйлар аңардан.

— Бакалыга, базарга, — дип җавап бирә агай һәм басу юлы белән генә китә икән.

Бакалы — хәзерге Башкортстанга керә торган, күбрәк керәшен татарлары яшәгән төбәк. Габделнурлар авылыннан илле-алтмыш чакрым бардыр.

Сихри моң иясе скрипкачы бабай да дөнья куйган икән. Ул шушы урамда, түбән очның тау башында яши иде. Аның инде күзләре сукырайган, гәүдәсе шактый таушалган, шулай булса да үзе ясаган скрипкасын ябык кулларында нык тота, борынгы көйләрне ару сайрата һәм урамда гөр килеп уйнаган малайлар, капка төбенә җыелып, тын калып аны тыңлыйлар иде. Кайчагында, карлыккан, хәлсез, әмма ләкин моңын җуймаган зәгыйфь тавышы белән скрипкасына кушылып, бала-чаганың күңеле булсынга җырлап та җибәрә иде ул. Бер җыруы да истә калган:

Эскерипкә ни дип әйтә?
Мияу, мияу, дип әйтә.
Кызлар егермегә җиткәч,
Кияү, кияү, дип әйтә.

Урыны җәннәттә булсын халык музыкантының...

Бер итек басучы бар иде. Ул салырга яратучан карт, әмма үзе таза иде әле. Бервакыт, кыш көне, бу кибеткә килә. Ул чорда аракы мичкәләрдә була торган иде. Магазин эче суык, аракы аннан да салкынрак.

— Кая, сеңлем, тутырып сал әле,— ди бу сатучы хатынга.

Мөлдерәмә тулы бер стаканны аудара да:

— Ярар, әйбәт булды әле, мунчадан гына чыкканыем, рәхмәт, — ди.

Учларында стакан җылытып торучы ир-атлар авызларын йомып исләренә килгәнче, китеп тә бара. Тегенең артыннан чыгып, карап торалар, янәсе, бабай кайчан кар өстенә авып төшәр. Юк, селкенми дә, терк-терк атлавын белә.

Тагын бер бабай — мич чыгаручы абзый да юк икән инде...

Бакча буендагы эскәмиядә утырган Галләм абзый:

— Менә шулай, улым, әкренләп картларны кайтмый торган җиргә илтәбез, дөнья бәһасе торырлык кешеләр иде, — диде авыр сулап. — Вакытың булса, бабаң каберен карап кайт.

— Ярар.

— Кайда икәнен беләсеңме?

— Хәтердә.

Габделнур бераз тын утыргач сорап куйды:

— Бик арытмыймы соң машинада?

— Әле түзәрлек. Әбиең әйтмешли, тәбәлдереккә генә басып утырам бит. Ранин аяк сызлаштыра, осколкы кузгалырга маташамы... Беркөн, тоягы алынган ат кебек, аяк тая да китә, тая да китә, машинага менеп кенә булмый... Ходайның рәхмәте, җибәрде тагы... Булыр инде, улым, алтмышны куам бит... Клубка чыгасыңмы?

— Әйе.

Галләм абзый кузгалды һәм, елмаеп:

— Ишекне биклимме? — дип сорады.

— Биклә, — диде солдат һәм үзе дә көлеп куйды.

Чөнки ул өйалды ишегенең келәсен пәке белән генә ача иде. Атасы онытмаган икән.

Өйдә әнисе:

— Улым, иртәгә ни пешерим? — дип сорады. — Нәрсә ашыйсың килә?

— Ни дә ярый, алай тансыклаган әйбер юк, — диде дә көлемсерәп өстәде: — Тәмлегә — талымым, тәмсезгә комагайлыгым юк.

Әтисе, төрттереп:

— Солдат кеше әйбер тәпсерләп тормый, ни бирсәләр, шуны ашый инде ул, — диде.

Әнисе бирешмәде. Бәләкәй генә булса да, кирәк чакта ул үз сүзендә каты тора белә иде.

— Бәрәңге тәкәсе пешеримме?

— Онытмагансың икән минем нинди ризык яратканны...

— И улым, — диде ана, — балаларның бернәрсәсе дә онытылмый ул...

Хәер, әнисенең хәтере аеруча яхшы икәнне белә Габделнур. Ядәч аерырга бик әвәс иде әнисе. Атна гына түгел, айлар буе исендә тота. Берчакны Габделнур аны, йокларга ятмыйча, тегү машинасында күлмәк теккәндә, кич буе сагалап утырды. Инде күзләре йомыла башлаган әнисе кәтүк ээләгәндә, ялт кына кулына тоттырды.

— Ядәч! — дип кычкырды да шундук сәкегә, энесе янына менеп ятты.

**29**

Урам тулы яшьтәшләренең-чордашларының күбесе авылда юк иде инде. Берәүләр һөнәр училищесыннан соң шахтада, икенчеләр шәһәр җирендә төпләнеп калган, кайсылары Ерак Көнчыгышта балык тотуда, кемдер солдатка алынган. Шулай да ике-өч егет калган иде. Алар кунакны кереп алдылар.

— Әйдә, кызлар күзләп кайтыйк әле, — дигән булды Касыйм атлысы, күз кысып.

— Авылда кызлар бармы соң?

— Җитәрлек, — диде икенчесе. — Ил сакчыларына үзебезнекеләр дә җәл түгел.

— Алырсың эт авызыннан сөяк.

— Әҗәткә генә.

— Уртак малны эт җыймас.

Шулай шаярып сөйләшә-сөйләшә, егетләр клубка юнәлде.

Кичке авылның үзенә күрә бертөрле яме бар: пәрдәләре тартып куелган тәрәзләрдә утлар яна; абый-апалар, авыр эштән соң ашап-эчкәч, ял итәргә әзерләнә; яшь-җилкенчәк клубка җыена. Авылда сирәк кенә булса да гармун тавышын да ишетүең ихтимал. Ул кичке тынлыкка чумган авыл өстенә әкрен генә тарала, моң иңдерә, якында гына уйнасалар, ерактан ишетелгән комбайн тавышларын да күмеп китә. Ә соңгылары әле басу-кырларда тәмамысы караңгы төшкәнче, хәтта фараларын яндырып та эшлиләр. Буровой вышкаларында да ут алынган, прожектор ут көлтәсе сибә, көчле лампочкалар бораулаучыларның эш урынын яктырта. Элекке кебек гөрелдәмәсәләр дә, анда эш кайнавы шәйләнә.

Көнбатыш тарафта таулар артына төшеп югалган кызгылт кояшның нурлары әле бик озак шәфәкъны балкытып тора. Сирәк болытларның итәкләренә «ут кабыза».

Клубка барышлый Габделнур ике катлы зур кирпеч бинага тап булды.

— Бу нәрсә?

— Дом культуры төзеп яталар, — диде егетләрнең берсе.

Бина Урта урамның гына түгел, бөтен авылның бизәге булыр төсле иде. Зур-зур тәрәзәләрендә утлар балкый, эчтә кемнәрдер кайнаша.

— Ике смена эшлиләр, — диде Касыйм. — Октябрь бәйрәменә ачарга җыеналар.

Озын итеп урам буйлап агачтан салынган иске клуб эчендә яшьләр шактый иде. Гадәт буенча Габделнур эскәмияләрдә утыручы егет-кызларның, яңарак өйләнешкән парларның барысы белән дә исәнләшеп чыкты, соңрак кергәннәр үзләре килеп күрештеләр. Гармунчылар да җитәрлек икән: элеккеләр дә бар, яшьләр дә үскән — ике рәтле җиңел хромкасын да, өч рәтле зур баянны да, бер-берсен алыштырып, оста тарталар.

Вальс әйләнделәр, кулъяулыклы, өчле, дүртле, сигезле (анысына кунакны да чакырдылар) уйнадылар. Клуб эче гөр килеп торды, күтәрелгән тузан киң сайгаклы такта идәнгә кунып өлгерә алмый, гел аяк арасында бутала иде.

Аннары, тәбәнәк зифа гәүдәле клуб мөдире, хәзер инде шушы авыл килене, баян күтәреп, солдат янына килде.

— Габделнур, уйнале, син бию көйләрен матур уйный идең. Үзем башлап биим.

Һәм... Их, ул авыл халкының биюләре! Аз күрдеме Габделнур аларны! Яшь кызларның дәртле ашкынуы, киленчәкләрнең сагышлы тыйнак хәрәкәтләнүе, ирләре сугышта югалып, яшьли тол калган хатыннарның назга сусаган гәүдәләренең ярсулы өзгәләнүе!.. Бер ишләре биемиләр — йөзәләр, су өстендәге аккошлардай талгын гына йөзәләр! Кул-аякларының төрледән-төрле килешле хәрәкәт ясаулары, зифа буйларының су буендагы таллардай сыгылуы, кигән киемнәренә хәтле күңелгә ятышлы булуы... Өч ел күрмәгән иде Габделнур шушы гүзәл манзараны, хозурлыкны!..

Унбиш-уналты яшьлек кызларның канат чыгарып беренче очышка әзерләнгән кош балаларыдай талпынулары, тәүге мәхәббәттән зиһеннәре чуалыр дәрәҗәдә әсәрләнүләре — барысы да бар иде ул биюләрдә!

Ә егетләр?! Кайсыдыр дәртенә чыдаша алмыйча очып-очып кунгандай итә, ә бер ише кеше көлдерергә тырышып кылана-яклана, кемдер җитезлек белән масая — аякларына күз иярми, ә бәгъзеләр — җитдирәкләр — бөтен шартын китереп, хәтта ки үз-үзенә сокланып, буыннан буынга югалмыйча килгән борынгы үрнәкләрне саклап бии. Биюче саен бер бизәк, биюче саен төрледән-төрле холык-фигыль... Ул гына да түгел — һәрберсенең үзе яраткан, темпераментына туры килгән көе бар!..

Хәер, гармунчылар да бер үк музыка коралын төрлечә, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек итеп, җанындагы бар моңын кушып сайрата бит!

Габделнур, күптән кулына баян тотканы булмаса да, уйный башлагач (бер белгән һөнәр онытылмый икән), үзе дә биючеләрдән ким әсәрләнмәде — өздереп-өздереп, йөрәгенә йон үсмәгән һәркемне уртага атылып чыгарырдай иттереп уйнады да уйнады... Клубта була торган өзлексез гөләү-сөйләшүләр дә пышылдауга күчте...

Чираттагы бер кызга биергә бастылар. Төз гәүдәле, тездән түбән төшеп торган юка күлмәкле, изүләре ачык джемперлы, сары чәчләре иңбашларына таралып яткан озынча аксыл йөзле бу кыз Габделнурга таныш түгел иде. Хәер, клубтагы кызларның байтагын ул инде танымый. Кайберәүләрен эти-әниләренең йөз чалымнарыннан төсмерләп, кайсыларын абый-апаларына охшатып кына шәйли, ә күбесен иптәш егетләреннән, бусы кем, бу кем кызы, дип сораштыргалап утыра иде. Ләкин хәзер, баян уйнаганда, сүз катып булмый, буталып китүең ихтимал.

Әмма кыз, башкалар кебек, уртага чыккан уңайга биеп китмәде, ә туп-туры баянчы каршына килеп басты. Егет уйнаудан туктады.

Кызның ирен читләрендә беленер-беленмәс кенә елмаю хасил булды, йөзенә кызыллык йөгерде, зәңгәр күзләрен тутырып солдатка карады да русча:

— «Цыганочку» знаете? — дип сорады.

— Когда-то знал, — диде егет, елмаеп. — С выходом?

— Да.

Клуб эчендә тынлык урнашты. Бөтен күзләр ят кызга һәм үз авылларының кунак егетенә — солдатка төбәлде. Йөрәкләр ешрак тибә башлады: сынатмаса гына ярар иде! Дөнья бит, бәлки, кайберәүләр шикләнеп тә куйгандыр: ни кыйратырсың икән, янәсе. Кемдер гүя аңа көч бирде сыман: «Әйдә, күрсәт маһирлыгыңны!»

Габделнур, бер генә мәлгә пауза ясап, баянның төймәләрен һәм бака ягын тәңгәлләштереп басып алды да сыздырып җибәрде. Яшьләр җиңел сулап куйды, йөзләргә елмаю чыкты, күңелләрдә горурлык хисе калыкты.

Кыз да төшеп калганнардан түгел икән: ике кулын ике якка кош канатыдай җәеп, бармакларын бию тактына шартлатып, озын күлмәгенең итәкләрен җилфердәтеп, тәбәнәк үкчәле кызгылт туфли кигән аякларын шыкшык басып биеп тә китте... Музыка отыры кызулана барды, көчәйде, аның саен кыз да җәһәтрәк бөтерелде. Аның сыгылмалы гәүдәсе әле түгәрәк ясый, әле кырт борыла, әле бер урында әйләнә, икенче караганда — иңбашларын калтырата... Башта әкренрәк, үз-үзенә бигүк ышанып җитмичәрәк уйнарга керешкән баянчы бармакларының отыры языла баруын, үзләреннән-үзләре кирәкле төймәләрне табып, тигез йөрешен тойды; аңарда азарт кузгалды.

Гармунчы (әгәр ул чын оста икән) беркайчан да, хәзер менә шушы төймә белән әнә теге бакага басыйм әле, дип уйламый, чөнки моңа аның вакыты юк. Ул бары көйне, моңны саклый, ритмны тота, кирәк икән, аягы белән такт биреп утыра. Ә бармаклар... алар үз эшен белергә тиеш: күз иярмәс тизлек белән йөгерергә, буталмаска, әле түбән төшеп, әле югары күтәрелеп, кирәкле төймәләргә басарга һәм өзлексез хәрәкәттә булырга. Аркасы тирләп күлмәге тәненә ябышса да, маңгаеннан яки чәч төбеннән бәреп чыккан тир бөрчекләре агып төшеп күзенә керсә дә, бармаклары суда чыланган шикелле дымланып юешләнсә дә, гармунчы сер бирмәскә тиеш.

Габделнур да менә шул халәттә иде хәзерге мизгелдә. Монда ярыш бара! Егетнең исенә төште: кечкенә уенда яки урамда, капка төбендә яшүсмерләр, җыелышып, гармун белән ярышып бииләр иде. Гармунчы арыймы, әллә биючеме?! Габделнурның бер үк кешегә яртышар сәгать уйнаганы булды, ләкин оттырганын хәтерләми. Дөрес, ул чакта аның кулында ун телле җиңел тальян гармун, көе дә әллә ни катлаулы түгел — гел бер үк төрле мотив — ачы юмор белән әйткәндә — «Эт сөяктән кайткан көй». Аны такмаклап, кул чәбәкләп тә бала-чаганы биетәләр иде олылар: «Кеңгер-кеңгер, кеңгә-кергер, кеңгер-гергер, кеңгә-кеңгер... Сыер сава җиңгәсе лә...»

Ә монда... ярты потлы баян, күнегелмәгән берничә дистә төймә, онытылган көй-мотивлар... Юк, барыбер сынатырга ярамас! Дәрт өстенә дәрт өстәлде кунакның йөрәгенә, илаһи көч керде өч ел авыр солдат күнегүләреннән бераз тупасланган бармакларына һәм... ул бәйгедә бирешмәде. Алай гына да түгел, кыз белән гармунчының йөрәк тибеше бер ритмга салынды, күңел кыллары бергә чиртә башлады сыман.

— Ну малай, кыҗыра бу! — дип башын чайкады аның белән янәшә утырган дусларыннан берсе.

Габделнур «әйе, килешәм» дигәнне аңлатып ияген селкетеп куйды, ярым борылып баш какты. Ул кызның оста биюче икәнен аңлады һәм мөмкин хәтле аңа булышырга тырышты. Чөнки, әгәр бик теләсә, гармунчы мәшһүр биюченең дә аяк йөрешләрен саташтыра ала, иң атаклы җырчыны да тамашачы алдында хурлыкка калдыра. Егет кызга булдыра алганча ярдәм итте. Кыз моны аңлады һәм түгәрәк әйләнеп Габделнур каршына килгән саен аңа рәхмәт хисләре тулы күзләрен тутырып сокланып карады, бит очларын чокырайтып мөлаем елмайды. Клубтагы яшьләр түгел, әле үзләре дә анык тоймаган ниндидер якынлык урнашты гармунчы белән биюче арасында.

Ниһаять, иң ахырда кыз, баянчы каршына килеп, иңбашларын матур боргалап, чәчләрен чөеп җибәрде һәм... башы артыннан ярты гәүдәсе дә артка бөгелеп төште. Шулай да көен һич саташтырмыйча кул хәрәкәтләре белән биюен тәгәлләүне дәвам итте. Менә ул туктады, сыгылмалы билен турайтты һәм реверанс ясады — бармак очлары белән генә тотып күлмәк итәген җәйде, уң аягын артка чигереп куйды, тез чүкте, башын иде.

— Спасибо!

Егет тә, аккорд биреп, уйнаудан туктады, кызга баш иде.

— Вам спасибо!

...Баянны клуб мөдире алып китте дә икенче егеткә бирде.

Габделнур, янәшәсендәге Касыймга карап, сорап куйды:

— Бу кем булды соң?

— Үзем дә белмим. Хәзер сорыйм.

Ул бераздан әйләнеп тә килде.

— Күрше авылга Әлмәттән практикага бер группа гыпытыу кызлары килгән. Болар монда икәү. Берсенең иясе бар, безнең урам егете, монысы — буш. Барасыңмы? Әйтеп куям.

— Ярар.

Авыл егетләре кунак кызларын, алдан ук сөйләшеп, элекке заманда колак тешләп үзләренә атап куйган шикелле, үзара бүлешәләр. Габделнур, барам, дигәч, каршы төшүче булмас, бәлки.

Армиягә киткәндә аны авылдан озатып калучы кыз юк иде. Шуңа күрә бүген аңа кем булса да барыбер. Клубка чыгып, кыз озатмау да (бигрәк тә солдат кешегә) егетлек саналмый.

...Кызлар клубтан чыгуга ук аларны як-яктан ике егет култыклап алды. Монда өлгер булырга кирәк: йә алар качып китә, йә кызларны чаярак егетләр эләктерә. Кунак дип тә, солдат абый дип тә намус саклап тормас хәзерге яшьләр, җебеп торсаң, борын төбеннән алып сыптырырга да күп сорамаслар кулга керә язган малны! Калырсың авыз ачып...

## 30

Яшьләр клубка җыенганда, күк йөзе чалт аяз иде. Ләкин хәзер аны болыт каплаган. Яңгыр алдыннан була торган бөркү һава. Шуңа да карамастан егетнең күңеле күтәренке. Бигрәк тә кызлар белән барганда Ходай тел ачкычлары бирә бит ул! Табигать турында башлап җибәрәсең дә вак-төяк лыгырдый башлыйсың. Телең генә тик тормасын.

Клуб ягыннан дүртәү китсәләр дә, бераздан алар пар-пар булып аерылыштылар. Габделнур белән Наташа (кызның исеме шулай икән) алгарак киттеләр, ә икенче кунак кыз белән авыл егете артта калдылар.

Габделнур, кызны биленнән алып, аңа иелә төшеп әйтте:

— Әлмәт кызлары шундый оста биидер дип күз алдына да китермәгән идем.

— Нигә алай дисез? Әлмәттә булганыгыз бармы әллә?

— Армиягә хәтле мин шунда эшләдем, тулай торакта яшәдем.

— Кайсы урамда?

— Шевченкода.

— Ә-ә, беләм.

— Әллә егетләр янында булганың да бармы?

— Әйе, — диде кыз һәм, бераз баргач, үзенең ялгыш сүз ычкындыруын абайлап, хатасын төзәтергә уйлады: — Абый янында.

Ләкин сүз әйтелгән, ул кош түгел, ычкынды — тотармын димә. Габделнур моны уена салып куйды.

— Без яшь чагында кызлар болай ук чибәр дә түгел, матур да биемиләр иде.

— Комплимент?!

— Чыны шулай. Бик оста биисез.

— Ә сез уйныйсыз. Кайда өйрәндегез?

Солдатка бераз гына үзенең тәрҗемәи хәле, кайда укуын сөйләп узарга туры килде. Аннары әйтәсе итте:

— Армиядә бер чегән егете бар иде безнең. «Цыганочка»ны һәм чечетка бии иде. Безне дә өйрәтте. Казармада, ике урындык аркасына тотынып, яртышар сәгать чечетка тыпырдата идек. Миңа күбрәк хромка тотралар иде.

— Әйтәм оста уйнадыгыз?!

Урта урамнан уңга борылып, тыкрыкка төшеп киттеләр. Габделнур, кыз белән араны якынайту өчен, «син»гә күчте.

— Ә син кайда биергә өйрәндең?

— Училищеда. Безнең анда түгәрәк эшли, бер егет өйрәтә.

— Алабугада укыганда безне дә биергә өйрәткәннәр иде, дөресрәге, танцыларга. Әле без укый гына башладык, ноябрь аенда бугай Вальс кичәсе булды. Аның тарихы турында махсус доклад сөйләделәр. Аннары бию, танцы, төрле уеннар булды. Ахырдан, хәтерем ялгышмаса, «Висла өстендә җырлар» исемле фильм карадык.

— Ә нинди танецлар өйрәндегез?

— Безгә падэграс, падэспан, кроковьяк, конкобежцы, танго, вальс шикелле борынгыларны өйрәттеләр, — диде Габделнур, «борынгы» сүзенә басым ясап. — Хәер, бөтенесен дә иске заманныкы дип булмый. Тангоны, мәсәлән, хәзер дә бөтен Аргентина бии. Биючеләр бер-беренә нык терәлеп, сарылып бетеп биегәнгә, кемдер аны вертикальное выражение горизонтального желания дигән вальс шулай ук мәңге яшәр төсле. Әлбәттә, сез, яшьләр, джайв, пасодобль, румба, ча-ча-ча кебекләрне өйрәнәсездер?

— Юк, безгә аларны өйрәтмиләр шул. Болар — бальный танецлар бит. Ә сез аларны каян беләсез?

— Кайчандыр «борынгы» танецларны өйрәнсәм дә, мин үзем замана кешесе бит. Квикстеп, самба дигәннәре дә бар бугай әле.

— Соңгысы көрәш төре түгелмени? — диде кыз, үз-үзенә бигүк ышанып җитмичә. — Минем абый, армиядә шөгыльләндем, дигән иде.

— Юк, — дип, кызны төзәтте егет, — алар — икесе ике әйбер: бию булса — самба, ә көрәш — самбо. Мин үзем дә ярты ел шул секциягә йөрдем.

Кыз беравык дәшми барды да, егеткә карап, сорап куйды:

— Ә сез нигә үз авылыгыздан берәр кызны озата бармадыгыз?

Бу кызлар бирә торган гадәти, беркатлы сорау булса да, монда бераз хәйлә дә бар. Кызлар шулай егетләрне сыный. Асылда, Наташа үзен нәкъ шушы солдат озатуына һич тә үкенми, якынрак белә барган саен күңеле аңа ныграк тартыла кебек. Дөрес, беренче тәэсир алдаучан. Ләкин тышкы кыяфәтенә карап бирәләр бит беренче бәяне дә, ә ул Габделнур файдасына иде. Әгәр бу егет бүтән берәүне озата киткән булса, кызның бәгырен көнчелек корты кымтырыклап торган булыр иде. Чөнки биегәндә шулхәтле җайлы һәм оста итеп баянда уйнавы белән үк ул кызның күңелен яулаган иде.

Габделнур Наташаның колагына:

— Син дип кенә дәш, — диде. — Минем авылдан чыгып киткәнгә сигез ел инде, ә бөтенләй кайтмаганга — өч.

— Армиядән кунакка кайталар бит.

— Бөтенесе дә түгел. Дөрес, чираттан тыш отпуск игълан иткәннәр иде. Ләкин көтмәгәндә бер солдатка «әниең үлем хәлендә» дигән печатьле телеграмма килде. Аны җибәрдек. Ә авыл кызларын озатуга килсәк, безнең яшьлек мәхәббәтләре күптән бәби үстерә инде.

— Кияүгә чыкмаганнары да бардыр әле.

Габделнур кызны тагын да үзенә якынайтып, колагына пышылдады:

— Тагын бер сәбәп бар: клубта синнән дә чибәр кыз юк иде.

Әлбәттә, дөнья күргән егет буларак, андый сүзләрнең кызлар йөрәгенә сары май булып ятасын ул яхшы белә һәм Наташа колагына мөмкин хәтле мулрак итеп йомшак «токмач элә» иде.

Дөрес, кызны ямьсез дип әйтеп булмый. (Хәер, ямьсез кыз дөньяда була микән?!) Аның сары чәчләре матур булып иңнәренә яткан, ул хәрәкәтләнгәндә, алар да, урыннарыннан кузгалып, дулкынланып алалар; юка борыны аның аксыл озынча йөзенә килешеп, үзенчә бер тәңгәллек биреп тора; иреннәрен мул итеп иннеккә буяса да, кызларга кызыл килешә ул дигән төшенчәдән чыгып караганда, аннан гына гаеп табып булмый. Сары кашлары нечкәртелеп йолкынган һәм көрәнгә буялган булса да, нур өстенә нур гына. Кыскасы, бөтен килеш-килбәте аның инде шәһәрдә беренче генә көн яшәмәүче авыл кызы икәнен сиздереп-белдереп тора иде. Аның озынча аксыл колагындагы кашлы алкаларына хәтле шәһәрчә иде инде. Киң маңгай һәм әлеге көрән төскә буялган кашлар астында озын керфекләр һәм зәңгәр күз — болар кызга сокланып карауны таләп итә иде. Наташаның күз төпләре күгәребрәк торуы да егет игътибарыннан читтә калмады.

Ике урамны бер-береннән кечкенә елгачык аерып тора, аңа салынган тар гына күпернең ике ягыннан да эреле-ваклы таллар тезелешеп киткән. Һәм алар ялга кайткан кунак солдатны да, ул җитәкләгән зифа буйлы кызны да сәламлиләр: башларын иялар, шыбырдашалар, лепердәшәләр. Агачлар арасыннан сирәк-мирәк кош тавышлары да ишетелә; болытлы булса да, киче җылы.

Габделнурлар урамына килеп кергәндә, вак кына яңгыр сибәли башлады. Егет, кызны култыклаган хәлдә бәләкәй капканы ачып, аны ишегалдына алып керде. Алар урыс капка түбәсе астына ышыкландылар.

Күрәсең, хәрбиләрнең погонындагы «Ф» хәрефе бик күп кешеләр өчен яңалык, моңарчы андыйны күргәннәре булмагандыр. Наташа да шул хакта солдаттан сорады. Әлбәттә, егет, гадәтенчә, башта үзен футболчы дип таныштырды. Фәкать берникадәр паузадан соң гына бу хәрефнең ни-нәрсә аңлатканын әйтеп бирде.

— Ә диңгезне без ерактан гына күзәттек. Дөрес, Кронштадтта чагында уртасында ук яшәдек. Бу шәһәр Фин култыгындагы Котлин дигән утрауга салынган. Фин култыгы кечерәк диңгез кебек. Бер ай Выборг шәһә-

ре тирәсендә, фин чигендә, диңгез буенда яттык, хәрби өйрәнүләр вакытында. (Бер белмәгән кызга, урман кистек, дип дөресен әйтеп, дәрәҗәсен төшерә алмый бит инде солдат егет!)

— Диңгез матурдыр, әйеме?

— Искиткеч. Шуңа күрә без әйтә идек: люблю море... с берега. Балык та тоттык.

— Ә анда давыллар булдымы?

— Без барында алай бик көчле штормнар булмады.

— Анда куркынычтыр?

— Билгеле. Шуңа күрә моряклар әйтә бит: люблю шторм... в ресторане. Ресторанга гади матрос керә алмый инде, моны офицерлар уйлап чыгаргандыр яисә сәүдә флоты моряклары. Миңа калса, алар, гомумән, диңгезне күбрәк беләләр. Бик күп китапларда алар белән булган маҗаралы хәлләр бәян ителгән бит. Алар диңгездә төрле җанварларга, су хайваннарына тап булалар, бигрәк тә сигезаякка. Ә ул ялгыш суга мәтәлеп төшкән морякны сагалап кына тора икән дә, имеш, үзенең сигез аягы белән берьюлы аны эләктереп ала икән дә су төбенә өстери икән...

— Нинди куркыныч! — диде кыз, егеткә карап.

Габделнур кызны кочагына алды да аның колагына ук пышылдады:

— Менә шулай итеп, үзенә тартып китереп, аны кыса икән...

Наташа егетнең кайнар кочагына кереп бетте, аңа үзенең гәүдәсе Габделнурныкы белән тоташып, бер тән, бер җан кебек тоелды; аларның иреннәре кушылды. Тансыклаган солдат аны озак итеп, суырып-суырып үпте, кыз да шундый ук дәрт һәм ихтыярына буйсынучанлык белән җавап кайтарды, аның күзләре йомылды, гәүдәсе йомшады, егет кочагында эреп бетү теләге бөтен вөҗүден биләп алды. Болар берсе дә Габделнурның сизгер тоемлавыннан, моңарчы туплаган тәҗрибәсеннән (Зоя өйрәткәннәрдән) читтә калмады. Ул, сигезаяк роленә кереп, кызны җайлап кына үзенә арты белән борып бастырды һәм, джемпер төймәсен ычкындырып, юка күлмәге аша имиләрен тотты. Алар йомшак иде. Тәмам мәлҗерәгән кыз фәкать беркавым торгач кына солдат куеныннан чыкты.

Аннары Габделнур, Кронштадт, Петродворец фонтаннары, Ленинград турында сөйләп, кызны тәмам әсир итте. Ахырда, булган булсын инде дигәндәй, кайчандыр, кемнәндер (әллә экскурсия вакытында гид сөйләдеме) ишеткән бер вакыйганы да кыстырып җибәрде:

— Ленинградта заманында бик күп атаклы кешеләр яшәгән. Бөек композитор Штраус берничә ел рәттән җәен шунда үткәргән. Билгеле, ул чорда шәһәрнең исеме — Санкт-Петербург. Штраус бу шәһәргә берничә әсәрен багышлаган: полька, полонез, вальс. Ә вальсны ул Ольга Смирницкая исемле кызга атап язган. Кыз бик акыллы, зифа гәүдәле, нәкъ менә синең кебек гүзәл икән. Штраус аңа үлеп гашыйк була, Ольга да композитор егетне ярата. Ләкин алар кавышмыйлар.

— Нигә?

— Монда ниндидер киртәләр, социаль хәлләренең тигезсезлеге сәбәп була.

— Анысы нәрсә?

— Ул чорда бай кызы ярлы егеткә кияүгә чыга алмаган, ә дворян баласына берәр мещан кызына өйләнү тыелган, чөнки аларны социаль яктан тигез түгел дип караганнар. Менә шул: соңгы җәендә Штраус «Петербург белән хушлашу» дигән вальс яза. Ул бик матур, ләкин моңсу вальс. Аны калын тавышлы виолончель башлап җибәрә, оркестр дәвам итә, тора-бара кларнет кушыла... Вальс беткәнче бу көйне буеннан-буена моңсулык аһәңнәре озата бара...

Габделнур теленә килгән бер мелодияне шыңшып та күрсәтте. Шулай итеп ул Наташаның зиһенен тәмам чуалтты.

Аннары Ленинградка багышланган тагын бер җыр җырлап күрсәтте. Ул солдат-матрослар арасында киң таралган, җиңел мелодиягә салынган иде.

Всю ночь над городом в ненастье,
Всю ночь колдует темнота.
Остановилось чье-то счастье
У разведенного моста...

— Анда күперләр төнлә ике якка ачыла, өскә күтәрелә.

— Ни өчен?

— Кораблар Нева елгасына керсен өчен.

Яңгыр явудан туктамады.

— Без монда чыланабыз, — диде Габделнур, капка түбәсенә ымлап, һәм кызны култыклап ишегалды түренә алып китте. — Өйдән дә чыгалар бугай, бәләкәй якта ут кабыздылар шикелле.

Алар, мыш-мыш килеп, авыр сулап күшәп яткан сыер, бер-беренә сыенышкан сарыклар ябылган туры лапас янынннан узып, бакча капкасын ачып керделәр. Турыга — сукмак биек сиртмәле коега илтә, ә сулга — мунчага. Кыз аны-моны абайлап өлгергәнче, Габделнур, теленә салынып, аның игътибарын үзенә җәлеп итте

һәм, тиз генә баскычтан күтәрелеп, мунча алдының ишеген ачып, кызны эчкә үткәрде. Ләкин кыз үзенең тозакка эләгүен сизде, ахры, мунча эченә керүдән баш тартты.

— Мин анда кермим!

Әмма егетне туктатырлык көч юк иде инде.

Аны кызның кайнар, яшь тәне, чәчләреннән аңкып торган исерткеч хуш ис, сыгылмалы нечкә биленең һәрдаим дәрт бөркеп торуы күптән кызлар назы күрмәгән солдатның аңын томалаган иде. Бу минутта аның алдында фәкать фәрештәдәй гүзәл кыз һәм шул мизгелдә барлыкка килгән максат — аны яулап алу биләгән иде. Гасырлар буена килгән инстинкт алдында ул көчсез иде, аны хәзер беркем дә, берни дә бу уеннан кире кайтара алмас, аның ташкын дәртен тыеп тора алмас кебек иде. Аңа ут та кирәк түгел: ул кайсы ишекнең келәсе кайда икәнен күз йомып та белә. Габделнур тышкы ишекне эчтән бикләп куйды һәм, бер кулы белән мунча ишеген ачып, икенчесе белән Наташаны култык астына кыстырып диярлек, эчкә үк керде. Бу ишекнең дә келәсен төшерде.

Бая капка түбәсе астында торганда ул беренче мәртәбә кызны үпте, аның иреннәренең егеткә буйсынып, үзенә дә ләззәт алуын сизде, имиләрен зур учлары белән иркәләде, назлады һәм аларның бигүк каты түгеллеген белде. Шуңа күрә хәзер артык нәзакәтлек саклап тормады.

Ләкин мунча эчендә кызны алыштырып куйдылармыни: ул киреләнә башлады, үзе бертуктаусыз сөйләнде:

— Син нигә мине монда алып кердең? Мыскыл итәргәме? Мин кеше күзенә ничек күренермен? Кызлар ни әйтер? Әнигә ни дип җавап бирермен?..

Тик Габделнурның каты кулыннан ычкыну мөмкин түгел иде инде. Егет аны бөтереп алды һәм уң як стена буендагы эскәмиягә сузып салды. Кыз елый ук башлады. Һәрхәлдә, Габделнурга башта шулай тоелды.

— Әрәм итмә минем яшьлегемне! Мин бит әле саф кыз! Кирәкми, кирәкми! Ой, әнием! Нишлим мин? Әнием-бәгырем! Сезгә шул гына кирәк. Ә без... теләсә нишлик... Балага узсам?.. Нигә шулай кыланасың? Салдырма... Син әйбәт егет бит... Мин бит сине... Ой, кирәкми!.. Не губи мою молодость!..

Кыз бәргәләнә, чәбәләнә, карыша, үзе һаман сөйләнә, ә егет аны тагын да көчлерәк дәрт белән үбә, коча, үзенә буйсындырырга омтыла иде. Бермәл, зиһененә ачыклык кереп, Габделнур, әллә ялгыштыммы соң, чыннан да саф кыз микәнни, дип уйлап аның өстеннән тормакчы да булган иде. Ләкин шулчак тавышында бернинди дә елау-сыктау чагылмаган кыз аны үзе шашкын дәрт белән үбә, коча, яратуын аңлата башлады. Аның өзек-өзек җөмләләре каяндыр ерактан ишетелә сыман, йокы аралаш эндәшкән дә кебек, аерым сүзләре бөтенләй аңлаешсыз иде.

Бераздан кыз:

— Мин үзем, сабыр ит, — диде һәм, урыныннан торып, чишенә башлады. — Син дә чишен...

...Габделнур янәшәсенә эскәмиягә торып утырган Наташа аның куенына кереп бетте. Ул озын бармаклары белән солдатның кыска каты чәчләрен назлады, юан беләкләрен сыйпады, аның дәү кулын үзенең бәләкәй учына салып иркәләде.

— Син нинди көчле?! Мин сине яратам! — диде ул һәм, башын күтәреп, Габделнурның иреннәренә үрелде.

Егет аны тыны кысылганчы үпте.

Аннары:

— Ә син нигә башта карыштың? — дип сорады.

— Ә миңа шулай рәхәт, — диде кыз, берни булмагандай, караңгыда аның колагына ягымлы кайнар сулышын өреп. — Бер кыз әйткән бит: «И Алла, зачем дала, еще бы девочкой была». Ә минем үземне һәрчак саф кыз итеп тоясым, күрсәтәсем килә. Шуңа күрә мин көч белән алганнарын яратам. Мямля, хлюпикларны җенем сөйми. Ә син көчле! Мин сине беренче күргәч тә ошаттым. Кил, тагын телисеңме?!

## 31

Алар мунчадан чыкканда, яңгыр туктаган, күк йөзе ачылган, көнчыгыш тарафта алсуланып таң беленә башлаган иде.

Габделнур кызны алдан үткәрде. Ул мунча ишеген япкан арада Наташа кичә килгән сукмак буйлап бер-ике адым атлап өлгерде.

— Наташа, анда барма, — диде егет. — Мин сине моннан гына озатам.

Ул бәдрәф янындагы бәрәңге бакчасына чыга торган арт капканы ачты. Алар күршеләр бакчасы белән ике арада калган ызаннан үргә таба киттеләр. Кеше йөргән сукмак булса да ул тар иде. Юеш бәрәңге сабакларыннан, яфраклардан коелган салкынча яңгыр тамчылары кызның аягына тама, артык биек булмаса да, туфли үкчәләре йомшак җиргә батып керә иде.

— Мин яланаяк барам, — дип, кыз туктады.

— Салма, — диде солдат һәм кызны җәлт кенә кулына күтәрде.

— Ой, мин авыр бит, — диде Наташа, чытлыкланып, ә үзе Габделнурның таза муеныннан кочып алды. — Мине әле берәүнең дә шулай кулында күтәреп йөрткәне юк иде. Загстан чыккан кәләш кебек булдым. Какой ты славный! Рәхмәт.

Ул егетнең иреннәренә үрелде. Габделнур туктарга мәҗбүр булды... Янә алга атлады.

Бакча башына җиткәч, кыз:

— Булды, җитте, үзем барам, — диде.

Габделнур аны сак кына җиргә бастырды. Үр аша чыктылар. Алда, ундарак күренгән ферма өе яшьләрне озатып калды. Дөресен генә әйткәндә, ул ферма өе түгел, ә мәчет иде. Заманында Урта урамны (калган ике урамның — мәхәлләнең — үз мәчетләре булган) бизәгән бу мәчетнең истәлеге булып янындагы күл генә һәм аның атамасы — Мәчет күле генә калган. Габделнурлар үскәндә манарасыз бу мәчет алар урамындагы бер буш ихатада тора һәм ашлык склады ролен үти иде. Хәзер әнә бәрәңге бакчаларыннан да читкә, ындыр артына ук, дуңгыз фермасы янына ук күчереп салганнар. Ул әле дә кыйблага каратылган михрабы, калай түбәсе, зур-зур тәрәзәләре белән горур утыра, тик искергән, таушалган, ремонтланмаган кыяфәте белән иртә-кичме, көндез яки төнләме яныннан үткән-сүткәннәргә рәнҗеп кала сыман.

Наташаны озата баручы Габделнурга да шулай үпкәләп калды микән, әллә аны сәламләде микән, солдат ул турыда уйлап баш ватмады. Бу горур бинага бары бер генә карап алды да юлын дәвам итте. Дистә еллар дәвамында рәнҗетелгән мәчет түбәсендә утырган бер карт карга, әллә мазасын китәргәнгә ачуланып, әллә гадәттәге табигый бер халәтен — вазифасын үтәү йөзеннән, аны бимазалаган кыз белән егет артыннан әле төнге йокыдан айнып җитмәгән карлыккан тавышы белән ризасызлык белдереп калды.

Колхоз фермасы яныннан борыннарын җыерып бераз баргач, элек кичке уен була торган болыннан киттеләр. Аннан алар таш юлга чыктылар. Уң якта зират агачлары моңсу гына утырып калды, сулда урылмаган иген басуы тымызык җилдә беленер-беленмәс кенә чайкала, чөнки тук башаклар яңгырга чыланып тагы да авырая төшкәннәр. Иске авыл күпереннән межага хәтле уйный-шаяра бардылар. Каршыларына машина-фәлән очрамады. Тирә-юнь гаҗәеп тынлыкка чумган иде.

Межа турысыннан алар сөйләшкәнгә уянган таң кошларының тавышларын тыңлый-тыңлый берникадәр юл үткәч, Габделнур туктады.

— Моннан үзең генә кайт инде, — диде ул. — Курыкмыйсыңмы?

— Юк, — диде кыз, аңа сарылып. — Минем әле синнән аерыласым килми.

— Минем дә, ләкин... кирәк.

— Тыңлыйм, иптәш командир, — диде кыз һәм, уң кулын чигәсенә тидереп, честь биргәндәй итте.

— Пустой голове рука не прикладывается!

— Как? У меня пустая голова?! — диде Наташа, ярым шаярып, ярым шелтә белән.

— Үпкәләмә. Синең баш киемең юк.

— Аңладым, — диде кыз һәм, кисәк кенә үрелеп, солдатның фуражкасын алып киде. — Хәзер честь бирергә ярыймы?

Габделнур: «Син честеңне әллә кайчан кемгәдер биргәнсең инде», — дип уйлады, ләкин үзенә бәхетле минутлар, ләззәт биргән кызны рәнҗетәсе килмәде.

— Ярый, — диде ул, көлеп, аннары өстәде: — Хәзер син минем кырык көнлек хатыным булдың!

— Ничек?

— Хатын-кыз берәр ир-атның баш киемен кисә, шулай әйтәләр.

— Аңладым, — диде кыз, фуражканы солдатның башына кидереп, һәм моңсу гына әйтте: — Мин синең бер көнлек хатының булдым.

Наташаның күңелен тыелгысыз сагыш биләп алды. Ул, күзләрен тутырып, егеткә карады. Бер кич, бары бер кич! Ә никадәр якын иде бу асыл егет аңа! Горур килеш-килбәте, чын ирләрчә кырыс йөз-чырае, хатын-кызга мәңге онытылмаслык чын ләззәт бирә алырдай көчле, таза-сәламәт тәне һәм... гади, ләкин ательеда теккәндәй таман киеменә хәтле үзенә тартып тора иде кызны. Ул аның белән гомер буе менә шушылай назлашып-сөешеп яшәргә, хәтта колы булырга да риза иде. Тик ул гына каршы килмәсен... «Хыялый, исәр, — дип, үз-үзен битәрләде кыз. — Җитте сиңа... Әгәр очрашуны дәвам итәргә теләсә, ул үзе бу хакта сүз кузгатыр иде. Ул бит Әлмәттә эшләп киткән. Мөгаен, анда бармый калмас. Ләкин ул бу турыда ләм-мим... Димәк... Бер кич өчен дә рәхмәт әйт». Бүген аларның практикасы бетә, алар китәргә тиеш. Үзенең күңеленә хуш килгән тагын берәү белән аерылыша...

Кыз, егеткә яны белән борылып, сагышлы карашын уңга, каядыр еракка-еракка, зәңгәрләнеп күренгән биек тауларга төбәп, йөрәк өзгеч тавыш белән җыр сузды:

...Ах, я сама, наверно, виновата,
Что нет хорошей любви у меня.

Хәер, бу җыр гына түгел, ә яшьлегенең алсу чәчәкләрен вакытсыз койдырган җилбәзәк кыз баланың бәгыреннән ташып чыккан сагыш, әрнү-өзгәләнү, иңрәү авазы иде.

Наташа «Ах, я сама, наверно, виновата...» дип җырласа да, чынында, әгәр вакытны бер-ике елга арткарак чигереп караганда, беренче мәртәбә егетләр астына ятуында ул үзе гаепле түгел иде. Аларның авылы кечкенә булганлыктан, ул урта мәктәпкә күрше авылга йөреп укыды. Соңгы елны җәй көне туганнан туган абыйсы аны мотоциклга утыртып алып китте дә урман эчендә көчләде, беркемгә дә әйтмәскә кушты, куркытты. Аннан инде китте... Кызның үзенә дә рәхәт була башлады...

...Ах, кавалеров вполне хватает,
Но нет хорошей любви у меня.

Егет дәшмәде. Кыз, кисәк аны муенынnан кочып, иреннәреннән суырып-суырып үпте дә, килеп тыгылган күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, кырт борылып, торып йөгерде. Габделнур урынынnан кузгалмыйча аның артыннан карап калды. Бераздан Наташа туктады, борылды һәм, солдатның әле һаман урынында басып торуын күргәч, күңеле күтәрелеп китте: елмайды, кул изәде.

— Ху-уш!

Габделнурга килеп ирешкән соңгы сүзе шул булды.

**32**

Икенче көнне, кичке якта, җизнәсе кереп, кунакны үзләренә, сигез чакрымдагы авылларына алып китте. Солдатның бертуган апасын күрмәгәненә дә өч елга якын иде инде.

Габделнурның апасы аңардан өч яшькә олы. Авылда җиде класс бетергәч, алар, ике кыз, Алабуга китапханә техникумына (апасына кечкенәдән үк китап җене кагылган иде) укырга керергә дип киттеләр. Апасы кергән, ә иптәш кызы имтихан бирә алмаган. Ләкин, яшьлек юләрлеге димичә ни дисең, апасы, иптәш кызыннан аерыласы килмичә, документларын алып, аның белән бергә авылга кайтты.

Ул кышын фермада сыер сауды, ә җәен берничә ел рәттән, кызлар белән җыйнаулашып, Горькийга китәләр иде. Көз җиткәч, өс-баш бөтәйтеп, сандык-чемоданнарын кием-салым, ситсы (күбрәк үзләренә бирнәлек) һәм кучтәнәчләр белән дыңгычлап тутырып, су юлы белән — пароходка утырып — Чаллыга кайталар. Ә аннан кызларны машина белән барып алалар иде.

Горькийга дип китсәләр дә, эшләре шәһәрнең үзендә түгел, ә шул төбәктә — торфта. Бу хезмәтнең никадәр авыр икәнен, көннәр буе бил бөгеп эшләүләрен, каз оясы хәтле зур кәрҗиннәр белән торф кирпечләре ташуны, кулларына һәм иңбашларына кан төшүне шунда эшләгән кеше үзе генә белә. Чөнки кайбер җегәрсезрәкләр, ата-ана канаты астыннан чыкмыйча җылыда гына үскән кызлар, бер күреп кайткач, икенче елны ике аякларының берсен дә атламыйлар иде. Әмма авыл җирендә андый кызлар сирәк була. Горькийдан кайткан кызларның абруй зур — «базары тиз күтәрелә» — аларны үз авыл егетләре дә, елгыррак күршеләр дә «чүпләп» кенә торалар. Җир җимертеп эшләгән кешене кем генә тормышта үзенә юлдаш итмәс икән?!

Җизнәй буласы кеше белән танышканчы, Габделнурның апасы авылның бер егете белән йөри иде. Ләкин аны зур фаҗигадән соң төрмәгә утырттылар.

Ул чорда авылларда үтә торган сабан туен «мәйдан» дип, ә райондагысын «җыен» дип атыйлар иде. Район җыенына һәр авылдан эскәмия рәвешендә кара-каршы беркетелгән такталарга яшьләр тезелешеп утырган берничә тройка бара иде. Егет-җилән булган төштә күп бәхәс кул көче белән хәл ителә: тәртә яки кучәр башы тиеп китсә дә, үрәчәләр эләгешсә дә, кемдер каршы килгән атларга сигездән үргән каеш чыбыркы белән селтәнсә дә, кызлар бүлешә алмасалар да...

Унике чакрымдагы күрше авыл егетләреннән берәү җыенда Шәяхмәткә суга. Ни өчен? Нәрсә ошамаган? Ул ничек берүзе аларга туры килгән? Күпләр өчен болары караңгы булып кала. Күрәсең, үче булгандыр. Низаг кызлар аркасында килеп чыкса кирәк. Туган Йорт егетләре, гомумән, авыл кызларын читкә җибәрмәскә тырышалар; кызлар элек-электән тирә-күрше авыл егетләренә бик сирәк эләгә. Шуңа күрәдер, үпкәләгән егетләр, рәнҗеп, җыр да чыгарып калдырганнар.

Туган Йорт ул — бик бай авыл,
Алагаем зур авыл.
Кызларын читкә бирмиләр —
Итәк саен каравыл.

Кыскасы, Шәяхмәткә дә тиктомалдан китереп сукмаганнардыр (аның буй җиткән сеңлесе бар иде), берәр егетнең үче булгандыр. Хәзер инде ул үчен кайтарырга тиеш. Егетлек шуны таләп итә. Мәсьәләне шунда, җыенда ук хәл итә алмыйлар — район үзәге, милиция бар.

Ә егетләрнең кайту юлы нәкъ Туган Йорт аша узасы.

Шәяхмәт, алданрак кайтып, берничә егет белән авыл башына олы юлга чыга. Әтисенең ике энесе дә яшьләргә иярә: алар инде өйләнгән ир-егетләр булсалар да, туганнарын рәнҗетергә беркайчан да ирек куймыйлар, сәбәп чыкканда, үзләре дә көч-җегәрләрен күрсәтеп алырга атлыгып торалар. Нәселләре шундый, данлыклы иде.

Тегеләрнең каршыларына чыгып, өчләп җиккән атлы егетләр-кызлар утырган арбаны юл уртасында туктаталар. Дугадагы кыңгырау, мичәүдәге атлар муенындагы шөлдерләр, өздереп уйнаган гармун, яшьләрнең дәртле җыр тавышы — барысы да ярты юлда өзелеп, тынып кала. Бары янәшәдәге иске зиратта бер кошның зар елагандай сагышлы тавышы гына ишетелеп тора.

Аякларын җәеп баскан иң көчле өлкән агай сорый:

— Кайсыгыз минем энекәшкә тиде?

Таза-таза кызмача егетләр арбадан коела. Каршы басалар. Кирәк бит, әзмәвердәй берсе алгарак чыгып баса:

— Мин!

Беләк юанлыгы имән күсәк күз ачып йомганчы егетнең чигәсенә килеп тә тия. Бу орудан әзмәвер сүз дә әйтә алмыйча гөрселдәп җиргә ава...

Исенә төшсә, Габделнур ул егетне әле дә күз алдына аермачык китерә: юл кырында, чирәмдә, озын гәүдәле берәү ята; йөзе яулык белән капланган, терсәктән сызганулы беләкләре өй бүрәнәседәй юан... Аның янында яулыгын бөркәнеп диярлек япкан бер кыз утыра, елый-елый шешенеп беткән, бер учында кулъяулык — әледән-әле борынына тидереп ала...

Берникадәр вакыттан авылга районнан милиция килеп төште. Башка вакытта урам малайлары милиция күренүгә кайсы кая таралыша торганнар иде, бүген зират киртәсе яныннан китмәделәр. Берсенең, авылга карап, револьверын болгый-болгый кычкырынганы, янаганы әле дә булса Габделнурның хәтерендә.

— Шушы Туган Йорт кешеләрен бөтенесен атып үтерәсе бар! Җыен саен кеше үтерәләр!

Монысын малайлар бигүк аңлап бетерә алмадылар. Чөнки андый хәлләр һәр елны булмый иде шикелле. Сугышу була, кеше үтерү гадәттән тыш хәл иде.

Шул көнне кичке якта Габделнурлар күршесендәге бер егетне арбасына салып алып кайттылар. Гөнаһ шомлыгына каршы, колхоз көтүен калдырырга кеше булмагач, ул җыенга бармаган һәм, берьялгызы кайтып килгәндә, теге авыл егетләренә тап булган. Аның карар җирен калдырмаслык итеп кыйнаганнар иде. Ул берничә ай урын өстендә ятканнан соң гына тернәкләнеп аякка басты.

Шул хәлләрдән соң Шәяхмәт тә, ике абыйсы да ябылуга эләктеләр.

Өч елдан Габделнурның апасы күрше авылның (колхоз да, авыл Советы да бер иде) шушы егетенә — Насифка кияүгә чыкты.

Җизнәсен Габделнур бик якын итте. Ул кара чәчле, уртача буйлы, гәүдәгә таза, нык бәдәнле, хәрәкәтләре җитез, йөзендә һәрчак елмаю. Өйгә килеп керсә, әби, бабай, дип үлеп тора, карт әбиләре белән дә сөйләшергә сүз таба. Каенишләрен һәм каенагасын хөрмәт итә. Салып алса, гармун да тартып җибәрә, кеше уйнаса, кушылып та җырлый. Эшкә килгәндә, колхоз шоферлары арасында беренчеләрдән санала. Яшьли авылда һәм шахтада эшләп чыныккан егет иде.

Сөйләве буенча, аны мәҗбүри рәвештә ФЗӨгә алганнар, аннары ул, яше унсигезгә җиткәч, бер ел шахтада — җир астында эшләгән. Армиядән соң да берничә ел күмер чабып бәхетен сынаган һәм, сагынуына түзәр әмәле калмагач, туган авылына кайткан. Армиядә өйрәнгән шоферлык һөнәре колхозда бик ярап куя аңа.

...Өйләре каршына килеп туктауга, Насиф кабинадан сикереп төште дә, бәләкәй капканы ачып, солдатны ишегалдына уздырды. Веранда ишегенең биген шакылдатып, көр тавыш белән эндәште:

— Карчык! Гөлсылу! Чык, каениш килде!

Кояштай балкып, өйдән Габделнурның апасы килеп чыкты.

— Каениш, апаңны бик каты кочаклама! — диде җизнәсе, авызын ерып. — Малайны имгәтә күрмә!

Кем әйтмешли, апасының корсагы борынына җиткән — түм-түгәрәк — баскычтан яны белән кырын-кырын, култыксага ябышып һәм аска карап төште.

— Исәнме, апаем, — диде ул, энесенә ике кулын сузып. — Исән-сау кайттыңмы?

— Әйбәт кенә...

Өч ел күрмәгән, гәүдәгә тәбәнәкләнеп калган апасы белән Габделнур бик җылы күреште. Яшь чагында Гөлсылу бик чибәр иде. Ул әле дә матурлыгын җуймаган: шул ук кыйгач кашлар, биек маңгай, килешле туры борын, якыннарына үз итеп карый торган ачык коңгырт күзләр. Шулай да хәзер әзрәк төс салган: битенә вак, соры ком бөртекләре сыман сипкелләр чәчелгән, авызын йоммыйча сулыш ала, иреннәре кабарып-бүлтәеп тора. Кул кысуы элеккечә каты, карашы ягымлы.

Аның белән бер-ике сүз алышкач, Габделнур җизнәсеннән сорады:

— Малай көтәсезмени?

— А как же! Кыз бар. Хәзер малай кирәк.

— Ходай ни язган инде, — диде апасы, уйчан гына.

— Ярар, кем булса да. Әйдә, каениш, кулларыңны юарсың. Карчык, ашың әзерме?

— Ие.

— Тегесе? — дип күз кысты Насиф хатынына.

— Анысы да бар.

— Вот маладис минем хатын! Эш кешесенең кадерен белә.

Шулчак бәләкәй капка ачылды һәм курчак кебек кенә бер кыз бала, йөгереп килеп, әтисенә сарылды.

— Кызым, солдат абыең белән күреш. Карточкасын күргәнең бар бит.

Кызчык сары чәчле башын чайкап, аскы иренен кысып, әтисенә сырпаланып, ятсынып торды. Әтисе тагын әйткәч, аның кочагыннан чыгып, Габделнурга килеп сыенды.

Солдат абыйсы аны култык астыннан күтәреп һавага чөйде...

Кечкенә булса да, башка чыккач яшьләр үзләре салып кергән йорт бик күркәм: шифер түбәле, урам якта — өч, ишегалды ягында ике тәрәзә, рамнары акка, йөзлекләре зәңгәргә буялган, бизәкләр төшерелгән. Үзенә күрә, җыйнак кына итеп, абзар, келәт, сарай ише каралты-кура да тергезгәннәр. Алардан читтәрәк тагын бер корылманың кыегы күренә.

— Җизнәй, әллә мунча да салдыгызмы?

— Быел өлгертеп булырмы-юкмы, күтәреп, түбәсен ябып куйдык.

Табын янында җизнәсе дә, апасы да Габделнурны кыстый-кыстый сыйладылар. Аш-су тәмле, кыздырган балыкка хәтле бар (елгалы авылның кунакларга куяр өчен үзенә күрә ят, затлы ризыгы). Табын мул иде — ир-атлар икесенә бер шешә бушаттылар.

Өй эче җиһазларына да күз салды кунак. Карават, шифоньер, өстәл, урындыклар — кибетнеке, ә идәнгә һәм караваткa җәелгән паласлар — карчыклар кул хезмәте, тәрәзә пәрдәләре һәм башка чүпрәк-чапрак апасы теккән-чиккән әйберләр иде.

Аштан соң Насиф, ишегалдына чыгып бакча буендагы эскәмиягә утыргач, ике рәтле хромкасын тартып җибәрде.

Аннары, бераз уйнагач:

— Олуг барда телең тый, оста барда — кулың, — дип, гармунын Габделнурга бирде. — Мәле, каениш, «Шахта»ны сыздыр әле.

— Онытмаган булсам...

— Бөгештермә, — диде җизнәсе, рәхәтләнеп көлеп. — Кичә син анда бер марҗа кызын «эштән чыгаргансың» диделәр.

— Юк ла...

Габделнур кызарды, ахры.

— Мин, биеткәнсең, диюем... Маладис, анда бөтен ындыр табагы сөйли синең баянда ничек оста уйнаганны...

Габделнур җиңел сулап куйды. Ул уйный башлауга, Насиф моңлы тавыш белән, ишегалдыннан читкә таралмаслык кына итеп, әкрен генә җыр сузды:

Шахтер егет күмер чаба,
Вак-вак итеп кисәген...

Бераздан ул җырлаудан туктады.

— Их, каениш, андагы хәлләр төшкә керсә дә сискәнеп уянып китәм. Яшьлек юләрлеге белән эшләдек инде. Кырык сантиметрлы пластны, аркага ятып, кәйлә белән чапкан чаклар да булды... Ничек Ходай саклаган... Ну аның каравы акчасын да көрәп ала идек инде. Шуннан кайткан акчага өй салып кердек. Ничава, монда да эшләгән кешене күрәләр. Узган ел бабай белән икебезгә орден бирделәр. Икебезнең бертөсле... Келәт тулы ипи, мал-туар да бар үзенә күрә...

Шуны раслагандай көтү кайтты: капкадан сыер, бәрәннәрен ияртеп сарыклар керде. Аларны әнисе белән бәләкәй кыз каршыладылар. Гөлсылу, ап-ак чиләк алып, ишегалдында ук сыер саварга кереште.

Шулчак капкада Насифның энесе күренде.

— Кунак бар икән, — диде ул, абыйсыныкы кебек зур кулларын сузып. — Исәнме, кода. Дембельме?

— Юк әле, — диде Габделнур, күрешеп.

Энесе гәүдәгә Насиф чамалы — эре сөякле, ләкин кыяфәте бераз үзгәрәк — чәче сап-сары. Шушы авылда, төп йортта яши, быел гына өйләнгән.

Бераз вакыт ничек, ни белән кайту, армия хәлләрен (үзе дә вакытында хезмәт иткән) сораштыру булды.

Аннары ул, кыяр-кыймас кына:

— Абый, бая синең кайтканыңны күреп калган ием, — диде. — Кода булгач, әйтүе дә читен... Капка баганасы утыртасы бар иде. Булышмассыңмы?

— Була ул, — диде Насиф берсүзсез. — Әзрәк җибәрәсеңме? Алып чыгам...

— Юк. Әле анда эш каты. Осталар бар. Соңынтын...

Габделнур:

— Мин дә барырмын, — диде. — Алыштырырга кием булса...

— Юкны сөйләмә, — диде җизнәсе. — Кунакны эшләтергә... Әллә син теге...

Энесе дә аның сүзен җөпләде.

— Килешмәгәнне... Анда кеше җитә. Олы абый да киләсе.

— Син клубка чыгарсың, — диде җизнәсе Габделнурга һәм елмаеп өстәде: — Любой кызны озат, миннән рөхсәт.

**33**

Районның читенә урнашкан, артык зур булмаган авылның клубы да уртача иде. Бүген кино икән.

Габделнур билетка акча сузды.

— Солдатны бушка да кертәбез, — диде клуб мөдире. — Уз әйдә, рәхим ит.

Клубта яшьләр шактый, ләкин берсе дә Габделнурга таныш түгел. Чөнки ул үскән чорда бу авыл балалары үзләрендә җидееллык мәктәптә укыдылар. Аннары күбесе күрше район үзәгендәге урта мәктәпкә йөреп унынчыны тәмамлады. Чөнки ул районга олы юл бар, арасы да якынрак. Хәер, үз район үзәгендә укысалар да, егет аларны белмәс иде.

Яшьләр борыла-борыла кунакны күзәттеләр, ул да караштырып утырды.

Ут сүнде, кино башланды. Ләкин, ун минут чамасы вакыт узгач, солдат бу фильмның эчтәлеген исенә төшерде. Армиядә чакта караган икән. Ул шыпырт кына, кешеләрне борчымаска тырышып, клубтан чыгып китте.

Урамда чагыштырмача тыныч. Клуб тирәсендә җан иясе юк. Уң якта, бераз арырак, капка төбендә ике-өч ир-ат сөйләшеп тора. Сулда кемнеңдер кайтмый калган сарыгы кая барып сугылырга белмичә каңгырып йөри. Күк йөзе аяз, көнбатышта, алар авылы ягында, шәфәкъ алсулыгы әле сүрелмәгән.

Агач клубның бүрәнә диварына ике велосипед сөяп куелган. Авыл яшьләренекедер инде.

Габделнур уйга калды: апаларына кайтса — җизнәсе өйдә түгел, кодаларына сугылса — алар әле капка белән мәшгульдер. Эшләгән кеше янында торганчы, тәмәке тарткан кеше янында тор, диләрме әле. «Аптыраган-йөдәгән, артын мичкә терәгән» дип куйды егет, көлемсерәп.

Ул баскычтан төште дә стена буендагы велосипедлар янына килде. Өр-яңа булмасалар да, таза күренәләр. Тәгәрмәчләренә күз төшерде. Көпчәкләре дә яхшы кабартылган сыман.

«Ни булса, шул булыр» дип тәвәккәлләде дә солдат җәлт кенә берсен эләктерде, менеп атланды һәм, урам аркылы чыгып, тау түбән төшеп тә китте. Елга аша салынган такта күпердән узып, каршы як тауга күтәрелә башлады. Яртысын менгәч, велосипедтан төшеп, аны җитәкләп барды. Аннары, тау башындагы юл тигезләнгәч, кабат «бахбае»на утырды.

Өч ел өзлексез спорт, хәрби күнегүләр белән шөгыльләнгән аяклары педальне җитез әйләндерде: вактөяк калкулыкны, яр-үрләрне менгәндә велосипедтан төшеп тә тормады, ә юл түбән таба булганда коштай очты гына.

Ярты сәгать узды микән, юк микән, ул инде үз авылының клубы янында иде. Баскычта ике егет тәмәке пыскытып тора.

— Исәнмесез, егетләр, — дип дәште Габделнур аларга һәм велосипедны стенага сөяп куйды. — Вечер бармы?

Икәве беравыздан исәнләшкәч:

— Бүген кино, — диде егетләрнең берсе.

«Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас» дип, әнисенең гел әйтә торган сүзләрен кабатлады егет. Шулай да эчкә узды. Егетләр дә аның артыннан керделәр.

Габделнур ишектә пәйда булуга, арткы рәтләрнең берсендә утырган дусты Касыйм аны күреп алды. Йөргән кызының колагына, мин хәзер керәм, дип, урыныннан торып, солдат янына килде. Исәнләшкәч, урамга чыктылар.

— Син кая югалдың? — диде дусты, тәмәке кабызып. — Тартасыңмы? Беләм. Тәки өйрәнмәдең.

— Җизнәй алып киткән иде. Менә качып кайттым.

Һәм Габделнур кыскача гына сөйләп-аңлатып бирде, клуб диварына сөяп куелган велосипедка төртеп күрсәтте.

— Күрмәделәрме соң?

— Кем белгән аны?! Мин артка карарга да онытканмын.

— Ну башсыз! — диде Касыйм, шелтәләгәндәй итеп көлеп. — Михаил Девятаев булгансың икән... Элек андый гадәтең юк иде сыман.

— Җәяү кайтып булмый бит инде, — диде солдат, авыз ерып. — Тегеләр юкмы?

— Күренмәделәр.

— Значит, киткәннәр. Ә... кунак кызлары да юкмы?

— Берәү бар. Түлке ул авыл кызы, Алабугадан кайткан.

— Бушмы соң?

Дусты тиз-тиз генә бер-ике суырды да, тәмәке төпчеген җиргә ташлап, туфли табаны белән өстенә басып изде. Аннары клубка кереп китте.

Бераздан ул чыкты. Үзе генә түгел, бер кызны да ияркән иде. Ул аны Габделнурга якынрак китерде.

— Бу абыеңны таныйсыңмы?

— Юк.

— Алайса танышырсыз.

Шулчак клубтан ике егет чыкты.

Касыйм, артына борылып:

— Нәрсә чыктыгыз? — дип җикерде.— Барыгыз, керегез! Әйттем бит!

Болар инде унҗиде-унсигез яшьтә, гәүдәле, мыек чыгып килгән егетләр булсалар да, әле олылар сүзен тыңлаудан «җәяү качкан» түгелләр иде. Аннары, кунак солдатның беләкләр дә таза күренә. Туганнан бирле меха-

низатор булып эшләүче Касыйм абыйларының бала башы хәтле йодрыгы нинди каты икәнен яшьләр ишетеп тә беләләр, үзләре дә «татып» караганнар иде инде. Шуңа күрә, тел озайтып, теш ыржайтып тормыйча, кире кереп киттеләр.

— Каты сөйләшәсең, — диде Габделнур дустына һәм янында басып торган кызга да елмаеп карап куйды.

— Һы, шулай итмәсәң, алар сыртыңа менеп атланырга да күп сорамас. Хәзерге яшьләр без түгел, олы абый дип сәвис саклап тормыйлар. Әле беркөн өчәү чүт тотып дөмбәсләмәделәр. Көчкә качып котылдым.

Ул шаркылдап көлде. Күрәсең, бер-икесен, үзе әйтмешли, тотып «ишкәндер». Юрамалый гына мескенгә сабышадыр. Тел төбеннән, сүзләренә шаян мәгънә салып әйтүеннән шул аңлашыла. Хәер, егетләрнең дәшми генә кереп китүе дә шул хакта сөйли иде.

Клубтан Касыймның үзеннән өч яшькә кечерәк энесе чыкты. Ул Габделнур белән кул биреп исәнләште. Анысының да маймылныкы кебек тез тиңентен төшеп торган озын куллары, кем әйтмешли, ташка үлчим — көрәктәй иде.

— Нәрсә анда теге малайлар тыз-быз килә? — дип сорады ул абыйсыннан.

— Берни дә юк. Бар, кер.

Егет, таза гәүдәсен әле бер, әле икенче якка ташлап, клубка кереп китте.

Касыйм да, дустына күз кысып, баш какты да ишектә юк булды.

Егетләр сөйләшкәндә, кыз читкәрәк китеп баскан иде. Солдат аңа күз ташлады. Ул уртача буйлы, уттай янып торган алсу яңаклы, тулы битле, эскәк-мазар яки лезвие тимәгән киңчә кара кашлы, чем-кара чәчле. Чәчен бер толым итеп үргән. Габделнур анысын кыз баскычтан төшкәндә абайлаган иде. Әллә тагы толымы тез астына ук төшкән.

— Ачуланма инде, кино каратмадык, — диде солдат, аның янына килеп, тулышып торган алсу иреннәреннән күзен алалмыйча.

— Шәһәрдә карарбыз әле, — диде кыз, батыр гына. — Сезне хәзер таныдым. Сез — Габделнур абый?!

— Әйе. Ә син?

— Мин — Зөнәйдә.

Сөйләшкәндә аның энҗедәй тезелгән ап-ак тешләре күренеп китә иде.

— Үпкәләмә инде, кем кызы икәнеңне белмим.

Зөнәйдәгә әти-әнисенең исемнәрен әйтеп бирергә туры килде.

— Апаң белән бергә укыган идек.

— Беләм. Ул кияүдә инде, күптән, ике баласы бар.

— Сәлам әйт.

— Ярар.

— Әгәр бик настаивать итсәң, кино карарбыз. Мәҗбүри булмаса, киттек.

— Кая?

— Кая телисең. Желание дамы — закон для джентельмена, диләр бугай. Урам әйләнербез. Син дә авылны сагынгансыңдыр.

— Әйе. Мин Алабугада педта укыйм. Җәй көне, тик ятканчы дип, үзебезнең районда пионерлагерьда эшлим. Бер генә көнгә сорап кайттым. Әле клубка да чыгасы түгел идем. Аннан кире уйладым. Кино башланыр алдыннан гына килдем.

Габделнур, велосипедны бер кулы белән генә тотып, кызның уң ягыннан атлады. Кыз чая булып чыкты.

— Егетләр кызларның сул ягыннан барырга тиеш.

— Оһо, этикетны беләсең, — диде солдат, киң елмаеп, — педагогическийда укуың күренеп тора. Ә мин уң яктан атларга тиеш. Әйт, ни өчен?

— Белмим, — диде кыз, солдатка эчкерсез мөлаем карашын төбәп.

— Мин — солдат. Димәк, каршыга килгән хәрбиләргә честь биреп китәргә тиеш.

— Сул кул белән ярамыймыни?

— Юк. Һәрнәрсәнең үз тәртибе бар.

Шулай юк-бар сөйләшеп, бер-беренең хәтерен калдырмаска тырышып (бу күбрәк Габделнурга кагыла иде), киң урамнан җай гына атладылар.

Урам инде тынган, кайбер өйләрдә утлар да сүнгән, арыган-талчыккан авыл халкының бер өше ял итәргә йокыга талган. Ләкин күпчелек өйләрнең тәрәзәләрендә әле ут балкый. Ут яктысы урамга да төшә. Хәер, җәйге кич болай да караңгы булмый.

Яшьләр, икесенә дә Алабуга таныш булгач, уртак сүз тиз таптылар. Сөйләшә-сөйләшә Урта урамның югары очына килеп чыктылар.

Авыл артта калды.

Ике якта да иген басулары: кайсы инде урылган-сугылган, кайсына бүген-иртәгә комбайн керәсе. Ә алда, еракта, тау битенә үрмәләгән сыек урман. Тагын да арырак күз ташласаң, күк йөзен һәм сирәк ак болытларны алсу төскә манган ут яктысын күрәсең. Бу — Әлмәт шәһәре өстендәге ялкыннар шәүләсе. Ул ялкыннар — газ факеллары. Алар монда да бар инде хәзер. Нефть вышкалары, аксыл-сары утлары белән балкып, караеп утыралар.

Габделнур:

— Хәзер нефтьчеләрнең җир тишүе ишетелми дә, — диде. — Ә элек бер буровой борауласа да тавышы әллә кайларга тарала иде.

— Нигә алай? — дип сорады кыз.

— Элек аларда көчле дизельләр дөп-дөп эшләп утыралар иде. Хәзер — электр моторлары.

— Ә сез аны каян беләсез?

— Мин армиягә киткәнче подстанциядә дежур тордым. Моторлары өстәлдән дә зуррак...

— Ә безнең авылга кайчан килделәр соң алар? — дип сорады Зөнәйдә.

— Син туганчы, — диде егет, шаяртып. — Илле дүртенче елдамы, илле биштәме. Буровойда өйләнмәгән егетләр дә күп иде. Кайсылары башлы-күзле булып киттеләр, ә берсен начальство бүтән бригадага күчерергә мәҗбүр булды.

— Нигә?

— Ул бер кызны көчләгән. Моны кызның ир туганнары кара канга батырып кыйнадылар. Алар сугышканда, без урамда идек. «Вы за каждый мой волос ответите!» дип янаганы әле дә хәтердә. Үзең беләсең, безнең авыл кешеләре андый килмешәкләрдән генә өркә торганнардан түгел. Так что, башы исән чакта үзенә табан ялтыратырга туры килде... Мастерлары безнең әбиләрдә торды, гаиләсе белән. Мастер янына иптәшләре — бораулаучылар килә, киңәшәләр, бәхәсләшәләр. Миңа кызык, тыңлап утырам... Әнә Ачыдан өстәрәк сыртта бер вышка да ауган иде әле. Без малайлар белән барып карадык. Ә беренче буровой килүе әле дә хәтердә: алты-җиде трактор җир тетрәтеп тегене сөйриләр...

Кыз көлеп җибәрде:

— Ә безнең казлар нефть базына төшкән иде, ул елны мәхрүм калдык.

— Бер елны әти белән машинада барабыз, бүген-иртәгә урасы иген өстеннән буровой вышкасы күчерәләр. Әти түзмәде, туктап, кабинадан чыкты да берәүне сүгә башлады: «Ник әз генә сабыр итмисез? Ипи таптыйсыз?» Теге, флажок тотып тракторлардан читтәрәк баручы, кулларын як-якка җәйде: «Абый, без бәләкәй кешеләр, кушканны үтәүче генә, — ди. — Мин үзем дә авыл малае, минем дә йөрәк сыза». Күрәсең, үзенә дә кызганыч булгандыр ипи әрәм итүе, ашлык таптавы. Ул нишләсен инде.

Буровойлар турында сүз чыккач, кыз:

— Әле шушы арада гына күрше авылның бер егете үлгән, — диде.

— Нишләп?

— Башына нәрсәдер төшкәнме, бәрелгәнме, төгәл әйтә алмыйм. Әлмәткә барып ике генә ай эшләгән булган.

— Производствода андый хәлләр була инде ул.

Габделнур да үзе белгән бер-ике хәвефле очракны сөйләде. Алар урамында туып үскән бер егетнең моннан ничәдер ел элек шахтада басылып үлүен дә әйтте.

Рудник дип йөртелгән урынга хәтле баргач, кыз әкрен генә әйтеп куйды:

— Габделнур абый, борылабызмы?

Егет каршы килмәде.

— Яхшы. Арыдыңмы? Әйдә, велосипедка утыртып алып кайтам.

— Юк, кирәкми.

— Ихтыярың.

— Мин авыр бит, — диде Зөнәйдә, оялып кына.

Егет аның гәүдәсенә карап сокланды.

— Синме?!

Алар борылдылар. Егет, бу такылдавык үзенең күп белүе белән мактана дип уйлатмас өчен, күбрәк Зөнәйдәне тыңларга теләде. Ләкин тормыш тәҗрибәсе һәм дөньяны шактый күрүе, танып белүе аркасында барыбер аның үзенә күбрәк сөйләргә туры килә иде. Мәскәү, Ленинград, Ярославль... Казан турында әйткән дә юк, хәтта кыз үзе бер ел укыган Алабуга каласына кагылышлы вакыйгалар да Зөнәйдә өчен яңалык иде.

— Музейда булдыңмы әле? — дип сорады егет.

— Юк, — диде кыз, бераз кыенсынып. — Оят булса да... Лекциядән кайтабыз да тагын укырга тотынабыз. Бик күп бирәләр... Анда тәртип каты. Стипендиядән дә колак кагасы килми. Төрле кичәләр дә оештырабыз...

Һәм Габделнур Алабуга, бөек рәссам Шишкин хакында, шәһәрдә күренекле шәхес булган атасының кабере хәзер дә исән икәнен, аның шәһәр бакчасында саклануы турында сөйләп бирде.

— Анда кавалерист кыз Надежда Дурова да күмелгән икән.

— Әйе. Ә Шишкинның «Утро в сосновом бору» исемле картинасы бар.

— Аны беләм.

— Шишкин — пейзажлар остасы. Кырларны, иген басуларын, урманнарны гаять оста ясый. Аның картиналарын карагач, гүя каршыңда җанлы урманны күрәсең, нарат урманында була торган тәмле ис сизәсең, агач шавын ишеткәндәй буласың. Икенче бер бөек художник Стасов әйткән: «Урман — Шишкинның патшалыгы һәм монда аның көндәше юк». Ләкин, беләсеңме, ул кеше һәм хайван сурәтләрен ясый белмәгән. Ясавын ясый, тик пейзажлары кебек әйбәт түгел.

— Ә теге картинадагы аюлар?
Габделнур көлеп җибәрде.
— Алар Шишкинныкы түгел. Хәтта томаны да...
— Ничек?
— Әйе, аныкы түгел. Аларны икенче бер художник ясый. Исеме хәтердән чыккан. Туктале, Константин Савицкий бугай ул. Башта, беренче тапкыр, картина күргәзмәгә ике имза белән куела. Аннары алар арасында низаг килеп чыга, судлашып та йөриләр. Ахырда теге художник үзенең имзасын сызып ташлый.

Сүз иярә сүз чыгып, алар сәнгатьтән әдәбиятка, аннары авыл хәлләренә күчеп, сөйләшеп, янә авыл башына кайтып җиттеләр. Габделнур, кызны Урта урамга алып кермичә, сулга таба борылды. Бераз вакыт болыннан, бәрәңге бакчалары буйлап баргач, тау башына килеп чыктылар.

— Без бу төшне Атау дип йөртә идек. Монда элек ике йорт бар иде. Әнә ярның теге ягында, Бабай елгасына таба урам булган. Без бәләкәй чакта анда бер йорт кына калган иде. Аларны Казан кешеләре дип йөрткәннәр.
— Ни өчен?
— Ачлык елны Казан ягыннан килеп утырганнар бугай. Хәзер ул урыннан халык җиңел балчык — туфракса ташый: түшәмгә сала, кар базы өстенә...
— Элек сезнең урам шулай озын булганмыни?
— Әйе. Кумәкләшү чорында безнең авылда ике колхоз хасил була: сезнең урам һәм Ындыр артлары — бер колхоз, ә безнеке — үзенә аерым. Колхозчылар очрашкач, бер-берен үрти торган булганнар:

Анда да бер кабырга,
Монда да бер кабырга;
«Ирек таң»нар үлеп беткән,
Әйдә, кабер казырга.

Сезнекеләр безне, «Ирек таң»нарны, шулай мыскыл иткән, ә безнекеләр — сезне. Хәзерге колхоз сезнеке исемен йөртә.

Шулай сөйләшә-сөйләшә ике як ярны тоташтыручы борынгы таш күпер аша чыктылар. Аксакаллар сөйләвенә караганда, булачак Казан—Чаллы—Бөгелмә юлы өчен унтугызынчы гасыр ахырында ук бу тирәдә бетоннан коеп өч күпер салганнар: берсе — Иске авылда, икенчесе — шушы, өченчесе Баллы дигән урында. Андый таза күперләр күрше авылларда да бар.

Габделнурлар урамына керделәр. Кыз Урта урамда, аның түбән очында яши иде. Шуңа күрә егет велосипедка ымлап әйтте:
— Бу җәфаны өйдә калдырыйк та, сине озатып куярмын.

Зөнәйдә ризалашты. Ләкин Габделнур, өйләре турына җиткәч, кызны да ишегалдына алып керде. Велосипедны агач келәт янына илтеп сөяде дә олы капка янында торган Зөнәйдәне кочагына алды. Кыз дәшмәде. Габделнур, кыюланып, аның кайнар иреннәреннән үбеп алды.
— Габделнур абый, алай итмә инде, — диде кыз, көч-хәл белән башын читкә алып.
— Нигә?
— Оялам.

Кызның сүзләрендә бернинди дә ясалмалык булмыйча, моны ихлас күңелдән әйткәне сизелә иде. Егет, ничек кенә теләсә дә, аны яңадан үпмәде, ләкин шулай да куенынннан чыгармады. Унсигез яшьлек кызның ут кебек янган таза тәнен ул бик озак кочагында тотты. Үзе берөзлексез сөйләнде: армия хәлләре, андагы кызыклы вакыйгалар, спорт ярышлары исенә төште. Кыскасы, теле тегермән тартудан туктамады. Хәтта Зөнәйдәнең апасын да искә алды:
— Синең апаң бик матур җырлый иде.
— Ә ул хәзер дә җырлый, — диде кыз, егетнең аны телгә алуына күңеле булып, апасы өчен горурлык хисләре дә кичереп. — Тавышы көчле түгел, әмма бик моңлы. Ә сез нәфис сүз сөйләргә бик оста булгансыз.
— Кем әйтте?
— Апам. «Томаулы гыйшык»ны.
— Әйе шул. Мин аның кайбер юлларын әле дә хәтерлим. Утыра торгач, ахры, мин дәртләнеп, тотып кызның ике кулыннан, бер кызык сүз әйтеп көлгән идем, чыкты куйды куык борыннан...

Икесе дә көлештеләр. Елмайганда, Зөнәйдәнең бит очлары чокыраеп китте, алсу иреннәре ачылганда, энҗедәй тезелгән ап-ак тешләре күренеп калды.

Аннары егет, верандага таба башын борып:
— Мин әнә шунда гына йоклыйм, — диде. — Керәсеңме?

Кыз куркып калды. Биек маңгаенда бер сызык хасил булды, кара кашлары җыерылды.
— Юк, Габделнур абый! — диде ул, баш селкеп. — Син ни сөйлисең?!
— Нигә, без яшь чагында аулак өйдә гел кызлар белән куна идек.

— Ул бит аулак өйдә. Без дә малайлар белән кунгаладык. Анда берничә пар була, идәнгә тезелешеп, уенкөлке сөйләшеп ятасың төне буе. Аның гаебе дә юк.

— Ә минем белән гаепмени?

— Икәүдән-икәү генәме? Гаеп, билгеле.

— Куркасыңмыни?

— Юк та... Мин сезне әле юньләп белмим дә...

Әмма кызның тавышында курку гына бар, ә катгый рәвештә каршы килү яки баш тарту галәмәте чагылмаган шикелле тоелды Габделнурга. Әлбәттә, япь-яшь кыз, җитмәсә, студентка, шуның өстенә үз авылы кызы... Болар егет хыялының тормышка ашмасын раслый торган сәбәпләр, моңа юл куелмаска тиешлегенә дәлилләр иде. Шулай да борын-борыннан килгән йола — егетләр һәм кызларның аулак өйләрдә куну гадәте, анда чишенмичә генә йоклау, кызларны мәсхәрә итүгә, алдауга юл куелмавы — әлеге дәлилләргә каршы үзенә күрә көчле аргументлар.

Зөнәйдә башсыз кыз түгел иде. Өендә әти-әнисеннән ярыйсы гына әхлак тәрбиясе алган, акны карадан аера, үзенең дә кадерен һәм бәһасен белүче зирәк кыз иде. Аның артыннан үсмерләр дә, егет-җилән дә йөрмәде түгел, хәзер дә кайткан саен озатучы табыла. Ул аларның берсен дә артык якын җибәрми торган иде. Ә бүген әллә нишләде, әдәп кагыйдәләреннән читкә тайпылды шикелле. Киноны ташлап солдат абыйсына ияреп үк китте. Аның кочагында, әйткән бер сүзенә мөкиббән китеп, бер теләгенә дә каршы килергә базмыйча оеп тора. Нинди тылсымлы халәт, беренче күрүдә үк якынайта торган сихри көч бар монда?! Нилектән шулай бу? Аның күңеле ниндидер серле, әйтеп бетергесез шатлыклы яшерен хис кичерә түгелме? Нәрсә бу? Кыз моны, бәлки, тәгаен генә әйтеп тә бирә алмас иде. Габделнур аны белмәсә дә, Зөнәйдә, апасы сөйләве буенча, егетне бик яхшы белә икән. Кыз аның, тәртибе бигүк шәптән булмаса да (хәер, малайларның кайсының гына тәртибе үрнәк була икән?!), мәктәптә яхшы укуын, чаңгыда тиз шууын, әдәби кичәләр оештырып йөрүен белә. Әйе, белә. Хәзер әкренләп апасының сөйләгәннәре исенә төшә. Гармун уйнавы өстенә ул әле, күн итек белән дөп-дөп басып, сәхнәдә ярыйсы гына биегән дә икән, спектакльләр куюда да катнашкан. Ләкин, иң мөһиме, апасы аны бик яраткан. Балалык-үсмерлек самимилеге белән гыйшык тоткан, — тик ул җавапсыз мәхәббәт булган. Габделнур Зөнәйдәнең апасының дус кызын, күршесен, сары чәчле, зәңгәр күзле бер кызны әдәби кичәләрдән соң озаткалаган. Ләкин апасы үзенең ялкынлы, сагышлы мәхәббәте хакында Габделнурга да, дус кызына да сиздермәгән.

Җиденчедә укыганда, районнан фотограф килгәч, апалары класс белән карточкага төшкәннәр. Ләкин апасының альбомында үз классы түгел, ә параллель сыйныф (ул чорда бала-чага күп була бит) укучылары. Зөнәйдәнең соравына апасы, бер кыз белән алмаштык, диде. Чөнки ул яратып йөргән малай күрше класста укыган... Менә хәзер шул унөч-ундүрт яшьлек, апасы хыялындагы буй җитмәслек бер малай, техникум бетереп, Әлмәт якларында эшләп, өч ел армия сафларында хезмәт иткән солдат сыйфатында авылга кунакка кайткан. Бәлки әле, вузга да керер. Һәм Зөнәйдәгә ул беренче күрүдән үк ошады: буй-сыны да, төс-кыяфәте дә, мескенләнмичә, ләкин шул ук вакытта артык һаваланмыйча үз-үзен иркен тотуы да. Аны озаткалаган унҗиде-унсигез яшьлек авыл егетләреннән аермалы буларак, Габделнур яшькә дә олырак; дөньяны да күбрәк күргән; сөйләгән һәр сүзе кыз өчен яңалык; тиктомалга өзлексез кул озайтып, борчып, сагызланып та тормый.

Зөнәйдә апасыннан бик еш ишеткән бер җырны хәтеренә төшерде. Апасы әлеге фотога карап уйланып утыра-утыра да, әйләнә-тирәсендә кешеләр барын да абайламыйча, йөрәк бәгырьләреннән савылып чыккан моңлы тавышы белән җыр суза иде:

Сандугачлар булалмадым,
Талларга куналмадым;
Булды дусларым бәхетле,
Бәхетле булалмадым.

Билгеле, хәзер, күпме сулар акканнан соң, үз гаиләсе барлыкка килгәч, балалары тугач, апасы ул малайны, бәлки, исенә дә алып карамыйдыр — күптән булып узган хәлләр бит инде. Яшәвен дә апасы чит авылда яши.

Ләкин, ни гаҗәп, апасы сөя алмаган, үкенечтә калган яшьлек хыялы булган өчен дә Зөнәйдәгә бу егет ничектер якын иде сыман.

Ахырда, егет баягы тәкъдимен янә бер кабатлап, бик кыстагач, һәм, бүген өйдә барыбер үзе генә кунасы булгач (әти-әнисе апаларына, бәби туена киттеләр), кыз кыенсынып кына:

— Тимисеңме соң? — дип, тәшвишләнеп, озын керфекле күзләрен зур ачып, егеткә текәлеп карады.

Аның кара кашлары өскә чөелде, тулы бит очлары кызарып чыкты, озынча муенына хәтле алсулык йөгерде шикелле.

Шулхәтле ышаныч, аны якын итү, олылау бар иде бу караштa. Ялваруга тартым бу аваздан Габделнур, бизгәк тоткандай, калтыранып куйгандай итте һәм ирексездән баягы уеннан кайтты.

— Алай ышанмагач, озатып куям.

Ләкин үзе кызны назлап кочып алды, аркасыннан сөйде, чәчләрен сыйпады, колагына ягымлы сүзләр пышылдады, кайнар иреннәренә үрелде. Күңеле купшыган кыз да тарсынып кына аны кочаклады: тере җан иясе,

яшь, таза тәнле, сау-сәламәт... Нишләсен инде ул бу мизгелдә?! Алар бик озак бер-беренең назлы, кайнар, мәхәббәт тулы иреннәреннән аерыла алмыйча тордылар. Егет кызны суырып-суырып үпте.

Ниһаять, ул:

— Әйдә керик, курыкма, өйдә этиләр бар бит, — диде һәм кызны, кайнар, йомшак, беленер-беленмәс кенә дерелдәгән кулыннан тотып, болдырга таба алып китте.

Кыз карышмады, бер сүз дә әйтмәде.

Габделнур, кесәсеннән пәке чыгарып, аның очын ишек белән борыс арасына тыкты, келәне өскә күтәрде. Пәкесен җыеп кесәсенә салды. Бавы эчке якта булган тышкы бикләвечне күтәреп, әкрен генә ишекне ачты. Шыпырт кына кызга дәште:

— Кил. Туфлиеңне сал.

Зөнәйдә баскычка менде. Аяк киемен салып кулына тотты. Егет ишекне эчтән бикләде, аяк очларына гына басып, веранда янына килделәр, ишеген ачып, эчкә керделәр. Габделнур итеген салды, кызны ишек катында калдырып, верандадагы караватны тиз генә җайлады — урын җәйде. Зөнәйдә янына килде дә бармагын аның иреннәренә куйды.

— Күлмәгеңне сал.

Веранда тәрәзәсеннән тасраеп ай карап тора иде. Кыз тартынды, ләкин салмыйча да булмый, бөгәрләнеп бетәчәк. Ул эчке күлмәктән генә калды. Әрсез ай эре челтәрле пәрдә эленгән зур тәрәзәләр аша аның зифа буй-сынына күзен чекерәйтеп карап торуында булды. Әллә инде кызның калын, озын чәч толымын тотып карыйсы, шәрә калган йомры иңбашларыннан сыйпыйсы, ефәк эчке күлмәк аша беленеп торган нечкә биленнән кочасы килдеме? Тәгаен генә әйтүе кыен иде. Булгандыр, бу сылуга, алиһәгә тиң бер гүзәлгә ай да сокланмыйча калмагандыр!

Габделнур да чишенде: майка-трусиктан гына калды. Ул куркудан бөрешкән кызны җитәкләп караватка янына алып килде, юрганны күтәрде һәм эчкә, стена ягына ятарга кушты. Кыз артыннан үзе дә аның янына кереп чумды.

Аһ, ул яшьлекнең гамьсез, шул ук вакытта оялчан, бер үк вакытта куркуны да куып җибәрергә сәләтле дәрт ташып торган чоры! Зөнәйдә гәүдәгә Габделнурдан кайтыш иде. Хәзер ул егет кочагында бөтенләй эреп юкка чыккандай булды. Ләкин ул бар! Аның кайнар тәне, тартынып, кыяр-кыймас кына егетне кочкан куллары. Габделнур абыйсының таза муенына килеп бәрелгән кайнар сулышы бар! Аның сүз белән аңлатып-әйтеп бирә алмаган һәм бу минутта сүзләрнең кирәге дә булмаган сөю-сәгадәте бар! Ничек яратмасын ул кочагында эретә торган, бернидән дә курыкмас, теләсә нинди хәлләрдән дә җиңел чыга, югалып калмаучы бу асыл егетне!..

Габделнурның йөрәге дөп-дөп тибүен ишетә кыз. Ләкин бу тибү куркудан түгел, аны сөюдән бит! Ул — батыр йөрәк! Өч ел солдат хезмәте үтәгәндә нинди генә хәлләргә тарымагандыр дисең аны?! Солдат әле берике генә вакыйга сөйләде. Анда да кызның йөрәге жу итеп киткән иде. Каршына өй хәтле танк ажгырып килгәндә дә, кирәк чакта утка кергәндә дә курку белмәс йөрәкле бу солдатка ничек ышанмыйсың?! Һәрхәлдә, әлеге минутларда кызның зиһене ачык, фикерләве анык иде.

Әлбәттә, Габделнур Зөнәйдәгә кагылмаска вәгъдә бирүен, йөгәнсез уйлар белән вәсвәсәләнмәскә тиешлеген, аның үз авыллары кызы, әле саф кыз, беренче кичтә үк буен куя торганнардан түгел икәнен акылы белән аңлый иде. Юрган астында ул аның иреннәреннән аерылмады, тын алыр өчен пауза ясаганда аңа бик күп назлы сүзләр пышылдады, кайнар сулышы белән колак яфракларын көйдерде. Уң кулы кызның баш астында калган иде, ә сулы белән ул аның бәләкәй йон туптай (алар кечкенә чакта күрше кызлары шундый туплар белән уйный иде) тыгыз имиләрен тотты, иркәләде, назлады. Әллә авыртудан, әллә ләззәттән, Зөнәйдә ыңгырашып-ыңгырашып куя иде. Ләкин егетнең яшьлек дәрте шулхәтле көчле, бөтен тәне ут яна, каны котырынып ага; ул, үзе дә сизмәстән, кулын, кызның күкрәгеннән алып, эчке күлмәк өстеннән әкрен генә аска — кендек турына хәтле төшерде. Ул аны аңлы рәвештә, менә шуны эшлим әле, шушы хәрәкәтне ясыйм әле дип уйламады. Чөнки аның зиһене томаланган иде инде. Акылына буйсынмаган ул әрсез кул инде вәсвәсәгә бирелгән һәм аның туктыйсы килми иде. Чынында аны туктатырлык көч тә юк иде бугай. Бәләкәй сәдәф зурлыгындагы уемтыкны узып, ул тагын да түбәнгәрәк төшә башлады.

Шул мәлдә Зөнәйдә айнып киткәндәй булды.

— Габделнур абый, нишлисең?! Тимим, дидең бит! Хәзер кычкырам!

Егетнең вәсвәсәгә бирелгән әрсез кулын туктатырлык көч бар икән, ул яшь кызның әрнеп-өзгәләнеп әйткән, бәгыреннән чыккан сүзләре булды: башта — ялварулы, аннан тәвәккәл-катгый итеп әйтелгән сүзләр.

Һәм егет үзе дә кисәк кенә акылына килде. Беркавым хәрәкәтсез яткач, тыелып торудан башына саварга ургылган кан чыгарга юл эзли башлады һәм... шул минутта ук аның борыныннан кан китте. Ул борынын чак кына кулы белән тотып өлгерде. Торып, галифе кесәсеннән кульяулык алды, борынына каплады. Башын артка ташлап, бераз басып торгач, ул, кульяулыгын учында тоткан хәлдә, караватк янына килде. Утырды.

Кыз куркып калган иде.

— Габделнур абый, мин китим, озат мине, — диде ул, мондый очракта ни кылырга кирәген белми гаҗизләнеп.

Тәҗрибәсезлеге аркасында ул аны юатырга да, сак кына кагылып берәр җылы сүз әйтергә дә кыймады.

— Үтте инде, — диде дә Габделнур, кулъяулыгын идәнгә ташлап, юрган астына кереп ятты һәм көлеп әйтте: — Синең янда йөз яшьлек бабай да тик ятмас иде. Тәнең бик назлы, үзең кайнар...

Кыз тынып калды, дәшмәде.

Бераздан үзалдына уйланып чалкан яткан Зөнәйдәнең күзе өй стенасына, тәрәзә белән почмак арасына аслы-өсле эленгән ике картинага төште. Картиналар гадәттә өй эчендә була, болар нигәдер верандада һәм яки ашык-пошык кына, яки кайдадыр аунап ятмасыннар өчен генә эленгән сыман иде. Чөнки өстәгесе түшәмгә үк терәлеп тора. Бер картинада башларына шлемнар, тимер челтәр күлмәк-көбә кигән, кулларына кылыч, сөңге, җәя тоткан борынгы сугышчылар сурәтләнгән. Уртадагысы сөңгесен муенын борып кырын караучы атының сыртына аркылы салган, чөнки үзе чукмар аскан уң кулын каш өстенә куеп еракка караган. Атлары да өч төрле: сул яктагысы — башын күтәргәне — ак төстә, уртадагысы — кара, ә өченчесе — сакалсыз яшь сугышчы атланганы — җирән кашка. Өчесе дә озын яллы дәү атлар, каеш йөгәннәре, тезгеннәре бизәкле...

Ә икенче картинада ясалма буа яки күл, як-ягында агачлык, бер агач суда ук үсә, артта — ике катлы озын йорт.

— Габделнур абый, болар нинди картиналар? — дип сорады кыз.

— Өстәгесе — «Өч баһадир» — Васнецов картинасы, ә астагысын хәтерләмим кемнеке икәнен.

Картиналар майлы буяу белән киндергә төшерелгән. Ләкин гадәттәгечә бизәкле, сары рамнар белән әйләндереп алынмаганнар иде.

— Аларны кем ясаган соң? Кибеттән алынган дисәң, рамнары юк.

— Вакыт булмады. Рамлый алмадым.

— Бу рәсемнәрне сез ясадыгызмыни?

— Әйе. Техникумда безгә махсус фән керде, клуб бизәргә, лозунглар язарга өйрәндек. Анда безне бик яхшы художник укытты. Ә репродукцияләрне Әлмәттә ясаган идем. Ахырынача җиткереп булмады. Армиягә китәр алдыннан апкайтып калдырдым.

Кызның егеткә булган соклануы тагын да арта төште. Баягы гамәле онытылмаса да, ул аны гафу итте һәм хәзер аңардан курыкмый иде инде. Ул Габделнурга елышыбрак ятты. Егет аны кочагына алды.

...Габделнур ишек шыгырдаганга уянып китте. Ишектә әнисе басып тора иде.

— Улым, син кайттыңмыни?

— Әйе, — диде Габделнур юрган астыннан башын калкытып.

— Улым, әллә борының канадымы?

Һай бу ана кешене! Сизмиме соң, күрмиме соң?! Гөлзифа түти караватка таба килә башлады.

— Юк, юк, әни, канамады, — диде Габделнур тиз-тиз, чөнки кыз да уянган иде инде. — Бар, кер.

Егет юрганны өскәрәк тартты. Зөнәйдә шым булды — караватына сеңде. Гөлзифа түти верандадан чыгып китте. Габделнур үзен битәрләп алды. «Менә сиңа мә, веранда ишеген бикләмәгәнмен бит». Дөрес, ул эчтән бикләнми — келә куелмаган. Ә бит бик тырышса, Габделнур пәке очы белән өйалды ягыннан ишек тактасына аркылы беркетелгән шпингалетны да шудырып куя алган булыр иде. Аны кайтмаган дип уйларлар иде. Гел исенә килмәгән.

Таң беленгәндә, егет белән кыз шыпырт кына киенеп чыгып сыздылар.

Тыкрыкка борылгач, кыз:

— Габделнур абый, үзем генә кайтам, — диде һәм җылы гына саубуллашып китеп барды.

Солдат ишегалдына керде, велосипедны, әтисе күзенә чалынмасын өчен, бакчага кертеп, агач келәт белән кар базы арасындагы ышыкка яшереп куйды. Верандага кереп, әле Зөнәйдәнең кайнар тән җылысын, хуш исен саклаган юрган астына чумды.

Иртән, җизнәсе килгәч (ә ул аның бабасына сиздермичә генә киләсен чамалаган иде), велосипедны машинасына салып җибәрде.

Үзенең дә яшь чагы булган Насиф каенишен орышмады.

— Апаң бик борчылды, төне буе йокламады, — дип кенә әйтте.

**34**

Габделнур Әлмәт якларына юл тотты: бергә эшләгән хезмәттәшләрен, яшәгән урыннарын карап-күреп кайту иде теләге. Карьерда ни хәлләр бар икән? Таш кисүче комбайннарны, аларга хезмәт күрсәтүче машинистларны һәм ярдәмчеләрен күреп-сөйләшеп кайтасы килде. Механика мастерскоенда кулга-кул тотынышып эшләгән электрикларны, слесарьларны, тимерче һәм эретеп ябыштыручыларны да гел искә ала иде ул. Үзешчән сәнгать түгәрәгендә бергә йөргән җырчы-биюче яшьләрне дә сагынды... Ачык булса, клубка да сугылып чыгар...

Әлмәт инде — үзенә башка. Шәһәр матураядыр, үсәдер. Тулай торакка да кереп чыксаң ярар иде. Бәлки, бүлмәдәш егетләрне дә очратыр, әгәр алар анда булса. Эш урынына да кереп чыгар, анысы — һичшиксез. Вокзалдан ерак түгел. Кемнәр үз урынында, кемнәр китте икән? Мастер, участок башлыгы һаман шулар микән?

Олы юлга чыгып Әлмәт ягына баручы бер машинага утыргач, Габделнур әледән-әле шофер белән сүз алышып, гәп корып барса да, аның уйлары гел Әлмәт тирәсендә бөтерелде. Башында һаман истәлекләр булды. Ләкин, бергә эшләгән иптәшләрен, яшәү һәм эш урыннарын күрәсем килә, шул ният белән юлга чыгам, дип, үз-

үзен ничек кенә алдарга тырышмасын, аның баруының төп максаты — Рәйсәнәне күреп кайту иде. Әлбәттә, буласы булган, ул хәзер, олылар әйтмешли, кеше кешесе, әмма ләкин яшь йөрәк һаман аны сагына, аны юксына. Сөйгәненнән килгән соңгы хат, аның кияүгә чыгарга җыенуы Габделнурның яшь йөрәгенә тирән җәрәхәт салды. Солдат инде ахырда кызны онытты да кебек. Ләкин монда кайткач, аның белән ара илле чакрымга хәтле кыскаргач, егет түзә алмады. Болай гына, бернинди максатсыз, нурлы йөзен күреп кенә кайтасы килде. Ул аны әле кемнеңдер хатыны, бәлки, инде берәр нарасыйның әнисе итеп күз алдына китерә алмый. Рәйсәнә — аның өчен военкомат янында читтән генә кул изәп калган зифа буйлы гүзәл кыз. Уйларында ул әле һаман шул фәрештә белән сөйләшә, аны шул рәвешле төшләрендә күреп саташа. Хәлбуки, аек акыл белән уйлаганда, Габделнур моның хыялында үзе тудырган гүзәл зат икәнен яхшы аңлый. Ләкин башка Рәйсәнәне ул белми бит, аны бүтәнчәрәк, икенче кыяфәттә күргәне юк. Ул аның белән ничек очрашасын да, ни-нәрсә турында сөйләшәсен дә белми. Ләкин күрәсе килә. Форсаттан файдаланып каласы, бер генә тапкыр булса да, читтән генә булса да күрәсе килә... Яшерен-батырын түгел, аның Рәйсәнәне бик күрәсе килгән чаклары элек тә еш булды. Кызулык белән кызның фотокарточкасын ертып атуына да үкенде...

Тузан туздырып комбайннар гизгән кырлар-басулар артта калды, һәм Әлмәткә җитәрәк урманнар башланды. Юл каен, усак, карама, өрәңге, юкә агачларыннан гыйбарәт булган урман эченә керде. Ярославль якларындагы нарат һәм чыршы агачларын тәшкил иткән калын кара урманнар белән чагыштырганда бу бик сыек иде. Монда ятып җыярлык кара җиләк һәм гөмбә дә юк, сазлыкларны тутырып мүк җиләге дә үсми, әмма ләкин биредә урыны-урыны белән чикләвек куакларына тап буласың, аны җыя-җыя муеннар авыртып бетә, тук чикләвек белән тулы бөктәр капчыгының бавы иңнәргә батып керә. Юл читендә карлыган һәм кура җиләгенә хәтле очрарга мөмкин. Аланнар тутырып бөрлегән һәм җир җиләге үсә... Әйе, бу урманнар калын түгел. Ләкин бу — Габделнурның туган ягыныкы. Монда күк йөзе дә зәңгәррәк һәм биегрәк, болытлары да аграк һәм йомшаграк — күпереп торалар, җир өстендәге туфрагы да карарак, аста байлыгының иге-чиге юк...

Җитмәсә, бу тирә буровой вышкалары, электр линияләре белән чуарланган. Әнә озын тимер баганалар тезелеп киткән — алар сузган иде бит.

Габделнур бу баганаларга резин беркетелгән «тимер тырнаклар» киеп менә иде. Чөнки гадәти, агач баганага үрмәли торганнары монда кулай түгел. Алар бик җайлы. Көне буе дигәндәй багана башында йөриләр.

Әлмәттән иртәнге якта киләләр, көне буена эшлиләр дә, кич җиткәч, кайтып китәләр. Күңелле иде шау-гөр килеп, уен-көлке сөйләшеп бару-кайтулары, юктан гына да кызык табып бер-берен риясыз котырту һәм алдау-йолдаулары... Берчакны якындагы авылга бардылар. Көянтә-чиләк аскан ике хатын чишмәдән судан кайтып килә иде. Бер егетнең су эчәсе килде бугай.

Ул:

— Татарча су эчәргә сорау ничек була? — диде.

Кемдер аңа өйрәтте, теге тырыша-тырыша кабатлады, башкалар дәшмәде, мыек астыннан гына елмаеп тордылар.

Теге апалар якынлашкач, әлеге урыс егете:

— Апа, терәп-терәп... бир әле, — димәсенме.

Апаларның берсе, иелә төшеп, чиләкләрен җиргә куйды да көянтәсе белән егеткә сырт буйлап...

Әнә теге калкулык (ә алар монда атлаган саен, чөнки бу төбәк гомумән таулар-калкулыклардан гына гыйбарәт) артында подстанция бар. Бервакыт Габделнур, дежурда чакта (ә ул тәүлек буена сузыла иде), сырган телогрейкасын идәнгә җәйде дә, аз гына ял итим әле, дип ятып торды. Чөнки гел утырып тору да ардыра иде. Ятты. Трансформатор гөжләп эшләп утыра. Тиешле урыннарга түбәнәйтеп ток җибәрә. Егетнең башына төрле уйлар килә, планнар коргандай итә, техникумда укыган дусларын искә ала. Курсташларының берсе армиядә инде, корабльдә хезмәт итә, икенчесе — театрда, артист... Ә подстанциядәге приборлар, җиһазлар, гел бертөрле көй-тавыш чыгарып, гөжләвен дәвам итә...

Бермәлне каты итеп (йодрык белән булса кирәк) ишек дөбердәткәнгә Габделнур уянып китте. Телогрейканы бер читкә тотып атты да ишек ачты.

Атылып килеп керде иң данлыклы буровой мастерларның берсе.

— Син нәрсә, фәлән-фәсмәтән, йоклап ятасың?

— Мин йокламадым...

— Күрсәтермен мин сиңа, фәлән-төгән! — дип, ул күзгә чеби хәтле йодрыгын электрик егетнең борын төбенә китереп терәде. — Нишләп, алайса, фидерне тоташтырмыйсың?

— Нәрсә булды?

Мастер, кәгазь күтәрмәстәй сүзләр белән янә сүгенеп:

— Ярты сәгать инде токсыз утырабыз, — диде. — Бар, ялга!

Габделнур, баш сөяге һәм аның астына тагын аркылы-торкылы ике сөяк рәсеме ясалган тимер ишекне ачып, эчкә үтте; фидерләрне тоташтыручы рубильникларны карагач, чыннан да, тегеләр буровоена баручы линиянең сафтан чыгуын белде.

Шулай да мастердан сорыйсы итте:

— Замыкание булдымы әллә?

— Юк. Нагрузка гына, бик каты породага эләктек, — диде мастер, бераз йомшап.

Озын буйлы мастер, иелә төшеп, электрик янына килде. Габделнур рубильникны тоташтыргач кына тынычланды.

— Бу юлы беркемгә дә әйтмим, — диде ул урамга хәтле аны озата чыккан егеткә. — Тагын шундый хәл кабатланса, бер көн дә монда эшли алмассың. Минем һәр минутым кадерле.

...Әйе, бораулаучыларның һәр минуты-сәгате исәптәдер шул. Чөнки аларны, «кара алтын» чыгаручыларны, гелән генә радиодан сөйләп торалар, газеталарда мактап язалар. Габделнур үзе еракта булса да, Кронштадта да, Ярославльдә дә алар хакында укып-ишетеп торды, хәбәрдар булды. Кайчагында ул бу хакта бергә хезмәт иткән дусларына да горурланып әйтә, үзенең дә нефть чыгаруда катнашуын сөйли иде. Ә анда, хәрби хезмәттә, төрле һөнәр ияләре җыелган: шахтерлар, шоферлар, чирәм җирләрне үзләштерүдә катнашкан яки үз авылының басу-кырларын иңләгән тракторчы-комбайнчылар, заводларда эшләгән токарь яки фрезерчылар, төзүчеләр... Һәрберсе үз һөнәрен мактый, горурлык хисләре кичерә. Күрәсең, хәрби хезмәтне алар вакытлы нәрсә, кайткач барыбер шул эшкә керешербез дип уйлый иде булса кирәк...

— Сине кайда калдырыйм? — дип сорады шофер, ир уртасы кеше.

— Иске Әлмәттә, — диде Габделнур һәм кыенсынып кына әйтте: — Күпме бирим?

— Андый сүз әйтәләрмени? Мин синең тиеннәреңә калганмыни? Әй, җегет...

— Гафу ит.

— Мин үзем дә җиде ел солдат шулпасы эчкән кеше. Исән-сау төгәллә хезмәтеңне.

— Рәхмәт.

Хастаханә тирәсендә гадәттә авырулар, аларны күрергә килүчеләр була, ак халатлы табиб һәм шәфкать туташлары яисә санитаркалар кереп-чыгып йөргәли. Монда да шул ук хәл иде.

Габделнур агачлар арасындагы эскәмиядә бертын утыргач, ишектә ак халатлы бер хатын-кыз пәйда булуга, урыныннан торып, аңа таба китте.

— Исәнмесез.

— Исәнме, солдат, — диде утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге юантык гәүдәле хатын, туктап. — Ни йомыш?

— Миңа бер кеше кирәк иде.

— Кем?

— Ул сездә эшли. Рәйсәнә.

— Ә, медсестрамы? — диде хатын һәм, егеткә янә бер карап алгач, йөзе ачылып китте. — Бик күрәсең киләмени?

Ул озын буйлы, ыспай гәүдәле солдаттан күзен алалмыйча мутланып карап тора башлады.

— Әйе, — диде Габделнур, бераз каушап.

— Ул кияүдә бит инде, хирургта.

— Беләм.

Баштарак сәерсенеп, аннан ничектер мыскыллабрак, соңра кызыгып эмсенеп караган хатын ахырда теләктәшлек күрсәткәндәй итте.

— И иркәм, син аны борчып йөрмә инде, ире бик көнчел кеше. Белсә, яхшы түгел.

— Юк, мин...

— Беләм, беләм, сагынгансыңдыр... Ул әле эшкә чыкмады шул, бала белән утыра. Тагын бер айдан чыга бугай... Сәламең булса, үзем тапшырырмын. Хуш, солдат.

Егет читкәрәк авышты, хатын үз юлы белән китеп барды.

Моңаеп утыручы өрәңге, тупыл агачлары арасыннан, тар сукмактан Габделнур урамга чыкты. «Борчып йөрмә инде...» Хатынның сүзләре күңеленә уелып калды. Колагында һаман яңгырый сыман: «Йөрмә инде...» Бик йөрмәс иде дә, күрәсе килә шул. Бәлки, Рәйсәнәнең үзенең дә бер күреп сөйләшәсе киләдер. Ярата иде бит ул Габделнурны. Әгәр килмәсә? Анысы да гаҗәп түгел...

Шулай да солдатны аяклары ул яшәгән йортка таба алып китте. Барды. Читтәрәк туктады. Өйне күрде. Урам якта өч зур тәрәзә. Бүрек кадәрле кып-кызыл яран гөлләр. Ак челтәр-пәрдәләр. Бакчада агачлар алмаларын чак күтәреп утыралар. Капка-коймалар да күчмәгән. Тик кергән-чыккан кеше генә юк. Ишегалдында да тавыш-тын сизелми.

Күпме басып торгандыр, ун минутмы, ярты сәгатьме, егет аны абайламады һәм, теләр-теләмәс кенә атлап, бу күңелгә якын өй тирәсеннән авыр адымнар, караңгы уйлар белән китеп барды...

Күңеленә сеңеп калган бу таныш өйдән шактый ераклашкач кына, Габделнур үз-үзе белән сөйләшкәндәй әйтеп куйды:

— Менә тинтәк... Ә кем сиңа әйтте аны монда яши дип? Ире кайда — Рәйсәнә дә шундадыр.

Әйе, безнең халыкта үз-үзен хөрмәт иткән һәрбер ир-ат кызны өенә алып кайткан. Шәһәр җирендә, үз почмаклары булганчы, кемгәдер өйдәш кергәннәр яисә тулай торактан аерым бүлмә юнәткәннәр. Шевченко урамындагы тулай торакта да берничә гаилә яши иде бит. Бәлки, хирург Иске Әлмәтнекедер... Андый кешегә — яшь белгечкә — фатир бирүләре дә мөмкин. Димәк...

Аннары солдатны шәһәр эче үзенең ыгы-зыгысына бөтереп алды. Эшләгән җиренә барып дус-ишләрен күрде, тулай торакка да сугылды. Кермәде, читтән генә карап узды. Рәйсәнәнең апалары яшәгән йорт тирәсен

дә әйләнде. Ялгызы каңгырып йөрде. Алсу, ак чәчәкле, кызара башлаган җимешле гөлҗимеш агачларына күз салды. Барысы да үз урынында кебек. Тик Рәйсәнә генә юк. Ул инде мәңгегә Габделнурдан аерылган. Аның белән ара өзелгән. Киселгән ипи кебек — кабат ялганмас. Моның шулай икәненә үз-үзеңне янә бер мәртәбә инандырып, күңелеңне алгысытмаска кирәктер.

Габделнур Ленин урамыннан җәяүләп китте. Машина кискән яки юнылган зур-зур «кирпечләр»дән төзелгән өч-дүрт катлы йортлар янында эчке бер дулкынлану, горурлык хисләре кичереп атлады: кайсыларыдыр ул кискән ташлардан төзелүе дә ихтимал бит.

Абыйларында кунак булып, ул иртәгәсен Чупайга юл тотты. Абыйсын хәзер мастер иткәннәр, участогы бүтән тарафта икән, Габделнурга эшкә китүче электриклар белән вахта машинасында бару насыйп булмады.

Ул, абыйсы һәм электриклар утырган машина күздән югалгач, юл чатына чыкты. Беркавым көтте. Менә бер үзбушаткыч машина, солдатны узып, кырыйга чыгып туктады.

— Кая барасың? — дип сорады шофер, кабинадан башын чыгарып.

— Чупайга.

— Әйдә утыр.

Солдат икенче яктан кабина ишеген ачты. Анда бер бабай утыра икән.

— Ярар, мин икенче машина көтәрмен, — диде солдат.

— Утыр, утыр, минем күңел киң, — диде түбәтәйле бабай. — Сыярбыз.

Машина кузгалып китте. Аны-моны сөйләштеләр. Солдатның кая, кемгә баруы белән кызыксындылар. Бабай күрше авылга — Мәмәткә кайта икән.

Бераздан асфальт юл сулга борылды һәм яшел урман эченә кереп китте, аннары янә ачыклыкка чыкты. Әледән-әле биек буровой вышкалары очрый, җир астыннан нефть суыручы, салмак кына әле өскә күтәрелүче, әле түбән төшүче «качалкалар» озатып кала, югары вольтлы электр тапшыру линиясе күзгә чалына.

Юлда машиналар бик күп: аларның кайберләренә озын-озын торбалар төялгән; куәтле насослар һәм зур тимер баклар утыртканнары да узып кына торалар; кузовларын тутырып ак таш төягәннәре дә каршыга килә.

Машина, яхшы ат үргә алдыра дигәндәй, әле ыргылып өскә таба күтәрелә, әле җил белән ярышкандай бөтен көчкә түбән таба оча.

Шофер, бабайдан рөхсәт сорап, папирос кабызды да беркемгә карамыйча гына әйтеп куйды:

— Эх, бай да соң безнең Әлмәт яклары!

Кара түбәтәйле, ак күлмәк өстеннән саргылт пиджак кигән чал мыеклы бабай кояшта чагылган күзләрен йомгалап алды да кан тамырлары бүртеп торган кулы белән алга күрсәтте.

— Әнә күрәсезме теге калкулыкларны? Таулык барда — байлык бар, ди халык. Әйтерсең лә Каф таулары. Бик әйбәт таш чыга аннан хәзер.

Бер йөк машинасын куып узгач, шофер:

— Ә элек монда таш чыгармыйлар идеме? — дип сорады.

— Коралсызның кулы ике, кораллының — унике, дигәннәр борынгылар. Көрәк, кәйлә белән нәрсә майтарасың. Шулай да Чупай тавыннан элек-электән үк таш чыгаралар иде. Аты-туны булмаган ярлы-ябагай иртә таңнан кичке караңгыга хәтле тауда кайнашты. Таш катламының ярыкларына тимер чөйләр сугып китеп төшерәләр, аны авыр чүкечләр белән вак кисәкләргә ваталар, аннан инде балта белән кыралар иде. Бик ераклардан киләләр иде Чупай ташына. Амбарлар, ташпулатлар салдырдылар байлар аннан. Кабер ташлары да юна идек. — Бабай үзенең кытыршы уч төпләренә карап алды. — Менә бу куллар көнозын балта тотып, кичкә кәкре агачтай тураймаслык булып каталар, билләр сызлый иде. Таш кисә торган машина төшкә дә керми иде ул вакытта. Хәзер бит шундый машина бар. Бик әйбәт эшли. Ә аларны кем эшләтә дисең? Күбесе балта белән таш юнган ярлыларның малайлары, оныклары — Чупай, күрше-тирә авыл егетләре. Эш анасы — корал, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул, хәзер эшнең үрчүе дә икенче.

Габделнур эчтән генә көлеп барды, елмаюын тышка чыгармады. Чөнки бабай аның шул машиналарны эшләткән егетләрнең берсе икәнен белми шул. Ул Әлмәттә, машинага утыргач та, солдатның кая баруы, Чупайда кемгә кайтуы белән кызыксынды. Габделнур кемнәргә баруын әйтте. Ләкин бабай аларны белми икән. Ул төп шул авыл кешеләрен, аларның да өлкәннәрен генә хәтерли. Күптәннән Әлмәткә, олы улы янына күчеп киткән. Габделнур да ул хакта сүз озайтып тормаган иде.

Машина карьерга борыла торган юлны узуга, Габделнур төшеп калды. Карьерга җәяүләп кенә китте. Көн иртәдән үк кыздыра, яңгыр булыр, ахры. «Анысы да бик кирәк, — дип уйлады егет бара-барышка. — Таш тузаны бик зәһәр нәрсә, күзләрне ашый».

Әлеге бабайның сүзләрен җөпләп, аны дәвам иткәндәй, солдат мондагы ташларның колхоз-совхозларга ферма ише каралты-куралар, авылларга клуб һәм мәктәпләр салуга китүен, бер өлеше промышленность объектларына җибәрелүен уйлап барды. Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск шәһәрләрендә эре ак таштан салынган йортлар бик күп. Күрше Башкортстан, Куйбышев, Ульяновск кебек чит өлкәләр дә аңа мохтаҗ. Карьер стена ташы гына түгел, әле известь (махсус мичләр бар) һәм бут ташы да бирә.

Солдат карьер кырына килеп басты. Монда җир катламы ун-унбиш метр булыр. Аны олы чүмечле экскаваторлар үткен, озын тешләре белән кимерә, үзбушаткыч җитез машиналар балчыгын читкә ташый, ташбака кебек әкрен кыймылдаучы бульдозерлар калдык-постык балчык кисәкләрен этә-төртә яңа мәйдан чистарталар

— эш урыны әзерлиләр. (Карьерда эшләгән чорда Габделнур да бульдозерчы һөнәренә укыган иде, ләкин эшләргә туры килмәде.)

Әлеге техникалар артында, аста, чакрымнарга сузылган ап-ак таш мәйданы җәелеп ята. Озын рельсларга урнаштырылган дистәләгән комбайннар шакмак-шакмак итеп таш кисә, җитез гәүдәле хатын-кызлар йөгерәатлый алар артыннан таш ала һәм аны өемнәргә тезә. Бер-ике урында машинага төяүчеләр дә күренә.

Комбайн кискән ташерактан шикәр шакмагы кебек кенә күренсә дә, чынында аның буе — кырык, аркылысы-иңе — егерме сантиметр, авырлыгы егерме килога тарта, җитмәсә, аска төшкән саен, чуерташ авырая һәм бу «шикәр шакмагы» ике потлыга әйләнә. Менә шуларны кызлар, яшь киленнәр һәм өлкәнрәк апа-җиңгиләр көнозын бил бөгеп комбайн артыннан алып тора, үзләре биеклеге машина әрҗәсенә төяп җибәрә...

Һәр комбайнга электр линиясе, кабельләр сузылган. Электр баганалары, җир өстендәге шикелле, казып-бораулап утыртылмаган, ә аркылы-торкылы куелган юан тимерләргә беркетелгән.

Комбайннарның бер ише бәләкәйрәк. Алар таш катламын буйлай гына кисә. Аннары бу «таш койманы», теге бабай сөйләгәнчә, тимер чөйләр, ломнар белән аударып, кувалдалар белән ватып, кирәгенчә үлчәмдә юналар. Ул бригадаларда эшләүчеләр иелеп, бөкрәеп сигез сәгать таш юна. Кичкә таба бармаклары кәкрәеп ката...

Зур комбайнны эшләтүче машинист һәм аларның ярдәмчеләре дә тик тормый: рельсларга утыртылган комбайн ташны башта аркылыга кисә, аннары — астан һәм буйлай, бераздан рельсларны күчерәләр, пычкыларны үткенлиләр-кайрыйлар... Пычкыларның теше әби-бабайларныкы сыман коелып кына тора (ләкин фәлән елдан соң түгел, ә бер-ике көндә) һәм аларга победит дигән каты материал ябыштыралар; пычкылар кәкрәя, ут сүнә (предохранитель янмасын өчен электриклар хәтта кадак тыгалар иде), моторлар янып чыга... Аска төшкән саен, таш катылана бара... Кыскасы, монда тик торган, эшсез йөргән бер генә кеше дә юк. Шулай да Габделнур белән бер-ике авыз сүз алышырга һәркем җай тапты. Байтак гомер карап-күрешеп йөрде солдат.

Берникадәр вакыттан соң Габделнур поселокка төшеп китте. Биек тау башыннан карасаң, ул уч төбендә генә сыман җәелеп ята. Бире — үз йортлы кешеләр — авыл, ары — бер һәм ике катлы бараклар, алар уртасында мәдәният йорты, читтәрәк — мәктәп.

Әйләнә-тирәне иген басулары, урман-куаклыклар белән капланган таулар чорнап-уратып алган. Уңда күрше авылның бәләкәй, тәбәнәк өйләре шәйләнә, асфальт юлда машиналар тыз да быз чаба.

Юлда бер абзый очрады. Габделнур аның белән кул биреп исәнләште, хәл-әхвәл сорашты. Аерылгач исенә төште: абзый балта белән таш юнучылар бригадасында эшли иде. Өч малае (Казанда һәм Мәскәүдә укучы студентлар) каникул вакытында әтиләренә булышалар. Акчаны — хезмәт хакын — хуҗалык сумкасына тутырып алып китәләр иде. Чөнки алтмыш беренче елга хәтле (алышынганчы) акча бик эре, күләме зур иде.

Эш димәктән, расценкалар гел үзгәреп тора, әлбәттә, түләү бәясен кисү-кыскарту ягына. Бервакыт ярты меңгә якын эшче контор тирәсендә өч көн утырды. Ул заманда забастовка капиталистик илләрдә генә булганлыктан (безне шуңа ышандырдылар), бу хакта беркайда да сүз чыкмады. Шулай да җаваплы кешеләр — олы түрәләр — Казаннан гына түгел, башкаладан да килгәннәр иде...

Габделнур урам буйлап китте.

Кибет яныннан узганда сулга, алтыпочмаклы зур биек йортка карагач, кылт итеп тагын бер вакыйга исенә төште.

Бу йортта әнисе белән генә Рафинад исемле бер егет яши иде. Армиядә булып кайткан, карьерда — машинист, яше егерме бишне узган.

Беркөнне ул (декабрь ае иде) Габделнур янына килеп гозерен әйтте:

— Башлы-күзле булырга исәп бар бит әле. Кыз алып кайтасы иде.

— Каян? Кичүчаттанмы?

— Әйе. Син бара алсаң шәп булыр иде.

— Була ул. Тик хәзер хромка әйбәт булыр, уйнарга да җиңел. Баян бик нәзберек инструмент, суыкта тиз бозылучан.

— Ярар, анысын үзең кара инде.

— Ә туйда баян булыр.

Кайчан, ничек барасы — анысын соңыннан янә бер очрашып сөйләштеләр. Бер атнадан Рафинад, Габделнур һәм кияү егете, кошевкага утырып, кыз алырга киттеләр. Юка йон перчатка кигән Габделнур юл буе уйнап кайтты. Ә кичен туйда да бөтен авырлык аның җилкәсенә (дөресрәге, бармакларына) төште.

— Син салмаска тырыш инде, — диде Рафинад, аңа ялынып. — Соңыннан иркенләп утырырбыз.

— Ярар, — диде баянчы, кияүнең хәленә кереп, һәм эчү мәсьәләсендә сак кыланды.

Ничек шулай туры килгәндер, хәзер инде Габделнур хәтерләми, ләкин аны алыштырырга бүтән баянчы яки гармунда уйнаучы туйда булмады. Шуңа күрә ул арыганчы уйнады.

Туй бетте, кунаклар таралды.

— Әйдә, иркенләп утыр, — диде кияү Габделнурга һәм тагын бер-ике иң якын туганын өстәл янына дәште. — Рәхмәт сиңа.

Берне чәкештерделәр, икене... Кабат-кабат тостлар да әйтелде...

...Берзаман Габделнур күзен ачты. Саргылт түшәм. Такталары нарат, иңле. Карашы аскарак төште — бәләкәй якка чыга торган ишек. Сулда — мич. Борылып карады — ризык өстенә кәгазь капланган өстәлләр. Урам

як тәрәзәләрдән, гөлләрне аралап, якты төшә. Каерылып аска — идәнгә караса, имәнеп китте: кияү белән кәләш идәндә йоклап яталар. Ә ул... кетердәп торган ак җәймәләр җәелгән, алар йоклыйсы сиртмәле караватта... Баш астында каз мамыгыннан тутырылган йомшак зур мендәр, өстендә юрган, кем әйтмешли, король кебек ята. Ә тегеләр... идәндә.

Габделнур сикереп торды, бөгәрләнгән чалбарын каккалап, ишек катындагы чөйдән пиджагын кулына эләктереп, кече якка чыкты.

Аны кияүнең әнисе шат йөз белән каршылады:

— Тордыңмы, иркәм. Әйдә, чәй эч.

— Юк, апа, рәхмәт, — диде Габделнур, аңа карамыйча гына, чөнки җир тишегенә кереп китәрлек хәлдә иде ул.

— Нишләп алай, чәй дә эчмичә...

Кияүнең әнисе, үпкәләп, һаман сөйләнә-сөйләнә, аны өйалдына хәтле озата чыкты. Габделнур чөйдән бүреген һәм пальтосын эләктереп чыгып китте. Ярый әле урамда кешеләр сирәк иде...

«Апа исән-сау микән? Теге чакны онытмады микән?» — дип көлеп узды Габделнур алар турыннан.

Аннары егет баракларда яшәүче туганнарына таба атлады. Клуб (ул бикле иде) тирәсеннән барганда концерт куеп йөргән чакларын сагынып алды. Каз өмәләре дә бик күңелле була иде. Бер озын барак яныннан узганда янә бер вакыйганы хәтерендә яңартты.

...Габделнур һәм тагын ике егет соң гына клубтан кайталар иде. Баракларның тәрәзәләренә күз салгалап бардылар. Күбесенең уты юк, булса — эчтә ни бары күренми, пәрдә эленгән. Ә берсенең пәрдәсе тәрәзәне яртылаш кына каплаган. Хуҗа — техникум бетереп узган ел карьерга килгән мастер. Ул яз күне өйләнгән иде. Аларга шундук бүлмә бирделәр. Барак беркатлы гына. Менә хәзер, төнката, болар тәрәзә пәрдәсен яртылаш кына тартып куйганнар һәм өйдәге бөтен нәрсә күз алдында.

Габделнурлар туктадылар да карап тора башладылар. Мастер өстәл артында китап укып утыра, эчке күлмәкчән генә калган хатыны урын җәя. Ул зифа буйлы, иңнәренә таралып торган сары чәчле чибәр хатын иде. Ялт — одеал астына керде. Матур аякларын чак күреп өлгерделәр егетләр. Чалкан яткан хатын иренә карап торды да нидер әйтте. Тегесе китаптан күзен алмыйча гына баш какты, ләкин укуын дәвам итте. Хатын тагын дәште. Ире илтифат күрсәтмәгәч, стенага таба борылып ятты.

Егетләрнең берсе:

— Ялындырган була тагы, — диде ачу белән. — Укымаган китабыдыр... Мин булсам, момент... кереп чумар идем.

Габделнур кул изәде.

— Егетләр, әйдә китик, яхшы түгел.

— Тукта инде, — диде бая сүз каткан егет. — Неужели ятмас?

— Юк, ул, яшь кенә булса да, бик үзсүзле,— диде өченче егет. — Әйдә кызык итәбез.

— Ничек? — дип сорады Габделнур.

— Әнә ишек төбендә өр-яңа көрән туфли тора, ул аныкы.

— Шуннан?

— Яшереп куябыз.

— Кая?

— Читкәрәк илтеп куябыз, сарайлар янына. Иртән эзләсен әле, яшь хатынны «тилмерткән» өчен бездән җәза булыр...

**35**

Габделнур, абыйларында бер кич кунып, авылга кайтты.

Үзләрендә урман түгел, утынга кисәрдәй бер агач та булмаган авылның хәле мөшкел: җәй буе утын юнәтү хәстәрен күрергә кирәк. Ярый әле Азнакай, Зәй якларында бик калын булмаса да урманнар бар. Авыл халкы йә үзе барып диләнкедән фәлән фисметр «урман кисеп» алып кайта, йә кемнәрдер китергәнне көтә. Ул якларда урман эшендә күбрәк яшьләр — чая егетләр эшли һәм алар, төн йокламыйча, күрше район авылларына агач сатарга йөриләр.

Кичке якта Габделнур Азнакай ягыннан килгән бер машинаны эләктерде. Дөресрәге, машина урам уртасында туктады да шофер, фуражкасын кыңгыр салган башын кабина тәрәзәсеннән генә чыгарып, аңа дәште:

— Исәнме, солдат.

— Исәнмесез.

— Утын кирәк түгелме?

«Газик» машинасының әллә ни биек булмаган кузовы өстеннән чак кына күренеп торса да, юан гына каен агачы икән. Авыл малае буларак Габделнур каенның кисәргә дә, ярырга да (чи килеш) җиңел икәнен һәм җылысы да әйбәт төшкәнен белә.

— Кыйбатмы? — дип сорады ул, эшлекле кыяфәт белән.

— Шалкан бәясе инде... Хак ярым хак, пот ярым борчак, — диде егет, шаяртып.

Ул, хакын әйткәч, Габделнур әтисен чакырып чыгарды.

— Исәнме, абый, — диде шофер, кабинадан төшеп. — Күргәнем дә бар шикелле. Үзең дә шофер бугай.
— Ие. Каян? Мантымастанмы?
— Юк, Тырыштан.
Галләм абзый, мал таный торган кеше, күп сөйләшеп тормады, машина артына чыгып, арткы бортны ачарга кушты. Шофер белән Габделнур аның әмерен үтәделәр.
Хуҗа бер генә карап алды да:
— Әйдә кер, — дип, шоферга кул селтәде.
Габделнурга әтисенең шул сүзе җитте: ул, ишегалдына кереп, олы капканы ачты.
Тиз генә бушаттылар. Шофер таза, елгыр егет икән — үзе дә кул кушырып утырмады.
— Тагын кирәкме? — дип сорады ул, саубуллашканда.
— Кирәк, — диде Галләм абзый. — Китер. Солдатка эш булыр.
— Кунакка гына кайттымыни? — дип сорады шофер. — Җигеп кал алайса.
Ул егет тәмам иялəште: күз бәйләнгәчме, төнләме — туп-туры килеп тә керә, тиз-тиз генә бушатып, әҗерен алып китеп тә бара.
Бер төнне Габделнур, катырак йоклаган, ахры, машина гөрелтесенә уянып, веранда тәрәзәсеннән караса — утын китергән шофер егет олы капканы ачып маташа.
Габделнур, тиз генә киенеп, ишегалдына чыкты.
— Солдат, озак йоклыйсың, — диде егет, авыз ерып. — Сәлам.
— Сәлам. Бу йөкне монда бушатасы түгел.
— Кая?
— Урта урамда әби берүзе тора. Аңа да кирәк. Шунда чыгарбыз.
Шулай итеп, берочтан аръяк әбисен дә утынга баеттылар.
Габделнурга эш табылды: утын кисү, яру, әрдәнәгә өю. Дөрес, кисүен алар икәү кистеләр: әтисе «Дружба» пычкысы булган Шәйхетдин исемле авыл кешесен дәшкән иде.
Габделнур бу эшне сөенеп башкарды. Чөнки утын, кем әйтмешли, утын инде ул, тирестән сугылган кирпеч түгел. Аһ ул кирпеч сугулары... Исенә төшсә, әле дә тәннәре чымырдап китә, эчләре сыза.
...Кыш буена мал-туар астыннан чыккан тизәк саламы-ние белән ишегалдына тау кадәр булып өелер иде. Яз җиткәч, астыннан сасы су ага башлый, аны, ерганак ергандай итеп, юл ярып, урамга — түбән таба агызасың. Ул шулай көн дә, төн дә әкрен генә ага. Төнлә катырак суытса, туктап тора да тагын ага башлый. Ә инде көннәр нык җылыткач, тирес сугу башлана.
Тирес тавының түбәсенә менеп, сәнәк белән беразын җиргә төшерәсең, читкәрәк түгәрәкләп таратып-өеп куясың. Чиләк белән коедан, арбалы ат юнәтсәң, Сабир бүәсеннән яисә Юкәле бүәсеннән мичкә белән су ташып, аны изә башлыйсың. Малай-шалай, чалбар балакларын сызганып, яланаяк тирес өстенә кереп баса. Беренче тапкыр аяк тыгуы гына чирканыч ул сасы тирескә, аннан иялəнəсең: лачтыр-лочтыр сәгатьләр буена тирес өстендә әйләнчек сарык кебек бөтерелеп йөрисең. Су сибәргә дә онытмаска кирәк. Аягыңа пыяла, кадак, сөяк яки шырпы (агач) кадалса, чыелдап акырып җибәрәсең дә, читкә чыгып, канаган аягыңны кулларың белән тотып, бүкән өстенә яисә келәт ишек төбенә баскычка утырасың. Олыраклар, аягыңа кадалган әйберне алып, чүпрәк белән бәйләгәч, сине җәлләп, бер телем ипи яки катлама сындырып бирә, бераз хәл җыйдырта. Ләкин озак түгел, чөнки эш көтә. Бу Алла каргаган эштән хатын-кыз да читтә калмый (ире яки кул арасына керердәй улы булмаганнарның бөтен авырлык үз җилкәләренә төшә): тула яки йон оекларын салып ташлап, озын ыштан балакларын сызганып, күлмәк итәкләрен ыштан бөрмәсенә кыстырып тирес басалар. (Биатасы, ягъни иренең атасы исән булган киленнәр алай итә алмый; ап-ак тула оек кигән аяклары белән тирес баса, күлмәк итәге дә үз урынында кала бирә.) Аларның да балтырлары суелып, аяк бармаклары канап-сыдырылып бетә, шырпы керә, ләкин балавыз сыгучы юк. Алда эш көтә. Алда — озын, салкын кыш... Шуңа җәйдән үк әзерләнергә кирәк. Кыш куены — суык, ягар нәрсә җиткез генә...
Тирес әзер булып, боламык хәленә кергәч, аны агач калыпларга салып урамга, ишегалдының тынычрак төшенә ташу-тезү башлана. Кул яссуы иңлеге, терсәк буе калыплар төрлечә: берле, икеле, өчле. Кем нindine күтәрә ала һәм күтәрергә тиеш, бу очракта яше, көче-хәле исәпкә алына, калыплар шуңа карап өләшенә. Көнозын, атналар буе шулай тирес басып, кирпеч ташып чиләнәсең... Көтү кайтканда, булачак кадерле ягулыкны мал-туардан саклыйсың, чөнки ул мәхлуклар кирпечләр өстенә басып йөрүне мәгъкуль күрәләр шикелле, кайчак сагалап торып та куып өлгерә алмыйсың.
Кояш карап, җылытып киптергәч, тирес кирпечләрен әйләндерү, тәмамысы кипкәч, аны өю башлана: коймa-киртә буена урамга, ишегалдына, сарай, мунча яннарына...
Кыш көне, арыш саламы белән аралаштырып, кипкән, җиңеләйгән тизәк кирпечләрне мичкә ягалар.
— Әйе, утын утын инде ул, тирес кирпече түгел, — диде Габделнур, киселәсе агачларга карап.
Шуңа күрә солдат, һич авырсынмыйча, сөенә-сөенә, утын әзерләү белән шөгыльләнде. Аның кулдашы Шәйхетдин исемле кеше иде. Ул Габделнурдан алты яшькә олы, Урта урамда яши. Эшкә булган, телгә беткән, үтә дә шаян һәм усал телле, тапкыр сүзле, ябык булса да гайрәтле ул Шәйхетдин. Эшләгәндә дә, тәмәке тартканда да аның теле тик тормый — өзлексез сөйләнә.

— Апаем, син аска бер генә агач куй, шулай җайлырак, — диде ул эш башлаганда, пычкысының бәләкәй багына май белән катыштырган бензин салып, аны кабызыр алдыннан. — Киселгән бүкәнне алып ата торырсың, агачны үзеңә тарта торырсың... Әнә шунда бас. Ярар, бисмилләһи бисмелчек... Башладык. Юан агачны үзең генә күтәрмә, биленңне каймыктырырсың...

Пычкысын кабызып җибәрде дә җан-фәрман әйләнә башлаган үткен чылбырын ап-ак каен агачына китереп салды... «Ә» дигәнче бер бүкән Габделнур кулына килеп тә төште, читкә очып та китте, аннары икенчесе...

Ишегалды төтен белән тулды, пычкы тавышы өзлексез яңгырап торды. Габделнур киселгән бүкәннәрне читкә аткалап, икенче агачны куеп кына өлгерә, Шәйхетдиннең пычкысы аны турарга тотына.

Комган күтәреп өйдән чыккан әбисе, оныгы белән останың тирләп-пешеп эшләвенә күңеле булып, бертын карап торды да үз юлы белән китте.

Ярты сәгатьләр чамасы эшләгәч, оста «Дружба»ны сүндерде.

— Тавышы башка капты, — диде ул һәм, кыска җиңле көрән күлмәгенә, киң балаклы кара чалбарына ябышкан пычкы чүбен сөякчел дәү куллары белән сыпыргалап, киселәсе агач өстенә утырды. — Кая, бер көйрәтеп җибәрик: бир кыягаз, сал тәмәке, шырпың булса — тартабыз.

— Тартмыйм бит, Шәйхетдин абый.

Оста ашыкмыйча гына ботинкаларын да берәм-берәм салып какты.

— Тәки өйрәнә алмадыгыз. Абыең белән дә бәләкәй чакта күпме шаярдык югыйсә: мүк тә тарттык, мамык та. Малай-шалайга — б... ни, боламык ни — төтене генә чыксын. Ул өйрәнмәде. Галләм абзый каты торды шул. Ә мин өйрәндем, авызыңа керим, хәзер бизеп булмый. Әле кәнсәләрдә, төпчек бирәбез, дип җырлаталарые.

— Кемнәр?

— Шунда җыелган ир-ат.

— Бирәләр идеме соң?

— Бирделәр. Эчкә алып тартырга кушаларые. Ютәлли-ютәлли тартадырыек, авызыңа керим. Ярар, үземнекен чыгарырга туры килә инде. Түлке, апаем, кешенеке нишләптер тәмле була.

Ул, шулай шаяртып сөйләнә-сөйләнә, тәмәке көйрәтеп җибәрде.

— Мә, тарт. Тартмыйсыңмыни? Төтен ашап кем рәхәт күргән, иеме. Без өйрәнгән инде. Әле бу арада эш каты булды. Ике-өч кешегә кистем. Безнең күрше Мөлих кайтканые, аңа да кистем. Китте инде.

— Күреп булмады. Ул бездән олырак булса да, бер чорда үстек бит.

— Күрерсең әле, ул кайткалап йөри, җимәгүр бит. Ә хатыны авылда. Менә шул искә төште. Беренче тапкыр киткәндә, атасы әйтә икән моңа: «Улым, берүк андагы хатын-кыздан начар чир эләктереп кайта күрмә, хатыныңа йоктырырсың, аннан — миңа иярер, миннән — әниеңә, анаңнан бөтен авылга таралыр».

Габделнур башта сыгылып төште, аннан чайкала-чайкала көлде. Аңа Шәйхетдин дә кушылды.

— Аны атасы гына өйләндерде, әле өйләнә дә алмас иде. Теге кемне алды бит ул, беләсең инде, ә аның инде яшьтән үк чаты ачылганые. Мөлих моны белә иде. «Әткәй, аның пыяласы юк», — ди икән. Атасы әйтә: «Миңа чыкканда, анаңның пыяласы гына түгел, рамы да калмаган иде инде, торабыз бит әле». Тәки өйләндерде.

— Һаман торалармы?

— Ике балалары бар инде.

— Шәйхетдин абый, сезнең ничә бала?

— Безнең дә икәү. Әле тагын авырлы «сөекле дошманым», канисына җитмәдек.

— Нинди канис?

— Безнең очтагы Галихан абзыйны беләсең бит. Шуның хатыны җиденче баласын тапкан. Минем әткәй сорый икән: «Кордаш, малаеңа кем исемле кушасың?» Теге: «Канис», — дигән. Әткәй: «Андый исем бармыни?» — дип сорый. «Барын-югын белмим, Канис булгач Канис инде, җитте, хәерче арттырып ятып булмас, канса да канис, — дигән Галихан абзый. — Төпчек бала шул булыр». Безнең әле өчәү генә була. «Ат үлсә, ни кала? Тоягы кала. Ир үлсә, ни кала? Баласы кала. Балаң — синең тоягың ул», — дип әйтергә ярата иде минем бабай. Әйе, мужыт тагын таптырырмын... аяк терәр урын булса. Элек заманда безнең авылның бер бае яшь хатынга өйләнгән. Ишеткәнең бармы? Юкмыни?! Өч ел торалар, хатыны балага узмый. Байның яшь, таза хезмәтчесе бар икән. Бераз акылга зәгыйфьрәк егет. Бай моны чакырып алган. «Ни, энем, бүген байбикә апаң белән йокларсың әле. Менә сиңа акча. Кешегә чыгарма», — дигән. Ярар, тугыз айдан бай хатыны игезәк бәби тапкан. Бай абзый батракны чакырып ала. «Рәхмәт, энем, тырышкансың, мә тагын акча, — ди. — Берәү түгел, икәү булган». Егет: «Әй, бай абзый, аяк терәр урын булса, әле өчне дә таптырадырыем», — дигән. Шуның шикелле мин дә... Ие, ни сөйлидерием әле? Ә, әйе, минем хатын таза бит. Узган җәй, ат булмагач, чапкан печәнне апкайтырга «уфалла» белән бардык. Бәләкәй арба, беләсең инде. Кайтканда хатын алдан кайта бау белән муенына тагып, мин арттан этәм сәнәк белән. Тәмәке кабызырга дип бераз бушаттым сәнәкне, карыйм, хатын яхшы тарта. Мин җиңелчә генә этәм — тарта. Шуннан сәнәкне кулга тотып кына тәмәке пыскытып кайттым. Хатын артына да борылып карамыйча сыптыра гына... Кичкә мунча яккан иде хатын. Мин алданрак кердем дә, лач, идәнгә шампунь түктем. Хатын килеп тә керде — гөрс — чалкан авып та төште. Мин, куян аулаган бүре кебек, гөрс, тегенең ике бот арасына... Шулхәтле эшләгәч , «уфалла»ны берүзе тартып кайткач, күңелен дә кү-

рергә кирәк бит... Ну кайтыр алдыннан тагы... Элек су тегермәне барые бит, хәтерлисеңме, бүәгә су җыела да, тулгач, тегермән ташын әйләндерә. Мин дә, хәл җыеп, тагын тегеңә менеп төштем... Ярар, апаем, әнкәй әйтмешли, сүзем догадан булсын, хатынның гайбәтен саттым. Син тагы кешегә сөйли күрмә. Ярар, сөйләсәң сөйләрсең, салган баштан мин аны үзем дә ычкындырам. Кая, Галләм абый ерак куйды микән?

Габделнур, башын юләргә салып:

— Нәрсәне? — дип сорады.

— Бөгештермә, мулла абзый, узган җомгада да биш тиен калды, дип әйткән, ди берәү. Бар, алып чык, Гөлзифа түтигә сиздермә.

— Чәй эчмисеңме соң? — диде Габделнур, үчекләп.

— Чәй белән кытай к... юган...

Габделнур өйдән шешә, стакан, кабымлык алып чыкты. Яртышар стакан салдылар. Пычкыга да май белән буташтырып бензин өстәделәр. «Дружба»ның тавышы, ишегалдын тутырып, урамга ук таралды; әче төтен күзгә керә иде. Ә киселәсе утын күзгә күренеп азая. Бераздан тагын хәл җыярга туктадылар.

— Әйдә, урамга чыгыйк. Әбиең тәмәке тартканны яратмас, — диде Шәйхетдин. — Хәзрәт, тәмәкең юкмы әзрәк? Салып җибәр тизрәк!.. Нишләсе? Кычкырсаң, кеше ишетәсе... Тагын үземнекен чыгарырга туры килә инде.

Койма буендагы бүрәнәгә утыргач кына авызына папирос капты. Бу юлы аны дөнья хәлләре кызыксындыра иде, ахры.

— Солдат, әйт әле, сугыш булыр микән?

— Юктыр.

— Син алай кистереп әйтмә әле. Шәйхетдин абый берни белми дип уйлама, мин дә политиканы әзрәк-бәзрәк чамалыйм. Менә шырпының башында күкерт бар бит, шуның хәтле генә булса да политиканы аңлыйм. Син кайда хезмәт иттем дидең әле?

— Ленинград, Кронштадт, Ярославль...

— Әйе, әйткән идең бит. Булмас, дисеңме?

— Алтмыш икенче-алтмыш өченче елларны Куба тирәсендә хәлләр хәтәр иде. Төнлә по тревоге күтәрәләр, плацка чыгып, машинага менеп утырабыз... Сәгатьләр буе утырабыз автомат кочаклап, йокымсырап, аннан — отбой. Ә быел тынычрак шикелле.

— Бирсен Ходай. Апаем, сугышның үзен күрмәсәк тә, нужасын ярыйсы гына татыдык. Кырык алтынчы елны да әле ачлыктан халык кырылды... Безне битамин коткарды: кукы, кәҗә сакалы, алабута, песи борчагы, кузгалак, юа... Шуларның һәрберсенә такмак та чыгара торганыек. Мужыт син дә беләсеңдер? Юа ашадым, юа ашадым, юанайды т... Ха-ха... Кукы ашадым, кукы ашадым, кукырайды... Ха-ха... Үзебездә булмаса да, радиодан ишетеп, телевизордан күреп торабыз, дөнья барыбер тыныч түгел.

Габделнурның нидер исенә төште.

— Шәйхетдин абый, телевизор дигәннән, син телевизор да төзәтәсең икән, әйеме?

Оста көлеп җибәрде.

— Аны син дә ишеттеңмени? Ул бит беренче телевизорлар чыккан заман. Кеше куян куа дип, син дә куян ку дигәндәй, алып кайттык. Бер атнадан күрсәтми башлады бу. Нишләргә? Исеме күтән булса да, сорты бүтән дигәндәй, үзем тотындым рәтләргә. Алып кайттым магазиннан бер ярты. Кыюлык өчен йөз грамм җиппәрдем. Шешәсен янга куйдым. Телевизорны сүтеп, сулы таска салдым чәсләрен. Тагын җиппәрдем. Лампаларны таста юам, чиста чүпрәк белән корытам. Бермәлне әткәй минем янга, олы якка чыккан. Мин телевизор тартмасына (буш бит инде) башны тыктым да: «Әйбәт күрсәтәме?» — дим. Әткәй, үзең беләсең, уенчак кеше иде, мәрхүм, әнкәйгә кычкыра: «Карчык, чыгып карале, телевизор күрсәтә, кешесе гел безнең Шәйхетдингә охшаган», — ди.

Тагын көлешеп алдылар.

— Ярар, апаем, эшкә тотыныйк, сүз бозау имезер, — диде оста, урыныннан кузгалып. — Тик торганга шайтан сыбызгы тоттырган.

Шулчак урамнан киермә түшле бер хатын узып бара иде.

— Күрше, нишләп йөрисең? — диде Шәйхетдин, күзен елтыратып.

— Корыны бушка әйләндереп.

— Син нишләп исәнләшмисең? Телең артта калдымы әллә? Синең үгезең дә үзеңә охшаган: көтүдә башын аска иеп йөри.

— Бүген күрешкәниек бит инде.

— Ниме, төнлә яныңа керәм, ишегеңне бикләмә.

Хатын туктады. Кунакны танып, килеп күреште.

— Габделнур, үпкәләмә, җаным, танымадым, — диде. — Ә син, Шәйхетдин абый, тол хатынның бот буена тезелгән, дип уйлыйсың, ахры, теләсә кемгә өләшеп йөрергә... Шулайдыр шул, берәү генә булса чәйнәмәсләр ие... Тегесе дә килеп сүз ката, монысы да... Ирле хатыннарның берәү генә...

Шәйхетдин гадәтенчә тел чарларга керешә:

— Күңеленә авыр алма, күрше, мин китап кушканны гына үтәүче: тол хатынның бусагасы алтын булса да сәдака тиеш.

— Син ул чәберчекләнеп беткән киртегеңне сәдака итеп өләшеп йөрмә инде, хатыныңа калмас.

— Сиңа да, аңа да җитәр. Күрмәдеңмени, җиңгәң тагын карбыз йоткан. Китап, әз керсә дә, кызга файда, ди... Ярар, миңа күңелең ятмаса, менә, апаем, солдат бар. Карале бер генә күтәрелеп! Йә, ничек?!

— И бытбылдык, — диде хатын һәм бик зәһәр бер сүз әйтеп китеп барды.

— Теленә тилчә чыккыры... Минекеннән дә әче, — дип калды Шәйхетдин, аннары үзалдына әйтеп куйды: — Жәллим шуны, иртә калды. Ире үлгәнгә ничә ел инде, ә бер гаеп-кыегын ишеткән юк шуның. Балалар дип, күрше авылдан сорап килгән ялгыз адәмгә дә бармады... Ире чирләшкә иде, мәрхүм, ятим үсте, ачлы-туклы, атасы сугыштан кайтмады...

Тагын беркавым гәпләшеп утыргач, оста белән Габделнур ишегалдына үттеләр.

Солдатның җаны түзмәде.

— Шәйхетдин абый, кая, мин дә кисеп карыйм әле.

— Мә, апаем.

Эшкә керештеләр. Бераздан оста пычкыны үз кулына алды. Шулай да егетнең күңелен үстерүне кирәк тапты.

— Болай кулың ятып тора икән, — дип үсендереп җибәрде. — Саллы егет күренәсең. Аңа бит, апаем, дурной көч кенә түгел, хәйлә, җаен белү дә кирәк. Һәрнәрсәнең җае бар, баканың да мае бар, диләрме әле? Җиңелгәрәк туры килә, кулыңа кан төшми. Шуннан инде эшеңне дә җиренә җиткереп эшлисең.

Алар бераз эшләгәч, болдырда Гөлзифа түти күренде, яннарына килде.

— Төш туры җитте, балалар, ашарга керегез, — дип, эшчеләрне өйгә дәште. — Бүген җомга көн, балалар. Җомга турында эшләмәгез, әзрәк ял итеп утырырсыз.

Икесе генә калгач, Шәйхетдин Габделнурга:

— Кергәнче тегене гөплик, — диде. — Аш алдыннан какрас була ул.

— Миңа җитте. Әти...

— Беләм, әйтмә. Галләм абзыйның талканы коры. Салган килеш мин дә аның күзенә чалынмаска тырышам. Шулай да син курыкма, мин барында... әгәр йөгерә алсаң. Ха-ха... Мә, тот... Менә рәхмәт, уважать иттең... Ярар, синең исәнлеккә тотам. Мин шулай кеше әйберсен шул кешенең исәнлеге өчен эчәргә яратам инде... Кеше күңелен күрәм диеп, тугыз балам тугыз төрле булды, дигәнме әле бер хатын... Ну, җибәрдем!

Эчеп куйгач, Шәйхетдин тагын сүзчәнләнеп китте:

— Апаем, какрас, дигәч искә төште. Яшь чакны бер хатынны кымтырыклыйм. Җай чыкты шулай, аулак җирдә. Ярамый, ди бу. Ну ризалаттым барыбер. Менә, мин әйтәм, ярамый, дип әйткән идең, какрас булды бит, дим ахырдан.

Үз сүзеннән үзе көлеп, кулын юды оста. Габделнур, Шәйхетдиннән этлек көтеп, үзен бик сак тотса да, барыбер теге эләктерде. Ак шадра сөлгегә кулларын сөртеп, өйгә керер алдыннан, баскыч төбендә, бик җитди чырай белән:

— Апаем, баядан бирле әйтергә читенсенеп торам, — диде ул.

— Нәрсә, Шәйхетдин абый?

— Минем башка кадак кадалды бугай, авызыңа керим.

— Кайчан?

— Әле генә. Түбәсе беленмиме?

Габделнур, аптырап, Шәйхетдиннең иелгән такыр башын тотып карады.

— Юк, беленми.

— Очы да күренмиме?

— Юк.

— Ә-ә, очы монда икән, апаем, — диде Шәйхетдин һәм кендектән түбән таба күрсәтте. — Эләктеңме? Каптырдыммы? Шулай була ул бик кәпрәйсәң. Мин — солдат, дип бик масайма, апаем.

Ул рәхәтләнеп көлгәч, Габделнурга да аңа кушылудан бүтән чара калмады.

...Өйдән чыккач, киселәсе агачлар өеменә утырып, бераз вакыт аш сеңдерделәр. Шәйхетдин тәмәке кабызды. Габделнур, аңа яннан карап, бу тагын ни алдар икән, дип уйлап көтеп торды. Ләкин оста сүз башламады, тәмләп тәмәке суыруында булды: аның бу шөгылендә дә илтифатсызлык чагылмады. Ул һәрнәрсәдән тәм таба иде, ахрысы: эшеннән дә, сөйләшүеннән дә, тәмәке көйрәтүеннән дә.

Габделнур, тәвәккәлләп, үзе сүз кузгатты:

— Шәйхетдин абый, син күрше авылда да эшләгәнсең икән.

— Эшләдем, апаем, эшләдем, — диде ул, көлеп. — Мин күп җирдә булдым инде. Тугыз өйнең түрен иңләп йөрдем. Бервакыт, мин шулай дигәч, берәү, китсәнә, торган буласың сөйләнеп, синең район үзәгендә дә булганың юк бит, ди. Ачу килде. Мин тегеңә, булмас, элек гел турыдан җәяү йөрдек, район белән авыл арасында мин тәрәт итмәгән урын юк, дип, тегенең чалыш авызын капладым. Әйе шул, апаем, эшләдем күрше авылда. Түлке мине анда озак тотмадылар, авызыңа керим, кыска вакытлы булып чыкты ул.

— Нишләп?

— Кулыңнан килмәсә, телеңнән килсен, диләр бит. Мин дә күп сөйлим. Ни әйтә миңа әнкәй, бөтен сүзеңне сөйләп бетермә кешеләргә, җигүле атлар торсын күңелеңдә, дип, юк бит, түзеп булмый. Минем тел тик тормый бит: яманны чыгарып селки торган гадәтем бар, яхшыны да әйтмичә түзә алмыйм, канишны. Берчак калхуз җыелышы уздыралар болар. Салган баштан шунда күбрәк сөйләп ташладым: «Сездә туры әйткәнне яратмыйлар, мин әйтәм, куштаннар заманы: главбух гармун уйный, персидәтел бии, авыл Советы белән парткум кул чабып тора, завхуз белән зафферма тост әйтә». Халык егыла-егыла көлде. Аңа нәрсә: ихахайлап авыз ерырга гына булсын... Ә персидәтелнең теш шыгырдатканы арттагы рәтләргә үк ишетелде... Китәргә туры килде шул, апаем, авызыңа керим. Түлке бер дә үкенмим. Үзебезнең авылга җитәме соң?! Халкы әйбәт, кызлары чибәр, егетләре батыр... Ата чыпчыкларына хәтле гайрәтле. Кичә аларның түбәдә мәш килгәнен карап тордым...

Шулай уен-көлке, тегене-моны сөйләшеп бертын утыргач, Шәйхетдин:

— Әйдә, апаем, тотыныйк, — диде һәм тәмәкесен сүндерде. — Атаң кайтуга бу өемне бетерик. Тегесенә тотынып булмас, түлке монысын аткарыйк. Әйдә, менә бу юан агачны куйыйк. Син, апаем, беләкне катырыбрак, муенны кызартыбрак күтәр, миңа гына салынма.

— Ну телең, Шәйхетдин абый.

Озак еллар чит-ят арасында йөргән зимагор солдатка күңелле дә, рәхәт тә иде бу тапкыр, туры сүзле, шаян кеше белән агач кисүе. Шуның өстенә ул әле бик фәһемле кеше дә булып чыкты. Соңгы көнне, мәсәлән, аның уй-фикерләрен ишетеп, Габделнур шаккатты.

— Башлы да кешеләр бар инде дөньяда, авызыңа керим, әллә ниләр уйлап чыгаралар, — диде ул, гадәттәгечә ялга туктап, тәмәке пыскытып утырганда. — Ә бит фактически ул аны тормыштан гына ала.

— Ничек?

— Менә вертолетны кара, — дип, ул һавага карады, чөнки бу вакытта яман гүләп авыл өстеннән бер боралак узып бара иде. — Беренче тапкыр ул турыда авыз ачкан кеше аны табигатьтән алган бит. Өрәңге орлыгының җиргә төшкәнен күргәнең бармы?

— Бар.

— Ничек төшә?

— Бөтерелеп.

— Шул шул менә. Теге адәм шуны күргән дә вертолет ясарга керешкән.

— Кызык.

— Ие шул, апаем. Әле менә беркөнне самосвал машинасына карап тордым. Атаңныкына димим, аныкы бортовой. Самосвалның кузовы астан, уртадан күтәрелә. Ә нинди дуракның малларга су сала торган озын тасны уртасыннан күтәргәнен күргәнең бар? Маллар суын эчеп бетермәсә, ничек түгәсең?

— Бер башыннан күтәрәсең дә җиргә агызасың.

— Менә шуңа берсенең дә башы җитми.

— Язып җибәр.

— Кая?

— Заводка.

— Әй, апаем, мин туганнарга хат язарга да иренәм. Булмый ул миннән. Тагы бер мисал. Шәһәргә баргач күрдем: торбалары тыгылса, ванна белән раковина тишегенә бер кара нәрсә куялар да пыш-пыш качать итәләр. Ә син хәтерлисеңме, колакка су керсә нишлидериек?

— Уч төбен колакка куеп бер аягыңда сикерәсең, йә учны төкерекләп колакка куясың да кулыңны тартыптартып аласың.

— Дөрес, — диде оста һәм тәмәкесен сүндерде. — Хәзер, апаем, шул хөрмәткә, учыңны төкереклап, бая келәткә бодай арасына яшереп куйган шешәне дә тартып чыгар әле...

Уен-көлке арасында эшнең авырлыгы сизелмәде дә.

Шул рәвешле алар берничә көн эчендә ике өйгә кышлык утынны турап бетерделәр. Габделнур бүкәннәрне ярып әрдәнәгә өеп тә куйды.

### 36

Габделнур, туган авылына кайткач, кем дә булса берәү аңа Ленинград турында искәртер, ул гына да түгел, тәфсилләп сөйләр, ул кешенең язмышы бу шәһәр белән бәйләнгән булыр, дип башына да китермәде. Чөнки Туган Йорт халкы күбрәк Донбасс яки Кузбасс шахталарында эшләгән һәм хәзер дә күпләр шунда җиде кат җир астында күмер чаба; бик сирәкләр генә Казанга яисә Пермьгә (ул үскән чорда аның исеме Молотов иде) барып чыккан. Әмма зур күпчелеге якын-тирә вак шәһәрләргә — Чаллыга, Бөгелмәгә, Әлмәткә урнашкан, шунда төпләнеп, тамыр җәеп калган. Ә Мәскәү яки Ленинградка бәйле язмышларны аңа очратырга туры килмәде шикелле. Баксаң, андый кешеләр дә бар икән. Әле кемнәр диген! Алар этисенең бертуган сеңлесе һәм аның ире булып чыкты.

Хәер, монда да гаҗәпләнерлек урын юктыр — татар халкы гомер-гомергә йөремсәк, илгизәр халык. Иң авыр, пычрак эшкә дә һич чирканмыйча барып тотынды. Әле Ленинградны, дөресрәге, Петр каласын төзегән-

дә үк безнең бабайлар аның «нигез ташларын салышкан» — имән субайларны сугуда катнашкан. Исаакий соборы нәкъ шундый субайларда ничә еллар инде һич селкенми утыра.

Ә кораблар төзүгә китәсе Кайбыч имәннәрен һәм Мамадыш наратларын исә бәетләргә кереп калган, нәләт камыты кисә кигән, әмма динен сатмаган горур җанлы лашманчы бабаларыбыз хәстәрләгән... Казандагы Адмиралтейтствога беркетелгән бу дәүләт крестьяннары Петр патшаның 1718 елгы указы нигезендә лашманчыурман кисүчегә әйләнгәннәр. Күбесенең гомерләре колач җитмәстәй юан агачлар астында өзелгән...

...Авылга кайтканның икенче көнендә, төшкә кадәр, Габделнур туган-тумачаларын йөреп-әйләнеп чыкты. Аннары аны ашка алдылар. Гомумән, күмәк эш — өмә үткәреп өй күтәрү булсын, бәрәңге утырту булсын, үлем-җитем килсә җыйнаулашып кабер казу һәм мәетне озату — җеназа булсын — болар авыл халкының борын-борыннан килгән изге йолалары. Шулар өстенә кунакка йөрешү, утырмага бару, Корьән укыту, үлгәннәрнең өчесен, җидесен, кырыгын, елын үткәрүләр дә нык саклана иде.

Иң авыр чорларда да халык, актыккы тиенен тотып, соңгы ризыгын авызыннан өзеп булса да табынга куеп, бу йолаларны үти һәм кайчагында мәзәк хәлләр дә булгалый иде. Мәсәлән, сугыштан соң бер тол хатын ашка җыя — ирләр табыны. Юклык ел, өйгә итле шулпа исе бик сирәк чыга, бу хатынның малае ит сорый икән.

— Улым, ир-ат соңгы кисәкне алмый ул, бадьян төбендә калыр, шуны бирермен, — дигән анасы.

Бала бүлмә тактасы ярыгыннан ике күзен дүрт итеп, авыз суларын корытып, ит өмет итеп карап тора. Менә берзаман, өй яңгыратып, урамда олырак малайлардан ишеткән сүзне дә катыштырып, кычкырып җибәрә сабый:

— Калыр, дигәниең, калды, пычагым, фәлән абзый соңгысын алды!

Һәм бала үкереп елый башлый...

Хәзер инде чагыштырмача муллык, солдатны кардәш-ыру ашка дәшкәләде. Кайберләре, ул китәр алдыннан, күчтәнәч тә китерде.

Галләм абзыйның бер сеңлесе Минафа түти дә бер түтәрәм каклаган каз алып килгән иде.

— Апаем, — диде ул Габделнурга, — бала-чага ишле булгач, әллә ни арттырып булмый, әз булса да, күп итеп ал инде.

— Рәхмәт, түти, — диде солдат чын күңелдән һәм кыенсынып кына күчтәнәчне алды.

— Син теге көнне, Ленинградта хезмәт иттем, дигәниең. Юньләп сораштырып та булмады. Хәзер Ленинград ни хәлдә? Бик җимерелгәние бит ул.

— Анда булганың бармыни, түти?

— И апаем, булу гынамы?! Җизнәң белән без шул якларда эшләдек бит.

— Ленинградның үзендәме?

Әллә ишетмәде Габделнурның соравын Минафа түти, әллә ишетеп тә, үз уйларына бирелеп, игътибар итмәде.

— Утыз сигезенче елны җизнәң белән икебез Ленинградка вербоваться ителдек. Яшь чак бит, дөнья күреп, бераз акча эшләп кайту иде ниятебез: башка чыгып, йорт җиткезербез, каралты-кура торгызырбыз, мал-туарлык та булыр дигәниек. Бик мулдан вәгъдә иткәннәрие. Туган илдән бер чыгып киткәч, тиз генә кайтып булмый икән шул... Безне Лигово дигән бер стансага апкиттеләр дә, шунда эшләдек. Сәмәлүтләр төшә торган җир дә ерак түгел ие. Ике ел узып китте. Кырык бернең җәе җитте. Ял көне киттек Ленинградка. Җизнәң, әйдәле, бер карап кайтыйк, көзгә китеп барырбыз, гомерне монда үткәзеп булмас, диде. Йөрибез шәһәр карап. Матур, кояшлы көн. Кердек зоопаркка. Берзаман радио, ә ул багана башында ие, немесләрнең сугыш башлавын әйтте. Китте җылаш-кычкырыш, олылар да җылый, бала-чаганы әйткән дә юк. Зоопаркка күбесе оланнарын ияртеп килгәние. Кем туктап калган, кем йөгерә, берни аңларлык түгел. Без дә кайтып киттек Лиговога. Общежитие шикелле бер йортта торадырыек. Анда кеше юк. Эшли торган җиргә барсак — бөтен халык шунда. Нәчәлство аңлата башлады...

— Бу егерме икенче июнь көнне инде?

— Ие. Шул каһәр төшкән Гитлер аркасында өйгә дә кайтып булмады. Җитмәсә, пленгә эләктек. Без бит тимер юллар римутлап, окоплар казып йөридериек. Нимес килә дә бомбить итә, без таралышып җиргә ятабыз. Эшкә генә керешәбез, тагын бомбежка... Җитмәсә, листовка ташлыйлар, безне котырталар. Берсе, такмак шикеллесе, әле дә истә калган: «Ленинградские дамочки, не копайте ямочки, пройдут наши таночки, пропадут ваши ямочки». Октябрь аенда әсир булдык. Анда, ул мәхшәрдә, сизми дә каласың икән кая барып эләккәненне. Без, берничә хатын-кыз, Эстониягә эләктек, ә җизнәңне Германиягә озатканнар. Кырык дүрттә генә безне азат иттеләр. Үзебез шатланабыз, үзебез җылыйбыз, безнең солдатларны күргәч. Ачлыктан коры сөяккә калганыек инде.

— Аннан кайтып киттегезме?

— Юк, апаем, кайтардылар ди. Эшләдек, тимер юлда. Кырык бишнең маен, Җиңү көнен Красное Село стансасында каршыладык. Син ул төшләрдә булгансыңдыр инде?

— Түти, без бер тирәдәрәк булганбыз икән. Безнең җәйге лагерь Низино дигән авылга якын иде, Петродворец ягында. Ә Лигово ул Пулково янындарак, Ленинградка терәлеп тора.

— Дөрес әйтәсең.

— Мин Ленинградның үзендә дә булдым, Яңа һәм Иске Петергофларны беләм, Петродворецта фонтаннар карап йөрдек. Күбрәк Кронштадтта хезмәт иттем. Фин чигенә дә барып җитә яздым.

— Бер карап кайтасы килә үзебез йөргән җирләрне. Кая хәзер анда барасың инде.

— Түти, ә авылга кайчан кайттыгыз?

— Кырык бишнең ахырында гына. Әткәй — үлгән, күреп тә калалмадым. Сугыш чыкмаса, әле яшәгән дә булырые, әнкәйдән ике генә яшькә олы ие бит ул. Абый ранин булып кайткан, Зыяфетдин энебез хәбәрсез югалган. Ә җизнәң миннән иртәрәк кайткан. Ул, пленнән качып, сугышып йөргән, яраланган, аннары кырык бишнең февралендә җибәргәннәр.

Габделнур көлеп куйды:

— Әйтәм җирле, салып алгач, немесчә сөйләшә, шул пләндә чакта өйрәнгәндер инде.

— Кайткан елларны ару сукалый торганые. Немес теле укытучысы белән гел немесчә сөйләшәләрие. Ул да пләндә булган бит. Җизнәң хәзер онытты инде. Шул сүгенә торган бер-ике сүзе бар, — диде Минафа түти, көлеп, аннары җитди итеп өстәде: — Шул пләндә булуы аркасында күпме кыен ашады ул. Тикшереп, чакыртып, җелегенә үттеләр. Ничек кирәк алай котылды. Авылдан ике-өч кешене утыртып та куйдылар бит. Балаларының, син пленный баласы, дип, күзләрен ачырмадылар. Аларның ни гаебе бар инде? И апаем, ул чакларны Ходай күрсәтмәсен инде кабат.

Габделнур җизнәсен бик якын итә. Чөнки ул җырга һәвәс кеше. Мәҗлесләрдә, каениш, минем көйне уйнале, дип кенә әйтә. Ә аның яратып җырлаганы «Зөләйха» булыр. Тавышы бик моңлы үзенең.

Моңарчы Габделнур әтисе һәм аның энесе генә сугышта булган дип йөри иде. Баксаң, әле бер сеңлесе дә сугыш михнәтен үз башыннан кичергән икән. Кем уйлаган гап-гади авыл хатынын яшь чагында шундый җәбер-җәфа чиккән дип. Сораштырсаң, бәлки, авылда андыйлар тагын да бардыр әле ул. Габделнурның колагына чалынганые: пункттагы медсестра апа да сугышта булган, яраланган, орден-медальләре дә байтак икән.

— Ленинград хәзер бик матур, — диде ул. — Анда, түти, халык та әйбәт.

Солдат, бәләкәй чемоданын ачып, фотоальбом алды. Ленинградта төшкән бер-ике карточкасы бар иде. Бертын шуларны карап утырдылар. Аннары, Минафа түтине олы якта әнисе белән калдырып, Габделнур чыгып китте.

— Әби, кызыңны сагынгансыңдыр, чөкердәшеп утырыгыз, — диде ул, елмаеп.

Кече якта Гөлзифа түти табын әзерләгән икән инде.

— Улым, әбиең белән тутаңа эндәш, — диде ул. — Чәй эчәргә чыксыннар.

Чәйдән соң Габделнур зиратка юл тотты.

Кайтканына ничә көн, әле һаман бара алганы юк иде.

Капка бау белән бәйләп куелганлыктан, Габделнур аны ачып тормады. Авыз эченнән генә бисмилла әйтеп тамак кырды да, кычкырып:

— Исәнмесез, кабер әһелләре, — диде һәм, иелеп, киртә арасыннан эчкә атлады.

Куе булып үскән биек тупыл агачларының юан-юан ботаклары як-якка җәелгән, бер-берсе белән аралашып, укмашып-буталышып беткәннәр. «Нәкъ авыл кешеләре кебек» дип уйлады солдат, аларга карап. «Бер уйласаң, бөтен авыл кан кардәшкә әйләнеп беткән бит инде: кыз биреп, ул өйләндереп туганлашканнар. Бик сирәкләр генә читтән өйләнә. Бүтән җиргә кыз бирә. Авыл халкы үлгәч тә бер тирәгә туплана».

Сирень куаклары буй җитәрлек кенә түгел, иркенләп үскәннәр: ботакларын ботарлаучы-сындыручы юк. Яз көне булса, алар аксыл шәмәхә чәчкәләре белән әллә каян күренеп торырлар иде, хәзер яфраклары да сирәк — корт ашап бетергән. Сиреньгә корт төшүчән.

Каберләр сул якта, ә уңда — бушлык. Түргә барып җитәрәк Габделнур сулга борылды һәм күбесе такта коймалы каберләр яныннан отыры эчкәрәк керде. Кечкенәдән үк килгәләп йөргәнгә, бабасының кайда ятканын чамалый иде. Янында сабый чакта ук үлгән өч баласы, ә бер-ике адым читтәрәк — анасы, ягъни Габделнурның карт әбисе.

— Менә шушы тирәдә иде бугай, — дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә, егет, алан-йолан карангалап, сулга таба баруын дәвам итте.

Ул туктады. Уңга карады, сулга — бабасы каберен күрмәде. Чөнки монда инде чытырманлык — бик куе булып чия агачлары үскән.

— Кайда булыр соң ул? — дип, үз-үзенә сорау бирде Габделнур.

Ләкин җавап таба алмады. Бабасының каберен дә таба алмыйча интекте.

— Тупыл агачлы иде балалары кабере. Бабайныкы — сәрвиле.

Солдат, башын күтәреп, югарыга карады. Бер ботагы сынган иде түгелме? Әйе шул. Исенә төште. Әнә бит, әнә! Ул шатлыктан кычкырып җибәрә язды. Ләкин зиратта сөйләшкәндә дә тавышыңны баса төшеп, шыпырт сөйләшергә кушалар иде.

Ул элеккегә караганда дәү булып, тармакланып үскән тупыл агачын таныды; аңа хәтле куе чытырманлык аша үтәсе бар иде. Чия агачлары шулхәтле куе булып үскән, сафта барган шикелле генә җиңел үтәрмен димә.

— Нишләргә соң? — дип туктап калды солдат пәрәвезле, кычытканлы чытырманлыкка карап.

Ул үзенең үтүкләнгән галифе чалбарына, гәүдәсенә сыланып торган җиз төймәле кителенә күз ташлады. Әгәр шушы килеш барып керсә, киеменең карарлыгы калмаячак иде. Дөрес, каккалап чистартырга мөмкин.

Ләкин... Рота старшинасының, солдат теләсә нинди ситуациядән дә югалтуларсыз чыга белергә, нинди генә хәлгә тарыса да исән-имин котыла алырга тиеш, дигән сүзләре хәтеренә килде. Әлбәттә, Габделнур кабер янына ничек тә керәчәк, ул турыда шикләнмәскә мөмкин. Ләкин... «Монда бит әле баш китәрлек бернәрсә дә юк. Хәзер барып карадым ни, соңрак карадым ни...» Шуннан егетнең башына икенчерәк фикер килде, һәм ул кайту юлына борылды.

Габделнур, верандага кереп, кием алыштырды: утын кискәндә кигән кара төстәге иске эш киемнәрен, ак фуражка киде. Келәттән балта, кул пычкысы һәм чиннек яныннан тимер көрәк алды. Балта йөзенә баш бармагын тидерде — үтә икән. Ярый әле беркөн кул белән әйләндерә торган чарны табып, тагаракка су салып, әтисе белән балталарны үткенләп куйганнар иде.

Егет зиратка китте.

Чия куакларының юанракларын балта белән чабып, нәзекләрен көрәк белән кистереп, бабасының кaберенә бер атлам чамасы киңлектә юл-сукмак ясады.

Бер сәгатьтән артыкка сузылды бу мәшәкать, фуражка астында кыска чәчләре дымланды, маңгаеннан тир бәреп чыкты, күлмәге аркасына ябышты. Ләкин ул бер генә минутка да туктамады, баш күтәрми эшләде. Әйләнә-тирәсен агачлардан әрчеп бетергәч, кабернең өстен дә чистартты. Янәшәдәге каберләрне дә онытмады. Корыган сәрви агачларының бер-икесен пычкы белән кисеп ташлады. Эчтәге агачларда чиясе дә калган, бисмилла әйтеп, бер-ике чия дә капты: мәмрәгән, баллы, авызда эриләр. Бөтен чыбык-чабыкны зиратның тышына ук илтеп ташлады — берничә тапкыр юллады. Кабер ташын абыйсы Чупай карьерында ясатып, үзе үк гарәпчә һәм хәзерге хәрефләр белән язуын да язып куйган иде. Ап-ак таш инде саргайган, бер якка янтая төшкән. Габделнур аны этеп карады. Бирешә икән. Читкәрәк китеп, турылыгын чамалады, якын килеп тагын бераз этте, төбен көрәк сабы белән тыгызлады. Таштагы язуларны, саннарны укыды, бармаклары белән сыпырып, тузанын койды. Беркавым кабер янында уйланып торды. Бер уйласаң, күп тә яшәмәгән бабасы — алтмыш бердә генә булган. Инде вафатына да егерме ел вакыт узган. Нииндирәк булды икән ул? Фотокарточкасы да юк. Әтисе сөйләве буенча, кара сакал-мыеклы. Хәзер, билгеле, ап-ак сакаллы намаз карты булыр иде.

Китәр алдыннан егет:

— Бу такталар озакка чыдамас, пожалуй, тимер рәшәткә кирәк булыр, — дип куйды.

Килгәндә ул күрде: кайберәүләр инде тимер чардуган куя башлаган, искеләрен алыштырганнар да берничә. Авыл тирәсендә нефть чыга башлагач, тимер-томыр, торбаише нәрсәләргә кытлык сизелми иде булса кирәк.

Бер кулына балта, икенчесенә пычкы белән көрәк тотып эшләп арыса да, гәүдәсен төз саклап, зираттан чыгып баручы кунак егетне сирень куакларындагы чыпчыклар чыркылдашып озатып калдылар. Үзләренчә рәхмәт әйтүләре булды микән...

**37**

Вакыты җиткәч, Габделнур Казанга китеп барды. Урак өсте булса да Галләм абзый улын район үзәгенә илтеп куйды. Юл буе сөйләшеп бардылар.

Ата кеше җай белән генә уртанчы малаеның колагына киртләп куюны кирәк санады:

— Улым, юк-барга кызыкма. Эшләп алырга тырыш. Эшләмәсәң, беркем дә китереп бирми. Аз булсын — үзеңнеке булсын. Безнең нәсел гомер-гомергә үз көнен үзе күргән: иген иккән, мал-туар асраган. Бабаңнар берсе дә кешедән ким-хур яшәмәгән... Анаң сүзен онытма...

Баягынак, капка төбендә саубуллашканда, Гөлзифа түти, күз яшьләрен көчкә тыеп, улына әйткән иде:

— Улым, кешеләргә начарлык эшләмә. Рәхмәт белән ләгънәт бер түгел, яхшылык эшләргә тырыш...

Аэропортта Габделнур:

— Әти, рәхмәт, — диде. — Самолетны көтеп торма инде. Эшнең тыгыз вакыты.

— Ярар, улым, исән йөре. Үз җаеңны үзең карарсың инде... Түлке, кая барсаң да, бер кояш — чыга да бата, улым, эшләргә кирәк. Әйбәт йөр. Мәһрүсә апаңнарга сәлам әйт.

Аның күзләре дымланды. Машинасына кереп утыргач, солдат улына янә бер карап алды да әкрен генә кузгалып китеп барды.

...Казанда Габделнурны күңелсез хәбәр көтә иде: югары уку йортының биек, авыр имән ишеген каерып ачарга аның көче җитмәгән, дөресрәге, солдатның борын төбендә генә ишек шапылдап ябылган икән.

Ирек белән коридорда, белдерүләр тактасы янында очраштылар. Ул Габделнурны колач җәеп, киң елмаеп каршылады.

— Сәлам, Старый, — диде ул. — Фамилияң юкмы?

— Күренми.

— Мин дә таба алмадым. Әллә берәрсеннән күзлек сорап торырга микән. Бәлки, бик кечкенә хәрефләр белән язылгандыр.

— Лупа белән карасаң гына инде. Юк әйберне алай да табып булмас. Караңгы бүлмәдә кара песине таба алмаган кебек.

Алар елмаерга һәм шаяртырга тырышып (үз-үзләрен алдап), сер бирмичә кыланып сөйләшсәләр дә, эчләрен корт кимерә — кемгәдер нииндидер үпкә сизелә иде. Күпмедер дәрәҗәдә нәрсәгәдер өмет баглап кайтты-

лар бит, тырышып-тырмашып имтиханнар бирделәр һәм нәтиҗәсе... Ә бит кемнәрдер кергән! Кемнәр икән ул бәхетле студентлар? Кем балалары икән?

— Мать якасына, эткәй әйтмешли, керербез әле, — диде Ирек, кул селтәп. — Авылда ничек? Әти-әниеңнәр исән-саумы?

— Әйбәт.

— Минем әнкәй чирләп тора әле.

— Шулаймыни? Урын өстендә ятамы?

— Больницадан кайткан, йөри инде.

Бераздан кабат уку турында сүз куерттылар.

— Карале, Ирек, безнең егетләр арасыннан керүче бар микән?

— Бер сержант үткән, диделәр.

— Не густо.

Әйе, керү бәхетенә ирешкәннәр башка уку йортларында да бармак белән генә санарлык булып чыккан. Балл җитмичә конкурстан узмаган ике йөзләп солдат-матросны кире үз частьларына озатмадылар (күп булса, ике-өч ай хезмәт итәселәре калган иде, юл чыгымнарын да исәпләгәннәрдер, бәлки, монда кирәкләре чыккандыр), Кремльдәге дивизиягә беркеттеләр. Дивизия кадрированный санала: офицерлар — күп, солдатлар — аз. Алай-болай мобилизация башланса, офицерлар ике дивизиягә җитәрлек, ә солдат-сержантлар запастан чакырыласы икән.

...Өч ел эчендә берничә тапкыр бер урыннан икенче урынга күчеп йөргән Габделнур бу частьтагы тәртипләргә дә тиз ияләште. Сугышчан һәм политик хәзерлектәге уңышлары өчен яки, җай чыгып, берәр төрле батырлык кылган өчен бирелә торган кыска сроклы ун көнлек ялда булып килгән солдатлар, кабат ияләшүе авыр, дип зарланалар иде. Алар сүзендә дә хаклык бар, чөнки гражданкада иркенлек: ата-ана янында яшәү, тәмле ашау, кыз-кыркын озату, дус-ишләр белән күңел ачу, теләгән вакытыңда яту, йокың туйгач кына тору... Шуңа күрә Габделнур бер яки ике ел хезмәт иткәч отпускага кайта алмавына бер дә үкенмәде. Менә хәзер ияләшү — кире эзгә төшү — бераз кыенрак иде. Ә шулай да яшь организм һәрнәрсәгә тиз күнегә, солдат юкбарга уфтанмый.

Монда аларның хезмәтен әллә ни авыр, катлаулы дип тә булмый иде.

...Иртән сәгать алтыда старшина казарманы яңгыратып кычкырып җибәрде:

— Рота, подъем!

Биек түшәмле, берничә зур тәрәзәле, тар тактадан җәелеп сарыга буялган идәнле озын казармада, концерт залларындагы шикелле, акустика шәп — тавыш бик каты яңгырый, икенче тапкыр кабатлау кирәк түгел: яшьләр атылып сикереп тора, икенче ел хезмәт итүчеләр җитез, ә картлачлар салмак кына караваттан кузгала. Ләкин шулай булса да соңгы елын тутыручылар, яшьләргә хәтле киенеп, яланбаш, каешсыз гына сафка килеп баса. Чөнки өч ел буена өйрәнелгән гадәт, тәртип үзенекен итә.

Озын буйлы, таза гәүдәле, кызгылт тукмак борынлы старшина барысын да үзенең үткер күзләре белән күзәтеп тора, ашыктыра:

— Живо! Живо, хлопцы!

Солдат-матрослар, коридор тутырып, бөтен бинаны дер селкетеп, яңгыратып, тимер баскычлардан аска, плацка төшеп киттеләр. Иркен ишегалдының аркылысын-буен берничә мәртәбә дагалы итекләре, ботинкалары белән үлчәгәч, туктап физзарядка ясадылар. Аннары, казармага кереп, аяк киемнәрен чистарттылар, юынып-кырынып алдылар. Киенеп, ашханәгә төшеп киттеләр. Аның соңында берәүләргә занятие, кемнәргәдер наряд башланды.

— Гаделҗанов, Макаров, Иванов, байрак янында постта торырга! — диде старшина. — Киемнәрегезне яхшылап карагыз, тәртипкә китерегез, һәрнәрсә ялтырап торсын.

Габделнур каеш аелын, китель төймәләрен, фуражкадагы йолдызны чистартты. Бары да тәртиптә икәнен белсә дә, янә бер мәртәбә күздән кичереп, кул тидереп алды, чөнки байрак янында сакта тору солдаттан үзенә күрә аерым җаваплылык таләп итә.

...Вакыт-вакыт әле бер аягын, әле икенчесен йомшартып (тезен чак кына бөгеп), ефрейтор Гаделҗанов дивизия байрагы янында тора. Ука чуклы, озын саплы кызыл байрак пыяла шкаф эчендә, йозакланган, мөһерләнгән. Ул инде озак елларга монда төпләнеп калган. Урыны да чиста. Ләкин бу — дәһшәтле сугыш елларында Казаннан Берлингача күп чакрымнар, тузанлы юллар үткән, шушы төбәктән сугышка алынып һәм дивизиядә бергә тупланган ир-егетләрнең аяусыз батырлыгын күргән байрак. Аңа тап төшермәс өчен, меңләгән каһарманнар арыслandaй рәхимсез сугышканнар, яу кырында ятып калганнар. Якташларының, шул җөмләдән ике әбисенең хәбәрсез югалган улларының да хәтере сеңгән байрак бу. Габделнур моны бик яхшы аңлый. Кычкырып әйтмәсәләр дә, байрак янында торганда бу халәтне, шуңа охшаш уй-хисләрне бик күп солдатлар кичерәдер. Часть байрагы ул — изге! Әгәр байрак югала икән, часть таркатыла. Һәр солдат беренче көннән үк моны яхшы белә. Ләкин гелән генә ул турыда уйламый солдат, аның башына төрле уйлар килә: әти-әнисе, дуслары, кызлар, туган җире...

Габделнурны хәзер күбрәк үзенең киләчәк тормышы борчый иде. Кайда төпләнергә? Чөнки бу мәсьәләне ул үзе хәл итәргә тиеш. Әтисе аның ихтыярына куйды. Абыйсы да үз фикерен көчләп такмады. Бер баш — ях-

шы, ике баш — тагын да шәбрәк, дисәләр дә, асылда (күпчелек очракта), кеше үз язмышын үзе хәл итә. Әлбәттә, кайбер гадәттән тыш хәлләрне исәпләмәгәндә, кемнәрдер мәҗбүри килеп тыкшынмаса...

Әлмәт ягы да тарта. Түбән Камада зур төзелеш башланган. Икесе дә өйгә якын. Ләкин мавыктыргыч Казан да бар, аның да үзенә иң нык җәлеп иткәне — уку йортлары. Уку. Ул юкка гына элекке хезмәт урынында ярты ел әзерлек курсларына йөрмәде бит. Юкка гына һәр яшь кеше кызыгырлык тәкъдимнәрдән баш тартмады. Ә тәкъдимнәр булды.

Кыш көне һәм язга чыккач, алар частена вербовщиклар сукмак салды. Берсе Мәскәүдән булса, икенчесе — Ленинградтан, калганнары Ярославль, Горький ише кечерәк шәһәрләрдән...

Штабның бер бүлмәсенә быел хезмәтен бетерәсе солдат-матросларны җыялар да сөйли-кызыктыра башлыйлар:

— Безнең завод фәлән төрле әйбер чыгара... Безгә токарьлар, фрезерчылар һәм башка һөнәр ияләре кирәк. Әгәр һөнәрегез булмаса, без сезне ике-өч айда өйрәтәбез; уртача эш хакы түлибез, ул фәлән сум тәшкил итә. Укырга теләсәгез, безнең заводның үзендә үк фәлән институтның кечке филиалы эшли. Бик әйбәт тулай торагыбыз бар. Йөргән кызларыгызны да чакырта аласыз, аларга да эш табарбыз. Яңа өйләнешкәннәргә аерым бүлмә бирәбез, фатир чиратына куябыз. Балалар бакчасы, ял базасы, санаторий һәм спорт комплексы...

Кыскасы, риза гына бул: беренче көннән үк оҗмахта яшисең. Әле подъемный дип аталган акча да бирeләчәк икән. Кайберәүләр, бигрәк тә авылдан хезмәткә алынганнар, ризалашып килешүгә кул куйсалар да, Габделнурның кайдадыр еракта яшисе килмәде.

Мәскәүнең бер хәрби заводыннан килгәне ефрейтор Гаделҗановка чат ябышты: командир аркылы яңадан чакыртып, аерым сөйләште.

— Гафу итегез, сезне тагын борчыйм...

Әйе, ул аңа, гади солдатка, берүзе генә булса да, «сез» дип эндәште. Күрәсең, ул алдан ук үзе сөйләшәсе солдатларның биографияләре белән ныклап танышкан, ничек хезмәт итүләре белән кызыксынган, кыскасы, үз эшен җиренә җиткереп башкарырга күнеккән кеше иде. Бәлки, отставкадагы яки запастагы офицер булгандыр. Һәрхәлдә, чигәләре агарган коңгырт чәчле, уртача буйлы ул кешенең үз-үзен тотышы бик итагатьле иде.

— Сез — коммунист. Ә безгә сездәй егетләр бик кирәк. Нинди продукция чыгаруыбызны әйтеп бетерә алмыйм, номерлы завод, ләкин бездә эшләүче һәркем үз хезмәтенең җимеше белән горурлана... Бездә үсү мөмкинлеге чиксез. Мин, шәхсән, үзем сезнең перспективагызны күзәтеп торачакмын. Бәлки, риза булырсыз?

«Коммунист икәнемә басым ясагач, мөгаен, бик яшерен заводтыр» дип уйлады Габделнур. Ул бер мәлгә югалып калды. Вәсвәсәгә бирелеп куюы да ихтимал иде. Ләкин барыбер кистереп әйтмәде.

— Уйлап карармын.

Икенче көнне, частьтан китәр алдыннан, завод вәкиле үзе аның хезмәт урынына килде.

— Ничек, ефрейтор Гаделҗанов, уйладыңмы? — дип, тәкъдиме көчендә икәнен искәртте.

Бу юлы, үз итеп, «син»гә күчкән иде.

— Бармамдыр, ахры, — диде Габделнур.

Алар, ике-өч пожарный, ачып куелган зур капка каршындагы кызыл машинаны сөртеп, янгын сүндерү кирәк-яракларын, инструментларны рәткә китереп мәш киләләр иде.

Вербовщик коңгырт күзләре белән аңа карады. Муенын кысып торган галстугын сул кулы белән рәтләп, саф татар телендә:

— Ярар алайса, сау бул, солдат, намуслы хезмәт ит, тик монда калма, туган ягыңа кайт, юкса гомерең буе тилмерерсең, — дип, кул биреп саубуллашты да штаб машинасына — «уазик»ка утырып китеп барды.

Габделнур, тораташ булып каткандай, нишләргә белмичә торды. Хәтта, сау булыгыз, дип тә әйтә алмады. Чөнки кисәк кенә ана телендә әйтелгән сүз башта аңына барып җитмәде, ә аннары соң иде инде... Кем булды икән ул? Нигә башта ук үзебезчә сөйләшмәде? Ни өчен үзенең татар икәнен сиздермәде? Болар ефрейтор Гаделҗанов өчен табышмак булып калды. Моның сәбәбен, бәлки, ул озак еллар үткәч кенә аңлар. Ә хәзергә ул моңа әзер түгел иде әле.

Ә баш тартуына килгәндә, нәрсә моңа сәбәп булгандыр, егет өздереп кенә әйтә дә алмас иде. Ундүрт яшеннән авылдан чыгып китеп, һаман читтә яшәүме, туган җир дигән аңлашылмый торган, ләкин синең бөтен барлыгыңны биләп алган төшенчәме, ни генә булса да, аның читтә каласы килмәде. Хәтта шул ук хәрби шәһәрчектә һәм поселокта урнашып калучылар да булгалаган: кайсы йөргән кызына өйләнеп, кайсы балалы хатынга йортка кереп, кемдер хәрби хезмәткәр яки гади эшче булып...

Габделнур бервакыт ике солдат дусты белән поселокның аргы башына — үз йортлары белән торучылар өлешенә — кибеткә чапты. Чөнки әгәр бераз соңга калсаң, машинасы белән батальон командиры килеп җитә. Кибет каршында яшел «уазик» торса, бетте, якын барам димә. Шуңа күрә, бераз рәтең булса, часть проходноеннан чыгу белән туп-туры поселокның азык-төлек кибетенә элдертәсең. Бер «акбаш»ны аласың да, кибет артына чыгып, өчкә бүлеп, бушатып та куясың. Кабымлык урынына шинель яки китель җиңен иснисең.

Әмма бу юлы өлгерә алмый калдылар. Алар эчтә чагында комбат килеп баскан икән. Моны солдатларга йомыш белән кибеткә кергән бер ир-ат әйтте:

— Сак булыгыз, комбат анда.

Янгынчылар ул батальонга карамаса да, офицер күзенә чалынмавың хәерле. Солдатлар инде чыгарга әзерләнгәннәр, шешә Габделнур кесәсендә иде. Кире биреп булмый бит инде шулхәтле «кадерле ризык»ны.

Ул тәвәккәлләргә булды.

— Ә сез ерак торасызмы?

— Шушы тирәдә, — диде ир кеше.

— Ярдәм ит, зинһар.

— Аңладым. Минем арттан килерсез.

Ул йортының кай тирәдә икәнен әйтте. Габделнур шешәне, кесәсеннән сак кына чыгарып, гәүдәсе белән каплабрак (сакланганны саклармын, дигән бит Ходай да, комбат керүе ихтимал), әлеге ир-атка бирде.

Ул:

— Ярар, магазинга соңрак килермен, — диде дә чыгып китте.

Берничә минуттан, берни булмагандай, өч дус та урамга чыкты. Комбатны да, тегене дә күздән югалтмыйча китеп бардылар. Күрәсең, шик-шөбһә уятмадылар, офицер аларны тоткарламады, кабинада утырып калды.

Әйләнечтән юл туры дигәндәй, урап-урап, капка төбендә басып торган ир-ат янына килделәр. Ул аларны ишегалдына дәште, үзе өйгә кереп китте.

Габделнур ихатага күз салды. Авылча, ләкин аның туган ягындагылардан бераз үзгәрәк итеп салынган зур, биек нарат йорт, кыегында балкон шикелле нәрсәсе дә бар; каралты-кура таза, тәртиптә; яшелчә бакчасында озын түтәлләр түгәрәкләп-дугайлатып, күтәртеп куелган. Ишегалдында ике дуңгыз баласы чабышып йөри, сары чәчле дүрт-биш яшьлек малай эт оясы янында йонлач көчек белән мәш килә.

Хуҗа кеше өеннән стакан, ризык алып чыкты. Улына зур гына тозлы кыяр бирде. Тегесе кабат эт баласы янына китте.

Башта хуҗаны сыйладылар, аннары — үзләре. Сүз иярә сүз чыкты.

— Мин дә монда хезмәт иттем, собаковод идем, биш ел элек шушында торып калдым, — диде коңгырт-кара чәчле, киңчә каратут йөзле ир. — Хезмәтне бетергәч, илгә кайтасы итмәдем. Кыз да ошады. Менә шулай яшәп ятам. Ике бала бар. Тормыш ярыйсы, шофер булып эшлим. Хатыным, Маруся, акыллы хатын булып чыкты, зарланмыйм.

— Анасы усалмы? — дип сорады егетләрнең берсе.

Урыс халкында ни өчендер кияү хатынының анасын — тещасын — бик яратып бетерми сыман. Бу хакта йөремсәк мәзәкләр дә күп. Солдат шуны истә тотыбрак әйтте булса кирәк.

— Юк, түзәрлек, — диде хуҗа, елмаеп. — Ләкин туган як сагындыра башлады. Мин үзем Оренбург өлкәсеннән.

— Татар түгелсең бит? — дип сорады Габделнур. — Охшагансың.

— Әйе. Әллә син дә татармы?

— Әйе. Татарстаннан.

Алар кул кысышып, көлешеп алдылар. Уртак сүз тиз табылды: Габделнур Кронштадтта бергә карантин узган Шәрипне, аның кайсы районнан икәнен дә, авыл исемен дә хәтерли иде әле. Әкренләп сөйләшү табигать, тормыш-көнкүреш шартлары тирәсенә күчте.

— Безнең яклар әллә ни бай як түгел, урман да, мондагы шикелле, өскә авып тормый. Булганы да юка.

— Әйе, мондагы урманнар калын.

— Кара җиләк, мүк җиләге күп. Гөмбә таный башладым. Шулай да сагындыра. Баштарак алай түгел иде... Сөйләшер кеше дә юк...

...Байрак янында сакта торган ефрейтор Гаделҗанов үрә катты, чөнки уң яктан, коридордан, алтын погонлы китель, кызыл лампаслы чалбар кигән озын гәүдәле генерал кереп килә иде. Байракка честь биреп киткән генерал-майорны һәм аның юлдашларын — ике полковник белән бер майорны — Габделнур күзе белән генә озатып калды. Ыспай киемле, төз гәүдәле часовойның кыяфәте барысына да ошаган булса кирәк, бераздан штабтан дежур офицер чыгып, бу якка күз ташлады. Ул бер сүз дә әйтмәде, кире кереп китте. Ләкин аның йөзендә кырыслык, канәгатьсезлек чагылмады.

...Менә шулай итеп, Оренбург егете белән очрашу ничектер күңеленә уелып калган икән. Казан Габделнурны үзенә тарткан иде. Шәһәр генә түгел, кендек тә тарткандыр бу изге, борынгы җиргә солдатны. Хәер, туган җир һәркемне шулай үзенә чакырып тора инде ул. Күп кешене чит җирләрдәге мал, байлык та кызыктырмый. Атаклы көрәшче Поддубный турында кайдадыр укыганы бар Габделнурның. Ул илле яшьтән соң да Америкага барып көрәшеп йөри, ярты миллион доллар акча эшли. Ләкин капиталистлар килешүне шулай төзиләр ки, әгәр ул бу илнең гражданины булмаса (ә аны калдырырга бик телиләр), тир түгеп эшләгән акчасын ала алмаячак. Һәм Иван Поддубный, бөтенесенә төкереп, бер тиенсез үз ватанына кайтып китә.

...Икенче көнне Болак буендагы мунчага барып юындылар, эчке киемнәрен, ә казармага кайткач, урын-җир алыштырдылар. Төштән соң шәһәр стадионында футбол уены бара иде, монда хезмәт иткән бер солдат каяндыр юнәткән бинокль аша, тәрәзәдән, алмаш-тилмәш басып, чиратлашып футбол карадылар.

Стадионның яшел чирәмле кыры да, анда бер туп артыннан йөгерешкән егерме уенчы да, корбанына сикерергә әзер торган леопард кебек җитез, сыгылмалы гәүдәле, кулларына күн перчатка кигән капкачылар да, эскәмияләрдә очынып-очынып утырган җанатарлар да — барысы да моннан аермачык күренә икән.

Бераз карап торгач, Габделнур бинокльне янәшәсендә түземсезлек белән чират көтүче солдатка бирде.

Сул кул яктагы тимер юл вокзалы тирәләрен, уң яктагы Казансу аша салынган күперне һәм аның артындагы эреле-ваклы йортларны ул гади күз белән генә күзәтте. Шәһәрдә яшеллек күп булуына игътибар итте. Ә каршыда, еракта-еракта, киң Идел җәйрәп ята, аның уң яры Ослан тау тезмәләренә терәлеп ага. Янәшәдә, Кремль диварлары артында, йортлар тезелешкән, фабрика корпуслары моңсуланып утыра.

Шимбә көн, увольнениегә чыккач, Ирек белән Кремльне сәйран кылып йөрделәр. Чөнки әле аны карарга вакыт тимәгән иде.

КППдан чыккач туктап калдылар. Каршыда үтә озын ике катлы бина. Уңда ап-ак төстәге, түгәрәк сәгатьле Спас башнясы очындагы йолдызын ялтыратып утыра, аскы өлешендәге капкасыннан кешеләр, машиналар үтеп-сүтеп йөри.

— Кая барабыз? — дип сорады Габделнур.

— Әйдә, сулга, — диде Ирек.

Ике ягында да тәбәнәк кенә яшел чыршылар үсеп утырган юлдан киттеләр. Сул якта казарманың өч катлы озын бинасы сузылып бара, ә каршыда — чиркәү калдыгы, аның артында Сөембикә манарасының яртысы (өске өлеше) күренә.

— Бәттәч, бу ава бит, — диде Ирек, аңа таба якынлашкач.

— Дәүләте җимерелгәч, башнясы гына исән калмас инде, — дип көлемсерәде Габделнур. — Әле ничек тора диген. Озакламый бу Пиза башнясына әйләнәчәк.

— Менә туристларга тагын бер экспонат.

Чыннан да, Сөембикә манарасы ике катлы, сыек яшел төскә буялган, тәрәзәләре гөмбәзле матур бинага таба авыш иде.

Зур, бизәкле түбәле капкадан эчкә үттеләр. Кызыл кирпечтән салынган сигез ярусլы борынгы манара башына фуражка козырекларын куллары белән тотыбрак карадылар.

— Кемнәр генә килеп, кемнәр генә китмәгән бу дөньядан, — дип авыр сулап куйды Габделнур.

Аннары ике солдат сөйләшә-сөйләшә әкрен генә кирегә таба атладылар. Ләкин кызыксыну көчле булганлыктан, чиркәү артындагы өч катлы бинага таба киттеләр.

Ирек үзенең хәрби хезмәттәге беренче көннәре турында сөйләде.

— Минем бит хезмәтнең беренче көннәре шушында башланды, дивизиядә, Кремльдә. Бер-ике көн тоттылар да алып киттеләр лагерьга. Җәяү барабыз. Ашыйсы килә. Урамда бер әби булка тотып бара иде, чүт кенә сорап алмадым. Стройдан чыгарга ярамый, бик строго иде. Лагерьга сәгать дүрткә генә барып җиттек. Өч ай карантин узгач, декабрь ахырында алып киттеләр Польшага. Танковый частька эләктек. Юньләп ашау булмады анда да. Егерме тугызы көнне безне урамда стройга тезделәр. Рота командирына ияреп өч офицер керде. Болар авиациядән иде, погоннары зәңгәр.

Күзе тирә-юньне айкаса да, Ирек сүзен дәвам итте:

— «Кем бездә хезмәт итәргә тели — ике адым алга» ди берсе. Беркем дә чыкмый. Мин икенче шеренгада идем, иң артта диярлек, буй кечкенә бит. «Парашюттан сикерәсе булса, егылып төшүең дә ихтимал» дим эчтән генә. Монда бит чүтеки җир өстендә. Шуннан бу офицер бармагы белән төртә-төртә китте строй алдыннан, сарык саныймыни: «Син... син... син...» Миңа да төртеп күрсәтте. Шуннан җыендык та грузотакси сыман машинага утырып киттек.

— Кешеләр авиациядә хезмәт итәргә атлыгып торалар, ә сез...

— Кем белгән аны нәрсә буласын. Кеше чыкмагач, мин дә кыймадым. Алып килделәр частька. Зур ангар. Столовая. Анда өч төрле столовой: летний, технический, солдатский. Без соңгысында инде. Ашарга утырдык. Шаккаттык андагы ризыкка: өстәлгә ап-ак булка турап өелгән, итле аш, икенчегә — изгән бәрәңге белән зур кисәк кыздырган балык, эчәргә — компот. Шуннан китте рәхәт тормыш. Бераздан мине мунча мөдире иттеләр. Кесәгә акча-злотый да керә башлады: офицер, макаронник хатыннары килә, мин себеркеләр әзерләп куям, чәй эчертәм. Шәп булды ул чорда.

— Оҗмахка эләккәнсең икән.

— Әйе. Тик соңрак бер макаронник хатыны бәйләнде. Берүзем генә чак иде. Ул да үзе генә. Аркасын ышкытты. Миңа нәрсә — ышкыдым.

— Аркасынмы? — дип көлде Габделнур.

— Башкасын да...

— Булдыргансың.

— Андый нәрсә сизелми каламы соң?! Иренә кемдер тишкән... Скандал булмады. Командир җайлап кына хозвзводка кладовщик итеп күчерде. Чөнки үзенең дә гаеп-кыеклары бар, мунчага мин хуҗа, бөтенесе минем аша үтә...

Өч катлы бина артында гаҗәеп киңлек ачылды: Казансу елгасы тын гына ага, сул якта болын-тугайлар җәйрәп ята, алар шәһәр йортларына барып тоташа; уңда, аста, чиркәү хәрабәләре, агачларга күмелеп утырган иске йортлар пәйда булды. Ул йортлардан да ары биек тимер мачтаны, урманны хәтерләткән агачлыкны шәйләп була.

— Казан бик зур икән, — диде Ирек.

— Әйе. Очы-кырые күренми.

Тегене-моны сөйләшкәләп, армия хәлләрен искә алып, солдатлар кайту ягына борылдылар.

Егетләр, истәлекләргә бирелеп, шулай тарау гына сөйләшеп тротуардан барганда, сары чәчле бер хатын-кыз боларны узып китте. Төс-биткә ничек булгандыр, абайламый калдылар, ә гәүдәсе — коеп куйган. Габделнурның күзе ут янды.

— Их, шәп нәрсә! — дип авыр сулап куйды ул. — Фәлән итәргә иде моны.

Һич уйламаганда зифа буй борылды да:

— Син алай бик ашыкма әле, энекәш, ул бит уч төбендәге нәрсә түгел, — дип китеп тә барды.

Солдатлар телсез калдылар.

**38**

Габделнурга икенче төнне тынычлап йокларга ирек бирмәделәр. Кем диген? Өченче елын тутыручы солдат, мондагы коптерщик.

Кичке аштан соң Габделнур йомыш белән коптеркага керде. Чөнки чемоданнар шунда саклана. Ул конверт белән кәгазь алып чыгып барганда, коптерщик дәште:

— Утыр әзрәк.

— Нәрсә?

Калын иренле, түм-түгәрәк симез битле, сары мыеклы, кыска муенлы Ильященков үзе дә соңгы елын хезмәт итә иде. Ул буйга Габделнурдан бераз кайтышрак, ләкин аңа караганда ярты гәүдәгә тазарак. Бигрәк тә аның ботлары һәм арты, егетләргә хас булмаганча, симез иде. Әле моңарчы аралашкан солдат түгел. Шулай да, санга сугып эндәшкәч, Габделнур туктап калды. Ул күрсәткән урынга утырды.

— Миндә шешә бар. Саласыңмы?

— Әйдә, — диде Габделнур, бик исе китмичә генә.

Коптерщик ишекне бикләде, тумбочка өстенә ризык чыгарып куйды: сыр, колбаса, ипи. Алар янына ачылмаган ярты да кунаклады.

— Мин хәрби училищеда укыган идем, Ульяновскида, — диде ул, өстәл хәстәрләгәндә.

— Анда нинди училище?

— Элемтә. Ләкин китәргә туры килде. Германиядә хезмәт иттем, монда төгәллим. Әйдә, якынрак утыр. Яратам укымышлы егетләрне.

Аның соңгы сүзләренә Габделнур игътибар итмәде.

Ильященков, шешәне ачып, ике кружкага аракы салды.

— Нәрсә өчен эчәбез? — дип сорады Габделнур.

— Синең исәнлеккә, — дип елмайды коптерщик һәм, калын иренле олы авызын зур ачып, кружкасын бушатып та куйды.

— Дембель өчен, — диде дә Габделнур да кыстатып тормады.

Гәп хезмәт, өй хәлләре, уку тирәсендәрәк барды.

— Син армиягә хәтле кайда эшләдең? — дип сорады коптерщик һәм, җавап алгач, дәвам итте: — Мин ресторанда официант булып эшләдем. Анда бөтенләй икенче тормыш...

Ул тагын кружкаларга аракы койды. Ләкин аларны бушатуга, коптерка ишеген шакыдылар. Ильященков, тумбочка өстенә гәзит каплап, барып ишекне ачты. Рота старшинасының озын буе күренде. Ул керде, тумбочкага күз ташлады, тукмак борынын җыерып иснәде.

— Сез нәрсә?

— Юк, иптәш старшина, — диде коптерщик, үз урынына утырып. — Болай гына, сөйләшеп утырабыз.

— Ә-ә, — диде старшина, ләкин үзенең чыгып китәргә исәбе юк иде.

Габделнур торып басты.

— Утырыгыз, иптәш старшина, — диде дә, бер киштәгә куелган конверт белән кәгазен алып чыгып китте.

Кич белән, гадәттәгечә, отбой алдыннан кичке прогулкага чыктылар. Бөтен Кремльне көр тавышлы солдатларның җырлары яңгыратты:

Не плачь, девчонка,
Пройдут дожди;
Солдат вернется,
Ты только жди.

Анысы бетүгә, мәңге популяр булып калачак «Катюша» җыры ишетелде.

Аннары бәләкәй генә юантык гәүдәле бер азәрбайҗан егете, җир буе сузып, үз телендә нindidер җыр башкарды. Габделнур, үзалдына елмаеп, теге солдатны жәлләп тә куйды. Частька берүзе килеп эләккән бу егетне ул әле яклап та маташты.

Беркөнне казармада моны солдатлар төркеме уратып алган да үртәпме-үртиләр:

— Ашур, синең апаң бармы?

— Бар.
— Мин синең апаңны ниттем.
— Кирәкми! Алай әйтмә!
— Ә синең йорт кенәгәң бармы?
— Бар.
— Мин шуны фәлән иттем.
— Нигә алай әйтәсең? Әйтмә андый яман сүз!
— Ә синең хатының бармы?
Калын кашлары кушылып үскән тулы битле көньяк баласы — беркатлы бәндә — һаман боларга ышана, мәрхәмәт яки теләктәшлек көтеп, сорауларына дөрес җавап биреп тора:
— Бар.
Шунда кемдер такмаклый:
— Спасибо Сулейману, помогал мне беда, пока я в армии служил, целовал моя жена.
Шул чакта каратут йөзе кызарып-бүртенеп чыккан, еларга җитешкән мескен егетне яклап бер-ике сүз әйткән иде Габделнур.
Ә кичке прогулкада аны кызык өчен һәрчак җырлаталар. Чөнки ул озын җырның сүзләрен аңламыйлар, аяк атлаган көйгә ритмы да туры килми. Егет исә карышмый, иренмичә җырлый. Бүген дә аның үз илендә тау-таш арасында еш яңгыраган моңлы, яңгыравык авазы, калын диварларга сыеша алмыйча, ерак-еракларга — Казансу буйларына тарала, Кремль астындагы туку фабрикасы цехлары түбәсенә иңә иде.
Бу карусыз тырыш егет бүген урысча да җырлап җибәрде. Аның җыры, әлбәттә, үзенең газиз туган ягы, күңеленә хуш шәһәр — Баку турында иде.

...Я полюбил тебя, родина огней,
Гордятся все друзья доблестью твоей,
Над вышками горит счастье твоих дней.
Ты — город красоты,
Ты — славы и мечты,
Мое богатство — ты,
Баку родной.

Казармага керделәр. Кичке барлау үттеләр. Солдат халкы өчен иң кадерле, ягымлы команда бирелде:
— Отбой!
Хәер, тагын берничә колакка ятышлы сүз бар икән әле: иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш.
Старшина чыгып киткәч, кемдер кычкырды:
— Теш!
Икенче тавыш аны куәтләде:
— Тарт!
Һәм, мылтыктан аткан кебек үк булмаса да, йөзтүбән яткан берничә солдатның салют биргәне ишетелде. Фейерверк кына күккә чөелмәде.
Кемдер сөенеч белән әйтеп куйды:
— Көн үтте!
Икенчесе шатланып җавап кайтарды:
— Хрен с ним!
Берәү стенадагы, ә калганнар тумбочка өстендәге бәләкәй календарьлардан бүгенге көнне аеруча зур тырышлык куеп матур итеп сызып ташладылар.
Юка одеал ябынып яткан таза тәнле, сәламәт егетләр күршеләре белән тегене-моны сөйләшкәләделәр дә бераздан тоныкут яктысында тирән йокыга талдылар.
...Габделнур кисәк уянып китте. Өстенә нидер килеп төшкән кебек булды. Ул күзләрен ачты. Бернәрсә дә аумаган, ә янына кемдер килеп яткан икән. Юньләбрәк караса — коптерщик.
— Тебе чего? — диде Габделнур, ачу белән.
— Не шуми. Хочу молока.
— Чего?
Ильященков итләч кулы белән аның бот арасына үрелде. Берни аңламаган Габделнур, ике аягын да берьюлы тездән бөгеп, арткарак авышты да, аркасын стенага терәп, тегеңә тибеп җибәрде.
Симез гәүдә лапылдап идәнгә барып төште.
— Ладно, ладно, не шуми! — диде моны көтмәгән коптерщик, көчкә санын җыеп идәннән торды һәм ары китеп барды.
Габделнур бик авырлык белән йокыга китте. Иртән ул юынгыч янында төнге хәл турында Иреккә әйтте. Дустының бер дә исе китмәде, тешен чистарта торган җиреннән пырхылдап көлеп җибәрде: авызыннан сыек ак порошок белән бергә щеткасы да атылып чыкты.

— Син белми идеңмени?
— Нәрсәне?
— Ильященковның нинди икәнен.
— Каян белим.
— Алайса, мин сиңа әйтергә онытканмын. Аны миңа беренче көнне үк җиткезделәр. Аны училищедан да шуның өчен куганнар бит.
— Ни өчен?
— Да, син күрәм, бөтенләй профан. Ул егетләр ярата...
— Менә... — дип сүгенеп алды Габделнур. — Ә мин аның белән коптеркада аракы эчеп утырам тагы.
— Ахыры ни белән бетте соң? — дип сорады Ирек, кара төкле битен кырыну өчен сабынлап.
— Старшина керде дә, чыгып киттем.
— Синең — бәхетең, аның — бәхетсезлеге, — дип авыз ерды Ирек.
Салкын суга манчылган юеш сөлге белән тәнен ышкып торучы Габделнур җирәнеп бетон идәнгә төкерде.
— Кичә үлгән булсам, белмичә үләсе икәнмен. Зараза... Өч елга беренче күрәм андый шакшыны.

**39**

Ике атна Кремльдә вакыт үткәргәч, Габделнурларны, өсте ябык машиналарга утыртып, Казан тирәсендәге хәрби лагерьларның берсенә илттеләр.

Каен урманы эченә урнашкан бу лагерьда тактадан гына әмәлләнгән, элек офицер дачалары булган җыйнак өйләр, зур-зур казармалар, озын барак рәвешендәге ашханә, чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган складлар һәм тыл хезмәте өчен кирәкле бүтән биналар бар иде.

Монда сасы, тынчу шәһәр түгел инде, күкрәк тутырып саф һава сулыйсың, табигатьнең гүзәл бер почмагына карап хозурланасың. Каеннар әле яшеллеген җуймаган, шулай да арада сары яфраклары да бар. Алар, башкалардан аерылып, виноград тәлгәшләре кебек ботагы-ботагы белән асылынып торалар.

Лагерьда хезмәт бүтәнчәрәк икән.

Иртәгесен монда карантин узып, чит илгә озатыласы, яңа гына хезмәткә алынган такыр башларны китереп тутырдылар.

Габделнурлар аларны корал сүтеп, майлап, яңадан җыеп, озак саклау өчен консервациягә салырга өйрәттеләр. Ул яшь солдатларны башкалар тагын нәрсәгә өйрәткәннәрдер, анысы Габделнурлар өчен караңгы һәм кагылмый да иде. Һәрхәлдә, яшь сугышчы курсын алар шушы лагерьда үтәләр, ант кабул итәргә әзерләнәләр иде булса кирәк.

Әмма бу салагаларны «стариклар»га беркетү соңгылары өчен мач килде. Чөнки яшьләрнең әле өйдән ата-аналары биреп җибәргән сәмәннәре бар, ә үзләренең каядыр чыгып йөрү мөмкинлеге чикләнгән. Үзләре өстеннән командалык итүче Машкин фамилияле капитан белән дә бик тиз уртак тел таптылар «картлар», чөнки ул тамак чылатырга ярата икән.

— Иптәш капитан, увольнительный кирәк иде, — дип, аңа мөрәҗәгать итте икенче көнне өч елын да Казанда хезмәт итеп үткәргән солдат Гена.

— Нинди сүз булуы мөмкин?! — диде офицер, гамьсез генә. — Кемгә?

— Ковалевка.

Ни өчен икәне аңлашыла иде. Капитан артыгын төпченеп тормады, өстәл янына килеп, артсыз урындыкка утырды да аркылы-торкылы каешлар белән чолганган куе яшел гимнастеркасының түш кесәсеннән кәгазь-каләм алып язарга да кереште.

Колгадай озын буйлы, ябык йөзле, кылыч борынлы Ковалев аның янәшәсенә утырды. Капитан аңа ярты бит зурлыктагы кәгазь тоттырды.

— Патрульгә очрамаска тырыш, киемең тәртиптә булсын.

— Есть, иптәш капитан, — дип, Ковалев урынынннан кузгалды, егетләргә күз кысты; сөйләшкәндә, аның тамак алкасы уйнаклый иде: әле югары күтәрелә, әле аска төшә.

Бөтен йөзен кара төк баскан Гена тагын Машкинга сүз катты:

— Иптәш капитан, кичке аштан соң безгә керерсез.

— Яхшы, — диде тәбәнәк буйлы, юантык гәүдәле, кып-кызыл йөзле офицер. — Яшьләр дә буламы?

— Әйе, акча аларныкы бит, — дип сүзгә кысылды тәбәнәк гәүдәле, йөргәндә җир үлчәгән кебек олы атлап йөрүче Вася исемле солдат.

— Булса соң, — диде капитан, илтифатсыз гына. — Әйдә, без болай итик...

Һәм ул үзенең планын сөйләп бирде. «Карт солдатлар» берсүзсез ризалаштылар.

...Кич белән, билгеләнгән вакытка, яшьләрне чакырдылар. Алар бишәү булып чыкты. Кайсы өстәл тирәли урындыкларга, кайсы тимер челтәрле койкаларга утырыштылар. Монда хуҗа кеше — Гена — калай кружкаларга көндез Ковалев Казаннан биштәр капчыгы белән алып кайткан аракының ике шешәсен бушатты.

Ул, як-ягына каранып:

— Ковалев кайда соң? — дип сорады.

Ирек аңа:

— Ул монда гына, — диде елмаеп. — Әллә Казанда ярамаган нәрсә ашаган, понос, ахры, эчен тотып чыгып китте. Хәзер керер.

Гена, бил каешын ычкындырып, үзенең караватына ташлады, гимнастерка изүен чишеп җибәрде, йонлач күкрәген юан бармаклары белән кашып алгач, кружкасын кулына тотты.

— Ну, күтәрдек, — диде ул, көр тавыш белән һәм берәм-берәм калганнар белән чәкеште. — Безгә исәнимин өйләргә кайтып җитәргә язсын, сезгә — хезмәт итәргә...

Генаның кружканы авызына китерүе булды, шулчак кинәт ишек ачылды, һәм анда капитан Машкинның кызгылт йөзе күренде. Ул алга таба кискен хәрәкәт ясап килеп тә керде, кычкырып та җибәрде:

— Нәрсә бу? Эчү мәҗлесе оештырдыгызмы?

«Картлар» урыннарыннан сикереп тордылар, төзәтенә башладылар: кем каеш буа, икенче берәве пилотка кия, өченчесе гимнастерка төймәләрен эләктерә. Аларга охшарга тырышып бераз тугарылып утырган яшь солдатлар да, офицерны күрү белән, аракысын чөмерергә өлгерми калган кружкаларын өстәлгә куеп, сикереп тордылар, гимнастеркаларының болай да озын итәкләрен тарткаларга тотындылар, муен турысындагы сәдәфләренә үрелделәр.

Машкин җикеренүендә булды:

— Кем сезгә рөхсәт итте? Безобразие...

— Гаеплебез, иптәш капитан, — диде хуҗа «картлач», аклана-аклана.

— Яшьләр дә монда?! — дип акырды яшелле-зәңгәрле тавыш белән офицер. — Бер елсыз бер атна хезмәт итәсез, инде тәртип бозарга керештегезме? А ну-ка марш!

Ул шулай дип, броневикка басып нотык сөйләгән Ленин бабай кебек кулы белә ишеккә күрсәтүгә, дер калтырап торган яшь солдатлар, бер-беренә һәм ишек борысына бәрелә-сугыла, калын табанлы өр-яңа олы кирза итекләре белән лаплоп басып чыгып йөгерделәр.

Алар юк булгач, баядан бирле көчкә чыдап, тыелып торган «карт солдатлар» эчләрен тотып сыгылып төштеләр, бүлмә яңгыратып көлә башладылар.

Машкинның да авызы ерылды:

— Ну, ничек соң, әйбәт уйнадыммы?

— Шәп, — диде Ирек.

— Чын артист икәнсез, иптәш капитан, — дип мактады аны Вася.

— Талант әрәм булып ята, — дип, капитанның салпы ягына салам кыстырды Габделнур.

— Монда ул маңкаларга әрәм итә торган аракы юк, — диде офицер, күңеле булып, һәм бер кружканы кулына алды. — Тутырып сал.

Хуҗа ул кушканны үтәде. Шулчак ишектән, башын ия төшеп, Ковалев керде. Ул да чыдый алмыйча көлә иде.

— Мин чак кына бәдрәф чокырына егылып төшмәдем, — диде ул. — Чыдап кына булмый тегеләрнең элдерүенә. Анда берсе, мәтәлеп, аягын сындырды бугай.

— Нәрсә? — диде кружкасын әле генә авызына каплаган капитан.

Аракы ялгыш юлга китте булса кирәк, ул чәчәде.

— Юк, юк, иптәш капитан, шаярып кына әйттем, — диде тиз генә Ковалев, арттырыбрак җибәрүен сизеп, һәм үзе дә кружкага үрелде. — Ул салага нәрсәгәдер абынып егылды да тагын торып йөгерде. Мин ярыктан карап тордым.

— Ну и шутки у тебя... полхрена в желудке...

Гена капитанга су бирде, олы тәлинкә тулы итне аңа табарак этәрде. Өстәлдә алма, тозлы кыяр, казылык белән ипи дә бар иде. Тагын берәрне тоттылар. Ковалев үзенең калын тавышы белән җыр сузып җибәрде:

Що ты меня пидманула,
Що ты меня пидвила,
Що ты меня молодого
С ума-разума свела.

Ул Киевта украин егетләре белән хезмәт иткән һәм, кирәксә-кирәкмәсә дә, алардан отып алган сүзләрне кушып җибәрергә ярата иде. Өйрәнгән бер җыры да бар икән.

Җырны белгәне дә, белмәгәне дә күтәреп алды. Бәләкәй генә дача йорты киңәеп, зураеп киткән сыман булды. Җырлау дәвам итте. Бу юлы Гена башлады. Аның тавышы, Ковалевныкы шикелле үк калын булмаса да, ярыйсы гына яңгырады:

Поишь меня, поишь меня
Горячим чаем.
За что тебя, за что тебя
Я уважаю.
Эх, подружка, моя большая кружка,

Полулитровая моя!

Аңа да бердәм кушылдылар. Чөнки хәрбиләр арасында киң таралган, өч ел буена солдаттан аерылмаган кружкага мәдхия укыган җыр иде бу.

Әлбәттә, гармун булса, Габделнур аны тартып җибәрер иде. Ләкин мондагы хезмәт урыны вакытлыча, җәйлеккә генә көйләнгәнлектән, музыка уен кораллары юк. Шуңа күрә ул да җырга кушылды, анысы беткәч, үзе үк икенчене башлап җибәрде:

В нашем батальоне все равны:
Русские, татары и хохлы.
Есть бойцы любого сорта,
Есть бойцы смелее черта,
Есть бойцы упрямы, как ослы.

Габделнурдан соң Ирек татарчага күчте:

Оныт мәшәкатьләреңне,
Оныт инде беразга;
Сыйпап-сыйпап чәчләремне
Бер иркәлә, бер назла.

Кушымтасын Габделнур белән икәү урысча җырладылар:

Садись рядом, ко мне, милый,
Сердцу будет веселей.

Икенче тапкыр кабатлаганда, барысы да күтәреп алды.

Әлеге җыр беткәч, Гена:

— Мин дә татарча бер җыр беләм идем, — диде. — Хәзер искә төшерәм.

Ирек:

— Ә син каян беләсең аны? — дип сорады.

— Безнең республикада татарлар күп бит, тоташ татар авыллары бар. Мин техникумда укыганда тулай торакта ике татар егете белән бер бүлмәдә яшәдем. Җырны шулардан отып алган идем.

— Нинди җыр соң ул? — дип төпченде Ирек.

Гена серле генә:

— Җырлагач белерсең инде, — диде. — Хәзер... искә төште.

Агыйдел каты ага,
Рәхмәт яусын Гатага;
Иртән торсам, сиеп куйган
Минем киез катага.

Габделнур, капитанга карап, җырын сүзгә-сүз тәрҗемә итеп биргәч, барысы да көлештеләр.

— Молодец, Гата! — дип кычкырды капитан Машкин, стаканга үрелеп.

Габделнур:

— Ә мин мордвача җырлый беләм, — диде. — Тыңлагыз!

Мәтик, мәкри, мәтик, мәкри,
Мәтик, мәкри, ңысалак.
Ним мәтик, мәкри, ңысалак,
Пынгас әгмек ңысрарак.

Гена, җилкәләрен җыерып, башын кыңгыр салып, ни дияргә белмичә аптыраашта калды.

— Юк, мин андый җырны белмим, — диде ул ахырда. — Бер сүзен дә аңламадым. Хәер, мордва ике халыктан тора: эрзя һәм мукшы. Мин — эрзя. Бәлки, бу мукшылар җырыдыр? Без бер-беребезне авыр аңлыйбыз.

Габделнурга эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп бирергә, серен ачарга туры килде:

— Без мәктәптә укыганда еш кына концерт куя идек. Анда таләп шундый: төрле милләт җырлары булырга тиеш. Гап-гади татар авылы. Урысчадан башка бер халыкның да җырын белмибез. Анысын да белмәс идек,

урыс теле укытучыбыз марҗа иде. Менә шул: бүтән милләт җыры дип, без татар җырын сүзләрен киредән укып җырлый идек. Мин җырлаган татарча болай:

Китәм, иркәм, китәм, иркәм.
Китәм, иркәм, каласың.
Мин китәм, иркәм, каласың,
Сагынып кемгә карарсың?

— Ну хәйләкәр дә бу татарлар! — диде капитан Машкин, көлеп. — Ә шулай да батыр халык! Юкка гына «один татарин в две шеренги становись» димиләр. — Аннан Габделнурга карап: — Бүлдердек, дәвам ит, — диде.

— Бетте инде. Шулай итеп, без бик күп милләт вәкилләре булып җырлый идек. Шәп ятлатканнар. Күрәсез, әле һаман онытмаганмын.

— Гена, үзегезчә җырла әле, — диде капитан Машкин, үтенеп.

Солдат ялындырып тормады, такмаклап алды:

Дрига озась лей чирентень
Ульманть ёртызе ведентень, —
Учи тосто кал.
Калось ульманть ноцковтызе, —
Картне весе начксть.
Эх, карть, эрзянь карть,
Семеричка карть.

Ахырдан тәрҗемә итеп тә бирде:

Гриша ярга утырды да
Суга кармагын ташлады, —
Ул көтә балык.
Кармакны балык капты да,
Гришаны суга тартты да, —
Чабатасы юеш.
Их, эрзя чабатасы шул,
Җиледән үргән.

Бераздан офицер, сәгатенә карап, торып басты.

— Ну, егетләр, яраттым мин сезне! — диде ул, күтәренке пафос белән. — Гомумән, хезмәтне яратам! Күңелле сезнең белән!

Капитан, хезмәтне яратам, дип дөрес әйткәндер. Чөнки ул кечкенәдән Суворов училищесында тәрбияләнгән, хәрби училище тәмамлаган, кыскасы, гомеренең күп өлешен биленә каеш буып үткәргән чын гаскәри иде.

— Да, кстати, сез похмельдән нишлисез? — дип сорады капитан һәм, җавап көтеп тормастан, түш кесәсеннән бер кәгазь кисәге тартып чыгарды. — Безнең йортта бер спортчы егет тора. Кичә миңа СССР һәм Чехословакия футболчылары белән хоккейчыларының ничек баш төзәткәнен язып бирде. Тыңлагыз. «Проснулсы Рагулин в Понедельник с Хмельницкого: в животе Колотов, в глазах Черни, во рту Сухи. Взял Копейкина и Поспешил в гастроном, а там братья Холики и Третьяк. Взяли Сухи. Хорошевски, но Мальцев. Тогда взяли Краснецкого и пошли к Бабичевой. Он ее за Кохту, она — Недомански. Тогда он ей на Пузач и Горбатько Мотовилова промеж Белоножкина и появился Малофеев. Она: «Плати Альметьев». А он: «Хусаинов». Тогда она звонит в милицию и приезжают братья Майоровы со Старшиновым, а на поводке — Репс».

Солдатлар бүлмә яңгыраттылар. Вася гына тыныч утырды.

— Ә син нигә бик җитди?

— Иптәш капитан, мин кайчан көләргә икәнен белмәдем.

— Жирафка да шулай соң барып җитә, — диде колгасар Ковалев, кәтәнә Васяның җилкәсеннән кагып. — Башың яшь, бераз үскәч аңларсың.

Офицер төзәтенде: портупея каешларын тарткалады, гимнастерка төймәләрен каптырды, фуражкасын киеп алды.

— Рәхмәт, иптәш капитан, — диде Габделнур, ихласлык белән, чөнки хезмәт дәверендә аңа офицерларның төрлесен күрергә туры килгән иде.

— Гена, — диде капитан Машкин, хуҗага мөрәҗәгать итеп һәм уң кулының имән бармагын өскә күтәрде. — Тәртип булсын! Комендант ротасыннан патруль килгәнче җыештырыгыз!

— Есть, иптәш капитан, — диде Гена, честь бирмичә генә.

Офицер, берни булмагандай, төп-төз атлап чыгып та китте. Аны аягүрә озатып калдылар.

Ул чыгып киткәч, Ковалев:

— Безнең старшина алдында да сиздермәс иде бу, — диде. — Без увольнениедән кайтканны сагалап кына тора иде, паразит. Берәрсендә ис сизсә, ну-ка, бер тактага гына басып бар әле, дип, казарманың бер башыннан икенчесенә — түргә хәтле атлата иде. Хәтерлим, бер шаян егет, иптәш старшина, сезнең хакка бөтен такталарны иңләп-буйлап бара алам, дип алпан-тилпән атлап китте. Чөнки ул лаякыл исерек иде.

Беркавым хезмәттәге мәзәк хәлләрне, кызык вакыйгаларны искә төшереп, сөйләшеп утырдылар да өстәлне җыештыра башладылар.

Шулчак урамда, тәрәзә каршында, кемнеңдер йомшак кына сызгырып тавыш биргәне ишетелде.

— Әһә, кызлар килде, — диде Гена, елмаеп.

Габделнур:

— Нинди кызлар? — дип сорады.

— Алар монда килгәли, — диде Гена, Васяга карап, расла дигәндәй. — Кем чыга? Дәртегез булса, барыгыз.

Ирек белән Ковалев бер-беренә караштылар. Габделнур дәшмәде.

— Үзем, — диде Ковалев. — Алар ничәү соң? Бәлки, бөтенебезгә дә җитәрлектер?

Гена көлде, тавыш килгән якка ымлады:

— Каян белим. Бар, санап кер.

Ковалев каешын буып, пилоткасын киеп, иелә төшеп чыгып та китте. Бераздан ул әйләнеп керде. Авызы ерылган иде.

— Дүртәү. Беребезгә җитми.

Гена баш тартты. Башкалар, киенеп, «бәхет эзләргә» чыгып киттеләр.

...Габделнурга эләккәне — өлешенә тигәне — бик дәртле нәрсә булып чыкты. Ул солдатны, авыл хатыннары әйтмешли, алтынчы бүрәнәгә хәтле чөя иде. Егет астында ятканда, ул буш дачаны яңгыратып аһылдыйуһылдый башлады.

Эшен бетереп, үзләре йортыннан алып килеп идәнгә салган матраска чалкан яткач, солдат бераз хәл җыйды.

Егетнең чәчләрен сыйпап, янәшәсендә яткан кызга Габделнур:

— Нигә син ай буена ир күрмәгән хатын кебек кыланасың? — диде.

— Чыны да шулай. Мин монда сирәк киләм.

— Нишләп?

— Эшлим. Баламны карыйсым бар.

— Синең балаң да бармыни инде?

— Әйе. Ә син мине саф кыз дип уйлаган идеңме әллә?

— Юк. Карт күренмисең.

— Рәхмәт. Иртә бала таптым.

— Иреңнән аерылдыңмыни?

— Аның булганы да юк.

— Ә бала кемнән?

— Әллә тагы... Әллә солдаттан, әллә сержанттан — белми дә калдым, — диде хатын, авыз чите белән генә ачы елмаеп. — Яшь чак — җүләр чак... Менә хәзер йөрим тилмереп... Теләсә кем астына ятып...

— Нишләп, сиңа кем булса да барыбермени?

— Билгеле, — диде хатын, ничектер ямьсез итеп авыз ерып. — Мине бер солдат биш тапкыр канәгатьләндерсә ни дә, биш солдат берәр тапкыр басса ни...

Габделнур хатынның бу сүзләрен килештермәде һәм уйлап куйды: «Авылда ветврач абзый, ата каз бер генә баса, дип әйтергә ярата иде. Дөрес әйткән икән. Күп ир-ат белән чуалса, хатынкыз баласының кемнән икәнен дә белми кала шул».

Хатын сөйләвен дәвам итте:

— Ишеткәнең бар микән бу җырны: «Эх раз, еще раз, еще много, много раз, лучше сорок раз по разу, чем по разу сорок раз!» Их син, ефрейтор! Берегез дә безнең хәлне аңламый...

Габделнур шаярткан булды:

— Син солдатлар яратасың, ахры.

— Әйе. Мин үзем дә солдат кызы, — диде хатын, җитди төстә.

Габделнур аптырап калды. Кызыксынуы артты. Кыек атып, туры тидергәнмен икән, дип уйлады.

— Ничек?

— Без моннан ерак түгел бер авылда торабыз, өч кенә чакрым. Сугыш вакытында әни шушы лагерьда кухняда эшли, посудомойкада. Аны бер повар солдат үзенеке итә дә мин туам.

— Әтиең исәнме соң?

— Юктыр. Сугышка алып китәләр аны. Шунда хәбәрсез югала. Мин солдатларны яратам, ә сугышны — күралмыйм.

— Сез әниең белән икегез генәме?
— Әйе. Хәзер. Элек әбием бар иде. Үлде инде.
— Әйе-е, язмыш... Гафу ит.
— Бер кешегә дә әйтмәсәң, мин сиңа бер әйбер сөйлим.
— Бик яшерен сермени?
— Түгел дә... Сөйләргә дә ярамый. Аны үләр алдыннан әбием әнигә сөйләгән, ә ул — миңа.
— Тыңлыйм.
— Вәгъдә бирәсеңме?
— Эчемдә саклармын. Тешем сирәк булса да, мин сер саклый беләм.
— Мин сиңа, сугышны күралмыйм, дидем. Әтисез калган өчен генә түгел... Минем әби... кеше ашаган...
— Нәрсә?
— Әйе. Ул сугышка хәтле Ленинградта яшәгән бабай белән. Бабай инвалид булган, шуңа күрә сугышта катнаша алмаган, шәһәрдән дә китмәгән. Әби үзе киткән дә булыр иде, бабайны ташлап калдырмаган. Ә әнине сугыш чыккач та авылга озаткан, менә шушы хәзер без яши торган авылга. Әбинең туган авылы бу. Ә Ленинградта блокада башланган. Халык кырыла, ачлык... Бабай кырык өчнең кышында үлә. Үләр алдыннан әбигә үзе әйткән.
— Нәрсәне?
— Мине ашарсың, дип.
Габделнур — дары иснәгән, күпмедер дәрәҗәдә утны-суны кичкән солдат, шулай да бу сүзләрне ишеткәч, аның чәчләре кымырҗып куйды; салкын суга кереп чирканчык алгандай булды — тәне чымырдап китте.
Хатын дәвам итте:
— Әби ул чорны сораштырганны һич яратмый иде. «Куй, куй, сөйләмим», — ди дә утырып елый торган иде. Аның сәбәбе булган икән. Әби үләр алдыннан (ә ул, блокада беткәч, кырык дүртнең җәендә монда кайта) гына серен әнигә тишкән. Гомер буе үз-үзен гафу итә алмаган.
Бераз тын торгач, Габделнур:
— Нигә син моны миңа сөйләдең? — дип сорады.
— Үзем дә белмим. Син бүтәннәргә охшамаган: иркәлисең, матур сүзләр әйтәсең. Әллә ничек рәхәт булып китте. Абыем шикелле итеп тойдым сине. Мин абыйлы кызларга кызыга идем. Әтием дә булмагач...
Хатын, солдатның күкрәгенә капланып, беравык аны кочаклап ятты. Күз яшьләре гимнастеркасына тамды. Егет аның йомшак чәчләрен сыйпады, кулын тирләгән аркасына куйды.
Хатын кисәк кенә торып утырды.
— Әйдә, эчеп бетерик.
Тәрәзәдән төшкән тонык яктыда ул үзе алып килгән очсызлы кызыл аракыны стаканнарга салды, чәкештерде. Эчеп куйдылар. Габделнур ризык капты. Хатын буш стаканнарны һәм газета өстендә калган ипи телемнәрен сумкасына салды. Сәгатенә карады.
— Мине кызлар көтәдер. Йә, хуш, мин киттем. Рәхмәт. Күңелемне күрдең.
Ул чыгып киткәч, матрасны каккалап, бөтереп култык астына кыстырды да Габделнур үз йортларына юл алды.
Урман эче караңгы, ачулы җил агач башларын чайкалдыра, карасу болытлар түгәрәк айны каплаганнар һәм әкрен генә, гамьле кешеләрнең уйлары сыман, каядыр еракка-еракка агылалар иде.

**40**

Икенче көнне, бүтән яшьләрдән акча җыеп, тагын шул ук рәвешле бәйрәм иттеләр. Әмма бүген кич тәрәзә каршында сызгырып йөрүче «сандугачлар» булмады.
Габделнур, урынга яткач, тиз генә йокыга китә алмады, нигәдер мондагы тормыш (моны хәрби хезмәт дип әйтергә тел әйләнми иде) турында уйланды.
Әйе, дөресен әйтергә кирәк, солдат өчен бу мохит — бик кулай, уңай күренеш. Ләкин... «Армия нинди булырга тиеш? — дип фикер йөртте солдат, караватында әле болай, әле тегеләй боргаланып ятып. — Менә шушындыймы: тәртипсезлек, эчү, хатын-кызлар белән типтерү... Әллә мин элекке частьларда хезмәт иткәнчәме?..»
Габделнур одеалын башына бөркәнде дә, ник чукынып китми дөньясы, дип саный башлады: «Бер, ике, өч... дисциплина... Менә сиңа авыртмаган башка тимер тарак, — дип, ул, тагын уйлана башлавына аптырап, одеалын ачып ташлады. — Миңа дисә... Әнә егетләр инде гырлап йокыга киткәннәр... Нәрсәгә миңа юк белән баш катырырга? Оборона министры мәллә мин?!» Ләкин, юк икән шул, өч ел буена политзанятиеләрдә аның башына өзлексез тукылган уй-фикерләр, идеяләр эзсез генә югалмаган икән. Пионерда, комсомолда тәрбияләнеп, армиядә партиягә кергән егерме ике яшьлек егетнең башы уйламыйча гына тора алмый иде инде. Партиягә керүе дә фәкать үз теләге белән һәм изге дип саналган эшкә хәерхаһ булудан, шул бөек идеалларга чын күңелдән хезмәт итәргә омтылудан иде бит. Армиядә (яки флотта, анысы барыбер) аңа бернинди дә ташлама яисә өстенлек кирәкми, карьерага үрмәләү дә максат түгел. Бу гамәле тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүгә дә корылмаган.

Шуңа күрә, үз каланчасы югарылыгыннан торып, ул хәзер фикер йөртте: көч-куәтен арттырып, дары иснәп, дөнья күреп, кайберәүләре гражданкада кирәге чыгардай һөнәр үзләштереп, һәм, иң мөһиме, ир-егет булып кайтучы солдат-матрос аңа якынрак. Солдат хезмәтенең дә төрлесе бар: берәүләр хуҗалык взводында дуңгыз карап вакыт үткәрергә дә риза, икенчеләр пешекче булуны хуп күрә, кемнәрнеңдер күңеленә стройбат якын, кайберәүләр кочегарка мичenә көрәк белән ташкүмер ыргытып җылыда ятуны бәхеткә саныйлар, штабта писарь булып утыру — монысы инде оҗмахның җиденче күгенә ашу белән бер. Ләкин Габделнур андый урыннарда хезмәт итәргә атлыгып торучыларны өнәмәде, үзе омтылмады. Алар турында ул, ничек бөкре килгән, шул бөкре килеш кайтып китә, дип кенә җибәрә иде.

Чөнки Габделнурларга беренче көннән үк, хезмәт авыр булган саен мактаулырак, дип тәкрарладылар, миләренә сеңдерделәр. Хәер, ул моны алдан ук белеп килде. Хәрби хезмәт шулай булырга тиеш икәнен кечкенәдән үк укып-ишетеп үсте алар буыны.

Габделнур өчен армия — олы максат куеп, кулына корал тотып, мактаулы хезмәт итү. Моңа, бәлки, ул караган киноларның да тәэсире көчле булгандыр. Чөнки кинода атакага баручы, юлында очраган дошманны куркусыз тар-мар итүче батыр солдат, берүзе өч-дүрт истребительгә каршы торучы яисә яна башлаган самолетын дошман колоннасы өстенә ташлаучы очучы, чокыр-чакырларны бар дип белмәүче һәм окопларны сытып-изеп алга ыргылучы танкист, соңгы патронына хәтле немецларга ут яудыручы ялгыз пулеметчы, дошман позициясенә бәреп кереп, үзеннән ике тапкыр авыррак симез офицерны — «тел»не — аркасына салып алып кайтучы разведчик, буй-буй тельняшка киеп, тасмалы бескозыркасын кыңгыр салган киң күкрәкле, гайрәтле һәм кыю матрос гәүдәләнә иде. Сугыш чорында туган малайлар өчен алар үрнәк булды, ә кайдадыр артта сөйрәлүче обозларны, солдат-офицерларны ризык һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин итүче интендантлык хезмәтен башкаручы солдатларны алар күрмәделәр һәм хәтта андый хезмәт барын башларына да китермәделәр.

Габделнурга төз буй-сын белән, чыныгып, тиешле срокны тутырып әти-әнисе янына, туган авылына, карчыклар әйтмешли, чын ясау булып кайтучылар якынрак иде. Әлбәттә, вакытында кайтучылар.

Кисәк кенә исенә төште: Кронштадтта, Флот экипажында, күчмә рота дип аталган подразделение бар. Анда Хәрби диңгез флотының төрле частьларыннан җыелган, кайсы кая озатылуны көтеп ятучы солдат-матрослар вакытлыча хезмәт итә, дөресрәге, җыелып ята иде. Шундагы бер матросны хәтерли. Ул яшьләр белән ярышып гер дә күтәргән иде. Аңа ике ел дисбат бирәләр. Шуннан күчмә ротага кайтып төшкән чагы иде. Димәк, алты ел хезмәт иткән. Дөрес, сугыштан соң җидешәр ел солдат шулпасы эчкәннәр дә булды. Анда барысы да тигез. Ләкин моның яшьтәшләре инде ике ел гражданкада бит. Кемгә кирәк булды икән аңа — дүрт ел авыр хезмәтне намуслы башкарган егеткә — шушы хәтле каты җәза бирү? Үзен тәртипкә чакыру өченме? Ул бит хезмәттән баш тартмаган. Башкаларга сабак булсын өченме? Ә бит аны өендә газиз ата-анасы зарыгып көткәндер, бәлки, вәгъдәләшкән сөйгән кызы да, аңа тугры калып, дүрт елдан кайтырына өмет баглап, кияүгә сорап килүчеләрне кире боргандыр... Ә теге мичман берәр төрле вөҗдан газабы кичерде микән? Үзен шушы матрос хәленә куеп карадымы икән? Әллә озак еллар тимер корабта яшәп, бәгыре дә тимергә әйләнде, бүтәннәр хәленә керә алмаслык, кешеләрне гафу итмәслек хәлгә килде микән? Бу вакыйганы күреп торган матрослар ничек хезмәт итте икән: курка-өркәме, әллә намус эше, гражданлык бурычы дип санапмы? Габделнурның ишеткәне бар: солдат-матросларны каты җәберләгән, берәзлексез чокчып торган сержант-старшиналарны, дембельгә бергә эләксәләр, поездда тотып ыргытулар да булгалаган. Шуңа күрә андый кансызларның күбесе, үз кул астында хезмәт иткәннәрдән аерым рәвештә, йә алданрак, йә иң ахырдан частьтан китәләр икән.

Ә икенче төрле фикер йөрткәндә, армиядә каты дисциплина урнаштыру — мәҗбүрият. Шунсыз көчле армия була алмый, ул анархиягә әйләнә. Армия яшьләрне тәртипкә, төгәллеккә, өлкәннәргә буйсынуга өйрәтергә, аларга җебегәнлек, йөгәнсезлек, курку, икеләнү, таркаулык кебек тискәре сыйфатлардан арынырга булышырга тиеш. Ир балалар мәктәп елларыннан ук ил терәге — аны саклаучы булырга үзләрен әзерләргә тиеш. Кыз баланы бизәгән сыйфатлар сафлык-инсафлык, гүзәллек-нәфислек булса, егет асылы — ул батыр, кыю, көчле, ватанпәрвәр... Ә командирлары нинди булырга тиеш? Әлбәттә, тәртип алардан башлана. Үзе буйсына белмәгән кеше башкалардан буйсынуны таләп итә алмый.

«Мин болай артык күп уйласам, иртәнгә тикле йокыга китә алмам», — диде Габделнур үз-үзенә һәм, урамга чыгып кергәч, егетләрнең гамьсез тигез сулышына кушылып, тирән йокыга талды.

**41**

Өченче көнне акча бирүче булмады. Күрәсең, яшь солдатлар да гел үк миңгерәү түгел, башларына барып җитте булса кирәк төп башына утырып калулары, үз акчаларына алынган исерткечтән колак кагулары.

Гена коры калдык дип аптырап тормады, кичке аштан соң бер чиләк ниндидер сыекча алып кайтты.

— Нәрсә бу? — диештеләр «картлар», яшькелт төстәге, автолга тартымрак куе сыекчаны караштырып.

Гена тәфсилләп аңлатып тормады.

— Моны пушкаларга салалар. Ә мин аны хәзер мордва бражкасы — пузага әйләндерәм.

Ул аны эшкәртү чарасына да кереште: мич ягып җибәрде, караваt астыннан катыргы тартма сөйрәп чыгарды. Ә анда самогон куа торган аппарат икән. Аны көйләде. Бераздан аракыдан бушаган шешәгә әкрен генә су шикелле чиста сыекча тама башлады.

— Безнең якта моны «әкрен тамган» дип йөртәләр, — диде Габделнур.

Аның сүзен куәтләүче булмады. Чөнки барысы да дүрт күз белән шешәнең тулганын көтәләр иде. Ул тулуга, Гена икенчесен куйды. Беренче шешәдәге самогонны биш кружкага тигезләп бушатты.

— Хәзер жирәбә салабыз, — диде ул, бил каешын ычкындырып.

— Нәрсәгә? — дип сорады Ирек, аңышмыйча.

— Кем өскә чыга, шул беренче эчә. Барыгыз да ризамы?

— Риза, риза, — диештеләр бүген-иртәгә демобилизацияләнеп кайтып китәсе, өйләрендә аларны ата-аналары өзелеп көтеп торучы солдатлар.

Арада буе бер метр да кырык тугыз сантиметрлы солдат — Вася бар иде. Киров өлкәсеннән хезмәткә алынган. Алар, Ковалев белән кара-каршы басып, каш өстенә кулларын куеп, кызык өчен бер-беренә карашырга, кеше көлдерергә яраталар иде. Буе ике метрга ун сантиметр гына җитмәгән Ковалев түбән карый, ә теге — өскә, гүя агач башына. Васяның солдатка алынуы да, көлсәң көләрлек, еласаң еларлык дигәндәй, кызык та, аяныч та була. Буе бер дә иллегә тулмаса, егетләрне армиягә алмыйлар. Аңлашылса кирәк, Васяны калдыралар. Ләкин бу эчүгә сабышып, азып-тузып йөри башлагач, икенче елны әнисе, военкоматка барып, моны мәҗбүри озаттыра. Военком: «Апа, аның буе җитми бит», — ди. Анасы аптырап тормый: «Син аны, милый, турникка кулларын бәйләп асып куй, — ди. — Ярты сәгатьтән нәкъ бер сантиметрга озаер».

Һәм инде Вася өченче елын тутыра. Гена белән бергә Казанда хезмәт итә. Жирәбә аңа чыкты.

— Ни булса, шул булыр, — диде ул һәм, кружканы күтәреп, күзен йомып, башын артка ташлады да эчеп тә җибәрде.

Ул бүтән сүз әйтмәде, ризык та капмады. Чыраен сытып булса да түзде. Калган дүрт солдат, сәгатьләренә карап, бер авыз сүз дәшмичә, бер-беренә карашып утырдылар. Дөресрәге, күбрәк Васяга караштырдылар. Чөнки әгәр шушы ун минут эчендә аның белән бер-бер хәл булмаса, калганнар да кружкадагы «затлы ризык»тан авыз итә башлый.

Армиядә чакта Габделнурның аракыдан битәр эчемлек татып караганы булмады. Авиациядә хезмәт итүчеләр технически спирт эчеп харап булалар икән, дип ишеткәләделәр. Аларда спирт юк иде. Карабин, пулемет ише коралларны, гомумән, юмадылар, чистарттылар гына, ә янгын сүндерү машиналарын юарга гади су гына сарыф ителде. Хәер, исенә төште: быелгы Яңа елны каршылаганда хушбуй эчкән икән. Аракы беткәч (ун кешегә ике генә шешә иде), берәү кырынгач сибә торган хушбуен алып килде. Исеме «Свежесть» иде бугай. Аны кружкаларга бүлеп, су өстәделәр. Сөт шикелле ак, күбекле нәрсә барлыкка килде... Өч көн авызыннан хушбуй исе бөркелеп йөдәтте. Монысы ни-нәрсә һәм тәэсире ничек булыр икән?

Габделнур берәм-берәм солдатларның үз-үзләрен ничек тотуларын күзәтеп утырды, төс-кыяфәтләренә беренче мәртәбә, менә әле яңа гына күргәндәй игътибар итте. Генага карагач, ул Кронштадтта алар белән бергә карантин узган грек Сарьевны хәтеренә төшерде. Төс-кыяфәтләре ягыннан Гена белән Сарьев гел бертуганнар диярсең: уртача тулы гәүдә, кара төк баскан ияк-яңаклар, йонлач күкрәк һәм беләкләр, хәрәкәтләре салмак, йөзләре җитди. Сарьев җәһәннәм читендәге җылы яктан булса, Гена күрше Мордовия республикасыннан гына. Ул өйләнгән, малае бар.

Гена белән Габделнур арасында беренче көннән үк дустанә мөгамәлә урнашты. Шуңа күрә солдат хисләрен яшереп тормады.

— Бик сагынам шул бәләкәчне, — диде ул, Габделнур белән сөйләшеп утырган чакта. — Әле ярый якын хезмәт итәм. Хатын ике айга бер килеп китә. Улымны да калдырмый.

— Мин әле өйләнмәгән. Анысы — качмас. Укырга кереп булмады менә.

Гена техникум бетергән икән, колхозда агроном булып эшләгән.

— Минем дә читтән торып институтта укырга ният бар, — диде ул, Габделнурның университетка конкурстан узмавын белгәч. — Син киләсе елга тагын биреп карыйсыңмы?

— Исәп юк түгел. Авылда бер бабай әйтә иде: янган салам кебек булмагыз, оланнар, кабынып китәргә дә сүнәргә... Тотынган эшне ахырына җиткерү мәслихәт... Көндезгегә булмас инде, әти-әни җилкәсен кимереп ятар вакыт узган.

— Анысы да дөрес.

...Габделнур карашын Генадан Васяга күчерде. Аңа карагач, Нурмөхәммәтов фамилияле солдат исенә төште. Аның белән каравыл ротасында таныштылар. Ул күрше Башкортстаннан, татар егете иде. Васядан күп булса биш-алты сантиметрга гына калку булгандыр... Ә Ковалев аңа Балтыйк буе егетләрен хәтерләтте, күбесе озын буйлы иде алар: Заранка, Красаускас, Бразаускас...

Габделнур, уйга батып, онытылып киткән икән, аны Ковалевның тавышы айнытып җибәрде.

— Булды, ун минут үтте, — диде ул, сәгатенә карап һәм кружканы авызына түндерде. — Що было — бачили, що буде — увидим.

Ләкин аңа җавап кайтаручы табылмады. Чөнки әле тугыз гына минут узган иде. Ниһаять, тагын бер минутны үткәреп җибәрделәр. Барысы да җиңел сулап куйды, куллар кружкага үрелде.

Ул арада янә бер шешә тулды, тагын...

...Габделнур уянып китте. Берникадәр вакыт кайда икәнен аңышмыйча як-ягына каранды — үзләре йортында икән. Ләкин чишенмәгән, башкасын әйткән дә юк, хәтта итеген дә салмаган. Калган ике караваттагы солдатлар да шул ук хәлдә иде. Бераздан Гена да торды, Ковалев та.

Хуҗа, тумбочкаларны ачып, тулы шешә эзли башлады. Шулчак Вася килеп керде.
Гена, беркемгә дә карамыйча:
— Берәү дә калмаган, — диде.
Чырае сытылган, калын кара кашлары җимерелгән, күзләре ачылыр-ачылмас дустына карап, Вася авызын ерды.
— Әле үзең исән калганга рәхмәт әйт. Монда кичә комендант ротасыннан булдылар. Тулыларын җыеп чыгып киттеләр. Үзебезне дә алып чыгып китәселәр иде, рәхмәт капитан Машкинга — бирмәде.
— Ул монда идемени? — дип сорады чатнаган башын кысып тоткан Габделнур.
— Тегеләрне күреп кергән иде.
Гена буш шешәләрне кеше күзеннән ераграк яшерергә кереште. Караватастына күз салды — аппараты исән икән.
— Ә син аек идеңме?
— Миңа кыз киләсе иде, шуңа күрә сакланып кына эчтем.
— Килдеме соң? — дип сорады моңарчы койкасында бөкрәеп, башын иеп утырган Ковалев.
— Килде.
— Ә минеке?
— Синеке дә.
— Ә мин? — дип мәгънәсез сорау бирде Ковалев.
— Ә син — ләх, — диде Вася, авыз ерып һәм егетләргә хәйләле генә карап алды. — Ия табылды кызыңа.
Ковалев сүгенеп алды. Кемне орышты ул: үзенме, әллә башка берәү астына яткан таныш кызынмы — аңлашылмады.
— Ә Ирек кайда? — дип сорады Габделнур Васядан, чөнки алар бергә — күрше йортта иде.
— Өйдә. Йоклый иде. Уяттым инде.
— Ярый алайса.
Яңадан сүз куертучы булмады, — һәркемнең үз хәле хәл иде. Шулай да, ялкау гына торып, урамга чыгып юындылар, кырындылар да ашханәгә киттеләр. Аннары, складка барып, автомат, карабин, пулемет кебек коралларны сүтеп-җыеп, майлаштырып, саклауга кую эшенә керештеләр.
Кичке якта Гена, Вася, Ирек һәм Габделнур кызып-кызып домино уйнарга тотындылар. Бүген барысы да аек. Шулай да өй эче өстәлгә шап-шоп шакмак сугудан, кычкырып-кычкырып сөйләшүдән шау-гөр килеп торды.
Күпмедер вакыт узгач, Ковалев кайтып керде. Ул — кызмача, кайдадыр кәгеп өлгергән, авызы — ерык. Ләкин шул ук вакытта аның үз-үзен тотышында моңарчы таныш булмаган ниндидер үзгәлек тә бар шикелле — ул иптәшләренә сиздерергә ярамаган гамәл кылудан читенсенү, басынкылык һәм серлелек, ахры.
— Кайда сыйландың? — дип сорады Ирек, сул кулына җыеп тоткан домино сөякләреннән бер генә мизгелгә аерылып.
Күрәсең, Ковалевның теле кычытып торса да сөйлисе килми иде, ул әүвәл кул гына селтәде. Ләкин, караватында берникадәр вакыт сузылып яткач (барыбер кайчан да булса бер сөйләмичә калмас иде), тәвәккәлләп, торып утырды һәм көлеп җибәрде.
— Ильященков сыйлады.
Аны берәү дә ишетмәде, шау-шу арасында ишеткәне дә аңламады, чөнки уен дәвам итә.
Онытылып беткәч кенә Вася сорап куйды:
— Нәрсә дидең?
Ковалев кычкырыбрак җавап бирде:
— Ильященков сыйлады.
Генаның сугарга дип күтәрелгән доминолы кулы, өстәлгә төшеп җитмичә, ярты юлда һавада асылынып калды: әйтерсең аны бау белән тарттырып түшәмгә бәйләп куйдылар.
— Бушкамы? — дип сорады ул һәм егетләргә күз кысып елмайды.
Ильященковның кем икәнен барысы да беләләр. Шуңа ишарә итеп күз кысуы булды Генаның. Теге биредә азык-төлек складына урнашкан иде.
Ковалев сөйли башлады:
— Бу мине очратты да, эчәсең киләме, ди. Сорыйсың тагы, дим. Кичәдән соң үзегез беләсез хәлне, көне буе кеше түгел... Шунда складына алып керде. Чыгарып утыртты бер ярты, авыздан сулар килде, селәгәй ага башлады... Кабарга — җаның ни тели. Шуннан стакан тутырып салды бу, үзенә — ярты гына. Ну бераздан миңа сырпалана башлады. Салган баштан бит, кичәге сөрем дә очып бетмәгән, шешәдә калганны да эчәсе килә. Ну мин, ярар әйдә, мин әйтәм. Үзем: «Һай, миңа начар булсын», — дим эчтән генә. Әйтүем булды, чалбарын төшереп, миңа арты белән борылды...
Солдатлар, плацта командирларны сәламләгәндәй, бердәм рәвештә өй яңгыраттылар — шаркылдап көлеп җибәрделәр. Аннары кем эчен тотты, кем башын артка ташлады, кем селкенә...
Бераз хәл алгач, Гена телгә килде:
— Шакшы, җирәнмәдеңме?

— Юк, — дигән булды Ковалев, үзе идәнгә төкерде һәм акланасы итте. — Бик эчәсе килә иде шул.

— Аны шул гадәте аркасында хәрби училищедан да сөргәннәр, — диде Гена. — Өч елын тутырырга монда солдат итеп җибәргәннәр.

— Тартырга да бирдеме? — дип сорады Вася. — Безне дә сыйла инде.

— Ярар, бәйләнмә кешегә, — дигән булды Гена. — Күрәсең бит ничек арыган. Хәл җыйсын. Иртәгә дә чакыргандыр, мөгаен.

Бер метр да кырык тугыз сантиметрлы Вася, егетләргә аркаланып, озын торык Ковалевны мыскыллавын дәвам итте һәм җыр сузды:

Безгә хатын-кыз кирәкми,
Яшибез аларсыз да.
Маймыллар да булдыралар
Бик каты яратырга.

**42**

Габделнур урман читенә чыгып утырды. Ерактагы биек, юан бер каенга күз салды. Яшел яфраклар арасына буй-буй саргылт тасмалар сузылган сыман — көз билгесе, озын «яллары» тымызык җилдә җилферди. Каяндыр югарыдан торна каңгылдавы ишетелде. Солдат, башын күтәреп, күккә карады. Зәп-зәңгәр һавада, биектә торна көтүе. Әйе, көтүе. Чөнки алар, гадәттәгечә, төгәл өчпочмак ясап очмыйлар. Дөрес, зур өчпочмак хасил булган шикелле. Ләкин аның янында тагын бер бәләкәе барлыкка килә, аңардан янә бер-ике торна аерыла һәм зур төркемгә кушыла, тагын берничәсе бүленеп чыга... Ләкин берсе дә көтүдән читкә китми, үзбаш очмый... Берзаман алар зур түгәрәк ясап бер урында бөтерелә башладылар. Әйләнгән саен югарырак күтәреләләр, өзлексез кычкыралар... Аннары алар аваз сала-сала кыйбла тарафка юл тоттылар да бераздан ак болыт эченә кереп күздән югалдылар...

«Матур вакыт, бәрәңге алу чоры» дип уйлады калкурак җирдә аякларын үләнгә сузып утырган солдат. «Алып бетерделәр микән? Авырга туры килгәндер инде. Абыйлар кайткандыр. Ә мин монда тик ятам... Бая һавада биек-биектә әйләнгән торналар кебек, гел бер урында тулганам-бөтереләм... Алар югары күтәрелү өчен шулай эшләсә, мин түбән төшеп барам шикелле...»

Кичен, увольнительный алып, солдатлар Казанга киттеләр. «Победа» кинотеатрында әле генә экраннарга чыккан «Живые и мертвые» дигән фильм карадылар. Ял паркында буталдылар, шәһәр эчендә кызлар күзләп, эңгер иңгәч, соң гына кайтырга чыктылар.

Троллейбус «Кольцо»дан аларны шәһәр чите юнәлешенә таба алып китте. Павлюхин урамы беткәндә күпер астыннан (халык күпер дисә дә, чынлыкта ул виадук, чөнки өстә тимер юл үтә иде) чыгып, Оренбург тракты буйлап киттеләр. Сулда сазлык, ә аның артында, өстәрәк, биек йортлар, унда ВДНХ һәм танк училищесы калды.

— Нимесләрнең атаклы танкисты, генерал-полковник Хейнц Гудериан шушында укыган, — дип әйтеп куйды Ирек.

— Чынмы?

— Әйе, — диде Ирек һәм Габделнурга үзе белгәннәрне сөйләргә кереште.

Троллейбус авыл өйләре шикелле бер катлы агач яки кирпеч йортлар буйлап юлын дәвам итте. Кабан күле кичке караңгылыкка чумып йокымсырап ята иде. Аның аргы ягында ТЭЦның биек торбаларында кызыл утлар җемелди. Сулда, юл буенда, тагын үз йортлары белән торучылар, ә тау башында бакчалар, күп этажлы өйләр шәйләнә.

Үз йортлары белән торучы шәһәр кешеләренең тормыш-көнкүреше авылчарак, күрәсең, сарай, мунча ише каралты-куралары бар икән, ут сүнмәгән кайбер тәрәзәләрдә чиккән пәрдәләр, яран гөлләрен искәртергә була.

Габделнур кебек, Ирек тә шуларны күзәтеп, уйлап бара икән.

— Старый, карале боларны, гел безнең авыллардагы шикелле яшиләр икән, — диде ул.

Соңгы вакытта Ирек дустына исеме белән түгел, күбрәк Старый дип эндәшә. Чөнки соңгы айларны хезмәт иткән солдатлар өчен бу сүз бик якын. Ул «старослужащий» дигәннән кыскартылган.

— Әйе, — дип килеште Габделнур. — Шәһәрдә эшлиләр, яшиләр, үз өйләрендә торалар. Яннарында гына бакча...

— Мунчасы да бар, — дип ялгап алып китте Ирек, көлеп. — Шушы тирәдәге берәр кызны эләктерсәң, начар булмас иде.

— Карыйсың инде. Казанда кал, бәлки, хыялың тормышка ашар.

— Шәп идея бу, Старый.

— Тик бер четерекле ягы бар: йортка кергәнче, кая кер, диләр?

— Син хаклы.

Троллейбус олы юлдан уңга — Борисковога кереп китәргә тиеш иде. Солдатлар чатта, «Урта Кабан» тукталышында төшеп калдылар һәм җәяү киттеләр. Тау менә башладылар. Сул якта текә үр, аның артында, тау ба-

шында, агачлар арасында, үз йортлы кешеләр, ә уңда — бакчалар. Алар биек очлы койма белән әйләндереп алынган, дача өйләре бәләкәйләр.

Бу тарафта төнге моңсулык хөкем сөрә. Шулай да әнә бер машина, тынлыкны бозып, уфылдап тау менеп бара икән, ә каршы килгәне җилдертә генә — түбән төшә.

Егетләрнең күзе бакчага төште. Ә анда — алмагачлар. Әле уңышы җыелмаганнары да бар. Алмалар, ай яктысында ымсындырып, болай да тормышта кызык, мәзәк эзләп йөрүче чуар күңелле, диңгезне дә тубыктан гына дип уйлаган гамьсез солдатларны үчекләп, зур-зур булып шәйләнәләр, тирә-юньгә хуш ис тараталар. Ул ис борыннарны кытыклый, башны әйләндерә, йөрәкне җилкетә...

Арадан кемдер:

— Алмалары шәп бугай, — диде.

Ул әйтте дә тынды. Берәү дә аңа җавап кайтармады, әңгәмә куертмады. Ләкин яшь, дәртле күңелләргә откы салынды. Димәк, тәвәккәлләргә кирәк. Туктадылар. Берничә секунд бер-беренә карашып тордылар.

— Кем кала? — дип сорады Гена һәм Васяга таба борылды.

Вася, үпкәләгән сыман, моңсу гына әйтеп куйды:

— Нәрсә сорап торасыз инде.

Аның да җаны бар, аның да, үз авылындагы шикелле, егетлеген күрсәтәсе килә. Ләкин монда шартлар бүтәнчәрәк шул.

Әйе, чыннан да, ике метрга якын биеклектәге утыртма койма Вася өчен коелмаган иде. Җепсә турыннан, һәр тактага кадак белән эләктереп, нәзек тимерчыбык тарттырылган. Димәк, кубарып маташу файдасыз: вакыт сузыла, тавыш та чыгарасылары килми.

Васядан кала барысы да, койма аша сикергәндә баштан төшеп калмасын өчен, козырек өстендәге тар каешын ияк астына төшереп, фуражкаларын батырып киделәр.

Үзе өчен кулай булмаган койма янына килеп, Вася, иелеп, кулларын җиргә терәде. (Күрәсең, аларның бакча басуы беренче генә түгел иде.) Гена куллары белән койма башына ябышты, Васяның сыртына менеп басты да «ә» дигәнче гәүдәсен бакча эченә ташлады. Аның артыннан Ирек тә шулай итте. Ковалев белән Габделнурга Васяның кирәге булмады — алар үзләре койма аша бакча эченә сикереп төштеләр.

Бакчада хуш ис — көзге алма исе таралган. Куллар, тиз-тиз хәрәкәтләнеп, алма җыя. Әле коелмаган яфраклар арасыннан алмалар күренми (чөнки ай каршы яктан яктырта иде), шуңа күрә бармакларыңны өскә таба каратып кулыңны күтәрәсең һәм, җаныкайлар, үзләре үк учка килеп керәләр: берәмләп тә, икешәрләп тә... Яшь кызларның каты, хуш исле күкрәген тоткан шикелле рәхәт булып китә... Тик аерма шунда гына: болар салкынча һәм... тоттырмаска тырышмыйлар, тоткач, чәбәләнмиләр.

Солдат кешегә күп кирәкмени — галифе кесәләре тулды, куенга берничә шуды.

— Егетләр, китәбез, — диде Гена, пышылдап.

Тиз-тиз чыгу ягына борылдылар. Бу яктан Васяның кирәге юк, җепсәләр ярдәм итә. Ирек күтәрелде дә юк булды, аның артыннан — Гена; Ковалев та күз ачып йомганчы теге якка очып төште.

Габделнур, үз-үзенә артык ышанып (янгын сүндерү командасында хезмәт иткән, спортның янгын сүндерүгамәли төре буенча икенче разрядлы солдат өчен койма аша сикерү — төчкерү кебек үк гадәти нәрсә), иң азакка калды. Ул койманы бер талпынуда алдырачак бит.

Койма башына ябышып, сикереп чыгыйм дигәндә генә, уң аягы караңгыда нәрсәгәдер эләктеме, кемдер тоттымы — ул авырайды. Борылып караса, тавыш-тынсыз гына килгән бер бәләкәй эт аның кирза итеген арттан, тубыктан югарырак каптырган икән. Габделнур аягын кисәк селкүгә, итеге эт авызыннан ычкынды. Шул секундта ук солдат сул аягы белән ырлаган этнең башына тибеп җибәрде, тегесе чинап өрергә тотынды. Солдат, моменттан файдаланып, койманы сикереп чыкты, һәм егетләр дәррәү торып йөгерделәр.

Артта, бакчада, ир-ат тавышы ишетелде:

— Тотыгыз, тотыгыз каракны... Фас, Тузик, фас...

Тау башына менеп җиткәч туктадылар.

Ирек көлеп артка карады.

— Фас түгел, һәс, диген син аңа, мәхлук сарыкка.

— Булыр мәхлук, — диде Габделнур. — Ул бит минем итекне әрәм итте.

— Ничек? — дип сорады Гена.

— Теше белән. Бәләкәй генә нәрсә, шыпырт кына килгән дә — цап! Шуңа тоткарландым.

— Нәрсә, нәрсә?

— Каяле...

Габделнур вакланып тормады, кайткач карарбыз, дип кул гына селтәде.

— Михнәтең каты булса, капканың татлы булыр, — диде Ирек, авыз ерып. — Алмаң тәмлеме соң?

— Ярыйсы, ашарлык.

Һәрберсе Васяга алма бирде. Ашый-ашый, кычкырып сөйләшә-сөйләшә алга атладылар.

— Карак өчен иң мөһиме — вакытында табан ялтырату, — диде Ковалев, уенын-чынын бергә кушып. — Мондый чакта җитез булырга...

— Син һәрчак җитез — рас, рас и на матрас, — диде Вася, аны үчекләп. — Бу алма синеке бугай, кортлысын биргәнсең. Алма танымыйсың икән.

— Минме? Мин Украинада хезмәт иттем. Ә анда бөтен җир алма белән тулган.

Егетләр төнге тынлыкны яңгыратып көлделәр. Әле басуга чыгып җитмәделәр, сул якта үз йортлары белән торучылар — шәһәр читендә яшәүчеләр бистәсе иде.

Бу тәбәнәк өйләр арасына ни хикмәттер ике катлы йорт та кереп кысылган. Габделнурга ул абыйлары белән бергә Чупайда яшәгән ике этажлы таш баракны хәтерләтте. Моның янында озын торбасы кукраеп утырган котельня да бар. Түгәрәк формадагы су башнясы да авыл өйләреннән бер башка өстен булып масаеп утыра. Йортлар артында агачлар белән капланган калкулык. Ә уңда тәбәнәк агачлар үсеп утырган межа.

Сулдагы ихаталарда берничә эт ярсып аваз салды.

— Болар бакча эчендә калган эткә дә дәрт биреп өрәләр инде, — диде Ирек.

— Үзләренчә пролетар теләктәшлек, — дип җөпләде Габделнур.

Шатыр-шотыр алма кимереп, уңышлы аудан соң җанланган сунарчылар кебек, күтәренке кәеф белән бер төркем солдат шәһәрдән ераклаша барды.

Каршыга килгән сирәк машиналарда да, күзгә бәргән ут көлтәсендә дә аларның эше юк; арттан килүчеләр төнлә барыбер утыртмас иде. Машинасы да сирәк. Алар бит бишәү. Шулай да берсенә «тавыш» биреп карадылар, җиңел машина — «Победа» булып чыкты, выжлап кына үтеп китте, кабинасы тулы кеше иде. Аннан соң инде бөтенләй кул селтәделәр: артка борылып карамас булдылар.

Бүген-иртәгә өенә кайтасы солдат ни генә сөйләшсә дә, ахырда сүз сөреше туган төбәгенә таба юнәлеш ала... Аннары кызлар тирәсенә күчә...

Караңгы, куе зәңгәр күк йөзендә түм-түгәрәк ай йөзә, янында бихисап йолдызлар чекердәп, җем-җем итеп торалар. Шәһәр эчендә боларга әллә ни игътибар итмисең, ә монда үзеннән-үзе алар күңелне җәлеп итә.

Габделнур берөзлексез иптәшләре белән әңгәмә корып сүзгә катнашса да, төнге хозурлыкка сокланып барса да, аның үз фикере башында формалаша һәм солдатны һәрдаим бимазалап тора.

Габделнур үзе атлый, үзе уйлана. «Менә аны кечкенәдән үк кеше әйберсенә тимәскә өйрәттеләр. Ләкин, ни хәл итәсең, малай кеше малай кеше инде, ул чакта да шуклыклары булгалап торды. Сирәк, әмма булгалады. Менә тагын, бу юлы инде акыл утырткан — егерме ике яшьлек, җитмәсә, солдат — ил сакчысы. Ә шулай да яшьлек дәрте бар бит. Аннары, биш солдатның дүртесе бертөрле гамәл кылганда, син генә бүтәнчә эшли дә, читтә дә кала алмыйсың, юк, мин бу авантюрага катнашмыйм, дип баш тарту килешми. Хезмәттәшләрең дөрес аңламаслар. Хәер, без бит агач сындырмадык, мародерлар кебек талап-тиенеп йөрмәдек, ачкүзләнеп капчыкка тутырмадык, фәкать берничәшәр генә алма урлап чыктык». Үзләрен ничек кенә акларга тырышмасын, менә шул, «урлап» дигәне бераз күңелен тырнады Габделнурның. Ярар инде, буласы булган. «Артык баш ватма, урламадык — сорамыйча гына алдык», — диде егет үз-үзенә һәм дуслары әңгәмәсенә кушылды.

**43**

Лагерьга тагын яшьләр килде. Аларны, мунча кертеп, өр-яңа солдат киеменә киендерделәр: гимнастерка белән галифе, пилотка, кирза итек бирделәр, киң каеш будырдылар.

Гена, дусларын ияртеп, мунча тирәсендә кайнашты һәм арурак чалбар, күлмәк, костюмише нәрсәләрне яшьләрне киендерүче старшинадан сорап алды. Старшина үзе дә күзе төшкән киемле егетләрне алдан ук чамалап-күзләп тора. Монда кием-салымның иге-чиге юк — барысына да җитәрлек. Аларны соңыннан, сүсәргәнме, кияргә ярарлыкмы — аралап тормыйча, барыбер өеп яндыралар.

Гена белән килгәннәр барысы да, култык астына шактый «товар» кыстырып, дача йортына кайттылар.

— Минем белән кайсыгыз бара? — дип сорады Гена, алып кайткан чүпрәк-чапракны идәнгә ташлап.

— Кая?

— «Сорочка»га, базарга, боларын сатарга, — диде Гена һәм идәндә яткан иске-москыны аралый башлады. — Үзегезгә ошаганнарын сайлап алыгыз, гражданкада беренче чорда ярап куяр.

Ул шулай дигәч, һәрберсе, гомуми өемнән кулга тотардай ни дә булса алып, читкә куя башладылар.

— Ишәкләрегезне алыгыз, үземнекен атам, — дип шаяртты Ирек һәм әлеге мәгълүм мәзәкне сөйләп бирде. Генаның тәкъдиме җавапсыз калган иде.

— Мин барам, — диде Габделнур, ярыйсы гына күренгән бер кара костюм һәм шакмаклы күлмәк алып.

— Мә, кепка да сиңа булсын, — диде Гена һәм аңа ак фуражка сузды.

Габделнур, дөресен генә әйткәндә, Казанны әле юньләп белми, ә «Сорочка» дигән базар хакында беренче ишетүе иде. «Сорочинская ярмарка» дип кайдадыр укыганы бар иде. Шул микәнни? Ләкин сорарга кыенсынды. Ә менә яңага омтылыш, күп беләсе килү теләге көчле булганлыктан, ул Гена белән барырга ризалашты. Апаларына да сугылып чыгу иде нияте.

Якшәмбе көнне, капитан Машкиннан увольнительный кәгазе алып, Габделнур белән Гена базарга юл тоттылар. Сатасы әйбер-караны, кичтән үтүкләп, «адәм рәтенә керткәннәр» иде.

Урман эчендә:

— Әнә ур сикерә, — диде Гена, агач башына төртеп күрсәтеп.

— Нәрсә, нәрсә?

— Тиен, — диде Гена, көлеп. — Алдадым. Бу урманда бер җәнлек тә юк, бигрәк ярлы.

Сары яфраклар коелган сукмактан турылай гына олы юлга чыктылар. Моңсу каеннар, аларга хәерле юл теләп, тымызык җилдә тирбәлгән озын чукларын чайкалдырып озатып калдылар.

Көн матур. Кәефе күтәренке. Габделнур җырлап җибәрде:

Әйдә, җаныем, базарларга,
Одеколон алабыз;
Тор, җаныем, таңнар ата,
Үбешә алмый калабыз.

— Аңламадым, — диде Гена, бик бирелеп, дикъкать белән тыңласа да.

Дусты тәрҗемә итте. Көлештеләр. Ходайның рәхмәте — озак көтмәделәр. Бер миһербанлы шофер аларны «ЗИЛ»ына утыртты.

Сентябрь ахыры җиткән. Кояш саранлана башласа да, әле аңа зарланырлык түгел: лагерь белән шәһәр арасындагы басу-кырлар яп-якты, урылган игеннең камыллары сапсары булып ялтырап ята, сөрелгән җирләр Габделнурлар авылындагы кебек чем-кара түгел түгелен, шулай да киләсе елга муллык вәгъдә итеп күпергәннәр. Урман читендәге вак куаклар да, күккә ашып, биек-биек булып үскән һәм эчтәрәк утырган агачлар да инде саргайган. Миләш яфраклары тәлгәш-тәлгәш булып салынып төшкән җимешләре төсенә — кызгылтка маныла башлаган.

...Шәһәр эчендә әллә ни үзгәреш юк: шул ук трамвай-троллейбуслар, автобуслар, биек таш йортлар, каядыр ашыгучы яки ялкау гына гомер сөрүче кешеләр... Хәер, агачлар монда да саргайган.

Компрессор заводы янынннан үттеләр.

— Бервакыт мин үзебезнең частьта бередә эшләнгән компрессор күрдем, — диде Габделнур. — Иллә рәхәт тә булып китте инде. Якташларымны очраткандай сөендем. Корпусына кулымны куеп сыйпап тордым. Күзләр яшьләнде. Егетләр көлделәр дә әле үземнән.

— Син бераз сентиментальрәк, — диде Гена, гәптәшенә сокланып. — Хәер, мин үзем дә, бая басу-кырлар күргәч, әллә нишләп киттем, телдән яздым. Яз җырын көз тәмамлый, диләр бездә. Тизрәк кайтасы да эшкә керешәсе иде. Өч ел буе мондый тормыш туйдырды. Чүкечнең авыр икәнен бер сандал гына белгән кебек, мин дә үзем генә беләм. Бигрәк тә минеке шикелле һөнәр иясенә бу тормыш — мәгънәсез.

— Илне сакларга кирәк бит кемгә булса да.

— Анысын мин аңлыйм, — диде Гена, авыр сулап. — Барыбер... гаделсезлек күрәм. Миңа иген игәргә булсын... Чабатага итек пар түгел... Ә синең уйлаганың бармы: безнең белән кемнәр хезмәт итә?

— Таза, сәламәт егетләр.

— Ә кем балалары? Берәр завод директорының, обком дип әйтмим дә, райком секретаренең кадерле баласын күрдеңме?

— Анысы дөрес — юк. Ә бит аталары чат саен вәгазь укый: яшьләрнең ватанпәрвәр булуын тели, патриотизм хакында лаф ора, идеалларга тугрылык таләп итә... Бәлки, алар бракоделдыр, малай ясый алмый торганнардыр.

— Ясамас. Әле ничек кенә... Монда берәү ялгыш килеп эләккән иде, КДН эчә башлады да комиссовать иттеләр. Үзем күрдем дару эчкәнен, — диде Гена, ачу белән.

— Бездә дә берәү астына җибәрә башлады, ә икенчесе, постта торганда, үзенә атты.

— Үлдеме?

— Үләр сиңа... Колагына әз генә эләккән. Юри эләктергән, билгеле. Кабат күрмәдек без аны. Кем баласы икәнен дә белә алмадык...

Габделнур, автобуста кысылып барса да, Гена әйткәннәрне уйламыйча булдыра алмады. Дөрес, аның белән хезмәт иткәннәрнең бөтенесе дә авыл малайлары түгел, Мәскәү, Ленинград кебек мәшһүр кала егетләре дә бар иде. Ул аларның фамилияләрен, күбесенең исемнәрен дә хәтерендә саклый. Ләкин нигәдер олы түрә баласы дип әйтерлекләре истә калмаган, күрәсең, булмаган. Мәскәүдән Лавров Володя, шофер иде, әти-әнисе — төзүчеләр, Постнов Вячеславның әнисе... ул да заводта мастер гына иде шул. Тресков Горький шәһәреннән, үзе — шофер, җиңел машина чыгаручы завод эшчеләре династиясеннән. Литвадан килгән егетләрнең байтагы хуторлардан, икесе Каунастан, берсе Шауляудан — гади халык балалары. Егетләр хәзер кайда, нишли икән бу минутларда... Юк, әле берсе дә китмәгәндер, дембель — соңрак...

...Габделнур, кабыргасына Гена төртүгә, уйларыннан аерылды. Төшәргә кирәк икән.

Уң якта авыл тибындагы поселок, аның артында, еракта, тау хәтле балчык өемнәре. Алар әле соңгы елларда гына актарылып өелгән булса кирәк. Габделнурга алар Чупай тавында эшләгән елларны, андагы тау-таш өемнәрен хәтерләтте. Анда да карьер, таш катламы инде унике метр тирәнлектә җир астында ята һәм өсте менә шушы рәвешле көчле экскаваторлар, бульдозерлар белән актарылып, кыш көне шартлатылып, читкә этәреләә иде.

Базар эчтәрәк, сул кул якта икән. Аңа әле шактый барасы. Юл аркылы чыктылар һәм авыл йортлары кебек өйләр арасыннан, кечкенә сай елга аша салынган тар басмадан үтеп, тигезле-тигезсез бер урынга килеп җитте-

ләр. Биредә халык мыжгып тора: өзлексез алга таба агыла, тулгана, кайберәүләр каршыга килә, койма янында өелешеп торалар, читтәрәк бер-ике машина, мотоцикл күренә. Капкадан базар эченә керделәр, монда да мәхшәр: койма тирәли әйбер сатучылар тора, ни-нәрсәләрен койма башына да элгәннәр, кулларында тоталар, катыргы кәгазьләр өстенә тезеп җиргә салганнар. Сүзләре аңлашылмаган сөйләшү тавышлары кәстрүлдә быгырбыгыр аш кайнавын хәтерләтә, һәр тарафтан колакка кычкыру, сатулашу авазлары чалына, кайдадыр бер читтә гармун тарталар.

Габделнур түзмәде:

— Әллә гармун да саталармы? — дип сорады.

— Монда атаң белән анаң гына юк.

Әйбер дә күп, кеше дә. Халык чуар: картлар-карчыклар, абый-апалар, яшьләр... Кыскасы, бөтен Казан халкы монда җыелган диярсең.

Габделнур үзалдына елмайды, чөнки авылда яшьләр гармунга кушылып суза торган бер җыр исенә төште: «Җимәгүрләр толчокта, кайгырмыйлар мал юкка, кайгырсалар кайгыралар тәмәкеләре юкка». Менә нинди икән ул толчок дигәннәре!

Гена Габделнурның, телдән әйтмәсә дә, кая барасы килүен чамалады. Әйберләрен чыгарырга ашыкмады, ары китте. Гармун тавышлары отыры якынайды. Алар монда берничә икән: ике-өч тальян, хромка, баян, кыңгыраулы саратски да бар. Кемнең нинди көй уйнаганын аерырлык түгел, бөтенесе берьюлы тарта, товарын күрсәтә.

Габделнур иң кырыйдагы тальян янында туктады. Олы яшьтәге абзый, кыска юантык бармакларын җитез генә йөгертеп, бер озын көй уйный иде. Күренеп тора: кайчандыр оста гына гармунчы булган яки үзе гармун ясаучы-төзәтүче.

Ул, каршында ике солдат торуын абайлап, көен тәмамлады, күрекләрен кысып, гармунын ике куллап тотып тора башлады.

— Солдатларга гармун кирәкме әллә?

— Юк, абый. Әйбәт уйныйсың, тыңларга гына килдек.

— Шаяртма, солдат, — диде абзый һәм, сул кулы белән тар мыегын сыпырып, хәйләкәр елмайды. — Синең кебек егетләр гармун янында болай гына тормыйлар. Уйныйсың киләме? Мә.

Абзый, сул кулы белән уң як иңбашыннан каешын алып, гармунны Габделнурга сузды.

Бик матур иде тальян: буялган-бизәлгән, пөхтә эшләнгән, җизләре ялтырап тора, телләре перламутр яшел төстә, бакалары калай, биш планкалы...

Габделнур кыстатып-ялындырып тормады, каешын җайлап киде дә, уйнап та җибәрде. Татар халкының дәртле, һәркемгә таныш, бөтен кеше дә ярата торган «Баламишкин» көен сузды. Бу арада бик тупас физик эшләр башкармаганга, бармаклары җитез йөгерә, өлгер һәм көйне дә дөрес тота иде. Тирә-яктагы гармун сатучылар да солдатка ихтирам йөзеннән уйнаудан туктадылар. Көй агылды да агылды, аны биек такта койма да тотып кала алмый, стенадай тыгыз кеше ташкыны да туктатырлык хәлдә түгел. Ә өскә таба — сирәк болытлар йөзгән зәңгәрсу күк йөзенә —ул, язгы сабан вакытында яңгыраган тургай моңы кебек, бернинди киртәгә тап булмыйча өзлексез күтәрелә. Габделнурның үзенә дә рәхәт иде. Ләкин артык мавыкмады, кеше әйберсе белән озак файдалана алмыйсың. Тагын бер көй уйнагач, ул туктады. Гармунны хуҗасына бирде.

— Рәхмәт, абый.

— Үзеңә рәхмәт, — диештеләр аны сырып алган яше-карты, чөнки кеше шактый күп җыелган иде инде.

Габделнур белән Гена кузгалып киткәндә, абзыйның гармунын сатулаша да башладылар.

Күрәсең, Генаның монда беренче тапкыр гына килүе түгел. Ул капкадан ун-унбиш адым гына читтәрәк торган бер толчокчы апа янына килеп исәнләште, колагына нидер пышылдады, алып килгән әйберләрен берәм-берәм аның беләгенә салды һәм, тиешле әҗерен алып, китеп тә барды.

— Булды, — диде ул Габделнурга.

Алар капкадан чыктылар, кайту ягына борылдылар. Басмага җитәрәк, бер читтә озын итәкле күлмәк, калын йон кофта, ачык изүле куртка кигән ике чегән хатыны бер кызны кысрыклап, ай-ваена карамыйча тарткалапйолыккалап азапланалар иде.

Моны ике солдат берьюлы күреп алды. Габделнур дустына дәште:

— Анда теге кызны кыерсыталар, ахры.

— Әйдә барыйк әле, — диде Гена, аның тел төбен аңлап.

— Киттек.

Гена, тавышын юри калынайтып:

— Нәрсә бар монда? — дип сорады.

Авызына папирос капкан, чуар яулыгын чөеп бәйләгән чегән хатыны кул селтәде:

— Узып кит, чибәр егет, берни дә юк.

— Барыгыз, бар, служивые, — диде икенчесе дә.

Габделнур карашын кызга төбәде, яшьле күзләреннән, төс-битеннән чамалап, татарча дәшәргә булды:

— Нигә елыйсың?

— Ун сум акчамны алдылар, — диде кыз, яклаучы булуга сөенеп, әмма елавыннан туктый алмыйча. — Хәзер алкамны сорыйлар. Бирмәсәм, бозым белән куркыталар.

Зәһәр хатыннарның тиз генә бирешергә, кулга керергә торган табышны ычкындырырга исәпләре юк иде, билгеле, алар кызга ябырылдылар: берсеннән-берсе уздырып такылдарга, көчек кебек чәңгелдәргә тотындылар.

— Мы тебе гадали... Баккан өчен алкамны да бирәм, дидең... Акчаңны үзең чыгарып бирдең... Мәрхәмәтле кешеләр, нәрсә инде бу? Без — намуслы чегәннәр!.. Ә сезгә ни кирәк? Үзебез аңлашырбыз...

Алар бичара кызга алтын йөзек кигән карасу нәзек бармаклары белән чытырдатып ябышканнар. Ләкин солдатларның каты торуларын һәм китү исәпләре югын күргәч, кулларын бушаттылар. Шуны гына көткән кыз, кисәк тартылып, алардан ычкынды һәм солдатларга таба омтылды. Аннары, икесенең уртасына ук кереп, беләкләренә чат ябышты.

— Зинһар, коткарыгыз! — дип ялварды ул, әле һаман сулкылдап. — Булышыгыз, абыйлар, ташлап китмәгез!

— Курыкма, — диде Габделнур кызга һәм Генага баш какты. — Киттекме?

Солдатларның берсенең калын кара кашлары җыерылган, йөзе усал, рәхим-шәфкать көтә торган түгел, икенчесе аннан бер башка калку, киң җилкәле — анысының да чыраенда иман нуры юк шикелле тоелды чегәннәргә. Күпне күргән, байтак матавыклардан исән-имин чыга торган булсалар да, солдатларга каршы кабат сүз әйтергә базмадылар. Аянычка каршы (алар өчен), халык агымына ияреп, нәкъ шул минутта тагын бер хәрби узып бара иде. Ул, бер хатын-кыз белән янәшә атлаучы офицер, солдатларны күреп туктады, кеше ташкыныннан аерылып, алар янына килде.

— Солдатлар, нәрсә бар?

Тавышка борылып караган Габделнур белән Гена (алар халык йөргән сукмакка арт белән торалар иде, офицерның килгәнен күрмәделәр) башта бер мизгелгә югалып калдылар, аннан, тураеп, үрә катып честь бирделәр.

— Иптәш майор, менә бу кызны талыйлар, — диде Гена, йомшак тавыш белән. — Ярдәм итәргә булдык.

— Ул сезнең танышыгызмы?

— Юк, — диде Гена.

Габделнур да сүз кыстыруны кирәк тапты:

— Иптәш майор, барыбер кызганыч.

Офицерга хәлне сөйләп бирделәр. Ул чегән хатыннарына карап алды да солдатларга:

— Яхшы иткәнсез, — диде. — Барыгыз. Мин хәзер милиция җибәрермен.

Майор хатынын култыклап китеп барды. Аның артыннан ике солдат белән кыз да кузгалдылар.

Чегән хатыннары, «мал»ның кулдан ычкынуына җен ачулары чыгып, аты-юлы белән сүгенеп, каргап калдылар:

— Эт керәнен тыкмаган җиргә борыныгызны тыгасыз...

Кыз су аркылы салынган тар басмадан чыкканда да Габделнурның кулын ычкындырмады. Юл киңәйгәч, тагын икесен дә култыклап алды. Автобус тукталышына барып җиткәч кенә алардан аерылды.

— Рәхмәт инде сезгә.

— Ачыгавыз булма, — диде Гена, төксе генә. — Алар янында бөтенләй туктыйсы юк. Туктадыңмы — беттең, алар сөлек кебек ябыша.

— Хәзер аңладым инде, сабак булыр.

Кыз, кат-кат рәхмәтләр укып, килеп туктаган автобусның алгы ишегеннән керде, солдатлар — арткы ишектән.

...«Вузовец» кинотеатры каршында автобустан төшкәч, Габделнур Генага:

— Минем монда апалар бар, — диде. — Берәр нәрсә алып, кереп чыгасы иде.

— Була ул, — диде Гена һәм, дустына күз кысып, тамак астына чиертте. — Безгә барыбер кибеткә керергә кирәк.

Алар, «Кольцо»дагы кибетләрнең берсенә сугылып, Габделнурның апаларына — күчтәнәч, ә үзләренә берничә шешә алдылар. Соңгыларын, яхшылап төреп, сумка эченә яшерделәр. Шушы арада Гена янына баласы белән хатыны киләсе икән, аларга тәм-том алды.

— Минем себерке җыеп саткан акча да бар әле, — диде ул, сере белән уртаклашып. — Иренмәсәң, «котелогыңны» эшләтсәң, ничек тә җай чыгарырга була. Төлкене хәйлә туйдыра дигән сыман.

Габделнурга дустына карап соклanudан башка чара калмады, аңа булган хөрмәте бермә-бер артты.

Кызганычка каршы, Габделнур апаларын өйдә туры китерә алмады; күчтәнәчләрен күршеләренә биреп калдырды.

Юл читеннән терек-терек җәяү атлаганда, Гена бераз дәшми барды да әйтеп куйды:

— Август аенда Җәлил турында күп сөйләделәр. Сезнең халыкның горурлыгы.

— Әйе.

— Ә син беләсеңме, безнең дә дөньяга билгеле атаклы бер кешебез бар. Дөрес, ул каһарман да, шагыйрь дә түгел, ә сынчы.

— Кем ул?

— Эрзя. Бу — псевдоним, үз фамилиясе — Нефедов. Мордва халкының бер тармагын эрзя дип йөртәләр бит, шуны алган. Әле революциягә хәтле үк Италиядә һәм Франциядә үз әсәрләрен күргәзмәгә куйган. Аны «Мордва Родены» дип атаганнар. 1926 елны Латин Америкасына китә. Аргентинада таштан да каты, әмма бик матур альгарро дигән агачны файдалана. «Лев Толстой», «Бетховен», «Әнием портреты», «Ева» һәм башка әсәрләре белән дан казана. Гаҗәеп шәп итеп тегендәге чибәр кызларның сыннарын ясый.

— Шәп дигәнең нәрсәне аңлата? — дип елмайды Габделнур.

— Аңлыйсың инде, эротик кыяфәттә — шәрә килеш, — диде Гена, күз кысып. — Ләкин эш анда түгел, эш — осталыкта, ул бервакытта да чикне узмаган, натурализмга төшмәгән. Аның иң яраткан сыны — «Моисей». Аны кебрачо агачыннан ясаган, авырлыгы ике тонна. Моның белән ул үзенең дөньяга карашын белдерергә теләгән. Ул гаять көчле тәэсир калдыра. Аңа өч яктан карасаң, ул өч төрле кыяфәттә сыман күренә... «Моисей» скульптурасына бер америка бае йөз мең доллар тәкъдим итә. Ул заманда бу гаять зур акча. Ләкин Степан Дмитриевич сатмый, 1950 елны байтак сыннары белән бергә, пароходка төяп, иленә алып кайта. Ул хәтта Лион исемле этен дә читтә калдырмый.

— Димәк, ул да патриот.

— Әйе. Атаклы совет скульпторы Коненков аны үзеннән өстен санаган... Менә шулай, ялгам*, бәп-бәләкәй кырмыска да зур итеп таулар өя...

Һәм Гена бик озак үзенең мәшһүр якташы турында сөйләп кайтты.

Лагерьга җитәрәк Габделнур:

— Гена, син нишләп кызлар янына чыкмыйсың? — дип сорады.

— Ә нигә кирәк алар миңа? Хатын ике айга бер килеп китә... — диде Гена, серле елмаеп, аннары көлеп әйтте: — Ул килгән саен бер-ике пар киез итек тә алып килә әле.

— Нәрсәгә?

— Сатарга. Безнең Орозбие авылында борынгыдан бөтен кеше итек баса.

— Син дә беләсеңме?

— Билгеле, — диде Гена, горурлык белән һәм янә баягы сүзгә кайтты: — Бүген, бәлки, тагын кызлар килер. Чыгасыңмы?

— Әгәр мине сораучы булса, авырый, диярсең.

Генаның көндез әйткән сүзләрен Габделнур Ирекккә дә җиткергән иде.

Ул да Ковалевка:

— Мин дә авырыйм, — диде.

Ковалев, батыраеп, берүзе чыгып китте.

Ә өч-дүрт көннән аның сөмсере коелды, чыраен сытып йөри башлады. Аны нәрсәдер борчый иде. Үзе әйтмәсә дә, фәһемле Генаның үткер күзеннән берни дә яшерә алмыйсың икән.

— Эләктеңме? Мин бит сине кисәттем. Тыңламадың. Хәзер үзеңә үпкәлә.

— Нәрсә булды? — дип сорады Габделнур, төшенеп җитмичә.

Ирек көлде дә аңа татарча такмак әйтте:

— Тамчы, там, там, тамуыңны яратам... Менә нәрсә булган.

Эшнең нидә икәнен белгәч, Ковалевка киңәшләр бирә башладылар. Вася да сүз кыстырды:

— Урамга чыкканчы берәр нәрсә белән юасың калган.

— Нәрсә белән? — дип сорады Ковалев, төксе генә. — Син дә сөйләшеп торган буласың.

— Безнең авылда теләсә кем кереп йөри торган бер хатын бар иде, — диде Вася, елмаеп. — Минем дә керәсе килә, ә үзем шикләнәм. Шуннан «Тройной» одеколоны белән юдым да... тәвәккәлләдем. Ай, син нинди кайнар, дип, үземне иркәләде дә әле.

Ковалевтан кала барысы да көлештеләр.

Ләкин Гена аларны тиз туктатты:

— Башка чарасы юк, капитан Машкинга әйтергә кирәк. Булышса, ул гына булышыр. Җаен табар.

Һәм шулай иттеләр дә. Ковалев көн саен Казанга, дәваланырга йөри башлады.

**44**

Беркөнне, ашханәдән чыкканда, Габделнурга яшь солдатлар сафы яныннан үтәргә туры килде. Өр-яңа, тезләренә үк төшеп торган озын итәкле яшел гимнастерка киеп, аның өстеннән йолдызлы сары аеллы киң каеш буган солдатларның галифе чалбарлары ике якка капчык шикелле бүлтәеп торалар; алар чәчләре машинка белән төптән үк алынган, колаклары тырпаеп торган зур башларына кызыл йолдызлы яшькелт пилотка батырып кигәннәр; киң кунычлы өр-яңа кирза итекләрен мул итеп ваксалаганнар. Үзләре ашханә каршына килеп туктаганнар да, аннан карт солдатлар һәм алдарак кергән икенче бер ротаның чыгып беткәнен көтәләр иде. Сафны ике шеренгага тезеп бастырып куйган командирлары аларга вәгазь укый. Ыспай киемле сержант алардан икеөч адым читтәрәк тора, әле уңга, әле сулга карап ала: хәрби кием аның зифа буена шулкадәр ятып тора, гүяки ул туганда ук шул кием белән дөньяга килгән: пилоткасын турылап кимәгән, ә кыңгыр салган — баш түбәсендә генә эләгеп тора һәм менә-менә төшеп китәр кебек, ләкин ул ябышкан, ахры, селкенми дә. Сержантның гимнастерка итәге бик кыска (чөнки ул йә кисеп алына, йә күтәртеп каеш астына кыстырыла), чалбарының га-

лифеләре бүлтәеп түгел, ә аска таба тартылып, ботына сыланып диярлек торалар. Аның да үзенә күрә хәйләсе бар: балак очына бармак бите киңлегендәге кереш тегеп куясың, һәм кигәндә ул табан астында кала; итегенең кунычларын җыерып куйган, шуңа күрә алар гармун күреген хәтерләтә, итек йөзе көзге кебек ялтырап тора, шик юк, кичтән үк гуталин белән майлап куя да, иртән, бераз су бөркеп, озаклап щетка белән чистарта булыр. (Мондый итек кигәч, кызлар каршына басып, бер аягыңны алгарак сузсаң, итәк асты көзгедә чагылгандай аермачык күренә инде.) Күрәсең, бу сержант үз-үзенә бик таләпчән һәм көяз йөрергә ярата. Хәер, шулай булмыйча, әле аның тагын бер ел хезмәт итәсе бар бит.

Габделнур, устав кушканча, сержантның артыннан әйләнеп узып китмәкче иде, шулчак сафтан кемдер аңа исеме белән дәште:

— Габделнур абый!

Егет туктады, сафтагы солдатларга карады, ләкин таныш кеше шәйләнмәде. Ул, кире борылып, тавыш килгән якка бер адым атлагач кына икенче рәттә бер солдатны таныгандай булды. Озынча ябык йөзле, әле бик куе булмаган кара мыеклы бер солдат аңа карап елмаеп тора иде.

— Әнир, синме?

— Әйе.

Габделнур сержант янына килде.

— Картлач, минем якташ егет бар икән. Сафтан чыгарга рөхсәт ит әле.

Сержант, үзенә шулай олылап мөрәҗәгать итүләренә күңеле булып, берсүзсез рөхсәт бирде. Күрәсең, ул әле солдатларның фамилияләрен хәтерендә калдырмаган (гаеп түгел, яңа гына килгәннәр бит), егеткә бармагы белән төртте.

— Рядовой, сафтан чык.

Габделнур авылдаш егетне очратуга бик шат иде. Ләкин иркенләп гәпләшеп тора алмадылар, бер-ике авыз сүз сөйләшүгә, тегеләргә команда булды:

— Напра-во! В столовую шагом марш!

Солдат өчен ризыклану — иң кирәкле нәрсә, иң мөһим гамәл. «Ашханәгә!» дигән боерык — иң кадерле, көтеп алынган сүз. Шуңа күрә Габделнур егетне озак тоткарламады.

— Бар, соңга калма, чыккач иркенләп сөйләшербез. Мин сине эзләп табармын.

Әнир ашханәгә кереп китте, Габделнур үз юлында булды. Аны бер читтә Гена көтеп тора икән.

— Якташмы әллә?

— Авылдаш.

Алар сөйләшә-сөйләшә әкрен генә кузгалдылар. Ләкин Габделнурның күңеле алгысыган, уйлары яшь солдат — авылдашы тирәсендә бөтерелә иде. Ул хәрби хезмәтнең беренче чорында ашау җитмәвен үз башыннан кичергән кеше: Кронштадтта карантин узганда плацта дүртәр сәгать сафта йөрделәр (аяклары ут яна, төнлә йоклап китә алмыйча җәфаландылар), шуның аркасында — энергия күп сарыф ителү нәтиҗәсендә — иң борчыганы, бәгырьгә тигәне өзлексез ашыйсы килү иде.

— Гена, — дип, Габделнур туктады һәм дустына карады, — синең пешекче белән дуслык ничек?

— Әйбәт, — диде тегесе һәм елмайды. — Үзең беләсең: повар белән дус булу — сәламәтлекнең нигезе. Нигә сорыйсың?

— Авылдашка берәр порция ДП алып бирсәк?

Гена күп сөйләшеп тормады.

— Әйдә, — дип кире борылды һәм көлеп өстәде: — Наполеон нәрсә дигән әле: «Әгәр халык үз армиясен ашатмаса, чит ил армиясен туендырачак». Ашатыйк егетләрне.

Алар ашханәгә кергәндә, тирән эчле алюмин җамаякларда алюмин калаклар берөзлексез шакы-шокы килеп, үзенә бер күңелле симфония (үзе солдатта булмаган кеше аны какофония дияр иде) яңгыраталар иде. Шәрә башлары түбән иелгән солдатлар, таза кулларындагы ипине мулдан кабып, хаптыр-хоптыр итле макарон сыпырталар — берөзлексез колакларын уйнаталар.

Гена белән Габделнур кухня тәрәзәсе — амбразура каршына килеп бастылар. Гена, пешекче солдатны чакырып, колагына нидер пышылдады. Тегесе, хәзер, диде дә, бераздан, алюмин миски тутырып, макароны пофлотски бирде. Аның макароны күренми диярлек, өсте тоташ ит иде.

Габделнур рәхмәт әйтте һәм, савытны кулына алып, артына борылды, залдан авылдашын эзли башлады. Ул аны уртадагы рәтләрнең берсендә күреп алды, янына килеп, каршына миски түбәләмә итле макарон куйды.

— Үзебезнең баштан узган. Иркенләп аша.

— Рәхмәт, Габделнур абый, — диде Әнир һәм, янәшәдә утырган солдатлар да ашасын өчен, ризыкны уртага этәрде.

Габделнур, аның бу гамәленә горурлык хисе кичереп: «Монысына кул куям, молодец, мондый гадәтең белән коллективка тиз ияләшерсең», — дип, эчтән генә егетне мактап куйды. Аннары, хлеборезкага барып, Иректән (ә ул шунда урнашкан иде) бер буханка ипи дә сорап алды, аны да яшьләргә биреп калдырды.

Габделнур белән Гена тагын сөйләшә-сөйләшә үз йортларына таба атладылар.

— Миңа да баштагы чорда ашау җитми иде, — диде Габделнур, үзалдына әйткәндәй. — Без бит, татарлар, бик күндәм, тәртипле халык. Күндәм — өндәмсез эшләр, дип юкка гына әйтмәгәннәр борынгылар, эшне дә

җиренә җиткереп башкарабыз. Мине, гәрчә миннән озын солдатлар булса да, сафта йөргәндә иң алга куялар иде.

— Нигә шулхәтле тырыштың соң? — диде Гена, елмаеп. — Лычка кирәк булдымы әллә?

— Көләсең. Мин бит хохол түгел. Алар гына лычка өчен үлә. «Лычкасыз хохол — мөһерсез белешмә» дип әйтәләр бит. Алар погоннарына бер тасма булса да тагып кайтырга тырышалар. Мин кече командирлар мәктәбен бетереп кайткач та отделение алмадым.

— Нигә?

— Үземнең яшьтәшләр өстеннән командалык итәсем килмәде. Бәлки, соңрак мәҗбүр иткән булырлар иде, каравыл ротасыннан пожаркага күчерделәр. Синең баягы сүзеңә җавап болай: артыгын тырышмадым да шикелле, күрәсең, командирларга минем атлау рәвеше ошагандыр. Карантин беткәндә, ант кабул иттерергә, Ленинградтан адмирал киләсе, диделәр. Кем ул, нинди должность биләп торган, хәзер хәтердә түгел инде. Менә шуның алдында йөзгә кызыллык китермәс өчен командирлар мине алга куйдылар.

Шулай, истәлекләргә чумып дигәндәй сөйләшә-сөйләшә дача йортына кайтып җиттеләр.

— Мин кермим әле, — диде Габделнур һәм сәгатенә карап алды. — Авылдаш янына барып кайтыйм.

Ул кире борылды һәм яшь солдатлар казармасына юл алды.

Бераз сөйләшеп торгач, Габделнур Әниргә кайбер киңәшләрен бирүне кирәк тапты:

— Болай таза күренәсең, шулай да исеңдә тот: солдатка көч һәрвакыт кирәк, хезмәтең дә җиңелрәк үтәр, иптәшләрең арасында да абруең булыр. Хатлар яз. Күбрәк язсаң, үзеңә дә ешрак килер. Баштагы чорда мин унар хат аладырыем. Соңрак сирәкләнде. Беренче ярты елда читен инде, аннары ияләнәсең. Безнең район егетләре бармы?

— Бар.

— Анысы әйбәт. Мин гел берүзем булдым. Әле сезне дә аерырлар, канишны. Үзегез чамаларсыз, бергә булу ягын карагыз диюем. Габделнур абый акыл сата, дип ачуланма тагы.

— Юк, нишләп алай дим. Рәхмәттән башка сүзем юк.

— Хезмәттән зарланма, шыңшыма. Беренче көннән үк үзеңне настраивать ит, үзеңә әйтә тор һаман: мин — ир-егет, мин хезмәт итәргә тиеш, минем бурыч ул, әткәй-әнкәйнең йөзенә кызыллык килмәсен. Ярар, күп лыгырдадым. Исәнсау йөре. Әле күрешербез.

— Рәхмәт, Габделнур абый.

**45**

Октябрь уртасында халыкны аптырашта калдырган хәл булды: озак еллар илнең хуҗасы булып торган Хрущев урыныннан алып ташланды. Беренче көннәрдә бу вакыйга ничектер кешеләрнең аңына барып җитмәде шикелле. Әле бит югыйсә бернәрсә дә Хрущевның шулай тиз чөеләсен искәртми иде. Әллә аның «урындыгы какшаганны» халык сизми калдымы?

Ни генә әйтсәң дә, ул — илнең хуҗасы, Сталин дәрәҗәсендә үк булмаса да, каты куллы җитәкче иде. Яшерен-батырын түгел, соңгы вакытта мәзәкләр дә ишетелгәләде, үзе турында гына түгел, туган-тумачасы, аның тирәсендәгеләр хакында да ямьсезрәк сүзләр ычкындыра башладылар. Мәсәлән, халык арасында «Известия» газетасының баш мөхәррире, Хрущевның киявенә багышланган әйтем барлыкка килде: «Не имей сто друзей, а женись как Аджубей». Хәтта «тозлы» частушкаларны да ишетергә туры килде. Шулай да ул әле озак еллар хуҗа булып утырыр кебек иде.

Лагерьда Габделнур ике офицер сөйләшүенең шаһиты булды.

— Брежнев яшь, энергияле күренә.

— Анда бүтән кандидатлар да бар иде. Ләкин арада берәү генә, иң көчлесе генә өскә чыга. Ә син беләсеңме акула ничә бала таба?

— Белмим. Ничек «таба»? Уылдык чәчмимени ул?

— Юк. Бер бала таба. Ә карынында унбиш-егерме ярала. Үсә-үсә арада иң көчлесе, дөньяга туганчы, бүтәннәрен ашап бетерә. Үз туганнарын...

— Чагыштыру бигүк урынлы түгел сыман.

— Бәлки. Ә нәрсәсе белән аерыла?

Габделнур, солдат буларак, офицерлар әңгәмәсенә кушылып китә алмады. Ләкин ул да үзенчә фикер йөртте. Чөнки ил-көн, дөньяви вакыйгалар белән ул даими танышып бара, һәрнәрсәгә үз карашы бар. Хрущевның урыныннан бушатылуы аны да битараф калдырмады.

Август аенда гына, мәсәлән, Никита Сергеевич, Татарстанга килеп, республика районнарында кукуруз басулары карап йөрде. Казанда булды. Габделнурларны имтихан вакытында аудиториядән урамга куып чыгардылар. Бөтен кеше аны алкышлап кул чапты. Әле үзе дә, чырае бигүк якты булмаса да, «аягында нык басып тора» иде шикелле. Кыскасы «ике ай тулар-тулмас Хрущев урыныннан төшерелер» дигән уй гади халыктан берәүнең дә башына килмәгәндер.

Тик шулай да озак еллар кукуруз үстерү белән мавыгып, хәтта төньяк өлкә-крайларга хәтле аны игүне таратырга теләгән кешегә ышаныч бетә башлаган иде шикелле. Хәрбиләр арасында да, сугыш авырлыкларын үз

җилкәсендә күтәргәннәр арасында да аны өнәп бетермәүчеләр шактый иде. Чөнки Сталин рухы белән яшәгән, аны Алла урынына күргән кешеләр миллионлаган иде бит.

Дөрес, Сталинны да яратып бетермәүчеләр, аңа карата ямьсез сүз әйтүчеләр юк түгел иде. Габделнурның хәтерендә шундый такмаклар калган: «Ярар, ярар, барыбер янар Сталин чыгарган карар», «Сталинның мәкаләсе, артка чыккан әкәләсе». Шулай да аларны ачыктан-ачык урамда кычкырып йөрергә җөрьәт итмиләр иде шикелле.

Әйе, Сталин Хрущев ише генә түгел, бик көчле шәхес иде. Үзе үлгәч тә ул бөтен илне дер селкетте.

Габделнурның хәтерендә: илле өченче елның мартында Сталин үлгәч, бөтен ил кара кайгыга батты. Ул әле дүртенче класста гына укый иде. Беркөнне, иртән балалар мәктәпкә килгәч, гадәттәгечә укулар башланмады, барысын да линейкага җыйдылар.

Агач мәктәпнең уртасындагы зур зал укучылар һәм укытучылар белән шыгрым тулы. Чөнки ул заманда авылларда бала-чага күп, һәр сыйныф диярлек параллель ике класстан тора.

Үзенең катылыгы белән бөтен мәктәпне зар елатып, балаларны кан калтыратып торган мәктәп директорын алыштырып куйганнар диярсең: гәүдәсе бөкрәеп, кечерәеп калгандай, күзләрендә — яшь. Залда мәет чыккан йорттагыдай шомлы тынлык урнашты, урамда март бураны биек тәрәзәләргә кар бөртекләрен бәргәләсә дә, аны күрүче юк: барысының да игътибары директорның аксыл чыраенда.

Директор әкрен, йомшак тавыш белән, сүзләрен өзек-өзек әйтеп, нотыгын башлады:

— Укучылар, туган илебезгә кара кайгы килде: кичә даһи юлбашчыбыз, бөтен халыкларның сөекле атасы Иосиф Виссарионович Сталин вафат булган...

Бер катлы мәктәп бинасының залына тезелешеп баскан йөзләгән бала бердәй:

— Аһ! — дип куйды.

Кечерәкләр шул мәлдә үк җылый да башлады.

Алар артыннан бишенче-җиденче класслар һәм, укучыларга ияреп, укытучылар балавыз сыгарга кереште. Барысы да күз яше түкте: әти-әниләре тигезләр дә һәм ятимнәр дә, бераз хәлле гаиләдә үскәннәр дә һәм ачлы-туклы яшәгәннәр дә, аталары сугышта үлгәнлектән кыш көне өстенә кияргә киеме булмаганга «утырып калган» балалар да, әсирлектән кайткач үзенә көн күрсәтелмәгән немец теле укытучысы да, биш кило арыш өчен ире төрмәгә ябылган укытучы апалары да... Габделнур һәм аның яшьтәшләре, өлкән классларда укучы абый-апалары, түбән сыйныфтагы эне-сеңелләре — барысы да үкседе... Ире каһәр төшкән сугышта, яу кырында үлеп, итәк тулы бала белән утырып калган җыештыручы апалары да бер почмакта тавыш-тын чыгармый гына сыктады... Аларның ни-нәрсә кичергәнен, башларында нинди уйлар чуалганын сабый күңеле аңларлык түгел иде. Алар әле үзләре дә бу үлемнән соң ничек яшәп китәселәрен, совет иле киләчәгенә нинди юл сабачагын уйламыйлар иде. Хәер, әле бу хакта илдә беркем дә белми иде бугай.

Ә директор абыйлары, күз яшьләрен учындагы кулъяулыгы белән өзлексез сөртә-сөртә үзенең нотыгын дәвам итеп, бөек юлбашчының совет халкы алдындагы хезмәт вә казанышларын тәфсилләп саный иде. Кара тасма эченә алынган, бераз гына елмаю чыккан йөзендә бернинди кайгы-хәсрәт әсәре булмаган калын мыеклы юлбашчы, аның һәр сүзенә колак салып, стенадан карап тора. Сурәте беркем дә уйный белмәгән кара төстәге иске пианино турысында иде.

— Аның җитәкчелегендә Бөек Октябрь социалистик революциясе тормышка ашырылды, илебез гражданнар сугышында акгвардиячеләрне тар-мар итте... Индустриализация... Күмәкләшү... Бөек Ватан сугышы... Аннан соң кадерле Ватаныбызны аякка бастыру, җимерелгән шәһәр-авылларны торгызу — барысы да даһи Сталинның исеме белән бәйле... Аның зирәклеге... Ул сезнең, балалар, атагыз кебек иде. Ул сезне кайгыртты... Совет мәктәбендә белем алып, аның эшенә турылыклы булып...

Директор сөйләде дә сөйләде, укытучылар һәм укучы балалар елады да елады...

Габделнур да, шул шаукымга ияреп (гәрчә күп нәрсәне аңламаса да), лышык-лышык борын тартты...

Ул көннәрдә «Сталин булмагач ничек яшәрбез инде» дигән уй кара кайгыга төшкән һәр совет кешесен борчып-бимазалап торгандыр.

Мәктәпләрдә аны күмгән көнне, тугызынчы мартта, кайгы митинглары булды. Сталинны күмүне радиодан турыдан-туры тапшырдылар.

Калын тавышы белән тыңлаучыларны һәрчак сискәндерә, бөтен эшләрен ташлап, сагаеп, кара тәлинкәгә якынаерга, сүзенә колак салырга мәҗбүр итә торган дикторның авазы бүген дәһшәтле-салмак.

— Говорит Москва... Колонный зал Дома союзов... Здесь собрались из всех уголков нашей страны...

Аның Гитлерның да җен ачуын чыгарган (тотса, теленнән асып кую белән янаган), миллионнарны тетрәндерә торган көр тавышы бүген кайгылы иде.

— ...Последние минуты прощания... Выносят венки... Гроб устанавливают на артиллерийский лафет... Вдоль Охотного ряда и Манежной площади выстроился воинский эскорт...

Габделнур да, бүтән малайлар-кызлар да радиодан шәрехләнгән сүзләрнең күбесен аңламыйлар иде, әлбәттә. Алар фәкать шуны гына беләләр: дөньядагы бөтен балаларның якын дусты, туган илебезнең юлбашчысы, әти-әниләре кебек (бәлки, артыграктыр да) изге җанлы кеше вафат булган.

...Ләкин, ни хикмәт, Хрущев үлгәч, елаучы булмады. Каны каткан солдат кына түгел, сәбәпсез дә борын юешләтергә яратучы карчык-корчыклар да, Индия киноларын караганда да күз яшьләрен мул агызучы тол хатыннар да әллә ни кайгырмаган, диделәр, ул көннәрдә.

«Хикмәт нәрсәдә соң?» дип уйлады Габделнур. «Күрәсең, ничәмә-ничә еллар халыклар атасы, даһи, мәрхәмәтле дип, Алла урынына йөргән бөек Сталинны хурлап, съездда аның шәхес культын ачканнан соң, үзенең үк шул юлга басуындадыр. Гади халыкның Хрущев ялгышларын сизенүендә, күрүендәдер».

Замполит килеп солдатларны җыеп алды да, ашык-пошык кына аңлату — әңгәмә корып китеп тә барды. Аның аннан-моннан гына, бернинди чара да уздырылмаган, дип әйтмәсеннәр өчен үткәрелгән политзанятиесен солдатлар да шулкадәренчә генә миләренә сеңдерделәр.

Шулай да солдатлар арасында сирәк-мирәк бәхәс чыгып алгалый иде. Кичен, яткан килеш кенә, ялкау гына һәркем үз фикерен белдерергә тырыша, көндез, тәмәке көйрәткәндә дә, ул хакта әңгәмә куера иде.

— Шул кирәк аңа!

— Нәрсә өчен?

— Нәрсәгә булсын, Сталинга тигән өчен. Кемгә кирәк иде аның гаебен казып чыгару?

— Халыкка.

— Һе, халыкка, имеш. Халык Сталин исеме белән илдә зур эшләр башкарды. Сугышта Гитлерны җиңде. Солдатлар: «За Сталина! За Родину!» — дип атакага бардылар, дошман амбразурасын үз гәүдәләре белән капладылар.

— Атакага йөз грамм эчкәч барганнар алар, сүгенә-сүгенә...

— Сталин урынында башка берәү илбашы булса, сугыш та чыкмаган булыр иде. Яисә бу хәтле халык кырылмас иде.

— Ух син, кая алып  кереп киттең!

— Дөрес түгелме әллә?! Утыз җиденче елларда күпме генераллар, офицерлар кырылган, армия командирларсыз калган. Разведчиклар әйткәч тә Сталин фашистларның безнең илгә басып керәчәгенә ышанмаган.

— Хрущев Сталинның шәхес культын фаш итеп зур эш эшләде. Халык җиңел сулап куйды.

— Хрущев аркасында гына халык ипи ашый башлады.

— Дөрес әйтәсең. Аннары, карагыз: илле җиденче елны җирнең ясалма иярчене Галәмгә очты.

— Мин Алабугада укый идем, — диде Габделнур, ул елларны исенә төшереп. — Урамнан барабыз шулай. Берзаман багана башындагы репродуктордан «пип-пип» дип спутник кычкырта. Халыкның шатлануы...

— Гагарин очты, башкалары...

Ирек:

— Егетләр, ә сез беләсезме, ни өчен Гагарин бик тиз төште? — дип сорады.

— Юк, — диештеләр солдатлар.

Ирек дәвам итте:

— Хрущевка космоска кеше очыру турында доложить иткәннәр. Илбашы: «Кем?» — дип сорый. «Гагарин», — диләр. «Нигә татарин? Урыс яки украин юкмы әллә? Кичекмәстән төшерегез!» — ди.

Көлештеләр.

— Әңгәмәне бүлдердең, — диде Гена һәм баягы эзгә төште: — Боларда Хрущевның ни катнашы бар? Иярченне, ракеталарны үзе ясап очырганмы әллә? Шулай булырга тиеш иде инде ил башында кем утырса да... Бу — прогресс. Аны туктатып булмый.

— Ярар, аларда эше булмасын ди...

— Ничек булмасын ил җитәкчесенең?!

— Ә Берләшкән Милләтләр Оешмасында трибунага ботинкасы белән бәрә-бәрә: «Я вам покажу кузькину мать!» — дип кычкыруы?! Минемчә, теләсә кем моны эшли алмый. Американың борын төбенә үк Кубага ракеталар тезеп куюы, су асты көймәләре... Америка, моны белеп алгач, «астына җибәрде».

— Ә аның бөтен илне кукуруз белән тутыруына ни әйтәсез?

— Әллә начармы? Күпме силос, сенаж...

— Ул интеллигенциягә яхшы караштa иде, алтмышынчы еллардагы «Хрущев җепшеклеге»н онытырга ярамый.

— Соңыннан ул да нәкъ Сталин шикелле эш итә башлады, партиянең шәхес культын бетерү турындагы илле алтынчы елгы карарын онытты.

— Әйе, оборона министры Жуковны алып ташлавы...

— Хрущев та фәрештә түгел, — диде Ирек. — Польшада аны бик өнәмиләр иде. Илле алтынчы ел вакыйгаларында аның катнашы бар. Ә сез беләсезме, әле илле өченче елны ук, унҗиденче июньдә, Германиядә восстание була. Берлиндагы демонстрантларга атудан баш тарткан өчен безнең кайбер солдатларны хөкем итәләр. Хәрби трибунал карары белән үзләрен аталар.

— Кит аннан! — диде Вася, шаккатып. — Булмаганны сөйләмә! Сталин вакытындадыр ул.

— Надан, Сталин март аенда үлде, ә сиңа июнь аендагы хәл турында сөйлиләр.

— Ярар, ярар, үзең бик белдекле инде, — диде Вася, Ковалевка хәтере калып.

Габделнур Ирекнең сүзен җөпләде:

— Минем абый Германиядә хезмәт итте, Марксштадтта, элекке Химниц шәһәре. Салып алгач, ялгыш кына ул да ычкындырды. Чөнки ул турыда сөйләп йөрмәскә кушылган була. Ә абыйларга кемдер тишкән. Абый анда 1955—1958 елларда хезмәт итте. Так что... Менә шулай, егетләр.

Инде тына дигәндә, бәхәс куерганнан-куерды гына.

— Илле алтынчы елны Венгриядә дә чуалыш булган бит әле. Ни өчен безнең солдатлар ул илләрдә хезмәт итәргә тиеш?

— Социалистик илләрне яклыйлар.

— Бүре баласы бүреккә салсаң да урманга карый.

— Алар мөстәкыйль ил, үзләрен-үзләре якласын. Аларны фашистлардан азат иткән бит инде, шул җиткән. Анда да күпме совет солдаты үлде. Гомумән, кирәкме кеше эшенә тыгылу? Авылда һәр гаилә үзе теләгәнчә яши бит. Күрше кереп, син фәлән хәтле мал асра, дими, һәркем үз хәленә карый, кызыңны фәләнгә кияүгә бир яки улыңны фәлән кызына өйләндер, дип тә тыкшынмый.

— Ул — гаилә, ә илләр...

— Асылы — бер.

Кыскасы, Хрущевны өзлексез очкылык тоткандыр ул көннәрдә.

Авиациядә хезмәт иткән Ирек:

— Анда бер мәзәк йөри иде, — дип сөйләп китте. — Имеш, Хрущев белән Булганин Индиягә дуслык визиты белән очалар. Летчиклар боларның ни сөйләшкәнен тыңлап бара икән. Хрущев әйтә: «Менә мин ун сум акча ташласам, җирдә аны берәү тапса, бик шатланыр иде». Булганин: «Әгәр мин дә ун сум ыргытсам, сөенүче икәү була», — ди. Экипаж командиры икенче пилотка әйтә: «Әгәр без боларның икесен дә тибеп төшерсәк, илдәге бөтен кеше шатланыр иде».

Габделнур әңгәмәгә йомгак ясагандай әйтеп куйды:

— Власть шундый нәрсә инде ул, егетләр, аның башында утыручы һәркемгә дә ярап бетми. Халык бер юлдан йөри, ә җитәкчеләр — икенче... Аларны барыбер бөтен халык та өнәми. Сталин үлгәч, Хрущев булмаса, бүтән кеше килеп чыгар, ил белән идарә итәр иде.

— Анысы — хак. Изге урын буш тормый, — диде Гена.

...Илдәге вакыйгалар миллионнарны уйланырга мәҗбүр итсә, һәркемнең шәхси тормышы бар бит әле. Анысы фәкать бер-ике кешегә, кайчакта таныш-белешләренә һәм туган-тумачаларына гына кагыла.

Бер кичне, озак уйланып ятканнан соң, Габделнур тирән йокыга талды. Ләкин төне тынгысыз узды. Ул төш күрде.

Рәйсәнә тукталышта тора, имеш. Егет арттан килеп аны кочып алды. Каты имиләре икесе ике кулына эләкте. (Өнендә аларга кагылганы юк иде.) Бер сүз әйтмичә, ул аларны йомшак кына кысып торды. Рәйсәнә башын чак кына артка ташлады, бөтен гәүдәсе егеткә сыланды... Каяндыр агылган җыр егет колагына чалынды:

Алмалар бирәм алсаң,
Кесәләреңә салсаң.
Белерсең кадерләремне,
Ятлар кулына калсаң...

Кем җырлады моны? Рәйсәнә ишетте микән?.. Күп тә үтмәде, кызның тәне калтырап куйды, иңбашлары селкенде, үзе сулкылдый ук башлады. Ләкин елавы тыныч, тавыш-тынсыз иде. Автобус килде. Алар бер-берсенә карашмыйча, сүз әйтмичә аерылыштылар: Рәйсәнә автобуска утырды, Габделнур юл буенда калды. Ни кыз, ни егет бер-беренә карамадылар, кул болгамадылар...

Бераздан Габделнур уянды. Ул бу төшне нәрсәгә юрарга да белмәде. Исенә төште: алтмыш икенче ел ахырында, Рәйсәнә кияүгә чыгар алдыннан, ул бу төшне бер күргән иде инде. Хәзер ник керде микән? Нәрсәне аңлата бу? Әллә Рәйсәнә бәгыренә уелып калганга кабат керәме бу төш? Ике елга якын гомер узган, онытылып ук бетмәсә дә, һәрхәлдә, егетне һәрдаим борчып тормый иде бит инде. Нигә кирәк булды аның йөрәгенә тагын тоз салырга? Онытырга, онытырга... Рәйсәнәнең үз тормышы...

**46**

Октябрь ахыры җитте. Көннәр сүрелде: көндез дә, төнлә дә күк йөзен карасу болытлар каплап ала, еш кына салкын яңгыр ява, кай төннәрне су да ката. Агачларның яфраклары коелып бетте диярлек, бик сирәкләрендә генә анда-санда сары яфраклар эленеп тора, алар да, каты җил чыкса, теләсә-теләмәсәләр дә тузгып җиргә төшәләләр.

Яшь солдатларны сафларга тезеп җыялар да, машиналарга утыртып, тимер юл вокзалына озаталар. Командалары кая билгеләнгән булса, шунда җибәрәләр: бер ише — Германия, икенчеләре — Польшага, өченчеләре — Венгрия яки Чехословакиягә.

Габделнурга ул якларда хезмәт итәргә туры килмәде, шуңа күрә бу такыр башлар кая китсә дә аңа барыбер иде. Ул аларга, исән-сау хезмәт итеп кайтыгыз, дип кенә әйтә ала иде.

Ирек исә өч елның ике елдан артыгын Польшада хезмәт иткән. Шунлыктан ул Польшага китүчеләргә битараф түгел иде, аларны бик теләп, хәерхаһ белән озатты.

— Егетләр, фәлән шәһәр тирәсендәге частька эләксәгез, икенче ротаның беренче взводындагыларга минем әманәтне тапшырыгыз, — дип, кайбер солдат-сержантларга сәлам юллады, исем-фамилияләрен дә язып, китүчеләрнең кулларына тоттырды.

— Абый, сездән дә сәлам әйтикме? — дип сорады бер татар малае Габделнурдан.

— Юк, энекәш, анда минем танышлар юк.

Ирек үз тирәсенә җыелган яшьләргә акыл сата башлады:

— Полякларга вак-төяк кием-салым гына түгел, зуррак әйбер дә сатарга була, — диде ул аларга. — Безнең күрше частьта (беренче көннәрне мин шунда хезмәт иткән идем) ике солдат хәтта танк та аткарганнар иде.

Иректнең бу сүзләре яшь солдатларны хәйран калдырды, ахры, алар, авызларын ачкан килеш, аңа карап каттылар, исләренә килеп, сорау яудыра башладылар.

— Танк?

— Ничек?

Ирек Габделнурга күз кысып алды да шыттыруын белде:

— Ничекме? Кабызып чыгып китәләр дә парктан, өч чакрымдагы хуторга баралар. Исеме... Ярар, анысы мөһим түгел. Урамда туктап, берәүнең капкасын шакыйлар. Олы корсаклы, салынып төшкән калын сары мыеклы пан чыга.

— Пан кем соң ул?

— Йорт хуҗасы инде. Аларда ир кешегә шулай зурлап эндәшәләр. Ну солдатлар әйтә: «Пан, танк кирәк түгелме?» Моны ишеткәч, поляк башта өнсез кала, аннан өр-яңа, алагаем зур, аның өе хәтле машинаны күргәч, күзләре ут яна башлый — хуҗалык өчен менә дигән техника бит. «Ә пан солдатлар ничә злотый сорый?» — ди бу.

— Ә нәрсә ул злотый? — дип сорады бер солдат.

— Польшада акча берәмлеге, — диде Ирек һәм сүзен дәвам итте: — Бүлдермәгез икенче. Менә хәзер оныттырдыгыз. Кайда туктаган идем әле? Ә, әйе, пан бәясен сорый. Ну, тегеләр, панның саран икәнен белеп, юри бәяне югары куялар: «Бер литр коньяк, пан». Хуҗа үз хакын бирә: «Коньяк — нема. Үзем куган бар». Ну, егетләр ризалаша.

— Ике ярты самогонгамы?

— Аларның самогоны безнең спиртка тиң, — диде Ирек. — Тагын бүлдердегез. Әйттем бит югыйсә. Ишегалдына кертәләр танкны. Панның бәйдәге эте, чылбырын өзеп, куркып кача. Өйдән пани атылып чыга, тагын сугыш башланган бугай дип. Пан тынычландыра хатынын, ну, панины инде. Ике шешә чыгарып бирергә куша... Икенче көнне иртән ротаның замполитехы паркка керсә, чак кына егылып китми: бер танк юк.

— Шуннан? — дип сорыйлар түземсезлек белән яшь солдатлар.

Ирек тагын Габделнурга карап алды.

— Шуннанмы? Утырган да шуган, — диде ул, көлеп, һәм «әкият»ен дәвам итте. — Кем танкы юк? Фәләннеке. Кичә кемнәр исерек булган? Фәләннәр. Шуннан китә тикшерү, эзләү... Особистлар... Эләгәләр егетләр...

Иректнең сөйләгән уйдырмасы (бәлки, чыннан да андый хәл булгандыр) ышандырырлык булсын өчен Габделнур да сүзгә кушылды:

— Чыннан да, поляклар бик йорт җанлы халык. Безнең ротада Литвадан чакырылган ике поляк егете бар иде. Старшина коптеркада тикшергәндә, берсенең (Гасянец фамилияле иде) чемоданыннан түшлек чыкты. Түшлекнең ни икәнен беләсезме?

— Ат җиккәндә аның корсак астыннан алдырып беркетелә торган киң брезент каеш, — диде бер авыл егете.

— Дөрес әйтәсең! — дип, аны мактады Габделнур. — Гасянецка түшлекне хозвзводта ат җигеп йөрүче бер солдат саткан икән.

«Әкиятләр»ен сөйләп бетергәч, Габделнур белән Ирек, йөзләренә җитди кыяфәт чыгарып, сүзләрен йомгакладылар:

— Вәсвәсәгә бирелеп, самолет сата күрмәгез тагы. Ә вак-төякне, әйтик, ыштыр, бияләй ише нәрсәләрне ярый. Тик яңа портянка алгач, аягыгызга чолгап, башта карточкага төшегез...

Монысын яшь солдатларның өлкән абыйларыннан ишеткәннәре булгандыр, күрәсең, кычкырып көлделәр генә.

...Габделнурлар кабат Кремльгә кайттылар. Тагын элеккеге тәртипле солдат тормышы башланды: вакытында йокыдан тору, физзарядка, юыну-чистарыну, иртәнге аш, политзанятие, кухняга яки каядыр башка урынга нарядка бару, часть байрагы янында сакта тору... кичке барлау...

Ротага яңа командир билгеләгәннәр икән. Белокуров фамилияле, кечкенә гәүдәле, караңгы чырайлы ябык капитан бик зәһәр бәндә булып чыкты.

Беренче көнне үк казармада «картлар»ны сафка тезеп бастырды.

— Үрә кат! Отставить! Тигезлән! Үр-рә кат! Шәлперәй!

Һәрберсен күздән кичереп, киемнәрен тикшереп чыкты.

— Якаларыгызны ычкындырыгыз!

Моңарчы эленке-салынкы йөргән карт солдатлар теләр-теләмәс кенә гимнастерка төймәләренә үрелделәр. Капитан шеренганың башында беренче булып басып торган Ковалевка ябырылды. Ул аның гимнастерка изүеннән күренеп торган җылы йон пуловерын нәзек бармаклары белән чеметеп кенә эләктерде.

— Бу нәрсә?

— Пуловер, иптәш капитан.

— Салып ташла!

— Иптәш капитан, салкын...

— Сөйләшүләрне туктатырга! Рядовой Ковалев, чираттан тыш нәрәт аласың киләме?

— Һич юк, иптәш капитан!

— Шул шул... Лагерьда бөтенләй тугарылгансыз...

Һәм ротный шеренга буйлап китте. Һәр солдат каршында туктап, гимнастерка эченнән кигән җиңсез жилет, җылы күлмәк, якасыз свитер ише нәрсәләрне салырга кушты. Хәтта гимнастерка якасына тегелгән ак ситсы — подворотничегы каралган, кырынмаган яки итеген юньләп чистартмаган өчен дә кайберәүләргә кисәтү ясады.

— Рядовой Крылов, сез бүген кырындыгызмы?

— Так точно, иптәш капитан!

— Икенче юлы бритвага якынрак торыгыз.

Ул, кабат «картлар»ны үзенчә мыскыл итеп, команда бирде:

— Тигезлән! Үр-рә кат! Шәлперәй! Барыгызга да үз-үзегезне тәртипкә китерергә! Унбиш минут вакыт бирәм! Тарал!

Капитан очлы күзләрен караватһәм тумбочка тирәләренә дә йөртеп чыкты.

— Иптәш матрос, бу нинди язу? — дип сорады ул, бер койка башына эленгән кәгазь кисәген кулына алып һәм кычкырып укыды: — «Адмиралдан түбән якын килмәскә!» Миңа ярамый инде алайса?

— Иптәш капитан, бу — шаяру. Бирегез, ертып атам.

— Истәлеккә миндә калсын.

Белокуров ары китте. Берәүнең тумбочка өстендәге язуын алып укыды:

— «Янгын вакытында иң беренче чыгарырга!» Рядовой, башта җиңелрәкләрне чыгарырбыз. Сез иң ахырга калырсыз, — диде ул, таза гәүдәле солдатны кызартып.

Ротный тикшерү-каравын дәвам итте:

— Ә монысы нәрсә? «Тревога булса — уятмаска!» Бәлки, сезне иртәнге ашка дәшмәскәдер?..

Солдатлар, нишләсеннәр, сукрана-сукрана җылы киемнәрен салып аттылар, төзәтенә-бизәнә башладылар.

— Менә бу солдафон! — диде Ковалев, рота командиры чыгып киткәч.

Кемдер әйтте:

— Әле күрәселәр алда икән.

Аны башкалар күтәреп алды:

— Түзәргә туры килә.

— Бу мәрхәмәтсез белән бәйләнеп, кайсыбызның артыгын хезмәт итәсе килсен.

— Бу эт җан утыз беренче декабрьгә хәтле дә тоткарларга мөмкин.

— Сак булыйк, егетләр, сүзгә килмик.

Шулай бер-беренә үгет-нәсихәт бирделәр. Караватларны кабат рәтләп, җыештырып куйдылар, тумбочка эчләренә күз салдылар. Чөнки демобилизация көткән солдат өчен иң хәтәре утыз беренче декабрьдә китү иде. Тәртипсезрәк солдатларны командирлары шуның белән генә куркыта. Солдатны беренче айларда, мин сине Макар бозау көтмәгән җиргә җибәрермен, дип куркытсалар, соңгы көннәрне исә, утыз беренче декабрьдә өеңә китәрсең, дигәне иң үтемле сүз була. Ә ул — иң авыр җәза. Чөнки яшьтәшләрең-хезмәттәшләрең инде берәмберәм китеп беткән, син, судагы йомычка кебек, кая барып сугылырга белмичә тулганасың, өеңдә әти-әниең, кияүгә чыкмаган булса, сөйгән кызың зарыгып көтәләр. Күңелсез, ямансу көннәрнең андый солдат өчен берсе дә айга торырлык була.

...Габделнурны рота дневальные дәште:

— Гаделҗанов, телефонга!

Егет аптырап китте. Кем булыр икән? Нигә дәшәләр икән? Иң беренче уе: өйдә бер-бер хәл булганмы әллә? Алай дисәң, хат алышып тора, кемне дә булса, «авырый», дип язганнары юк. Күрәсең, полктан яки дивизиядәндер? Бу бит эчке телефон гына. Ә кем чакыра?

Килде. Трубканы алды.

— Ефрейтор Гаделҗанов тыңлый.

Трубкада ир-ат тавышы:

— Дивизия штабы буенча дежурный сөйли. Кичекмәстән дивизия штабына килеп җитегез.

— Кемгә?

— Штаб начальнигына.

— Есть!

Ирек тә, Габделнурны телефонга чакыруларын ишеткәч, дневальный янына килгән иде.
— Нәрсә бар, Старый?
— Начштаба дивизии чакыра.
— Оho!
Габделнур киемен күздән кичерде, уң кулын йолдыз турысына хәтле күтәреп, фуражкасын рәтләде.
— Тәртип, Старый, бар, — диде Ирек.
Габделнур озак юанмады, казармадан чыгып та китте.
...Штаб начальнигы кабинетында берүзе иде. Габделнур ишек катында тураеп басты, кирза итекләрен шык иттереп бер-беренә бәреп, уң кулын чигәсенә тияр-тимәс калдырып, бөтен шартын китереп честь бирде:
— Иптәш полковник, ефрейтор Гаделҗанов сезнең приказание буенча килде.
— Исәнме, — диде кырык-кырык биш яшьләрдәге киң җилкәле полковник, җылы гына, һәм, кулы белән ишарәләп, өстәл янындагы урындыкка күрсәтте. — Утыр.
Бераздан ул, әлегә үзенә буйсынган ефрейторның күзенә туры карап, аның хезмәте, әти-әниләре, туганнары турында җентекләп сорашты. Уку мәсьәләсе белән кызыксынды. Ахырда ул, «сез»гә күчеп, чакыруының төп максатын әйтте:
— Сезгә сверхсрочник булып калырга тәкъдим ясамакчы идем.
Габделнур озак уйлап тормады. Чөнки ул бу мәсьәләне күптән хәл иткән иде инде:
— Иптәш полковник, мин киләсе елга укырга керергә ниятлим.
— Очныйгамыни?
— Әйе, көндезгегә.
— Бездә ике өлкән сержант һәм бер старшина вузда укыйлар. Читтән торып. Сезгә тәкъдим ясар алдыннан ул вариантны да истә тоттык. Сез кече командирлар мәктәбен бетергәнсез, техникум белемегез бар. Риза булсагыз, иртәгә үк званиегезне күтәрәбез. Кече сержант турында сүз бармый, сержант яки өлкән сержант итеп. Әйбәт кенә должность тәкъдим итәбез. Клубка кеше кирәк. Дөрес, клуб начальнигы офицер булырга тиеш, шуңа күрә әлегә анысын вәгъдә итә алмыйм. Ләкин ул — вакыт эше, начальник отставкага җыена. Бер-ике курс укыгач, офицер дәрәҗәсе бирербез.
— Рәхмәт, иптәш полковник, — диде Габделнур, тынычланып. — Мин армиядә калмаска булдым инде.
Штаб начальнигы аны артык үгетләп тормады. Күрәсең, башта ук өмете чамалы булгандыр. Аннары, ефрейторның үзен тыныч тотуы, җитди фикер йөртүе дә тәэсир иткәндер. Йөз төзелеше буенча холкының ныклыгы да егерме биш ел хәрби хезмәттә булган офицерның күзенә бәрелеп тора иде. Димәк, бу инде үз юлын сайлаган.
— Яхшы. Ихтыярыгыз. Кире уйласагыз, туп-туры үземә керегез. Китә аласыз.
Габделнур торды, честь бирде. Штаб начальнигы, китә аласыз, дисә дә, устав кушкан таләпне төгәл үтәде.
— Иптәш полковник, китәргә рөхсәт итегез.
— Барыгыз.
...Соңгы көннәр ничектер бик җанлы үтте. Хезмәтен тәмамлаучыларны клубка җыйдылар. Эшкә чакыручы — вербовщик килгән икән.
Озын буйлы, күзлекле, яхшы костюм-чалбар кигән, култык астына папка кыстырып кергән бу ир-ат, үзенә сүз бирелгәч, кәгазьгә карамыйча гына сөйли башлады:
— Татарстан — нефть төбәге. Үзегезгә мәгълүм, нефтьтән бик күп төрле әйберләр эшләп чыгарыла. Менә шуңа күрә дә Казанда органик синтез заводы төзелә башлады. Бу эшкә моннан алты ел элек, 1958 елда тотындык. Хәзер исә беренче комплекслар сафка басты. Узган ел, 1963 елның 27 маенда, фенол, ацетон цехлары продукция бирә башлады...
Ул кеше нинди продукцияләр эшләп чыгарылуы, аларның күләме һәм сыйфаты, ил өчен әһәмияте һәм башка якларын тәфсилләп сөйләде.
— Ләкин, — дип дәвам итте эшкә яллаучы, — бу әле эшнең башы гына — төзелеш яңа җәелеп килә. Шуңа күрә безгә эшче көчләр бик кирәк, менә сезнең кебек батыр, таза беләкле, өч-дүрт ел буена ил сагында торган кыю солдат-матрослар, иртәгәсе көннән граждански тормыш башлап җибәрәчәк егетләр кирәк...
— Салпы якка салам кыстыра белә бу, — диде Ирек Габделнурның колагына. — Ә үзе нинди эш икәнен әйтми. Кара эштер инде.
Теге әле һаман сөйли иде:
— Заводта тагын берничә комплекс булачак — завод эчендә завод...
Ләкин шулчак аны бер матрос бүлдерде:
— Эшчеләр заводка кирәкме, әллә төзелешкәме?
— Төзелешкә, — диде вербовкалаучы, сүзен бүлдерүләренә бераз хәтере калса да, йөзенә чыгармады, кызыксыну уятуына сөенде генә. — Мин — трест вәкиле. Ә безнең трест — генподрядчы.
— Анысы нәрсә тагын? — дип сорады Ирек тә, әңгәмәгә кушылып.
— Бу — төзелеш өчен җавап бирүче төп оешма дигән сүз. Безгә субподрядчылар белән дә эшләргә...
Аны тагын бүлдерделәр.
— Сезгә нинди һөнәр ияләре кирәк?

— Балта осталары, бетончылар, арматурачылар...

— Тапкан юләрләрне, — диде Ирекнең сул ягында утырган, Казанда туып үскән бер солдат, күршеләре ишетерлек итеп кенә. — Саз ерырга үзең бар.

— Ә электриклар? — дип кычкырды Габделнур, чөнки залдагылар нык кына шаулаша башлаганнар иде.

— Рәхим итегез.

Шул сүз җитә калды: Габделнур Казанда калырга ризалык белдерде. Ирекнең, авылдан киткән егетнең, төзелештә ярардай һөнәре юк иде. Ул балта остасы булып язылды.

— Бәлки, моннан иртәрәк җибәрерләр, — диде ул Габделнурга.

Гадәттә солдат «дембель» дигән татлы сүзне соңгы елының гыйнвар аеннан ук кулланышка кертә. Ләкин дембель үзе кемгә ничек елмая: укырга кергәннәр августта ук андый бәхеткә ирешә, ә калганнарга сентябрьдән башлап утыз беренче декабрьгә хәтле сузыла. Тәртибең бишле булса, алмаш килсә — иртәрәк китәсең, ә инде «гөнаһлар»ың күп икән, бәхетең юк икән — соңгы көнне кötәсең.

Клубтан чыккач, Ирек көлеп җибәрде. Ләкин аның елмаюына шатлык тойгылары салынмаган, ачы сагыш күбрәк кушылган иде.

— Безнең бәхет шуннандыр инде: әтиләр шахтага барып акча эшләгән, абыйларны мәҗбүри ФЗӨгә алганнар, апалар вербоваться ителеп читкә киткән. Их, дөнҗа, буялган җонга, буялса иде мамыкка, рәхәт булыр иде халыкка.

Казармада Габделнурны Мораттан килгән хат көтә иде. Дусты теге хатынга өйләнүен һәм киләсе елда хезмәтен бетергәч тә Кронштадта калачагын язган иде. «Тәки каптырганнар икән егетне», — дип уйлады Габделнур.

**47**

Өченче ноябрь көнне полк командиры, таза гәүдәле полковник, быел хезмәт срогын тутырасы солдат-матросларны җыйды да, кулларын артка куеп, алар каршында әрле-бирле йөргәләп:

— Солдатлар һәм сержантлар, матрослар һәм старшиналар, хезмәтегез өчен сезгә рәхмәт белдерәм, — диде. — Сез Ватан алдындагы изге бурычыгызны намус белән үтәдегез, өчәр ел, моряклар дүртәр ел, илебезнең иминлеген тәэмин иттегез. Сез тәртипкә, җыйнаклыкка өйрәндегез, дуслык, туганлык, Ватанны ярату кебек төшенчәләрне күңелегезгә сеңдердегез. Инде сезнең белән саубуллашыр чак җитте. Мин сезгә тыныч тормышта, кайсы гына тармакта эшләргә туры килсә дә, уңышлар телим. Хәрби хезмәттә алган күнекмәләр — физик көч, тапкырлык, тәртиплелек һәм башка сыйфатлар сезнең тормыш юлдашы булсын... Бүгенге сержант-старшиналар иртәгә үк колхоз-совхозларда бригадир булып эшли ала, чөнки сезнең кешеләр белән аралашу, коллектив белән җитәкчелек итү тәҗрибәгез бар. Үзегез буйсына һәм кешеләрне дә буйсындыра беләсез. Завод-фабрикага яки төзелешкә китүчеләргә дә кагыла бу. Гомумән, сез барыгыз да зур чыныгу алган ир-егетләр...

Ул шактый озак сөйләде, яше белән алардан ике мәртәбә өлкән кеше буларак та үзенең киңәшләрен бирде. Үгет-нәсихәттән туктап, ул ахырда, тулы, кызгылт йөзендә елмаю галәмәте чагылдырып:

— Җитәр сезгә яшьләрне аздырырга, — диде. — Гражданкада хәмер белән шаярырсыз. Иртәгә мин сезне «куып чыгарам».

Аның соңгы сүзләре гаскәриләр йөрәгенә сары май булып ятты: гөрләтеп кул чаптылар. Казарма — туган йортың түгел, өеңнән куып чыгарсалар гына кара кайгыга төшәрсең, ә өч-дүрт ел каеш буып йөргән, ил алдындагы бурычын ахырынача түләгән ир-егетләр өчен мондый «куып чыгару» — сөенеч кенә.

Командир сүзендә торды. Дүртенче ноябрьдә, иртәнге сәгать уннарда Кремль капкасыннан зур төркем солдат һәм матрослар чыкты. Алар гадәттәгечә сафта түгел, таралышып баралар, һәрберсенең кулында кечкенә чемодан, йөзләре шат. Ак башнядан берничә адым ераклашуга, алар туктадылар, чөнки хәзер юллары аерылачак иде. Китте кочаклашып яки аркадан кагып, кул биреп яки телдән генә саубуллашу-хушлашу... Аннары алар вак төркемнәргә бүленеп яки берән-сәрән тарала башладылар.

Габделнур белән Ирек музей каршында туктадылар, артларына борылып, кирпечтән өелгән биек, калын ак диварга соңгы мәртәбә күз ташладылар һәм, иркен сулап, шаркылдап көлеп җибәрделәр.

— Котылдык, — диде Ирек һәм карашын дустына төбәде. — Старый, син кая?

— Университетка. Әзерлек курсларына язылам.

— Ә мин — апаларга. Аннары күз күрер. Ярар, ул да булды, кыз кирәк, дип әйткән, ди, берәү. Исән-сау «изге» бурычтан котылдык. Шуңа сөеник.

Алар университет бинасына хәтле бергә атладылар. Өсләрендә яшькелт бушлат, башта — фуражка, аякларында кирза итек, кулларында кечкенә чемоданнар — өч ел җыйган «байлыклары» шул. Аларның аяк атлаулары гадәтләнгәнчә — җитез, гәүдәләре — төз. Алар әле үзләренең озак еллар буена уклау йоткандай гәүдәләрен төз тотып йөриселәрен, гомер юллары кайсын кая таратып, әле генә утырган тормыш арбасының кай тарафларга илтеп чыгарасын, юлда бик күп төрле хәлләр булачагын белми һәм, иң мөһиме, бу турыда уйламый да. Бүген — иректе көн. Кая телисең — шунда барасың, сиңа «подъем» дип акыручы да юк, «отбой» дип мәҗбүри яткыручы да, сафка тезелергә кушучы да...

Ләкин иртәгәдән, хәер, бүгеннән үк, сине төшке һәм кичке ашка дәшкән күңелгә якын команда да булмаячак. Иртәгәдән үк иртәнге аш хәстәрен дә үзеңә кайгыртырга туры киләчәк. Ул гына да түгел, гомумән, тормыш «уфалла»сына җигелеп, йөкне үзеңә тартырга туры киләчәк. Армиядәге гамьсез, кешене күпмедер дәрәҗәдә боза торган ваемсыз тормыш инде бетәчәк: солдат йоклый, хезмәт бара, дип кенә яшәп булмаячак. Командир — эти, замполит — әни, әмма ләкин ятимлекне кулайрак күрер идем, дигән чаклар әле искә төшәчәк. Чөнки бүгеннән үзең, бары син үзең генә язмышың өчен җаваплы, үз көнеңне үзең кайгыртачаксың. Ләкин алар — яшь, таза тәнле, көчле рухлы: алга куелган максат, нәрсәгәдер омтылыш, кояш астында үз урыныңны табарга теләү, нидер өмет итү, нәрсәгәдер дәгъва кылу бар...

Менә ул — аны беренче омтылыштан үз түбәсе астына сыендырмаган бихисап колонналы, ике катлы озын ак бина. Ләкин егетнең аңа ачуы юк. Димәк, башкалардан бер башка өстен торырлык итеп, сынау бирәсе фәннәрне су урынына эчеп, һәр сорауга чатнатып җавап бирерлек итеп тиешенчә әзерләнмәгән. Бәлки, бәхет елмаймаган.

Авыр имән ишекләрне кабат ачарга туры килде.

Габделнур, университетка кереп, әзерлек курсларына егерме сум акча түләде. Аның ун сумын оборона министры исеменнән бүген биргәннәр иде, ун сумы — үзе юнәткән. Аннары ул, вербовщик калдырган адресны кесәсендә капшап, трестны эзләп тапты, аннан чыккач, армиягә киткәндә паспортын тапшырганлыкка бирелгән квитанцияне милиция бүлегендә калдырды. Трестның тулай торагы төзелеп ятучы завод янында ук, әллә кайда шәһәр читендә — җәһәннәмдә икән, анда барып, бер бүлмәгә урнашты.

Паспорт алып, эшкә урнашып ике көн үтеп тә китте. Шундый ук эшләрне Ирекка дә башкарырга туры килде. Җиденче ноябрь көнне, иртүк торып, Габделнур белән Ирек вагон бушатырга киттеләр.

Аларны төзелеш объектыннан ярты чакрымдагы, халык телендә «Жилплощадка» дип йөртелгән шәһәрчеккә урнаштырганнар иде. Биредә соңгы елларда калкып чыккан берничә биш катлы, дистәдән артык ике катлы йорт бар. Күбесе — тулай торак, егетләр һәм кызлар аерым йортларда яши, ә калганнарының яртысы — гаиләләр өчен махсус төзелгән «малосемейка», фәкать берничә йорт кына бөтен уңайлыклары булган аерым фатирлы.

Габделнурлар тулай торагы — ике катлы таш бина, аңа тоташып ук УМ, СМУ кебек механикалаштыру яки төзү идарәләре конторалары, базалары урнашкан.

Әле генә хәрби хезмәттәге казармадан (нигездә, шул ук тулай торак) күчкән егетләр өчен әллә ни искитәрлек нәрсә түгел иде бу — алып мактарлык түгел, салып таптарлык түгел: шул ук билгеле бер тәртип белән җыештырылган тимер караватлар, тартмасына кием, итек һәм теш щеткалары белән крем, хушбуй һәм башка кирәк-яраклар салынган тумбочкалар. Дөрес, уртада өстәл, берничә урындык, карават асларыннан көрән яки кара төстәге чемоданнар күренүе, өстәлдә электр чәйнеге, сулы графин һәм каплап куелган кырлы стаканнар булуы — моның солдат казармасы түгеллеген искәртә. Буяулы идәндә палас-мазар юк, тәрәзәләрдә гади генә озын пәрдәләр. Кием шкафы ишек янындагы почмакка поскан. Стенага билгесез бер рәссамның төссез генә картинасыннан күчермә дә эленгән. Коридорда, дневальный урынына — вахтер карчык. Телефоны гына таныш кебек — кара төстә.

Бәйрәм алды булгач, Казан тирәсендәге районнардан килгән ике егет кичә үк өйләренә кайтып киттеләр.

Габделнур белән Ирек, иртүк торып, физзарядка ясап, урын-җир җыештырып, тиз генә коры-сары белән җиңелчә чәйләп, погоннары салдырылган бушлатларын киеп чыгып та киттеләр.

Урамда көз: күк йөзенә авыр карасу болытлар хуҗа, җирдә — лыжырдык. Шуңа да карамастан бар булган затлы киемнәрен кигән халык, шәһәр үзәгенә барырга ниятләп, автобус тукталышына агыла. Әнә автобус та килде, ишекләрен ачты; ләкин ул тулы икән инде.

Шофер сукрана:

— Автобус резин түгел бит, икенчесен көтегез.

Аңа игътибар итүче юк. Этешә-төртешә торгач, кичәге ике солдатка да, янә тагын өч-дүрт кешегә дә урын табылды. Биш-алтысы юл кырыенда калды. Аяк басар урын булса да, тын алырга һава беткән иде инде. Кемнәрнеңдер ай-ваена карамыйча, автобус тәрәзәләренең ике өлгесен ачтылар. Егерме-утыз минуттан ничек кирәк алай Восстание урамына хәтле барып җиттеләр: кем бер аягында торып, кем ишеккә сыланып...

Аннары егетләр трамвайга күчтеләр. Монда иркенрәк иде. Ә урам... әләмнәр, транспарантлар җыеп тоткан, бәйрәмчә киенгән халык җәяүләп алга агыла. Яннарыннан төрле төстәге шарлары һәм кечкенә флагчыклары белән бала-чага юырта, аграклары әтиләренең җилкәләренә кунаклаган. Трамвай тәрәзәсеннән кайбер урыннарда инде колонналарга укмаша башлаган төркемнәр дә күзгә чалынып калды.

Бәйрәм көн булуга карамастан, трамвайда кондуктор бар иде.

— Апа, акча юк, — диде Ирек, аның сүз әйтүен дә көтмичә.

— Өч тиен дәме?

— Өч тиен биргән кешенең малае булыр идем әле.

Хатын елмайды, «барыгыз әйдә» дигән сыман, кул гына селтәде.

Тимер юл вокзалында, монысыннан төшеп, бүтән трамвайга, елга портына бара торганына күчтеләр. Белгән кешеләр әйтүе буенча, бушатыласы йөк вагоннары шул тирәдәрәк туплана икән, конторлары да янәшә генә, имеш.

Һәм шулай булып чыкты да. Бәйрәм көн булганлыктан, анда хезмәткәрләр күп түгел иде. Шулай да кемнәргәдер эш биреп, кайда, нәрсә эшләргә кирәген аңлатырлык, күрсәтеп йөрерлек кешеләр бар иде.

— Безгә эш кирәк иде, — диде Габделнур, бәләкәй генә бүлмәгә — диспетчерскийга кереп исәнләшкәч.

— Табарбыз. Сез ничәү? Бригадамы? — дип сорады мондагы ике ир-атның берсе.

— Юк. Икәү генә.

— Барыбер. Киттек.

Кичәге солдатларны үз артыннан иярткән таза базык гәүдәле, яхшы куртка һәм мех фуражка кигән адәм юлларда торган бихисап товар вагоннарының берсе янында туктады.

— Менә сезгә задание, — диде ул, коры гына, — шушы вагонны бушатырга. Әнә тегендә өярсез.

«Сораулар юкмы?» дигән кыяфәт белән ул егетләргә карады. Чөнки күп сөйләшеп торырга вакыты юк, ахры. Бәйрәм көн бит.

— Нинди сорау булсын, — диде Ирек, ирен читләре белән генә елмаеп. — Бери больше, кидай дальше.

— Да, закидаешь боларны, — диде Габделнур, юан-юан бүрәнәләрнең башларына карап.

— Киткәндә диспетчерга күрсәтерсез эшегезне, — диде ир кеше һәм китеп тә барды.

Ничектер миһербаны килепме, әллә шулай тиеш идеме, ул бераздан егетләргә ике пар эш бияләе калдырып китте.

— Мәгез. Армый эшләгез.

Гомерендә бер генә мәртәбә булса да вагоннан бүрәнә бушаткан кешегә аңлатып-сөйләп тору кирәкмидер бу эшнең нидән гыйбарәт икәнен. Үзе башкармаса, күпләрнең кеше бушатканны күзәткәне бардыр. Дошманыңа да күрсәтмәсен, дигәннәре шул буладыр инде. Каяндыр салкын яклардан килгән ылыслы агач бүрәнәләре бозланып каткан, үзләре чи, юеш, авыр... Аларны көчәнә-көчәнә тартып чыгарырга, иңнәргә салып күтәреп читкә илтергә, ишелмәслек итеп тигезләп өяргә дә кирәк... Кыскасы, өч ел бөрөзлексез физик күнегүләр ясап, спорт белән шөгыльләнеп, хәрби өйрәнүләрдә катнашып, корал тотып тыгызланган тәннәрне дә ватты бу эш...

囊 Эштән туктагач, Габделнур авыр сулап куйды:

— Бәхетеңне керпе нитсә, атлаган саен чәнчер, дип юкка гына әйтмәгән борынгылар. Алабугада укыганда да баржа бушатып, кешеләргә утын кисеп көн күрә идек. Тагын да шуңа калдык бугай. Табанны талдырмыйча тамак туймас инде безнең.

Ирек, җеп өзәрлек хәле калмаса да, шаяртырга көч тапты:

— Бер бәхетсез — гел бәхетсез, аның гүре ләхетсез, дисең инде.

— Син әйтәсеңме аны, мин әйтимме, икебез бергә әйтикме...

— Да, Старый, минем колхозда атлы эштә йөрүем уен гына булган икән.

Төшке ашка елга вокзалы янындагы «Прибой» кафесына барып килделәр. Ризыклары ике стакан катык, өчәр пирожки белән өчәр стакан чәй булды.

— Ач карынга — ачы катык, чукындыра да куя, ди торган иде минем әткәй, — дип, Ирек стаканны «эһ» дигәнче бушатып та куйды.

Габделнур:

— Ипиләре дә буш түгел, ичмаса, — диде. — Алабугада берара шәһәр ашханәләрендә ипине өстәлгә тәлинкә белән куялар иде. Ул өелеп торыр иде. Без өчәр-дүртәр стакан чәй алабыз да тегене орабыз. Үзебезнең өстәлдәгесен ашап бетергәч, буш тәлинкәне күрше өстәлгә илтеп куябыз да аннан тулысын алып киләбез.

— Рәхәтләнгәнсез икән.

— Тик нигәдер озакка бармады ул коммунизм галәмәте.

Кафедан чыккач, Ирек:

— Татарның тау башына менеп җиткәч кенә исенә төшә дигәндәй, макаронник булып каласы калган икән, — диде. — Ашау — байдан, үлем — Ходайдан, дип, ике кулны кесәгә тыгып, бильярд уйнап тик йөр идең. Сирәк-мирәк паниларны да өшкерер идем хәзер.

— Алар да эләккәли идемени?

— Күрде инде башлар, күрде, дип әйткән, ди, берәү, марҗасын да, башкасын да... Татар кызларын гына очратмадым. Анда, бездән ерак түгел, Польша-Литва кенәзлеге чорыннан ук татарлар яши икән, дип сөйләделәр.

— Ашагач, җан керде кешегә, — диде Габделнур, шаяртып. Аннан җитди тонга күчте: — Әй, зарланмыйксана. Өч ел көтеп алган дембельнең кадерен җибәрмик әле. Безнең аһ-зарны барыбер беркем дә ишетми. Гелән генә болай эшерелмәбез әле.

— Әйе шул, түз, йөрәгем, түз, мин дә түзәм бит, дигән ди берәү.

Бераз баргач, Габделнур үзалдына көлеп куйды.

— Нигә көләсең? Тора-тора бер амин дигән шикелле...

— Әнә бер егет агач арасында бер кызны кыскалап маташа.

— Менә сиңа да дәрт керде, әллә ниләр күрәсең.

— Искә төште... Беләсеңме ни өчен матросларның чалбар кашагасы ябык?

— Ничек?

— Ну, төймәләре яннан.

— Ә ул шулаймыни?

— Әйе.
— Каян белим. Мин бит, синең шикелле, коры җирдә булса да морфлотта хезмәт итмәгән.
— Тыңла алайса. Аны Петр I шулай тектерткән. Берзаман бу Кронштадтка килгән. Мең җиде йөз ничәнче елдыр, анысы хәтердән чыккан. Менә шул, кичке якта бакчада йөри бу. Анда, яр буенда, бакча бар. Хәзер аның исемен йөртә, һәйкәл дә куелган. Бара, значит. Күрә: бер матрос бер кызны юкә агачына терәгән. Матросның чалбары төшкән, арты — шәрә. Ә көз бит, теге кыска бушлаттан гына. Шуннан патша үзен озата йөрүче адмиралдан сорый: «Күрәсеңме?» Адмиралның бер күзе Кутузовныкы шикелле кара тасма белән бәйләнмәгән бит, патшага хәтле үк күреп алган. Дәшми генә бара. Калтырый-калтырый әйтә бу: «Күрәм, Ваше Высокопревосходительство, государь мой повелитель. Виноват. Хәзер ул сукин сын ахмакны җәзага тарттырам». Петр I әйтә: «Юк, ул үз эшен эшләсен. Ләкин арты ябык булсын, туңмасын. Миңа таза матрослар кирәк».
Алар рәхәтләнеп, рельсларда торган товар вагоннары селкенерлек итеп шаркылдап көлделәр.
— Тельняшка да шул заманда кергәнме? Мәзәге бармы?
— Юк. Ул соңрак, 1874 елда. Ак җилкән фонында матрослар күренеп торсын өчен. Ә менә унҗиде кырлы зур стаканны Петр I эшләткән. Бервакыт, матрослар белән аракы эчкәндә, шома стакан моның кулыннан төшеп китә. Шуннан задание бирә пыяла өрүче мастерларга: «Качка вакытында да моряклар кулыннан төшеп китмәслек булсын». Һәм, сынап карагач, әйтә: «Осанистый и по руке впору». Янәсе, хәмер эчәргә бик җайлы.
Ирек тә мәзәк сөйләде.
Габделнур көлде. Аннары теге тилемсә исенә төште дә ул да җавапсыз калмады:
— Алабугада бәләкәй генә башлы, әзрәк җитеп бетмәгән бер егет бар иде. Хатын-кыз яныннан узганда, «баба ни мне, баба ни мне» дип китә торган иде. Күрәсең, юләр булса да, табигать үзенекен иткәндер, кызкыркынга күзе төшкәндер.
Бераздан Ирек әйтеп куйды:
— Син — оптимист.
— Үз күңелеңне үзең күтәрмәсәң, синең күңелеңне кеше күтәрмәс, ди торган иде бездә бер бабай, — диде Габделнур һәм дустыннан сорап куйды: — Авылда кызыңны күрмәдеңме?
— Юк. Ул башка авылда кияүдә бит.
— Кияүдә икәнен әйткән идең. Барасың калган.
— Юк инде... Кеше арасын бозып... Күңеле дә суынгандыр инде.
— Үзең, бер-беребезне бик ярата идек, дидең.
— Мин аны әле хәзер дә яратам... Хатын-кыз — күкнең яртысы, дигән кытайлар. Шулай да, беләсеңме, Старый, урманда янгын чыкса, утка каршы ут җибәрәләр — янгын туктый. Ә мәхәббәттә киресенчә: ике ут бергә кушылса, сөю учагы тагын да ныграк дөрли башлый.
— Шулай булгач...
— Өч ел буена ут бер генә яклы булды бит. Мин бит читтә, еракта...
— Хатлар...
— Нәрсә ул хат?! Ул бит тере кешене алыштыра алмый! Яшь йөрәккә ялкын өстәп торырга кирәк... Чит җирләрдә озак йөрсәң, сөйгән ярың ят була. Кыз килеш калдырганга гына үкенәм.
— Алай булса, көтәр идеме?
— Кая барсын... Урлап чыгарылган чебешебез дә булса...
— Өйләнер идеңме?
— Әйе.
— Шушы яшьтәнме?
— Ә нигә? Мәскәүдән Сергачка хәтле поездда бер мишәр абзый белән кайттым. Минем әллә ни йокы килми, ә аңа йоклап калмаска кирәк. Поезд барган уңайга әкрен генә төнге бергә хәтле гәпләшеп, аныңча әйтсәк, сүләшеп кайттык. Шул болай диде: «Мине әти уналты тулгач өйләндерде, мин дә олы малайны унҗидедә, кечесен унсигездә өйләндердем».
— Нәрсә күргән инде ул малайлар? Яшьлектә рәхәтләнеп йөреп тә калмагач...
— Озак йөрсәләр, алар бозыла башлый, ди абзый.
— Юк, мин укып бетермичә өйләнмим. Башта укырга, адәм рәтле белгеч булырга кирәк.
— Син техникум бетергән бит инде, бүтән һөнәрләрең дә бар.
— Бөгештермә. Нигә үзең университетка керергә дип кайттың? Шул шул. Замана икенче хәзер.
— Сиңа ничә яшь була соң ул чакта?
— Сиңа ничә булса, миңа да шулай.
— Юк, Старый, мин алай озак йөрмәм шикелле. Керүен керсәк, укылыр әле әкренләп.
— Өйләнүне бер акыллы баш «камалган крепость» дигән: эчтәгеләр чыгарга тели, тыштагыларның керәсе килә.
Һәм бераздан кичәге ике солдат кабат эшкә тотынды.
Кич җиткәндә киемнәре манма су булды, кулларының карарлыгы калмады, авыр эш җелекләрен суырды.
— Сырттан су акты, — диде Ирек, авыр сулап.

Ә кайтканда, үч иткәндәй, бөтен шәһәр бәйрәм итәргә чыккан диярсең. Хәер, чыны да шулай. Чөнки Октябрь бәйрәме — олуг тантана. Демонстрацияләр төгәлләнгән, машиналар үз юлы белән транспарантларны, байрак-әләмнәрне, портретларны алып киткән, ә халык — урамнарга, бакча-скверларга, ишегалларына, подъезд төпләренә сибелгән. Җыр-музыка һәр тарафтан яңгырый; көләч һәм салмыш йөзләр, кочаклашкан яки култыклашкан парлар, бергә эшләүче хезмәттәшләр, таныш-белеш, туган-тумача, дус-иш — һәрбарчасы бәйрәм итә.

— Анасын сатыйм, — диде Габделнур, трамвай тәрәзәсеннән тышка, урамдагы манзарага карап, — «кому — война, кому — мать родная» дигәннәре шушыдыр инде.

Ирек тә нәкъ шул хакта уйлап бара икән. Арыган, талчыккан йөзе агарып калган, һәрчак шат, елмаюлы чырае кырыс, ачулы, калын кара кашлары җыерылган.

— Әйтәсең бармы... — диде ул да, бер-ике колакка ятышсыз сүз кушып.

— Өч ел от и до намус белән хезмәт иткән кешегә өч көн яшәрлек тә акча бирмә инде! — диде Габделнур һәм дусты ишетерлек итеп кенә тагын сүгенде: — Сабирҗанның сырт сөяген сугып сындырыйм.

Ирек төрттереп алды:

— Малиновский биргән ун сумны әзерлек курсларына тапшырдың бит.

Габделнур көлеп җибәрде:

— Укыйсы да килә бит. Күбрәк бирсәләр, ни булган инде. Эчне төртеп тишмәс иде.

Егетләр тынып калдылар. Урамга карасаң — ачу килә, карамасаң — күрәсе килә. Ләкин яшьлек үзенекен итә. Егет кешегә күп кирәкме кәефен күтәрү өчен?! Трамвайдагы яшь, чибәр кызларга да күз төшә, әле килеп кенә урнашкан зур шәһәрне дә күздән кичерү теләге зур. Өч айлап бу шәһәрдә булсалар да, аларның маршрут чикләнгән иде бит: казарма, мунча, җәйге лагерь, казарма...

Кайтып аудылар. Яттылар гына кебек, тагын торырга кирәк. Йоклаган сымак та булмадылар.

Ирек, көйләп:

— ...Тәмле йокылар йокладым сабый чакларда гына, — дип киерелеп алды. — Их, тагын бер алты йөз минут кына черем итеп алырга.

Гәүдәнең һәр буыны сызлый, авырта, тән каткан. Җиңелчә физзарядка ясап алгач, хәл керде тагы үзләренә: изелгән-сытылган тәннәре язылды, күзләре ачылды. Урын-җир җыештырдылар, юынып-кырынып адәм кыяфәтенә керделәр. Кичәге «сукмак» белән янә вагон бушатырга юнәлделәр.

Яңгыр сибәләп торуга карамастан, иртәдән кичкә хәтле эт булып арыганчы эшләделәр. Ял көне — исәп-хисап ясаучы булмады. Исем-фамилияләрен, башкарган эшләрен генә язып калдылар. Тиярен атна уртасында килеп алырга куштылар.

Тагын җәһәннәм читендәге тулай торакка кайтып, сиртмәле тимер караватның ак җәймәле матрасына аудылар. Чөнки иртәгә — тугызынчы ноябрьдә — икесе ике төзү идарәсенә — инде чын эшкә барасылары бар.

**48**

Габделнур Галләмович фатирының тимер ишеген, бик анасы җыламый, дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, ике инглиз йозагы белән бикләде. Гомуми коридорның да ишеге тимер, ләкин өске өлеше рәшәткәле (килеп кыңгырау биргән кешене эчке яктан күрү өчен) һәм биге бер генә. Кергән-чыккан саен Габделнур Галләмовичның теленә шигырь юллары килә һәм, берүзе генә булса, ул аны кычкырып ук әйтә:

— Сижу за решеткой, в темнице сырой...

Бу йозак заводта махсус ясатылган, каләм озынлыгы ачкычы яссы, кыйгач сырлы, каттагы гаилә әгъзаларының һәрберсендә бар. Ачкычларын кесәсенә салгач, Габделнур Галләмович дивардагы кара кнопкага басты. Лифт тавыш биргәләгәнче, пыяла ишекне ачып, чүп-чар төшерә торган торба тирәсен, бомжлар һәм яшь-җилкенчәк юкмы дип, күздән кичерде. Үзләре юк, әмма эзләре калган: сырадан бушаган калай банкалар, презерватив, ак төстәге пластмасса шприцлар аунап ята. Габделнур Галләмович башын чайкап куйды. Ул арада лифтка җан кергәне ишетелде. Күчәренә күптән дегет тимәгән чытыр арба тавышлары чыгарып, шыгырдый-шыгырдый лифт менде, ишеге ачылды. Габделнур Галләмович кереп басты. Аста подъездның тышкы тимер ишеген шапылдатып япты да, баскычтан төшеп, ишегалдына чыкты.

Чүп савытлары янында өч кыз бала тора. Икесе үткән-сүткәннәргә арка белән баскан. Алар каршындагысы нәзек бармаклары арасына кыстырган озын папироска имән бармагы белән чирткәләп көлен коя. Арт белән торучыларның берсе черт итеп читкә төкерде, икенчесе башын чөеп төтен өрде.

Габделнур Галләмович түзмәде, аларга карамыйча гына, ләкин ишеттерерлек итеп:

— Минздрав кисәтә, — дип, яннарыннан узып китте.

Шәһәр моннан бер сәгать элек ничек булса, нәкъ шул хәлдә: сулышка каба торган эссе һава, ыгы-зыгы, тынчу, тузан, бер-беренә теләр-теләмәс кенә юл сабучы машиналар һәм җәяүлеләр, унары берьюлы җылы асфальтта мәлҗерәп, озын телләрен салындырып әлсерәп ятучы этләр...

Ул, тәртипкә өйрәнгән һәм кануннарга буйсынып аларны төгәл үтәүче кеше буларак, эшенә соңга калмас өчен, трамвай белән барасы итте. Арткы ишектән кереп алга узды, ләкин утырмады. Салонда халык чуар: әбибабайлар тыныч кына гәпләшә; уйчан карашлы эш кешеләре тавыш-тынсыз гына утыра; юлаучылар, зур сумкаларын аяк тирәсенә куеп, куллары белән аларга ябышып, ят шәһәргә алан-йолан карангалап баралар; кыз-

кыркын чыркылдаша; керлэнеп каткан киемле, күз төплэре күгэргэн шешенке йөзле, тарак күрмэгэн тузгак чэчле бер бомж җэрэхэтле кулы белэн стойкагаябышкан; арткы ишек каршында ике яшүсмер кычкырып-кычкырып сөйлэшэ һэм үз сүзлэреннэн үзлэре тэм табып көлешэ.

Габделнур Галлэмович, беренче мэртэбэ күргэндэй, шэһэр карап барды: башкала матурая, йортлары югары үрмэли, машиналары күбэя... Кибет тэрэзэлэренең генэ түгел, кеше яши торган йортларның да беренче каттагы тэрэзэлэре челтэрле-рэшэткэле, дөрес, төрмэнеке сыман бармак юанлыгы арматураны аркылы-торкылы куеп эретеп ябыштырылмаган, э күбесе сэнгать эсэре дэрэҗэсенэ җиткерергэ тырышып сырлы-бизэкле итеп эшлэнгэн. Лэкин аларның вазифасы, асылы шул ук калган: кэкре куллы бэндэлэрдэн милекне, мал-мөлкэтне саклау...

Габделнур Галлэмович үзенең бала чагын, йозаксыз ишеклэрне күз алдына китерэ: кеше өенэ рөхсэтсез керү, өй басу дигэнне белми иде авыл халкы. Ул, кайда гына булса да (соңгы вакытта бигрэк тэ), һэрнэрсэне, эш-гамэллэрне, кешелэрне Туган Йорт белэн чагыштыра, янэшэ куеп карый. Ни аяныч, гел авылы файдасына була чагыштыру. Шундый чакларда ул бүгенге көн өчен борчыла, йөрэге сыкрап-сыкрап куя, аннан ирексездэн күңелендэ моң уяна, сагыш ярала, уйларына җыр килеп кушыла: «Туган илне чыккач та ла бастым кара җирлэргэ; сагыну түгел, саргайдым мин, кайталмадым иллэргэ».

Икенче тукталыш. Алдан берничэ пассажир төшкэн арада арткы ишектэн биш-алты үсмер атылып килеп керделэр дэ, берни абайламый калган теге ике яшүсмерне кыска арматура кисэклэре белэн җэһэт-җэһэт бэргэлэп, кергэндэге җитезлек белэн трамвайдан атылып чыгып та киттелэр, һэм тимерлэрен яшерэ-яшерэ як-якка таралыштылар...

Трамвай эче аһ-ваһ килүче эби-чэбилэр тавышы, кызлар чырылдавы, кара канга баткан үсмерлэрнең ыңгырашу авазлары белэн тулды. Трамвай йөртүче сүгенэ-сүгенэ «бахбае»н алга куды. Күрэсең, мондый галэмэтнең шаһиты булуы беренче мэртэбэ генэ түгел.

...Габделнур Галлэмович эшенэ килде. Берничэ санлы кодны җыеп, тимер ишекне этэрде, эчкэ үтте, бүлмэсен ачып керде. Бер тэрэзэне каерып ачып куйды. Почта тартмасыннан газеталар алган иде, шуларны дипломатыннан чыгарды, утырып актара башлады. Берсендэ тагын яшьлэр төркемнэренэ кагылышлы мэкалэгэ юлыкты. Аны читкэ алып куйды. Икенчесенэ күз салды. Анда да күзен иркэлэрдэй, күңеленэ хуш килердэй язмалар тапмады. «Кая бара бу дөнья?» — дип, авыр сулап куйды. Гэзитэнең ахыргы битен ачты, спорт темасына язылган кыска-кыска материалларны укырга кереште. Бераздан, сэгатенэ карап алгач, газеталарын җыештырып, өстэлен тэртипкэ китереп, җиң сызганып дигэндэй, казна эшенэ чумды.

Беренче кисэк тэмам.

*2005*

Литературно-художественное издание

Рафкат Карами
(Карамиев Рафкат Карамиевич)

УХАБИСТАЯ ДОРОГА

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Әдэби-нэфис басма

Рэфкать Кэрами
(Кэрамиев Рэфкать Кэраметдин улы)

ОЛЫ ЮЛ ДА СИКЭЛТЭЛЕ

Мөхэррире *И.Г.Ногманов*
Рэссамы һэм бизэлеш мөхэррире *Р.Х.Хэсэншин*
Техник мөхэррире һэм компьютерда биткэ салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Р.Н.Шакирова, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.07.2007. Форматы 84x108$^{1}/_{32}$. Офсет кэгазе.
«Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,32. Шартлы буяу-оттиск 19,74.
Нэшер-хисап табагы 21,56. Тиражы 3000 д. Заказ С-738.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/    E-mail: info@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.